Камил Кәримов

# САКАУ КҮКЕ

*Роман һәм повесть*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат-44
К 95

**Кәримов Камил**

Сакау күке: Роман, повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 303 б.

Танылган язучы Камил Кәримовның «Сакау күке» романы укучылар өчен таныш булган «Ком сәгате» дилогиясенең икенче кисәге. Әлеге китапта авторның шактый ук үзенчәлекле «Ак бүрек» повесте дә урын алган.

ISBN 5-298-01445-3
© Татарстан китап нәшрияты, 2005

# САКАУ КҮКЕ

*(Роман)*

## I. ФАЗЫЛ

### Түгәрәклә дә аягыңны суз

Елларның көе китте...

Табигать фасыллары буталды... Җәй уртасында кар ява, яңа ел төнендә түбәләрдән тамчы тама. Кышны яздан эзлибез, ярты ел буена көздән котыла алмыйбыз. Кара каргалар җылы якка китмәскә өйрәнде, ә сайрар кошларның күбесе никтер кире кайтмый.

Бала-чагада — өлкәннәр уены, картларда — бала-чага акылы, ирләрдә — малайлар шөгыле.

Шөкер, тормыш дәвам итә үзе.

Хөррият яулаган кырларыбыз сатып бетерә алмаслык уңыш китерә, йокымсырап аккан чишмәләребез сөттән кыйммәт су бирә... Нинди генә кырыс һәм кискен үзгәрешләр кичерсә дә, кеше өчен ашауэчү, киенү, күңел ачу кебек көндәлек мәшәкатьләр барыбер яшәешнең төп асылы булып кала...

Табигатьтән күрмеш — кешеләрнең дә көе китте...

* * *

Фазылның алҗыган чыраена озак кына текәлеп карап торгач, неврология бүлеге мөдире үз бүлмәсендә бик сирәк яңгырый торган сөйләшүгә күчте.

— Туганнарың бармы?

— Шушы яшькә җиткәч, мин ятим, дип, мескенләнеп утырасым килми.

— Зарлануга, ыңгырашуларга ияләшкән халык без. Елап кызгандырсаң да, сүз әйтмәм. Күз яшьләренең дә файдасы тия — организмны чистарта, сызлауны баса.

— Авыртуларга түзәм мин, Генадий Иваныч, сагынып еласам гына инде...

— Ә сагынырдай кешеләрең бармы?

Бар, әлбәттә... Ләкин Фазыл әлеге сорауга иңбашын сикертеп кенә җавап бирде. Әгәр, кадерле вакытын кызганмыйча, туганнар хакында сораштыра башлаган икән, димәк, ул кызлар турында сөйләшергә дип чакырмагандыр.

Мөдирнең тел очындагы хөкем карарын алдан ук белә иде, ахрысы, каршыдагы ак өстәл артында ак елъязмачы булып утырган шәфкать туташы әңгәмәне бераз сузарга теләде.

— Кырык көн эчендә Шәмсетдинов янына беркем дә килмәде. Гаилә менә шушындый көннәргә калгач кирәк ул. Буйдак килеш нужадан качып йөрүләре рәхәттер дә...

Аңлый алмый боларны бүген Фазыл, айдан артык дәваланып, инде туганыңа әверелеп беткән мөдир дә, янына килүеннән үк хәлләреңне җиңеләйтә алырлык елмаюга юмарт шәфкатьле туташ та кырысланган. Карашларында ягымлылык юк, эндәшүләре өшетә.

Мөдир, үзе язганнарны үзе танымагандай, Фазылның авыру тарихын җентекләп укырга кереште. Ә тегесе журнал битенә кыстырылган буш рецепт кәгазенә, кара пастаны кызганмыйча, ясле баласыдай рәсем сызгалый — сөзәк түбәле озын өе тәрәзәсез-ишексез, читтән карап торган кешегә табутны хәтерләтә иде. Почмагындагы чытырманы да каендыр кебек.

— Туганнарың булмагач, туп-туры үзеңә әйтергә туры килә...

Әгәр бу сүзләрне сау-сәламәт кеше өстенә шушылай кинәт әйтсәң — йөрәге ярылыр иде... Ләкин соңгы ике айда сызланудан котыла алмаган Фазыл тән газапларының ахыр чиктә җүнлегә илтмәслеген белә иде. Шуңадырмы бер мәлгә сызлауларны оетып торган әлеге хәбәрне ул тыныч кабул итте.

— Ниһаять, котылам икән бу чирдән!

Мөдир аның гамьсез кыйлануын әллә ошатты, вакыт кысанлыгына ишарәләп кул сәгатенә күз салгач, әңгәмәне ашыктырды.

— Без өч атнадан ары асрамыйбыз. Гел бер үк кешеләрне генә көйләп ятсак, калган авыруларны кем карар?! Сине, әле дә инде чамадан тыш артык иркәләп, алты атна буе дәваладык. Ләкин сукыр бер тиенлек тә алга китеш юк.

— Әйе шул, алга-артка китмәдем, гел бер килеш...

— Безнең телдә ул чирне вакытлыча туктатып тору, дип атала. Син хәзер даруларга ияләштең, алга таба дәвалауның мәгънәсе юк.

— Алайса, әҗәлне тоткарлап торырга була әле?

— Әгәр врачлар кулында үләргә теләсәң, үзең яшәгән тирәдә яңадан кереп ята аласың. Безгә бит сине «скорый» белән китерделәр. Ул көнне шәһәр буенча кизү тора идек. Күрәсеңме, син хәтта безнең уникенче өчен бөтенләй чит пациент әле!

— Генадий Иваныч, бил авыртудан да үләләр микән?

— Синдә Бехтерев авыруы.

— Сез бит мине, радикулитның азынган төре дип, люмбагодан дәваладыгыз!

— Гадәттә, ревматик чирләрнең бөтенесе дә бер төрлерәк дәвалана, дарулары да шул ук. Ләкин Бехтерев авыруы — котылгысыз, җүнләп өйрәнелмәгән әле. Ул билдәге сеңерләрне ташка әйләндерә.

— Үз хәлемне аңлыйм, кызганмагыз, турысын әйтегез, минем тагын ничә көн яшисем калды?

Туташ кулындагы рәсем бу бүлмәдә бердәнбер кара җисем иде. Ул аны бөгәрләп чүп кәрҗиненә ыргыткач, Фазыл котылгысыз һәм шомлы аклык әсирлегендә калды. Геннадий Иванович Кукушкин җавапны сузды. Пеләшен каплар өчен генә киелгән ак калфагын салып атты. Һәр минуты яшәү булып яңгыраячак көннәрне күңеленнән генә бармак белән санап, ул шушы мәлдә бик юмарт холыклы табиб кыяфәтендә күренергә теләде. Әйтерсең лә Фазыл исемле табигать баласының йөрәге аның учында, теләсә — ул аны бүген үк туктата ала, теләсә — иртәгесе көнгә чаклы күтәргә риза...

— Күңелеңә авыр алма, күп дигәндә бер ай гомерең бар. Вакытыңны әрәм итмә, тизрәк кайт син, эшләреңне түгәрәклә!

Бик аңлаешлы итеп әйтте мөдир: «Түгәрәклә дә — аягыңны суз!» Васыятеңне яз да Самосырово зиратында экскаватор казыган озын канаудан сыңар ләхетлек урын бүлеп ал, ягъни мәсәлән...

Яшел вагонның аскы сәкеләрендә гел урын җәелгән килеш. Бил сызлавы көчәйгәндә, Фазыл берсеннән икенчесенә күчеп ятты. Урын алмаштырып, матрас салкынына җилкә тидергәч, умыртка сөягенә сызлый торган теш сыман кереп кадалган чир юашлангандай итә...

Менә нинди икәнсең син ялгызлык!..

Сау-сәламәт чакта кешесез вагон эчендә берүзең аунап ятулары — ял итү булган ул! Әҗәлне көтеп чарасыз калуны белмәгән, тәнеңне оя иткән сызлауга сүгенмәгән, кулга эләккән нәрсәне стенага атып, тынлык белән сугышуларны кичермәгән кеше мин ялгыз, дияргә ашыкмасын икән...

Менә, ичмасам, Фазыл хәзер уйлар эчендә япа-ялгызы. Бүләк ителгән гомернең тагын ун көне үтеп китте. Егерме көннән килеп җитәсе булгач, Әҗәл юлга чыккандыр инде. Ә бүген нинди көн? Сәгать ничә соң? Фазыл вакыт агышын якты көннәр саны белән чамалый. Таң аткан саен, өстәлдәге будильникны гадәт буенча гына бора, анысы да яткан килеш кенә йөри ала, бастырып куйсаң, тына. Бик күптән дөресләгәне юк инде аны. Мөгаен, ул хәзер, Мәскәү вакытыннан тайпылып, вагон вакыты белән яшәүгә күчкәндер.

Геннадий Иванович Кукушкин җирдәге мәшәкатьләрне тизрәк түгәрәкләргә кушты. Илле ел буе чәчелеп килгән язмышны мөдир биргән вакыт эчендә генә ничек түгәрәкләп өлгерәсең ди?!

Җәйнең үсмер чагы.

Аркылы-торкылы искән җилләр кардан котылган болытларны арлы-бирле иләп йөртә. Өйрәнчек яңгыр вагон түбәсенә учлап-учлап сибәләгән була. Шундук кояш, күренеп, ул тамчыларны киптереп тә куя.

Фазылның әле моңарчы яңа җәйне сәгатьләп саный-саный каршы алганы юк иде. Бактың исә, аның тагын егерме көнлек кенә җәе калган. Шул җәйне бер генә көнгә озынайтыр өчен, хәсрәт диңгезенә батмыйча, кечкенә генә салам кисәгенә тотынып калырга да риза ул хәзер. Егерме көнлек өмете кая ябышырга белми. Ә бар бит ябышыр нәрсә! Бала чакта чегән хатыны әйткән юрамыш бар...

Әнисе, колхоз эшенә киткәндә, өйдә үзе генә калган Фазылга ут-күз белән уйнама, өйгә бала-чага җыеп ятма, каз бәбкәләренә күз-колак булырга онытма, урамда чегәннәр олавы күренсә, тизрәк капканы эчтән бикләп куй, дип, көндәлек нәсыйхәтләрен әйтеп калдыра торган иде.

Көн саен бер үк сүзне ишетә торгач, әниләрнең «чегәннәр балаларны урлый» дигән янаву әкият сыманрак кабул ителә. Шуңа күрәдерме авыл уртасына килеп кергән чегәннәр олавын сизмичәрәк калды Фазыл. Ә авыл уртасында ачык ишегалдылы йортларның берсе шушы... Җәйге каникулның җылысын сизмәгәндәй, чәчәкле-чуклы шәлләргә кат-кат уралган чегән хатыны Фазылларның ишегалдына бала күтәреп керде. Урланган балага һич охшамаган иде ул. Шулай ук чәчәкле-чуклы шәлләргә урасаң — койган да куйган әнисе инде! Әнисенең каратутлы йөзе дегете юылып бетмәгән трактористлар чырае шикелле, колакларында беләзек шәе симез алкалар. Клубка җыенган апалар кебек маңгай чәчен көдрәләткән, шома итеп артка таралган өлеше кипкән сумаладай кара-кучкылланып елкылдый. Ул ян тәрәзәдән куркынып карап торган Фазылны ишегалдына чакырып чыгарды. Теләмәсә дә, никтер карышмыйча чыкты Фазыл, баскыч төбендә тораташ булып оеп тора.

— Әниең өйдәме?

— Эштә.

— Әтиең өйдәме?

— Сугыштан кайтып үлде. Бүтән әтиебез юк.

Чегән хатыны белән җиңел сөйләште — русчаны шәп сукалый Фазыл. Мәктәпкә кергәнче үк ул инде берничә тапкыр Питрәч бүлнисендә ятып чыккан иде. Аның күзенә кан сава. Әбиләр бу хастаны «елан карагы» дип атадылар, фельдшер Мәүлидә апа «золотуха» диде. Район табиблары «скрофулез» дип дәваладылар. Кешенең канында кирәкле витаминнары бетеп, бәрәңге белән кысыр ашы күбәйгәндә яңара икән әлеге чир. Питрәч ул елларда урыс бистәсе иде, аралашу гына түгел, хәтта дәвалау һәм аша-

ту кебек көндәлек мәшәкатьләр дә урысча бара торган иде. Фазыл Питрәч телен хәйран өйрәнеп кайтты.

— Әниеңнең чәчкә тагып йөри торган көмеш тәңкәләре бармы? — дип сораганда, чегән хатынының баласы, беләгеннән ычкынып, җилкәсенә таба үрмәләп китте.

— Саба көмешчеләре ташып бетерделәр. Соңгыларын кичә җыеп чыктылар, илле тиенлекләре дә, бөтен тәңкәләребез дә барые. Акчабыз юк, әни хезмәт көненә эшли, көз көне ипи бирәчәкләр, — дип тезеп китте Фазыл, чегәннәргә ни кирәген аңлап...

— Ярар, ышанам. Суыгыз бармы хет?

— Бер чиләк кенә.

— Миңа бер чүмеч тә җитә. Алып чык!

Җәһәт кереп китсә дә, Фазыл эленгән кадактан чүмеч сабын ычкындыра алмыйча чиләнде. Чегән каршына чыгып басканда, чүмечтәге су җил бәрелгән күл өсте шикелле дулкынланып торды. Тегесе суга төртелде, әмма эчкән атлы кыланды гына, чүмечне ишегалдына бушатып кире бирде.

— Суыгыз җылынган.

— Кичәге инде ул. Әни чишмә башына эштән соң йөри.

— Сезнең тавыкларыгыз күп, — диде ул, ташкабак сыярдай авызын чөгендер телеме шикелле түгәрәкләп.

— Тавык җидәү генә безнең. Икесе кыртлый. Берсе бәрәңге буразнасында качып чеби чыгара. Дүртесе көнаралаш сала. Бүген ял итәләр.

— Беләм. Оягызда кичәгедән калган өч йомырка бар. Алып төш шуларны.

Сарай өстендәге тавык йонына баткан кәрҗин эченә үрелсә, ни күрсен Фазыл — чынлап та, ояда нәкъ өч йомырка, берсе әле суынып өлгермәгән. «Вәт калдун бу чегән!» дип тел шартлатканын ишеткәндер әле.

Алъяпкыч итеп бәйләнгән капчык кесәгә өч йомырканы тәгәрәткәч, чегән хатыны Фазылның уң кулын үзенең учына алды.

— Йомыркаларыгыз кара черек, мин ул бозыкларны кырга чыгарып ташлыйм. Ә тәмле суың өчен рәхмәт... Хәтерләп кал... Үскәч, акча күп эшләрсең, ну бай булалмассың. Сиңа дигән хатын тагын ун елдан соң туачак. Улыңны кеше үстерер, кызың үз кулыңда үсәр. Туксан алты яшькәчә яшәрсең... Хәтерләп калдыңмы?

— Юк, катлаулы итеп әйтәсең.

Чегән хатыны, әйтелгәннәрне тагын бер кат кабатлагач, кырт борылып чыгып китте. Фазылның кулы һавада эленеп калды. Чатырлы олау өй түреннән югалгач, ниһаять, аңына килеп, ул тизрәк капканы терәтеп куйды. Маңгаеннан бәреп чыккан салкын тирне сөрткәндә, аның кулыннан учак төтене исе килә иде.

Ун яшьлек малайга өлкәннәр хыялланырдай киләчәк вәгъдә итү нигә кирәк булгандыр, монысына Фазыл әле дә булса төшенә алмый.

Хасталанган кешенең күңеле китек, шуңа күрәме ул дингә ныграк табына, җенгә ышана, ырымюрауларга сизгер була, күргән төшләреннән чынбарлыкны эзли, очраклы бәхетнең күктән ишелеп төшәсенә өмет саклый. Ялгызлыкның язылмаган формуласы бу. Фазыл сызланулы минутларда, чегән хатыны тудырган күрәзәне дога урынына кабатлап, рухын канатландыра, чатыр әүлиясы санаган гомернең икенче яртысын кичә.

## Чалбарсыз бабай

Шунсы сәер, малай чакта уеннар гел хәвеф тирәсендә була. Көн үткәнче син әллә ничә тапкыр яшәү белән үлем арасында каласың. Ләкин син әле ул вакытта Әҗәлнең барлыгына ышанмыйсың, күзгә-күз очрашсаң да танымыйсың. Шуңа күрә дә үҗәтләнеп үсәсең.

Ир кеше әкрен үсә ул...

Ир бала егет булып аягына басканчы, җүнле сыер унҗиде бозау үстерә. Бозау, дөньяга килү белән, әнисенең җиленен үзе эзли башлый, әнә шул тамак ихтыяҗы яңа туган җан иясен ярты сәгать эчендә аякка басарга мәҗбүр итә — дүрт аягына басмаса, ачтан үләчәк ул. Ак биләүгә төреп, тал бишектә тибрәтеп, чәйнәп биреп суырткыч каптырсаң, кулдан-кулга йөртеп назласаң — бәлки, бозаулар да аякка басарга ашыкмас иде.

Кеше табигатьнең иң иркә җан иясе.

Бишек җырлары җырланып беткәч, ул әнисенең алдыннан төшә. Лепкәсе ныгыгач — урамга чыгарга ишек эзли башлый. Яшьтәшләренең чыр-чулы тавышын ишетеп, су буена килә. Теле белән сөйдереп, һөнәрләре артып, күрше-тирәдәгеләрнең соклануын җәлеп итә башлагач, Лаеш ягыннан биштәрле бабай килә дә малайларның уенын берәр атнага туктатып тора.

Бабай килер алдыннан өйдәгеләрнең телендә гел сөннәтне мактау: «Зур егет инде син, су коенганда «урыс малае» дип көлмәсләр, менәтерәк чистарып каласың...» Өлкәннәр сүзенә ияләнеп, үзең дә бабайны көтеп йөрисең, сиңа үсәргә комачаулаган нәрсәдән тизрәк котыласың килә.

Бабайның исемлеге бар, кемнең ничә яшьлек малай үстергәнен алдан ук белеп тора, шуңа күрә аны эзләп яисә ияртеп кайтасы юк, ул үзе килеп керә. Иске чалбарыңны салып урын өстенә ятарга куша. Яңасын тегеп алып киләм, дип, үлчәм алырга тотына. Яңа чалбар кигәндә комачаулыйсы әйбереңне үртәштергән арада, «чебен» тешләп ала. Еларга ярамый, юкса бабай син елакны башка малайларга сөйли.

Фазылҗан ятып калды. Җәрәхәткә чебен кунмасын дип, бил түбәнтен ак марлядан чыбылдык элделәр. Динә ул көнне колхоз эшенә чыкмады. Тәрәзәдән карап улын юата: «Әнә, Мәгъсүмне дә егет иттеләр. Мәрьямниса апаң да Мөдәррисне эзләп йөри, бүген таба алмаса, тагын бер ел әрәм үтә, Мөдәррис аңынчы сезнең арада урыс булып йөрер микәнни?..»

Фазылҗанның хәлен белергә дип, Фәризә җиңгәсе керде, буш кул белән түгел, кала күмәче тоткан. Хәер, кергән бер кеше күчтәнәчсез йөрми, ике көн эчендә башлы шикәр, кызыл прәннек, кипкән хөрмә, хәлвәле конфетлар хәйран өелде инде.

Тәмле-томлы кимереп ятсаң, җәрәхәт тиз төзәлә икән. Бер атнадан Фазылҗанның хәле Пожарный буасына су коеныргa килгән сөннәттәшләренә мактанырлык иде инде.

Читтән генә Фазылҗаннар төркеменә кызыгып йөрүче өч малай бар. Казбек, Марсель һәм Митәйнең әти-әниләре таралып беткән урыс авылларыннан күчеп килгән. Гомер буе чеп-чи татар авылында яшәп, үз телләрен оныта язганнар. Каты авазларга артык басым ясамыйча, йомшак сөйләшүләре генә ул гаиләнең нәсел агачы читтә икәнлекне искәртеп тора. Ә Казбек, Марсель һәм Митәй — Шәлегә күчеп утыргач туган балалар, алар урысча бөтенләй белмиләр. Исемнәренә күрә, «керәшен» кушаматы тагып, җыр чыгардылар үзләренә:

Керәшен, керәшен,
Ник чиркәүгә керәсең?
Анда ниләр күрәсең —
Чыккач безгә сөйләрсең...

Җыр җавапсыз калмый:

Татар — үзенекенә батар,
Чыгалмыйча тик ятар!..

Кара-каршы әйтешеп башланган уен урам сугышына әверелә. Кыш көне булса — кардан окоп казып «ядрә атышу»; җәй җитүгә, тыкрыктагы юл тузанын кепкаларга тутырып «бомба ыргыту» башлана. Җәйме-кышмы ул — сугыш уеннары тансык, чөнки ахыры юл өстендә әүмәкләшеп җиңү белән бетә. Сугыш уенында җиңелгән «керәшеннәр», Фазылларны уздырыр өчен, яңа ярышлар уйлап таба. Суга чумсаң — алар төптә озаграк утырырлар; чаңгы шуганда, текә Ишем ярыннан алар гына сикерә ала; җиләк җыярга барсаң, тере еланны күлмәк эченә тыгып кайтырлар; шырпы мылтыгы корганда, дарыны Фазылларга караганда икеләтә күбрәк тутырырлар. Гарьлек ярышының хәвефләргә китергәнен балалык белән тоеп бетермисең...

Авылның инеше карурманнан килеп төшә. Гадәти көннәрдә ул иренеп кенә ага. Яшенле яңгырлар мул яуганда, биш чакрым буе ерганаклардагы гөрләвекләрне җыя торгач, бәләкәй инеш язгы ташкынга әверелә — юлында очраган чыбык күперләрне җимереп, бакча башына салынган мунчаларны агызып, Мишәгә алып китә. Дүрт субайга плөтән үреп кызыл балчык төелгән буа ташкын астында кала.

Яңгыр тынып, ташкынның әүхәте кимегәч, ялан тәпиле малай-шалай, соңгы гөрләвеккә ияреп, инешкә килә. Буа артында бусагаланып аккан су шарлавык ясый — ул лимонад фонтаны кебек күбекләнеп, кызыктырып үзенә тартып тора. Коры көннәрдә кендек күмелмәслек су, яңгырдан куәт алып, тирәнлек, маҗара, сер һәм яңалык булып килгән.

1964 елның июлендә, яшенле яңгыр үтеп киткәч, малайлар гадәттәгечә шарлавык төбен үлчәргә килделәр. Чоңгыл тирән иде — аяк очына бассаң, сузылган куллар күмелерлек. Су җылысына ияләнгәч, һәркемнең кыланасы, тамаша кыласы, ярышып мактанасы килә. Фазыл буа читендә картайганчы исән-имин үсә алган өч аерлы өянкегә менеп сикерде. Канат итеп җәелгән куллар су өстендә шапылдап тоткарлык ясый — аяклар су төбенә батып керми. Фазылдан соң әлеге сикерүне кабатлап чыктылар. Марсель үзенчә рекорд ясарга теләде: чираты җиткәч, ботакта талпынып торды да шарлавыкка башы белән чумды. Җирдәгеләр саный. Бер, ике, өч... биш... ун... Ну, малай, Марсель моряклар кебек су астында утызга хәтлек санаганчы тора ала... Утыз биш, утыз алты... кырык... илле биш... алтмыш ике... Санау өзелде. Яр өстеннән физкультура укытучысы узып бара иде.

— Рәкыйп абый! Марсель батты...

— Ул ташбаш батканчы әле...

— Җитмешкә хәтлек санадык инде, чыкмый.

— Сездән качып йөзеп киткәндер, яхшылабрак эзләгез!

Рәкыйп абый китте. Малайлар шомнан арына алмады. Чоңгылдан чыксаң, инеш йөзеп качардай түгел. Шарлавык төбен аулау китте. Чумып чыккан берсенең җавабы салкын: «Юк! Юк! Юк ул анда!» Ниһаять, Юныс чыкты: «Аягын таптым, тыным җитмәде. Хәзер алып чыгам». Һәм Юныс Марсельне аягыннан тартып алып чыкты. Сикергән хутка башы белән чоңгыл төбендәге ләмгә кадалган Марсель. Буа ярында ясалма сулыш алдырулар, авыл уртасындагы медпунктка алып баруларның ярдәме тимәде... Көнгә унбишәр, хәтта унҗидешәр тапкыр су коеныргa килә торган малайлар Пожарный буасын күралмас булдылар.

Митәй... шуклыкның чиген белмәде, утырып уйныйсы уеннарны тәгәрәп, биш адым атлыйсы җирне йөгереп үтә торган иде ул. Аларның тыкрыгы атлар фермасы юлы өстендә иде. Эштән кайткач тугарылган атларны капкадан чыгарып җибәрсәң, шул җитә — солының кайда икәнен беләләр тегеләр — «конюшныйга» үзләре теркелди... Митәй тыкрыкка хуҗа — өй турысына килеп җиткән атларны, йә таш атып, йә таяк күтәреп, фермага куалый. Менә бервакыт, тояк астында тузан шартлатып, Буян килә. Буян өч ел рәттән чабышта беренче килде, быел җыен алдыннан, кайсыдыр ки көнчесе аның койрыгын төбеннән үк кисеп алган, бәйрәмгә алып чыгарга хурлансыннар, дигәндер... Фазыллар җиңүче айгырга сокланып торган арада, Митәй инде каезланмаган тал чыбыгы белән койрыксыз Буянны куа китте. Өркетелгән ат кушаяклап йөгерергә тиеш иде. Нишләмәк кирәк, һәр малкайның үз холкы шул. Буян, көнозын камчылаудан туйган инде дигәндәй, ыргылудан кисәк тыелып калды. Гаярьлеген кая куярга белмичә, Митәйгә таба кырын-кырын биеп килде дә дагалы тоякларын уйнатып тибеп җибәрде. Митәй, тыны чыккан туп шикелле, шапылдап очып төште. Үз исемен ул ике-өч минуттан соң гына ишетә алды...

Җәйге каникулның бер аен караватта үткәреп урамга чыккач, Митәй бәрелеп-сугылып уйный торган уеннарда катнашмады. Онытылып йөгерсә, шундук чүгәләп, эчен тотып өнсез кала иде. Әлеге балалык шугы аны кырык яшендә гүр иясе итте. Митәйнең чын исеме Дмитрий икәнен кабер ташыннан укыгач кына белделәр.

Ә Казбек... үзенчә югалды.

Аны күргәч, кызларның чырык-чырык көлүе, малайларның су коенганда: «Нихәл, керәшен?» — дип үрелә-үрелә караулары көннәрдән бер көнне гарьләнүенең соңгы чигенә җиткерде. Һәм унҗиде яшьлек Казбек, Лаеш районына барып, бабайны үзе эзләп тапты... Армиядән соң ул авылга бөтенләй кайтмады. Сөннәтле керәшеннең бер марҗага өйләнүе билгеле, ләкин шуннан ары хәбәрнең дәвамы юк.

Шулай итеп, Фазыл язмышында кешеләр әкренләп әтиләр һәм ятимнәргә, мөлкәтлеләр һәм хәерчеләргә, сөннәтлеләр һәм кяферләргә бүленде. Ә теге бабай вәгъдә иткән яңа чалбар йола гамәленең матур ялганы булып калды. Үсеп кеше арасында эшли башлагач, Фазыл чалбарсыз бабайны канатлы сүз итеп кулланыр, эшләрбез, табарбыз, бирербез, булыр, ярар, дигән вәгъдәсезләрнең авызын томалар.

Килә бер көн, ир бала малай-шалай уеннарына кызыкмый, шырпы мылтыклары югала, тал ботагыннан бөгелгән җәяләр турая, уенчык машиналар ватылып бетә, җиңел сөякләр авырая, урамга яланаяк чыгу хурландыра, Пожарный буасы кечерәкләр кулына кала...

Урамнан почтальон үтеп китсә, хат көтәсең, өеңә күрше керсә, кемнәндер сөенечле хәбәр җиткерер кебек. Кич җиткәч, күңел оясына сыймый. Ыспайланып капка төбенә чыгып басасың. Чөнки клубка чыга торган чак. Ләкин сине беркем ияртми, син әле мәктәп баласы.

Митәйнең әтисе мәктәп интернатында тәрбияче булып эшли. Авыл советы аларга яз башыннан ук ике машина каен утыны китереп аудара. Каен утыны җәй буе кипсә, кыш көне җиңел ярыла. Митәйләр, каланча төбендә кәрт уйнаган мужикларны чакырып, чи бүрәнәләрне койма буена культуралы итеп өйдерәләр. Ишелмәсен өчен чәнти бармак юанлыгы шып белән урап боргычлап куялар. Шуннан соң малайлар көн саен кич, бүрәнә өстенә тезелешеп, утын киптерәләр. Фазыллар урамы — өлгереп пешкән кызларның клубка йөри торган олы юлы. Дөрес, бу урамнан яше җиткән егетләр дә уза, ләкин бүрәнә өстендә утыручылар өчен аларның поты бер тиен.

## Шулай башлана инде ул...

Кызлар үтеп киткәндә, малайлар, сүз куешкандай, сулыш алмаска тырышып тынсыз калалар. Урамы-урамы белән пардан киенүләрен күр! Каенлык очы кызлары барысы да ак җирлеккә кара түгәрәкләр төшкән «резидәкәй» күлмәктән. Артка җәеп бәйләнгән бүз яулыкның чигүле бизәкләре маңгай өстенә туры килер. Озын балтырлы гольфиклары акбур белән акшарланган чүәкләр эченнән үсеп чыккан кебек. Алар үтеп киткәндә, Фазыллар урамында хуш исләр эленеп кала. «Сирень», «Жасмин», «Красный мак», хәтта «Красная Москва» ислемайлары, бергә кушылып, утын киптерүчеләрне иләсләндерә, үсендерә, клубка чакыра.

Зур кызлар төркем-төркем йөри, билгеле инде, аларга берәр пионер яшеннән чыкмаган кыз ияргән булыр. Ике-өч тапкыр ияргән булырлар да аннан соң үзләре яңа төркем җыяр. Шулай башлана инде ул яшьлек дигәнең.

Апасы клуб урамында яшәгәч, Хәмдия утырмага еш килә. Кояш баеганчы апасы белән чәй эчәр. Ә саубуллашып чыккач, өенә түгел, зур кызларга ияреп, клубка китеп барыр. Чибәр кызлар тиз үсә инде ул... Бер көзтте моны Фазыл, ике сизде... Өченчесендә түзмәде — классташы Хәмдия артыннан клуб ишегалдына барып керде. Көндезләрен балалар киносы карарга күп килде ул монда. Ләкин кояш баеп, махсус ватылып беткән лампочкалар өчен күктә йолдызлар кабынгач, клуб тирәсе бөтенләй башка. Көн саен кич бәйрәм монда. Язга чыккач, биюләр гел урамда гына үтә.

Клуб мөдире Наилә апа алты йөз утыз кеше арасыннан Фазылны танып алды.

— Фазылҗан, әйдә, баянчыга урындык алып чыгыйк әле.

Алты йөз утыз кеше аны көтеп кала — ким дә түгел, артык та түгел. Нәкъ алты йөз утыз кеше! Санап торасы юк! Митәйнең әтисе әйтте моны: мәктәптә ничә бала укыса — клубка йөрүче яшьләрнең саны шуныңча, диде.

Клуб тәрәзәсеннән төшкән яктылыкка баянчы килеп утыргач, кычкырып сөйләшүләр, кирәксезгә бакырулар, урынсызга сызгырулар кими. Төркем-төркем кызлар, урамнарын сакларга тырышып кына, вальс көтәләр. Алай икән... Татцик кызлары косынка бәйләп, ак гольфы урынына эре челтәрле кара оек кигәннәр... Татцикның ярты халкы Казанда яши, ял көне җитте исә, берәр яңалык алып кайталар... Татцик кызлары быел кигәнне Шәле кызлары киләсе елга гына кия башлый әле...

Наилә апаның зурлавы Фазылны кеше күзенә чыгарды — тар балаклы яшел чалбарга озын җиңле ак нейлон күлмәк кыстырып кигән, йөзек кашы ябыштырылган кара галстуклы ике кала егете кул биреп күрештеләр:

— Нихәл, малай?!

Кала егетләре кул биргәч, авылнныкылар да санлый. Фазыл белән күрешү башланды. Кайсы кызык өчен, кайсы күңелен күрер өченгә, кемдер үртәү йөзеннән, тик нәтиҗәсе бер — кул биреп күрешәләр икән — димәк, син инде егет кеше! Шулай башлана инде ул.

Клубка быелларда гына йөри башлаган кыз-кыркын, тәрәзә яктысына кызыккан ут күбәләгедәй, баянчы янына елышкан. Яктылык килеп җитә алмастай читтә базар торырдай яшьтәгеләр. Ә инде кияүгә чыгу өметеннән ваз кичкән сазамыклар яктылык белән караңгылык кушылган якка карап лаф оралар.

Галстугына йөзек кашы ябыштырылган егетләрнең берсе Хәмдияне биленнән тотып алган. Вальс көенә салып тәрәз яктысыннан караңгыга таба бөтерә. Әйләнешкә керде кызый. Фазыл ише салагаларга кунак егетләр белән ярышу кыенга килер.

Шәһәргә китеп төпләнгән яшьләр атна уртасында кайта алмый. Танцы-мансылар ял көннәре генә үткәрелә. Башка вакытта клубта гел кино гына. Зурлар арасында буталып йөрмәсеннәр дип, балалар өчен көндез аерым күрсәтәләр. Биш тиенлек кенә үзе. Ләкин Фазылларга егерме тиенлек зурлар киносы кирәк. Көндезге сеансларда фильмнарның үбешә торган урыннарын төшереп калдыралар. Малайларның нәкъ әнә шул төшеп калган өзекләрне күрәсе килә. Егерме тиенлек кинода әтиле малайлар гына. Хәмдиянең дә әти-әнисе исән, ул балалар арасында йөрми.

Кунак егетләр кайтканчы кызны күрергә атлыгып тора Фазыл. Иртәгә һинд киносы кайта, дигән хәбәр белдерүдән алдан таралды. Өч сәгать буе Хәмдия янында утырасың килсә, керү хәйләсен табарга кирәк.

Уеннар беткәч, гармунчы урындыгын клуб мөдире бүлмәсенә илтешли, Фазыл Наилә апасына пышылдады:

— Иртәгә «Бродяга» кайтамыни?

— Әйе бугай. Индийский фильмнарның киләсен алдан әйтеп булмый ич. Иртән китерәләр, кичен алып китәләр. Башка киноларны өчәр көн яткыр — кинопрокат бер сүз әйтми... Нигә дип соравың әле? Сезгә кызлар кочаклап утырыр өчен нинди фильм куйсалар да барыбер түгелме?

— Ике серияледер инде ул...

— Әйе, журналы бардыр «фитиль» белән. — Һәм Наилә апа егетнең тел төбен сизеп алды, ахрысы, — ниме, Фазылҗан, син төшкә хәтлек сугыл әле клубка, каенлык очына белдерү ябыштырып килерсең. Аны Әнвәр ябыштыра торганые, Лаештагы консервы заводына киткән, ди. Бушлай кино карап туйгандыр. Лаеш шулпасын чөмерсен бераз.

Ни өчен Фазылга тапшырды соң әле Наилә апа бу эшне? Ятим баланы кызганыпмы? Юк. Авылдагы ятим балаларны саный китсәң — үзе бер клуб... Хикмәт шунда ки — Наилә апагызны Фазылның абыйсы озатып йөри. Булачак каенегә якты йөз күрсәтүе яратышып йөрүләренең нәтиҗәсе булса кирәк.

Фазыл Хәмдияләргә уртадан урын алып кала. Куанычын сиздерер өчен арткы рәттәге сөннәттәшләренә кычкырып сәлам бирә. Ут сүнеп, экранда Һинд күренә башлагач, ул, пешкән каен җиләгенә үрелгәндәй сабырсызланып, кызның кулын тота. Кинодагы мәхәббәт җырларын тыңлаганда, куллар кысылып тирләп чыга... Өч сәгать буе утырып Фазыл нибарысы өч сорау биреп өлгерә.

«Апаңнарда кунасыңмы әллә? Иртәгә клубка чыгасыңмы? Берәр фотоң юкмы, бир әле...»

Хәмдия, җавап бирүен башкаларга сиздермәс өчен, «Юк. Әйе. Ярар» дигәнне аңлатып ым кага.

Кызны озата кайта торган урам кыска, ә Фазылның җырлары озын. Атна тиз үтә, ял көннәре ялыктыргыч. Уеннарда Хәмдия аны бөтенләй күрмәмешкә сабыша. Авыл кызларына тагын кунак егетләр хуҗа булыр микән?..

Әгәр бу ялда галстуклы кунак егет тагын Хәмдиянең биленә килеп ябышса, Фазылның клубка чыгарлыгы калмый. Малайны чүлмәк ватканчы кыйнарга кирәк, дигән Хуҗа Насретдин, ваткач соң була.

Эңгер-меңгерне күтәрлек сабырлык юк. Капка баганасына кагылган колгада сыерчык сызгырына, «фи-фи-и-и!» ди ул, Фазылны үртәп... Әйе, кул кушырып утыра торган бала чагың үткән, әйдә, көрәшкә чык!

Яшь үләннән исерешеп кайткан мал-туарлар абзар тоткынлыгында тыпырдаша. Әниләре йоклата алмаган карга балаларын тирәк очындагы шәфәкъ нуры борчый. Мишә буеннан килгән җилләрдә шомырт чәчәге исе. Кыш буе шикәр ашап чыккан бал кортлары, кайтыр сәгатьләрен онытып, читән төбендәге тузганак чәркәләреннән комсызланып ширбәт чөмерә. Җәй хакимиятне үз кулына алмаган әле, калын киенсәң — эссе, күлмәкчән йөрсәң — салкынча...

Фазыл утлы күмер кебек чәчелгән тузганак чәчәкләре янында туктап калды, нindидер бер карарга килеп иелде һәм, озак уйлап тормастан, башы белән чәчәк тузанына чумган бер бал кортын, ике канатыннан тотып, уң кул сыртына утыртты. Монысының чагуын азсынып, тагын берне тотты... Клуб янына килеп җиткәнче, егетнең кулы ике корт агуыннан күзгә күренеп өрелде.

«Нихәл, малай?» дигәндә, Фазылның кабартма чаклы кулын тотып аһ! иттеләр, кайберәүләр хәтта ышанмыйча икешәр кат күреште әле. «Нишләде кулың?» дип йөдәткән саен аклана торсаң, кабартмаң шиңәр. Ул вакыт әрәм итмәде, корт чакмаган кулын кесә төбенә яшереп, туп-туры кунак егетләр янына юнәлде. Килә-килешкә үк галстуклысына кул сузды:

— Нихәл, мине сагынып кайттыңмы?

Бу чаклы әрсез шаяртудан шаркылдап көләргә тиешле кунак, гаҗәпләнүеннән чайкалып, артка түнде, күз карашлары ирексездән корт чаккан йодрыкларга иярде.

— Кул кычытып тора бүген, — дип өстәде Фазыл һәм, бәләкәй гәүдәсен эре тотып, Наилә апаның сөйгән егете янына, әйе, абыйсы янына килеп басты. Күрсеннәр, ул ялгыз түгел! Абыйсының минем тирәдә бик балкыма әле, дип әйтәсен белә, шуңа күрә, куганны көтмичә, симез йодрыгын уйнатып, сөннәттәшләре ягына күчте. Үзе кырын күз белән генә Хәмдияне күзәтте — янында шәһәрнекеләр күренми... Ул көнне кыз озатылмады һәм гарьлегеннән атна буе клубка чыкмады.

## Низам тавык түгел...

Һәр авыл үзенә күрә бер кечкенә дәүләт ул... Аның патшасы — колхоз рәисе, баш вәзире — партоешма секретаре. Идарә әгъзалары үзләрен, һичшиксез, сенат дип исәпләр. Конторда эшләүчеләр авылда министрдан ким яшәмәс. Бригадирлар — урядник, авыл советы рәисе — староста, участок милиционеры — пристав.

Патша сараеның матбугат органы эшләп килә — бәйрәм саен конторда, мәктәптә, савымчылар йортында һәм автопаркта даими рәвештә стена газеталары чыга, кимчелекләрне читкә түкмичә генә колхоз радиочелтәре эшли. Авыл «корылтаенда» чәчрәп сөйли торган сәясәтчеләр бар. Патшаның коллары арасында батырлар, куркаклар, алдынгылар һәм ялкаулар да җитәрлек. Күрше патшалыктан кунаклар килсә, аларны шамакайлар каршы алыр.

Кыскасы, һәр дәүләтнең ким дигәндә бер җүләре булыр...

Зуррак авылларда икәү дә әле ул.

Низам егетләр кулыннан утлы төпчек җыеп йөри. Төпчекләр кыска, ике суырдың исә — янып бетә. Шуңа күрә Низам аларны, бармак араларына кыстырып, җиде-сигезне берьюлы тотып тора. Клуб тирәсенең лампочкалары сүнгән эңгер-меңгерендә Низам кушучлап утлы күмер тотып йөргән күз буучыны хәтерләтә.

Ул үзен белә башлаганнан бирле абыйсы белән җиңгәсе кулында яши. Әтисе сугыштан кайтмаган. Ике бала тотып калган әниләре черек бәрәңге җыярга чыккан җиреннән карлы балчыкта аягына салкын тидереп шешенеп үлгән. Низам абыйсы белән өй борынча йөреп көн күрә. Ләкин ничек кенә кыен булса да, хәер сорашып авылдан ары китми, чөнки мул хәер өметләнеп авылдан капчык асып чыгып киткән ятимнәрнең күбесе кире әйләнеп кайтмады; кемдер адашып үлгән, кем тифтан җан тәслим кылган, кайберләре исә, өтермәгә эләгеп, өйгә кайту юлын бөтенләйгә югалткан. Сигез яшькә олы булгач, абыйсы сугыштан соңгы елларда өйләнерлек егет иде һәм үзе кебек бер ятимә кызны ризалаштырып иске нигезгә алып та кайтты. Ятимә кыз абыйсына хатын, Низамга исә җиңги, апа һәм үги ана булды. Низам өйләнеп башка чыгар, өйдә зур кашык бушар дип күпме генә көтсәләр дә, өметләре акланмады. Низамга инде утыз тулып килә... Өч кешелек гаиләдә берүзе яши, ике кешелек ашый, өч кешелек эшли. Клубка көн саен төшә үзе... Кызлар аны якын китерми. Өсте-өстенә кигән кепкаларының ике катлы козырегын, кечкенә буйлы абыйсыннан калган кәчтүннең кыска җиңнәрен, каеш урынына чалбар билдәмәсенә уралган бичәүкәсен, түбә буявы белән тигезләп капланган кызгылт ботинкаларын күргәч, көлми

нишләсеннәр инде... Низамның кушаматы юк. Ул үзе кушамат. «Син Низам мәллә?!» дип өстеңә әйтсәләр, кылган җүләрлегеңне аңла шуннан. Малайларга Низам дигән исем кушу бетте.

Акылдан шашмаган ул, җүләр генә. Колхоз акча биргәч, кибет тирәсенә җыелган дивана, тинтәк, ахмак, котырган ирләрне күрсәгез сез — Низам ул көнне авылның иң акыллысы, сабыр, тәүфыйклы баласы булып кала. Низамның холкы гел бертөрле — дуамалланмый, кызмый, сүгенми, рәнҗетми, бары тик чамасыз беркатлы гына. Кичерегез, беркатлы кеше, дип, безнең якларда тиз ышанучан самимиләргә әйтәләр. Расланмаган хәбәрләргә, ялган идеалларга, буш вәгъдәләр һәм су кушылган җиңүләргә ышанып яшибез ич әле... Димәк, җәмгыятебезнең горизонталь баскычында яшәүчеләр — һәммәбез дә Низам кебекләр икәнбез. Хәер, сүз безнең турыда түгел...

Күз алдыгызга китереп карагыз: Алып, Салсал, Турайларның өчесен бил алышка чакырырлык гәүдәсе белән Низам күн итек буе малайлардан өркеп яши.

Зират тавыннан хутлы төшеп, кибет күперенә кинәт борылганда, Юаш Нотфулланың бәрән себеркесе төялгән арбасы кендегеннән ычкынды. Низамның клубка килеше иде. Нотфулла җөмлә араларына нокта куймыйча гына тоташтан шундый озын итеп сүгенде ки, алгы күчәрле тәртәне элдереп качкан атны йөк янына куып алып килгәндә дә әйтер сүзләре бетмәгән иде әле. Ник дисәң, әлеге күпер авылның кыл уртасында, кичке тынгысыз халык, кая бармасын, гел шушыннан үтә. Ат биеклеге өеп төягән себеркеләр тавыклар фермасы өчен кышка әзерләнгән яшел витамин запасыннан иде. Өйгә алып кайтканыңны күреп, идарәгә барып чаксалар, кәефне бозачаклар. Дөрес, Сакал Шәйхи үз кеше, кырыс указлар чыгарып тормас, ләкин идарә составында берсе-берсе чишмә башына торырлык егерме мужик, районга җиткерерләр... Нотфулла, тагын сүгенәм дип авыз ачканда, Низамны күреп алды.

— Апак, атны чигендер әле, мин арба башын кендегенә утыртам.

Килде Низам, атны йөгәненнән тотты. Тик Юаш Нотфулла, күпме көчәнмәсен, күчәрдән төшкән арба башын күтәрә алмады. Юкә себеркеләре бүген генә урылган, чи һәм авыр иде шул әле. Гомер буе ат тирәсендә чуалган Низам нишләргә кирәген шундук аңлап алды:

— Үзем күтәрәм. Син чигендер.

Юаш Нотфулла, Низамның җененнән куркып, тагын сүгенә башлады, күр әле моны — кендеге тырпайган арбаны күтәреп урыныннан күчерде, атны чигендергәнне дә көтмичә, күчәренә утыртты! Ат хуҗасы сөенергә теләп «әгүзе...»не укый башлады, ләкин аның бисмилласы сүгенү катыш иде. Үзе кесәсен капшый — өч сум, биш, ун сум акча чыкса, менә хәзер Низамга тоттырасы иде. Юк шул, куен кесәсеннән бая гына ачылган «Беломор» чыкты. Низам монысына ныграк сөенде.

Ә бүген кич ул күргән бер малайга «Беломор» бирде. Көн саен төпчек җыеп куаныч тапкан Низамның тәмәке өләшеп йөрүен аңламыйлар. Ул үзенчә әҗәтен түләргә тели иде.

— Абыеңныкын суктыңмы? — диде бер кәрлә тәмәкече.

— Юк, — диде Низам, күкрәк киереп, — абый «Памир» тарта. Сигарет ярата ул.

— Каян алдың?

— Юаш абый бирде. Арбасын күтәреп кендегенә кидердем.

— Буш арбаны любой хөрәсән күтәрә аны.

— Менә кара, ышанмасаң, яфрак яшеле буялган.

Низам күлмәк җиңендәге яшел сутны иснәтмәкче булып иелә, теге кәрлә шулчак җирәнеп читкә тайпыла.

— Низам! Мин сине хәзер әнә теге тал ботагына элеп куям!

Өч батырга тиң Низам чиртеш хәтлек малай алдында куркак куянга әверелә. Куып китсәләр, тиз генә тоттырмас өчен, бәла-казадан читкәрәк китеп баса. Үзе такмаклый-такмаклый аклана.

— Без синең белән ахирләр ич инде, агайне, тимә яме...

Ах бу беркатлылык...

Табигать кешегә кодрәтне тигез өләшми: дөньялыкка чибәрне мәгънәсез итеп, акыллыны — явыз, көчлене җүләр итеп ярата. Беркатлылар исә өстенлек сөйгән кешеләрнең күңелен күтәрер өчен кирәк, патшалар янында йөргән шамакайлар кебек. Низам өеннән чыкмаса, яшьләргә күңелсезрәк тә әле. «Кичә ник күренмәдең?» — дип аптыратып бетерәләр үзен. Авырдым, дигәнен ишетмәссең, җаваплары бик гади: «Абыйның «Памир»ын алган өчен, җиңги галошларны яшереп куйганые...», «Пәрәү болынына печән урларга бардык...», «Күлмәкне юганыем, кибеп өлгермәде...»

Башка очракларда җәен-кышын клубтан калмый.

Өйләнәсе килә Низамның.

Чаршау артында абыйсы белән җиңгәсе пышылдаша башлагач, йокыга китә алмыйча интегә ул. Тыңлап ята торган гадәтен сизенеп, Низамга урынны өйалды ягына җәя торган булдылар. Карлар ява башлагач кына, өйгә кертәләр. Туңа белми, ару-талуны сизми, җен-пәриләрдән курыкмый Низам. Төн уртасы дип тормый, инеш ярына салынган мунчаларның челпек янган тәрәзәләреннән хатын-кызларны күзәтеп йөри. Пәрдә ярыгы калмаса, шап-шоп юынган тавышларын озаклап тыңлап утыра. Хатыны булган ирләр иң бәхетле кеше аның өчен. Ул аларның юрган астында, мунчада нишләгәннәрен белә, тик барыбер күзәтәсе, һич югы, тыңлап торасы килә.

Низам яшендәге карт кызлар да йөри клубка. Күңелләрендә мутлык булмаса, тәмле йокы сәгатьләрен әрәм итеп, яшьләр янында бәясе төшкән мал кебек мескенләнеп йөрмәсләр иде. Карт кызлар яшь-җилкенчәкләрне өйләнергә өйрәтә, өйләнгән ирләрнең күңелен күрә; азарлар-тузарлар, уйнаштан бала тапса табарлар, ләкин Низамны якын китермәсләр, үртәрләр генә.

«Низам, кыртлыйсыңмы инде?»

«Кыртларга мин тавык түгел ич».

«Кем соң?»

«Әтәч. Менә син ичмасам кыртлый торган тавык. Оядан качып чеби чыгарыр чагың җиткән».

«Андый тавыкны караңгыга ябалар ич, Низам!»

«Кичә Нәгыйм абыйлар мунчасына япканнарые сине».

«Кит моннан, авызыңа сиим, тинтәк, дивана, паражит, кеше әллә ни уйлар!..»

Берәү әрли, бишәүләр көлә... Аңламассың бу сазамыкларны... Ә менә Гадиләне мунчаларда күргәне юк Низамның. Вәт өйләнер иде ул аңа. Айгыр җигеп урлар иде. Гадилә җылый башласа, ул аны чаршау артыннан ишетелә торган сүзләр белән юатыр иде. Туй итмәсләр, мәҗлесләргә бик күп ризык китә. Мулла никах укыр ярты сәгать буе... Һи, ярты сәгать кенә түзәргә була! Аннан соң Гадилә гел синеке. Эзләп клубка чыгасы юк. Тезмәгә — печәнлеккә күчеп яшисең, җәй буе сөешәсең. Кышка кергәч, чаршауның бу ягында Низам белән Гадилә, ә теге якта абыйсы белән җиңгәсе, менә хәзер яшьләрне тыңлап ятсыннар. Ник мышнийсыз анда, дип, инде Низамнан сорап карасыннар, җавапны күптән әзерләп куйды: «Иртәгә иртүк эшкә торасы бар, ашыгыбрак йоклыйбыз...» — дияр. Их-ма! Хыялы күзенә күренә инде. Гадилә генә алдалап йөртә. Беркөнне бөтен кызлар алдында тел яшермичә сөйләште әле ул Низам белән.

«Мин нәрсәгә кирәк соң сиңа?» — дигән була.

«Уенчык итеп уйнарыем», — диде Низам.

«И җүләрем...» — диде Гадилә сөенеп. «Җүләрем» дигән сүз сөйгән кызлар авызыннан бигрәк ягымлы булып ишетелә икән. Тыңлап торган кызлар көнчелектән нишләргә белми, кайсы көлгән була, кайсы елмая... Гадилә юата белә, очрашуны үзе билгели: «Урамда икебезнең бергә йөргәнне күрсә, әни үтерә мине. Бүген төнге уникедә җил тегермәне янында көт».

Төнге уникедән иртәнге бишкә чаклы көтте Низам. Әле тагын көтә ала иде, тик иртән-иртүк ат җигәсе бар.

«Мин килдем килүен, тик син инде кайтып киткәниең. Бүген әниләр йокыга киткәч чыгам, түлке көт, Низам», — ди Гадилә, кичәгесе өчен үпкәләми.

«Билләһи, валлаһи көтәм, Гадилә!»

Һәм Низам, «уенчыгы» килмичә, җил тегермәне яныннан китмәскә булды. Төн үтте, ай сүнде, чык кипте. Җигүле атлар тезелешеп Торна күленә печәнгә китте. Ә Низамның алашасы аратасында салам чәйнәп калды.

Аны, сынык канатлы тегермән астыннан табып, уята алмыйча арбага салып алып кайттылар. Җиңгәсе эшсез калган колхоз аты өчен үгез арканлый торган бау белән кыйнады. Аннан соң Гадиләләргә барып, гөнаһсыз баланы үртәп йөргәне өчен, карт кызны каргый-каргый әрләде... Һәм бу каргыш киләчәктә Фазыл башына төшәр дип кем уйлаган?!

## Уенчык Шәмсия, яки башсыз-күзсез малайлар...

Бу тормышта уеннан уймак чыгару бар бит әле.

Җиңгәсе кыйнаганга карамады, Низамның гыйшыклы күңеле уенчык көтте.

Сазамыклар күкрәгенә буе җитмәстәй малайлар Гадиләдән күңеле бизгән Низамны өйләндереп куйдылар бит тәки...

Яшерен-батырын түгел, авылның нәкъ икенче ягында тагын бер сәер кеше, Низамнан да беркатлырак ятимә хатын Шәмсия яши иде. Авыз чалшайтырга ашыкмагыз, мең морҗалы авылга ике җүләр күп түгел ул. Хәтта туксан капкалы Чыпчык бригадасының да Әки атлы беркатлы агае бар. Бактың исә, бу күрсәткеч, башкалабыз белән чагыштырганда — йөз, Рәсәй белән тулаем чагыштырганда, мең тапкырга кимрәк. Яшьлектә сөйгән ярларыбыз, парлашып тормыш кичкән багалмаларыбыз: «И җүләрем...» — дип әйтәләр икән, димәк, без сөелгән минутларда үзебез дә Низам белән Шәмсия хәлендә...

Авылда гомер бакый яшәп, шөкер, Шәмсия данлыклы «сары йорт»ка эләкмәде. Ул яшь пенсионерка. Җәй көннәре колхоз эшеннән калмый. Июль чилләсе дип тормас — аягында баганалы оекка киелгән галош, өстендә бәби итәксез, озын җиңле көлсу күлмәк. Татарча җәеп бәйләгән яулыгы, кайчан күрмә — ак булыр. Ул ике як күршесеннән гайре кешеләрне танымый. Авылныкылар аңа сәлам бирми, аралашмый, ләкин телдән төшерми. Низамнан аермалы буларак, күзенә күренсә, ни ишеткән, ни белгәнен бәйнә-бәйнә сөйли, җөмләләр арасына нокта куеп тормый, сулышы җиткәнче әйтәсен әйтеп кала. Икенче сулыш алганда, теге тыңлаучы үтеп киткән була инде. Шәмсиянең өе иске, ярдәм итәр кешесе булмагач, вак ботак утыны гына тартып ташый, эре мал асрамый — ике баш сарыгы, бер кәҗәсе бар.

Үзалдына сөйләнеп йөрүе дә гел шул көндәлек мәшәкатьләренә бәйле. Авылның яшь «әтәчләре» өчен Шәмсия бик җайлы тәтәй, килгән бер хәсис үзен зур нәчәлник итеп таныштыра, вәгъдәләр белән бичараның күңелен йомшарта, ашый-эчә, күңел ача һәм бәрәңге бакчасы ызанынннан чыгып кача. Икенче көнне Шәмсия, сөенечен уртаклашырга теләп, үзалдына сөйләнә: «Кенән кичкырын Казаннан зимлямир килеп бакчаларымны үлчәп китте, Сигәк Хәсәнне Себергә кудырып, бәрәңге җирләрен миңа бирдерәм, диде, печән үстерерсең, тартып ташыйсы булмас, ике сарыгыңа кышка җитәрлек курмы булыр, ди.

Райком кешесе кереп өйгә акт төзеде. Сакал Шәйхине эшеннән алабыз, аның урынына үзем булам, ди, өч көннән миңа өй салып бирәм, ди, бик гыйшыклы, үзе төне буе өстемнән төшмәде.

Кичә ике инженер килде. Максимнарның мәктәптән туратып алган каен утыннары миңа тиеш булган икән, бүген төяп китерәбез, диделәр».

Гап-гади җәйге бер кичтә малайлар тагын клуб ишеге төбендә сөзелеп калды. Подвалда движок тырылдый, кинобудкада аппарат чырылдый, ишек артында киномеханик сүгенә, залдагылар рәхәтләнеп фильм карый. Бушлай керергә теләсәң, киноның яртысы беткәнен көтәргә туры килә, механикның ярдәмчесе ишек төбеннән китмичә сакта тора. Дөрес, кайсыбер көннәрдә малайлар, подвалга төшеп, движокның бензинын ябып куялар иде. Ут сүнеп, кино өзелгәч, клуб эчендә сызгырыш, кычкырыш, дөбердәтеп аяк тибеш һәм сугыш башлана. Механик подвалга йөгереп движокны яңадан кабызган арада, залдагы халык түзми, озын тәнәфес ясап, урам ишегенә ябырыла, билет тикшерү бетә, бушлай керүчеләр өчен «коммунизм» башлана. Ләкин соңгы көннәрдә яңа механик Жит Каюм малае хәтсез усалланды. Әгәр ут сүндерүчеләрнең берәрсен тотсам, Пожарный буасына сөйрәп иманнарын себерәм, дип әйтә ди. Белдерүләрне үзе ябыштыра, беркемне бушлай кертми.

Малайлар, иманнарын исән-сау саклап кына, киноның яртысы беткәнне көтеп йөриләр, маймыч өере шикелле әле бер, әле икенче күләгәгә сыеналар. Низам ике катлы кепка арасына җыелган төпчекләрен кабыза. Малайлар аны үртәргә кызык эзли. Тәмәке тартмагач, Фазылның авызы буш.

— Низам, сине Шәмсия чакырды.

— Чынлап мәллә?!

— Әйе, әйе, — дип күтәрелде малайлар, Фазылның уенын хуплап, — бик күптән кызыгып йөри икән инде ул синә.

— Җалганлыйсыздыр әле.

— Кем ялганлый — безме?! Ышанмасаң, әйдә, Шәмсия урын җәеп, бер чуен аш пешереп, ике чәкүшкә аракы белән көтеп торам, диде.

— Чынлап мәллә?..

— Чынлап. Әйдә!

— Әйдә, әйдә, — дип, әйлән-бәйлән уйнагандай, түгәрәктән чыгарга ирек бирмичә, Низамны алып киттеләр.

Бай кеше капкасына бер йозак элсә, ялгыз хатын бишне элә. Әллә куркудан, әллә мал кадерен сакларга теләпме — Шәмсиянең капкасында эчке яктан җиде тәрәү бар иде. Дөбердәтә торгач, ике-өч тәрәү ауды. Урам ягы тәрәзәсеннән:

— Каравыл кычкырам, китегез! — дигән тавыш ишетелгәч, малайлар тынып калды.

— Шәмсия апай, райкомның теге кешесе килде. Ач капкаңны.

— Хәзер, хәзер ачам!..

Капка ачылуга, Фазыл белән Мәгъсүм ике кулыннан сөйрәп, башкалар этеп дигәндәй, Низамга кире чигенергә ирек бирмәделәр. Шулай итеп, җиде күсәк яңадан тәрәү булды. Малайларның уйлавынча, өй эчендә нидер дөбердәргә тиеш һәм аннан соң, бите-күзе тырналып, Низам очып чыгачак. Әгәр кино беткәнче дип клубка ашыкмасалар, малайларга, ай-һай, озак көтәргә туры килер иде.

Шәмсия апагызның алпамшадай көчле, нарасыйдай ягымлы, ком гарәбе шикелле әрсез, аю кебек талымсыз егетне әле бүген дә куып чыгарырга исәбе юк. Икенче көнне үк, капка тәрәүләрен утынга турап, Низамга тавык бәлеше пешереп бирде ул.

Абыйсы белән җиңгәсе эзләп килмәделәр Низамны. Карыны ачса, ашаган җиренә кайтыр әле, диделәр. Ат җигәр вакытка уянып: «Җарар, мин киттем!» — дисә дә, кояш баеганда, ул яңадан Шәмсиягә әйләнеп кайтты. Ярты гына сәгатькә клуб янына да килеп китте әле. Кино карарга түгел, малайларга «кияү бүләге» өләшергә. Ачылмаган бер кап «Аврора» сигаретын малайларга таратып бетерде. Гомердә тәмәке тартмаган Фазыл белән Мәгъсүмгә дә эләкте.

Низам, ике козыреклы кепкасын ташлап, яланбаш килгән, сул якка таралган чәче күпереп тора. Кыска җиңле сары күлмәге сырлы бәләк астыннан әле яңа чыккан. Үкчә астында тапталып йөргән сатин ыштан балагы кыскартылган. Ул «Аврора»ның икенче кабын өләшмәде, бер сигарет шудырып малайлардан ут алды. Авызын клуб түбәсенә төбәп, эчендәге төтенен сытып чыгаргач, уенчыгы исенә төште бугай.

— Кайтам! Шәмсия җиңгәгез эзли чыгар. — Һәм ул, саубуллашырга теләп, кулын сузып торды.

Малайлар, берәм-берәм килеп, аңа кул бирде.

— Әллә акыл кергән инде моңа?! — дип, сынык теш арасыннан төкерек атты Мәгъсүм.

Арадан бер зуррагы җавап тотты:

— Һе! Өйләнде, димиләр, башлы күзле булды, диләр бездә...

Башсыз-күзсез малайлар, көнләшеп, Низам артыннан карап калды.

## Төртеп төшер

Икмәк белән пычак гел бер табында. Икесе дә үз урынында. Берәүләр җитештерә, икенчеләр бүлә. Җитештерүче бүлүчене сөймәс, бүлүче җитештерүченең моң-зарына колак салмас.

Кемнәрдер тир түгә, эзләнә, таба, югалта, ялгыша...

Кемнәрдер шул кешеләрне бәяли, хөкемгә тарттыра, акыл өйрәтә, мәхрүм итә.

Байлар һәм хәерчеләр, явызлар һәм мескеннәр, түрдәгеләр һәм ишек төбендәгеләр, комсызлар һәм гаделләр, кораллылар һәм буш куллылар, сайланганнар һәм сайлаучылар арасында барган мәңгелек көрәш — яшәү дип аталадыр...

Фазыл әлеге хакыйкатьнең кайсы төркемендә соң? Шушы яшенә чаклы тапкан-табынган мөлкәте юл капчыгына сыйса да, ул үзен сукбай дип исәпләми. Матди яктан нужасы юк. «Ак Чишмә»нең төгәллек сөйгән булдыклы хисапчылары, үз көенә яшәргә күнеккән бораулаучыларны акча алырга кайчан кайтырлар микән дип, кул кушырып көтеп ятмадылар, хәләл тиешлесен банктагы исәбенә күчерә тордылар. Шунда ук пенсиясе дә җыелып бара. Яңа сәясәтчеләр акча белән шаяра башлагач, абзагыз бөтен булган сәмәнен талир тәңкәләргә алыштырды.

Көрәшмисең икән — тәнеңдә җаның бар килеш яшәүдән туктыйсың! Бәхет өчен көрәшергә дисәң, бала чактан бирле авырлыкта чыныгып үскән Фазылның физик көче җитәрлек. Язмыш сынаулары һәм югалтулар хисабына яши-яши җыелган акыл көче җиңелергә ирек бирмәс. Ир егәре — физик һәм акыл көчендә. Ә егәрлекне бездә ат көче белән үлчиләр. Татар тумышыннан җигүле ат инде ул. Ат җигүчеләр безгә утырып йөри, йөк төяп ташый, сүгенә-сүгенә камчылый, дилбегәне кая тели — шунда тарта, тугарып болынга җибәрсә, куш аякны аркан белән тышаулый...

Вагон тәртәсенә ат булып җигелергә әзер ул бүген... Фазылның калган гомере — бәхетнең бер төре. Ә бәхетле кеше бервакытта да үзен ярдәмгә мохтаҗ мескен дип санамый.

Тагылмалы язмышны алып, Әҗәл эзләп тапмаслык сукмакка качасы иде бу тирәдән. Ә бәлки, киресенчә, каршысына чыгасыдыр? Нигә дип әле аны урын өстендә көтеп ятырга?!

Фазыл юл читенә чыгып басты.

Көн оешып җитмәгән әле. Кояш күләгә кыскартырлык күтәрелмәгән. Җилләр җылынмаган. Исән кайткан сыерчыклар, кырларга сибелмичә, авылдан качып электр чыбыгына тезелешкән. Көздән коргаксып калган саран болыннардан үлән ялварып кычкырган көтү тавышы әле якында гына…

Ул башта Чаллы ягына баручы машиналарга кул күтәреп карады. Күбесенчә «КамАЗ»лар чаба, юк, чапмыйлар, бер-берсе белән узышалар! Уңга-сулга карамыйча, бәйге тоталар — һәммәсе үзенең финишына ашыга. Һәм Фазылның кул күтәреп басып торуы аларга хәерле юл, изге җиңүләр теләп калуише генә. Иллеләп машинага сәлам бирде ул... Шуннан соң, Казан ягына ашкынучыларны аулау өчен, трассаның икенче ягына чыгып басты. Шунысы сәер, Актаныш ягына вагонны иярткергә теләмәүләрен оптимист Фазыл үзенчә яхшыга юрады...

Казан ягына бәйге тотканнарның да аңа исе китмәде. Бөркәүле-бөркәүсез, йөкле-йөксез, прицеплы-ялгыз, иске-яңа машиналар, кул күтәреп торган ир уртасы кешене үртәп, тизлекләрен генә арттыралар. Хәтта, исереккә санапмы, аның турысына җитәрәк, бәла-казадан сакланып дигәндәй, рульне юл уртасынарак каералар иде.

Ярты сәгатьләп вакыт үткәндер инде, шәт. Үртәлде Фазыл, һай, үртәлде... Ялыныч көнгә калсаң, юк инде ул, штурвал үзеңнең кулда булсын икән! Менә тагын бер генә машинага өметләнеп карый да, вәссәлам... Юк, монысы туктамады, ярый, әнә теге ак кабиналысы туктар кебек... Менә тегесе өметле күренә... Тагын берне генә... Тагын... Бетте, соңгысы... Юк, тагын иң соңгы тапкыр күтәрәм дә кулымны, вагоныма кереп ятам... Тагын бер генә... дия-дия, Фазыл инде күтәрелгән кулын төшерергә дә хурлана башлады. Дөрес юлны күрсәткән юлбашчы һәйкәле кебек, Мәскәү ягына карап, тораташтай басып тора. Бил сөяген вак тешле пычкы белән кискән кебек, сызлавы көчәйде.

Ә менә бөтенләй өметләнмәгән транзит килеп туктады: аклы-кызыллы, зәңгәрле буяуларны кызганмыйча буяганнар үзен. Бөркәүле арбасы йөк ташучы поезд вагоны кадәр озын, калай тышлы, алты күчәрле. Чит ил сүзләрен самолеттан укырлык зур итеп язганнар... Тормозлары «чыш» итүгә, кабинасының сул яктагы ишегеннән бер кыз сикереп төште, төшүгә үк аяк астында барган буаз сумкасын тартып алды. Фазыл, ул кызыйга ишек ябарга ирек бирмичә, шофер белән сөйләшергә тотынды.

— Туганый, әнә теге вагонны Казанга чаклы гына алып бар әле.

— Вакыт юк!

— Нибарысы җитмеш чакрым ич инде.

— Ашыгам!

— Әйбәт вагон ул! Төзек, тагарга да җайлы.
— Көтәләр мине!
— Түлим мин, күпме сорасаң да түлим.
— Ярамый!
— Алайса, кольцога чаклы гына! ГАИ постында калдырырсың.
— Яп ишекне!
Туктамаганнары өчен сызлануга өстәлгән хурлыктанмы, әллә бу транзит автопоездның кирәкмәгәнгә туктавына ачуы чыгыпмы — ишек шактый ук каты ябылды.

## Син – Казанга, мин – Казаннан

Ялынычлы мосафир әлегә Фазыл гына иде, инде икәү булдылар. Кызый, бөркәнчеген җилкәсенә төшереп, кара күн куртка кигән. Тар итәге дә күннән тегелгән, материалы җитмәгән, ахрысы, тезен капларлык түгел. Ә инде елан кабыгы сыман колготкие күн куртка белән күн итәкнең дәвамы кебек кенә. Шәмәхә шакмаклы тыгыз брезенттан тегелгән сумкасы да таныш, андыйлар базар тирәсендә көн күргән алыпсатарларда кул саен берәү...
— Мин ничек машина туктатырга белмим, син утырганыннан төшеп калдың.
Кызый, йөзен яшергәндәй, Казан ягына карап баскан иде, Фазылның сүзләрен бәйләнүгә санапмы, җавап кайтарырга кирәк дип тапмады. Ул йөк машиналарына кул күтәрмәде, автобус көтәргә иде, ахрысы, исәбе. Фазыл да, иртәнге уйларыннан ваз кичеп, юл кырыена ник чыкканына үкенә башлаган иде инде.
— Ә монда автобуслар туктамый. Иске зират өстендә торабыз синең белән. Күпме хәвеф күрде бу тау бите... 1971 елның җәендә Әмир Ашрапов белән юл төзүчеләр өчен су скважинасы бораулаган идек без монда. Кире күмдерделәр. Бу юлны «Каздорстрой» салды. «Каз» дигәне Казан түгел түлке, Казакъстан юл төзүчеләре... Ул елны минем әле Ростов өлкәсеннән яңа гына укып кайткан чагым иде... Хәер, боларны нәрсәгә дип сөйләп торам инде мин сиңа... Сыртың белән тыңлагач?! Туктамаган машиналардан да хужы икәнсең син, — диде дә, кызыйга, тыз-быз килгән машиналарга, гомумән, егерме көнлек дөньясына кул селтәп, вагонга таба атлады. Башта әкрен генә атлады, чөнки алга таба нишләргә кирәген белми иде әле ул. Бераздан, тормыштагы барлык кимсенүләрдән котылу чарасын тапкандай, адымын тизләтте. Әгәр теге кызый эндәшсә, туктатып кала иде... Туктатмады кызый, әмма, кире борылып, Фазылның эзенә карап калды үзе.
Хәллерәк төзелеш оешмасының тулай торагы чаклы автобус тизлеген киметмичә, битараф кына узып киткәч, күн тышлыклы кызый да юлның икенче ягына чыгып басты.
«Бу кызга да мәшрикъ белән мәгърип икесе бер якта икән, — дип уйлап куйды яшел вагонның тәртәсенә килеп ябышкан Фазыл, — максатлы кешенең юл юнәлеше үзгәрмәс иде...» Хәер, башкаларда ни эше бар, кыйбласызлар күбәйде лә бу заманда...
Көчен кая куярга белмәгән шалапай кебек тиктомалдан вагон тәртәсенә барып ябышкан Фазылны күрмәмешкә сабышса да, кызый кызыксынырга мәҗбүр булды. Кояш астыннан алып китеп, тар урман күләгәсенә урын алыштыра, ахрысы, бу, дисәң — юк, тәртәсеннән көчәнә-көчәнә, чыраен сытып тарткан саен, алгы көпчәкләре олы юлга таба борыла, ә яшел вагон үзе тар урман тоткынлыгыннан котылмакчы. Җир өстенең көпшәклеге хут алырга ирек бирми, йолкып-йолкып тартканда гына, көпчәкләрнең кыймылдаганы сизелә. Фазылның нишләргә теләгәнен бик төшенеп җитмәсә дә, юлаучы кызый интеккән кешегә булышырга кирәк дип тапты һәм, базар сумкасын каен төбенә сөяп, кулларын бушаткач, яшел вагонның артыннан этешә башлады. Юл өзегендә бик күп машиналар эткәнгә охшый — кызый ирләрчә тырыша белә, көчен кызганмый, аваз чыгарып көчәнми... Ләкин тәртә читкә каерамы — вагон таш юлга чыгарга теләми, чит-читләп бара. Менә тизлеге дә арткannan-арта тора, чөнки ярты чакрымга сузылган таулы юлның сөзәк өлеше иде инде бу. Кызый, тиз генә һушына килеп, вагонның алдына чыкты һәм Фазыл кулындагы тимер тәртәне бөтен гәүдәсе белән җиргә батырды. Тәртәнең бөгәлҗәле башы шуып барган җиреннән көпшәк чирәм астына кереп кадалгач, вагон сискәнеп туктап калды.
Алар бер-берсенең күзенә карамадылар әле.
— Каян килеп тыгылгансыңдыр, үзем дә тәгәрәтә идем.
— Үзем, имеш, — дип, шамакайларча үртәде кызый, — мин килеп тотынмасам, вагоның тау астына очасы иде. Рәхмәт әйтәсе урында, әтәчләнеп тора, ичмасам...
— Мин бит инде аны тау астына очырырга дип кузгаттым.
— Ие... Ну, бар алайса, төртеп төшер.
— Хәзер, документлар белән биштәремне алып чыгам да Аллага тапшырам. Бу арбаның урыны күптән упкын төбендә.
— Әллә чынлап әйтәсең инде?
— Утыз ел буе сөйрәп йөрдем мин аны. Җимерергә вакыт. Юкса, язмышымның кара сакалы кебек, котыла торган түгел. Бөтен яшьлегем шушы вагонда үтеп китте. Эш урыным, клубым, кунакханәм, ни-

гезем, гаиләм дә шушы вагонда... Инде улым үсеп җитеп утка-суга керердәй егет булгандыр, ә мин һаман вагон карачкысы.

Кызый шундый итеп текәлеп карады ки, хәтта Фазылның сызлануы көчәйгәндә күбәя торган маңгай җыерчыклары югалды, әйтеләсе фикерләре буталды. Җавапка караш кайтара алмады абзагыз, гаебен танып читкә борылды. Чынлап та, нигә соң әле үз арбасындагы йөкне моңарчы бөтенләй күрмәгән-белмәгән кыз бала арбасына күчереп маташа ул?

Ләкин бүгенге тамашаның сәхнәсе тарайды, инде кояш алар барып җитә алмаган шәһәр өстендә баеп бара. Машиналар туктамаса, юл өстендә кич утырыр өчен ышык урын юк. Берәр авылга таба җәяүләп атлыйм дисәң, базар юлында адашып калган шакмаклы сумкасы урыныннан кузгатырлык түгел. Нинди уйга килергә, нинди рольгә керергә, дип, сайланырлык мөмкинлекләр күренми. Ә яшел вагон тирәсендә өмет бар...

— Танышыйк әле тизрәк, Гөлсөяр мин.

— Гөлсөяр?!

— Нәрсә куркып калдың? Гөлсөярләр белән гаебең бармы?

— Курыкмадым. Татар илен аркылы-торкылы йөреп тә, мондый исемне беренче тапкыр ишетәм.

— Игезәкләр без. Беребез — Илсөяр, миңа Гөлсөяр кушканнар. Үзеңнең исемең дә әллә кем түгелдер әле?

— Фазыл.

— Вәт. Әйтәм ич, безнең Акбулатта да ике Фазыл бар иде. Берсе — акыллы, икенчесе — буйга озын.

— Утыз еллар чамасы элек булганыем мин сезнең авылда.

— Нәкъ мин туган елны... Нишләп әле син елларны чама белән генә саныйсың, Фазыл әфәнде?

— Еллар белән айларга хәтерем юк минем. Көннәрне генә саный беләм... Ә гел вагонда яшәгән кешегә «әфәнде» диләрмени?

— Әфәнде, әфәнде! Хәзер бөтен ирләр дә әфәнде! Яңа байлар уйлап чыгарган кагыйдә.

— Ә сиңа, Гөлсөяр, кем дип дәшим?

— Туташ әле мин, кияүгә чыкмадым. Ирләргә баш имәдем. Ханым итәргә теләгән бер төнлек кияүләргә тәнемне сатмадым.

— Нәрсә сатасың соң син? Сумкаң авыр күренә.

— Китап сатам.

— Китап?! Базардамы! Кием-салым, җиләк-җимеш, конфет-мазар, ну ахыр чиктә «Буш ботлары» белән көнбагыш дисәң дә ышаныр идем. Китап сату ничектер ышандырмый.

— Аның каравы җаным тыныч! Рэкет бәйләнми, салым инспекциясе кызганып үтеп китә, кая килеп утырсам да, лицензия сораучы юк.

— Табыш та юк.

— Көннеке көнгә җитә. Байлык артыннан кумыйча гына эзлим мин бәхетне.

— Китап яраткан кешене полиглот, диләрме әле?

— Юк, библиофил, диләр. Югары белемле библиограф мин үзем, махсус институтын бетердем. Чаллыдагы бер китапханәгә эшкә җибәрделәр. Көне буе көтеп утырасың инде... Китап сорап кергән кеше йә студент, йә мәктәп баласы... Башкалары йөрми. Ай ахырында, фәлән-фәлән хәтле эшче, интеллигенция, хезмәткәр укый, дип, ялган формулярлар тутырып, отчет бирәбез.

— Юкса ханәңне ябалармы?

— Бушка асрап ятмаслар шул. Ә болай мин җәмгыятькә күбрәк файда китерәм. Гади халыкка сатам, ялынмыйм, үгетләмим, эчтәлеген сөйләп кызыксындырам, алсалар, сөенәм.

— Гөлсөяр туташ, нигә соң син утырган машинаңнан төшеп калдың? Бактың исә, монда ни тукталыш, ни кала, ни сала түгел.

— Дальняк иде ул. Польшага бара, әйдә загранкага, дип кодалый башлады.

— Әйбәт ич инде. Бушлай гына чит илдә йөреп кайтулары ни тора. Мин менә, ичмасам, чит илнең кайсы якта икәнен дә белмим.

— Ул транзитларга ышанып утырып китсәң... Чит илләре Мари урманында гына аларның. Моның да куллары тизлек тартмасын минем тез башымнан эзли башлаган иде. Әнә абыем каршы алырга чыккан, дип, юри синең янында туктаттырдым машинасын.

— Кая барышың иде, Гөлсөяр?

— Чаллыдан качтым. Сәүдәгәрләрнең алтын богавыннан. Кая гына урнашсам да, эш көненең азагы бер — һәр яңа бай утыз яшьлек кыз баланың беренчесе булырга тели... Җәелеп яттылар ди менә... Казанда иптәш кызларым бар әле. Берәрсенә сыенып торырмын.

— Алайса, син дә минем хәлдә икәнсең?!

— Ә сиңа нәрсә булган? Ир кеше! Сау-таза! Төскә-биткә яман, буең таман...

— Ак халатлы кәккүк списать итте мине.

— Безнең гомер кәккүк кулында түгел! Зәгыйфь кеше ат урынына вагон сөйрәп йөри аламыни?! Баһадир бит син! Мин әйткән икән — димәк, баһадир инде! Карале, вагоныңда эчәрдәй су юкмы? Сине кеше итәм дип сөйли торгач, тамак төбем көйде.

— Кирәксә — чәй, кирәксә — мәй, ипи, йомырка, бәрәңге, май... Бөтенесе дә бар минем вагонда.

— Һи, җүләр әфәнде, шушындый хәзинә оясын чәлпәрәмә китерергә йөрисеңме? Әйдә, кире урынына илтеп куябыз. Юкса чәй эчкәндә чайпалып аска тәгәрәмәсен.

Кәгазьне агачтан ясыйлар, ди. Китап тутырылган олы сумканы вагон янына алып килгәндә, агачның чын авырлыгын тойды Фазыл. Моны урыннан урынга күчереп йөри алгач, Гөлсөярдә пәһлеван көчләре бардыр, дип уйлап куйды ул.

— Эшсезлекнең әйбәт ягы шунда, Гөлсөяр, кайчан получка бирерләр икән дип, көннәрне санамыйсың. — Фазыл елмаерга бик теләгән иде, тик сызланудан сытылган чыраен үзгәртә алмады...

— Фатирым булмагач, шунысы шәп — ай саен квартплата түлисе юк.

— Миннән курыкмыйсың дамы?

— Заложник итеп алмадың ич әле.

— Бәлки, мин, атарга хөкем ителеп, төрмәдән качкан берәр маньяктыр?..

— Әфәндем, китапханәчеләр, сатучылар — психологлар бит алар, яхшыдан яманны аера беләбез. Аннан соң, куркыныч кешеләр белән көрәшә-көрәшә, көрәшчегә әйләнеп беттем инде. Мине үтереп кенә җиңеп була.

— Шушы яшемә җитеп тавык та суйганым юк.

— Күреп торам. Ә нәрсә белән генә туенасың син, Фазыл абый?

— Табигать хәзинәсендә ни бар — шуның белән.

— Майның унбишләрендә алмагач чәчәгеннән гайре нәрсә юктыр ул.

— Акчаң булса, һәммә нәрсә бар хәзер. Кыска итәкле кызлар, бәлки, чәчәк белән генә туеналардыр. Үзең әдәпле кыз кебек күренәсең, үзең ирләрне ымсындырырлык итеп киенгәнсең.

— Үрсәләнүеңне аңлыйм. Кыр уртасында ялгыз кыз, үзе яшь...

— Исең киткән икән...

— Миңа исем китми, дип әйтәсең киләме?

— Мыегым да селкенми хәтта.

— Кыз бала өчен бик авыр сүз әйттең әле син, Фазыл абый. Моңарчы күргән бер ир дә миңа өметен азындырмыйча калмый торган иде. Шуларның бәйләнүләренә түзәлмичә, урыннан урынга күчеп йөрим.

— Озын итәкле күлмәк кисәң, күрмәмешкә сабышып үтәрләр иде әле.

— Син моны юри әйтәсең, Фазыл абый. Үртәү — ирләр хәйләсенең иң көчлесе, иң мәкерлесе. Мин юри кыска киям. Бозык ирләрне ирештереп йөрү кызык ич. Тыңлап торсаң, хәсисләр юха телләнә, хәйлә кора, акчасы белән мактана, мәхәббәт легендалары уйлап чыгара, куркыта, алай да җиңә алмаса, ялына, ахыр чиктә елый башлый. Бактың исә, барысының да максаты примитив — тик бер генә тапкыр...

— Ләкин мин түгел.

— Алайса, вагоныңда төн кунудан куркасым юк икән...

Нәкъ менә шушы сүзне ишетер өчен тырышкан иде инде Фазыл. Кара күн костюм якасына яшеренергә теләгән озын сөтләч муенына, күз төбенә күләгә төшерердәй куе керфекләренә, озынча яңагына килешеп торган кылыч борынына, чәч юлы калдырмыйча күпертеп артка таралган купшы толымына, ике алмалы күкрәгенең текәлегенә, итәк каешы буш килеш тә тотамлап куйган төзек биленә һәм кысан колготки челтәреннән яктылык чәчеп торган балтыр-ботларына карап, күрәләтә исем китми, дип үртәп торулары җиңелдер дисезме? Әгәр сүз башыннан ук соклануыңны сиздерсәң, кызның йомыласы билгеле иде. Калсын ул. Соңгы вакытларда Фазылның бәгыренә үткән ялгыз төннәрнең берсен генә булса да уртаклашсын. Матурлык һәм сафлык һәрвакыт тансык. Хәтта көннәрең санаулы булса да!

Ачык учак өстенә чәйнек эленгәч, Гөлсөяр хуҗабикәгә охшап калды. Ул, күн костюмын саклар өчен, утка якын килмәде, табын әзерләү мәшәкатенә чумды. Ак гипюр шарфы белән маңгай чәчен каплады, иңенә сөлге элде. Чүмеч белән су койдыртып бит-кулын юды. Асылмалы сумкасыннан рәсемле пакетка салынган күчтәнәчләрен чыгарды. Ул арада Фазыл, билен ял иттерер өчен, үлән өстендә йөзтүбән сузылып ятып торды.

— Тавык суймый торган әфәнденең пычагы бар микән?

— Пычак тумбочка эчендәге икмәк янында.

Гөлсөяр, пычак эзләп, вагонга керде. Бу калай тышлы бүлмә зур тозак кебек тоелды аңа. Сәкеләргә җәелгән урын-җир тузгыган... Артыңнан ук тимер ишек шартлап ябылыр да сине корбан итәр. Күңелендәге шик-шөбһәләрне таратыр өчен, кыз сөйләшүен туктатмады.

— Фазыл абый, бу ике чиләк йомырканы каян алдың?

— Хәмдия апаңнан.

— Кем ул Хәмдия апа?

— Мәхәббәтем.
— Мәхәббәтең ояңа килеп йомырка салып китәмени?
— Ие. Казанга сатарга дип чыккан чакта аркылы төшәм дә чиләге-ние белән сатып алам.
— Бәрәңгеләрең үргән.
— Утыртыр вакыт җитте ич.
— Канистраң буш — суы беткән. Каен суы җыеп чәй кайнатабызмы?
— Китер монда, чокыр төбендә чишмә булмый калмас. Каен суы әче инде ул хәзер.
— Ник һаман чокыр төбенә ыргыласың соң син? Суга үзем барам. Учагыңны сүндермә.
— Адашырсың йә...
— Әйдә икәү эзлик чишмәне. Үзең генә табалмассың!
— Сумкаңны саклап тик утыр! Мин, Гөлсөяр туташ, утыз ел буе чишмә эзләдем.
— Ә-ә! Шулаймы?! Алайса аунап ятма, тизрәк йөр, кайткач, эшең турында сөйләрсең.
Фазылга бик кызык тоелды әле бу очрашу. Бер чиләкле канистра тотып су эзләп китүе Гөлсөярне тагын бер кат сынау өчен генә. Чынлап та вагон янында төн уздырырга җыенамы ул? Су алып кайтканчы, сумкасын сөйрәп, билгесез тарафка китеп олакмасмы?
Тар урманның каеннары кашлакка чаклы гына озата барды. Яр астында кабыклары каушакланган гаярь өянкеләр белән тамырга тамыр үскән тирәкләр каршы алды. Авылсыз тирәкләр. Димәк, авыл бу үзәннән күчеп киткән. Тал-тирәкләр бары тик авылда гына үсә.
Үз урынында чокыр-чакырлар, тигәнәк һәм кычыткан камыллары, сагышлы карга ояларын калдырып кая киткән бу авыл? Чишмәсе кипкәнме? Ут йотканмы? Су басканмы? Юк, хәрабәләре күренми, су комы утырмаган, черек улаклы чишмәсе исән. Бу авылны шәһәр йоткан...
Ә бәлки, чишмәләренең суы тәмсезләнгәч китеп барганнардыр? Әнә, авылдан бушаган бакчаларны бульдозер белән тигезләп, казыклар какканнар. Казык аралары тигез — димәк, дача төзер өчен өлешләргә бүлгәннәр.
Савытны тутырып, капкачын япкач, ул аны күтәреп карады. Туктап-туктап, ял итеп кайтканда, түзәргә була кебек... Кинәт ул, үзенә ниндидер игътибар барлыгын сизгәндәй, сискәнеп, артка борылып карады... Якын-тирәдә кеше күренми. Ләкин казыклы өлешләр беткән җирдә, тирәк янында тугарылган арба кебек, сырлы калай белән тышланган тагылмалы яшел вагон тора иде. Аннан ерак түгел бораулау вышкасы күтәрелгән. Читтән күзәткәндә, ул тал-тирәкләр арасында үсеп утырган кебек.
Фазыл, алган суын кире түгеп, шул вагон янына ашыкты.
«Кем бригадасы икән? Ник тавыш-тыннары юк? Сулары чыкты микән?» дигән сорауларга тагын әллә ничаклы кызыксыну өстәлде...
Аны туган нигезенә әйләнеп кайткан мосафирныкы кебек сөенү хисе биләп алды. Әле монда, әле тегендә сугылды, бораулау мәйданын әйләнеп чыкты, вагон ишегенә ябышты, платформага менгәч, кабина тәрәзәсеннән үрелеп карады, әмма хуҗалары күренмәде. Эшне төгәлләгәннәр болар: скважинага насос төшереп, каеш кабыклы чыбыкны җирдән сузып кына җәһәннәмдәге баганадан электр сузганнар. Яңа гына киткәннәр, ахрысы — су канавы чыланып тора, вышканы да аударып өлгермәгәннәр. Их, сызгырып кына элеккеге хезмәттәшләреңне чакыр идең дә, агрегатны кабызып, җир кабыгын шалтыршолтыр китереп, тик бер генә көн бораулап кара идең! Калган унтугыз көнең Әҗәлгә бүләк булсын... Яшисе килмәсә дә, эшлисе килә Фазылның...
Хискә бирелеп, платформадан җиргә сикереп төшкәч, ул кисәк авыртудан бер мәлгә өнсез калды. Ләкин озак утырмады, буш канистраның капкачын ачып, скважина авызына килде, кыска баганага кагылган тимер әрҗәдәге ак төймәгә басты... Шаулап бәреп чыккан су Фазыл кулындагы тар бугазлы савытны йолыккалады...
Эчтән бикләнеп йоклаган икән, су тутырып, гөрләвек агышына куанып басып торганда, вагон эченнән бер егет килеп чыкты. Ул, чыгу белән үк Фазыл өстенә ыжгырып килсә дә, кул уйнатмады, җикеренде генә. Ала-кола костюм чалбардан «омон» кешесенә охшап торса да, ул аның көндәлек эш киеме икән — баштанаяк кызыл балчык измәсенә быкырдаган иде. Сары чәчле бу кара урыс Фазылның күзенә Әҗәл булып күренде.
— Ник утка тыгыласың белмәгән башың белән! Әгәр шунда насос янса?!
— Нихәл, брат?! Кем бригадасыннан син? — дип, Фазыл кочагын җәеп күрешергә риза иде.
— Ә сиңа нәрсә, барыбер түгелмени?!
— Без бит коллегалар... Кайсы оешмадан сез?
— Шәхси милек бу... Синең кебек коллегалар монда күп йөрде инде: йә торбаны чәлдерәләр, йә электр чыбыгын өзгәләп алып китәләр.
— Соң, брат, мин бит үз кеше! — дип өзгәләнде Фазыл.
— Да пошел ты! Әле син һаман үз аягың белән китәргә теләмисеңме? — Һәм ул, кесәсеннән телефон чыгарып, читкә борылып басты. — Алло! Шеф, монда бер псих килгән... Патруль җибәр әле.
Калганын тыңлап тормады инде Фазыл. Черек улаклы чишмәдән су өстәп, килгән эзенә төште.

Уңнан сулга күчерә-күчерә, канистра сөйрәп кайтканда, лимон сыман кояш, җиргә төшеп, әфлисун төсенә кергән иде инде. Вагон янындагы нәни учак җан тергезеп маташа. Гөлсөяр, Фазылны күреп алу белән, аңа каршы йөгерде. Туташ инде кыска итәкле күлмәкләрен ак сызыклы зәңгәр спорт костюмына алыштырган. Килә-килешкә үк, Фазылның су салкыныннан күшеккән кулын кысрыклап, канистра тоткасына ябышты. Абзагызга авыр күтәрергә ярамаганны чамалый иде инде ул.

Су килгән арада, Гөлсөяр тар урманнан бер тотам төпле юа — уксын җыйган. Әле бер сәгать элек кенә, үз-үзен әллә кемгә куеп, Фазыл кебекләргә сәлам бирергә дә теләмәгән, горурлыктан ашкан тәкәббер, башимәс, таныш булмаган ирләр гаменә битараф күренгән Гөлсөярнең тышкы киемен генә түгел, холкын алыштырып куйганнар гүя. Бер сәгать вакыт өчен хәйран зур үзгәреш инде бу! Фазылның хәтта: «Бик ашыга идең, кунып каласыңмыни?» — дип, янә үртәргә исәбе бар иде, ләкин баягы горурлыгын җиңәргә азапланган кызның күңеле кителүен теләмәде.

— Яшерен-батырын түгел, чишмәдән су алып килгәнче китеп баргансыңдыр инде, дигән идем...

— Бу вакытта Казанга килеп төшсәң — ул бандит оясында нишләмәк кирәк? Төнлә транспорт юньләп йөрми, такси туктатсаң тагын — ялгыз кыз баланың кул күтәреп торуын дөрес аңламаслар... Шушы учак сүнгәнче таң атар әле. Зур эшләрне иртән башларга кирәк.

— Әгәр учак төн уртасында сүнсә?

— Керәм дә ятам вагоныңа, эчтән бикләнәм. Ә син, Фазыл әфәнде, утсыз күмерләрне тәгәрәтеп утырырсың. Лутчы сүндермә инде... Язгы төндә салкынча ул.

— Син — Казанга, мин — Казаннан...

— Шәһәрләр борын-борын заманнан ук сәүдәгәрләр өчен төзелгән, тауар алыштырырга базарлар кирәк булган. Мин базардан курыкмыйм.

— Ә миннән?! Әле милиция хезмәткәрләре килергә мөмкин. Сине минем кеше дип уйларлар. Суга барган җирдә сүзгә килеп кайттым...

— Кешедән куркырлыгым юк. Кирле-мырлы сөйләп маташма. Әгәр кул сузмасаң, беркая да китмим.

— Алайса, сер бирмәм. Бәлки, берәр атнага утырмага калырсың? Иптәшкә шәп кеше син.

— Тормыш иптәше кирәк мәллә?

— Юк. Иптәшкә ияреп йөри торганы кирәкми. Хатын кирәк.

— Өйләнәсе кеше арбаны юл читендә тугармый. Ат җигәргә вакыт.

— Бу вагон минем өчен тау астыннан тәгәрәде инде.

— Ярар, мин аны синнән сатып алам.

— Үзем өстәп түлим, рәхәтен күр.

— Башыңны кая куярга белмәгән көннәрдә килеп егылырсың, өске сәндерәдәге урыныңны саклармын. Гел син эзләп табардай җирдә тукталырмын.

— Сөйләшүебез сәхнәдәгечәрәк бара. Әллә уен, әллә чын, әллә мин шыттырам, әллә син үртисең... Кайсыбыз кунак — кайсыбыз хуҗа?

— Беләсеңме, Фазыл абый, кечкенә чакта, яз җитү белән, күрше-тирәдәге кызлар, җыелышып, бәрәңге бакчасына ябырыла идек. Кар астыннан юылып чыккан пыяла ватыкларын учыбызга җыябыз да тәрәзә каршындагы чирәмлеккә өябез.

— Кулыгыз киселмиме?

— Пыяла дигәч тә, чәчәкле тәлинкә ватыклары, чынаяк-чокыр китекләре, ислемай шешәләре ич ул. Без, аларны тезеп, үзебезчә өй бизәшле уйный торган идек. Һәркем үзенең уенчык өен бизәп бетергәч, бер-беребезгә утырмага киләбез, янәсе, кунакка йөрешәбез, күчтәнәчләр бирәбез... Бүген менә шул бала чагым искә төште. Минем бу вагонның эчен бизәп карыйсым килә...

## Сикеримме мендәреңә

Көндезге тәүбә төн уртасы өчен әйтелми.

Вокзал урындыгында төнге поезд көткәндә юлыккан очраклы күршең дә кайвакыт якын туганга әверелә.

Шәм яктысы вагон эчендәге бөтен серлелекне үз тирәсенә җыйган... Табада туралган уксын өстенә сытып кыздырган йомырка тәбәсе чыжылдый. Буйга ярылган яшь кыяр көнбагыш маена чыланган, савытыннан бөтен килеш төшкән балык консервасы янында телем-телем ак серкәле редис тәгәрәшеп ята. Кәгазь кирпечле ананас суы белән кагор шешәсе арасында буш стаканнар икеләнеп тора. Сыңар тәрәзәне йөзе белән каплаган кытай сөлгесенең эре бизәкләре шәм шәүләсендә биешә. Чәчәкле тартмада тезембәргә салынган шоколад конфетлар өстендә кул күләгәсе уйный.

Шешә бушагач, шәм ике тапкыр сүнде. Беренчесендә Гөлсөяр, кул сыртындагы черкигә сугам дип, ялгыш җил чыгарды. Анысын тиз кабыздылар. Икенче юлы Фазыл үзе юри өреп сүндерде һәм учындагы шырпы кабын урыны җәелгән сәке өстенә ыргытты.

— Бар, ал шырпыны!

Мин нәрсәгә кирәк инде сезгә дигәндәй, ашыгып-ашыгып янган шәм сүнгәч, табын өстенә төтен таралды һәм бу ис, борынны ярып кереп, кандагы шәрабның куәтен көчәйтә кебек иде. Ике арада сизгер караңгы тынлык урнашты. Һәркем үзенең уйларына чумды. Күченгән авылның ташландык инешендә ятим калган гыйшыклы бакалар хоры уйларны бүлдерми бүлдерүен. Ләкин тал-тирәктә чут-чут сөенгән былбыл тавышы сискәндереп ала, ике кешенең фикер тарафларын бер тирәгәрәк җыя. Җәйгә чыктык дисәң дә, яз ич әле бу! Тар урманнан чиксезлеккә чаклы байый торган кояшлары, колак төбендә тuктаусыз пышылдап коткы таратучы купшы җилләре, кулыңны сузсаң, сөйгән ярыңа килеп төртелерлек караңгы төннәре белән юлыңнан яздырырлык яз тагын килде... Әгәр син яшисең икән — язларың гамьсез үтәр димә! Фазыл белән Гөлсөяр яз уртасында калды.

Төнлә белән сәгатьләр әкренрәк йөри. Шәм сүнгәннән соң күпме вакыт узганын чамалавы кыен. Вагон эчендәге дөм караңгылык һәр хәрәкәтне фаш итәрлек эңгер-меңгергә алышынды, авыр сулышлар җиңеләйде, көчләр тигезләште.

Гөлсөяр, икеләнүләрен җиңеп, урынга барып ятты. Мендәрнең әле бер, әле икенче ягын әйләндерүе, кирәкмәгәнгә еш-еш тамак кыруы аның уяулыгын сиздерде, үзенчә йокыга каршы көрәшүе иде.

Әйе, төн уртасы пружиналарның да хәлен ала.

— Төшемә ниләр керер икән, Гөлсөяр, сыеныйм инде, яме?!

«Яме?» дигән ялварулы сорауга җавап ишетелмәгәч, Фазыл тәвәккәлләп ятакка якынайды. Идәнгә тезләнгән килеш кенә үрелеп, кызның мендәр читенә маңгаен терәп торды.

— Синең әле хыял кебек чагың, янәшәдә килеш кул җитми. Ашыктырмыйм. Минем янда иркенләп яшә. Сына. Күзәт. Өйрән. Купшы сүзләремнең ялтыравыгы коелсын. Ризалыгыңны алмыйча кагыласым юк. Түзәрмен, ике кулымны кесәмнән чыгармам... Гөлсөяр, җилкәмне терәп кенә яныңда ятып торыйм инде...

Колак төбендә шулчаклы өзгәләнүгә мәрткә киткән патша кызы да уяныр иде. Гөлсөяр дәшмәде. Карышу-нитүнең юклыгына тәмам инангач, Фазыл сагаеп кына урын өстенә үрмәләде. Бу минутта куркуын җиңәрлек тә көче юк иде, ул тын калып хәл җыйды. Йә Хода! Гөлсөяргә карата булган алгысыну тән сызлауларыннан да көчлерәк икән бит!

Фазылның бер кулы гына кесәсендә иде.

Гөлсөяр сикереп тормасынмы!

— Бәйләнә калсаң, төн уртасы димим, чыгып качам!

— Без өй бизәшле уйныйбыз түгелме соң, Гөлсөяр?

— Малайлар без бизәгән өйләрне җимереп китәләр иде. Яндыр утны, Фазыл абый! Караңгыга күрә батыраясыңдыр...

— Нинди утны?

— Әйе бит әле... Ярар, син йокла, Фазыл абый, мин китәм.

— Юк, китмисең, Гөлсөяр, мин хәзер ут кертәм.

— Төнге сәгать икедәме?

— Лампочкалары исән. Электр чыбыгы күпме кирәк — бар ул бездә. Багана ерак түгел. Китмә... Китсәң дә, үземне генә калдырма.

— Ут кертсәң, су китерсәң, мич чыгарсаң — өй була инде бу.

Кеткелдәп көлүенә караганда йокысы бөтенләй качкан иде инде кызның.

Фазыл, тай тышавы сыман бичәүкәне аягына киеп, сумаласы каушакланган багана буйлап менеп китте. Чалбар каешына бәйләнгән кабельнең очларын эләктергәч, вагонның ачык калган ишегеннән яктылык чәчелде.

— Ишекне яп, черки тутырасың! — дип, Фазыл биеклектән аваз салган иде, җавап багана төбеннән ишетелде.

— Бала-чага шикелле кычкырма инде.

— Кулыңда нинди ак әйбер ул, Гөлсөяр?

— Мендәр. Егылып төшә калсаң, аяк астыңа ыргытырмын дигән идем.

— Сикеримме мендәреңә?

— Син гел яшәүдән туйган кеше кебек сөйләшәсең...

Фазыл җиргә төшкәч, Гөлсөярнең сораулары күбәйде. Аларга бәйнә-бәйнә җавап биргәнче, ким дигәндә, тагын бер көн һәм дә бер төн кирәк иде.

## Улым дигәнгә үпкәләмә

Фазыл тар урманга кереп туктаган яшел вагон эчендә, ниһаять, сабыйларча изрәп йоклап ята. Ул хәтта Гөлсөярнең китеп барганын да сизми калды. Әлеге каенлыкны олы юл кисеп үтә. Машиналар җиленә күнегә алмаган бәби яфраклар һәр тавышка сискәнеп дерелди. Кышкы аклыктан яралган каен тузы керләнмәгән әле. Яшел вагонга кошларның исе китмәде, сайрауларын белделәр.

Төнне тыныч үтте дисәң — бик үк дөрес булмас. Кичкырын өч «Жигули» килеп китте. Вагон тирәли йөреп чыккач, тәрәзәне шакыдылар:

— Сезнең «комок»та аракы бармы? — янәсе.

Төн уртасында тагын уяттылар. Ике күләгә, «Беларусь» тракторы белән килеп, вагонның көпчәкләренә тибеп карады, тагып китәргә җайлы микән, дип, тәртәсен уңга-сулга каерып селкеткәләделәр. Шундый чакта ничек йоклап ятмак кирәк?!

— Кем бар анда? — дип җикеренде Фазыл, тавышын юри карлыктырып.

Һәм трактор, олы юлга чыкмыйча, тар урман эчләтеп авыл ягына сыпырды.

Инде яктырды, чакырылмаган кунаклар кирәккә-кирәкмәскә мазасызлап йөрмәсләр, дип, җан тынычлыгына инанганда гына, яшел вагонның калай кабыгына таяк белән суга башладылар. Ә бу вакытта Фазылның йокысына бик тәмле төшләр кереп килә иде. Язгы табигать дәрьясына чумган алты сәндерәле вагонда берүзе йоклап яткан буйдак ирнең нинди төшләр күрәсе билгеле инде. Фазыл, гыйшыклы төшләрдән арынып, тәрәзәдән караса — шәрә погонлы милиционер тегендә.

— Откройте! Ачыгыз! Юкса ишекне ватам. Мин ГИ-Бы-Ды-Ды инспекторы Шабаев! — диде ул, үз эше белән горурлануын яшермичә.

Фазылның бу егетне тәрәзә аркылы үртисе килде.

— Безнеңчә ГАИмы инде ул?

— ГАИ! ГАИ! Теләсәң ДПС! Инспектор дорожно-патрульной службы Шабаев! Праваңны давай!

— Ну шушы өч хәрефле сүзләргә тел ияләшми... ДСП, СНГ, СПС... Ниткән права ди ул, мин рульдә түгел бит?!

— Өйрәтмә, абзый, яме! Вагоныңның дүрт көпчәге дә таза, юеш балчыкка буялган. Димәк, әлеге транспорт чарасы күптән түгел генә урланган!

— Үземнекен үзем урларга, чарасыз калган карак түгел ич мин...

— Әкиятеңне протоколга теркәрбез. Ач ишегеңне, документларыңны давай!

Кемлегеңне исбатлыйсың килсә, шикләнгән кеше каршына расламаларыңны өеп куй. Документларыңны баш астына салып йоклый торган хәвефле заман хәзер... Утыз ел буе артезиан чишмәләр бораулавы турындагы хезмәт кенәгәсенә пенсиянекен дә өстәп, вагонны хосусыйлаштырганлыкка сертификат, страховка һәм ИНН саннары язылган шома кәгазьләрне, хәтта урта мәктәпне тәмамлаганда бирелгән холыкнамәгә чаклы, берсен-бер калдырмыйча, үзе белән йөртә Фазыл... Ләкин шәрә погонлы инспектор, боларына ышанам дигәндәй, паспорттан гайре язуларны сәндерәдәге йокы капчыгы өстенә ыргытты.

— Кая барасың бу атсыз арбаң белән?

— Энекәш, син дөньяга туганда, мин инде Актанышта кызлар сөя идем. Яшемә күрә булса да «сез» диярсең, бәлки.

«Актаныш» дигән сәяси сүздән сагаепмы, инспекторның тавышында тантаналы күтәренкелек кимеде.

— Шас, разберемся, кемлегеңне ачыклыйк әле. — Һәм ул, иншадан хата эзләгән укытучы шикелле, җентекләп актара башлады. — Беренчедән, бу паспортың СССР калдыгы, тиз арада алыштырырга кирәк! Икенчедән...

Инспектор, нидәндер җитди шикләнеп, вагонның ачык ишеге аркылы урамга кычкырды.

— Командир! Салих абый, бу кеше синең адреста прописке тора! Менә Водстрой урамы, беренче йорт... Шәп подделка, ичмасам. Ну ты влип, мужик! Яле, сәке астыңданиләр бар — наркотухамы, корал, урланган малларамы?! Сизеп торам, федераль розыскта кеше син...

Вагон эченә керүгә үк паспорт командир кулына күчте. Йокы капчыгы эченнән майка-трусиктан гына чыккан Фазыл, аңлашуның озакка сузыласын сизенеп, өске сәндерәдән күлмәк белән чалбар алып киде.

Командир дигәнебез, Фазыл паспортының беренче битен ачуга ук, аскы иренен салындырып кына елмайган төс чыгарды.

— Шабаев! Бар, машинаны сакла, селектордан берәр хәбәр килмәгәе, җомга бүген — аварияләр көне!..

Шәрә погонлы инспектор командирның әлеге әмерен көтелмәгәнрәк яңалык итеп кабул итте. Җитмәсә, лейтенантның үзен артык тыныч тотуыннан бераз каушады да бугай.

— Мин соң нәрсә, бик теләсәгез, икегезне генә калдырам... — Һәм ул Фазыл алдында мескен булып күренмәс өчен өстәп куйды: — Ә бу зимагурны бер йөз граммлык кына исерек иде, дип, акт яза торыйммы?

Фазыл күлмәк төймәсен командирга таба борылгач каптырып бетерде:

— Нәрсә инде сез, мине йөз граммнан исергән иде, дип мыскыллап торасыз, авылдашлар алдында оят, язгач-язгач: «Берүзенә бер литр аракы эчеп бетергән, ищу акыл өйрәтерлек хәлдә», — дип өстәгез!

Лейтенант яшь инспекторны куып дигәндәй чыгарды.

— Бар инде, Шабаев, бар, диләр сиңа! Кәгазь әрәм итмә анда. — Һәм ул, икәүдән-икәү генә калгач, Фазылның ябык паспортын җилләвеч итеп, болай да салкынча вагон эчендә үзенең янып торган бит алмасын җиллэтә башлады. — Шәмсетдинов Фазыл Сәләхи улы; Шәледә туган, гомере буе кырда яшәсә дә, Казан кешесе дип саналган; егерме биш ел элек алты яшьлек улы белән хатыны Язиләне, өч бүлмәле фатирда калдырып... ташлап киткән.

Үзенең кыскача тормыш юлын моңарчы бервакытта да башкалар авызыннан ишеткәне булмагач, Фазыл, язмышындагы ялгышларны барларга әзер торгандай, аяк очына гына карап зур кызыксыну белән тыңлады. Ләкин погонлы күрәзәченең паспортка карамыйча да төгәл хикәяләве абзагызны сагаерга мәҗбүр итте.

Алар, күзгә-күз карагач, икесе дә беркавым тынып калдылар. Яшел вагонның ачык ишегеннән янә тургай тавышы ишетелде... Лейтенантның маңгаен киң итеп күрсәтердәй кыска чәче, ярымтүгәрәк калын кашлары, җәенке борыны, сирәк һәм коңгырт мыегы — нәкъ Фазылның паспортындагы беренче фотога охшаган. Яшькелт күзләрен кысыбрак хәйләкәр елмаеп тора икән — бу охшашлыкны киметми, киресенчә, якынайта гына. «Мин синең турыда бөтенесен беләм, әйтеп кәефеңне бозасым килми инде» дигән чакларда, серле әңгәмәдәшләренә Фазыл үзе дә нәкъ менә шулайрак итеп сынаулы карый торган иде.

Лейтенант үзенең киләчәген зурайткыч пыяла аркылы күргәндәй хис итте... Каш җыеруга маңгаена килеп чыга торган әзер җыерчыклар хәйран тирәнәячәк икән; борын шул ук калачак; ияк очындагы чокырчык саега; мыегының төсе уңа, ә чәченә чал кермәячәк. Буй-сынына, сабан туе батырыдай нык торыклы бәдәненә игътибар итсәң, киләчәккә карата авыр сүз әйтерлек урын юк. Яшеңә күрә болай сакласаң — сөбханалла! Әмма бу кешенеке шикелле язмыш кичәргә теләми Салих.

— Синме бу?! — диде Фазыл, соклану, каушау, сөенеч һәм көенечнең барсын бергә бутап.

— Әйе, мин... — диде Салих, артык исе китмичә генә. Әйтерсең лә ул әлеге очрашуга күптәннән әзерләнеп, сиздермичә сагалап йөргән.

— Чынлап та синме соң бу?! — диде Фазыл тагын бер кат.

— Әйе инде, мин! — диде Салих, җавабын җөпләп.

— Исәнме, улым?! Улым дигәнгә үпкәләмә...

Боларны читтән күзәтеп торучы булса: «Соң, җанкисәкләрем, кул биреп күрешегез хет!» — дияр иде. Каушадылар шул...

## Хушлашканда нихәлме?..

Гомереңнең беренче яртысында югалтулар күп булса — калган соңгы яртысында көтелмәгән, дөресрәге, очраклы дип әйтердәй очрашулар күбәя икән. Аңлашылса кирәк, гомерне ике тигез яртыга бүлү мөмкин түгел. Әмма икегә бүленгән алманың зур кисәгенә кечкенә кисәген капласаң, барыбер бөтен алма булып күренер...

Улы Салих — ир уртасы яшенә җиткән. Фазыл аны бервакытта да эзләмәде. Ике арада почта аша акчалар гына йөрде. Язиләгә карата булган нәфрәт Салихны күрергә теләүдән көчлерәк иде. Мин кыр кешесе, дип акланма икән, кырларның да күрештерә торган юллары бар. Әнә Салих ятимлектән сорау алырга килгән намус кебек басып тора. Фазылның җавабы юк. Мондый очракта сүзне уенга бору хәерлерәк.

— Мин, улым, ташбака кебек, өемне үзем белән сөйрәп йөрим.

Салих озын гомерле җир-су хайваннары отрядына иш килерлек табылдык этисенең шаяртуына бирешмәде. Ул, аның яшәү рәвешен чамаларга теләп, вагон эчен күздән кичерде. Шырпы тартмасы калынлыгы стенага йөз иллеле кадак кагып, «Альпинист» радиоалгычы элгәннәр. Түшәмнән салынган тимерчыбык асбест торба кисәген күтәреп тора — үзенчә электр мичедер инде — бик теләсәң, эченә кабыклы бәрәңге тәгәрәтеп пешерергә була. Ишек төбендә калай «буржуйка» дүрт аягын күтәреп ята — ток беткәндә, гамәлгә ярый торгандыр. Пәрдә, кашага, келәм урынына соры стенага кино индустриясенең элеккеге артистлары ябыштырылган.

— Син, улым, менә бу сәкегә утыр. Өч табуреткабыз бар иде, Гена Ипполитов дигән бер хөрәсән буржуйкага якты. Культуралы көтүлеккә кое бораулаганда ут сүнгәние, салкынга чыдый алмадык. Калай савыт белән солярка ягып та җылыта торганыек. Төрле чак була инде... Җылы җәй кыска бит ул.

— Сугыш елларында абзар-кураларны сүтеп якканнар, ди ич.

— Сугышның беткәне юк аның, улым, кемне кайда куып тота — шунда егып сала... Болай гына әйтүем. — Фазыл сызлануы хакында сүз чыгарырга теләмәде.

— Башкаларыгыз кая соң?

— Төрлебез төрле якка таралыштык. Бораулау станогын сүттеләр, су ташый торган машинаны саттылар. Ә бу вагон минем өлешкә тиде... Монголия келәме белән бергә.

Салих, афишадан афишага күчеп, вагон стенасыннан келәм эзләгәндәй иткәч, Фазыл сабыйларча акланырга кереште.

— Шәп иде, икегә өч метрлы... Савин бистәсендә фатирда торган чагында урладылар. Һәй, аның белән вагонда нишләрсең? Хәрәм булган ул миңа... Пенсиягә чыгарыр өчен кул җылысы, имеш.
— Пенсиягә?! Иртәрәк ич әле сиңа!
— Безнең эштә ирләр иртәрәк сына, улым. Таныклыгымны синең инспекторыңа да күрсәттем.
— Аварияда-мазар имгәндеңме?
— Чумарага кое бораулап маташканда, Ходай җәзалады... Сиксән ике яшенә чаклы яшәп, әни мәрхүмә миңа күпме изге теләк теләде! Шуларның берәве генә кабул килде.
— Гаилә мәшәкатьләреннән иза чикмә, дигәнеме?
— Юк шул. Хәләл көчең белән яшәргә насыйп итсен, Ходай сине хәрәм малдан сакласын, амин, дигәннәре рас килде... Ә инде гаилә җылысы күрергә мәхрүм булсын, дип, мине бары тик синең әниең генә каргый ала. Ләкин Язиләнең каргышы төшмәячәк миңа.
— Ышанма! Белмәссең бу дөньяныкын!
— Әти кешеләрнең улларына әйтеп бетерә алмый торган серләре бар.
— Мин үзем дә әти хәзер, Фазыл Сәләхиевич, синең оныгың бар. Бабай кеше инде син, бик беләсең килсә. Ә бабайлар вагон түбәсе астында йокы капчыгы эчендә йоклап ятарга тиеш түгел, синең урын җылы мич башында...
— Ашыкма, улым! Минем әле санаулы көннәрем бар.
— Ник соң юл өстендә туктап калды вагоның?
— Бер «ЗИЛ»га таккан идек, илле чакрым да үтмәде, радиаторы кайный башлады.
— Агыйделнең аръягында бер инәгә бер сыер, барып карасаң, бернәрсә дә калмаган, ди, Фазыл Сәләхиевич...
Салихның «әти!» дип әйтергә теләмәвенә һич үпкәләмәде Фазыл, үртәлде генә. Белә бит инде ул, «әти» дип әйтергә күнекмәгән телне ярты сәгать эчендә ялына-ялына өйрәтү мөмкин түгел. Алимент түләп торган өчен генә әйтелми ул сүз. Хәтта җибәргән акчаларың колхоз председательләренең айлык хезмәт хакы чаклы булса да. Ялгыз ана кулында үскән малайлар ташлап киткән этиләргә әнисенең үче белән карый. Һәм үзеннән дә мескенрәк күренгән ир кешегә балалары «әти!» дип ягылырга ашыкмый. Аның иң авыр сәбәбе менә шушы — соңгысы. Улының «Сәләхиевич» дип дәшүенә шуңа күрә үртәлә Фазыл.
— Үзең гел Актанышны сагынып яшисең икән, ә үзең гомер буе әни янында пропискада саналасың.
— Мин Язиләдән дошманлашып китмәдем. Әгәр пропискадан төшкән булсам, әниегез белән сезне урамга куып чыгаралар иде.
— Ничек инде урамга?! Минеме?! — Салих фуражкасын төзәтеп куйды.
— Синең әле лейтенант булганыңа күп түгелдер. Ул елларда Гражданнар Кодексында 334 нче статья бар иде. Эш урынына бәйле фатирдан куып чыгару турында... Сездән киткәнне ишетеп, «Ак Чишмә» абзыйлары мине судка бирделәр. Имеш, хәзер бу гаиләдә безнең эшчеләр юк, димәк ки, ведомственный фатир бушатылырга тиеш. Һич онытасым юк, 1975 елның унбишенче мае иде бу.
— Һәм син...
— Әйе, алдан ук кисәтеп куелган көнне, судтан вәкил килеп, күршедән ике кешене пүнәтәй итеп чакырдылар, «Ак Чишмә» прорабы Кислов, ике грузчик... Кыскасы, алтау җыелдылар да йорт җиһазларын исемлеккә терки башладылар.
Урамда күмер вагоны чаклы машина, төйисе дә «Ак Чишмә»нең складына илтеп биклисе.
— Урланган мал түгел ич инде ул...
— Әйе. Законнарыгызның ни икәнен сиңа аңлатып торасы юк. Теләсә кайдан берәр почмак тап та шунда ташы үз әйберләреңне — пожалысты, сүз әйтмиләр, ләкин фатирны бушат.
— Һәм син...
— Юк, мин түгел, әниең! Язилә мине кирәксә Татарстанның теләсә кайсы почмагыннан эзләп таба торган иде... Әгерҗегә сигез сәгать поезд белән барып, станциядән кырык чакрымдагы Таңсар авылын табып, кибетләренә кереп, кайда ул, дип, бер генә сораган... Мине эзләп таптылар... һәм миңа суд вәкиле әзерләгән спектакльдә катнашырга туры килде.
— Әнине яраткансың, димәк...
— Синең хакка, улым. Кечкенә баласын сөйрәп Язилә фатирдан фатирга йөрмәсен, дидем... Килеп керәм ул көнне, берни белмәгәндәй... Өй тулы кеше. Һай, минәйтәм, кунаклар бар икән, син нәрсә инде, Язиләкәем, табын әзерләмисең, өстәлне дә ишек катына куйгансың, дим. Үзем күн итекне салам, үзем тагын әниеңә дәшәм, хатын, коры носкиларны китер әле, болары белән суга баттым, дигән булам. Әниең Суфия әбиеңнең йон оегын китереп бирде, аркамнан сөеп, грузчиклар килеп ябышкан шифоньерга киемнәремне элә башлады... Пүнәтәйләрнең күзе шакмак булды. Грузчиклар, тәмәке тарткан ише кыланып, урамга шылдылар. Суд вәкиле прорабка текәлде, прораб миңа: «Син гаиләңне ташлап китмәдеңмени?» — дип, кул биреп күрешә үк башлады. Мин суд вәкиленә паспортымны сузам, ә үзем прорабка җавап тотам: кайсы бораулаучының үз гаиләсендә яшәгәнен күргәнең бар, минәйтәм, өйдә ятып бораy-

лаган коеның суы чыкмый аның. Без бораулаучылар кыр эшчеләре, сез прораблар гына ул, скважина тапшырырга киттем, дип, командировочныйлар аласыз да өегездә ял итеп ятасыз, дим...

— Ышандылармы?

— Ышанмыйча! Иң мөһиме — паспортта пичәт бар!

— Һәм син...

— Әйе, шуннан бирле әниең яныннан пропискадан төшмәдем. Кырдагы кешегә кайда язылса да барыбер түгелмени?!

— Өч бүлмәле шәһәр фатирында туып үскәнем өчен тагын бер кат бурычлы икәнмен әле мин сиңа...

— Бурыч нәрсә ул, бурыч ул кешеләр арасындагы ялган дуслык кына. Ә дуслык белән туганлык — икесе ике нәрсә.

— Алайса, Актанышка туганнарыңны эзләп китешең инде?

— Улым, сиңа мин дөресен сөйләргә оялам.

— Әнидән соң сөйгән кызларыңны эзләп йөрисеңме, шуңамы ояласың?

— Әниеңә кадәр сөйгәнен, улым, күңелеңә авыр алма.

— Элегрәк булса, әни өчен көнләшер идем, бәлки... Ә хәзер үземнең дә гаиләмне саклыйсым бар... Әни белән икегезнең язмышны кабатламас өчен, сезнең турыда күбрәк беләсем килә.

— Белеп бетерә алмассың, улым.

— Син бая «дуслык, туганлык» дидең. Әмир бабай мактап бик еш искә ала иде үзеңне, бергә эшләгән чакларыгызны сагына.

— Ә ул мәрхүммени?

— Исән әле.

— Ник, алайса, «иде» дип сөйлисең?

— Әби белән бабай янына сирәк барам хәзер. Безнең эшне беләсеңдер — гел дежурда, ялыбыз — санаулы. Күптәннән күргән юк. Әмир бабай эзли сине.

— Әниеңә әйтсәме... теләсә, ике сәгать эчендә таба!

— Юктыр. Әни эзләргә теләми инде.

Ул арада патруль машинасының улап-улап кычкыртуы ишетелде һәм, күп тә үтмәде, вагонның ачык ишегеннән тагын инспектор Шабаевның гәүдәсе күренде.

— Командир! Җитмешенче чакрымда бик хәтәр авария! Бер редактор һәлак булган. Срочно безне чакыралар.

Фазылның улы Салих шул мизгелдә үз вазифасына керде, табылдык этисен дә, эти нигезенә әверелгән яшел вагонны да онытып, патруль машинасына ыргылды. Фазыл, хәвефле хәбәргә ияреп, ирексездән улы артыннан йөгерде.

«Улым!» дип өзгәләнеп кычкырганда, инде бер кулы белән рульгә тотынган лейтенант кисәк иңрәп куйды. Ә Фазыл «улым!» дип кабат дәшкәндә, Салих, кабинадан чыгып, ике арадагы сукмакны тизрәк кыскартырга теләгәндәй, аңа таба ике-өч адым атлап өлгерде. Әллә ашыгу этәрде, әллә этисенең ялварулы күз карашы мәҗбүр итте, бәлки, саубуллашырга оныта язганмын дигәндәй, гафу үтенергә теләгәндер — Салих аны кочаклап алды:

— Нихәл соң син, эти?!

— Исән йөр, улым, яме... Бигрәкләр үземә охшагансың... Синең дә эш урының юлда икән!

Улының бу урынга яңадан әйләнеп киләсен сизенә ул. Салих карурманнан олы юлга килеп чыккан этисенә киңәшләр яудырыр, үгетләп-үртәп заманча яшәргә өйрәтеп, үзенчә ярдәм итәргә теләр. Ләкин бер гаиләнең икенче гаиләне яшәргә өйрәтергә хакы юк — хәтта газиз улың булса да...

## Дөнья матур бит, әй!..

Кич җиткәч, дөресрәге, урам базары ябылгач, Гөлсөяр кайтып төште. Шакмаклы сумкасының йөге кимегән, аның каравы икенче кулындагы сеткасы кала күчтәнәчләре белән бөселгән иде.

— Фазыл абый, ач ишекне, кулым буш түгел, — дигән таныш авазга ничек сөенүен тасвирлар өчен купшы сүзләр җиткереп булмас иде. Мәгәр сер бирмәде, үзен тыеп, тавышсыз-тынсыз юри ятуын белде. Кайткан икән, кермичә китмәс, шәт. Дарулар китергәнме, яңадан сырхауханәгә ятарга үгетләрме, әллә кызганудан юатып йөрүе генәме? Һәрхәлдә, шушы өч сорауның берсенә төгәл җавабы бардыр кызның...

— Әллә, Ходаем, авыртуга түзә алмыйча, йөрәгең шартладымы? — Вагон эченә керүгә, Гөлсөярнең беренче сүзе шул булды. Һәм ул, сәке читенә тезләнеп, йөзтүбән яткан Фазылның гәүдәсен әйләндерергә теләде. Абзагыз әйләнү уңаена, күзләрен ачарга оялып, йөзен кызның күкрәк астына терәде. Тегесе карышмады, киресенчә, авыр сумка күтәрүдән вакытлыча бөкшәеп калган бармакларын җылы тарак итеп, аның йомшаклыгыннан чуаланган чәчләренә кагылды.

— Сине бүтән күрмәм, ахрысы, дип котым очты.

— Бер көн эчендә үк шулхәтлек гашыйк булмыйлар инде, Фазыл абый!.. Фазыл абый... Кофтаны юешлисең...

— Еламыйм ич мин!

— Беләм, Фазыл абый, барыбер күз яшенең табы кала, — дисә дә, Гөлсөяр сәкедән төшәргә ашыкмады. — Бүген мин бер китап алып кайттым... Тән сызлавы турында Европа табибларының йөздән артык хезмәтен туплаганнар. Эзләп таптым мин сине интектергән нәрсәне. Исеме әйтеп бетергесез катлаулы аның. Бехтерев авыруы дип, гади итеп, безнең илдә генә атап йөртелә икән ул.

Һәм Гөлсөяр җыелмаган урын өстенә күн пинжәген салып ыргытты да, кофта җиңен сызганып, вагон эчендә арлы-бирле йөренә башлады... Кыяфәтендә җиңүчеләргә хас тантана иде аның. Әйтерсең лә ул бүген, Казан юлында очратып, Әҗәлнең үзен тукмап кайткан һәм Фазыл янына килерлеген калдырмаган.

— Мин китапларга ышанам, Фазыл абый! Анда язылган буенча син инде күптән үлгән булырга тиеш.

— Нишләп һаман исән соң әле?!

— Димәк, диагнозны дөрес куймаганнар. Бехтерев авыруыннан кеше кыймылдый алмый, тамагына үтми, умыртка баганасы бамбук сыман кибә, диелгән. Ә син багана башына менәсең, суга йөрисең, чиләкләп йомырка ашыйсың, олы юлдан кызлар ташыйсың. — Гөлсөяр соңгысын үзенә ишарәләп әйткән булды.

— Яңадан бүлнискә кереп ятарга кушасыңмы?

— Әйтә алмыйм. Менә ул китап — Бухарестта басылган, укып чык та үзең хәл ит. Шунысын белдем — ничек дәваларга дигән өлешендә йөз төрле чирнең һәркайсына да массаж ясарга кушкан.

— Массаж ясаучыны каян табарга кирәген әйтмәгәнме?

— Акча күрсәтсәң, унысы берьюлы йөгереп килә. Тик синең әле кризис чоры үтмәгән. Көчле авырту вакытында массаж ясау тыела.

— Каян беләсең соң син боларны? Әлеге китаптан укыдыңмы?

— Юк. Үзем беләм. Минем әти ел буе йөрәк чәнчи, дип йөрде. Тикшерделәр, җәфаладылар, гаебен тапмадылар. Кулбаш сөягенә массаж ясагач кына котылды. Акча түләп махсус курсларга йөрдем мин. Хәзер массаж ясар өчен врач чакыртканыбыз юк.

— Алайса, китап укып вакыт әрәм итмик... Үзең тотын!

— Фазыл абый, әгәр начараеп китсәң?!

— Кукушкин үләргә кушты бит инде. Кулда кәгазе бар. Көтеп озакка сузасы юк.

— Фазыл абый, ни сөйлисең син?!

Юлдан кайткан кеше, бәлки, тамак ялгап, чәй эчеп алырга тиеш булгандыр да, тик Гөлсөяр вакыт әрәм итмәде. Ул инде әлеге сөйләшүнең азагы ни белән бетәчәген алдан ук белә иде.

Беренче мәлдә җилкәгә иркәләп-назлап кына орынган мамыктай куллар акрынлап тимергә әверелде кебек. Һәм алар, Фазылның гәүдәсен сүтеп җыярга теләгәндәй, боргычлады, төйде, йомарлап алып яңадан җәйде, какшатты, өзде, ялгады... Билгә кереп кадалган сызлау эреп, бөтен аркага таралды. Кыз аның саен сөйләндерә торды. Ыңгырашудан тыелып, йөзе белән мендәргә капланган Фазыл авыртудан шабыр тиргә батты. Алай да сорауларны җавапсыз калдырмады.

— Фазыл абый, аңыңны югалтсаң, туктыйм. Минем белән сөйләшеп тор, яме!

— Ярар.

— Врачлар үзләре массаж ясау, үлән белән дәвалау, зоотерапия, күрәзә кебек чараларга бик ышанмыйлар.

— Мин ышанам.

— Әгәр түзсәң, көнаралаш унике сеанс ясап карыйм.

— Ул хәтле көтәрлек вакытым юк. Көн саен кирәк.

— Ярты сәгатьтән ары ярамый.

— Арсаң әйтерсең, Гөлсөяр.

Беренче кичне Фазыл массаждан аңын югалтмады. Моны күреп Гөлсөярнең өмете үсте. Иртән уянгач та ул, күрше сәкегә үрелеп, аның сулыш алганын тыңлап сөенде. Иртәнге йокы — иң сихәтле ял. Кыз бүген, базар сумкасын күтәреп, олы юлга чыкмады, абзыйның хәле көтмәгәндә кискенләшмәгәе, дип, янында саклап утырырга булды.

Икенче кичне, Гөлсөярнең кулы кагылуга, Фазыл кичәгедән дә ныграк авырту кичерде. Ләкин үзе тавышын көр тотарга тырышты.

— Из, ныграк боргычла, сызлау иркәләнеп ятмасын, бир кирәген! Рәхмәт! Әнә шулай!

Өченче кичне Фазылның тәне Гөлсөярнең кулын тоймады. Кагылган бөтен җиренә өшеткеч укол ясалган кебек иде.

Дүртенче кичне ул, массаждан соң, таң атканчы уянмыйча йоклады. Һәм иртән аның беренче сүзе гаилә башлыгына хас таләпчәнлек белән яңгырады: «Ашыйсым килә!»

Бишенче көнне иртән Гөлсөяр базарга сату итәргә китте. Фазылның: «Йөрмә интегеп, ял ит бераз. Акчам җитәрлек ич!» — дип ялварулары заяга гына булды. Кыз яшел вагонда үткән көннәрне әзергәбәзер яшәп яту дип аңлады, күрәсең.

Үзе генә калгач, вакыт агышы тагын әкренәйде. Бераз көн үтәр, ичмасам, дип, ул теге ташландык авыл чишмәсенә суга китте. Тал-тирәкләр арасында бораулау агрегаты күренми, сырлы калай белән тышланган вагонны алып китеп, аның урынында сыерчык оясына охшатып кечкенә сарай корганнар.

Бил сызламый хәзер, оеп авырта гына. Су алып кайтканда, ул, тукталып, кыйбла якка карап торды. Фазыл, үзенең йөзендәге елмаюны тоеп, сөенеченнән күзләрен йомды, тәненә көч булып кояш энергиясе җыелганын сизде. Өмет, сихәт, куәт, яшәү һәм мәхәббәтнең һәммәсе дә бар иде бу халәттә... Ә шулай да якты дөнья искиткеч матур бит, әй!..

## II. ӘМИР

### Сиңа — вагон, миңа — «джип»...

«Ак Чишмә» хуҗасы Наил Кадыйрович килеп төште.

Ул диңгез дулкыны төсендәге елкылдап торган өр-яңа «джип» машинасын буяулары купшакланган яшел вагон янына китереп туктатты.

Гөлсөяр, учактагы утлы күмерләргә өрә-өрә, корымлы табада маргарин кисәге эретеп азаплана иде.

Яшерен-батырын түгел, үзенең элеккеге начальнигын сагынып өлгермәгән иде әле Фазыл, шуңа күрәме, кул биреп күрешкәндә, йөзенә әллә ни куаныч чыгармады. Йомырка тәбәсен вагон эченә күтәреп кергәндә: «Әйдә, Наил яшьти, чәй эчәбез», — дип әйткәне дә таба чыжылдавын җиңә алмады. Наил Кадыйрович үзе әрсезләнеп табага ияреп керде, сәкегә килеп утыргач, кашык тоттырганнарын әдәпле генә көтеп утырды. Утлы күмерләрдән яңа гына котылган табада май куыкларының шартлап ярылуын исәпкә алмаганда, өч кеше арасында урнашкан сизгер тынлыкны билгесезлек чарасы дип атап булыр иде. Гөлсөярнең эндәшмәве билгеле — ул әле чакырылмаган кунакның кем икәнен белми. Ә Фазылның ни өчен сүз башларга теләмәвен начальник бик яхшы белә.

— Безнең илдә начальникларны сөймиләр... Ләкин хөрмәт итәләр, дип әйтә торган иде элеккеге бораулау остасы Фазыл Шәмсетдинов.

— Кая барышың иде? Кара тәрәзәләр аркылы ничек танып туктадың әле син?! — диде Фазыл, «әссәлам»гә «вәссәлам» кайтарып.

— Зур эш белән килдем.

— Килдем?! — Фазылның сул яңагы тартышып куйды, әллә үртәлүе, әллә ачуланырга теләве булды, аңламассың. — Адрессыз зимагурга килмиләр, аны эзләтеп табалар.

— Ярый, синеңчә булсын, таптым дип исәплә.

— Минем кайдалыгымны беркем белми ләбаса.

— Ник белмәсен... Әмир бабагыз белә. Аңа улың Салих әйткән.

— Сине эзләп килергә мәҗбүр итәрлек ниләр сөйләп кызгандырды икән?

Гөлсөяр күмер капкандай сикереп торды.

— Мин чыгыймммы? Рәхәтләнеп әрләшегез.

— Юк, кызый, тик утыр урыныңда. Наил белән безнең ике арада бүлешердәй мал калмады инде. Мелиорация министрлыгын таркатканда, мине инвалидлыкка чыгарып эштән кудылар. Яңа байлар базарына иске вагон сөйрәп кердем. Аерылганда безнең җитәкчеләр симез казны Хуҗа Насретдин кебек бүлә белә: сиңа — вагон, миңа — «джип». Без коелар бораулап йөргән арада, болар СССРны хосусыйлаштырып куйганнар...

Фазыл таба төбен бүлгәләгән йомры башлы пычакны ипи сыныгы өстенә ыргытты. Интеллигентларча зәвыклырак итеп әйткәндә: «Рәхим итеп, күз алдымнан югалсагыз, сезне тагын ун ел күрмәсәм дә риза!..» — дигәнне аңлата иде бу. Ләкин Наил Кадыйрович үзен тыныч тотты: «Рәхмәт!» — дип, әлеге пычак белән бер телем ипи кисеп алды, өстенә тәбә кисәге каплап, бутерброд итеп капты. Сабырлыгын җыеп түзә икән, димәк, бүгенге визитның сәбәбе җитди.

— Беренчедән, Фазыл, эштән бер сине генә кумадылар, бөтенебезне тараттылар. Аннан соң, вак-вак «АО», «ООО»лар оештырып, кире җыя башладылар. «Бегущая строка»ларга белдерү биреп, телевизор аркылы ай буе эзлибез инде без сине. Ярый әле улың күргән, ярый әле Әмир бабаена кайтып сөйләгән. Ә син таптык дигәнгә ышанмыйсың.

— Әллә берәр орденым эзләп таптымы?

— Юк, яшьти, начальствоны яратмаган кешегә орден бирмиләр хәзер.

— Сиңа нинди орден кирәк, Фазыл? — дип, сүзгә ияРде Гөлсөяр. — Базардан любоен сатып алам.

— Сез аңа телевизор алып кайтыгыз, кулга күтәреп йөри торганны... Гафу итегез, исемегезне белмим... Фазыл, таныштыр инде безне.

— Үземнең дә рәтләп танышканым юк әле. Исемен генә беләм: просто Гөлсөяр!

— Мин инде, әллә чит илләргә чыгып, Язиләңә пластик операция ясатып кайттыгыз микән дип торам. Үзе яшь, үзе...

Гөлсөяр Наил Кадыйровичка комплиментлар тезеп китәргә ирек бирмәде:

— Баш ватмагыз, мин үзем шундый чибәр, әйе, әллә ни карт түгел, уртача дияргә була, ну уртачадан бераз яшьрәк.

— Гөлсөяр белән без... — дип ни акланырга теләгәндер Фазыл, ләкин кызый ирек бирмәде:

— Ир кешене акча яшәртә, егетләр.

Ике арада киеренкелек кимеде. Наил белән Фазыл, алюминий кашыклар белән төртешә-төртешә, таба төбендәге касмакны кыра башладылар. Гөлсөяр консерва ачмакчы булды.

— Юк, — диде Наил, аны туктатып, — закусканы әрәм итмә.

— Ә бездә кичә эчелеп бетмәгән кагор бар.

Гөлсөярнең бездә дип әйтүенә Фазылның сөенүен күрсәгез — ул хәтта, дулкынлануын тыя алмыйча, кул очы белән кызның ялангач беләгенә орынып үтте: «Әйбәт әйттең!» янәсе.

— Наил Кадыйрович рульдә бугай.

— Юк, мине шофер йөртә.

— Ник соң аны чакырмыйбыз?

— Юк инде, Фазыл. Ул эш урынында көтеп утыра. Шоферлар хуҗаларының ни сөйләгәнен тыңлап, күпме эчкәннәрен санап йөрергә тиеш түгел. Минем особый случай өченгә саклап йөрткән бер коньягым бар...

Һәм Наил, ишектән башын тыгып, шоферга кычкырды.

— Вәли! Теге коньякны китер әле. Бардачокта ачылган шоколад булыр.

«Джип»ның ишеге ачылып киткәч, кара тәрәзә артында качып утырган күләгә олы гәүдәле, зур авызлы ямьсез, әмма сөйкемле егеткә әверелде. Ул алып килгән күчтәнәчне җирдә килеш кенә вагон эченә сузды һәм зур авызына тезеп тутырган вак тешләрен җемелдәтеп елмайды да янәдән кара тәрәзә артындагы күләгәгә әверелде.

Коньякның йолдызлары юк иде. Гөлсөяр, шикләнеп, аны кулында әйләндергәләде. «Реми Мартин Х.О» дип, тышындагы язуны таныганча укыды. Бәрәңге боламыгы төя торган тукмакка охшаган шешәнең һәр киртегең, һәр уентыгын тырнак очы белән капшап чыкты. Шуннан соң гына:

— Татар коньягы икән, исеме латин имласы белән язылган, — дип, шешәне егетләргә бирде.

Камыш бөке бораусыз гына ачыла торган итеп эшләпәләп төелгән иде. Фазыл пластик стаканнарның өчесенә дә тутырып салгач, Наил, тыела алмыйча, кеткелдәп көлә башлады. Ул көлгәндә, колак мендәре чаклы корсагы селкенеп, вагонны дерелдәтә иде сыман.

Бу көлүне Гөлсөяр үзенчә аңлады.

— Коньякны стакан тутырып эчмиләр, Фазыл!

— Әй, кырык градуслы булгач, барыбер түгелмени...

— Сез әле аның бәясен белмисез. — Наил көлүеннән һаман туктый алмады. — Белсәгез, бәллүр уймаклар эзләп, Казанга җибәрер идегез.

— Соң инде.

— Ашыкма, Фазыл, бәясен белик инде.

— Әйтмим! — диде Наил, көлүеннән көчәнеп туктап.

— Алайса эчмибез.

— Барыбер түгелмени, Гөлсөяр, аны хәзер кире тутырып булмый инде. Бүләк ич ул.

— Әйтсен! Минем беләсем килә. Мондый коньякны күргәнем юк. Нәрсә эчкәнемне кызларга сөйләрмен.

— Алайса, Наил Кадыйрович, әйт тизрәк. Юкса коньяк җылына.

— Мин моны ипподромның «Алтын дага» ресторанынннан алдым, — дип, тыныч кына, сүз уңае гына әйтеп куйды Наил, — биш йөз утыз долларга.

— Уналты мең сумгамы!!! — Гөлсөярнең шоколад сыныгы тоткан кулы авыраеп төште. — Әти белән әнинең өч айлык гаилә бюджетын эчеп утырабызмы? Бу акчага балалар йорты өчен китапханә сатып алып була лабаса!

— Ярар, күрешүдән сәясәт ясамыйк инде, синең белән минем кесәгә кермәгәннәр ич. — Фазыл үзен тыныч тотарга тырышты, ләкин стаканга үрелерлек көч тапмады. — Аның белән генә Наил Кадыйровичның акчасы бетмәс.

— Акча бетми, Фазыл абый, — диде Гөлсөяр, үзе дә сизмәстән кичәгечә «абыйлап», — акча ул бер кесәдән икенчесенә күчеп кенә йөри. Сиңа керсә — миннән чыга...

— Вәт-вәт. Нәкъ менә шул турыда сөйләшергә килдем мин Фазыл янына.

Алар коньяклы стаканга карап беркавым сүзсез калдылар. Әллә бер йотымы мең сум торган эчемлек гипнозлады, әллә моңарчы сөйләнгәннәрне сызып ташларлык үзгәреш көттеләр... Ниһаять, Наил сыгылып торган стаканны билләп тотты. Аңа Фазыл иярде.

— Тост әйтегез инде хет, — диде Гөлсөяр, ниһаять, тәвәккәлләп.

— Тыңлагыз, — диде Наил. Ул әлеге очрашуның әйдаманы булырга тели иде. — Үзем әйтәм... Татар халкы ашамыйча кырык көн түзә ала, су эчмәсә — җиде көннән үлә, ә эшсез бер генә көн дә түзалмый... Әйдәгез, кешеләрне ризыклы һәм сулы иткән кое бораулаучылар хакына күтәрик...

Коньякның хакына карап градусы артмый, бары тик тантанага затлылык, нәзакәтлек һәм бәрәкәтлелек кенә өстәлә. Савытны йотымлап бушаткач, нишләтер икән бу безне дигәндәй, маҗара көтеп бераз тынып тордылар. Ләкин маҗара күзгә күренмәде, кәеф күтәренкелеген исәпкә алмаганда, фикер йөртү сәләте үзгәрмәде. Җырлыйсы-биисе, буш вәгъдәләр бирәсе, якын туганнарча антлар әйтәсе килмәде.

— Яшермичә генә әйт әле, Фазыл, хезмәттәшләреңне сагынасыңмы?

Наилнең, рәсми сөйләшүгә күчәргә вакыт дип, башланган җөмләсе Фазылга тагын бер шешә хәмер өстәгәндәй булды. Кеше организмында, күңеленең иң нечкә кылларына кагылган очракта, җанны кинәт исертә торган берәр биологик матдә качып ята микән әллә?! «Сагынасыңмы?» дигән сүз барып житте Фазылга: кан тамырларында энергия бәргәләнде, муены башны күтәрә алмастай хәлсезләнде, күзләре авырайды, бөтен көч аякка төште. Әгәр урыныннан торып китмәсә, ашыгыбрак җавап биргән булса, еламсыраган тавышы фаш ителәсе иде... Шул хәйлә белән Фазыл учак читендә калган чәйне алып керде. Кайчандыр вагон түшенә пар итеп алынган чәйнекнең яшел төсе капкач тоткасында гына калган иде инде.

— Мин, — диде Фазыл, Наилнең җавапсыз калган соравына ишарә итеп, — буровойда эшләгән елларымны — яшьлегемне эзләгән кебек сагынам...

— Шушы сүзең бик җиткән. Кайт әйдә «Ак Чишмә»гә.

— Каравылчы булыпмы?

— Сакчыларга кытлык заманы түгел ансы. Ә менә синең кебек бораулау осталары бетте... Кайсысын мур кырды, хәвеф-хәтәрләр берәм-берәм чүпләп тора. Кемнедер менә бу алып китте, — диде Наил, буш шешәгә төртеп. — Исән калганнарның күбесе ватык-сынык... Кыскасы, бригадаңны җыеп яңадан эшкә тотын.

— Чү, яшьти, мине бит син, инвалид дип, пенсиягә озаттың!

— Хәзер бөтен пенсионерлар эшли. Синең кебек сәламәт кешегә пенсия акчасы ул ун көн ашарга җитми.

— Нинди инвалид инде син, Фазыл, оялмыйсыңмы? Әле төн уртасында, багана башына менеп, ут ялгаганыңны күрсәң... малай-шалай ише кыландың.

Гөлсөярнең «төн уртасында... менеп... малай-шалай ише...» дигән сүзләрен аерым-аерым ишетте Наил. Һәм бик күңеле булды.

— Вәт-вәт! Гөлсөярләрне тыңларга кирәк. Ир кешенең мөмкинлекләрен хатын-кыздан сора. Алар арттырып сөйләмәс.

— Минем пенсия кенәгәм бар ич. «Ярамый-ярамый» дип теңкәгә тия торган белгечләрең ни әйтер?

— Юк алар. Куркынычсызлык техникасы инженерын маркетинг буенча урынбасар иттек, прораблар урынына — менеджерлар килде, технологлар реклама бүлегендә утыра... Ә бораулау осталары җитми. «Ростовдонводстрой»ның син укыган мәктәбе ябылды. Су эшендә иң яшь бораулаучылар сез хәзер, эзләп тап егетләреңне. Тапмасаң, яшьләрне җый — өйрәтерсең. Так што — яшереп куй кенәгәңне...

— Ертып ташла син аны, Фазыл абыйкачаем. — Гөлсөяр, батыраеп, зур белгечнең маңгаеннан пәп итеп алды. Кызыйның үз гомерендә беренче тапкыр стакан тутырып эчкәнен белми әле болар. — Бир ул явыз катыргыңны, үзем ертып ташлыйм.

Әгәр бу тәкъдим Наилдән чыксамы — абзагыз, җавабын табып, әйтергә ярамаганны тоттыра белер иде. Ләкин Гөлсөяр алдында мескенләнеп торасы килми бит, әй... Кызлар күңелне үстергән саен, көч керә икән ул ир канатына. Ул сөт кәгазенә төрелгән пенсия язуын, күкрәк кесәсеннән алып, кызга сузды. Гөлсөяр исә, абзагыз кире уйламагае дипме, учак янына йөгерде. Эшне бик тиз тотты: тотты да ертты, ертты да, һәр битен тураклап, атналар буе сүнмәгән учакка сипте...

## Син дә президентмы...

— Айнығач еламасам ярый инде, — диде Гөлсөяр, учактагы кара көлдән сискәнеп.

Ул әлеге вагонда үзенең бөтенләй чит кеше икәнен исенә төшерде. Фазыл исемле абыйның гомер буе эшләп яулаган бердәнбер юанычын утка якты түгелме соң?.. Бу бит бер дә белмәгән юлаучы язмышына тыкшыну кебек килеп чыкты... Әгәр абый дигәнең кызып китсә, кул күтәрсә... уналтышар мең сумлык коньяклар эчә торган начальнигы көлеп карап торса... Йә Хода, Гөлсөяр туташыгызның соңгы тукталышы шушы мәллә?!

Кыз учак сүнеп, күмерләре салкын көл белән капланганчы уйланып торасы иде. Буш стаканнарны тотып, Фазыл килеп басты. Егетләр инде вагоннан чыккан. Калган сүз урамда дәвам итте.

— Мә, боларны да як! — Һәм Фазыл Гөлсөярнең борчылганын сизде, ахрысы, юату рәвешенә китереп әйтә куйды: — Мин үкенә белмим, син дөрес эшләдең. Бу җүнсез ярлыкны, югалтырга теләп, тишек кесәгә дә салып йөргәләдем инде.

— Ашыгыбрак яктың, Фазыл, — диде Наил, парлыларны ирештерүдән тәм табып. — Мин бит сине шәһәргә эшкә чакырам. Пенсионерлар трамвайларда бушлай йөри.

— Су ташый торган машина бирәсеңдер ич?

— Минем кебек кызлар янына да «водовозка» белән йөрерсеңме?

— Юк, Гөлсөяр, кызлар янына такси белән йөри ул. Әлфинәне күрәсе килгән саен, Казаннан Актанышка такси яллап кайта иде.

— Димәк, икенчесе Әлфинә икән...

— Һи, Гөлсөяр, гомер буе шул бер Әлфинә белән җенләнде инде ул. Әлфинәне сөйде, Язиләгә өйләнде. Язиләне ташлады, Әлфинәне таба алмады.

— Шулхәтлек чибәр идеме? Алай оныта алмагач.

— Ул сиңа охшаган иде.

— Наил Кадыйрович, сезнең бу эшчегез ялганчымы?

— Ялганга өйрәнер өчен кешеләр арасында яшәргә кирәк. Ә Фазылның карурманнан чыкканы юк. Чамадан тыш турысын сөйләгәнгә күрә кыргыйланды инде ул, шәһәргә кайтырга курка. Мин аны эшкә чакырып торам, ике сәгать буе үгетләгәнмендер, «ярар» дигән сүзен ишетмәдем әле. Әйтерсең лә минем башка мәшәкатем юк! Яз гаризаңны — президент исеменә! Начальник дип бутый күрмә.

— Нинди президент?! — Фазыл гаҗәпләнүдән имән бармагы белән күк йөзенә төртеп күрсәтте.

— Мин — президент. «Ак Чишмә»нең исеме шул ук калды. Ләкин ул хәзер «акционерлар компаниясе» дип зурлап атала. Мине шуның президенты итеп сайладылар. Дөрес, компаниябез су скважиналары казу белән генә шөгыльләнми, төзелеш эшләре дә безнең кулда, сәүдә тармагын киңәйттек.

— Син дә президентмы?!

— Бездә президентлар, ачуым килмәгәе — туксан тугыз.

— Шуларның безнең турыда кайгыртучысы тик берседер.

— Мин дә сине кайгыртып йөрим ич.

— Белмим шул, — диде Фазыл, «джип» ягына борылып, — күбрәк үз кирәгеңне кайгыртасыңдыр әле. Юкса мин үҗәтне үгетләп килергә йөрәгең җитмәс иде... Ярар, Наил Кадыйрович, миңа нишләргә кушасың?

— Иске агрегатны ремонтлап аякка бастырырга кирәк. Запчастьләр җитәрлек. Егетләреңне тап. Яңадан башла. Хәзер заказлар күп. Колхоз-совхозлар җимерелсә дә, шәхси сектор күтәрелеп килә. Бөтен кешегә су кирәк.

Наил Кадыйрович китте. Фазыл Гөлсөяр белән күзгә-күз карашып калды.

— Син ни диярсең, белмим, әмма мин тәвәккәллим.

— Мин причем монда. Мин җылынырга кергән юлчы гына.

— Ничек причем?! Син минем Әҗәлнең башына җиткән кеше! Вагонны кая куябыз, менә шуны әйт син миңа?..

Гөлсөяр, өлгергәнлек аттестатына имтихан тапшырасы мәктәп баласыдай, өстәл өстенә карап өнсез калды: гүя нинди билет алырга, ничегрәк җавап биреп «яхшы» билгесенә лаек булырга? Сораулары буталчык, үзе катлаулы. Әгәр җавабың әзер түгел икән — вакытны суза тор... Әле өстәмә сораулар да бирерләр. Ләкин кызыйның әзерлеге җиткән, җавапны башкалардан күчермичә, үз күңелендәгесен әйтер...

— Минем ашыгыч эшем юк, әйләнеп кайтканыңны саклап торырмын. Син эзләп табарлык җирдә булырмын.

— Вагон ишегенә дегет сылап китмәсеннәр...

— Үзеңне бел! Калага китеп барышың.

— Әйдә, бергә китик.

— Юк! Адәм баласын кем дә булса, нәрсә дә булса көтеп торырга тиеш. Юкса ул сукбайга әверелә...

## Әмир белән Мәдиярны тузан күмгән

Хуҗасыз мал... Хуҗасыз өй... Хуҗасыз ил... Бөтенесенең дә язмышы бертөрле...

Тәүлек саен алмашка килгән каравылчылары, чылбырлы этләре, кеше буе җитмәслек таш коймалары, көчле прожекторлар, сигнализацияләр белән саклана торган «Ак Чишмә» ишегалдында хуҗасыз калган машиналарны күзгә күренмәс җан ияләре талый тора. Вакыт агышына каршы килә алмыйча, үзләреннән-үзләре сүтелә диярсең. Кайчандыр ир уртасы Әмирнең мазутлы кулларына буйсынган, ак кәчтүн киеп эшкә килгән өйрәнчек Фазылны үз иткән, Шүләнгер егете Мәдиярны һөнәргә өйрәткән бораулау агрегаты, көпчәкләрен урлатып, җиргә баткан. Олтаны бозланып каткан итекләр кигән килеш Фазылны Әлфинә каршысында биеклеккә күтәргән тимер баскычны каерып маташканнар, алып китә алмаганнар — эретеп ябыштырылган җирләреннән купмаган. Барабанга уралган илле метрлы корыч аркан төбеннән үк кисеп алынган... Платформадагы дизельнең «баш капкач»ын сүтеп алганнар, радиа-

торы да юк... «Ватылды» дип, запчасть сорап килгән бораулаучыларга кирәк нәрсәне: «Әнә, Вангаев агрегатында бар; Фазылларныкы әрәм ята; Ашраповныкыннан сүтеп ал, складка кайткач, урынына борып куярсың», — дип, табардай юлын күрсәтә торгач, койма буендагы бораулау агрегаты металл зиратына әверелгән. Берәү рөхсәт белән сүтсә, икәү, аннан күреп, рөхсәтсез генә сүтә бит әле ул бездә... Шунысына сөенде Фазыл, өстенә авыр вышка ятып торгач, үзйөрешле агрегатның «КамАЗ» кабинасын күтәрә алмаганнар, юкса аның двигателен аякка бастыруы катлаулырак буласы иде.

Югары басым белән балчыклы су кудыра торган җайланма хәзерге агрегатларда вышка астындагы сәндерәгә беркетелә. Элек аларны аерым арбага төяп йөртәләр иде. Фазыллардан калган «грязьнасос» көпчәкләре сытылган арбада пычракка баткан, җәен-кышын кар-яңгырда коенып та чистара алмаган — корымлы ләпеге шул килеш... Арбадагы тимер әрҗәне каерып ачып эзләгәннәр, күрәсең — сандык маллары идәнгә таралган, һәрнәрсә, җир төсенә кереп, элеккеге кыяфәтен югалткан.

Онытылган, тик яткан җисем кирәксезгә әверелә, тынычлана, тузанга бата, әкренләп мүкләнә һәм ахыр чиктә балчык өеменә әверелә. Табигать аны таркатып, үз вакыты белән яңадан әйләнешкә кертә... Әмир белән Мәдиярның яшьлек елларын арбада тузан күмгән. Фазылны да күмәсе иде, әгәр Наил Кадыйрович эзләп килмәгән булса...

Бик чекерәеп карасаң яисә җирәнмичә кулыңа алсаң, Әмирнең сырмасын, Фазылның плащ-курткасын, Мәдиярның сырган чалбарын танырга була... Тишек-тошык эш бияләйләре арба төбенә ябышып кипкән — аларның кемнеке икәнен танырлык түгел. Ә таныйсы килә. Үзеңнекен табып алып, яңадан кул җылысы сеңдерәсе, күгәргән рычагларга кагылып, салкын тимерләрне уятасы, яшьлекнең каберенә әверелгән иске машинага җан өртеп, яшәүне дәвам итәсе килә. Бигрәк вак-төяк кисәкләргә таркалган инде бу олы язмыш. Иске киемнәрне, күгәргән тимерләр, җавапсыз хатлар, тузган өйләр, югалган юллар һәм аерылган ярларны таралып яткан тарафлардан кабат бергә җыя алсаң — аккан суларга каршы агарсың, язмышыңны яңартырсың. Бу киемнәрнең хуҗаларын да бергә җыясы бар.

Арбада аунап яткан плащ-куртка тимер сандыкның төбенә салынган иде. Эштән киткән чакта ташларга кызганды аны Фазыл. Онытылмас елларның яшьлек дип аталган бер чорында киелгән кием ич.

Ул елларда болонья тукымадан тегелгән куртка белән ак куян бүрек модага кергән иде. Көз көнеме, кыш уртасымы — авылыңа кунакка кайткач, башыңда ак болыттай кабарып торган йөнтәс бүрек, өстеңдә дүрт төймәгә каптырылган, кыйгач кесәле, эчке сүрүе мамык белән түшәлгән озын куртка булырга тиеш. Тездән аска таба балагы киңәеп төшә торган лавсан чалбар, каеш табанлы «прощай, молодость» дип аталган каптырмалы киез ботинкаң булса — син инде культурный егет, димәк, синең инде шәһәрдә эшең һәм пропискаң бар яисә син укырга кереп өлгергән япь-яшь өйрәнчек интеллигент кисәге. Авылда яшәп калган яшьтәшләрең сине «стиляга» дип үртәр, кызлар «блатной» дип хөрмәт итәрләр...

Иске Актаныш универмагыннан киенде Фазыл.

Юл өзегенең унынчы көне.

Казаннан һаман самолет килми. Язгы ташу Минзәлә күперен яңадан корырга ирек бирми. Әмир кызы Язилә ун көн инде Фазыл куенында. Бригада Казанда бүленеп калды.

Актаныш кибетенә төшәрлек сукмак кипкән иде инде. Язилә, вагоннан чыгу белән, Фазылны култыклап алды. Егет «нахаллар бистәсе»н үткәнче аны-моны сиздермәде. Ләкин «Актаныш басмалары»ннан төшеп, үзәк урамга якыная башлагач, Язиләнең кулын алды:

— Асылынып барма әле, җаным!

— Әллә Әлфинәң очрар дип, минем өчен хурланасыңмы?

— Култыклашып йөрергә өйрәнмәгән.

— Бер юрган астында йоклаганыбыз да юк иде, өйрәндек ич... Ун көн инде, Аллага шөкер, мин синең хатының!..

— Яучы җибәргәнне көтмәдең ич...

— Оятың юк икән синең, Фазыл, эти килсен әле, бәйнә-бәйнә сөйләп бирәм.

— Нәрсә дип? Сөйгән кызын куып җибәреп, аннан бушаган куенга үзем кереп утырдым, дипме?

— Их, син! Ни егет, ни мужик! Каргасам, каргышым төшәр, сволочь!

— Ник һәр башлаган сүзебез әрләшү белән тәмамлана соң безнең, җаным, дип килә, сволочь, дип китә?!

## Борыласы килеп тора

Кабыгыннан аралыйм дигәндә, иреннәреңнән ялгыш бер көнбагыш бөртеге төшеп югалса да, башкаларга артык сиздермәскә тырышып, син аны эзләргә керешәсең. Көнбагыш төшенең тәме тел очында кала, тынгы бирми... Ә монда Фазылның мәхәббәт төше югалды. Унсигез яшьлек егетнең кара-каршы сөешә алырдай кадерлесе, мәхәббәт турында китаплар укыганда яисә кинолар караганда капылт күз алдына килеп басардай гүзәле, алыштыргысыз сөеклесе Әлфинә, икәүләшеп көтеп алган язларның берсендә, Фазылны тургай оялары өстендә калдырып китеп барды. Җәяүләп куып тотарлык итеп түгел —

Әлфинә абыйсының машинасына утырып китте. Мәктәпне тәмамларга торган кыз бала, үзенең самими горурлыгын җиңә алмыйча, Язилә каршысында җиңелеп китте... Яз ул — гел сайрар кошлар белән тулы таңнар гына түгел, күз явын алырдай аллы-гөлле чәчкәләрдән генә тормый... Яз дигән өмет ул — ләйсән яңгырлары кар белән буталган, кояшка сусаган җир өстен тузан болытлары каплаган, бер-береңне эзләп барырдай юлларның өзелгән чагы да икән.

Әлфинә яшел вагонда Фазылны Язиләгә калдырды. Ләкин Фазыл белән Язилә арасы, кояш баеган саен, берәр көнгә ерагая бара.

Ун көн инде яшел вагонда аулак өй... Монда бик күп нәрсә сүзсез генә эшләнә. Уяналар. Урам ягындагы юынгычка гөрләвектән алып су тутыралар. Алмаш-тилмәш юынган арада, электр плитәсе өстендә корымлы чәйнек кайнап чыга. Язилә сөйләштерә күрмәсен дигәндәй, Фазыл тизрәк «Альпинист» радиоалгычын акыртып куя. Яңалыкларны һава торышына чаклы тыңлап бетергәч, егет, эш киемнәрен киеп, агрегат янына китә, кыз вагон эчен җыештырып кала. Кояш «нахаллар бистәсе»н өстән яктырта башлагач, кыз платформа өстендә юк-бар төзәтү эшләре белән маташкан егет янына килеп баса, берәр тимер сыныгы белән платформага суга. «Аш пеште!» дигән сүз инде бу... Кояш Казан ягына төшеп югалгач, тагын чәй... Радиоалгычтан кичке концерт башлана... Эңгер-меңгер җиткәч, бер сәкегә ике мендәрле урын җәелә — анысы да сүзсез генә... Стена кырыена егет менеп ята... Кыз ашыкмый, вагон уртасына басып чишенә башлый, алкаларын сала, кул сәгатен өстәлгә куя, колак артына ислемай тидерә, вагон эченә суыра торган конфет исе тарала. Куенына кергәч, барыбер салып ташлыйсы була инде дигәндәй, бөтен мәшәкатен алдан күреп, шәп-шәрә килеш уртак юрган астына чума. Җылы тәнгә кайнар тән тигәч, тагын артык сүзнең кирәге юк — егет белән кыз арасындагы киеренкелек беркавым онытылып тора. Кыз бала, егет белән йоклагач, үзен беренче төнне үк хатын итеп тоя, ләкин егет кеше кызыл туйлар белән өйләнсә дә, үзен тугыз айсыз ир кеше итеп тоймас, анда да бала туса гына әле...

Яратмаган кешең белән яшәү — ялгыз яшәүнең бер төре ул.

Төне буе юрган эченнән чыкмагач, суыра торган конфет исе ком өстендә онытылып калган балык исенә әверелә.

Фазыл конфеттан бизде, хәзер чәйне шикәр белән эчә.

Ул нигәдер бүген иртән радионы кабызмады. Язиләнең күңеле ниндидер шом сизепме — кружкага үрелмичә, чәйнең суынганын карап утырды. Фазылның шомы озак көттермәде.

— Актанышка төшеп менәм.

— Ник?

— Контордан хәбәр юк микән?

— Кичә генә барып тикшердек ич?

— Бәлки, отпускнойны җибәргәннәрдер, телеграф белән килсә, өч көннән ары тотмыйлар аны почтада...

— Нәрсәгә соң ул отпускной. Кулыңда тотарга дигән акчаң күп ич әле.

— Акча бервакытта да күп булмый ул. Куртка аласым килә. Куян бүрек тә кирәк.

— Язга чыккачмы?

— Алган әйбер кулда кала. Кыш тагын җитә ул... Свежий ипи дә кирәк. Шикәр дә бетеп килә.

— Алайса, бергә төшәрбез.

— Син нәрсәгә анда? Моңарчы, кием алганда, киңәшче чакырганым югые. Әнә ашарга пешерә тор. Мин хәзер, озак йөрмәм. Водовозканы кузгатып карыйм. Көпчәк эзләре кипшегән анда. Җитәр. Гел җәяү йөрергә димәгән.

— Машина белән барасы җиргә дә ияртмәгәч, аңлашыла инде.

— Нәрсә аңлашыла?

— Бөтенләй үк җүләргә санама мине...

Олы юлга авырлык белән чыкса да, машина батып ятмады.

Рульне уң кул һаман саен ныграк каера. Уң якка борылыш очраган саен борыласы килеп тора. Аккүз юлы уң якта шул. Соңгы борылыш аны Әлфинәгә таба алып китте. Кибетләргә кереп вакыт әрәм итә торган чак түгел — кыз мәктәптән кайтканчы, сукмагына төшәргә кирәк...

Шул ук машина, шул ук юл, Аккүз авылы да шул ук.

Ләкин бүгенге очрашуга ашкынуның өмете өзек. Көрешүнең олы шатлыгы булырга тиешле минутлар алдан ук шикләнү, икеләнү, үпкәләү, сагаю һәм хәтта курку кебек вак борчуларга таркалып беткән. Соңгы ун минутлык көрешүдә Әлфинәнең мәхәббәте — нәфрәткә, Фазылның сөенече көенечкә әверелеп калган иде. Бактың исә, ун минут эчендә кешедә алай ук кискен үзгәрешләр булмаска тиеш, әгәр арага хыянәт кермәсә... Зурдан кубып гаепләмәгәндә, дус белән дус, туган белән туган, күрше белән күрше арасындагы үпкәләшүләр, күп еллар дәвамында кабатлана торгач кына, әкренләп нәфрәткә әверелергә мөмкин. Әйе, әйе. Күп еллар дәвамында... Ә ике гашыйк арасында туган үпкәләшү ун минут эчендә бөтен бәхетеңне чәлпәрәмә китерә ала... Җил орынган чык бөртеге сыман, дөрләп янган ай уртасында калган күмерле көл өеме сыман, дегет тамган бал сыман, мазут кушылган чишмә сыман...

Яратышып йөргән парлар өчен андый нәфрәткә бары тик хыянәт кенә сәбәп була ала. Ул ун минутлык сөйләшүдә Фазыл хыянәтсез иде әле. Әгәр дә Әлфинә, үзенең горурлыгын җиңеп, Фазылны тыңлап торырлык көч тапса, бу дөньяда бәхетсезләр саны өч кешегә кимрәк буласы иде. Саф мәхәббәтнең аңлашырлык вакыты юк — ашкына ул, ашыгычлык белән ике арага кергән ялгышларны язмыш итәргә ашкына. Аннан соң, шул хатаны төзәтәм дип, тагын күпме хата эшләнә.

Фазылның Язилә белән үткәргән ун төне Әлфинә беркайчан да гафу итә алмаслык хыянәт инде хәзер. Аулак вагонда, уртак юрган эчендә никахсыз яшәп яту — гаилә коруның бер очрагы инде ул... Аулакта, йолага каршы, ризасызлык белән ашыгып корылган гаиләләр адым саен, ләкин аларны ни көткәнне беләбез... Әнә Фазыл, сагынуын тыя алмыйча, Язиләдән кача-поса, Әлфинәсе янына китте. Ялгышны төзәтмәкче ул. Әлфинәдән ялынып алып кайткан күрешү мизгелләренең ялган бәхетеннән айнышмаган килеш ул тагын Язилә юрганы астына чума. Бу хәл икенче көнне дә, өченче, дүртенче көнне дә шулай кабатланды. Аптырагач, Язилә машинаның ачкычын яшереп карады. Ләкин Фазыл җәяү чыгып качты. Таң атканда гына кайтты. Кайтты да Язиләле сәндерәгә алып керә торган вагон баскычына утырып хәл алды. Егерме биш чакрым йөреп кайткан егет алҗыганын танырга теләмәде. Йокы Аккүз авылында калды. Бераз ял иткәч, яңадан җәяү китәргә әзер инде ул әзерен, тик иртә бит әле. Агыйделнең аръягыннан кояш чыксын. Әлфинә мәктәбенә барсын. Өлгергәнлек аттестаты алыр өчен «Кем булырга?» дигән темага инша язсын. Дәресләре бетүгә, мәктәп ишеге төбендә аны, болонья курткасын иңенә салып, Фазыл көтеп торыр.

Үпкәләшкәннән соң беренче килүдә Әлфинә аны күрмәмешкә сабышты, өенә кайтып җиткәнче ияреп барган Фазылга сүз катмады. «Исәнме» юк, «Хушыгыз» юк... Икенче көнне «Нихәл?» дигән сәламгә «Әйбәт хәл!» дип кенә җавап бирде кыз... Өченче көнне Фазыл ияреп түгел, кыз белән ике араны якынайтыбрак, янәшә атлады.

— Сагынам, Әлфинә, авылыңны, өегезне, йөргән юлларыңны, кигән киемнәреңне, чигүле бияләйләреңне, исемеңне сагынам...

Тыңламый ни, тыңлый инде Әлфинә, тыңласа да, егетнең сүзләре үтеп керми. Элек кызның хисләре якында гына иде, Фазыл хәтта аның исемен әйтсә дә, йөрәк тибешләре ешая иде. Әгәр инде шул чагында сагындым, дип тә өстәсә, Әлфинәнең бөтен тәне дерелдәп куя, күзләренә яшьләр тыгыла иде...

Дүртенче көнне Әлфинә, дәресләрдән чыгу белән үк, иптәш кызларыннан арткарак калып, мәктәп сукмагыннан Фазылны эзләде: бүген дә килде микән? Бәй, килгән ич! Бераз сөйләштеләр бугай. Юл бик кыска тоелды. Капка баганасы янына килеп баскач, кыз атылып-бәрелеп кереп китәргә ашыкмады. Өй күләгәсендә салкынчарак тоелды, Фазыл теге куртканы кызның иңенә элде һәм, шул форсаттан файдаланып, дөресрәге, махсус җаен туры китереп, аның ике беләгеннән тотып алды.

— Әлфинә, дим, үләм!!! Әйдә яңадан танышабыз!

— Танышканчы, иң әүвәл сөйләп бир, кем ул Язилә? Просто беләсем килә.

— Безнең мастер Әмир абыйның кызы ул.

— Туганың түгел ич, теге көнне синең муеныңа асылынуын күрсәң...

— Соң мин чит кешемени?! Әтисе белән бергә эшләгәч, якын иткәндер инде. Ә син, туктап мине тыңлыйсы урында, киттең дә бардың.

— Юл өзегендә ярты мең чакрым әйләнгечтән сиңа юл табарлык Язиләң булгач, нигә дип минем башымны әйләндереп йөрдең? Бу җүләр мәктәп баласы, күңел ачып калыйм, дидеңме? Картрак кызларны алдарлык тәҗрибәң юкмы?

— Әлфинә, нинди карт кызлар ди ул! Минем дә мәктәпне тәмамлаганыма ике генә ел бит әле.

— Әллә миңа хәтлек кызлар сөйгәнең юк иде, дип әйтәсең киләме?

— Яшермим, туган авылымда Хәмдия исемле кызым барые.

— Мине күргәч, аны оныттыңмы?

— Алай түгел, бер дә алай түгел! Урладылар аны...

— Башкаларга урлаттыргансың. Ә үзең саклап кала алмагансың.

— Мин чирәм җирләрдә җир сөреп калдым.

— Анда да кызлар эзләп киттеңме?

— Сорауларың ачулы синең, Әлфинә! Җавап биргәндә, җанны сызлата.

Фазылның сизенүе дөреслеккә туры килә. Чынлап та, Әлфинә үзенең ачуын тыя алмый. Бүген генә түгел, ун көн буе җыелып килгән ачу инде ул. Фазыл исемен «беренче мәхәббәт» дигән горур хис белән бизәгән һәм, шуңа ышанып, сөенә-сөенә унҗиде яшен тутырган Әлфинә әрнүле зур югалтуга бөтенләй әзер түгел иде. Аерылышу дигән газапка адәм баласы үз-үзен әкренләп әзерләргә тиеш. Сәбәпләрен алдан ук белеп торганда, бер-береңне югалтуның котылгысызлыгы хәвефкә әверелми, ә бары тик хисләрне чыныктыра тора. Көтелмәгән, кинәт килгән югалту гына хәвефле. Беренче мәхәббәте куенында йокымсыраган Әлфинәне уятып, ике арага кинәт Язилә килеп керде. Ап-ак кәчтүн-чалбар кигән Фазыл муенына асылынырга торган Язилә белән вагон тирәсендәге төнге пычракта басып калды кыз бала. Өйгә кайтып җитү белән, Әлфинә, почмакка кереп, ләгәнле суда ялтыравык итекләрен юарга кереште. Язгы төннән тизрәк чистарыну өченгә түгел, ә, күз яшьләрен сиздерергә теләмичә, су белән юаныр

өчен. Язгы каникулдан соң, укуны өзеп, Чаллыга китәргә дигән исәп тә кинәт килде аның уена. Ләкин өйдә әле эти кеше дигән идарә бар. Самат абый, хатынын арадашчы итеп, кызының хәлен сорашкач, яртылаш идән уртасына шуышып чыккан чемоданны кире караваt астына тибеп кертте. Әти кешенең карары шул: «Зимагурдан исән-имин котылгач, рәхмәт. Тапкансың үкенер нәрсә. Егет югалткан саен чемодан тутырсаң, үзең дә зимагурлыкка китәрсең!» Әлфинәнең әйтелми калган соңгы сүзләре, ун көн буе тел очында йөри торгач, нәфрәткә әверелде. Ул, шушы нәфрәтне сыйдырырлык кәгазь алып, Фазылга хат та язмакчы иде. Ләкин кырда эшләгән егетнең адресы юк, димәк, тапшыру өчен Әлфинәнең үзенә хат ташучы булырга туры киләчәк иде һәм, ниһаять, менә ул нәфрәт иясе Әлфинәнең каршысына хөкем карары өметләнеп килгән: гомерлеккәме, вакытлыча гынамы, әллә сынар өчен шаяртып кынамы? Шушы ун көн эчендә кызның башы туктаусыз шаулады — күрәсең, акыл җыеладыр; уйлары авырайгандыр — гәүдәсе басынкыланды. Гел сагышлы уйларын яшереп йөрткәнгәме — күзләренә сер тулды, адымнары салмакланды — анысы таныш сукмактан да сагаеп атлагангадыр, тавышы калынайган сыман үзгәрде — әйтелми йөргән сүзләре тамак төбендә борчып торадыр. Сер бирмәскә тырышты Әлфинә, кичләрен клубка чыгудан ваз кичмәде. Шунысы сәер, моңарчы артык исләре китмәгән авыл егетләре дә үзгәрде. Ун көн эчендә Әлфинәне Аккүзнең алты егете озата кайтты. Ә җиденчесе күрше Кадермәтнеке иде... Алар кызның кинәт олыгаеп китүен үзләренчә юрадылар.

— Җавап бирмәдең, Фазыл, Ырымбур далаларында кызлар эзләп йөрдеңме?

— Акча эшләргә иде исәп.

— Өйләнергәме?

— Әйе инде...

Фазыл, үпкәләвен күрсәтмәскә тырышып, читкәрәк китеп басмакчы иде дә, Әлфинә өенә кереп качыр дип, баскан җиреннән кузгалмады. Үпкәләү — дөреслекне күзгә бәреп әйткәндә, җиңелү дигән сүз ул, җиңел җиңелү...

Хакны нахакка санап ялган җавап кайтарып өлгергән кеше үпкәли белмидер. Ялганлар өчен тәҗрибә кирәк. Әлфинәнең мәхәббәт һәм нәфрәт тулы күзләренә карап турысын җавап бирми хәлең юк. Ул күзләрнең явы котылгысыз, хәтта үпкәләп читкә борылып бассаң да, син Әлфинәнең җете карашын тоеп торасың.

— Акча эшләп кайттың да өйләнеп карадыңмы?

— Урладылар, дидем ич инде.

— Әгәр син Хәмдиянә өйләнеп өлгергән булсаң, бүген миңа ниндирәк әкиятләр сөйләп маташыр идең икән?

— Хәмдиягә өйләнгән булсаммы... Буровоең ниемә кирәк!

— Димәк, син аны яраткансың! Мәхәббәт бер генә була, Фазыл! Менә ни өчен мин сине гафу итә алмыйм! Минем икенче буласым килми.

— Алай да кискен җавап бирмә әле, Әлфинә. Сине очраткач, мин үземнең үткәнемне онытым, әйтерсең лә булмаган ул, язмышымның киләчәге генә исән калды.

— Болары китап сүзләре, үз йөрәгеңнән чыкканы түгел.

— Нәрсәгә соң ул меңәрләгән китаплар, шушындый минутта сүзләрен кулланырга да ярамагач?! Әле безнең аерылышуга ун гына көн үтте. Ун ай... ун ел үткәч соң булыр. Иртәгә нишләрмен соң мин?

— Унберенче көнеңне яши башларсың, миннән башка гына. Сине бит яшел вагонында Язиләң көтә. Ачуланма, егетләр муенына асылынырга өйрәнгәч, бәлки, мин дә үзгәрермен әле. Хуш!

Аерылганда тигез хокуклылык булалмый. Берең җиңеп китә, икенчең җиңелеп кала. Алдан китеп өлгергәннәр үзләрен җиңүчеләр итеп тояр — бу мәхәббәт баталияләренең сугышчан кануны. «Язиләң көтә» дигән сүз искәртү генә түгел, ә бәлки Фазыл өчен иң авыр сорау! Әлеге сорауга «Әйе!» дигән җавап бар барын, ләкин аны әйтү — Фазыл өчен иң мескен җиңелү, фаҗигале кимсенүгә тиң булыр иде. Җиңелү, хыянәт, фаҗига, җиңү — мәхәббәттә гел сугыш чалымнары.

Фазыл бер сүз дә дәшмәде — әйе, җавапның андый төре дә бар. Горур гына җиңеләсең килсә — дәшмә! Җавап көтеп алҗырлар. Ә соңыннан исә үз сорауларына үзләре җавап эзли башларлар. Дәшми калу — ялганның бер төре. Дәшми калу Фазыл белән Әлфинәнең унберенче көне... Актаныш кибетенә дип чыгып киткән ирнең якты көн буе кайтмыйча кайдадыр йөрүен Язилә җиңел генә кичерер дисезме? Кайтсын гына Фазыл. Ул аны икесе өчен дә берүзе елмаеп каршы алыр, кирза итекләрен салдырыр, чыланып та өлгермәгән аяк чолгауларын электр миче өстенә тарттырылган чыбыкка эләр. Көне буе суытмыйча саклаган чиләкле суны түгәрәк калай ләгәнгә бушатып, Фазылны шунда бастырыр, аның аякларын юар. Үзе юар, үзенең сул кулы ирнең чәлтереннән кысып тотар, уң кулының балдак киярга хаклы бармагы тынгысыз ирнең табан астын кытыклар, үзе бәет сөйләгәндәй такмаклар:

Тагын шунда бер барганыңны сизсәм —
Ул кызны эзләп табармын,
Бөтен мәктәп алдында рисвай итәрмен,
Хатынлы ирләрне азындырмасын.
Син минем чәчәгемне койдың.
Ир бирмәк — җан бирмәк...

## Яшел вагон килене

Актанышны Казан белән бәйләп торган юлның язгы өзеген ялгадылар — ташуларның әүхәте сүрелгәч, Минзәләдәге Ык күперен торгыздылар. Казан аэропортында өелеп яткан хатларны, газета-журналларны брезент бөркәүле ике «ЗИЛ»га төяп китерделәр. Посылкаларны соңыннан ташып бетерделәр.

Самолетлар оча башлаганчы түзмәде Әмир. Актанышка баруның тагын бер юлын белә ул. Теләче — Тәкәнеш — Мамадышны үтеп, ике елганы кичсәң, Чаллы авылына килеп җитәсең, ә аннан инде эш урыныңа тагын ике сәгатьлек сәяхәт. Әлбәттә, телгә алынган авыллар арасында автобустан — арбага, арбадан — паромга, паромнан тракторларга күчеп утырырга туры килә.

Маңгаена «Мамадыш» дип язылган «пазик»ка егерме дүрт урынга алтмыш кеше төялде. Әби патша тарантасы өчен салынган ташлы юлда дүрт сәгать буе дыңгырдаткач, пассажирлар чөелеп бетте, автобус эче бераз иркенәеп калган кебек булды. Мамадыш пристанендә ул бишекле мотоциклга күчте. Чулман кичүендә сөт машинасы йөртүчесе белән танышты. Минзәлә белән Актаныш арасында бер тракторга һәм ике тапкыр атка күчеп утырды.

«Нахаллар бистәсе»нә килеп кергәндә, инде ягасы мичкә ягып, савасыны савып, йоклатасыны йоклатып, тыныч төнне каршылар чак җиткән иде.

Клевер басуыннан яшел вагонга таба яңа эз төшкән. «Монысы Фазыл кияү белән Язилә кызымның гастрономга йөри торган яңа сукмагыдыр», — дип уйлап куйды Әмир абзагыз. Бораулау агрегаты янында шундый тынлык хөкем сөрә иде ки, әгәр вагон эчендә ут барлыгын күрмәсәң — бу тирәдә кеше-мазар барлыкка ышануы да кыен хәтта. Урам ягына радиоалгычтан «Маяк» хәбәрләре ишетелеп тора, әллә сүндерергә онытып йокыга киткәннәр, әллә икәүләшеп ил күләмендәге яңалыкларны тыңлыйлар. Бәлки, сөешеп яталардыр... Һәрхәлдә, Әмир ишек шакырга ашыкмады. Бераз сабыр итәргәдер. Клевер басуындагы әлеге тынлыкка яңадан ияләшергә кирәк, ни дисәң дә, юл өзеге беткәнне көтеп вакыт үткән. Эш урыны сагынылган. Әмирнең менә хәзер, агрегатны кабызып, төнгә каршы эшне башлап җибәрәсе, роторның, шалтыр-шолтыр сөенеп, бораулау торбаларын әйләндергәнне күрәсе килә. Нибарысы бер генә ай узган лабаса! Пенсия дигәне исән калган гомернең буеннан-буена бирелә бит. Әгәр Әмир тагын җитмеш-сиксән яшенәчә исән булып, үзен-үзе йөртә алса, һәм шушы бораулау агрегатын, су ташучы машинаны, пычрак кудыргыч насосның, кызыл балчыкка манылган хезмәттәшләрен биш, ун, егерме ел буе күрми торса... Ничекләр түзәрсең! Әле дә ярый, бу техникага Фазыл хуҗа булып кала, дөресрәге, Әмир аңа хуҗалыкны тапшырырга дип килде. Язилә, әтине эзлим дип, Актанышка бер ай элек чыгып киткән иде. Шул вакыттан бирле ул монда әтисе яучылаган Фазыл белән бер вагонда яшәп ята... Әмир үзе дә бит Язиләнең әнисе Суфия белән нәкъ шулай кавышкан иде, айлар буена шушы яшел вагонны өй итеп яшәгән иде... Ахыры ни белән бетте соң? Бетте дә, бетмәде дә! Әмир белән Суфия бергә яшиләр дә, яшәмиләр дә, Әмир бәхетле дә, бәхетсез дә... Аның бәхете Язилә булып гәүдәләнде. Кызының Фазыл белән генә кавышуын әти кеше үзе теләде, ышанычлы кулга тапшырып, картлыкта тынычлап яшәргә аның исәбе. Бергә эшләгән арада, Әмир Фазылның холкын өйрәнеп, һәр адымын күзәтеп, кияү булмаган килеш тә «Кияү!», «Кияү!» дип дәшеп, экренләп кулга ияләштерде бугай. Кем белә, юл өзеген сәбәп итеп, ялгыз Фазыл белән вагонда бүленеп калмаса, алар, бәлки, бөтенләй дә кавыша алмаган булырлар иде. Фазыл йөрер иде әле һаман мәктәп балалары арасындагы сөйгән кызын эзләп... Бу парлар да Әмир белән Суфия язмышын кабатламас микән? Ник? Ярар, Әмир белән Фазылны бер калып белән үлчәп булсын да ди. Ә Язиләнең яшьлеген Суфия яшьлеге белән һич чагыштыра торган түгел. Язилә Фазыл өчен генә үскән һәм өзелмәгән чәчәк. Ә Суфия дигән чәчәкне Әмир абзагыз кеше кулыннан кызыгып алды.

Әмир, шушы уйларын таң атканчы дәвам итәргә дип, «МАЗ» машинасындагы йомшак утыргычларга менеп ятарга уйлаган иде. Ләкин ишекне ачканда, кабина эчендәге буш чиләк шалтырап төште. Тавышка вагон прожекторы кабынды, Әмир яктылык әсирлегендә калды. Тәрәзәдән Фазылның каравылчыларга хас кырыс тавышы ишетелде:

— Кем бар анда?

— Мин әле бу, кияү!

Фазыл кулына монтажка тотып чыкты. «МАЗ»ның ачык кабина ишеге янында Әмирне танып, каушавыннан тизрәк күрешергә кирәген дә онытып торды.

— Исәнме, Әмир абый?

— Абый... Һе... — Ут яктысында Әмирнең елмаюы аеруча нык сизелде. — Үзебезчә, татарчалатып... «бабай» диген, малай актыгы! Син кияүдер ич инде?

Үзе күренмәсә дә, тәрәзә аркылы Язиләнең тавышы ишетелде, Фазыл өчен ул җавап бирде:

— Кияү инде, әти, кияү!

Язиләнең чыгып күрешергә ашыкмавын әти кеше үзенчә юрады — киенәдер инде, бахыр, дип кенә уйлап куйды.

Халатын бик тиз киде Язилә, ул икенче сәндерәгә урын җәеп мәтәшә иде. Капылт кына өсләренә килеп төшкән этинең күз алдында ике сәкегә җәелгән урын-җир белән күренәсе килгән иде аның.

— Нәрсә, кияү, мастерыңны кисәү тотып каршы аласың?

— Бермәлне, без кибеттә йөргән арада, агрегатны талап киткәннәр иде. Участковый чакырып, акт төзергә туры килде.

— Бәй, буровой эшкә яраксызмыни?

— Таптык без ул кешеләрне. Куян авылы егетләре булып чыкты. Урланган детальләрне китереп, алынган урыннарына куйдылар.

— Судлашып йөрдегез мәллә?

Нәкъ җавап кирәк вакытта гына, өйдәгечә чәчәкле халатын киеп, Язилә чыгып өлгерде.

— Юк, эти! Фазыл аларны «Игенче даны» газетасына язып чыкты. Шул җитәр ул озын куллы мөртәтләргә. Әти, ник өйгә кермисең инде? Юлдан алҗып килгәнсеңдер. Хәзер аш җылытам... Әйдә...

— Ну әнкәң мескен! Яшел вагон килене!

Бу сүзләрне әйткәндә, Әмирнең тавышында кырыслык юк, киресенчә, яратып үртәүгә тиң йомшаклык бар иде.

Ул төнне төш күрүче булмады. Өч сәндерәдә өч җан иясе йокыга киталмыйча тилмерде — әллә берберсенең йокыга киткәнен көтеп яттылар, әллә, алданрак оесам ярар иде дип, узыша-узыша артык тырыштылар... белмәссең. Таң атканчы тәк аунадылар шунда. Өч баш өч мендәрдә. Әти, аның кызы һәм кияү. Бүре, кәҗә һәм кәбестә дигәндәй...

## Язиләгә эш табылды

Әмирнең юл капчыгыннан дүрт проект килеп чыкты. Аларны «Ак Чишмә»нең гомерлек прорабы Сәфәров биреп җибәргән иде. Дүрт проект — ягъни дүрт авылга яңа су скважиналары казырга кирәк, димәк, алар сусыз интегә. Ә бу исә, Суксу, Адай, Күҗәкә, Чат авылларын сулы итмичә торып, агрегатны Казанга алып кайтырга һәм бригаданы Фазыл кулына калдырып китәргә рөхсәт юк дигән сүз иде.

Мәдияр ике көнгә соңга калып килде. Ул юлыккан очраклы машиналар аны Актанышка Саескан тавы кичүе аша Чистай, Акташ, Зәй аркылы, Әмир килгән юл белән чагыштырганда бөтенләй кире яктан алып килгәннәр иде. Мәдияр бу юлны үзе сайлады, ул моны таныш юл дип исәпли, Тәкәнеш аркылы йөрергә никтер яратмый. Мәдиярның соңарып килүенә берәүнең дә эче пошмады — әйдә, ярар, ике көн эчендә җир кабыгы ныграк кибә торыр, юкса юл төшкәнгә карап кына, авыл читләренең кое бораулардай болыннары ныгып җитмәгән иде әле.

Яшел вагонны, гадәттәгечә, су ташучы машинага тагып, Мәдиярга тапшырдылар. Тагылган вагон сикәлтәләрдә артык уйнатмасын өчен, машина мичкәсенә су тутырдылар. Җиһазлар төялгән арбаны унике тонналы вышка күтәргән «МАЗ» сөйрәп бара иде. Чегән кәрванындай агрегатны әйдәп бару Фазыл кулына калды. Рульгә утырмады Әмир.

— Иялнә тор, агрегатка син җаваплы, — диде ул Фазылга, — мин инде Актаныш белән саубуллашып киткән кеше. Алмашка берәр салага килгәч, кайтып китәрсең, диде начальнигыбыз. Бу дүрт авылны йөреп чыга алсак, шәп булыр иде.

Әмир «салага» дигән сүзне аеруча мәгънәлерәк итеп әйтергә тырышты. Шушы яшенә чаклы гел бер һөнәргә көч түгеп, юаныч тапкан «Ак Чишмә» аксакалы Әмир «вакыт җитте» дигән булып китеп бара һәм бушаган урынга өйрәнчек бер малай, баягыча әйткәндә, «салага» килеп басачак. Яратты Әмир үз эшен, һай, яратты! Бер күрүдә гашыйк булган үсмерләрчә, эти-әнисен сагынып яшәгән ятимнәрчә, туган илен югалткан зимагурларча, суга сусаган гөлләр сыман яратты. Хәзер ул, дулкын бәреп чыгарган балык кебек, йөгереп торган су өстенә карап, яр читендәге кояшлы комлыкта соңгы минутларын көтеп ятарга тиеш. Бу хөкем карарын Әмир чыгармаган. «Ак Чишмә» эшчеләренең язмышы шул, мондый төр һөнәр өчен вакыт кысалары санаулы. Килә бер көн һәм пенсия дигән кырыс дулкын сине ярга чыгарып ата. Һәм яшәп кара шуннан соң сусыз — яңа чишмәләреңнең җир өстенә ургылып төне-көне шаулавын ишетмичә... Әмир китәр — аның урынына СПТУ бетергән берәр «салага» килер — яратыпмы, әллә акчасына кызыгып кынамы, «Ак Чишмә»дә тырышып эшләсәң, фатир тиз бирәләр икән, дип кенәме? Хыялланган кешегә күп инде ул офыклар... Эшче-салагаларга партиягә керүе дә җиңел. Коммунист билеты алыр өчен интеллигенция вәкиле ялынып йөри, чират көтә, кабул итү комиссиясенә кабат-кабат килә. Ә инде эшче кешене сафка алу өчен парторглар үзләре ялынып йөри. Гаризаңны язарга иренмә һәм взносыңны вакытында түләп бар. Коммунистның хыялын сорамыйлар — билгеле бит инде болай да! Партбилетың булса гына син начальник була аласың! Ә начальник дигән сүз ул — бүген колхоз рәисе, иртәгә райком секретаре; бүген идарә начальнигы — иртәгә министр, министр икән — димәк, илбашлыгының эш стилен өйрәнә тор! Ләкин «Ак Чишмә»нең партия уставларында исәпкә алынмаган кануннары бар. Әгәр кое бораулаучы булып сәфәрдә эшлисең икән — сине даими рәвештә ай саен үткәрелә торган партия җыелышларына эзләп табалмыйлар. Взносларны хезмәт хакыннан тотып калырга рөхсәт ителми, взносны һәр коммунист ай саен үз куллары белән китереп түләргә, партбилетының чисталы-

гын һәм исәнлеген һәрдаим күрсәтергә тиеш. Хезмәт хакы алырга да кайта белмәгән бораулаучыны взнос түләр өчен чакыртып кайтару мөмкин хәл түгел. Гадәттә, бораулаучыларның акчасы саклык кенәгәсенә күчерелә бара. Тагын шунысы бар — коммунист кеше белемен арттыру турында туктаусыз кайгыртырга тиеш. Еллар буе командировкада саналган «кыр кешесе»н укытыр өчен, уку йортларын агрегатка яшел вагон белән таксаң гына инде. Менә ни өчен Әмир абзагыз, пенсия яшенә чаклы эшләп тә, мелиорация министры булып җитә алмады! Ә теләге юк түгел иде аның! Хәзер ул үзенә алмашка «салага» көтеп ята. Кем киләсен белми әле ул. Ләкин шунысын яхшы белә Әмир — әгәр син чишмә бораулаучы эшен яратмасаң — аның кыргый шартларына бер ел да түзә алмыйсың. Әгәр инде син сынау йөзеннән бер ел түзсәң, ягъни язны-җәйне-кышны кичеп, агрегатың белән тагын яңа язга килеп керсәң — димәк, син бораулаучы һөнәренә түздең, гашыйк булдың дигән сүз. Димәк, эш мәсьәләсендә синең инде башка хыялларың булалмый!

Татар Суксу белән Мари-Суксу авыллары арасындагы күпергә килеп кергәч, бораулаучылар кәрванына юл бирәм дип, читкә чыгып туктаган «Москвич-412» машинасы колхоз рәисенеке булып чыкты. Машинасына күрә бу колхозның хәлләре әллә ни мактанырлык түгел, ахрысы, дип уйлап өлгергән иде инде Әмир, рәис белән күрешеп беренче сүз башыннан ук уйлаганы юш килде.

— Сезнең вышканы Такталачыкта күргәч, озакламаслар, безнең авылга ерак калмаган дип уйлаган идем аны. Өч көннән бирле сезгә фатир эзләп йөрим — теге якта да, бу якта да кертергә теләүче юк, — диде ул, мари белән татар авылларына таба күрсәтеп. — Колхозга эшләүчеләр берәү-икәү генә инде монда. Халык Дербешка пристанена качып бетте. Анда элеватор, фабрика, причал, ике катлы шәһәрчә фатирлар... Хәер, андагыларның көннәре санаулы — Чаллы плотинасы ябылгач, Дербешканы су басачак. Яңарак өйләрне сүтә башлаганнар инде — утынга саталар... Суксудан качканнарның ялынып кайтасылары бар әле — безнең авыл «зона затопления»гә керми.

— Алайса, без, сезне үтеп китеп, «Фрунзе» колхозына күченә торабыз, анда ике кое бораулыйсы бар. Башта Күҗәкәгә керсәк — аннан Адайдан кайтышлый сезгә тукталырбыз. Ул арада фатир табылыр, бәлки.

Әмирнең тәкъдиме рәисне рәнҗетте бугай.

— Егетләр, болай да әнә бөтен район миннән көлә инде. Өчәр ел буе көтеп ала торган бурильщикларны кулыңа кергәч ычкындыргансың, диярләр. Зинһар, күрәләтә үтеп китмәгез. Көтеп торыгыз бераз гына, апайларым, машиналарыгызны сүндерегез түлке. Салпы ягына биш олау салам сыя торган бер агай бар инде минем. Барып килим әле шуның кырына. Хатынының аш-суга кулы бәк тә ятышлы, ну агае гына бераз көнче кеше.

Рәис белән Әмир генә сөйләште.

— Хатыны чибәр мәллә?

— Чибәр димәсәң — хәтере калыр. Өченчесе инде ул аның.

— Бездән көнләшмәс. Фазылның хатыны әнә үзе белән, ә миңа инде алтмыш яшьтә ашау белән йокы эләксә — шул җиткән.

— Эләгә, эләгә, апаем... Бәй, чыраеңа күрә апаем да, яшеңә күрә агаем икәнсең ләбаса... Кем әйтмешли, Нурлыгаянның тәмәкесе сүнгәнче фатирлы итәм мин сезне.

Нурлыгаянның тәмәкесе бер сәгатьсез сүнми икән...

Фатир хуҗасының көнчелеге дә бераз гына булмаган...

Агайның өе иркен, тәрәзәләре күп, түшәме биек, ләкин стеналары буш. Бүрәнә аркылы тишеп кергән ут чыбыгының оясын каплап агач кысалы зур көзге эленгән. Тәрәзә арасындагы тар стенада пыяла артына тезелгән фотолар... Ул фотолардагы ир кешенең, яшьлегенә-өлкәнлегенә карамыйча, һаман да шушы агай икәнлеге танылып тора. Хатын-кызлары гына төрледән-төрле.

Төшкелеккә колхоз итеннән шулпа өлгерде. Ләкин табынны агай көйләде, ипи турады, тоз белән борыч куйды, ашны да кәстрүлдән үзе состы. Бу хәл Фазылга сәер тоелды.

— Абый, хозяйка өйдә юкмыни?

— Сиңа нәмәгә минем хуҗәйкә? Ашыгызны пешереп биргән ич — шул җитмәгәнме? Сез ашаганда, яныгызда биеп торырга тиеш мәллә ул? Әнә, синеке минекеннән дә яшьрәк, биет шуны.

— Юк инде, гаеп итеп соравым түгел, өйдә юкмыни, дип, болай гына...

— Нәмә эшләп өйдә утырсын. Сарайда ул, палас суга, заказлары күп аның. Бик теләсәң, әнә хатының өйдә хуҗәйкә булыр, кичкә бәрәңге боламыгы пешерешер... Ул яшьрәк тә, чибәррәк тә.

Агай, сосып бетергәч, кәстрүлне үзенә алды, ләкин ул ашны тәлинкәгә салмады, ә сосмалап чөмерде. Бу вакытта аның мут күзләре бөтенләй кысылды, чөнки шулпа кайнар һәм эчәр өчен парны суытып пырыш-пырыш өрергә кирәк иде. Сосма агайның йөзен каплаган арада, Язилә Фазылның колагына пышылдап өлгерде:

— Бу маньяк янында калдыра күрмә мине!..

Су скважинасы бораuланырга тиешле урынны билгеләгәндә, Әмирнең рәискә әйтер сүзе берәгәйле иде.

— Дустым, көне-төне тырышсак, өч тәүлектә эшне бетерербез. Торба төшергәндә, янда булырсың — сай борауладылар бугай дип шикләнмәс өчен. Бу фатирында өч тәүлектән ары түзалмабыз...

— Әгәр эшегез озаккарак сузылса?..

— Озакка сузылса — суы чыкмады, диярбез. Коры скважина итеп акт төзербез дә — хуш, Суксу, исәнме, Адай?!

— Алай нитмәгез инде, егетләр. Мин ул кулак малае белән сөйләшәм әле, сезнең белән ягымлырак кылансын. Өч төн түзмәскә инде.

— Нинди төн?! Кем анда төн кунарга җыена?! Безнең вагоныбыз бар. Ашауны да үзебез...

— Ашауны да үзебез пешерә алабыз, әйеме, эти, Фазыл, әйеме, — дип сүзгә кушылды Язилә.

Тегеләр каршы сүз әйтмәгәч, рәис сөенде генә.

— Алайса, көн саен свежий продуктыларны вагоныгызга лично китереп торам.

Менә шулай итеп буровойда Язиләгә дә эш табылды.

## Алиментны кем түли?

Май аеның сайрап торган көннәре исәпсез-хисапсыз озын кебек тоелса да, барыбер кич җитә. Агыйделнең аръягыннан кояш баеп кайтты — сырхаулабрак тора, ахрысы — кайтты да яшьнәп торган уҗым басуы читенә, алсу болытларга төренеп ятты. Дымлы кич яңа гаиләне Язилә учагына якынайтты. Табигать яшәрешендә сайрар кошлар бәйге тота. Тургайларның көндезге чыгышын инеш таллыгындагы былбылларның кичке концерты җиңде.

— Миннән яшереп кенә нәрсәләр турында уйланып утырасыз икән сез, балалар? — дип башлады сүзен Әмир, кызы белән Фазылны җавап тотарга өндәгән мөгаллимдәй. Бу ике кешегә эти булып дәшүаның үзенә дә бик ошый иде, ахрысы, тавышында яшеренеп яткан сөенечтән бер дәртле гөрелте бар.

Яраткан кеше белән яшәсәң дә, яратмаганына түзсәң дә, гаиләнең кыйбласы бер — ир кеше хатынның әсире ул. Әсирлектән котылмакчы булып качып караган бик күп агайлар исән түгел инде, исән калганнары җан асраучы мәхлуклардыр. Никах сарайларына гариза язып гаиләне рәсмиләштерү — әнә шул әсирлекне тану ул. Шуңа күрә Әмир абзагыз Фазыл белән Язиләдән загс кәгазе сорамас. Гаилә бөтенлеген яшәп исбат итсеннәр. Иртә-кич, көне-төне, айлар һәм еллар буе, гомер бакый чүкердәшеп кенә яшәп булмый. Бер карында үскән игезәкләр дә тынышмый дөньясында, ә гаилә исә бөтенләй ике чит кешедән ярала — ничек тынышмак кирәк! Әй лә, әрләшү-үпкәләшүләрдән соң татуланып сөелүе кызык. Әмирнең уйлавынча, әрләшкәндә кеше миенең бөтен күзәнәкләре уяна, сизгерлеге арта, хәрәкәтләре көчәя, каны кыза, күзләре яна, теле шомара. Әрләшү — җан һәм тәннең өстәмә генераторы кебегрәк. Әмир абзагызны битәрләргә ашыкмагыз. Яратмаган кеше белән яшәү — ялгызлыкның бер төре дип уйлап куяр ул. Уйлап кына калыр, Фазыл киявенә ишеттермәс. Язилә Әмир абзагызның иң газиз, иң гүзәл, иң яраткан хәзинәсе һәм бу хәзинә ышанычлы кулларда сакланырга тиеш. Кадерле байлык турында сүз барганда, кануннар кушканча гына эш ителми, дөреслеккә хилафлык кылып булса да, хуҗа кеше үзенекенә ирешәчәк. Язилә белән Фазылга бүгенгесе көндә Әмир хуҗа! Тегесе — үз кызы, монысы — кул астында эшли.

Фазыл белән Әмир арасында зур сөйләшү өлгереп килә. Һәм ул сөйләшү эш турында түгел, һич юк! Берәр авылга, ягъни яңа урынга күчеп утырдың исә, кемнең нидән эш башлыйсы билгеле, бернинди күрсәтмәләр, әйтеп торулар, җикеренеп-бакырынып өйрәтүләр дә кирәкми. Бораулау агрегатын проектта күрсәтелгән урынга остаз Әмир үзе китереп куя. Әгәр инде ерак araларга күченсәләр һәм кул алмашу өчен рульгә Фазыл утырган булса, барыбер Әмир сүндерелгән «МАЗ»ны яңадан кабызыр, агрегатның эш мәйданын үзе генә күргән тарафларга борып куяр, гәрчә кайсы якка карап бораулаудан нәтиҗә үзгәрмәсә дә. Нәтиҗә үзгәрми үзгәрүен, ләкин кояшка яраклашып эшләүнең бораулаучылар кәефенә ничек тәэсир итүен утыз еллык тәҗрибәсе булган Әмир эчке бер сизгерлек белән тоя иде, ахрысы. Сизгерлекме, әүлиялыкмы, гадәтме бу?.. Фазыл элегрәк, остазының холкын өйрәнгәндә, әлеге сорауларга җавапны озак эзләде. Яңа урынга күченеп кое бораулыйсы ноктага килеп туктагач, платформага чалкан яткан уналты метрлы вышка алагаем компаска әверелә иде. Яз айларында ул «компас» көнчыгышка таба күрсәтер, димәк, вышканы аягына бастырып, дүрт яктан корыч арканнар белән җиргә тарттырып ныгыткач, егетләр эш урынында таңны якты чырай белән каршы алырга тиешләр. Кояш чыгышына карап эш башлау кәефне күтәрә, көне буена җитәрлек егәр бирә, яшәү рухын сафландыра, яз сихәте тәнгә күчә... Өч айлык язны күрер өчен генә килгән сыерчыкларның ояларын да кояш чыгышына төбәп күтәрәләр һәм шушы өч ай эчендә алар сайрашып сөендерә, оя яңарта, бала үстереп өлгерә, иген кырларын саклый... Бер елны Таңсар авылына килеп туктагач, Фазыл агрегатны Шәрык илләре ягына таба борып калдырган иде. Ләкин Әмир әлеге «компас»ны, яңадан кабызып, төньякка таба үзгәртеп куйды. Бактың исә, чиллә җиткән, кояшка җилкә белән басып эшләр чак! Тал сулары кипкән, болыннарда, сары чәчәкләрне җыеп, кызыл чәчәкләр күтәрелгән; каен урманнарына ләүкә исе сеңгән; Әгерҗедә төенләнгән тимер юлларның шпалларында май эри; Ижаудан кунаклар килеп төшә торган Умга урманы эчендәге юллар тигезләнгән, Мукшур битендәге сабантуй аланының печәне чабылган. Ябалак аланы җиләккә

бөреләнгән, дүрт авылны сөендереп ураган йөгерек Чажда, каникулга кайткан малай-шалайга мактанып, авылныкылар су коена... Җәйнең мактанчык чагы башланган бит инде... Ә күзләрне Әмир кояш баешыннан эзли. Бухгалтерия кәгазьләрендә бригаданың эш көне сигез сәгать дип тамгаланса да, бригада якты көн үлчәме белән яши. Таң аткан икән — дизельне кабыза, кояш баегач — кайтып ял итә. Әгәр июнь ахырында эш көне унҗидешәр сәгатькә сузыла икән — моңа һичкемнең эче пошмый, авырыксынмый, күпсенми... Кояш юлы кыскара төшкәч, их, әрәм була озын көннәр, дип, уфтанулар башлана. Эш сәгатен көзнең сары сагышы кыскарта...

Соңгы вакытларда Әмир елның фасылларын буташтырып яши башлады. Егетләрне үртәгәндәй, җәйге кичләрдә тиктомалдан гына киез итек киеп куя; сайрар кошлар киткәнче үк, арбадагы тимер әрҗәдән сырган чалбарын эзли башлый; ике катлы эш бияләен кулыннан төшерми. Чүп өстенә чүмәлә өстәлә дигәндәй, иң сәере шул — Әмир хәзер, яз дими, җәй дими, гел көзге гамь белән яши, агрегатны көнбатышка борып куя. Егетләр чыраенда күбрәк шәфәкъ нурлары моңая. Мәдиярның мәзәкләре бетте, Фазылның иңендәге канатлары салынды. Эш тынып торганда, озын җөмләләр белән сөйләшүче юк. «Кабыз», «кит әле», «су куерды», «кувалда кая?», «үлчә!», «карын ачты» кебек өзек-өзек сүзләр, көннән көнгә күчеп, ымлыкка әверелде инде. Бу сүзләрнең ни аңлатканын һәркем белә... Егетләр кулдан килгәнне кабат-кабат әйттереп тормый, үзләре белеп эшли. «Кабыз!» дигәнче, двигательнең маен, ягулыгын тикшереп өлгерә. Читтә тезелешеп яткан бораулау торбасын якын китереп элмәкләгәч, аны күтәргән чакта «кит әле!» дип искәртәсе генә кала. «Су куерды» икән — өстән йөз атмосфералы басым белән кудыра торган су җир астындагы борауны — долотоның сырлы тәгәрмәчләрен юдыра алмый — су ташучы машинаны бушатырга кирәк. Бораулаганда көч белән кысылган торбаларны кыйный-кыйный сүтәр өчен — «кувалда кая?». Су катламын үтеп китмәгәек, проект белән чагыштырып «үлчә!». Кояш офыктан югалгач, кайтып ял итсәң дә ярый, чөнки «карын ачты». Бу ымлыклар да күбесенчә эш көне буена сузылган тынлыкны сискәндерер өчен генә әйтелә. Юкса яңа чишмәнең язмышы белән кызыксынып килгән авыл агайлары, боларга карап, буровщиклар бик нык үпкәләшкәннәр, су чыкмаячак икән, дип, хәбәр таратырга мөмкиннәр.

Фазыл Әмир белән зур сөйләшүгә әзер түгел. Үзеңне яклардай нинди генә дәлилләр китереп азаплансаң да, Әмирнең бер җөмләсе сине телдән яздырачак: «Башка кызларда өметең булгач, минем Язиләгә кагылмаска иде!» Шушы катгый хөкемнән соң каршы төшеп маташ син: кызың үзе бәйләнде, тәннәр тәнгә тигәч, шайтан котыртты, ай буе аулак вагонда яткач, ахыры ни белән бетәсе билгеле инде, дип, бала-чага шикелле акланып кара!.. Әмир сүз башларга җаен эзләп тора, кияүнең ялгыз чагын туры китереп янына килә дә баса. Фазыл инде моны белә, шуңа күрә эти кешенең авыз ачып сүз башлаганын көтми, юк-бар хәйлә табып, тизрәк шылу ягын чамалый, йә дизельнең радиаторындагы суын тикшергән атлы кылана, җир астына төшерәсе юан торбаларның озынлыгын үлчәргә тотына, йә вагонга Язилә янына кереп, су эчеп чыккан атлы итә.

Ахыр чиктә Фазыл үз язмышына күнде, күпме генә тартып-сузып йөрсәң дә, әлеге сөйләшүдән котылу юк, ике арада әйтелмәгән сүз сагалап йөрмәсен, эти кеше эчен бушатсын, тыңлап карыйм, диде.

Мәдиярның су ташый торган машина белән инешкә китүе иде. Язилә бораулау вакытында агрегат янына якын килми, аңа шулай әйтелгән. Тыгыз кызыл балчык катламына туры килдеме — долото агрегатны дыңгырдатып сикерми, тигез юлга чыккан җиңел машина шикелле тигез гүелди. Мондый катламда бораулау бик акрын бара.

«МАЗ» кабинасыннан арка терәвечен алып чыгып, чирәм өстенә куйгач, Фазыл уң аягындагы брезент ботинкасын салды. Майда кайнатылган сүсне баш бармагына эләктереп үрә башлады. Йөз атмосфера басымы белән су кудыра торган пычрак насос өчен, кирәге чыга калса дип, сальник әзерләве үзенчә. Шуны гына көткән Әмир тизрәк Фазыл янына елышты.

— Нихәл, кияү?!

Кияү дигән сүзенә үртәлми хәзер Фазыл, гел ишеткәнгәдерме, бу кушаматка ияләнде. Ә менә «нихәл» дигән сорау сабыр төбендәге тынычлыкны үртәде.

— Минем хәл күз алдында инде.

— Синнән генә калмаган, кияү, бөтенебез шулай өйләндек. Язиләнең әнисе белән дә менә шушы яшел вагонда кавыштык. Бөтен гомереңне кырда үткәч, хатынны да кырдан эзләп табасың аны.

— Мин хәзер синең язмышны кабатларга тиешме?

— Тәүбә, диген, кияү! Кызны синең өчен генә үстердек. Әнисе Суфия кем өчен үскәнен үзе дә белми иде. Булачак әбиең турында тәмсез сүз сөйләп, бүгенге кичне пычратасым килми. Ни дисәң дә, Язиләнең әнисе лә...

— Ник өйләндең соң син Суфия апага.

— Әбигә, дип әйт, җүнсез...

— Ну... әбигә инде, алайса, ник өйләндең?

— Ә менә син ник өйләндең?

— Мин өйләнмәдем әле.

— Өйләнмәдем?! Ай буе кызым белән вагонда ирле-хатынлы уйнап ятасыз да, җитмәсә, өйләнмәдем, дип, авыз тутырып сөйләп торасың.

— Мин өйләнүне «Никах сарайлары»на гариза язып, рестораннарда туйлап, диңгез буйларында ширбәт ае үткәрү дип белә идем.

— Соң, кем тыйган, загска барырсыз, туйны «Татарстан» ресторанында ике көн буе үткәрербез, ә диңгез ярына хет ярты елга китегез, мин кыз өчен акча җәлләмәм.

— Нинди загс, нинди ширбәт ае? Хәер, вагонда үткән бер айны ширбәт дисәң генә инде. Ә загска барыр өчен сөйгән кыз кирәк бит ул. Мин әле синең кызның кем икәнен дә белмим.

— Ничек белмисең?! Әнисе Суфия исемле, әбисе Разыя, әтисе менә мин булам, синең буровой мастерың. Тагын нәрсә белергә кирәк инде монда, калганын куеныңда, төн җиткәч өйрән, кем кушмый? Миннән хәер-фатыйха. Загска барасың килмәсә — барма! Язылышу дигән кагыйдә аерылышканда мал бүлү, фатир алмаштыру өчен генә кирәк ул. Әйтик, алимент түләүгә аның катышы юк!

— Нинди алимент?

— Бала-чага эше кыланмасана! Ай буе кочаклашып йоклагач. — Фазылның чырае агарып, үрелеп бетмәгән киндере кулыннан төшеп киткәч, Әмир әлеге хәбәрне ашыгыбрак әйтеп ташлаганын абайлады. — Нәрсә, Язиләнең сиңа ул турыда ым какканы булмадымыни әле?..

Фазыл бөтенләй каушап төште. Салып ташланган брезент ботинкасының парын яланаякка кияргә әзер иде ул, ләкин аягының баш бармагыннан бауның элмәген ычкындыра алмады, күрәсең, Әмирнең тәрбияви нәсыйхәтләрен тыңлый-тыңлый, бау чамасыз тыгыз үрелгән, ычкындырыр өчен кире сүтәргә йә кисеп ташларга кирәк иде.

— Мин хәзер синең күзеңә җен булып күренәмдер инде, әйеме, кияү. Ничава, түзәрбез. Бер-беребезгә түзгән өчен зарплата түлиләр безгә... Ә менә Язилә ятим бала үстерә калса, миннән иман әсәре көтмә! — Фазылның сыңар ботинкадан, яланаяк бармагына бау сөйрәлгән килеш вагонга — Язилә янына ашыгуының сәбәбен аңлап, чабыш атын куып җитәрдәй тавыш белән кычкырып калды. — Кызымны рәнҗетсәң, башың белән скважинага кадыйм мин сине, өстеңнән унҗиделе долото белән бораулап төшәм! Туксан метрлы коены кабер итәм үзеңә, бел шуны!..

Фазыл Әмирнең соңгы сүзләрен ишеттеме, юкмы, әллә исе китмәдеме, әллә барыбер идеме — уңгасулга карамыйча, туп-туры вагонга таба атлавын белде. Язилә аның баш бармагына бәйләнгән бауны күреп әүвәл көлемсерәгән иде, аннары күзләреннән нәфрәтле сорау барлыкны тоеп өнсез калды.

— Дөресме шул?! — диде Фазыл, әйтерсең лә Язилә ике ир кешенең сөйләшүен тыңлап утырган да җавапны алдан ук әзерләп куйган.

— Нәрсә дөресме?

— Син балага уздыңмы?

Шунда гына эшнең нидә икәнен аңлап алды Язилә.

— Абау, әллә нәрсә булган дип торам.

— Синеңчә балага узу пүчтәк эшме?

— Һи, Фазыл, ай буе сөешеп тә балага узмагач, корган агач булам түгелме соң?

— Миннән рөхсәт сорадыңмы син? Ризамы мин әти булырга, риза түгелме?

— Кеше көлдермә инде, Фазыл. Бирәү дә баланы Ходайга гариза язып сорамый. Бала табигать бүләге ул, үз вакыты белән килә.

— Причем монда табигать?! Алиментын табигать түгел, мин түлисе бит аның!

— Тәүбә, тәүбә, тәүбә! Ниткән алимент ул? Мине елатып калдырсаң, каргышым төшәр! Әллә шулай түгелме? Мин алимент өчен көтмим баланы, миңа син кирәк!

## Чегән туе

Килер бер көн, хезмәт кенәгәңә язылган елларны авылы-авылы, кешеләре-вакыйгалары белән исеңә төшереп юаныч табарсың. Каенлык авылы — суга килгән каз бәбкәләре тавышы, фатир хуҗасы Ниса кортканың онык-кызы Әлфинәне очрату белән; Актанышбашның клевер басуы шул Әлфинәне югалту белән хәтердә калыр... Әҗәкүл Агыйдел кичүендә яланаяк бозлы су ерып чыккан язгы минутлары белән төшләргә кереп сискәндерер. Уразайдагы Сәхипҗамал түткәйнең капка төбендәге торбалар өеме гел күз алдында торыр. Адай авылы исә Үмәни күлләре белән туенган печән болыннары һәм үскәч калага китеп җырчы булам, дип, бораулаучы Казан абзыйлары янында бөтерелгән ун яшьлек Асаф исемле малае белән искә төшәр. Донорлар саны буенча беренче урынны алсын дип, Зәмфирә исемле фельдшерга ияреп, бригада белән кан биргән Куян авылы бар әле... Баеп төшкән Актаныш кояшын дулкыннарга төреп көнбатышка алып киткән Чулманлы Дербешка саласын ничек онытасың?.. Олы урамыннан көн саен Казан самолетының күләгәсе үтеп китә торган Иске Актаныш... Ник соң гел Актанышка каныгып яши бу хатирәләр... Башка районнар, башка авыллар да бар бит... Бөтен сайрар кошларны үзендә әсир итеп toткан алма бакчалы Биектау Торнаязын, Әлфинәгә охшаган Суриясе белән Балтачның Смәелен кая куйдың, хәтер? Әгерҗегә сабантуйга кайткан коралльы кунакларны әлсерәтеп Чаж елгасы буй-

лап йөгерткән Сокман бәртәсләре, авыл уртасындагы карга ояларын Менделеев каласының төсле металл кәсепчеләре җыеп алган Бәзәкә тирәкләре ник алай тиз онытылырга тиеш?.. Хәтер дигәнең, җене белән үҗәтләнеп, карышып, бик күп авылларны ераккарак яшереп тора. Буш вакыт табылып, искә төшерердәй шарты һәм уйланып өлгерерлек минутлары булган саен, Актаныш авыллары күз алдына килә. Мәхәббәт хыянәт итсә дә, хәтер дигәнең Әлфинәгә хыянәт итми.

Ләкин... Суксу авылы да Актанышныкы. Ул исенә төшкәндә, Фазыл үртәлә, кимсенә, хәтта үкенә дә кебек. Суксу, Актаныш картасына түгелгән язу карасы шикелле җәелеп, хәтер өчен тансык авылларның исемен каплап тора. Әлбәттә, авыл һәм бигрәк тә аның Суксу дигән матур исеме Фазыл алдында гөнаһсыз. Бу — бары тик яшел вагонлы язмыш юлының уңышсыз тукталышы гына.

1971 елның җәе дөрес килде, хуҗалык мәшәкатьләрен үз урынына куйды. Майның унбишләре җиткәч, көтү чираты язып йөрүчегә маллар соңрак чыга быел, дип үпкәләүче юк. Балалар су коенырга киткәндә, күке кычкырдымы соң әле, дип аркылы төшмәделәр. Пешкән микән әле, дип, икеләнмичә җиләккә бардылар. Печән бүлгәндә яшьрәк түгелме, кипкәч кимемәс микән, дип, акыл сатучылар булмады. Халык печәннән урып-җыюга күчте, икмәкне үз вакытында ындырга салып, бәрәңге сабагы урырга кереште. Октябрьдә кар яумыйча торды — буранлы болытлар азык чөгендере җыелып беткәнне көтте...

Җәй көне эш белән ял бергә кушыла. Мари-Суксу белән ике арадагы инеш буасын карап кайткач, Мәдиярның гайрәте чикте. Су өстен кабилә-кабилә булып бәбкәле ак үрдәкләр каплап алган. Казлар исә, тегеләр боламык иткән буадан җирәнеп, яр читендәге өянке күләгәсенә тезелешеп яткан. Кое бораулау өчен суны Ямал авылының яр астындагы Агыйделдән ташырга туры килде. Суксу калын кызыл балчык катламы өстендә утыра. Мастер аны яратып «Уфа ятмалары» дип җиффәрә. Үзле балчыкка су сеңми, бораулаганда су күп китми. Мәдияр чокыр-отстойникка мулдан тутырып ике машина бушата да өченчесен мичкәдә килеш калдыра. Үзе Агыйделгә барган саен су коенып кайта. Ә инде җиләк кояшында бил тиңентен чишенгән килеш кызынып эшләп йөргән Фазыл машина мичкәсенә чумып рәхәт таба. Соңгы елларда җәйләр җиткәч, кыска сырманы арбадагы тимер әрҗә төбенә ыргытырга ашыкмый торган Әмир дә, кыска җиңле ачык изүле күлмәктән калып, трико ыштаннан йөри — бу инде «карт остаз»ның, үз теле белән әйткәндә, шәп-шәрә йөрүенә тиң...

Кызыл балчык тирәнгә төшкәч тә каты токымнардан исәпләнми, ләкин ул долотоның тешле тәгәрмәчләренә сыланып, аяк чолгавы сыман урала һәм тиз бораууларга ирек бирми. Таш катламын тишүе җиңелрәк — анда долото бушка әйләнми, тешләре, ташны уалап, бии-бии барыбер аска төшә... Бораулау тизлеге күзгә күренерлек булмагач, егетләр эч пошканнан агрегат тирәсендәге чокырлардан кузгалаклар, җиләк чәчәкләре арасыннан уксыннар өзеп чемченеп йөри. Язилә электр плитәсен озын шнур белән вагон эченнән чыгарттырды, аны ике кирпеч өстенә куйды... Сөт чиләгендә шулпа кайнаган арада, ул да, басу читеннән зәңгәр чәчәкләр җыеп, такыя үреп кигән. Үлән өстенә утыргач, аның җиңсез яшел халаты болынга сеңә һәм шул вакытта башындагы зәп-зәңгәр такыясы Язиләнең үзен ялгыз чәчәк итә, елмаеп утыруы күзнең явын ала. Ә кояшның җете нурлары, баш өстеннән туп-туры төшеп, яшел халат каплый алмаган ботларына ягыла...

— Ямьсез, дип әйтә алмыйсың син Язиләңне!..

— Минем аны ямьсез, дигәнем юк, Мәдияр.

Әти кеше ишетмәсен өчен, егетләр кузгалак яфрагы аркылы гына сөйләште.

— Әгәр Каенлык авылында Әлфинә урынына шушы Язиләң туры килгән булса?! Күз алдына китереп кара әле... бер белмәгән авыл урамында, төн уртасында, моңарчы таныш булмаган Әлфинәгә ияреп кайтып киләсең...

— Ияреп түгел, озатып.

— Ярар, озатып, дип әйтик. Хәер, без бит ул көнне икәү идек. Әлфинә дә иптәш кызы Нәсфия белән иде. Мин танышу көннәренең шаһиты, шуңа күрә озатуыбызны төнлә ияреп кайту, дип әйтергә ирек бир.

— Миңа барыбер, — диде Фазыл, кузгалак тоткан кулын селтәп.

Ләкин Мәдияр сизеп, күреп, тоеп тора, Каенлык, Әлфинә дигән изге исемнәргә ай буе битараф булып кыланган Фазылның күзләрендә янәдән өмет чаткылары сирпелеп үтте. Миңа барыбер, дип кул селтәгән ише кылануы чарасызлыктан гына, чынлыкта исә ул Мәдияр белән көне буе сөйләшеп утырырга риза — әгәр дә сүз Әлфинә тирәсендә барса.

— Менә шулай Богады белән Каенлык арасында ияреп кайттык. Тавышларын ишеттек, ислемай исләрен иснәдек, төн уртасында шәүләләрен күрдек.

— Төнлә, күз ияләшә торгач, йөзләрен дә күрдек.

— Күрдек. Төнге сурәт сыйфаты бозылган аклы-каралы фотокарточка кебек инде ул. Төнлә төсләр күренми. Күзләре, ирене, чәче нинди төстә икәнен белмәдең ич. Әгәр икенче көнне Ниса кортка оныккаена «Әлфинә!» дип эндәшмәгән булса, син әле ул кызны танымаган да булыр идең. Шулаймы, Фазыл?

— Дөрес инде...

— Вәт, мисал өчен, әгәр Әлфинә урынына ул төнне, Нәсфиягә ияреп, менә шушы Әмирнең кызы Язилә кайткан булса?.. Син хәзергесе минутта Язилә өчен саргаеп утырасы идең... Әнә ул Язилә, безгә ашарга пешерә. Янына бар да шап-шап итеп сөй үзен, бит алмасыннан гына үбеп ал, күңеле булсын кызның.

— Яучы итеп ялладылар мәллә сине?!

— Файдасы тисә, муллагыз булырга да риза... Җиңел килгән бәхетнең кадере юк аның. Безгә көрәш кирәк. Югалту, сагыну, газап, тән ярасы китерердәй мәхәббәтне олыларга оста без.

— Кем инде ул без?

— Без... ирләр! Кемдер синең Язиләң белән, күзгә-күз карашып, бер генә минут сөйләшеп утырыр өчен гомерен бирергә ризадыр әле... Ә син ах-ух киләсең, үкенүдән бүселеп — кулыңдагы песнәкне күрмисең.

— Ачу китереп торасың, Мәдияр, син дә. Ник соң үзең Әлфинәнең иптәш кызы Нәсфия белән кавышмадың? Әллә кайдагы Ростов өлкәсенең атаң-анаң күрмәгән Галинасы өчен өзгәләнәсең, ике шәһәр арасында свиданиегә йөрисең?

— Син генәмени, мин дә ир кеше ич!

— Өйләнүне сихри бер экияттер дип көтә идем мин.

— Һиндстан киноларындагычамы?

— Әйе... Танышасың... Яратышасың. Кавышу турында сүз кузгатасың. Никах сараена гариза бирәсең. Кире уйламасмы, башка егете килеп чыкмасмы, мине ташламасмы, дип дулкынланасың. Туйдагыларның «Ачы!» дип тагын-тагын кычкырганнарын көтеп үбешергә тилмереп утырасың. Туйдан соң... Кунакларның таралышканына сөенәсең. Ниһаять, сине аның белән аулак өйдә калдыралар. Бикле оҗмах эчендә син — шашкын да ул гына... Синең өчен генә, бары тик синең өчен генә үскән кыз бала ак-тан түшәлгән урын өстендә дерелдәп ята. Ул курка, чөнки аның әле моңарчы беркем белән дә болай якын килгәне юк. Ул карышмый, чөнки үз теләге белән синеке булырга риза! Ул ныграк курыккан саен, сине сөендерә генә. Аңыңны югалтыр дәрәҗәдә куанып, кыз баланың гомер буена саклап тоткан сафлыгына үреләсең. Ләкин син закон алдында да, туганнарың алдында да лаек. Кыз синеке...

— Кинолар да гел бертөрле түгел. Син әле генә сөйләгән сюжетны башыңнан кичергәнсең инде. Язилә синең өчен генә үскән. Икегез дә риза, этисе шат. Киноларның мондый төрләре юктыр дисеңме?

— Әйе, Язилә минеке. Ә кая соң ул — ярсу, шашу, дулкынлану? Сөенүләр кая? Туй кая?

Әлфинә исеменнән башланып киткән бәхәс куера торгач, Әмирнең якынаеп соңгы җөмләгә килеп кушылганын сизми калды егетләр.

— Һәй, кияү! Шашу, ярсу, сөенүләр — барысы илаһи уптым, беренче төндә ир кичергән бәйрәм генә ул. Кавышкач, җан тынычлана. Юкса гомер буе шулай дулкынланып яши калсаң, йөрәгең озакка түзмәс иде... Якын китермәсәләр, хатыннарыбызны гомер буе өзелеп сөяр идек без... Ә менә туй мәсьәләсендә хаклык бар... Мәдияр әйтмешли, үзебезчә кино ясарбыз. Ник әле минем бердәнбер сөекле, газиз, яраткан кызым никахсыз яшәп ятарга тиеш?! Җитмәсә, вакыт бик аз калып бара, кавышуыгызны Язилә яшерә алмас. Ир кешенең кыңгыр эше кырык елдан гына, ә хатын-кызныкы тугыз айдан ук беленә ул.

— Әрләшәсез мәллә, эти?! — Язилә, учак янындагы мәшәкатьләрен калдыра торып, ирләр янына килеп басты.

— Әрләшмибез, кызым. Менә Фазыл кияү баядан бирле мине үгетли, хәер-фатыйха бирсәң, бүген үк Суксу авыл советына кереп язылышыр идек, ди.

Ирләр сүзен башыннан ук тыңлап тормагач, Язилә этисенең уртәвен чынга алды.

— Дөресме шул, Фазыл? Син язылышырга ризамы?!

Бораулау торбаларын әрләән балчык өстендә әйләндерүне көйгә салган ротор гүләвен исәпкә алмаганда, вагон тирәсендә искиткеч тынлык урнашты. Бөтен чынбарлыкны тыеп тора алырдай һәм күңелдәге барлык хакыйкатьне фаш итәрдәй әлеге тынлыкны Фазыл тудырды. Аның җавабына карап йә тавыш чыга хәзер, йә сөенеченнән үрле-кырлы сикереп Язилә бии башлый.

— Әйе, — диде Фазыл, — безгә беренче төнне үк язылышудан башлыйсы калган...

Фазыл мондый имтихан тотарга әзер түгел иде. Җөмләнең сүзен сүзгә ялгап, ул гүя Язилә ишетергә теләгән җавапны Әмирнең күзләреннән укып әйтте. Әнә ич яшел вагон тирәсендәге сәхнәдә бүген зур спектакль бара. Әмир шул спектакльнең суфлеры, ул үз рольләрен яхшылап өйрәнмәгән яшь артистларга — Фазыл белән Язиләгә — бөтен әйтелергә тиешле сүзләрне йоласына туры китереп җиткерә бара. Фазыл үзенә тигән уенны авырыксынып, тартынып һәм карышып башкара. Язилә исә, гомер буе уйнарга тиешле образны эләктергән яшь актриса сыман, куанычын, канәгать дулкынлануын, өмете аклануын, кыскасы, бәхетле минутларын яшерә алмыйча, тыелгысыз сөенечен уртаклаша. Мәдиярга роль юк, ул бүгенге уенның бердәнбер тамашачысы. Ниһаять, спектакльнең ахыры бик күңелле бетте, дип кул чабарга әзер иде ул. Кавышу — язмыш дигән олы драманың кереш өлеше генә икәнен каян белсен ди Мәдияр?! Нинди роль башкарганыңны белер өчен, ул язмышны үз башыңнан кичерергә кирәк.

Эш тукталды. Долотоны күтәртеп, бораулау агрегатын сүндерделәр. Машина мичкәсендәге су кояшта җылынган иде, аны янгын сүндерү җиңсәсе белән һавага сиптереп яңгыр яудыра башладылар. Мичкәле машинаның насосы үзендә, двигательнең әйләнешен арттыргач, су фонтаны бәллүр колга булып күккә үрелә дә, болытларга буе җитмәгәнгә уалып, Фазыл белән Мәдияр өстенә коела. Сиптергеч брандспойт Әмир кулында иде, аны Язилә килеп алды, этисе егетләр белән бергә душ керсен дигән иде үзенчә. Ләкин зур басым белән атылган суның көчен абайлап өлгермәде — брандспойт, кулыннан ычкынып, ком өстенә ташланган чуртан кебек тоттырмас өчен бәргәләнә башлады. Фазыл килеп ул «чуртанның» өстенә сикерде. Әлбәттә, машинаны сүндереп суны туктатырга була иде, ләкин берәүнең дә моңа кулы бармады, су чәчрәтеп уйнау сагындырган...

— Бар, тизрәк вагонга кереп коры киемеңне ки, сиңа туңарга ярамый! — диде Фазыл, сиптергечне үз кулына алгач.

Ниһаять, ир роленә кереп әйтелгән кисәтүне ошаттымы, Язилә, сабыйларча чыркылдап, вагонга таба йөгерде. Ни арада киемнәрен алыштырып бетергәндер, ул инде кояшлы яңгыр астында канатланган ирләрне пәрдәсе корулы тәрәзә почмагыннан күзәтеп тора иде.

Машина мичкәсендәге дүрт кубометр су бөтен икеләнүләрне, борчу һәм шикләнүләрне юып төшерде.

— Кияү, бар, вагоннан безгә коры күлмәкләр алып чык. Анда сиңа гына керергә ярый.

Әмир белән Мәдияр юеш комбинизоннарны корыч арканга элгәндә, Фазыл, юеш трусигын күтәрә-күтәрә, вагонга ашыкты. Ишек кул белән кагылганны да көтмичә ачылып китте, чөнки тәрәзә почмагыннан күзәтеп торган Язилә көтә иде инде аны. Юеш киемнәрен салса да, Язилә корысын кимәгән әле. Җиңнәренә тыгылмыйча гына зәңгәр халатын бөркәнгән.

— Биклә ишекне тизрәк,— дип келәгә үрелгәндә, халаты да, иңеннән шуып, вагон идәненә төшә язды.

Фазыл бер кулы белән халатны тотып өлгерсә, икенче кулы белән Язиләне үзенә кысты. Инде ай буе бергә яшәгәннән соң, ниһаять, беренче тапкыр үбешүләре иде бу. Тик ни хикмәттер, Фазыл үбешкәндә күзләрен чытырдатып йомды һәм күңеле белән билгесезлектән тиз генә Әлфинәне эзләп тапты... Әлфинә Сөн суында чирканчык алып сөлге белән сөртенгән. Аның тыгыз һәм шома тәнендә дулкын салкыны. Менә ул Сөн дулкыны кайнап чыга һәм Фазылга үтеп керә. Урын өстенә ашыктыручысы да, сөлге канаты белән кабыл-тибел тәнен корытучысы да, «Сал инде шул юеш трусигыңны!» дип искәртүчесе дә Әлфинә үзе сыман... Йә Хода, хыянәтнең мондый төре дә бар микәнни?! Бу мәхәббәт уенында катнашу искиткеч рәхәт иде Фазылга...

Рәхәт булган җирдә хәтәр бар. Һәм Фазыл, янәшәдәге чынбарлыктан кача-поса гына, үз-үзен ирексезләп, әкияткә табынган самими малай кебек, яшьлектә югалган рәхәтен гел күз алдына китереп юаныр.

Вагоннан коры киемнәр күтәреп чыкканын ишек төбендә саклап торган диярсең, Әмир, хәл белер өчен, Фазылны баскычтан ук каршы алды.

— Нихәл, кияү?!

Моңарчы кушамат рәвешендә тагылып килгән «кияү» бүген, ниһаять, бөтенләй башка мәгънә белән яңгырады. Кызның этисе шушы сүзгә тантаналы вәкарь белән үртәүнең икесен бергә сыйдырган. Әлеге яңгырашны чит кешеләр аңларлык җөмлә белән тәрҗемә итсәң: «Мин ничек әйтсәм — шулай булды! Кушамат белән юраган юш килде», — дигән мәгънәне аңлата алыр иде. Су ташучы мичкәле машинага утырып киткәндә, ул вагон тирәсендәгеләргә кабина ишеге аркылы кычкырып калды:

— Мин бер сәгатьтән әйләнеп кайтам, любой маҗарага әзер торыгыз!..

Маҗара озак көттермәде.

Маңгаена «Агыйдел» дип язылган «Кубань» автобусыннан берәм-берәм туй кунаклары төште. Кемнәр икәнен кай арада хәтерләп өлгергәндер, Әмир агитбригада җитәкчесе кебек таныштырып барды. Иң беренче булып автобустан ак кепкалы, күн чабаталы, соры футболка өстеннән ашыгычлык белән бәйрәм пинҗәге кигән түгәрәк гәүдәле, әмма җитез агай төште.

— Суксу авыл советы председателе, кулында пичәт белән загс журналы! — диде Әмир, тантаналы пафос белән.

Ак кепкалыга шәмәхә сатин халатлы ике хатын ияргән иде.

— Болары никахның пүнәтәйләре! Гафу итегез, ике свидетель, алдынгы сыер савучылар. Төшке ашка кайтып килешләре. Кызым, доярка апаңнарга аш сала тор.

Гармунчы һәм җырчы Азат дигәннәре баскычларга басып тормыйча очып кына төште бугай — оста биюче дә икән үзе.

— Күрше Иске Кормашның сатучысы, районның танылган җырчысы — Хәния! Туп-туры район мәдәният йортыннан репитициядән урлап алып килдем, — дип, таныштыруны дәвам итте Әмир...

Авыл советы, язылышу турындагы таныклык тутырыр өчен, Фазыл белән Язиләне вагонга алып кереп киткәч, калган кунаклар учак янындагы брезент җәймәгә аяк бөкләп утырдылар. Алай да Мәдияр, ыгы-зыгыдан файдаланып, гармун тавышын җиңәрлек итеп кенә, Әмирдән сорашып өлгерде:

— Бу кадәр халыкны ничек көндерә алдың?

— Һәммәгезнең дә өй түренә кое бораулап бирәм, дидем.

— Мастер булгач, рәхәт сиңа! — Мәдияр, ничаклы бушлай эшлисе барын ачыклагандай, кунаклар санын барлады. — Алты коелы алтын туй!

— Алты түгел, бишәү генә! — диде Әмир, Мәдиярны җиңәргә теләп.

— Ә «Кубань»ның йөртүчесе «лә-лә-лә»гә йөриме? Рульдәге кеше эчми дә әле ул. Мөгәрич белән котыла алмассың!

— Ярар, кызны кияүгә биргән көнне вакланып тору килешмәс.

Күчмә загс эшне тиз тотты. Язилә «шпилька» үкчәсе белән вагон баскычына чык-чык басып, язылышу турындагы таныклыкны укый-укый брезент җәймә янына килеп басканда, Әмир майга томаланган кильки белән ташкабак уылдыгы банкасын гына ачып өлгергән иде әле.

Кунаклар, сүз куешкандай бердәм борылып, Язиләгә текәлделәр. Туй күлмәге кимәсә дә, кәләштән нур бөркелә. Сатин халаттан килгән савымчылар һәм сабан туена әзерләнгән җиреннән борынгы татар кызы булып киенгән җырчы Хәния янында Язилә аеруча балкыды. Кыска һәм күпертмә җиңле, тезенә тияр-тимәс яшел күлмәге, юк җилне дә тоеп, тәнендә уйнап тора. Путасы кысып бәйләнгән нечкә биле аны курчакка охшата иде. Толымга сыймаган калын кара чәчен, тузгымасын өчендер, күлмәк җирлегеннән телenгән яшел тасма тыеп тора. Очлы үкчәләре батып-батып җиргә кадалса да, аның чем-кара туфлиләре үлән арасыннан калкып бара.

«Нәкъ әнисенең яшь чагы!» — дип уйлап куйды Әмир. Һәм, күз тимәсен дигәндәй, авыз эченнән «ботка пешереп» алды: «Тәүбә, тәүбә, заразы, җүләр башка җүләр уйлар килә дә тора...»

Актаныш гастрономының коопторг бүлегеннән алган дүрт оч поши колбасасын кискәлисе урында, кисәкләргә сындыргалап ипи телемнәре өстенә ыргыткач, Әмир туйга килгән халыкның кыймшанырга куркып җансыз утырганын абайлап алды.

— Мәдияр, чит кеше кебек утырма, сыйла кунакларны. Бүген безнең бәйрәм. Стаканнарны тотырып сал, аракы җитәрлек!

Калай тәлинкәләргә шулпа бүленде, ләкин кунаклар кулга кашык тотарга ашыкмады. Авыл рәисе, бүгенге мәҗлеснең сәяси ягын кайгыртыпмы, вагон хуҗаларына ымлады:

— Дога урынына дигәндәй, берәрегез сүз әйтсә, яңа кавышучыларны хуплар идек...

— Сүз әйтер кеше мин инде монда, — дип, Әмир янә табын хуҗасына әверелде, тик аш янында утырган урынын ипли алмыйча интекте.

Кунаклар әнә — кыр ыстанында колхоз шулпасы чөмереп үскәннәр диярсең — тәлинкәләрне аяк астына туры китереп, брезент өстенә сузылышып ятканнар. Аяклары чирәмгә чыккан, терсәкләренә нык таянганнар, бер кулларында кашык, икенче кулда икмәк телеме.

Әмир, намаз сабагына өйрәнгән шәкерт кебек, тезләнеп утырды.

— Әйтсәм әйтим, кунаклар, без бүген кызыл туй алдыннан репетиция ясыйбыз. Чын туй Казанда булачак, Суксуда эш беткәч. Менә, сез, — диде ул, Азат белән Хәниягә аяк кагып, — район сабан туена репетиция ясап ята идегезме бүген, без дә шулай. Язилә кызымны, бердәнбер баламны, җил-давылдан саклап, кул-теш тидермичә, Фазыл кияү өчен генә кадерләп үстердем. Әйеме, кияү? Фазыл, әйеме, дим?

Авызында ипи кисәге булгандырмы Фазылның, «әйе» дигәне «ы-ы» булып ишетелде.

— Әти кешенең җаны кыз балада. Язиләм өчен генә яшәдем. Гомер буена тырышып эшләвем дә аның өчен. — Һәм Әмир күкрәк кесәсендәге документлар арасыннан күгәрчен тамагы төсендәге саклык кенәгәсен аерып алды. — Мә, балакаем, туй күлмәге, алтын балдак, бер «Москвич» машинасы — бөтенесе шушында, тормыш башлап җибәрергә ярап куяр. Иеме, кияү!

Бу юлысы Фазыл «әйе» дип тә, «ы-ы» дип тә җөпләмәде, каршы дәште.

— Үзем дә әйбәт эшлим мин. Кызыңа дигәне кызыңа булсын.

— Ничек инде кызыңа?! Вәт син аны чумарлы авыз! Хәзерге яшьләр сөйләшә белми, хатыныма, диген!

— Ну, шуны әйтәм ич... Бирнәле кызга өйләнергә мин гарип-гораба түгел лә!

Әмирнең сүгенергә исәбе бар иде, кунаклар алдында чак тыелып калды. Тезләнгән җиреннән кырын янтаеп, кулына эләккән беренче стаканны сусаганда тустаган каплаган ише генә бушатып куйды.

— Эчәсезме инде, юкмы сез, — дип җикеренде ул, кабымлык кабарга ашыкмыйча, — мәет озатырга җыелмадык ла! Нормальный совет семьясы корып маташабыз, идрит-кудрит!

— Су чыгаргач, санэпидстанциядән анализ кайтканны көтмибез, иң беренче булып үзебез эчеп карыйбыз, менә болай итеп, — диде Мәдияр, бер стаканны бушатып.

— Язгы чәчүләр беткәч, механизаторлар белән, Үмәни күле янына җыелып, без дә өлешне тигезлибез. — Һәм машиналы авыл рәисе буш стакан эзен ак кепкасы белән сөртеп куйды.

Кырлы стаканга Азат үрелде.

— Берәрне капласаң, биюченең аяклары җиңеләя.

Кунаклар чират буенча Хәниягә таба борылды.

— Атналык ревизия уңышлы үтсә, безнең эше сатучыларга да хәрәм түгел ул...

Сыер савучылар парлашып чәкештерделәр.

— Ирләребезгә азрак калсын өчен, бу зәхмәтне үзебез чөмерергә дә риза!

— Сезнең бу фикерегезне хуплыйм мин, — дип, Язилә дә тулы стаканга үрелгән иде, өлгермәде, аның кулыннан Фазыл тартып алды.

— Сиңа ярамый... Миңа ярый.

— Дөрес, кияү, эш узгач, уйнарга ярый...

Аштан алдан ач карынга стакан тутырып эчкәнгәдер, кунаклар, җиңеләеп, тиктомалдан көлешә башладылар. Хәзер алар өчен бөтен нәрсә көлке: автобус йөртүченең эчмәве дә, чиләктә пешкән ит күтәрәменең коштабакта туралмаган килеш кукраеп торуы да, авыл рәисе кулындагы ак кепканың кулъяулыкка әверелүе, үзеннән көләләрдер дип уйлап, Фазылның турсаеп утыруы, күләгәсез табын өстендә җәйге кояшның көйдерүе, сыер савучыларның сатин халат итәген җилфердәтеп уйнаган шаян җил дә кәеф күтәрерлек сәбәп булып тоела иде.

Әмир, кырын яткан килеш, ике генә кашык аш каба алды. Тагын тезләнеп утырды.

— Кызым, синең фамилияң ничек хәзер?

— Шәмсетдинова Язилә Әмировна, әти, — дип, яттан белгән нәрсәне язылышу турындагы таныклыктан укыган булды. Аның тавышында әтисе генә сизәрлек зур җиңү тантанасы бар иде.

— Хатын-кыз бәхете — ана булуда, балакаем.

— Ә ир бәхете нәрсәдә? — дип, фырт җавап таләп итте Фазыл.

— Ир бәхете — мәхәббәттә! Хатын-кыз бәбиләгәч бөтен мәхәббәтен балага бирә. Мәхәббәтнең гарантиясе тугыз ай гына, сөеп кал, кияү! Ана үрдәк ояда утырганда, аучыларга ата үрдәкләрне атарга рөхсәт бирелә. Ир кеше симәнә чәчәр өчен генә кирәк ул.

— Әйе, безнең Суксуда язгы-көзге чәчү кампаниясе гел ирләр кулында, — дип, киеренкелекне уенга бормакчы булды авыл рәисе, — механизаторлар арасында хатын-кызлар юк.

— Причем монда механизаторлар! Кепкаңны ки, башыңны кояш сукты мәллә, нәсел орлыгы чәчү турында сүз бара, надан! Менә бүген Фазылның фамилиясе минем фамилиямне җиңде. Кыз бала ул нәсел агачының ышанычсыз ботагы. Шуңа күрә сез миңа малай алып кайтырга тиешсез. Гомер буе тел очымда йөргән исеме дә бар — Салих дип кушарбыз, Ходай боерган булса!

— Ярар соң, әти, ярар! Малай да, кыз да апкайтырбыз, исән генә булыйк.

— Малай кирәк, и бетте-китте!.. Әгәр ул малайның исемен Фәрит дип кушсагыз — белегез шуны, мин аны кулларым белән...

Әмир ипи урынына тоткан поши колбасасын учы белән кысып өзде дә үлән арасына ыргытты. Шуны гына көтеп йөргәндәй, ике ала карга, юктан бар булып, ике кисәкне күтәреп күккә ашты.

Кунаклар, теләсә-теләмәсәләр дә, ашауларын дәвам итәргә тырышты. Янәшәдәгеләр белән сирәкмирәк сүз ыргытышып, ишетмәмешкә сабышып яту дөресрәк иде бу минутта. Язилә, оялуын яшерә алмыйча, әтисен юатырга мәҗбүр булды.

— Әти! Син ничек әйтсәң, шулай итәрбез! Салих — бигрәк матур исем бит, әйеме, Фазыл? Әйт инде, Фазыл, әйе, диген!

— Әйе! Салих Фазылович — матур яңгырый.

Әмирнең кирелеге хәтсез иде.

— Әниегез Фәрит кушыйк, дияр! Беләм мин аны, уйнаштан туган нәмәрсә, кешедән калган курчак...

— Әти, дим, кунаклардан оял! Тигезлек белән парлашып гомер иткән хатының турында шулай әшәке сүз әйтеп. Әни ич ул миңа! Ир кеше була бел, ичмасам...

— Кем парлашып гомер иткән? Минем гомер менә шушы яшел вагонда үтте. Яшьлегем дә, картлыгым да шушы дүрт көпчәк өстендә. Әниең кая соң? Кызының туе бара, ник юк ул монда?

— Соң, әти, туй түгел, уен гына, дип, үзең әйттең ич.

— Уен?! Загс белән шаяралармыни...

— Алайса, — дип, авыл рәисе тагын кепка белән авызын сөртеп куйды, — әйдәгез аерабыз! Пичәт кесәдә, журнал безнең кулда, пүнәтәйләр яныбызда!

— Мин сиңа аерырмын! — дип, Әмир йодрыгын төйнәп, аягүрә баскан иде, шаяртучының рәсми кеше икәнен абайлап, кисәк айнygандай булды. — Ярар, кызым, кияү, ачуланма, кунаклар, бигайбә, мин ләх икәнмен, вагоныма кереп ятыйм лутчы. Ә сез — туйны бетермәгез. Ник җырламыйсыз? Гармун кая?

— Ашамыйча эчкәч, мондый кызуда тиз исертә шул. — Язилә әтисен көйләп вагонга озатып куйды.

— Болай нык исергәнеңне шушы яшемә җитеп беренче тапкыр күрәм әле, — дип аптырашка калуы кунаклар алдында әтисе өчен гафу үтенү кебегрәк яңгырады.

Мәҗлес тагын ярты сәгать чамасы дәвам итте. Кунакларның сабырлыгы шуннан арыга җитмәде.

— Минем нәрәткә әзерләнәсем бар, — диде рәис.

— Лагерьга кичке савымга киткәнче өйдәгеләргә күренеп чыгыйк, — диделәр савымчылар.

— Безнең сабан туена әзерләгән номерларны райком кешесе тыңларга тиеш бүген, — дип, Хәния Азатны ашыктырды.

Ә Азат, агитавтобуска кереп китәр алдыннан, тальян гармунны колачлап тынып калды. Ул нинди көй уйнарга белмәде. Мәхәббәт җыруы сузсаң, әле Хәния кушылып җырлап та җибәрсә, Әмир тагын уянып чыгар. Татарның мәхәббәт җырлары гел үкенечле бит ул, майт якаңны, любой исерегеңне уятып тәүбәгә китерерлек!

— Һәй, чегән тормышы инде боларның, билләһи! Туйлары да «чегән туе» шикелле, — дип көрсенеп куйды Азат.

Тальян гармун, авыр сулап, «Хуш, авылым» көен сузды. Автобус киткәч тә, җыр Фазылның колак төбендә бик озак чыңлап торды. Әйе шул, гаилә кору өчен дә, бәхетсез булыр өчен дә мең төрле шарты бар... Ә бәхетле булыр өчен бары тик бер генә мөмкинлек — яратышып кавышу кирәк. Хәтта ике бәхетсезне кавыштырып та, бәхетле гаилә корып була. Ләкин үзем яратам дип кенә яратмаган кешене парың итәргә тырышу иң зур бәхетсезлек, чөнки бәхетле янында бәхетсез яшәргә тиеш...

Әмир йокысы туеп уянганда, Чулман белән Агыйдел кушылган тарафлардан таң атып килә иде инде. Вагон эчендә ул үзе генә йоклаган булып чыкты. Мәдияр савыт-сабалар өелгән брезент җәймә читендә тәгәрәп калган. Колак төбендә зыңлап торган иртәнге тынлыкта ул күңеле белән яшьләрне эзләде — кияү белән кәләш, аулак өй эзләп, авылдагы фатирга киткәннәрме әллә? Юк икән — алар «МАЗ» кабинасының сәндерәсендә, сулышлары тәрәзәнең эчке ягына томан булып кунса да, Фазылның күкрәгенә капланып йокыга киткән Язиләнең яшел күлмәге күренеп тора... Әмирнең моңа күңеле булды — димәк, җиһанда тәртип! Эчке дөньягыз көйләнер әле. Беребезнең дә гамь казаны буш түгел...

Ул, шыгырдавык идән өстендә йөргән тынгысыз каената кебек, башкаларны уятмас өчен, үлән өстендә килеш аяк очында йөрде. Сызык-сызык салкын төтен чыгарып яткан кечкә учак читендәге корымлы чиләкне күтәреп, калган ашның шулпасын чөмерде. Шул минутта ул үзенә куәт, гайрәт һәм тәвәккәллек өстәлгәнен тойды... Кереп юл капчыгын тутырды, документларын барлап күздән кичерде һәм, чыелдап уята күрмәсен дипме, вагонның ишеген дә япмыйча китеп барды.

Кызы борчылып тормасын өчен, куен дәфтәренең сыңар битенә язып калдырылган хушлашуда ике генә җөмлә иде:

«Мин пенсиягә киттем. Агрегат кияү өстендә кала.

Әмир бабай».

Суксу авылында, су чыгарып, эшне төгәлләгәч, гадәттәгечә Казаннан прораб Сәфәров килеп төште. Колхоз идарәсендә исәп-хисап кәгазьләрен тутырган чакта бораулаучыларның күчеп китәсен сизеп алгач, «чегән туе» кунаклары Әмирне бик нык эзләгән, диделәр. Өй түребезгә коелар бораулап бирмисезмени, дип, Фазылны үгетли башлаганнар иде. Яңа мастерның җавабы кискен булды: «Прораб алдында кыек-мыек эшләр тәкъдим итеп җинаятькә этәрмәгез. Кем вәгъдә биргән — килер дә эшләр!»

«Агрегат кияү өстендә кала...» дигән язу кисәге коры сихер ише әфсен-төфсен генә иде. Пенсиягә китеп баручы Әмирнең теләге тәкъдим буларак искә алына. Ләкин кадрлар мәсьәләсен Казандагы мелиорация тресты хәл итә. Аннан соң Фазылның Мәдиярныкы кебек махсус белеме юк. «Бораулау остасы» дигән катыргыны алыр өчен Ростов өлкәсенең Батайск шәһәренә барып, бер ел укып кайтасы бар. Моңарчы укырга җибәрәбез дигән боерык ишетсә, Фазылның җен ачуы чыга иде, быел әзер түгел әле мин, дип, еракка китеп белем алып кайтуны елдан-елга күчерә килде. Ә дизелист рәвешендә гади бораулаучы булып эшләү өчен аңа урта мәктәп күләмендәге механизаторлар курсын бетергәне дә бик җиткән. Ләкин быел Ростов өлкәсенә укырга китү чынлыкта Фазыл өчен еракка олагып, яшьлекнең Әлфинәдән алып Язиләгә кадәр булган өлешеннән онытылып тору, уйлану һәм хәлиткеч нәтиҗә ясау, дөресрәге, беразга югалып тору өчен кирәк иде. Элегрәк укырга дигәндә ялындырган, икеләнгән, тешетырнагы белән карышкан булса, хәзер ул үзе теләктә тора һәм хәтта, җибәрсеннәр өчен, җитәкчеләргә ялынырга да әзер, кирәк икән качып китәргә дә риза.

Мәҗбүри укытуның сәер яклары бар аның. Ел саен трест карамагына өч бораулау остасы әзерләргә дип, әнә Мәдиярны исемлеккә кертеп җибәргәннәр иде. Ә ул, лимит буенча әйбәт кенә укып кайтып та, агрегатны үз өстенә алырга, яңа бригада төзергә теләми. Трестка чакыртып үгетли башлагач: «Алайса, мин бөтенләй үк эштән китәм!» — дип, гариза язарга тотына. Җитмешенче елларда Казанның һәр баганасы, һәр белдерү тактасы, һәр гәҗите «Эшкә чакырабыз», «Ашыгыч рәвештә кирәк», «Түләп укытабыз», «Килегез!» дигән игъланнар белән тулды. Шуңа күрә «Эштән китәм» дип сүз ору начальствоны бераз шүрләтү, куркыту өчен янау алымына әверелгән иде.

Суксудан соң бораулау агрегатын Казандагы гаражга куаладылар. Мәдияр вакытлыча гына башка бригадага кушылды. Машиналарның күпчәкләрен акка буяп бүкәнгә күтәрделәр.

Фазылны, фронтка озаткан кебек, ерак сәфәргә әзерләделәр.

Язилә елады да елады. Аның хәер-фатыйхасын алыр өчен әтисе дә шактый тырышты: «Кияү дөрес итә, җае килгәндә укырга кирәк. Син җиде ят кулында калмыйсың. Әниең белән икебез дә пенсиядә. Онык туса, кулдан төшермәбез. Моңарчы хатынын вагонда ияртеп йөргән бораулаучы булмады. Үз өеңдә яшә, ирееңне көт. Кайтыр, сугыш заманы түгел...»

Үгет-нәсихәтнең нәтиҗәсе булды, Язилә Фазылны аэропортка чаклы озата барды, самолет Казан өстенә күтәрелгәч, артыннан каргап калмады.

Чемоданыңны үлчәүгә чаклы булса да күтәрешеп йөрермен дип кенә ияргән Мәдияр, аэропорт бинасындагы радиодан «Имеются билеты рейсом до Ростова-на-Дону...» дигән игълан ишеткәч, ирексездән кесәләрен капшап алды. Паспорты — урынында, акчасы — җитәрлек! Ул инде кияү белән киңәшеп тормады. Тиз арада билет алып килде.

— Никтер кисәк кенә Галинаны сагынып куйдым. Барып хәлен белеп кайтыйм. Миннән башка типтереп ятмый микән анда?! — диде Мәдияр, акланган ише кыланып. — Сиңа да иптәш булырмын. Ни дисәң дә, чит шәһәргә үзеңне генә җибәрәсем килми...

## Тән башка, җан башка

Соңгы елларда Әмирнең җаны тәненә буйсынмады. Тәне тәвәккәлләп берәр гамәл кылса — җаны шуның киресенә өнди. Әйдә, Әмирҗаным, ди Тән, кайт өеңә, сөендер Суфияңны, җан атып йөрергә син бит инде малай-шалай түгел, иярләнгән түшәгеңә чум, баш астыңдагы мендәрдән каз бәбкәләре тавышын тыңлап йокыга китәрсең, ди. Юк, ди, Әмирнең Җаны үзенең Тәненә, мин бераз йөрим әле, син бар, кайтып кайнар шулпаңны чөмер дә, ваемсыз хөрәсән булып тирән эчле утыргычка ишелеп, телевизор кара, ди. Тән тагын ялынып карый: кайт инде, Җаным, кайт, олыгайган көнеңдә кеше көлдереп йөрмә!.. Киребеткән Җан тәки үзенекен итә... Шулай итеп, Әмирнең Җаны урамда кала. Тәне өенә кайтып керә — исән-имин, сау-таза килеш, Җанын югалтып...

Суфияттәй ирен ишектән каршы алу йоласында Әмирнең күзләренә тутырып бер карый да катгый карарын әйтеп сала: «Абау, Әмир, бүген чистый җаның чыккан, ничек кайтып җиттең?!» Өч төрле бал тулы касәләр, яктырып торган юка фарфор чокырларга ясалган бөтнекле чәй, көмеш чәнечке кадалган сумсалар, бүксәле банкага салынган балан суы, чүлмәк шешәле Рига бәлзәме, ачык тәрәзә аркылы күршеләргә барып җитсә, уңмаган киленнәрне әрләттерерлек шулпа исләре дә кайтара алмый Әмирнең Җанын.

— Әмәлең азган нәмәрсә! Җитмешкә җиткәч, ата мачы кебек чорма эзләп йөрмәсәң... Оныгыңа утыз тула! Кыямәт көнендә ни дип җавап бирерсең?! Кем белгән аны, әллә ул көн бүген җиткән. Тәүбәгә кил, оланнардан оят...

Орышып кына иреңә Җан кертеп буламыни?! Бер тәүлек кизү торып, өч тәүлек ял итә торган эше бар Әмирнең. Әнә шул өч ял көненнән шикләнә хатыны. Сабырлыгы төкәнгән көннәрдә Суфияттәй хәтта Әмирнең Җанын эзләргә чыга. Сәгатьләр буе иренең артыннан күзәтеп йөри. Әмир, хатынның эзәрлекләвен сизгән шикелле, Казан каласының бер башыннан икенче очына сугылып, көнче бичәне хәлдән тайдыра, башка эшең юк икән, әйдә, яшь киленнәр кебек тик йөре шунда дигәндәй, мәйданнар гизә, паркларга керә, үзенең җанына урын табалмый.

Гомеренең иң көчле елларын сәяхәтле һөнәр белән мавыгып үткәргән элеккеге бораулау остазы Әмир хәзер телевизор каршысында чит илләрнең бозык рәсемнәрен карап утырсынмы?! Җырларда җырлана торган авылларда атналар буе яшәп, исемнәре шигырьләргә күчкән елгаларда коенып, бәетләргә-дастаннарга әверелгән язмышлы кешеләр белән аралашып, карталарда сызылмаган сукмакларны таптап, сусаганнар өчен яңа чишмәләр өләшеп йөргән ирне кем аңлар? Урынга егылмаган килеш, саусәламәт Тәне белән колбиләүче Суфияттәйнең шәхси колы булып ята алмый ул.

Йокы бүлмәсендә пәрдәнең корылганы юк. Балкон тәрәзәсе аркылы йолдызлар санап яту — кайчандыр бораулау мәйданындагы болын өстендә үткән кыргый төннәрне хәтерләтә. Айның унбишләре җитте исә, Суфияттәй, тулган айны каплар өчен, кер бавына үзенең берәр эчке күлмәген элеп куя...

Кырда эшләп үткән гомернең сәер киләчәге бар икән... Әмир, мактаулы картлык көнендә суган-сарымсак, җиләк-карлыган үстерербез, дип, бакча җиткермәгән; май ахырында өзелгән каен ябалдашлары белән кинәнеп табыныр өчен мунчасы юк; туганнарның хәлен белеп кунактан кунакка йөрим дисә — үз машинасы кая? Әмир картлыкка әзерлексез килде. Димәк, ул һаман иске рәвеш, әүвәлге гамь, мажарага юмарт көннәр белән яшәргә тиешле кеше.

Яшәү — эшләү инде ул. Эш урыны су тирәсендә булганда яши әле Әмир абзагыз...

## Тән ачкычы

Олыгайгач кеше барометрга әверелә икән. Һава торышларын ярты көнгә булса да алданрак әйтеп, дус ишләреңә искәртеп, кирәксә кисәтеп, күңелеңә килгән табигать шартлары белән таныштыра аласың. Тыңлап торучың яшьрәк булса, тагын да әйбәтрәк. Яшьтәшләр белән бераз җайсызрак, чөнки һәр өлкән кеше үзен генә иң төгәл барометр дип исәпли, башкаларның фаразын бик өнәп бетерми... Олыгайган саен, кешедә кыласы гамәлләрне күз алдына китерү арта, тотынмаган эшнең ахырын алдан күрү һәм хәтта киләсе хәвефне җаны белән сизеп тору көчәя, гүя кемдер, сиңа гына ишетелерлек итеп, кола-

гыңа пышылдап куя: «Тор, Әмир, эш урыныңда йоклый күрмә, бар, урамга чык, иренеп ятма, картлач!..»

Берсе-берсе тегермән ташы әйләндерерлек дүрт электр моторы гүелдәп торганда, әүлияларның пышылдавын ишетер өчен күңел колагыңның хәйран сизгер булуы кирәктер.

Тимер сәкедән торып, астына җәелгән җиңсез сырманы җилкәсенә элгәч, калай бүлмәдә эсселәнде. Үзләрен-үзләре өрдереп суытса да, тәүлекләр буе эшләп торгач, электромоторларның тәне җылына һәм кизү торучы агайларның эш урыны бөркүләнә. Тимер баскычлардан күтәрелеп, калай палубага чыгып баскач, Әмир иң беренче эш итеп җилнең юнәлешен эзләп тапты. Бозлы Идел өсләтеп кенә Әстерхан ягыннан язгы җил килеп тора — ул үзенең барлыгын сиздерерлек талгын һәм кемдер җылытып торгандай дымлы иде.

Ул тәмәке кабызды, бер уңайдан янып бетмәгән шырпы яктысында кул сәгатен карап алды. Төнге сәгать өч. Тагын ике сәгатьтән яктыра башлый, аннан соң тагын өч сәгатьтән Әмирне алыштыручы икенче «барометр» килә.

Тоз базасында нужасыз калган әлеге баржаны, арканнар белән сөйрәп китереп, мехчылар фабрикасы өчен су кудыру станциясе иттеләр. Бу баржа язгы ташкыннарга ияреп бик агып китәр иде дә — колач җитмәслек торбалар белән фабрикалы ярга койрыгын бәйләп куйганнар. Эчәр өчен түгел, хөрәсән сарыкларның тиреләрен юып, затлы туннар тегәр өчен бик күп кирәк шул ул су... Көтү тузаннарын, әрәмә тигәнәкләрен, абзар таплары сеңгән тиреләрне тәүлекләр буе җебетеп, кер сабыннары белән баркасларда кат-кат юып, тунаганда калган майларын кырып, йоннарын тигезләп кыркып, шомартып, кыскасы, хатын-кызлар тәнен сөендерердәй назлы кием иткәнче, һәр тун саен уникешәр тонна Идел суы әрәм ителә.

Әмирнең эш урыны җәй көннәрендә зур дулкыннар бәрелгәндә уйнаклый. Ярдагы торбалары шарнирлы — язгы су күтәрелгәндә өскә калкырга, җәйләрен, Идел кимегәндә, су өсте белән тигез торырга тиеш. Һәрхәлдә, бүгенгәчә шулай иде.

Таң ерак әле. Иделнең сул ярына фабриканың яшел таш коймалары таң нурларын кертми. Шуңа күрә кояш түбәләр арасыннан чыккач кына баржа тирәсе кинәт яктыргандай була.

Бүгенге җилнең Әмир кулындагы шырпыны сүндерергә дә көче җитми. Әмма абзагызның барометры сизә: язның җылы җиле тымызык, хәйләкәр, мәкерле була. Томалап куелган дулкыннарны ирекkә чыгарыр өчен боз астына кереп исә бугай мондый җилләр... Баржаның бүрәнә төягән арба кебек шытырдавын ишетер өчен әллә ни тынлык кирәкми, мондый хәбәр баскан җирендә табан астыңнан үтеп керә, сизгерлекне көчәйтә. Бүселгән боз ярылганда, Идел өсте баржаны күтәрерме? Шарнирлар эшләрме, аларны кыш буе беркемнең дә майлаганы юк лабаса?! Хәер, Әмир әлеге хәвефкә юраган халәтне үзе өчен уйлап кына чыгара бугай. Аның еллар буе хәвеф-хәтәрсез эшләгән су насосларын өч-дүрт сәгатькә генә хуҗасыз калдырып киткәләгән чаклары бар. Баржада бер тәүлек кизү торганнан соң, өч тәүлек ял итәргә тиешле. Мех берләшмәсенең генераль директоры һәм су белән тәэмин итү цехы начальнигы имзасы куелган график буенча Әмир абзагыз кебек дежурныйлар айга җиде-сигез көн генә эшли булып чыга. Түзәрлек анысы... Ләкин кеше дигәнең аунап яткан мөмкинлекне күрмәмеш-белмәмешкә сабышып үтеп китмәс... Төнлә белән начальство үз өендә, кизү торучы слесарьларның эш урынындагы хәлен тикшереп йөрүчеләр юк, үзеңә-үзең хуҗа булып тик утырасың. Утырасың-утырасың да: һәй, мин җүләр, нәрсә утырам әле монда, бу насослар, мин барында да, мин югында да, ун ел буе шул килеш исән-имин эшләп ята лабаса... Өйгә кайтып тамак ялгап килергә кирәк, мәҗбүри вакыт дигәнең ике-өч сәгатькә кыскарып өлгерер...

Һәм Әмир язгы төн уртасында, баржа тирәсен йомып алган тимер капкага тыштан алкалы йозак элеп, кайтып китте. Өенә түгел, әлбәттә... Аена җиде-сигез тапкыр, ягъни график буенча күрешә торган Фираясы бар аның. Төннең кайсы сәгатендә килеп керсәң дә уяу, чөнки баржаның калай ишегенә ябыштырылган графикның күчермәсе Фираяның көзгеле тартмасында ята. Әмир киләсе көнгә ханым өч тәүлек буе хәстәрләнә. Ишек ачылып, коридорда сүрән ут кабынуга, Фирая аны «Дежурныем минем!» дип каршы ала, баржада киеп йоклый торган сырмасын салдыра. Әмир бит-кулын юганда, беләгенә сөлге салып янында тора, үзе ике дежурство арасында булган яңалыкларны тезеп сөендерергә керешә.

«Яңа кофта алдым. Чәчем матурмы, буявын үзгәрттем. Санаторийдагы безнең белән торган теге Альмиралардан открытка килде, сине дә котлаганнар...»

Әмир Фираяның фатирына малай-шалайлар баскыч төбендәге лампочканы бәреп ваткан төннәрдә дә кармалап керә ала. Тимер ишекнең ачкычлары үз оясын бик җиңел эзләп таба. Әлеге ике ачкыч Әмирнең эштә кия торган чалбар кесәсенә куен сәгате чылбыры белән тагылган. Ясле яшендәге балаларның бияләйләрен пәлтә җиңенә кереш белән тегеп куйган кебек, Әмирнең Җан ачкычлары да эш киемендә. Шуңа күрә эш сәгате бетүгә, абзагыз иң әүвәл чалбарын салып элеп куя, аннан соң гына сырмасын сала башлый. Менә шуңа күрә дә ул ачкычлар өйгә ияреп кайтмый. Әгәр ялгышып кайтсамы?.. Суфияттәй әлеге ачкычлар белән Казан каласындагы бөтен ишекләрне тикшереп чыгар һәм төн эчендә барыбер автовокзал тукталышын ышыклап торган биш катлы йортның Әмир Җаны саклана торган фа-

тирын эзләп табар иде... Әйе, кергәләп йөр, дип әйткән ди йозак бер ачкычка. Абзагыз Фирая фатирына гел эш киеменнән килеп керә. «Мин өйдә, мин көтәм» дигән хәбәрне аңлатып, дежур көннәрдә Фираяның кухнясында төне буе сүрән ут сүнми.

Үзе өчен генә махсус сатып алынган дежур халат белән киез табанлы калын чүәкне киеп куйгач, Әмир Фираяның фатирында хуҗа кешегә әверелә — фатирына гына түгел — яшь ханымның хәятына, хисләренә һәм таушалмаган тәненә... Суфияттәй тирәсендә чал чәчле бабай булып яшәгән Әмир агай, Фирая ханымның фатирына кергәч, башка вакыт үлчәме белән яшәүгә күчә. Йокың киләме, дип сораса, абзагыз, киресенчә, ваемсыз аю йокысыннан уянып китә. Сакалың үскән, дип, яңагыннан сөйсә, ханымның өч көн буена җыйналган энергиясе аңа күчә. Өй исе сеңгән чүпләмле сөлге белән битен сөртсә, чыраена нур өстәлә. Фирая төн уртасында пешергән чәй, аның канына таралып, әкияттәге тереклек суыдай, утыз яшькә яшәртә. Йокы күлмәгенең күкрәк өлешендә беләзек чаклы гына уелган ачыклыктан балкып торган сөтләч тәне, мәктәп баласыныкы кебек кашларына чаклы төшеп торган маңгай чәче, сулаганда саңаклары тибеп торган почык борыны, ягымлы сүзләрен берьюлы әйтеп бетермәс өчен мәҗбүри йомылган яшь иреннәре, көлемсәр күзләре — мине сөеп кал, санаулы көннәреңнең кадерен бел, минем янда гына Җаның бар синең, дип ымсындырып тора.

Бактың исә, Суфияттәйнең дә юкны күрердәй үткен күзләре бар, сизгер борыны, яшереп калган сүзләрне ишетерлек колаклары исән, бәлеш ярата торган авызы, Аллага шөкер, сулы чиләк күтәрердәй куллары сау. Әмир яратканга күрә, чүпләмле сөлгесе шкаф өсте тулы, ул да шундый ук базар чәен эчерә. Әмир кайтып кергәч, иннек-кершәннәрен юып төшерсә, имән чикләвеге чаклы гәрәбәләрдән тезелгән муенсасын, җинаятьчеләр кулына кидерә торган богау чаклы көмеш беләзеген салса, колак кикриге чаклы алтын алкаларын кими торса, Суфияттәй дә матурая. Нәрсә эзләп чыгып китә соң картлачның Җаны?! Фирая белән Суфия арасында тик йөри Әмир, ник йөргәнен аңлый, тик сораган кешегә кайтарып әйтә генә белми. Урталыкта аның урыны. Әгәр урталыктан чыкса, Суфияттәй белән Фирая чәкәләшеп бәрелешерләр кебек.

Яшьләр куенында яшәрерсең, карт кулында картаерсың, дигән фараз Раббым исеме белән яратылган яшәүнең үсеш канунына шик төшерә түгелме соң? Димәк, олыгайган һәр кешенең Җанында яшьлек качып ята. Димәк, картлык дигән афәтне сизмәмешкә сабышып, яшьләрчә күңел иләсләндерү бәхетсез җаннарны сагалап йөри... Картлык әсирендәге Тәннең канатлы Җаны гел яшьлек тарафына ашкына.

Фираяның баш очындагы сәгатьнең сакау күкесе көч-хәл белән бишне кычкырды. Апрель ае өчен бик уяу вакыт инде бу. Тынгысыз сакчылар авыл буйлап дудур шакылдаткан кебек, мехчылар бистәсен уятып, трамвай рельсларны саный башлады. Шәһәр халкының теге яктан бу якка, моннан тегендә йөренә торган чагы җитә. Кеше күзенә чалынганчы Әмиргә эш урынына ашыгырга кирәк. Тавыш-тынсыз гына юрган астыннан чыгып качсаң — Фирая хыянәткә саный, берәр җиремне ошатмадың мәллә, дип сорау алачак.

— Кызый, бу сәгатеңнең күкесе бөтенләй сакауланган бит синең, саный белми.

— Яңасын алып бирмисең ич.

— Беләсең лә, базарларда сәгать эзләп йөри торган кеше түгел мин. Акча гына калдырыйм.

— Төн кунып чыккан өченме?

— Ну шушы телең — үзе тәмле, үзе әче.

— Китәр вакытың җиткәч, көнләшә башлыйм. Шул ястык карчыгың янына җибәрәсем килми... Әмир уяна, юына, киенә, пәп итә һәм өенә кайтып китә!

— Өйгә түгел, эшкә. Өч көннән көт.

— Дежурныем минем.

— Кыланма, Фирая, вакыт юк.

— Ник әле Суфияңны гына дежурный итмисең? Өч көн буе миндә яшәриең, эш төнендә аның янына — баржага йөрерсең...

— Шушы яшьтә судларда аерылышып йөрүләре оят ич инде.

— Өч көнгә бер сөяркәгә килү оят түгелме?

— Хатыннан китәр өчен «обходной»лар тутырып йөрер чагым үткән.

Әмир ике ачкычлы чалбарын һәм күпне күргән сырмасын киеп куйгач, Фирая телсез кала, тимер ишек ачылып ябылган арада: «Исән-сау эшлә!» — дип әйтерлек ягымлылык таба.

Үзен эш урынында ни көткәнен белми әле Әмир.

## Их, җаным суларда

Әйе, чыннан да, олыгайган кеше барометрга әверелә. Ләкин Фирая куеныннан чыккан мәлдә Әмирнең барометры атмосфера басымын дөрес күрсәтмәде. Бүгенге таңның атуына ул үз өлеше кергән дип исәпли. Иртәнге якта кар булып яварга тиешле язгы дым күңелендәге өмет җылысыннан эреп юаш яңгырга әверелгән. Төннең кыскаруына ризасызлык белдереп, түбә песиләре төшеп килә. Яңа бистәдә туып үскән каргалар, кайтканнан бирле, ояларында саташып ыңгыраша.

Эш урынына килеп җиткәнче, тәнгә юрган астында сеңгән кайнарлык суынды. Кеше тәненең иң сизгер төше — муены... Урамга чыгу белән яңгырның ике-өч тамчысы тиюгә үк, Әмирнең муены кыскарып калды. Сырманың тар чүпрәк якасы юешләнеп муен чокырын чиркандырып бара. Әмир, башын аска игән килеш кенә, калай капкадагы алкалы йозакны салдырды. Капкадан баржага чаклы сузылган тимер басмага менде. Шунысы сәер... Гадәттә палубага, ягъни өскә таба алып менәргә тиешле тимер басма никтер аска таба алып төшеп бара, алай гына да түгел, аның икенче башы су эченә кереп киткән! Әмир Идел өстенә таеп төшәсе иде, басма читенә тотынып өчен сузылган колгага таянып калды.

Эш урыны юк Әмирнең — Идел йоткан аны.

Идел ярның ныклыгын тикшергәндәй киерелгән, дулкыннары боз кантарлары арасыннан кысылып чыга, яр читенә көздән үк ябышып каткан такта кисәкләрен көчәнеп-көчәнеп каера. Су биеклеге арт-канда баржага күтәрелергә ирек бирергә тиешле шарнирлар күгәреп каткан, турыдан-туры насосларга тоташкан торбалар каерылып баржаны ерткан һәм су баскан. Берсе-берсе олау чаклы дүрт электр двигателенең утка тоташкан килеш су астына ничегрәк чумганын күз алдына китерү өчен махсус белгеч булу кирәкми. Әлеге култыкта су балык шулпасына әверелгәндер...

Баржа Идел өстеннән бөтенләй күренми, тимер басма гына түгел, багана башыннан төшерелгән бастырык юанлыгы электр кабеле дә су эченә кереп калган, хәтта мехчылар фабрикасының АТСына тоташкан чыбыкның телефонлы очы да су төбендә. Вәт шылтыраталардыр хәзер Әмирне сүгеп! Сәгатенә 150 тонналап Иделне йотып, тәүлек буе туктамыйча тире эшкәртә торган җиде фабрика берьюлы кинәт сусыз калсын әле! Җиде фабрикадан өсте-өстенә шылтыратып та дежур Әмир белән сөйләшә алмагач, смена мастерлары хәзер үк эзләп килеп җитәчәк. Ә тагын ике сәгатьтән, цех начальникларын, инженерларын, энергетикларын һәм урынбасарларын ияртеп, генераль директор үзе килер. Баржаны күтәрергә дип, елга портыннан йөзмә краннар, агып киткәнче Әмирнең гәүдәсен кичекмәстән эзләп табарга дип, водолазлар китертерләр, ремонтчылар, ашыгыч медицина ярдәме, милиция җыелыр... «Кирәк бит әй... Ник шунда йоклап кына калмадым да баржа белән бергә су төбенә китмәдем икән мин?! Тукта... Эш урыным суга баткач... Ник соң әле мин җир өстендә йөрим? Сорау ала башласалар: «Ни булды? Ник син коры? Ничек исән калдың?» — дип теңкәңә тиярләр. Суфияттәң кебек «Кайда йөрдең?!» дип тә өстәсәләр... «Юк, мин бу хурлыкны үз күзләрем белән күрергә тиеш түгел. Мин юк! Югалдым мин», — дигән ныклы карарга килде Әмир һәм аның Җаны белән Тәне, бергә кушылып, Фирая фатирына кереп качты. Качкан урыны, аңа калса, әлегесе минутта тынычлык оясыдыр — юрган асты суынмаган иде әле... Күзен ачса да, йомса да, дөм караңгы. Фирая гәүдәсенең юрган астындагы өлеше күренми. Кабергә тиңләр идең — бөркү һәм чамасыз эссе монда. Метрлап-метрлап җир тишә торгач, кое бораулаучы абзагыз кабер тирәнлегендәге туфрак җылысының ни дәрәҗәдә булуын чамалый бераз. Газраил юрган астына кулын тыгарга оялып йөри торгандыр. Әмир, җанын-тәнен бер итеп, үз йөрәк тибешен үзе тыңлап ята. Бәләкәйдән үк үлемнән курыкты ул. Җил көчәйсә, шайтан өермәсе күтәрелә дип уйлады; «Яна!» дип кычкырсалар, үзенә ут капкандыр төсле тоелды; яшен яшьнәсә, никтер, башкалардан аерып, аны сугадыр кебек иде; утсыз бүлмәдә тирән йокысыннан бүленеп уянып китсә, үзен кабер эчендә яткан кебек итеп тоя иде. Өне алынган, коты ботына төшкән, җаны чыккан, мәрткә киткән минутлары күп булды инде аның. Үлемнән куркуы — җан биргәндәге тән авыртуыннан түгел, ә гомернең кыскалыгыннан. Әмир һаман бәхетен эзли. Бәхетле булыр өчен бу гомер генә җитмәде әле аңа. Бәхетне ул иске нигезләрне актарганда килеп чыга торган хәзинәле чүлмәк кебегрәк күз алдына китерә иде. Гүя, эзләп тапкач, кулыңа тотасың да — син шул минуттан бәхетле кеше! Фираяның юрган астында нинди хәзинә эзли соң әле Әмир? Әнә йокы җаен югалткан ханым ипсез калган аягын Әмир өстенә аркылы салды. Бәхет дигәнең шушыдыр, бәлки. Әлбәттә, шушы! Юрган астыннан чыкса, Әмирне өтермә көтә! Өтермә — шул ук кабер инде ул, бары тик зуррак, яктырак, тавышлырак, сасырак кына. Анда Фираяның кайнар аяклары да, җан җылысы сеңгән юрганы да, Суфия җанашы пешергән шулпалы бәлешләр дә юк. Иң мөһиме — яраткан эш өчен кырда кыргый бала булып гомер кичергән, иялэнгән иркенлек һәм иректән мәхрүм калачак. Әмир — дала кошы, читлеккә япсалар — үлә! Баржа белән бергә су төбенә баткан җиһазларны, аны күтәрергә сарыф ителгән чыгымнарны, Әмирнең гәүдәсен эзләп көне буе Идел төбен капшаган водолазларны бәхилләтер өчен картлык көнеңдә тоткынга ябылып түләргә туры килерме? Ничә сумга төшәр икән? Иске баржаны күтәреп яңадан ямарлар. Кырык бишәр киловаттлы дүрт двигательне алыштырсаң, мех берләшмәсенең ике көн буе сусыз утыруын исәпкә салсаң — егерме «Жигули»лык сәмәнеңне «даешь»! Хәер, чыланган двигательләрнең эчендәге кәтүкләрен яңадан урап алыштырырга була, тәк, моңа бер «Жигули» хакы җитә. Мехчыларга күрсәткән зыян өчен түләп котылырга рөхсәт итсәләр, сөенер иде Әмир. Эш урынын ташлап киткән, берләшмәне эшсез тоткан, водолазлар ялларга мәҗбүр иткән, дия-дия, матди зыян өстенә әхлакый зыяннарны чутлап өстеңә өйсәләр — Фираяның юрган астында качып яткан Җаныңны ирегеннән мәхрүм итәселәрен көт тә тор! Әллә барысын да ачыктан-ачык сөйләп Фирая белән киңәшеп карargaмы? Ул бит хәзер Җан сакчысы. Әгәр Әмир баржаны ташлап Суфияттәй янына кайтып киткән булса, абзагызны күптән алып киткәннәр иде.

Әллә аны үз өенә эзләп килмәгәннәр дисезме? Гаилә дип аталган фатирыңа кайтырга куркып ят менә хәзер.

— Әмирҗаным, чык инде, тынчып ятма юрган эчендә.

Фирая Әмиргә яшәү дәрте өстәп тора. Җитмешкә җиткән агага ялгышып та «бабай» дип дәшмәс, үртәмәс, үчекләмәс, киресенчә, ул, аның шушы яшьтә сирәк очрый торган гыйшкына сокланып, «дәртлекәем» дип зурлап сөя. Һәм Әмир аның саен үсенеп комарлана, үзен яңа гына өйләнгән яшь кияү итеп тоя, Фираяның мактавына гайрәт вә дәрт белән җавап бирә... Ә өенә кайткач ул бабайга әверелә. Язиләнең улы Салих, «бабакаем» дип, күпме генә төчеләнмәсен, Әмирнең күңеле эреми. Кызының: «Әти, буяулы идәнгә яланаяк басма, синең яшьтә үзеңне карабрак йөрергә кирәк, җиңсез сырмаң кая, ник кәләпүшеңне салдың?» — кебек сүзләре хәтта ачуын кабарта. Яңгырлы озын-озак кичләрдә Суфия еш кына үлемтеккә дигән малларны барларга ярата. Ул икесенә җитәрлек кәфенлекне, сәдакага өләшер өчен җыелган исле сабын, яулык, оек, кулъяулык ишеләрне санарга керешсә, Әмирнең Җаны тагын өйдән чыгып китәр өчен талпына башлый.

— Әнә телефон, Салихка шылтырат, киңәшеп кара. Ул бит милициядә эшли, — диде Фирая, баржа маҗарасын тыңлап бетергәч.

— Өстемә килеп төшсенме? Икебезне күрсенме? Кайсы өйдән шылтыратканны шундук ачыклый бит алар.

— Алайса, урамдагы таксофонга чык! — Фирая үз тавышындагы гадәти ягымлылыкны сакларга тырышты. — Бер минуттан ары сөйләшмә, юкса эзләп табарлар.

— Урамга чыксам, Яңа бистәнең ярты халкы таный.

— Алайса, ни дип әйтергә дә белмим инде.

Тәгаен фикергә килә алмыйча, өч көн буе качып ятты Әмир. Әле дүртенче көнне дә үзенең исәнлеген сиздерергә исәбе юк иде.

Гомердә булмаганны Фирая аңа беренче тапкыр бүген эш кушты. Утын сараеның түбәсендә кар авырлыгыннан сынган ике тактаны алыштырасы бар икән.

Әмир, йортка кергән мәхлук кебек, иренеп кенә киенде. Түбәгә менгәч күреп танымасыннар өчен, сарык йоныннан эрләп бәйләнгән беретканы кашларын капларлык итеп батырып киде. Мине кычкырып чакырырлык итмә, ишегалдына чыккалап тор, дип, Фираяны кат-кат кисәтте. Ләкин тегесе, Әмирҗанның тимер баскычтан түбәгә менә башлавын күрү белән, телефон төребкәсенә үрелде... Исем фамилиясен һәм кайсы районда эшләвен белгәч, лейтенант Салих белән бик тиз тоташтырдылар.

«Салих Фазылович, сезнең дәү әтиегез... Әйе, әйе, бабаегыз исән!»

«Тапкансың шаярыр нәрсә! Без бүген аның өчесен үткәрдек инде».

«Гәүдәсе табылган кешене генә үлде, диләр. Хәбәрсез югалган кешенең кабере юк ич. Күмелмәгәч, аның өчесен йөрәгең җитеп ничек үткәрмәк кирәк?»

«Суфия әбекәй әйтте, язгы су төбендәге кеше җир куенында инде ул, йоласын үткәрик, диде. Эшеннән килделәр, мактый-мактый бәхилләшү сүзләре әйттеләр. «Мехчы» гәҗитендә некролог чыгарганнар. Профком, конвертка салып, мәет сәдакасы китерде».

«Соң, алайса, бабакаең эш урынына барып суга сикерсенмени инде».

«Телефоныгызны куегыз әле. Мин сезгә... Фирая ханым, үзем шылтыратыйм. Никтер начар ишетелә башлады».

Салих хәбәр салучы кешенең дөреслегенә ышанып өчен үзе шылтыратты.

«Алло, Фирая ханым, апа, ул чынлап исәнме?»

«Исән инде, исән! Үзең генә кил. Безне табуы бик җиңел. Макаронный фабрика каршында яшел түбәле такта өй булыр...»

Капкадан килеп кергән лейтенантның Салих оныгы икәнен абайлап өлгергәнче, Әмир сарай түбәсеннән егылып төшә язды.

## Әмир өрәге

Газраил җаныңны алса, шайтан телевизордан күрсәтә икән хәзер. Мех берләшмәсендәге һәлакәтне кичке «Яңалыклар»дан ике көн рәттән күрсәттеләр. Гәүдәсе табылмагач, Әмир хәбәрсез югалучылар исемлегендә калды. Шулай итеп, Әмир Сабирҗанович Әшрапов, исән-сау килеш, ялган хәбәрләр арасында «хәбәрсез югалды». Әмирнең өшегән күңелен җылытырдай бер генә өмет бар — әгәр ул кылган гамәлләр законны бозу саналса, аны, һичшиксез, табарлар иде. Хокук сагында торган агайлар җинаятьчеләрне эзли, ә хәбәрсез югалганнарның гәүдәсе табылганын көтеп ята. Шуңа күрә дә Фирая капкасыннан килеп кергән милиционерның Салих икәнен танымаса, ул үзен закон каршында кем дип аталачагын чамалый иде. Хөкемдарлар алдында җавап тоту кыен хәлдер, әлбәттә, ләкин хезмәт формасы кийрдәй яшькә җиткән оныгың алдында акланырдай сәбәп табу да җиңел түгел.

— Дәү әти, ник син монда? Кем бу хатын?

Әйе, әйе, оныкның сораулары кургашыннан коелган. Дәү этисенең Җанын эзләп тапкач: «Син исәнмени?!» — дип, үрле-кырлы сикермәде, «Ник син монда?!» — диде. Чит ханымның итәге астында качып ятканчы, гәүдәң су төбеннән чыкса, туганнарың-якыннарыңның йөзе пакь калыр иде, ичмасам, дип аңларга кирәк әлеге кинаяне.

Аклану бары тик ялган җавап кына була ала иде, шуңа күрәме Әмир дәшмәде.

— Син безгә нинди үрнәк күрсәтәсең? Карт анаңа охшагансың, дип, гомер буе дәү әнине әрләдең. Ә үзең... Димәк, эти дә сиңа охшаган булып чыга. Менә ни өчен безнең гаиләдә, нәселебездә бер бәхетле кеше юк. Әйт, алайса, эти, мин кемгә охшарга тиеш? Сиңамы — җитмешкә җитеп, качкын хәлендә яткан хәсискәме, әллә утыз ел буе гаиләсен кайтып күрмәгән этиемә охшаргамы? Идеал итеп куярлык ирләр кайда соң ул хәзер?

— Балакаем, бәгыремне телгәләмә. Допрос алып торма, бир пистолетыңны, атылып кына үлим лутчы.

— Үлү җиңел ул, дәү эти. Үз-үзеңә кул салу куркак җаннар эше. Син тормыш авырлыгыннан курыкмыйча яшәп кара! Үлем батырлык түгел, яшәү батырлык хәзер...

— Минем батырлык кемгә кирәк инде ул...

— Миңа, дәү эти, миңа кирәк. Язилә кызыңа — әниемә кирәк. Һич югы, дәү әнине кызган... Бөтенегез дә бертөрле бит сез зимагурлар! Язмышыгыз, ялгышыгыз, тапкан-югалтканнарыгыз бертөрле... Хәтта бүлнис күрмичә картаюыгыз да... Гомер буе саф һавада, табигать кочагында гаилә нужасыннан качып яткач, саулык нык буладыр инде ул. Сез инде тазалыкка, көрлелегегезгә чыдый алмыйсыз.

— Балакаем, бу хурлыктан исән-имин котыла алмам шул.

— Ялган җәрәхәтне ялган шифа белән төзәтергә була. Телевидение белән сөйләшүне үз өстемә алам. Минем эштә мондый хәлләргә беркемнең исе китми. Кеше исән калган икән — сөенәләр генә.

Өчесен үткәргәннән соң капылт кайтып керсә, бусагада Әмирне күреп, Суфияттәйнең йөрәге ярыласы иде. Әле дә ярый, телевизор, яңа хәбәр җиткереп, өйдәгеләрне зур сөенечкә алдан әзерләп куйды.

«Мех» берләшмәсендәге авариядә хәбәрсез югалган Әмир Сабирҗан улы Әшрапов табылды. Ул исән. Шәһәр больницаларының берсендә ята. Кайда икәнлеген тикшерүчеләр әлегә сер итеп саклый. Су кудыру өчен станция рәвешендә файдаланылган баржаның җиде метр тирәнлеккә батканын әйткән идек инде. Язга тиешенчә әзерләнмәү аркасында, Идел кисәк күтәрелгән очракта амортизация ясарга тиешле торбаларның шарниры күгәрү баржаның стенасын яра... Ышанычлы чыганакларның хәбәр итүенә караганда, авария вакытында алтмыш җиде яшьлек оператор Әмир Әшрапов трюмда кала. Ул, җиде метрлы тирәнлектән йөзеп чыгып, Магистраль урамындагы телефон автоматка үз аягы белән килә һәм «скорый» чакырта. Бозлы сулар кичеп, ярдәм машинасын юеш кием белән урамда көткән Әшрапов өшүдән аңын югалта. Өч көн буе реанимациядә яткан агай, аңына килгәч кенә, үзенең кем икәнлеген әйтеп бирә. Алдагы тапшыруларның берсендә без сезне, хөрмәтле телевизор караучылар, әлеге нык рухлы агай белән якыннанрак таныштырырбыз...»

Авылда үскәндә карт-корылар теленнән бик күп ишеткән булса да, Суфияттәйнең өрәк күргәне юк иде әле... Туган-тумача, күрше-тирәләр өй тулып аның кайтканын көтеп торсалар да, таш баскычтан икенче катка менгәнен ишетүче булмады. Өч капкалы кирпеч йорт, бала-чагаларын тыеп, телевизорларның тавышын бетереп, кер юу машиналарын, тузан суыргычларны сүндереп, сигезенче фатирда ни барганны ишетергә теләп тынып калды... Ишекнең тоткасы кыймылдамады — ул үзе ачылды. Чыпчык атлап чыгардай бусагага үкчәсе белән абынып сөрлегеп китте. Һәм бөгәрләнеп беткән киемнәр эчендәге шиңгән гәүдә, чак егылмыйча, талпынып сискәнде дә өйдәгеләрнең күз алдында авырлыгын югалтып эленеп калды.

— Аллага шөкер! Менә этиегезнең Җаны кайтты, — диде Суфияттәй, кызы Язиләне Әмиргә таба этеп. Ә үзе ашыкмады, бүләк күргән нарасый ише елмайды гына. «Өрәкләр дә шушындый була торгандыр инде», — дип уйлап куйды ул.

Сигезенче фатирга тагын бер өрәкнең килеп керәсе бар иде әле...

## Җиләк корты

Әмирнең хәбәрсез югалып торуын Фазыл кибеткә кесә телефоны алырга кергән җирдә ишетте. Зур күләмле радиоаппаратура сатылырга тиешле шүрлектә биш-алты телевизорны кабызып куйганнар, һәркайсы аерым каналга корылган. Әмир... Әшрапов... су... дигән өзек-өзек сүзләр хәвефле хәбәр булып сискәндерде. Кем турында сүз барганын чамалавы кыен түгел.

Элеккеге бораулау остасын эзләү көн тәртибендә юк иде әле. Моның өчен адреслар өстәленә мөрәҗәгать итәсе юк, Язилә кайда — эти-әнисе шунда. Ул гаиләдә Фазыл язмышына кагылышлы өч кеше яши һәм алар белән мөнәсәбәтне ачыкламыйча, киләчәккә планнар кору егетләрчә булмас. Йә татулашып яңадан кушылырга, йә араны бөтенләйгә өзеп бәхиллеген алырга...

Уйлары кыска булды Фазылның, чөнки такси бик тиз килеп җитте.

Вак-вак такталар белән тышланган ишек яңагындагы кыңгырау төймәсенә үрелгәч, аны икеләнү хисе биләп алды: ачалармы-юкмы, килеп дөрес эшләдеме, нишлиләр икән өйдәгеләр, ишек артындагы дөньяның нинди күренешенә юлыгыр икән, аты-юлы белән сүгеп чыгарырмы, әллә чәй куеп каршылармы?..

Ташпулат капкасы кебек чыелдап ачылган авыр ишектән кергәч, Фазылның рухи әзерлеге: «Исәнмесез...» — дип әйтергә генә җитте. Зал ягындагы люстраның алты лампочкасы да яна. Аяклы тегү машинасының тыкылдавын җиңәр өченме, телевизорның тавышы көчле. Бу вакытта күршеләре утырмага керә торган чак булганмы, әллә Салих кайтты дип уйладылармы, ишекне ачып тизрәк түргә ашыккан Суфияттәй, кулындагы телевидение программасын ачып, нидер эзләвен дәвам итте. Бу урамда су тирәсендә эшләүчеләр генә яши. Халык бер-берсен яхшы белгәнгә күрә, кыңгырауга кем басты икән дип, «пыяла күз» аша тышкы якны күзәтү гадәте юк, тимер ишекләр дә куелмаган. Кергән кеше үз артыннан ябып йөрергә, келәне шудырырга тиеш бугай. Фазылның, ишек ябарга онытып, тавыш-тынсыз басып торуы сәер тоелды, ахрысы, Суфияттәй программаны дүрткә бөкләгән уңайдан кабат борылып карады, шунда гына, икенче өрәкне күреп, кулындагы гәҗите белән ботын чәбәкләп куйды:

— Абау! — Һәм үзенең намаз иясе икәнлеген исенә төшереп, сүгенүдән тыелып калыр өчен гәҗитне ыргытып, тизрәк кулына дисбе алды. Аннан тегү машинасы белән мавыгып, дөньясын оныткан кызының касыгына төртте. — Кайтты җиләк корты. Кулында күчтәнәче дә юк!

Язилә, тегелеп бетмәгән фланель халатка ике куллап ябышып, элеккеге иренә карап катты. Тик бер сүз әйтмәде. Торалар шулай карашып — Язилә белән Суфияттәй Фазылны сыный, ә Фазыл, үз чиратында, тегеләрнең икесенә берьюлы текәлгән. Өч арада күзгә күренми торган пружина кысылган, әгәр урынсызга бер ялгыш сүз ычкындырсаң, шул пружина чакырылмаган кунакны бәреп чыгарыр сыман... Фазылдан башка үткән гомер эчендә Язилә әнисенең яшенә күчеп утырган — Әмир өйләнеп йөргәндә, Суфияттәй дә нәкъ шушындый килбәттә иде... Чәченә тегермән тузаны кунган, муен белән ике арада ияге югалган, чәй эчкәндә чынаяк тәлинкәсе куеп торырдай күкрәкләре, кысан тышау белән богауланып, юка блузка белән капланган, кыска җиң эчендәге беләкләре унсигез яшьлек кызлар боты кебек тулып тора...

— Әмир бабай кая? — диде Фазыл, ниһаять, ник килгәнен сиздерергә теләгәндәй.

— Әнә ваннада юына. Бар, аркасын ышкып чык. — Җавапны Суфияттәй кайтарды, чөнки Язилә һаман өненә килә алмый иде әле. — Әмир, — диде ул, юыну бүлмәсенә якынаеп, — Фазыл килгән.

Әмирнең җавабы бераз тоткарланды, кайсы Фазыл дип кайтарып сорамас өчен искә төшерүе булгандыр инде.

— Әйбәт иткән килеп. Хәзер чыгам.

Тагын тынлык урнашты. Фатир эчендә стена кәгазьләре, пәрдәләр, төсләр алышынса да, җиһазлар гел элеккеге тәртиптә иде. Телевизор яңасына алышынган, әмма ул барыбер иске урынында иде, яңа диванны да Фазыл киткәндәгечә сервантка каршы якка куйганнар, ә кием шкафы исә шул ук, һаман исән, һәм гел ишектән кергән уңайда тора. Әгәр менә хәзер кинәт ут сүнсә, Фазыл караңгылык эчендә һич ялгышмыйча, суыткычтан эзләнер, диванны җәяр, шкаф шүрлегеннән йокы киемнәрен эзләп таба алыр иде.

Суфияттәй дисбе тартканда тизлеген арттырды, ашыгуының сәбәбе шул — аның нидер әйтеп каласы килә.

— Кияү, ник башыңны кыңгыр салдың, шигырь язасың юктыр ич?! Язилә, урын бир. Утыр, кияү, утыр. Көтәсең булыр. Әмир үзе генә юынганда бик озак кыймылдый ул. Безнең карантин әле аның белән. Янына кереп тәүбәмнән язар хәлем юк. Утыр, кияү, утыр!

Суфияттәйнең өч тапкыр «Кияү!» дип эндәшүенә сөенеп, идәнгә коелган корамалар арасыннан сары песи килеп чыкты, чыкты да шундук Суфияттәйнең алдына менеп, төкле мыегын яларга кереште...

Алар әнкәле-кызлы чәчелеп көлделәр. Песинең исеме «Кияү» икән. Шап-шоп итеп сөйгәндә, Суфияттәй моны үзе әйтеп бирде.

— Менә бит ул безнең яңа Киявебез... Түбәгә менеп китсә, айлар буе өйгә кайта белми. Мал иясенә охшамаса, хәрәм була... Утыр, кияү! — Монысын инде Суфияттәй Фазылга әйтте. — Түргә үт, бездән курыксаң, аяк савытларыңны салгач, чыгу уңаена борып куй.

Җәймә чаклы базар сөлгесенә төренеп, Әмир чыгып басты. Кыланмады, икейөзле булып уйнамады, арттырмады, кайнар судан парланып чыккан кулын биреп күрешкәндә түзмәде, кочаклап алды. Ул чынлап та Фазылны сагынган иде.

— Исәнме, кияү?!

— Телевизордан бүген генә ишеттем. Туры монда йөгердем. Суга батып хәбәрсез югалган, диләр. Әллә нишләдем.

— Суга батса, ояты булмас иде кана... Салих улым Фирая дигән бер сөйрәлчекнең түбәсеннән алып төште бит соң бу ата мачыны! — дип, Суфияттәйнең ике кешене берьюлы озаклап әрләргә исәбе бар иде.

— Телеңне тый. Җитәр! — дип бүлдерде Әмир. — Әйдә, кияү, минем бүлмәгә. Ә син, Язилә кызым, бернәрсә әзерләп керт.

Көмеш подноска төялгән ризыкларны Суфияттәй китереп куйды.

— Кайда Язилә? — диде Әмир, бу урында кызын күрергә теләп.

— Керәсем дә, күрәсем дә килми, ди. Мин үзем дә сөймим сезне.

— Сөймәсәң инде, сине сорап килмәгәннәр лә!.. Калдыр закускаларны, кирәксәң, үзем чакырырмын тагын...

...Фазыл бу минутта Әмир нәрсәгә үрелсә, шуны кабатлады. Ул бабайның кәефенә ияреп утырды. Ә үзенең уйлары күрше бүлмәдә иде... Язиләнең үпкәләве әйбәт анысы, якты чырай күрсәтсә, муенына асылынып елый башласа, ялынып ялварса, кызганып шушында яшәп калуың бар бит. Кайтып яшәрлек булгач, аны утызар елга сузасы түгел иде... Әмир гафу итте бугай, бер бөртек кызын ташлап киткән үги кияүне бүлмәдә аерып сыйлап утыра. Димәк, туганнарыңнан да якынрак хезмәттәшләр була икән дөньяларда... Кызык, Әмир бирешмәгән, бераз олыгаюы күзләренә чыкса да, гәүдәсе нык — бүген дисәң, бүген эшкә алып китеп, йөз егермешәр килолы бораулау торбалары күтәртергә була.

Фазылның соңгы уйларын тойды, ахрысы, Әмир сорауга җавап биргән рәвешле әйтә куйды.

— Ярдәмем кирәксә, дәш. Теләсәң, акча белән, теләсәң, көч белән кушылырмын.

Кунарга калмады Фазыл, иске тормыш өчен ул инде чит кеше иде...

## Әмир серен Фазыл белә...

Сагынды Әмир абзагыз сайлау көннәрен. Иске заманнардан бирле бәйрәм дип исәпләнгән ул... Туган көнгә җыелган бүләкләр арасыннан сүтелмәгән килеш чукмар эшләпәле энәләр белән катыргыга тарттырып төрелгән озын җиңле ачык-саргылт күлмәк сайлап алды — үтүкләп азапланасы юк — кәчтүн изүеннән күренергә тиешле күкрәк турысы тигез тора, калган өлеше хет бөгәрләнеп бетсен, участокта салдырып карамаслар әле.

Җыелган урын өстендәге мендәрләрне сытып кырын яткан Суфияттәй эч пошуын тавышына сеңдереп бәя биреп торды.

— Сабан туена иртәрәк түгелме соң әле? Иске күлмәгең ярамаганмы?!

Суфияттәй иртүк торып киенеп-ясанып куйган. Ул үзе дә бәйрәмгә әзер, тик Әмиргә иярми, Язиләсе белән икесе аерым бара — аларның серләре аерым-аерым. Кызый, этисе чыгып киткәнче вакытны сузар өчен, көзге каршына утырып керфекләрен саный.

Кием шкафының аркылы таягына эленгән килеш кенә, ярты гасыр эчендә модага кереп-чыгып йөри торган галстуклар арасыннан чия кызылын сайлап алып, кара кәчтүненә куеп карагач, Суфия кортканың төртмәле сүзләре тел очына килә торды. Ул, атлас күлмәге белән шуып төшкән мендәр чокырыннан баш калкытып, ир үртәүдән кызык тапты:

— Беләгенә ура син бу галстугыңны, дежурный дип белерләр.

Төенләп-сүтеп шактый чиләнә торгач, галстукның элмәге күлмәк якасын тотардай рәвешкә керде.

— Элмәгеңне каты кысма, «Ура!» кычкырулары кыен булыр...

Әмир абзагыз кичтән майлап куйган сай туфлиен бәрхет тасма белән ялтыратып, күн йөзендәге «ялык-йолык»ны күз карашы белән тотып алгач, Суфияттәй тагын түзә алмады:

— Шултиклем ялтыратмасаң... Әллә Иҗтимагый үзәк президенты белән фотога төшерерләр дисеңме?

Карчыгын әрләшү мөмкинлегеннән мәхрүм итеп, тәки дәшми Әмир абзагыз, күңел ачып ятсын шунда, ястык чокырында. Чакырган җиргә кунакка ияртеп йөрергә менә дигән тормыш иптәше лә ул. Кан тамырларының тараюы сәбәпле, аяклары шешенә аның. Брежнев заманында ук сайлауларга үзе йөрмичә, паспорты белән тавышын кызы аркылы гына биреп җибәрә торган иде. Бүген барырга тәвәккәлләде...

Әмир сайлауларны сагынды. Тормыш яхшыга үзгәрсен өчен ул сайлауларга ел саен барырга риза хәзер. Берөзлексез кырда эшләп, чит авылларда яшәп, бораулау агрегаты белән җир эчендә казынып үткән гомер, сәяси күзлектән караганда, заяга үткәндер кебек һәм бу югалтуны кайтарырга иде.

Йомышчы апа өченче тапкыр инде сигезенче фатирның ишеген ачтырды:

— Сайлауга барырга онытмагыз!

Плащ төймәләрен ычкындырып, юка ак шарфын җилфердәтеп, Әмир өеннән чыкты. Иртәдән бирле тавышын бирәсе килә аның бүген. Абзагыз горур — тавышы үзендә әле, ул аны беркемгә дә бирмәгән, исән-имин килеш сайлау сере итеп тота... Йомшак көннең ягымлы кояшы озата бара. «Кемне сайлыйсыңны беләм...» дигәндәй, күк капусыннан елмаеп көлә. Белмичә ни, бер урынга уникe кандидат дигәч тә... Кемнең ни өчен югарыга үрмәләгәне билгеле. Безгә милләт өчен җан атып йөри торган чиста куллы, акыллы, исемле шәхесләр кирәк. Бар ул андый кеше! Әмирнең кемне сайлыйсын бер Фазыл гына белә...

Сайлау участогының чик сызыгына сакка куелган этле милиционер янынннан үткәндә, Әмир үзенең сәяси халәтен тыя алмады.

— Командир! Кәеф бозучылар юкмы?!

Милиционер бауны ике-өч тотамга кыскартып, этне үзенә якынрак китергәч кенә елмаеп честь бирде:

— Все нормально! Сезне көтәләр!

Һәй, көткәнне кем яратмый инде! Әмирҗан, башын чөеп, галстугын бушатып, плащ төймәсенең берсен каптырып, кулларын тигез селкеп, горур рәвештә яңа мәктәп бинасындагы сайлау участогына ашыкты.

Ә инде ярыклы кызыл әрҗәгә бюллетень салгач, Әмир тавышсыз калды. Аны кинәт сагыш басты. Базар уртасында әнисен югалткан сабый шикелле ятимлек хисе биләп алды. Әрҗәдәге тавыш белән бергә гайрәте, кәефе, өмете ияреп киткәндәй тоелды.

Мәктәптән чыккан бер сайлаучыны урам ягында микрофонлы хәбәрчеләр каршы алып торалар икән. «Сез кемне яклап тавыш бирдегез?» дигән сорауларына үртәлде генә Әмир. Әйтте ди, сезнең кем кушуы буенча йөргәнегезне кем белгән?! Ашыгып әйтелгән һәр сүздән сәясәт ясала торган заман бу! Дәшмәде Әмир, бармакларын уйнатып, тавышсыз-телсез кешедәй кыланды.

Олы юлдан урын таба алмыйча атлаганын күреп, теге «чик сакчысы» аркылы төште:

— Нәрсә, мужик, тротуардан йөрсәң ярамыймы?!

Этенең бавын озынайтуы Әмиргә өстерү өчен түгел, кара тәрәзә артына поскан «БМВ» пассажирына честь биргәндә кул күтәрер өчен кирәк булган икән.

Югалткан тавышын аяк астыннан эзләгәндәй, Әмир башын түбән иде... Нәрсә дип мәктәпләрдә үткәрәләр икән бу сайлауларны? Кешеләр мәктәп елларын искә төшереп хисләнсен, киләчәкне күзаллап күңелләре йомшарсын дипме? Сайлауларны министрларның кабинетында, административ биналарда, фонд сарайларында, начальство офисларында үткәрәсе иде. Ул чагында һәр сайлаучы үз тавышының кемгә хезмәт иткәнен төгәлрәк аңлар иде. Мәктәпкә җыелып сайлау — ул караңгы бүлмәдә ишек тоткасы кармалау кебегрәк. Гаилә корыр өчен үзенә ир белән хатын да сайлый белмәгән Рәсәй гражданины дәүләт эшлеклеләре, Ил башлыклары сайлый аламы? Әмирнең тавышы сәяси карурманда адашкан ялгыз баланың җан авазы булып кына калмасмы, кушылырлармы аңа?!

## III. ШӘЙХИ

### Элек һәм хәзер...

Югалган дусларыңны эзләү — үзеңне эзләү ул.

Әгәр кеше кечкенәдән уйнап үскән, бергә укыган, эшләгән, яшәгән-бәхилләшкән дусларын, якыннарын һәм туганнарын яңадан исән-имин җыеп, зур очрашу оештыра алса, аның бөтен биографиясе, энәсеннән җебенә чаклы югалмыйча, әйләнеп кайтыр иде. Үткән тормыш юлы, өлешләргә бүленеп, алар белән ияреп киткән. Озаграк яшәгән саен, күбрәк югалтасың...

Кирәкле кешеңне акча түләп эзлисең.

Адреслар өстәлендәге ханым дүрт сәгать көтәргә кушты.

Бу болгавыр заманда билгесезлеккә китеп югалган Мәдиярны эзләп табар өчен күп вакыт түгел ул... Ә менә миллион ярым халкы булган шәһәрдә ялгыз башың бәргәләнеп йөрергә калсаң — ярты көн күбрәк.

Киң күңелле шәһәр ул — Казан...

Шөкер, мәрхәмәткә өметләнгән һәр мосафирның ихтыяҗына хәзинәдә барыннан өлеш чыгарырга тырыша. Эш эзләп килгәнгә — эше табыла, фатирсызны кайчан да булса барыбер фатирлы итә, җаны теләгән кешене өйләнерлек яр белән таныштыра. Укыр өчен, яшәү һәм үсәр өчен бөтен шарты килгән таш каланың урамында җаны, сандыгында малы, тәрәзәләрендә иман нуры бар аның. Шуңа күрәдер инде борынгыдан бирле җансыз, кансыз һәм имансыз дәүләтләр, Казанны кол итәргә теләп, гел яу белән килә тора. Яуланган чакта да җиңелмәгән, бил бөксә дә баш имәгән, исемен саклаган!..

Соңгы кырык ел эчендә Казанда нәрсә үзгәрмәде, дип сорасалар, иске трамвайларның юл маршруты диярсез. Әнисе белән килгән чакларда, бәрәңге сатылып беткәч, Фазыллар икенче трамвайга утырып, Чех базарыннан «Кольцо»га төшәләр иде. Авылга кайта торган кәҗүн бөркәүле такси иртәнге якта гына була. Авылдашларның күбесе капчык өстенә бөгәрләнеп базар чоланында төн үткәрә. Динә, ун яшьлек Фазылны ияртеп, Хаҗәр апаларга ашыга. Ана җилкәсендә күчтәнәчкә дигән бер чиләк бәрәңге, малай кулында йөзем кыстырып туңдырылган унтугыз тиенлек пломбир. Аның әле егерме ике тиенлек шоколадка төрелгән көмеш кәгазьлесе дә бар, тик Фазыл сорарга кыймый, ул өч тиенлек аерма трамвайда бер билет алырга җитә. Хаҗәр апа Меховойдан Суконныйга йөри торган алтынчы трамвайда кондуктор булып эшли. Аның улы Юныста өч тиенлек акчалар кесә тулы. Сыерчык оясы кебегрәк киоскаларда газлы су сатучы юан марҗаларга: «Двойным сиропом», — дип кенә ыргыта ул өч тиенлек-

ләрне. Фазыл алдында масаеп, икешәр стакан су белән сыйласа да, Юныс акчасын тотып бетерми, аның әле сигезенче трамвай белән Теплоконтроль ягына барып, «Казгрэс» суына коеныргa йөрисе бар. Пар турбиналарыннан җылынып чыккан су Кабан күленең югары очын кыш көне дә эретеп тота, ел буе коенып була. Кондуктор малае дип тормыйлар, Арча кырына йөри торган бишенче трамвайга да, Бишбалтаның беренчесенә дә билет алырга мәҗбүр итәләр Юнысны... Ах бу балачак!.. Сагынуларсыз-югалтуларсыз, башланмаган дәрбөтен, вак-төяк сөенечләрне зур бәхеткә тиңләп яшәлгән еллар...

Фазылга хәзер Мәдиярның адресы бик кирәк. Кайда яшәвенә карамастан, ул аны эзләп табарга һәм, Наил Кадыйрович аңлаткан кебек, яңача эшләү турында үгетләргә тиеш. Көн күрәм, кәсеп итәм, дип, теләсә кайда нужарасы юк, элеккеге бригаданы яңадан җыярга мөмкинлек бирәләр ләбаса! Ә бәлкем әле, элеккеге авылларга кабат кайтып, яңа коелар бораулapга насыйп булыр?! Элеккеге авыллар дип, Фазыл үзенең яшьлеген уйга сала. Бер карасаң, Кеше гомерен менә монысы үсмер чак, бусы яшьлек, аннан килә ир уртасы, ә соңгысы — калдык-постыгы — картлык дип, киртәләр белән бүлеп куймаганнар, чорларның ызаны юк. Ләкин шунысы бәхәссез — әгәр яшьлек елларыңны өзелеп-өзелеп сагынасың икән, димәк, син инде бик үк яшь түгел... Чорлар арасындагы межаны сагыну дигән төшенчә билгели. «Ак Чишмә» начальнигының бригадаңны җый, дигән тәкъдиме Фазылны Каенлык авылына, иң беренче су скважинасы казыган көннәргә кайтып килү кебек гайре табигый өмет булып чакыра. Алай гына да түгел, тургай канаты астында калган болыннарга, утлы чишмәләрдән бәреп чыккан су ташкынына сөенеп каңгылдашкан казлар авазына, Әлфинәле кичләргә, җыйнап кына әйткәндә, яшьлекнең үзенә сәяхәткә чыгарга өнди, алгысыта һәм ашыктыра иде. Яшьлеккә кайтып килер өчен яшьлектәге дусларны эзләп табарга кирәк. Тагын дүрт сәгатьтән соң, адреслар өстәле хезмәткәре Мәдиярның соңгы тукталышын әйтеп бирер...

Күргән саен хозурланырлык манзара — кайчандыр Сабын заводының юынтык чокырына әверелгән Кабан күле өстендә көяз акчарлаклар балык чүпли. Яр тирәли тезелгән чатырлардан теләсәң нинди ризык алып, Кабансу исеннән курыкмыйча, шунда ук тукланырга була. Әле ун гына ел элек чебен егылып төшсә, тончыгып үлә торган Болак елгасында, яшьлеген сагынып килгән Фазыл кебекләрне үртәп, купшы Аккошлар йөзеп йөри, алай гынамы — урамнарга җиләслек өстәп, фонтаннары бөркелеп тора. Бүгенге Болак — президентлар көймәдә йөрерлек купшы елга!

Әгәр теләсә, кеше суны ничек үзгәртә ала!

Әле егерме ел элек кенә лотокларда чат саен сатылган, стаканы өч тиенлек сироплы суның тәме тел очында тора. Ә бит ул суны, кара шланга белән сузып, урамдагы колонкалардан китерә торганнар иде, кем әйтмешли, кайнатмыйча, чи килеш!.. Ул вакытта да шушы Иделдән алынган су бит инде ул!.. Нинди чиста булгансың син, Идел, нинди чиста булган безнең Ил!

Фазыл самолет билетлары сата торган агентлык бинасының маңгаена чәпәлгән түгәрәк ак сәгатьне кул сәгате белән чагыштырды — дөрес, ун минут үткән. Тагын ике йөз утыз минут көтәсе бар...

Колхоз базарын читләтеп үтте.

«Базар мөнәсәбәтләренә күчтек» дигәнне яратмый Фазыл. Кечкенәдән үк бик яхшы белә ул базарның нәрсә икәнен. Шәле Казан артында гына, авылның бөтен байлыгы шәһәр базары өчен үсте. Лавкә артына баскач, үлчәвеңдә ни бар: маймы, эремчек, бәрәңгеме — барыбер, илдә булмаган сыйфатны тагып, юмакай сүзләр белән башкаларны уздырып мактыйсың... Ә шәһәрнең синнән дә хәйләкәррәк алучысы тауарыңны актара, исни, кабып карый, түкереп китә, тагын килә, бәяңне төшерә һәм ала. Син аны алдаларга тиеш, ул сине алдарга тели...

Үстергәнеңне сатасың да тәм-том, кием-салым аласың.

Кергән акча белән авылга базар гадәтләре ияреп кайта.

Бишенче сыйныфны тәмамлап, җәйге каникулның соңгы аена кергәч, Фазылның колхоз базарына үзе генә килгәне бар. Май, каймак, эремчек күтәреп түгел.

Динә ире үлгән елны сыерсыз калды. Өч баланы итәгенә төйнәп тол үстергән хатын, гомер бакый колхозда эшләп, сыер алырдай акча күрмәде... Фазылның ак чиләк белән алып килгән тауары — Питрәч сазлыгыннан җыйган шомырт иде. Ул елны шомырт чамасыз күп уңды. Базарның таш өстәлле бер рәте көн саен шомырт сатучылар белән тула иде. Иң тәмле шомырт безнең урманда ул, дип мактанган күрше авылныкылар да әлеге рәткә килеп баскач, бермәл телсез кала. Тауар янында тауар аерыла икән: синеке — чем-кара, минеке — эре; аныкы — баллы, моныкы — арзанрак. Агач башларына үрмәли-үрмәли җыйганда гел баллы, гел эресе кирәк дип кенә булмый шул, иң мөһиме — тизрәк чиләгең тулсын... Көннең беренче яртысында стаканына ун тиеннән сатулашса да, өйләдән соң базарда авылдаш апалардан аерылып калмас өчен, ике стаканын унбиш тиенгә җибәрә башлады. Тиз сатылып бетте бетүен, тик шуны гына көткәннәр диярсең, акча түкмичә генә ашарга өйрәнгән ышпаналар Фазыл тирәсендә бөтерелә башлады, алар малайның үзе генә килгәнен сизенеп, шомырт акчасына өметләнәләр иде. Тагын өчәүләп килеп бастылар. Берсе имән бармагы белән читкә дәшә, икенчесе зәңгәр тышлы катыргы күрсәтә. Инде килеп өченчесе, өстәл аркылы үрелеп, Фазыл кулындагы буш чиләкне «арестовать» итеп маташа. Чиләген йолкып алды да Фазыл, күрше рәттә яңа бәрәңге сатып торган авыл хатыннары тирәсенә качты һәм шундук, Фәризә апасының капчык авызын сүткән булып, кул арасына керде.

Үзе базар телендә такмакларга кереште: «Лорх, Лорх! Рассыпышный, полявой картушкы!!!» Теге ышпаналар Фазылны әнисе янына килде дип уйладылар, ахрысы, күздән югалдылар.

Авылга кайтып җиткәнче чалбарының сул кесәсеннән кулын чыгармады Фазыл. Динә санап караса — дүрт сум акча җыелган, мәктәп кибетеннән алтынчы сыйныф өчен яңа дәреслекләр сатып алырга да, яңа сумкага да җитә бу! Дөрес, шомыртның чиләгеннән җидешәр сум чыгарган кешеләр дә булган, ди... Ләкин Динә улының хәләл акчасына бар кадәресе өчен сөенде... Элек ул дүрт сум акчага дүрт йөз дәфтәр алып була иде.

Элек һәм хәзер...

Гомумән алганда, элеккеге бәяләр белән бүгенгесен чагыштыру, үткән заман белән хәзергесен чәкәләштерү кебек сәяси өянәк — күчеш чорының котылгысыз чире.

Кискен борылышлар ясарга ярата инде Рәсәй империясе... Аның тарихы да — реформалар тарихы. Туксанынчы еллар алып килгән үзгәрешләрдә моңарчы булган бөтен реформалар бергә буталып бетте. XXI гасырга килеп кергәнче: инкыйлаб һәм гражданнар сугышы, нэп һәм кризис, ачлык һәм хәерчелек, шәхес культы һәм азатлык өчен көрәш, акча алышыну һәм җинаятьчелек, кыскасы — сиксән ел буе гади халык җилкәсенә төшкән афәтләрнең барысын да «базар мөнәсәбәтләре» өр-яңадан кабатлап чыкты. Әйе, үзгәрешләр күз алдында. Җир буена сузылган чиратлардан котылдык, җәмгыять яңадан байлар кулына күчте. Күтәрә алмаслык акча җыйган яңа капиталистлар, яклау эзләп, чит илгә кача тора... Ә колхоз базары төбендә калган халыкны яулар өчен сатучылар арасында сыйнфый көрәш бара... Үткәнне сагынабыз, ләкин кире кайтырга теләмибез, киләчәктән куркабыз, ә үзебез алга омтылабыз.

Кеше гомере белән җәмгыять гомере — икесе капма-каршы нәрсә. Кеше үзенең үткәненә, ягъни яшьлегенә әйләнеп кайта алмый, ә җәмгыять кайта... Шулай да яңалык искелектән көчлерәк. Моны хәтта совет чорындагы яшь гомерен кырда, юлда, буровойда үткәргән Фазыл да яхшы аңлый. Базар уртасында калгансың икән — йә сат, йә ал! Юлда түмгәк булып ятма. Кулыңда акча уйнасын...

Колхоз базарыннан ерагайгач, Фазылның уйлары барыбер көрәймәде. Казанның элеккеге ишегаллары иске-москы өйләрдән котылган арада, Бауман урамын тәҗрибә рәвешендә яңа тормышка яраклаштырганнар. Һәр ике як буйлап сәүдә ишекләре пыяла койма булып тезелгән. Монда халык бик күп йөри — ләкин берсен-берсе күрми, һәммәсе үз шөгыле белән мәшгуль. Адым саен чуар манзара. Шунда ук муенына эленгән калай савытка акча салсыннар өчен гармунчы агай уйнап-җырлап утыра. Кыска торыклы чуен багана башындагы сүнгән лампага күзен акайтып, мәктәп яшендәге кыз белән егет, чәйни торган сагызларын авыздан авызга күчереп, үбешкән сыман кылана. Челтәрле урындыктагы кызлар өчәр-өчәр булып сыра чөмерә, шешәдән бушаган иреннәре тәмәке әвәли. «Тукымалар» кибетенең ишегенә ышыкланып, берәү җир уртасында сурәт ясый, ике сурәтсез аңа чиратка баскан. Ак әрҗәсен юл уртасындагы һәйкәлгә бәйләп, яшел алъяпкычлы кызый ялынып-ялынып кайнар кәһвә сата. Тузан суыртырга тиешле мини-трактор пыр туздырып үтеп киткәндә, халык төркеме манекенга әверелеп кала...

Элеккеге ашату-эчертү ханәләрендә яңа хуҗаларның исемнәре тышкы якка чыккан — карының ачса, кемгә керергә белмәссең...

Бауман урамындагы ташкын Фазылны, өнәмичәрәк, Казансу күперенә кысрыклап чыгарды. Ул элек үзе фатирда торган урыннарны юксынды...

Савин бистәсен түтәл сирәкләгән кебек иткәннәр. Фазыл фатирда торган өй урынында субай кагалар. Бакалы нигез, камышлы урам, сазлы сукмаклар метр ярым калынлыктагы елга комы астында калган. Күчмәс өчен мэрия белән бәхәскә кергән йортлар арасында Мәрьям әбинең ак кәҗәләре чемченеп йөри. Әби үзе чыбыклары өзгәләнгән багана кәүсәсеннән белдерүләр укыштыра. Ул күрешеп сөйләшкән һәркемгә дә ачык чырайлы. Фазыл аны күргәч, якын туганын очраткан кебек булды. Әбиләр дә яшәртеп сөйләшкәнне ярата, шуңа күрә «апа» дип күрешү урынлыдыр.

— Мәрьям апа, синең өеңне Савин музее итәрләр инде.

— Сүтеп атканнарын көтеп йөримен, дамба кырые булгач, чират җитми һаман.

— Ник кәҗәләреңне Кремль ягына алып чыкмыйсың, анда печәнне су сибеп үстерәләр?!

— Иркенләп җөрергә вакыт юк бүген. Кандидатлар белән очрашуга барамын, икеләрдә.

Фазыл белә-белгәннән бирле, Мәрьям әби Савин бистәсендә ак кәҗәләр ияртеп йөри. Аның бер кулында йолкып печән тутырылган ямаулы соры капчык, икенче кулында бәтиләргә кызыгып калган этләргә селтәнер өчен каезланмаган өрәңге ботагы. Унике кәҗәне көне буе ияртеп йөргәндә, куак-агач, кычыткан-кура арасында шактый тырналырга туры киләдер — ул җәй дип тормый, калын киенә: башында уртага бөкләнгән шакмаклы суккан шәл, аягында калошлы киез итек, иңендә озын бишмәт. Һәрхәлдә, моңарчы шулай киенә торган иде. Ә бүген ул башкача: чуклы кәшимир шәльяулыгыннан чал чәче күпереп чыккан; ашыгычлык белән сөртелсә дә, алсу кершәне шома иягенә тигез яткан, тик маңгай җыерчыкларының буразна чокырына үтмәгән — сызык-сызык алсуланып тора; яшел гамажына тигәнәк ябышмаган, кыска балтырлы юка зәңгәр оегы шнурлы ботинка кунычына чумган; өрәңге кабыгы төсендәге халатын салып ташласа, озаклап кием алыштырасы юк — җиң очыннан кара бәрхет күлмәге күренеп тора...

— Кандидатлар бик күп, менә монысын үзем ябыштырдым, — Мәрьям әби фоторәсемле игъланны сыпырып куйды, — бу багана төзүчеләрнең юл өстендә, күрерләр. — Һәм унике кәҗәле активист, Фазыл ягына борылып, баганага сөялде. — Син безнең тирәдә прпискада идеңме? Кайда сайларга җыенасың, димен?

Фазыл, миңа барыбер дигәндәй, иңбашын сикертеп куйды. Ояты ни тора, шушы яшькә җитеп, кайчан да булса, сайлауга катнашканын хәтерләми ул. Мәрьям әбигә әйтсәң — ил язмышына битараф яшәгәне өчен, кулындагы таягы белән кыйнар иде, билләһи!

— Ике дә уйлама, балакаем, открепление ал да Савин участогына күч. Монда гел татарлар гына, Мулюковны депутат итеп сайлап куярбыз.

Фазыл игъланны укыгач, дәресен әйбәтләп өйрәнеп килгән укучы кебек, җавап бирергә шатланып торды:

— Мәрьям апа, кечкенә чагымнан ук беләм мин Марат Мөлековны. Ул безнең авыл мәктәбенең директоры иде!..

Адреслар өстәле килергә кушкан вакытка чаклы әле өч сәгать бар. Фазыл, сөенә-сөенә, Савин бистәсе белән трамвай юлы арасындагы аланлыкка ашыкты. Бүкән башларына озын такталар кагып, ачык сәхнә ясалган урында биш-алты тынгысыз сайлаучы утыра иде инде. Депутатлыкка ашкынган кандидатлар күренмиләр әле.

Ике тулырга унбиш минут кала, тукталыш ягыннан салмак адымлы, киң җилкәле, базык гәүдәле берәү күренде. Атлаганда калын кысалы күзлек пыяласы кояш нурын уйнатып ала. Кара кәләпүшен баш түбәсенә батырып кигәч, маңгае киң булып күренә. Кәчтүн төймәләрен ычкындырган, тар галстугы Савин җилендә җилфердәп бара. Әбиләрнең «Иҗтимагый үзәк президенты килә...» дигән пышылдавыннан сикереп торганын үзе дә сизми калды Фазыл.

Ваемсыз үткән гомернең югалтулары күп булса, олыгайгач көтелмәгән очрашуларга юлыгасың икән. Алар фани дөньяның ыгы-зыгылы бер төшендә синең тирәдән югалып торалар да, көтмәгәндә берән-сәрән очрап, көндәлек тормышыңның ямансу халәтенә сөенеч өстәп куялар.

Ул, каршысында кинәт пәйда булган Фазылга юл бирергә теләп, сукмак читенә чыгып басты.

— Исәнмесез, Марат Әбдрәсүлевич?

— Исәнмесез? — диде Мөлеков һәм, күзлеген төзәтеп, Фазылга текәлде, ул әлеге егетне Азатлык мәйданында «Ура!» кычкырып йөрүчеләрнең берседер дип танырга тырышты.

— Мине белмисез, Марат абый, Сез авылдан киткәндә, мин икенче классны гына бетергән идем әле... Апа белән абыйга тарих укыттыгыз. Утыз ел элек!

— Тукта, тукта, кушаматыгыз ничек әле?

— Минем әби техничка булып эшләде. Безнең кечкенә өй иске булгач, сез аңа мәктәп өеннән бер бүлмә биргәнсез. Абый көн саен кич иптәшкә кунарга бара иде.

— Белдем. Син Динә малае... Исемең ничек әле?

— Фазыл мин, — дип әйтүе булды, Мөлековның аны кочаклап алуы булды, хәтта кулындагы портфелен җиргә куярга да онытты...

— Миңлебикә әбиең мәрхүмәдер инде, мин директор чагында ук алтмышта иде ул.

— Әйе, яңа өй салгач, безгә килеп үлде.

Мөлеков, яңа дәфтәрнең беренче бите шикелле пакь кулъяулыгы белән күзлек арасына тыгылган булып, күз төбен корытты.

— Син нишләп йөрисең әле монда, кем, Фазыл, кайда эшлисең, авылга кайтканың бармы? Сөйлә, әйдә, сөйлә, миңа барысы да кызык.

— Мин сезнең белән очрашуга килдем. Соңыннан иркенләп сөйләшербез.

— Әйдә, сайлаучым! — диде Мөлеков һәм Шәле кешесенә хас җорлык белән Фазылның иңбашына сугып куйды. Бу аның Себер татары булсам да, без синең белән якташлар бит, дип әйтергә теләве иде.

Алар бер сукмакка сыешып атладылар, гел боз өстеннән йөргән кебек һәр адымын сагаеп баса торган Мөлеков Фазыл алдында кинәт батырайды. Кәләпүшенең маңгай өстенә туры килгән чигүле сыңар бизәген сыпырып, башын югары чөйде. Атлаганда кулындагы портфеленең тигез атынуы — күңелендә уйнап торган үзенә генә билгеле маршка иярүе иде.

Аларның сөйләшеп утырыр өчен мөмкинлекләре бихисап күп булды. Фазылны ул Иҗтимагый үзәк офисына чакырды, Васильеводагы дачасына алып барып, гаиләсе белән аралаштырды. Шәледә туып Казанда үскән ике малае аны үз итте. Ә хатыны (күрше авыл кызы) аңа улым дип дәште... Хәтта 1992 елның июнь аенда Мөлеков Фазылны Төркиянең Ризе шәһәренә фестивальгә баручылар исемлегенә дә кертте. «Җыр һәм чәй» бәйрәме дип атала иде ул. Әйдә, балакаем, диде Мөлеков, син су чыгаручы кеше, диңгез буенда яшәүчеләрнең нәрсә эчкәнен күреп кайтырсың.

Элеккеге директор белән күбрәк аралашып, үткәннәрне искә төшергән саен, Фазыл бер нәрсәгә инанды — Мөлеков авыл халкына күңел рәнҗүе сакламый, киресенчә, сагына, горурлана иде. Чөнки яраткан эшне, мактаулы авылны ташлап китәргә мәҗбүр иткән бер кеше — ул әле бөтен авыл түгел. Ул хәтта Казанга күчеп килгәч язылган «Шәле таңнары» дигән китабында бу турыда искә дә алмаган иде.

Фазыл туган елны Мөлеков мәктәпкә тарих укытучысы булып кайтты. Кызыл диплом алган белгечләргә эш урынын сайлау мөмкинлеге бирелә. Казан педагогия институтында укыган елларда ук ул үзе үскән якларга кайту юлын онытты һәм егерме бер яшьлек Себер татары хатынының күрше авылына — Шәлегә кайтып төпләнде.

## Самолет кемгә килгән?

Чистай егете җөмһүрияткә беренче кеше булып килгәч, авыл һәм районнарга яңа түрәләр билгеләү буенча «шахмат уены» башланып китте. Җиңүчеләр төркеме, төрле йөрешләр, комбинацияләр, позицияләр корып, Рязань татары куйган фигураларны урыннарыннан алып, «шахмат партиясе»н егерме биш ел буе кулда тотты. Югары эшелоннан башлап, урта звено җитәкчеләренә чаклы, барысын да диярлек Чулман аръягыннан килгән уенчылар кысрыклап чыгарды... Туксанынчы еллар башында «Агыйдел» командасы җиңде, хәзер өстенлек алар кулына күчте.

Хрущев чорында алай түгел иде, район җитәкчесе итеп шул ук район кешесен куйдылар, авылга — авылдашны... Күмәк җыелышларга килгәч, урынга тәкъдим ителгән кешенең кем икәнен аңлатып-исбатлап торасы юк — ул шушы авылда туып үскән. Колхозчылар киләчәк рәисне бала чагыннан ук белә: укыганда нәрсә өчен икеле алганын да; егет чагында кем кызын сөеп, ни өчен башка берәүгә өйләнгәнен; ничә яшеннән тәмәке тартканын; туганнарының кемнән яралганын, елга ничәшәр хезмәт көне эшләгәнен, сабан туе төнендә кайда кунып калганын — барысын-барысын хәтерли... Ә читтән китереп куйган кеше, гадәттә, туган ягында кылган гөнаһларыннан качып, күбрәк үз мәнфәгатьләрен генә көйләп йөрүче карьерист булып чыга.

1957 елның бишенче октябрендә ындыр артындагы болынга «Кукурузник» килеп утырды. Әле кичә генә Җир тирәли беренче ясалма иярчен җибәрелгән иде. Бөтен планета радиолары тәүлек буе туктаусыз шул турыда гына сөйли... Инде менә сиңа мә — брезент бөркәүле такси арбаларыннан гайре чит машина күрмәгән авылга самолет төште. Спутник белән самолет авыл халкы телендә бергә кушылды.

Мәктәп өстеннән үтеп киткән гөрелтенең ни икәнен беренче булып Мәгъсүм күрде. Әлифбадагы уналтынчы хәрефне матур язу дәфтәреннән тактага күчереп маташа иде ул. Аның кычкыруы ике катлы мәктәпнең бөтен бүлмәләренә ишетелде:

— Яраплан!

Дәресләр кинәт өзелде. Барлык укучылар урамга ыргылды. Укытучылар, балаларны туктата алмагач, үзләре дә төркемгә иярде. Техничка Миңлебикә кыңгырау шалтыратырга мәҗбүр булды... Ындыр артына мәктәпнең иң соңгы кешесе булып директор Мөлеков килеп җитте. Колхоз рәисе Таҗиның «ГАЗ–69»ы әллә кайчан самолет янында иде инде, ул Мөлековны үз янына чакырып алды. Винты әйләнүдән туктагач, җиргә иң әүвәл күн тужуркалы, хром итекле яланбаш бер ир сикереп төште, ләкин ул очучы түгел иде әле, анысы шлемын салмаган, тәрәзә артыннан кырын карап, болындагы тамашаны күзәтә. Бер уйласаң, килеш-килбәте, кием-салымы буенча Мөлеков райком секретарьларына охшаган иде. Ләкин хром итекле кеше «хлопчато-бумажный» костюм, өске ике төймәсе ычкынган шакмаклы сары күлмәк кигән һәм чәчләре самолет җиленнән тузгыган Таҗи белән беренче булып күреште. Димәк, ул аны күптәннән белә иде инде. Ул арада спорт залындагы шау-шулы дәресе аркасында маҗарага соңга кала язган физкультура укытучысы Шәйхи, төркемне ыра-ера үтеп, директоры янына килеп басты, вәкил аның белән дә күреште, ләкин кул биргәндә йөзенә карамады, Таҗи белән турыдан-туры сөйләшүен дәвам итте.

Иртәгә иртәнге сигездә, КПСС өлкә комитетының ашыгыч утырышы булачак дип, телефоннан хәбәр алынган иде инде. Шуңа күрә самолет белән килеп алулары Таҗи өчен көтелмәгән хәл түгел. Ул әлеге колхозны сугышка чаклы ук җитәкләгән кеше, ТАССРның Верховный совет депутаты. Обком члены буларак, киңәшмәдә аның катнашуы мәҗбүри. Ул анда Үзәк Комитеттан килгән ябык хат укыласын белә. Ясалма иярченне Октябрь бәйрәменең кырык еллыгына багышлаулары да хикмәтсез түгелдер. Җирдә «салкын сугыш» бара.

Мәктәп балаларының килүе әйбәт булды, самолетны дилбегәләр белән тартып ындыр табагына кертәсе бар икән. Анда мәйдан иркен — җыелган икмәк амбарларга салынган, капкасы бикле, каравылчысы бар. Аэроплан шунда төн кунарга тиеш.

Шул көнне үк физкультура укытучысы Сакал кушаматлы Шәйхи, сургыч бөкеле ике ярты кыстырып, Юаш кушаматлы Нотфулланың өенә чакырылмаган кунак булып керде.

Көзнең калган эшкә кар яудыра торган чагы...

Яңгыр белән кар, чиратлашып җебетә торгач, бала-чага түгел, буй җиткән җилкенчәкләрнең дә клубка кадәр пычрак ерып, күңел ачам дип йөрергә теләге юк. Нотфулланың җиде баласы озын өстәл артына сыенып, калын китап өстенә куелган корымлы чуеннан кабыклы бәрәңге каезлаган чагы иде. «Берәр кило пыяла конфет күтәреп килсәң, яхшы буласы икән», — дип уйлап куйды кичке кунак, тик үзенең укытучы дәрәҗәсен саклап, бала-чагалар каршында аракы чыгаруны кирәк дип тапмады. Нот-

фулланың «Әйдә, Шәйхи, апак, чикмәнле бавырсактан авыз ит, укытучы кешегә тансык ризык ул, гомбагыш маена манып ашасаң, хәйран тәмле», — дип, табынга чакыруын Шәйхи тиз бүлдерде:

— Нотфулла абый, чыгып сөйләшәсе сүз барые.

Әгәр Шәйхи урынында бусага төбендә рус теле, арифметика, йә булмаса тарих укытучысы басып торсамы?! Нотфулла аларны чуенлы бәрәңге янына түгел, такта урындыкка да утыртмас иде. Җиде баланың дүртесе сабакка йөрсә, укытучыларның ник килгәнен чамаларга була. Рус теле дә, арифметикасы, тарихы да кирәкми бу балаларга. Дүрт кыз, берәм-берәм сигез классны бетергәч, кияүгә чыга, олы малай — тракторист, уртанчысы — шофер, кече малай әтисенә алмашка көтүче була. Ә менә физкультура укытучысының Юаш Нотфулла балаларыннан зарланырлыгы юк, гаилә башлыгы моны бик әйбәт белә, эшкә тере баланың һәр көне — физкультура дәресе!..

— Иркенләп сөйләшәсеме, әллә әйтердәй йомышың гына бармы?

— Киенеп чыксаң, иркенләп сөйләшер идек.

Хуҗалык маллары кулга кергәч, берара эшсезрәк йөргән көтүче Нотфулла, кунакның «иркенләп сөйләшү» дигән сүзеннән тиешле нәтиҗә ясап, бушлат кесәсенә мич каршында тоз сибеп көйдерелгән бер телем ипи салды.

Урамга чыгып ишегалды ягындагы тәрәзәдән төшкән ут яктысына килеп баскач, Шәйхинең исенә төштеме, әллә өй эчендә сүз кузгатырга уңайсызланып әйтми калганмы:

— Стакан юк бит безнең, Нотфулла абый,— дип тамак кырды.

— Әй, бер чыккач кире борылмыйм инде, гурласыннан гына чөмерик, — дип гайрәтләнгән иде дә, тик шешәдәш авылдашының алмашка йөри торган көтүче түгел, ә ни дисәң дә культурный кавем икәнлеген исенә алып, тәкъдименнән кисәк кире кайтты.

— Әйдә, Динәләргә!

— Кеше алдында сөйләшә торган сүз түгел иде.

— Нинди кеше?! Динәне безгә куабыз аны, кызы белән Фазылны ияртеп кич утыра керсен. Олы малае мәктәптә әбисе янында куна.

## Ике шешәле заговор

Фазылның әнисе, соңгы тапкыр калага бәрәңге сата барганда, ярты капчык чамасы кисәкле чүпрәкчапрак күтәреп кайткан иде. Тегү фабрикасында җыештыручы булып эшләгән бер апа биш кило бәрәңгегә алмаштырган бугай. Кич җитте исә, Динә шул кисәкләрне кулдан корамалап, урындык өсләре, матрас тышлары тегә, вак-вак өлгеләрне аралаштырып теккәч, төрле төстәге бизәкләр килеп чыга... Нотфулла белән Шәйхигә бикле капка ачарга чыкканда, аның сул кулына корама кисәге ияргән иде әле.

— Кем бар анда? — дип кычкырды Динә, капканың икенче ягына ишетелерлек итеп.

— Динә, мин әле бу — Нотфулла...

— Чукынып йөрисеңме, караңгы төндә? Бикле капканы ачар хәлем юк!

— Тукта әле, Динә, Нәфисә чирләбрәк тора анда, што-то ашамый да, эчми дә.

— Әллә Ходаем бәбиләр вакыты җиткәнме? Хәзер, аягыма бутый киям дә...

— Кабаланма әле шулхәтле, Динә, мин монда Шәйхи белән.

— Ниткән Шәйхи, Юаш тәресе, характерымны беләсең, миндә ирләр кайгысы юк. Әнә Шәйхиләреңне күрше авылга алып бар, ат җик тә...

— Динә, укытучы Шәйхи бу, ач әле капкаңны!

— Ә-ә?! Сакал Шәйхиме? Әстәгафирулла, Фазыл бер сүз дә әйтмәде. Ул-бу юктыр ич, үтерәм мин ул «урыс»ны?! Тәртипсезләнеп кенә карасын! — Динә капканың яңгырдан бүрткән шудыргычын боргалады, үзе сөйләнә торды, шудыргыч тыгызланган иде, ахрысы, көчәнүдән җөмләләре өзек-өзек ишетелде. — Әле батып кайткан, Фазылны әйтәм, өр-яңа күн итекнең эче чат балчык. Мич башында йоклап ята. Синең Мәгъсүм белән юка боз өстендә уйнаганнар.

Тол хатынның баласы әнисеннән алдан йоклап киткән, дисәләр, ышанмагыз. Капка дөбердәткән, тәрәзә шакыган төнге теләнчеләрдән, эштән гайбәт булып ияреп кайткан исемнәрдән көнләшү ятимнәрнең аңына сеңгән. Амбардан хезмәт көненә тиешле икмәкне колхозчыларга өләшеп йөрүче Чукрак Гарифулла өй түренә килеп туктаса, Фазыл ат җигүченең аркасына салынган һәр бодай, һәр арыш капчыгына тагылып өйалдына керер — чолан аулагында әнисенә орына күрмәсеннәр... Делянка чистартканда җыелган нарат очларын китереп аударгач, шофер Җитмеш Мөхәммәтне сыйлаганда: «Бар, улым, абыеңның машинасына күз-колак бул, бала-чага кабинасына кермәсен!» — дип, Фазылны урамга кусаң — ятимеңнең чырае тәрәзәгә ябышыр, ишегалды тәрәзәсен урам ягыннан карап торыр. Ишем Нәгыйме, сарык суеп биргәч, Динәнең бер литрлы әче балын мактый-мактый чөмереп, яңа кыздырылган бавыр белән нәфесен түгәрәкләгәч, тәмәке тартырга дип чыгып киткән җиреннән тагын әйләнеп кермәсме?! Әгәр инде төн шигеннән кача-поса Динә капка ачарга чыгып китсә, улын уятырга кызганган ана тавышы белән Фазылга йорт иясе эндәшә: «Уян, Фазыл, йоклап ятма! Әниеңне югалтасың!» — дигән әмер, колак эчендә чатнап, ток суккандай сискәндереп, теләсә нинди тирән йокыдан мәхрүм итә. Ләкин бала-

лык дигән самими чор бар. Фазылның әле маҗара эзләп, серле әкиятләргә ышанып, күмелгән хәзинәләр турында хыялланып, шпионнар турында кино карап үсә торган чагы.

Сакал Шәйхи «Динә апа, Нотфулла абый белән икәү генә ирләрчә сөйләшәсе сер бар иде...» дигәч, Фазыл мәрткә киткән ише йоклаганга сабышты. Җитмәсә, әнисенең күрше Нәфисә апа янына кереп китәчәген дә ишеткәч, малайның җаны тыныч иде. Нәфисәләрдә Динәгә кул сузардай ирләр юк. Анда бала-чагалар гына, Юаш Нотфулла үзе әнә Фазыл янында сакта калды. Хәер, Фазыл көнләшми аннан. Нотфулла гомер буе көтүче. Ул кырда, болында, урманда... Колхоз малының никадәр өлеше урланганын үз күзләре белән күреп йөри. Көтүендәге һәр малның нәрсә ашап кышлаганын белә, туарына карап хуҗасын таный. Туры юлдан көтүлеккә ашыкканда, читтәге көзлеккә тайпылган мөгезсез сыерларның артыннан йөгерми Нотфулла, аларны өрәңге саплы, алтыдан үрелгән, кыл койрыклы, биш колачлы чыбыркы куып тота, тәнгә тигән җирендә шартлый. Нотфулла ул чыбыркыны көн саен сумала белән сылый, кылын яңарта. Иртән көтү җыела торган тыкрыкка чыгып басканда, сыерларның гына түгел, хуҗаларының да күзе әнә шул кабыгын салган кара елан кебек елкылдап яткан чыбыркыда. Кичкә ул чыбыркы, сазлык, комлык, тузанлы сукмаклар аша үтеп, Нотфулланың үзе кебек тәмам искереп сөйрәлеп кайта. Иртәнгә исә тагын яңара... Инде ул чыбыркы бер атнадан бирле чормада. Нотфулланың эше юк. Җәй күргәннәрне исенә төшереп, район гәҗитенә фельетоннар яза, басылмаганнарының күчермә кәгазьдән төшерелгән икенче нөсхәләрен өлкә гәҗитләренә илтә. Авылдагы бөтен кыек-мыекны турайтыр өчен матбугатка озатып торучы өч кеше бар авылда. Бригада саен берәү алар. Фәсхет Гыльмие, Гәйсәр Галие һәм Фазылларның күршесендә классташы Мәгъсүмнең әтисе — Юаш Нотфулла. Ул беренче бригаданың файдалы киңәшләр, шикле проектлар, хыялый планнар һәм чынга ашмас идеяләр уйлап табучы генераторы. Динәне сыерсыз калдыручы да ул гына... Әдһәме сугыштан исән-имин кайтып кергәч, Динә яңа өй салу турында сүз кузгатуны ешайтты. Әдһәм орден-медальләрен тагып ничә тапкыр гына канатланмасын, тәки агач сорар өчен райпланга барып җитә алмады. Күрше Әдһәм абыйсына чын күңелдән ярдәм итәргә теләп, Нотфулла төшемле киңәш уйлап чыгарды:

— Җәй көне ит әйбәт үтә. Сыерыңны суеп базарга чыгасың. Яңадан бозау аласың. Калган акчага Кызыл яшьләр кардонына барып бура буратасың. Бер елдан таналы да, яңа өйле дә буласың...

Бер әйтә Нотфулла, ике әйтә... Әдһәмнең күңеленә коткы керә. Көнгә ике чиләк сөт бирә торган эре сөякле, тупырдап торган биш яшьлек сыер, таң белән туналып, Чукрак Гарифулланың ат арбасына төялә. Казан юлында чебен борчымасын өчен түшкә өстенә одеал ябалар. Гөнаһ шомлыгы... Өстәлгә җәя торган ике-өч клеенка белән капласаң, кырык чакрым араны үткәнче кояш астында ит тынчыр дип, бөтенләй үк баш тартасы калмаган икән. Кирәкмәсә дә, арба төбенә җәеп калдырасы булган... Анысына Нотфулланың да, Әдһәмнең дә башы җитмәде.

Авылдан чыгып, биш чакрымдагы Мишәнең чыбык күперен кичүгә, әллә кайдан — аэродром өстеннән котырган болытлар өерелеп килде дә айгыр атлый алмастай яшенле яңгыр коеп, ярты сәгать эчендә хыялларны юды, юлны бозды, тауарны әрәм итте... Базарга килеп кергәндә, җылы яңгырдан соң, бөркү һаваны пешергән рәхимсез кояш астында сыер түшкәсе пешегеп, симез урыннары чәерләнеп, итләч төше каралып, ит дигәнең җирәнгеч үләксәгә әверелгән иде. Әдһәмне базарга якын китермәделәр, келәймә сугучы яһүдә дымлы җәймәнең почмагын күтәреп карады да, бөтен чыраен җыерып, «фу!» диде.

Сыерны Сабын заводына тапшыргач, кулга дүрт «шешәлек» акча тиде, Әдһәм Казаннан авылга кайтып җиткәнче эчте дә эчте, барыбер үләм дип җылый-җылый эчте. Чукрак Гарифулла гына тыярлык түгел иде инде. Шуңа күрә ул аны капка төпләрендәге чирәм өстенә тәгәрәтеп төшерде дә, Динә күзенә чалынганчы дип, атны конюшнейга куалады. Ул көнне Әдһәм өйдәгеләрнең сорау алуларына җавап тотарлык хәлдә түгел иде. Икенче көнне, көтүгә чыгышлый, Нотфулла сәүдә хәлләрен белешмәкче булып керсә — Әдһәм ике колагын куллары белән каплаган да:

— Балаларны ризыксыз калдырдым, — дип кабатлаудан ары берни әйтә алмый.

Нотфулла, аның бер кулын каерып, сыңар колагына кычкырды:

— Юлда таладылармы?

— Юк. Ходай орды, яңгыр сукты...

— Бик бетермә әле үзеңне! Баш исән булса, мал табыла, — дип, Нотфулла гына түгел, бөтен күршеләр юатса да, Әдһәм инде хәлләнмәде, урын өстенә егылды.

Язмышына үпкәләгән мордар кебек, яшәүдән ваз кичеп, ашау-эчүдән баш тартты. Сугыштан алып кайткан үпкә авыруы шуны гына көткән икән... Әдһәм авылдагы иң иске өйнең сәке өстендә, боз каткан бер катлы тәрәзәгә карап, җан салды. Шул көннән башлап «Нотфулла гына харап итте» дигән нахак рәнҗү Динәнең уеннан чыкмады. Әнисенең уйларын ишетеп яшәгәндәй, Фазыл да аны сөйкемсез сөяк итеп күрде. Дөрес, әтиләре үлем түшәгенә яткач, Нотфулла көн саен берәр литр сөт күтәреп керә торган иде. Ләкин аның бу миһербанлы гадәте Фазыл ятим калганның икенче көнендә үк онытылды, чөнки үзенең дә гаиләсе ун тамаклы...

Сакал Шәйхи белән Юаш Нотфулланың серле сөйләшүләре, һичшиксез, этисе турындадыр кебек тоелды Фазылга. Төпчек улына ярты яшь тулганны да көтмичә, ник үлеп киткән ул? Батырлар үлмәскә тиеш. Әнә хезмәт батырлары әйбәт яши ич!..

Ләкин Фазыл өметләнгән сер менеп җитмәде мич башына. Шәйхи белән Нотфуллада бүген бөтенләй башка гамь иде. Иң әүвәл алар Фазыл белән әнисе чәй эчә торган чокырларга аракы бүлделәр. Ышаныргамы, юкмы бу тынлыкка дигәндәй сагаеп, шактый сүзсез утырдылар. Соңыннан аракы сеңдеме, әллә Динә пешергән кәбестә бөккәне ошадымы, үз өйләрендә утырган кебек телләре ачылды. Шәйхи, ниһаять, серен чишәргә булды.

— Күрдеңме самолетны?

— Бөтен авыл җыелды ич, мин монда причем? — диде Нотфулла, әңгәмәдәшнең тел төбенә төшенмичә...

— И Таҗиның кылануын күрсәң — обком секретаре диярсең! Бүксәле бүкән! Самолетлар белән каршы алырлык кем соң ул?! Җитмәсә, аның янында теге Себер татары ачу китереп йөргән була.

Физкультура укытучысы үз директоры исеменә илтифатсызлык күрсәткәч, Нотфулла да бераз куәтләргә теләде.

— Кысык күзләләр хәйләкәр була ул.

— Таҗиның яше җиткән. Мөлеков аның урынына калырга хыялланадыр әле.

— Ник, калыр да! Белеме югары, кешеләргә ягымлы, балалар да, укытучылар да ярата бит үзен. — Нотфулла шушы сүзе белән Сакал Шәйхине чыгырыннан чыгарырмын дип уйламаган иде.

— Мин дә укытучы! Мөлеков Себердән качкан кеше. Безгә үзебезнең кадрлар кирәк!!!

— Маратның хатыны күрше авыл кызы, димәк, якташ кебегрәк килеп чыга.

Әгәр сөйләшү гел мондый күтәренке тавыш белән барса, әрләшүгә күчәселәр иде. Шешә тирәсендә озын тынлык урнашты, хәтта Фазыл йокыга китә язды.

— Бүген педсоветтан соң озак кына бәхәсләшеп утырдык.

— Ну?!

— Таҗи турында...

— Ие... шуннан? — Нотфулла кемнән гаеп эзләргә белмәде.

— Радиодан нәрәт биргәндә оялып утырабыз. Һич кенә дә сөйләшә белми бит инде...

— Сез укытмаган ич аны, нәрсәсенә ояласыз?

— Суң, Нотфулла абый, сугыш беткәнгә унбиш ел була. Яңача яшәп карарга вакыт. Әнә күршедәге Күн, Чыты, Колай авылларында эшләргә кеше юк, ә без мең морҗалы колхозда коммунизм төзергә җитәрлек халык белән бер урында таптанабыз.

— Да, Шәйхи энем, мәктәп директоры итәргә вакыт сине, Мөлековны алып атыйк та... Кысык күзе түгәрәкләнер.

— Атыйк дип сөйләмә әле, Нотфулла абый, Сталинчарак килеп чыга. Шәхес культы фаш ителде...

— Ә син, итит-митит, һәр сүзгә бәйләнеп утырма, тайный полиция кебек. Мин коммунист түгел, булмам да, шәт.

— Үпкәләмә, Нотфулла абый, гариза язсаң да алмыйлар сине партиягә.

— Кәнишне, беләм мин аны. Минем кебек туры сөйли торганнар нәрсәгә анда? Әле ярый, утыз җиденче елларда малай-шалайлар рәтендә калганмын. Зуррак булсам, Әки Сәләхи күптән чагып кайта иде инде мине, авыр туфрагы җиңел булсын, заразының. Грамотный коммунист иде, күпме кешене әләк язып озатты.

— Әләк язарга дигәндә, Нотфулла абзый, син дә кимен куймыйсың!

— Шайтан башка, җен башка, энем. Мин әләк түгел — район гәҗитенә тәнкыйть мәкаләләре җибәрәм. Һәм язганнарым астына исем фамилиямне тутырып куям. Әгәренки колхоз җыелышларында минем киңәшләремә колак салучы табылса, бәлки, гәҗиткә дә язып тормас идем... Йә, кыскарак тот сереңне. Аракың эчкән саен айныта гына. Кәеф бетте дә бугай инде.

Сакал Шәйхи бушаган шешәне өстәл артына тәгәрәткәч, куен кесәсенә кул тыккан атлы кыланып, тагын бер сургучлыны муеныннан сөйрәп чыгарды. Буш шешә тәгәрәгән тавыш мич башында йокысын югалткан Фазылның өметен азындырды — башы кителә күрмәсен тагын, кибеткә тапшыргач, иртәгә дүрт прәннек эләгә бит аңар! Юмарт чәйнектән аккан ише шаулатып, стаканга аракы салганнарын ишеткәч, Фазыл үзе дә сизмәстән кисәк сөенеп кулларын угалап өлгерде: монысын да бушатсалар — вәт сигез прәннек була! Кеше өенә сер алып килгәнгәме — Шәйхинең колагы сизгер иде:

— Мич башында теге малай уянды дип әйтимме?

— Йокы аралаш кашына торгандыр, уянса, күптән инде әнисен эзләп елап төшәр иде... Ә син, энекәш, ныклап әзерләнеп килгәнсең бу сөйләшүгә.

— Минем мәктәп директоры гына буласым килми, Нотфулла абый. Син мине колхоз председателе итеп куй.

— Әйттең сүз, итит-митит! Мин сиңа әллә райком секретаремы? Районнан килеп куялар бит аны.

— Анысы шулай, районнан килеп әйтәләр, ә сайлавын халык сайлый. «Каршы» дип кул күтәргән кешеләрне җыеп алганнары юк әле.

— Әйттең сүз! «Әйе» дигәннәр тавыш биргәндә, «юк» дияргә теләүчеләр ике кулларын кесәгә тыгып утыра... Бер мин каршы күтәрәм.

— Тимиләр дә, исән-имин яшәп торасың.

— Кәнишне, мин коммунист түгел ич! Өстәгеләрне тыңламасаң, партбилетыңны өстәлгә чыгарып сал, дип, сезне куркыталар ул...

— Шуңа күрә синең яныңа килдем дә. Куркырлыгың юк. Сайлат син мине, Нотфулла абый.

— Теге сүзне әйттерәсең инде, кәләш сайлыймыни, итит-митит!..

— Председатель сайлау да кәләш ише инде, әйбәт кеше очраса, шул урында үлгәнче эшли.

— Ничегрәк итеп сайларга кушасың? Мисал өчен, дигәндәй...

— Вәт монысы, ичмасам, акыллы сорау. Күз алдында тоткан җиде кешем бар...

— Берсе минме?

— Әйе, Нотфулла абый. Тагын алты кешене аулакта туры китерепме, өйләренә барыпмы — Таҗига каршы котыртасың. Алар җыелышта бер-бер артлы чыгыш ясарга тиешләр. Таҗины бетереп сөйләргә кирәк. Сугышка китүдән куркып, бронь алыр өчен генә председатель булырга ризалашты. Берәр пот икмәк күтәреп килеп, колхоз хисабына фронтовикларның хатыннарын саплап йөрде.

— Шулай ук атап әйтергәме?

— Көчләп йөрде дисәң, үтемлерәк була инде. Теләсәгез, ул хатыннарның исемнәрен саный алам, диген.

— Ә санарга кушсалар?!

— Кушмаслар. Залда сугыштан кайтканнар күп. Һәркем үзенекеннән шикләнер, әйттертмәсләр.

— Әйттерсәләр?

— Әйттерсәләрме? Теге алты кешенең берсе хатын-кыз. Аңа да сүз бирәсең. Ире сугышта үлеп калган Һәдия апа кирәксә чыга да әйтә. Әйтмәсә, Нотфулла дөресен сөйли, дигәне дә җитә... Люткино, Андреевка бригадаларында җыелышта заготовительләрне ничек сүккәнен әйтерсез. «Мясо не сдаете, молоко кончал, яйца ниту, мала-мала шерсть видать» дигәннәрен дә әйтеп халыкны көлдер. Оялсын.

— Каян ишеттең, дисәләр? Минем ул бригадаларның җыелышында булган юк.

— Безнең җавап әзер. Шундый бер җыелышта Гайсәр Галие Таҗиның чыгышын протоколга теркәп барган. Безнең кулда ул... Ну, халыкны тузгытып җибәрү өчен шушылар җитеп торыр. Калган гөнаһларын өстәрләр. Кемгә утын, кемгә салам, кемгә фураж бирмәгән — берсен-берсе уздырып тиргәрләр. Син башла гына. Залдагы халык кире сөйләгәнне ярата.

— Әгәр Таҗи урынына Мөлековны тәкъдим итсәләр?

— Аны үзебезнең якка авыштырырга кирәк. Өметләнмәсен.

— Мин тәки бернәрсәне аңлап бетермим, Шәйхетдин, — дип, Нотфулла әйтер фикерен оныткандай тынып калды.

— Аңлаштык шикелле...

— Аңлаштык, ну килешмәдек. Без синең белән кардәшләр түгел, кода-баҗай буласыбыз да юк. Авыр сүзләр күтәреп, җәнҗал чыгарып йөрүдән миңа ни толк... Мәһәрен күрмим.

— Ә-ә-ә! — дип сузды Шәйхи, әңгәмә ахырында бу сорауны көткән сыман кыланып, үзе «ә!» дип аптырап торган арада, Нотфулланы сөендерерлек җавап эзләде. — Заффермы итәм мин сине.

— Үзеңә булсын фермың. Мин болай да гомер буе хайван койрыгына чыбыркы селтәдем, иртәдән кичкә чаклы сыер бугы таптап йөрим.

— Алайса, Нотфулла абый, мин сине сельсоветка куям, Алла боерса, үзем җайлы гына үтсәм.

— Юк, энекәш, авыл председателе итеп Таҗины куячаклар. Зур кешене сразы гына этеп екмаслар... Син мине лутчы урынбасарың итәрсең. Ике чабата — бер кием, икәү яулыйбыз, икәүләшеп җитәклибез. Ых-ых-ых!.. — Нотфулла, көләргә кирәк чакта йөзенә чыгармый, тавышы белән генә көлә...

— Рәхәтләнеп риза! — диде Шәйхи, тумаган тайны йөгәнләп.

— Зурдан кубып уйлаганда, патшаны бәреп төшерү кебегрәк килеп чыга түгелме?

— Чагыштыруыңны әйтерием. Патша кайда утыра да, Таҗи кайда?! Хәер, гаилә — җәмгыять ячейкасы, дигән Энгельс бабай. Безнең авыл да зур дәүләтнең бер кечкенә моделе... тәхеттән үзе төшәргә теләмәгәч... революция оештырырга туры килә...

Фазылның бала чагында кичергән бердәнбер йокысыз төне иде бу. Юрган астына сеңү белән ашыгып йокыга китә торган малайның көнозын өелгән ару-талулары отыры юкка чыкты. Ул үзен маҗаралы кинода катнашкан батыр пионер кебек хис итте. Нининдидер шпион турында сүз бара. Аны тотар өчен, иң әүвәл авыл халкы алдына чыгып сөйләргә, фаш итәргә, соңыннан кулга алырга кирәк. Юаш Нотфулла белән Сакал Шәйхи дошман тылында йөри. Ул шпионны тотканнан соң, тормышлар тагын да рәтләнеп, арурак көннәр киләчәк. Һәм бу киноның ахыры Фазыллар өчен сөенеч белән бетәр — колхоз аларга шифер түбәле өй салып бирер...

Бик күп еллар үтеп, бихисап сулар агып, иксез-чиксез юллар кичеп, ир уртасы яшенә җиткәч тә, әнә шул йокысыз төн төшенә кереп, Фазылны бик еш уятыр. Уятыр да җан тынычлыгын алыр. Уянган саен ул аңа яңача бәя бирер, төрледән-төрле нәтиҗә ясар... Ике кеше сүз куешса — өченче кешегә гаеп өелә икән. ...Урын кирәксә — икенче берәүне ул урыннан бәреп төшер... Исемнең асылы — бәрелеш... Ә ул бәрелешнең артында урындагылар заговоры икән...

Авыл язмышын ил язмышы белән чагыштырсаң, югарыдагы түрәләрнең кылган гамәлен күз алдына китерү өчен, Сакал Шәйхине белү җитә. Ул йокысыз төн хәтта көндезләрен дә күз алдыннан китми. Ил күләмендә хәвефле хәбәрләр таралса, кара җепнең бер очы Сакал Шәйхигә килеп тоташадыр төсле. Һәрхәлдә, Фазыл өчен шулай тоелды.

## «Берлинны алу...»

Мәскәү битен ачса — провинция бөтен җирен ача.

Әгәр яңа гына тәхеткә менгән Ил Башлыгы үзенә чаклы идарә иткән патшаны сүксә — гади халыкның теле үсә, караңгы авыздан якты дөньяга чыга... Хрущев заманында «Әйе, ярар, шулай шул, бүтән алай эшләмәм...» дигән беркатлылык урынына «Юк, алай түгел ул, алдамагыз халыкны, Мәскәүгә язабыз...» дигән катгый чыгышлар алмашка килде. Ярты сәгатькә дип исәпләнгән киңәшмәләр дә өчәр сәгатькә сузыла торган иде.

Колхозның отчет-сайлау җыелышы өч көн барды... (Алгарак китеп шуны әйтик, кырык биш ел үтеп, мондый тамашаның әле дә булса кабатланганы юк...)

Беренче көн, Питрәч райкомы раслаган көн тәртибе буенча, Таҗиның хисап докладлы белән башланып китте. Өч йөз илле кешелек клуб шыгрым тулы, рәт араларында басып торырлык мөмкинлек тә юк. Халыкның яртысы Юаш Нотфулла оештырган тамашада катнашырга килсә, калганнары җыелыштан соң «Берлинны алу» дигән киноны бушлай карау өченгә җыелган иде.

Уникe чишмәле авылда сүз бик тиз йөри. Таҗи үзенә каршы этлек оешканын белде, ләкин артык борчылмады, мәртәбәле кеше буларак, аны райком хөрмәт итә, ә партиягә каршы сүз дәшәр өчен Нотфулла төркеменең түшәме тәбәнәк дип тынычландырды ул үзен.

Клуб эчендәге озын эскәмияләрнең киносөючеләр өчен өч рәткә тезелүе колхозчыларны үзеннәнүзе өч төркемгә бүлде. Сул якта Таҗиныкылар — күрше-тирәләре, туган-тумачалары, аннан азмы-күпме ярдәм күргән кешеләр утыра. Уңда — Юаш Нотфулла, Бакый, Насыйбулла, Капаса Габдулла, Гайсәр Галие, Фәсхет Гильмие... Хәтта, үзенең укытучысын якларга дип, Мөлеков та җиң сызганып килгән. Ә урта рәттә — аумакай халык, Сакал Шәйхи юри алар арасына сеңде, тавышларын кемгә бирергә аптырап утырганда, үз ягына авыштыру аның теләге.

Таҗиның, калын пыялалы күзлеген киеп, химик карандаш белән язылган бер дәфтәргә теркәлгән докладтан: «Хөрмәтле колхозчылар!..» — дип, тәүге җөмләне әйтеп салуы булды — уң рәттән президиум өстәленә сүз сорап язулар агыла башлады. Һәр язу кисәге, кулдан-кулга күчеп, җыелыш рәисенә барып җиткәнче, залдагыларның бөтен игътибарын җәлеп итте, ә уң рәттә исә бөтенләй чуалыш тудырды. Президиумда утырган райком инструкторы әлеге ыгы-зыгыны ошатмады, сүз башыннан ук докладчыны туктатты.

— Җәмәгать, — диде ул, сулы графинны алтын балдагы белән зыңлатып, — сорауларны үзегез ташымагыз, рәт кырыеннан җибәрегез!

Инструкторның кисәтүеннән соң, зал бер мәлгә тынып торды. Ләкин, Таҗи бер ел эчендә ирешелгән уңышларны саннар белән җиткерә башлагач, яуланган тынлыкны Сакал Шәйхи бозды:

— Без бу саннарны пионерлар дружинасы алдында сөйләдек инде, боларны бала-чагалар да белә!

Таҗи уңга-сулга карамый укый тора — уң рәттәгеләр кушыла тора. Җыеп алынган уңыш, дәүләткә сатылган икмәк һәм сөт, ит һәм йомырка турындагы хисапка күчкәч, Юаш Нотфулланың тавышы ишетелде:

— Яшьләр җыелышында комсомол секретарегыз да шушы ук саннар белән мактанды.

Гадәттә, ел саен җыелыштан җыелышка Гайсәр Галие белән Фәсхет Гильмие генә каршы сөйләп маташа иде һәм халык инде аларның тел төбенә күнеккән иде. Ә монда бөтенләй колак ияләнмәгән авазлар карыша.

«Икенче көн тәртибенә күчик!»

«Давай, фикер алышабыз!»

«Җиңү байрагы» гәҗитен укыма безгә!

«Үзең ниләр кырдың, шуны сөйлә!..»

Доклад дәвам итте. Таҗи, зал гөжләвенә исе китмәгәндәй, канатланып укуын белде. Ул арада уң рәт белән суллар әрләшүгә күчте:

«Кыланып утырмагыз, тыңларга ирек бирегез!» — диде сул рәт.

«Җыен куштан җыелгансыз анда», — диде уң як.

«Таҗи аркасында авызыбыз икмәккә кинәнде!»

«Мактама! Сталин кадрларын алыштырырга вакыт!»

Әрләшү сәясәткә тайпылгач, райком инструкторы янә сикереп торды:

— Әгәр тынычланмасагыз, участковый Архиповны чакыртам!

Халык тынычланган ише тоелды, ләкин озакка түгел.

Таҗиның графиннан бер стакан су салып эчүе талаш оештыручылар өчен яңа сәбәп булды:

«Бетермә суны, сөткә кушарга калдыр!» — Уң рәттәгеләр, көләселәре килмәсә дә, дәррәү күтәрелеп көлешеп алды.

Фазылның әнисе Динә Сакал Шәйхиләр рәтендә иде. Кемнең ни кычкырганын отып калалмаслык шау-шудан файдаланып, ул да түзмәде, колхоз председателенең данына кергән гайбәтләргә ишарәләп кычкырып куйды:

— Таҗи минем кәҗә сөтен бик ярата ул!

Халык көлгән арада, Юаш Нотфулла, Динә ягына борылып, баш бармагын тырпайтты. «Шәп әйттең!» янәсе.

Җыелыш бер көнгә сыешмады. Бәлки, халык төнге сәгать унберләргә чаклы утырган булса, сайлау дигән иң мөһим көн тәртибенә килеп җитәрләр иде. Мәгәр Таҗи докладының урта бер төшендә президиумның кашкасы булып утырган райком инструкторы, өстәл артыннан торып, сәхнәнең пәрдәләре арасына кереп китте. Залдагылар аны баштагы мәлне борын сеңгерер өчен кеше күзеннән качты дип уйлаганнар иде. Район хуҗалыкларында исәп-хисап җыелышлары төрле көннәрдә үткәрелә. Инструктор, брезент түбәле «ГАЗ-69» белән көзге юлсыз юлларны кичеп, карлы-яңгырлы авылларны график буенча йөреп өлгерә, тамагы тук булса да, тәне җылыга кинәнми, аягы корыдан мәхрүм, томаудан арына алмый, президиумда утырганда гел пырыш-пырыш борынын тарта... Пәрдә артында озаграк югалгач, җыелыштагылар аны тәмәке көйрәтә дип белделәр. Җитмәсә, алгы сул рәтне сискәндереп, залга махра исе агыла башлаган иде. Ләкин тәмәке тартучы кеше алгы рәттә үзенә сүз биргәннәрен көтеп кыбырсып утыручы Фәсхет Гильмие булып чыкты. Гильмине бер аягы фронттан иртәрәк алып кайтты. Тәмәке тарткан саен, протезын шыгырдатып интекмәсен өчен аңа залдагылар каршы сүз әйтми. Ә райком инструкторы тәмәкесе янып беткәндә инде авыл белән Питрәч арасындагы сигез катлы урманның яртысына җиткән иде. Аның көндез сәгать унбергә, партия сафына яңа әгъзалар кабул итү комиссиясенең утырышына өлгерәсе булган икән.

Инструкторның китеп баруы җыелышның йөгәнен салдырды. Төннәр буе язылган докладны укып бетерергә ирек бирмәделәр. Таҗи янына фикер алышу өчен Нотфулла менеп басты. Шулай итеп, беренче көн тәртибен өзеп, икенчесе башланып китте. Таҗи докладны бүлеп президиумга килеп капланды. Чыгыш ясаучылар күбрәк уң яктан булып чыкты. Суллар трибунага барып җитә алмады, җиткәннәрен дә, Таҗины мактап авыз ачуга, сызгырып төшерә тордылар. Һәр сөйләүче үзеннән өсти башлагач, тәнкыйтьләү, җепшек тау башыннан тәгәрәп төшкән кар йомарламы кебек зурая барып, ахыр чиктә Таҗи өстенә ишелә... Ниһаять, уңнар тәкъдиме өскә чыга: райком секретаре үзе килмичә торып, Таҗи турындагы фикерләрне һавага сипмәскә, район җитәкчелеге иске рәисне ник тәнкыйтьләгәннәрен шәхсән ишетсен, бәлки, безнең якка авышыр...

Ләкин телефоннан секретарь урынына аның кабул итү бүлмәсендә ишек төбе саклаучы марҗа кызы сөйләште. Ни кызганыч, Беренче кеше Министрлар Советына «Кукуруз киңәшмәсенә» киткән.

Җыелыш бушлай кино карауга күчте.

Икенче көнне беренче секретарьның килүе киеренкелекне генә арттырды. Кичәге чыгышлар репетиция ясау гына булган икән, бүген алар аеруча гайрәт һәм нәфрәт белән кабатланды. Җае килгәндә, сүз уңаеннан секретарьның үзенә дә төртмә сүзләр әйтелде. Таҗиның озак еллар кәнәфигә ябышып утыруы райком яклавыннан башка түгел, диделәр.

Кичәге томана халык бүген «Совнархоз» исеменнән сөйли. Мөлековның бер җөмләсе ишек өстенә лозунг итеп язарлык иде: «Авыл — чишмә, башкалабыз — диңгез! Чишмәләр болганчык булса — диңгез нишләр?!»

Кояш баеп, клуб эчендә ут кабынгач, райком секретаре иң әүвәл Таҗи исемен ачыктан-ачык тавышка куйды. Суллар ягыннан иллеләп кеше ризалык бирде, каршыларны уң яктан эзләделәр. Шунысы сәер, Шәйхигә кул күтәрүчеләр дә шул чама иде.

Әгәр бушлай кино карар өчен генә берәр шәһәр кунагы кереп тавыш бирүне күзәтеп торган булса, ярсып сөйләүчеләр арасында икеләнеп кенә кул күтәрүчеләрнең күплегенә сәерсенер иде... Ләкин авылда төпләнеп яшәүченең кануннары кырыс. Мисал өчен, әгәр Таҗи үз урынында калды ди... Синең «каршы» кул күтәрүеңне аңа җиткерәләрме? Әлбәттә! Туганнары дәфтәр кебек язып бара... Шул ук вакытта Сакал Шәйхинең дә сайлануы мөмкин. Рәис булгач: «Син мине сайламадың, дип, нәселеңне корытыр. Алга таба ничек яшәрсең?! Трибуна артына чыгып күбек чәчкән «өйрәтелгән артист»ларны беләбез — алар йә пенсионерлар, йә сугыш ветераннары, Юаш Нотфулла — авыл көтүчесе, Мөлеков — мәктәп директоры, андыйларның колхозга ялынычы юк, кәнәфидә кем утырса да барыбер...

Урта рәттәгеләр өчен Мөхәрләм кул күтәрде. Ул гел шулай... «Битарафлар» сүзенең чын мәгънәсен аңлаучы кеше буларак, җыелыш саен беркетмәләргә берьялгызы теркәлә. Мөхәрләм трибунадан сөй-

ләнгән сүзләрне ятлый, чишмәдән чишмәгә йөргән гайбәтне куен дәфтәренә теркәп бара. Янгын чыкса, хәвеф килсә, низаглы урынга беренче кеше булып иң әүвәл Мөхәрләм барып җитә. Яңалыкка соңармас өчен махсус мотоцикл алды. Һәркемгә шикләнеп карар, сөйләшкәндә күп-күп итеп сораулар бирер, елмая белмәс, мактау сүзе ишетмәс, районга еш йөрер...

Ниһаять, сайлау бизмәне президиумдагылар теләгәнчә тигезләнде кебек. Көнозын барган бәхәстә көч түккән күндәм халык, соңгы парын чыгарган паровоз кебек уфылдап, сүнеп калды. Өч йөз илле кеше бер булып, үзенең кемне сайлавын аңлый алмыйча, райком секретареның соңгы сүзен көтте...

Шул чагында киномеханик Мәликә апай яңа зәңгәр сатин халатын җилфердәтеп сәхнәгә чыкты да җыелыш поставында зәгыйфьләнеп утырган саргылт графинны алып, аның урынына салкын судан тирләп чыккан яңасын куйды. Җыелыш бетәргә торганда, Мәликә апайның графин алыштыруын, залдагы оппозициягә ишарәләп нишләргә кирәген әйтеп тору, дип аңладымы — секретарьның күзлеге сикерә башлады. Әйтергә дип әзерләнгән карары тавыш карлыгуында төерләнеп калды. Ул стакан тутырып яңа су эчәргә мәҗбүр булды. Шушы өзеклек Мөлековка чәчрәп чыгарга мөмкинлек бирде:

— Җәмәгать, тагын иске чанага төяделәр сезне. Мондый очракта яшерен тавыш белән сайларга кирәк!

Тавыш җепселләре юылгач, секретарь кычкырыбрак сөйли башлады.

— Беренчедән, Марат Әбдрәсүлевич, сез колхоз члены түгел, бу җыелышта ирекле күзәтүче генә, икенчедән, без председательне сайладык инде.

— Алты тапкыр кул күтәртеп йөз кеше катнашкачмы?! Калган ике йөз илле тавыш кая?

Нотфулланы хуплау йөзеннән уңнар идән тибеп сызгырды, дәррәү күтәрелеп кул чапты. Соравына җавап ишетелмәгәч, «Юаш» оппозиционер трибунага чыгып басты.

— Менә мин — колхозчы! Үзем әйтәм! Җәмәгать, — диде ул, залдагы тавышны шып туктатып, — безнең әле моңарчы ике башлы сайлаулар үткәргәнебез юк иде, районнан килеп кемне күрсәтсәләр — шуны якладык. Инде килеп бүген ике кеше турында сүз чыккан икән, Мөлеков дөрес әйтә, яшерен тавыш белән сайларга кирәк.

— Сезнең сүзнең юридик көче юк. Яшерен сайлауны да тавышка куярга кирәк.

— Суң, кем мишәйт итә сезгә, алып барыгыз шушы рәвешчә...

Нотфулла, залга төшеп утыргач, секретарь алтын балдагын яңа графинга тидергәләде.

— Иптәшләр, тавышка куям, кем дә кем яшерен тавыш белән сайларга риза, шул иптәшләрнең кул күтәрүен сорыйм... Каршылар... битарафлар... Димәк, бертавыштан кабул ителә... Ләкин, иптәшләр, кеше саен бюллетень тутыру озак эш. Бүген соң инде. Иртәгә иртәнге сигезгә барыгызның да килүе сорала. Ә хәзер бушлай кино карагыз Кинопрокат сезгә «Берлинны алу» дигән фильм җибәргән.

Халык дәррәү көлеште, әмма кайтып китүче булмады.

Өченче көн дә «Берлинны алу» белән төгәлләнде.

## Сәрвиназ прәнниге

Авыл кибетендә, тапшырылган буш шешәләр өчен, акча тоттыру юк. Теләсәң, маен-шикәрен, тәмтомын сора, Лаеш заводы чыгарган карлыган вареньесын рәхим ит. Әгәр тауарга ризалашмасаң, буш шешәләреңне аркаңа ас та — дүрт ягың кыйбла. Сатып алучылар моны белә, күнә, карышмый, сүз куертмый. Ә менә бала-чаганың үз туксаны-туксан, кат-кат чират торып әрсезләнә, нәүмизләнә, үҗәтләнә, керосин шешәсен пешекләп алып килсә дә, унике тиен бакыр сорап тора.

Ләвкә чите буйлап этешеп, чираты җиткәнче, Фазыл пыяла тавышы чыгармады, ике шешәне берберсенә бәрмичә үлчәү турысына килеп баскач кына сатучы Сәрвиназ каршына китереп куйды. Малайның «Әйбер кирәкми!» дигән гозеренә, үҗәтлек йөзеннән, Сәрвиназ үлчәү тәлинкәсенә салып тормыйча гына бер учына тутырып алты прәннек сузды. Фазыл прәннеккә үрелмәде, ике кулын чалбар кесәсенә тыкты.

— Әйбер кирәкми, — диде ул киреләнеп.

— Нәрсә бирим, әйт тизрәк, чиратны тотма.

— Әйбер кирәкми. Прәннекне аны сабантуйда гына ашыйлар.

— Алайса, суыра торган конфет бар.

— Акча итеп бир.

— Шешәгә акча юк дип мең әйттем инде. Кире алып кит, әнә берсенең авызы китек бугай әле.

Һәм Сәрвиназ алты прәннектән бушаган учы белән ике шешәне, муеныннан алып, Фазыл каршысына бастырды. Чираттагылар дәшмәде. Пыр туздырып чыгарыр идең дә, ятим баланың рәнҗеше төшәр. Яклап сүз әйтсәң — авылның күз карасыдай сатучысы белән әчелешле булырга кирәк.

Фазылны оныткандай итеп, Сәрвиназ чиратны ашыктырмакчы иде, өлгермәде, малайның үпкәләүле, әмма масаюлы тавышы кибет эчен өнсез итте.

— Бу шешәләрне Юаш Нотфулла белән Сакал Шәйхи бездә эчте!..

Таш мәчегә егерме дүрт тиен акча салганын әнисе күргәч, Фазылга ничекләр итеп шешә сатканын сөйләп бирергә туры килде. Динә сөенмәде.

— Куандыргансың! Мин өйрәтеп куйган дияр әле, заразы. Ичмасам, нәкъ кешесенә эләккәнсең. Сәрвиназ бит ул Сакал Шәйхинең... Әй, — дип кул селтәде Динә, — сиңа әйтеп аңлата торган нәрсәме?!

Әнисе башлаган җөмләнең ни белән тәмамланырга тиешлеген, ягъни Сәрвиназның Сакал Шәйхи өчен кем икәнлеген үсә-үсә, яши-яши аңлады Фазыл.

Беренче идарә утырышында ук Сәрвиназны колхоз ашханәсенә мөдирә итеп раслалылар. Динә җәйге айларда өстәмә пешекче булып алына иде. Кич җитүгә, әнисен каршы алырга дип ашханәгә ияләшкән Фазыл яңа мөдирәнең кырын карашын тоя башлады. Бу артыксыну малайның ике кашык борчак боткасы ашавыннан түгел, кырдагы игенчеләргә дип пешергән ризык һәрвакыт артып кала, аны барыбер дуңгыз фермасына илтеп аударалар. Ике шешә тапшырыр өчен кеше алдында турысын әйтә алган малай үзе дә, аның әнисе дә Сәрвиназ өчен сөйкемсез сөякләр иде хәзер. Ахыр чиктә Динә барыбер ашханәне ташлап чыгарга мәҗбүр булды, хәтта ике елдан соң авылда сөт заводы салынып, Сәрвиназ анда директор итеп куелгач та, Динәне ахшанәгә чакырмадылар.

Фазыл балалыгы белән әкренләп Сакал Шәйхинең идарә итү чорына килеп керде. Аз сүзле, йомшак телле, ак чырайлы, кыска чәчле, сикергәк адымлы физкультура укытучысы күзгә күренеп төсен-битен һәм холкын алыштырды. Ул хәзер озын чәчләрен артка яткызып тарый, атлаганда үкчәләре җирне кадаклый: «Синең тракторыңа нәрәт кая бирелгән иде?» — дип әйтеп бетергәнче җөмләне җиде җирдән бүлеп сүгенү сүзе кыстыра һәм Таҗи заманында үзен техниканың хуҗасы итеп тойган шофер-тракторчылар Сакал Шәйхидән курка торганнар иде. Идарә утырышында аңа ошамаган сүз башланса, чыгыш ясаучыны шундук эт итеп сүгеп ташлар. Боерык кәгазе күтәреп килгән мал сораучыларны кабул итү сәгатьләре язылган такта кадакланган ябык ишектә туктатыр. Кеше белән сөйләшкәндә көпә-көндез «киек каз юлына» текәлер. Күзләре җетеләнде, йодрыклары төйнәлде, ак йөзе кызарды.

Бүгенгесе һәм бөтенләй ерак киләчәге гел шушы Сакал Шәйхи белән бәйле булачагын аңламый иде әле Фазыл.

Чишмә буена төшсә дә, кибеткә керсә дә, көтү куаларга чыкса да, халык көн саен берәр хәбәр алып кайта хәзер...

«Сабантуй аланындагы тимерче алачыгын яңа планга күчергәннәр».

«Ындыр табагы каршына яңа гараж корганнар, Габдулла мулла ишегалдындагы машиналарны шунда тезәләр, ди».

«Правлениедән бушаган өйне медпункт итәләр».

«Колхоз эшен сөймәгән шабашникларны җыеп алганнар».

Кышкы каникулдан соң һәр укучыга егерме биш кило көл һәм ун кило кош тизәге алып килергә йөкләмә бирелде. Раштуа суыкларында убыр урынына утын ашаган мичләр бушады, тавык куначалары җиңеләйде. Динә кебек өчәр бала укыткан гаиләләр ятимә карчыкларның мичен һәм кетәклеген чистартты. Әгәр мәктәп ишегалдына куелган трактор чанасы чүмәкәйләп тулмаса, мәктәп директоры Мөлековны идарәгә чакырталар. Һәм ул, йөгерү буенча ГТО нормасын үти алмаган пионер кебек, башын аска иеп, кичәге физкультура укытучысы каршында шелтә тыңлый.

Язга чыккач, балалар тимер-томыр җыярга кереште. Чөнки, яңа комбайн алып кайтыр өчен, дәүләткә шул комбайн авырлыгында металл ватыгы тапшырырга кирәк иде.

Җәйгә чыккач, каникуллар ике атнага кыскарды. Фазылларны мәҗбүриләп, авыл эшенә өйрәтеп үстерәбез дип, колхозның Мишә буенда яңа гына ачылган хезмәт лагерына алдылар. Суган чүбе утау, кәбестә басуына су сибү, кишер сирәкләү кебек «җәмәгать эшләре» пионерларның тантаналы вәгъдәсенә дә теркәлгән иде хәтта.

Икенче сайлауда Юаш Нотфулла Сакал Шәйхи урынына мәктәп директоры Мөлековны куячак икән, дип шым таралды. Ошбу хәбәрне Шәйхи Сәрвиназдан ишетте. Башкалар килеп әйтсә, Таҗиныкылар тараткан коткы дип кенә кабул итәр иде. Ләкин Сәрвиназ — җаны-тәне белән яңа рәиснеке. Казанга кияүгә чыгып кергәч, бер бала күтәреп кайткан тол, әмма яшь ханымның яңадан кибет үлчәве артына барып басарга теләге юк иде. Шәйхи аны сөт заводы директоры итте. Тәнендә гыйшкы, җанында уты булган хатын мондый игелекле кешегә матурлыгын да, яшь гомерен дә кызганмас. Кирәксә, иман нурын да корбан итәр, хатыныннан аермас...

Җылы куенга пышылдау булып килеп ирешкән ошбу хәбәрнең дөреслеген Шәйхи Юаш Нотфулланың үзеннән әйттерергә теләде. Һәм кичкырын аны идарәгә чакыртып «дежурный»ны җибәрде. Айлык акчасы һәм дәрәҗәсе белән контор каравылчысыннан өстенрәк саналган Чулак Газизәнең чакыруы теге-бу оешмалардан килгән повесткалардан көчлерәк санала. Бусагада Газизәне күргәч, агач караватка кырын яткан Нәфисәнең капылт торуыннан куенында ими капкан җиденче кызы шуып төшә язды...

«Йә Хода, тагын нинди генә казаларга барып тыгылды икән инде Нотфулласы... Районга чакырулары, әллә силсәвиткә генәме?»

Сугыш елларыннан бирле дежурда йөргән Газизә кемнең нинди хәбәр көткәнен белә, шуңа күрә түргә узмый, урындык сорамый, йә язу тоттыра, йә язып китерергә тиешлене телдән генә җиткерә:

— Нотфулланы Шәйхи чакыра. Хәзер үк!

— Көтүдән кайткач та әйтермен, барыр. Ниме соң, Газизә апай, председатель янында район кешеләре юкмы?

— Юк. Үзе генә. Ике килеп чакырырлык итмә, яме, Нәфисә, Шәйхи көтеп утырам, диде.

Нәфисәнең эченә җылы керде. Күкрәкчәсен каплап, кызын ике мендәр арасына салды — тәгәрәп төшмәсен диптер инде.

— Нотфулла көтү чираты буенча ашап кайткач, кичен Казанга аш та салмадым. Самавырны гына көйрәтеп җибәримме суң, Газизә апай?

— Юк, юк, Нәфисә, өй саен чәй эчеп йөри башласам, минем эшне кем эшләр?!

— Фәризәнең мунчасы кызу калган. Олы кызларым юынырга киткәннәрие. Көтүче хатыны кич бизәнә, ди. Кызларым әйләнеп кайткач, мин дә чайканып чыгармын дигәнием. Ярар инде алайса, Нотфулланы көтәрмен... Малайлар киногa киттеләр, ахрысы...

Чулак Газизә, алып килгән хәбәреннән үзе дә курыккандай, капылт чыгып китте. Нәфисә, Казан төбеннән аш-су соса-соса кырыйлары кайралып ашалган ак чүмечен тотып, салкын самавыр янында басып калды.

## Син кем дә – мин кем?

Сакал Шәйхи чакыртты дигәнгә бик исе китмәде әле Нотфулланың. Юл төсенә кергән чыбыркысын дүрт бөжралап өйалдындагы чөйгә элгәндә: «Эткә шулпа бир әле, көтүдә көне буе ашамады. Малайлар кайда?.. Кызлар тагын качтымы?» — дип, ашыкмыйча гына өйдәге хәлләрне сорашты. Көне буе кояш астында торгач, тавыклар башын тыкмасын дип, иске куна тактасы капланган ләгәндәге җылы суда быкырдап бит-кулын юды.

— Алып чык яшел күлмәкне, чалбары белән, — диде ул, мәйданга кия торганнарын соратып, — эш буенча чакыртса кирәк. Зампред итәм, дигән сүзе барые.

— И Нотфулла, шашма инде! Ниткән зампред ди ул! Писерме, нәчәлник малаемы син, укымышың бармы?

— Кичке мәктәпне бетерермен дә дәлше китәрмен. Укырга дигәндә, миңа куш. Гомер буе чыбыркы сөйрәп йөрергә Низаммы әллә мин?

— Укырсың әнә, — диде Нәфисә, бит алмасындагы шәфәкъ нурын куертып, — сигезенчегә узганмын әле менә.

— Вәт, әнәңне... Итит-митит! Бала имезгән килеш ниткән узу ди ул тагы?

— Суң нишләтим инде, миннән торамы? Ходай кушкач...

— Ярар, — диде Нотфулла, бәхәсләшерлек вакыты юклыкка ишарәләп кул селтәгәч, — Герой ана исемен тикмәгә генә бирмәгәннәрдер, организмыңда дуңгыз каны бардыр синең...

Үзе сайлаган рәиснең иң беренче соравы ук гарьләндерде Нотфулланы. Сабантуйга йөгергән малайшалай шикелле, бәйрәмчә киенеп, конторга ашкынганы өчен үз-үзен битәрләде ул.

— Халык дөресен сөйлиме синең хакта?! — дип башлады Сакал Шәйхи. Аның йөзендә елмаю, күзләрендә хәйләкәрлек чалымнары калмаган. Ачудан нуры сүнгән, кашлары тырпайган.

— Белмим, дежурный Газизәң нинди гайбәтләр җыеп кайткандыр?

— Чулак Газизә монда ни причем. Әле генә урта звено җитәкчеләре белән киңәшмә үткәрдем. Гөж киләләр. Сүз куешкандай барысы да бер балык башын чәйниләр. Син Мөлековны идарәгә баш итеп куярга йөрисең икән.

Шәйхи әңгәмәдәшнең ялт кына акланырга тотынмаслыгын яхшы белә. Җавап көткән арада урнашкан тынлыкны артык күтәрә алмады, киңәшмәдән җыелып калган исне җилләтер өчен дүрт тәрәзәнең дә өлгеләрен ачты.

— Дөресме шул? — диде Шәйхи, җавапны ашыктырырга теләп.

— Дөп-дөрес.

— Күңел өчен генә булса да хет ялганлар идең.

— Дөп-дөрес. Допрос алуың ошамый. Шуңа әйтерем кыска. Элегрәк син сүзне сургучлыны ачып башлый идең. Саранлашасың хәзер. Түрә булуың җитте. Колхоз рәисенең кәнәфие ике сайлау арасына гына түзә, әрләп кал.

— Син... — Шәйхинең авыз тутырып сүгенергә исәбе бар иде, мәктәп ягындагы тәрәзәнең ачык икәнлеген абайлап, тыелып калды... — син бит минем көрәштәш кешем.

— Ә урта звенонда Таҗи кешеләре. Аларны тарантаслы атка Таҗи утыртты. Димәк, кәнәфиең тирәли дошман тулы.

— Бөтенесен кырып-себереп алыштырам, иртәгә үк.

— Бик мөмкин. Ну мине алыштыра алмыйсың. Авылда көтүче табуы кыен хәзер. Рәхмәт үзеңә — уртага кертмәгәнең өчен рәхмәт.

Нотфулланың «рәхмәтеннән» Сакал Шәйхи, сөрхәнтәй кәҗә куып эченә кату чыккан көтүче кебек, хәрәкәтсез калды. Нидер исенә төштеме, аяк өсте килеш капылт кына берәр яңа план корып өлгердеме — аңламассың.

— Нәкъ менә шуның өчен чакырткан идем мин сине бүген. Дәүләт заданиеләрен үтәве кыен. Ит, сөт, йомыркага план арта, ә хуҗалыклардан җыю кимегәннән-кими. Өй борынча йомырка җыеп йөргәнче, зурдан кубып тавык фермасы ачарга булдык.

— Ну, миңа көтү чираты белән өй саен тавык җыярга кушасыңмы?

— Казан инкубаторыннан ике мең чеби кайтарырга сөйләшенгән. Иртәгәдән Сыер күленә барасың. Андагы ферманы бушатасың. Малларны пилорам каршындагы яңа коровникка күчерәбез.

— Сыерларны ияләшкән җирдән күчереп йөрткәнче, яңа коровникны гына тавыклар фермасы итәргәдер, бәлки.

— Киңәшмәдә андый сүз булды. Мин каршы. Беренчедән, Сыер күле ерак, яңгырлы-буранлы көннәрдә савымчыларны техника белән озатып йөрисе. Икенчедән, тавык фермасы авыл уртасында калса — исенә чыдап булмас, диделәр... — Һәм Шәйхи яшел сукно тарттырылган өстәлнең биек тартмасына тыгылды. — Никтер рәхмәтең йөзеңә чыкмады. Ризалашмасаң, әнә куян фермасын ал. Сукыр Кәримне тавыкларга күчерәбез.

— Дүрт аяклы хайваннардан болай да гарык. Ике аяклылары ничегрәк микән?

— Сайлаулар җиткәч күрербез инде нәтиҗәсен.

— Тавык халкы миңгерәү, анысын беләбез. Ну ашаткан кешесен таный, кулга бик тиз ияләшә. — Нотфулла, тамак төбенә кылчык утырган кешедәй, «хыр-хыр-хыр...» дип куйды. Бу аның, гадәттәгечә, көләсе килмәгәндә, әмма көләргә кирәк чакта үзенчә пырхылдавы иде.

Өстәл тартмасыннан кулына ияреп чыккан савыт мәктәпнең химия кабинетыннан соратып алынган бүксәле колба иде. Шәйхи, сургучлы шешәне мәктәп савытына бушатып, каеш бөке белән томалап куярга өйрәнде.

— Мәктәбем истәлеге, — диде ул мактанып, һәм өстәлдәге чем-кара телефонның трубкасын алды: «Алло, почта, молзаводны тоташтыр... Алло, Сәрвиназ, кабымлык алып кил әле. Ашханәдә күренеп йөри алмыйм, икәү без монда...»

Сәрвиназның ашханәгә кереп, Шәйхи өчен ризык алып килүе яңалык түгел. Нотфулланы уйландырганы башка нәрсә: «Физкультура укытучысы чагында пыяла колба белән мәктәптә нишләде икән бу?..»

Өеннән чыгып киткәненә өч сәгать тә үтмәде, көтүче Нотфулла җиде бала анасы Нәфисә янына мөдир булып кайтып керде. Өйдәгеләргә хәлне аңлатып биргәч тә, бәйрәм кәчтүнен салмады ул, чыбыркыны уртанчы малаена тоттырды. Һавадагы тавыкларга ышанып, гаиләне ашсыз калдыру килешмәс. Бер чыбыркы ун кешенең тамагын туйдыра алганда, мөдирлек вәсвәсәсенең заялыгы сизелмәс, ашказаны зыян күрмәс. Әгәренки тавык фермасын аякка бастырып булса, ул чагында чыбыркыга калган малае көзгә укуын дәвам итәр. Нәфисә белән олы улына кетәклек тирәсендә эш табылыр.

Сыер күле авылдан читтә, Казан юлына борылган калын комлыкта. Киртә белән әйләндереп алынган утарның бер ягы нарат урманына терәлгән, икенче ягында кукуруз басуы. Читтән килгән кешегә, бәлки, сәер тоелыр, әмма, Питрәч юлына чыкканда, югары урман эчендәге ком өстендә тагын бер күл кала — Печмән күле. Бу ике күлне ничек ком йотмыйдыр, анысы төбәкнең табышмагы. Күз-колактан читтә булгач, авылның карт-корысы бу ике күл хакында төрле куркыныч имеш-мимешләр сөйли. Ләкин бишек чыбылдыгыннан телеп алынган марля тотып килгәч, кәрәкәле җылы күлдә «Төпсез. Упкынлы. Аждаһа төшкән. Су анасы бар» дигән янаулар онытыла.

Күрше Күн авылыннан яңа укытучы килгән. Ул, өй борынча йөреп, класска язып китте. Фазыл белән Мәгъсүм шул сөенечтән Сыер күленә җыена башлады. Нәфисәнең эремчек саркытырга тота торган марлясын йомарлап чалбар кесәсенә тыккач, повидло чиләген эләктереп, тере кәрәкәләр алып кайтырга дип йөгерделәр.

Сыерлар җәйләүгә күчкәч, утар тирәсе кипкән. Ферма эченә ат белән ком ташыйлар. Ике балта остасы шифер түбә астындагы бәпкәлекләргә нарат сиртмәләрдән тезмә җәя. Ике абзый сыерлардан бушаган араталарга баскыч-баскыч итеп куначалар тезә. Озын-озын көрпә тагараклары ясар өчен шомартылган тар тактлалар китертелгән. Мәгъсүмнең этисе тавык фермасы мөдире түгел, күбрәк һаман шул көтүчегә охшаган әле, тегене куа, моны ашыктыра, анысына сүгенә — чыбыркысы гына юк.

Малайлар кайнар кул астына килеп керде.

— Безне бүген мәктәптән килеп яңа укытучы язып алды, — дип башланган җөмләсе белән мактанып өлгермәде Мәгъсүм, аны этисе бүлдерде:

— Әйбәт булган, менә зур үскәнсез. Барыгыз әле, ферма эчендәге комны таратыгыз. Таптый-таптый җәегез, чебиләр абынырлык булмасын. Кесәгездәге марляны чиләккә салып, әнә кадакка элеп торыгыз. Кояш күтәрелсен, күл җылынсын әле бераз, кәрәкәләрегез беркая да качмас!

## Тавык арифметикасы

Бөркәүле машинага төяп кырык әрҗә чеби алып кайттылар. Юаш Нотфулланың бөтен гаиләсе, хәтта Актырнак та шунда иде. Өйдә кош-корт үстереп сиксән яшьлек каенана белән карт киленгә әверелгән Нәфисә ике мең чебине аякка бастырганчы күпме чиләнәсе барын белә. Монда чеби анасының канат астын алыштырырлык кул җылысы кирәк. Ә бу инде бары тик хатын-кыз эше генә. Нәфисә Динәне дәштерде. Чебиләрне арата саен тигезләп таратырга, асылмалы лампочка нурына җыелсыннар өчен, җим сибәргә, инкубатордан җибәрелгән калай ялгашларга чыпчык тезеннән генә су салырга, юлдан ук хәлсезләнеп кайтканнарына авыздан сөт эчерергә кирәк иде. Соңгысына Фазыл белән Мәгъсүм дә өйрәнеп китте, дерелдәп торган кош баласы иреннәреңне кытыклап сөт эчкәндә күңел сөенә, тузганак чаклы гына җан иясе синең якын дустыңа әверелә, сөт эчкәч, уч төбең белән аның йөрәк тибешен тоясың һәм кошчык «Мине иптәшләрем арасына җибәр!» дигәндәй тыпырчына башлый.

Шул көннән башлап Актырнакны да көтүгә чыгармадылар, дилбегә озынлыгы чылбыр белән капка төбенә кадаклап куйдылар. Җәй җитте исә, көтү куып, кышын урамда адәм типкесендә йөреп әрсезләнгән эткә картайган көнендә тыныч эш таптылар. Дөрес, иртә-кич, авыл очында чыбыркы шартлатучыларга сискәнеп, колакларын торгыза ул, йоклап калган эшем кешеседәй киртә капкага ыргыла, ләкин аның сөенече муен каешын тартып торган чылбыр озынлыгы гына. Ул яңадан кадакланган урынына килеп ята.

Чебиләр үскән арада, ферма әйләнәсен тимерчыбыктан үрелгән челтәр белән урап куйдылар. Нәфисә белән Динә ашату белән шөгыльләнсә, Нотфулла җәй буе печән чабып ферма тезмәсенә җәйде, теге кырык әрҗәне шунда менгезеп, оялар ясады, түбә эченә сөяп юкә себеркеләре киптерде. Һәм чебиләрнең тизрәк үскәнен көтте. Сакал Шәйхи дә көтте, ашыктырды һәм ярдәм итте. Сәрвиназга әчегән сөтләрне дуңгыз фермасына җибәрүне тыйды, эремчек ясап көн саен тавыкларга илтергә кушты. Бер ат җигүчене махсус беркетеп, амбардан капчык-капчык бодай ташытты. Таҗи вакытында тугыз центнердан ары уңыш күрсәтмәгән гектарлар бу елны унөч центнер икмәк бирде. Сайлау җыелышында Шәйхигә авыр сүз әйтеп кара хәзер!

Чебешне көз көне саныйлар дигән мәкальне Юаш Нотфулла чыгаргандыр. Җәй башындагы кырык әрҗә чебинең югалганнарын үлгәнгә санап, яшь әтәчләрен иткә тапшыргач, тезмәдәге ояларга керердәй бер мең чамасы тавык үсте. Чамасы дип әйтми хәл юк, Питрәчнең заготконтора вәкиле белән Шәйхинең бухгалтеры килеп, яшь тавыкларның баш санын алмакчылар иде. Районда моңарчы тавык үрчетү тәҗрибәсе булмагач, санау эшен беренче тапкыр нидән башларга микән, дип, вәкил теш щеткасы сыман тырпайган мыегын кашып шактый торды. Иртәчәрәк килеп, куначада төшкәнче санап чыкмакчылар иде. Ләкин, ферма эченә кеше кергәч, ашарга китерү дип аңладылармы, очып-очып килеп вәкил белән бухгалтерны сырып алдылар, аяк астындагылары кулга сикерә, өсте-өстенә өелә. Атласаң, таптарга кирәк, тик кенә басып торсаң, чукып үтерәләр... Китте ыгы-зыгы, арата кырмыска оясына әверелде. Санарга тиешле кешеләр, аякларын комлы боламыктан шудырып-шудырып атлап, көчкә чыгып котылдылар... Ике канатлы капканы аз гына ачып, иртәнге җимгә чыгасы «титибаш»ларны урам ягыннан санап торырга уйладылар. Тагын унга хәтле җиттеләр микән... Начальство әйткәч, ярыктан берәм-берәм генә чыгасы урынга, бу миңгерәүләр, урамдагы көрпә тагаракларында бодай барлыгын сизеп, давыл булып ябырылды. Капканың ике канаты ике якка каерылды. Тавык давылы куллары белән битләрен каплап җиргә чүгәләгән бухгалтер белән вәкил өстеннән очты.

Заготконтора вәкилен белмим, каян китереп куйганнардыр, әмма Шәйхинең бухгалтеры авыл мужигы иде: «Кояш баегач, тавык күзле җан ияләре берәм-берәм оясына кайта, санап өлгерербез», — диде. Тавык та кош шул. Кош — димәк, романтик, хыялый, моңлы... Әгәр кеше үзенә ризык итәр өчен аларны борынгыдан кулга ияләштермәгән булса, әлеге мең тавык та, бәлки, авылга терәлеп үскән куе урманда иректә яшәр иде. Җәйге аяз кичләрдә алар, куначаны онытып, Сыер күле тирәсендә чебен-черки, чикерткә тоталар, койма читенә ияләшкән кәлтә еланнарны куалар, борынгыча бер калыпка салып, сузып-сузып җырлыйлар... Син аларның фермага борылып йокларга кайтырга теләгәннәрен көтеп кара... Төркем-төркем булып капкадан керәләр дә: «И-и-и, ашыгыбрак кайтканбыз, куначада беркем дә юк әле...» — дип, кире чыгып качалар. Кушу-алу уены ясап бухгалтер белән вәкилнең җеннәре котыра, күчтәнәчкә дигән йомыркаларны да онытып, караңгыга калганчы авылга ашыгалар.

Тавык исәбен алу район күләмендәге хафага әвереләсе иде, котылу чарасын сигез яшьлек Фазыл әйтеп бирде:

— Аларны буярга кирәк...

— Вәйт, малай актыгы, — дип бот чабып куйды Нотфулла, — атаң мәрхүм башлары бар үзендә...

Күршенекеләр белән буталмасын өчен, Динә ел саен тавыкларның сыртына язу карасы сылап чыга иде. Кош-корт яңгыр астына чыкмый, тамгалары кышка чаклы саклана, Фазыл әнә шуны исенә төшерде.

Бер савыт түбә буявын ике чиләккә салып, вәкил белән бухгалтерга тоттырдылар. Көрпә тагарагына тезелгән кошларның сыртына пумала тидереп бер, ике, дип саныйлар да ун булгач, исәп дәфтәренә тер-

киләр, ашаган чакта тавыкны буяу түгел, койрыгын киссәң дә исе китми. Ярты көн тырыша торгач, ап-ак кошларның күбесе кызыл кикрикле, яшел сыртлы булды. Ә сүз тыңламас-тиктормасларын Фазыл белән Мәгъсүм пумала күтәреп куып йөрделәр. Ну тавык халкын беләсез инде, бер үҗәтләнсә — малайлар түгел, этәч тә куып тота алмый. Тамгасызларны аерым санадылар...

Фазыл уку башланган көннәрне һич онытмас. Чөнки сентябрьдә ферма тавыклары йомырка сала башлады. Дүрт дәрес бетүгә, малайлар өйгә кереп сумкаларын ыргыталар да Сыер күленә йөгерәләр. Өйләдән соң Динә белән Нәфисә кырык эрҗәдән заготконтора өчен план җыя башлый. Ләкин иң кызыгы Фазыл белән Мәгъсүмгә... Тезмәнең чит-читенә сөяп куйган юкә себеркеләр артында, тавыклар үзләре урлап ясаган ояларда, бишәр-алтышар йомырка балкып ята. Малайларның сөенүен күрсәң — гүя мажаралар арасыннан хәзинә эзлиләр.

— Әни, монда җидәү! Әни, менә тагын... Әни!

Алты чиләк йомырканы колхоз складына тапшырып, боерык кәгазен кулга алгач, көнлек эш бетә. Чылбырлы Актырнакка кыр каравылчысы иптәшкә кала.

Ике күрше гаилә арасында тормыш җанланып, балалары көрәеп, тавык карау сөендерә башлаган иде. Колхоз эше дә гөрли, өйдәге мәшәкатьләргә дә кул җитә. Идарә утырышларына килгәч, Нотфулланы аягүрә бастырып мактыйлар. Балалар тук, өсләре бөтен, шөкрана кылып яшисе иде кана.

## Яшәсен!..

Нотфулланың кичке мәктәпкә укырга килүен ишеткәч, Шәйхи тагын мәктәп директоры Марат Мөлековны идарәгә чакыртты. Идарә конторы зиярат коймасына терәп салынган өч буралы йортка яңа гына күчкән иде. Дежурный Газизә, бисмилласын кабатлап: «Марат хәзер килә!» — дип әйтеп өлгермәде, Мөлеков ишектән килеп тә керде.

— Син нәрсә, кичке мәктәп белән ашыгасың? Колхозда көзге эшләр төгәлләнмәгән ич әле. Кырдан салам тарттырасы бар, туңга сөрүләр бетмәгән, — диде Шәйхи, Мөлековны каршы алышка, аннан соң кул биреп күрешергә булды. — Нихәл, пнимаете так.

Директор: «Әйбәт әле...» — дияргә дә онытты.

— Ел саен октябрьнең бересеннән эшли башлый инде ул.

— Күп килгәннәрме?

— Ну, җәмгысы алтмышка якын.

— Җыен икеле-берле, күчми калган тинтәкбашлар инде. Пнимаете так... Бүкәнне укыттың ни дә, укытмадың ни аны.

— Ул бүкәннәрне читтән җыймадык инде, үзебезнең колхозныкылар. Гомуми белем бирү мәҗбүриләнде. Күбесе көндезге укуны гаилә хәленнән чыгып ташлаган. Кичкегә ялынып дигәндәй чакырабыз.

— Ә Нотфулла, пнимаете так, нишләп йөри? Аңа кырык яшь бит инде.

— Кичке мәктәп кешенең яшен сорамый, пенсионерларга да ярый. Ә Нотфуллага килсәк — ул, класска керү белән: «Мин Таҗи өчен укыйм!» — диде.

— Бар! — диде рәис, мәктәп директорын куып чыгаргандай кул селтәп. Ул, Мөлековның җавапларыннан бигрәк, аның «Шәйхетдин Исламович!» дип мөрәҗәгать итмәвенә хурланды.

Уйлансаң уйланырлык нәрсә Шәйхи өчен — Юаш кушаматын тикмәгә генә такмаганнар Нотфуллага. Халык гел киресен әйтеп үрти. Югары очта ярты урамлы нәсел Чегән кушаматы йөртә — ни өчен диген — сап-сары чәчле, шадра йөзле булган өчен. Армиягә алынмасаң — син Әписәр, урамда җырлап йөрсәң — Карга. Шәйхинең үзенең дә нәселдән килгән кушаматы — Сакал, ата-бабалары ягыннан кайсын гына алма — мыек чыга, ә сакаллары үсми. Юаш Нотфулланың да ишеккә сыймастай юанайганын көтмәскә... Башы йомры, теле шома, үзенә дигәндә йөгерергә иренми. Урта мәктәпне дә тәмамлар, авыл хуҗалыгы техникумына да барып җитәр, кичкегә йөрергә иренмәгәнне, читтән торып укуга чыдар. Белеме арткан саен, теле үсәр!..

Колхоз отчет-сайлау җыелышына әзерләнде. Газизә, өйдән өйгә кереп, халык исеменнән әйтеп йөрде. «Кеше мактый, — дип башланган сүзе шигырь кебек ятланган. — Аллага шөкер, бер ел эчендә яңа правление салдырды, искесен медпункт итеп калдыра. Тавык фермасын күр — йомырка сату планын үти башладылар. Тугыз центнердан ары уңыш бирмәгән кырлардан, гомердә булмаганны, унөч центнер икмәк җыеп алдык, Ходайның рәхмәте яусын. Таҗидан колхозыбыз егылып калганые, Шәйхи торгызды. Үткән көннәр кире кайта күрмәсен инде...»

Элеккеге рәисне оныттырырга теләде Шәйхи. Җәй уртасында укытучыларга утын китертте. Сугыш елларында тол калган ялгызак әбиләр өчен мәчет янына картлар йорты салдырды. Көл, тимер-томыр җыюда алга чыккан пионерларны, туфраксадагы Ленин эзләрен күрергә, Кокушкино авылындагы музей-йортка җибәрде. Укуларын өзеп, бәрәңге басуында ун көн буе чиләнгән балаларга өч кило шикәр алырлык акча өләште. Уңыш амбарга кереп беткәнне дә көтмичә, бер хезмәт көненә алты йөз илле граммнан икмәк бүлеп бирде. Нотфулла белән Нәфисә янында тавык караучы булып йөргән өчен Динәләр капка төбенә егерме пот ашлык китереп аудардылар... Мөлековка әйтеп тормыйча гына сельпога

акча күчерде һәм ятим балаларны идарәгә чакыртып, бушлай кием-салым белән сөендерде. Фазылга быел сыек күрән төстәге бушлат эләкте. Киләсе елга кирза итек бирәчәкләр, ди. Бирмәделәр генә...

Озак еллар эшләгән Таҗиның әле һаман райкомда үз кешеләре бар, ул Шәйхинең беренче хисап җыелышын Октябрь бәйрәме алдыннан үткәрергә диган карар чыгарттырды. Башка хуҗалык җитәкчеләре чатыр чабып бәйрәмгә әзерләнгәндә, Шәйхи, мәшәкать өстәп, хисап доклады язып утырырга тиеш. Җыелышны күчерттерсәң — районга каршы килү кебегрәк, әгәр инде совет халкының иң зур бәйрәмен тиешенчә үткәрә алмасаң — персональ эшең обком утырышына барып җитәчәк. Һәр ике очракта да Шәйхи өчен хурлык.

Вакыт әрәм итмәс өчен, ул райком карарының хат белән килеп җиткәнен көтеп тормады, телефоннан белешкәч, шул минутта ук мәктәп директоры Мөлеков янына керде.

Озын тәнәфес вакыты иде. Ике катлы агач мәктәп штормга эләккән корабны хәтерләтә, балалар дулкын булып класстан класска күчәнә, үзләренчә кабинет алыштыра. Спортзалда октябрятлар вожатыйны уртага алган, алар өчен җыр укытучысы мандолина уйнап тора. Замазка сыланган тәрәзәләрнең берсен ачып, мәктәп бакчасына төшкән уенсыз малайлар миләш сыдыра. Аскы коридор белән өскесе бергә кушылгандай йөгереш бара. «Исәнмесез, абый?» дип, күрешергә тиешле узган елгы малайлар, узган елгы физкультура укытучысын танымагандай, бәрелеп-бәрелеп китәләр.

Мәктәптә директорның аерым кабинеты юк, Мөлеков укытучылар бүлмәсенең түренә бер өстәл куеп кына утыра. «Бу яңа рәис тагын нинди эш кушар икән безгә?» дигәндәй, элеккеге коллегалар шым булды. Хәлләрен сораштырган атлы кыланып, аларның дәрескә кереп киткәннәрен көтәргә туры килде. Мөлеков үзе тарихтан укыта, ләкин директорның дәрескә соңга калып керүе укучылар өчен сөенеч кенә иде.

— Исәнмесез, Марат Әбдүлрәсүлевич? — дип, элеккегечә ягымлы итеп эндәште ул, хәтта икәүдән-икәү генә калган уңайдан кочаклашып та күреште.

— Әллә спортзалыңны сагындыңмы? — диде директор, Сакал Шәйхинең кинәт йомшарып сөйләшүенә аптырап.

— Кире кайтуымны теләмисездер ич?

— Дөресен генә әйткәндә — теләмим! Әгәр укытучы мәктәпне бер ташлап китә алган икән, димәк, ул педагог буларак ышанычлы кеше түгел.

— Ләкин сезнең дә авылда өй салырга уегыз юк, димәк, китәргә телисез?

Мөлеков стенадагы Ленин портретына карап җавап эзләде.

— Әгәр партия кушса — бик мөмкин! Мине педагогия институтына өлкән укытучы итеп гел чакыралар.

— Һәм сез шундый перспективадан баш тартасызмы?

— Шәйхи, энем, «сез» дип сөйләшүеңнең тел төбен аңламыйм. Гадәттә, мин үзем яңа түрәләргә һәм икейөзле кешеләргә генә «сез» димен. Бу очракта...

— Ярар инде, Марат абый, үпкәләмә! Минем киредән мәктәпкә кайтуымны теләмисең икән — ярдәм ит. Пнимаете так...

— Менә монысы — үзебезчә, ичмасам! Балалар ярдәме кирәкме? Бушлай хезмәт, ягъни мәсәлән...

— Балалар укысын. Карлар яугач, көл җыярлар... Син миңа отчет җыелышы өчен чыгыш язып бир.

— Гыйльми конференциягә фәнни доклад язып ятам. Аспирантураны бетергәч тыныч кына эшләргә ирек бирмиләр икән... Ә синең читтән торып булса да укырга исәбең юкмы?

— Колхоз җитәкчесе читтән торып укый алмый.

— Ничек инде? — дип аптырап калды Мөлеков.

— Язгы сессияне тапшырырга ирек бирмиләр. Язгы чәчү вакытында, бөтен эшеңне ташлап, бер айга ничек китәсең ди? — Шәйхи, сүзнең артык читкә тайпылуын өнәмичә, тагын туп-туры сөйләмгә күчте: — Докладыңны тарих китабы кебек итеп яз, яме! Озын һәм минем турыда булсын...

Мөлековның ризалашуы Шәйхинең кәефен күтәрде... Карасана — моның күзе бөтенләй кысык түгел икән. Себердә шуңа күрә яши алмагандыр ул. Ялыныч белән килгән кешегә ярдәмчел үзе, андыйларны халык ярата һәм иярә... Юк шул, Марат Әбдрәсүлевич, отчет җыелышы үткәнче, халык мине генә яратырга тиеш. Һәм син, доклад язарга ризалашып, үзеңне күләгәдә калдырдың...

Ул көнне клубның кечке уеннар үткәрелә торган ягында алты үлчәүле сәүдә оештырылды. Райпо сатучылары билле прәнник, ысланган балык, ширбәт эчле кәгазьсез конфет, хәлвә, уналты тәңкәлек такта чәй, клиндер, «таракан» җимеше, ат һәм кит итеннән томаланган консервалар алып килде. Шунда ук ике чиләкле самавыр җырлап утыра.

Хисап җыелышы алдынгыларга тантаналы төстә бүләкләр өләшүдән башланып китте. Барысын да Шәйхи шәхсән үзе тапшырды, партоешма секретаре исемлекне укып чакыра торды. Бик үк алдынгы булып җитмәгәннәр өчен әз-мәз акчалата премия куелды. Ведомость белән акча кассирша кулында, җыелыш беткәч, клуб мөдире бүлмәсендә өләшенәчәк...

Колхозчылар алдында хисап тотар минут җиткәч, Шәйхи бер кулына тарих китабы калынлыгы докладны күтәрде, ә икенче кулына бер дәфтәр бите тотты.

— Иптәшләр, ел буена бергәләшеп ниләр эшләгәнебез турында ишетәсегез килсә, менә шушы докладны укып чыгам. Әгәр инде, пнимаете так, киләчәккә карата планнарымны белергә теләсәгез, менә бу кәгазь битендәге җөмләләрне санап чыгам.

«Доклад кирәкми, сүздән туйган, вәгъдәләреңне әйт!» — дип, премия алырга ашыккан кешеләрнең фикерләре яңгырагач, тавышка куясы гына калды.

...Авылга тагын ике кибет салдырабыз...

...Тау башында төзелеп беткән яңа правление бинасы якындагы бишьеллыкта егерме алты урынлы участок больницасы булып калачак...

...Вак буалар җәй уртасында кибә, инешнең Казан юлы өстендә ике йөз мең кубометрлы сусаклагычы корырга проект төзеттек...

...Салам түбәле иске өйләрне бетерү буенча идарә карары бар. Кулыннан килгәннәргә техника белән ярдәм итәрбез, хәленнән килмәгәннәргә колхоз хисабына ун еллык ссуда бүлеп бирербез...

...Киләсе елга уңыш күләмен унҗиде центнерга җиткерергә!..

Йөкләмәләрнең ахыры күтәренке сүзләр белән бетте:

«Яшәсен Бөек Октябрь Социалистик революциясенең 41 еллыгы!»

Көчле алкышлардан соң җылынган куллар Шәйхине егерме җиде елга җитәрлек дәрт белән кабат сайлап куйды...

## Аның исеме «Әй»...

Авыл кышка әзерләнде.

Язгы сулар идән астына төшмәсен өчен, өй тирәли казыла торган ерганакларны тирәнәйтеп, урам ягындагы базларны томалап, абзар коймасы белән кәрниз арасындагы ярыкларга абага тутырып, туфраксаларга балчык өстәп, яңа өйләрдә икенче кат тәрәзәләр куеп, искеләрендә рам араларын сылап, халык үзеннән-үзе әкрен генә кышка кереп бара иде. Өлкәннәрнең төрле ырымнарга карап, гел раштуа суыкларыннан гына торган кырыс кыш вәгъдә итүе елдан-елга кабатланса да, авыл әзерлек чараларын киметми, кар яуганчы ук итекләр бастыра, озын балтырлы йон оеклар бәйли, затлы шәлләр өчен Ырымбур кәҗәләреннән таралган мамык эрли.

Дәресләр беткәч, югары сыйныф укучылары мәктәп лапасында утын яра, балтасыз калганнары, кул алмашып, пүләннәрне әрдәнәгә өя.

Фазыл белән Мәгъсүм мәктәп мичләренә утын кисәрдәй сыйныфка җитмәгәннәр әле. Аларны өйдә көтәләр. Әтиле кешенең малае, укудан кайткач, сыер асты җыештыра, башакка салам турый... Ә Фазыл әнисенә нигез салыша. Әтиләре, сугыштан алып кайткан җәрәхәтләрен төзәтеп бетерә алмыйча, теге дөньяга ашыгып китеп барды. Динә, вакытлычага ярап торыр, дип, келәт бурасыннан күтәрелгән иске өйдә утырып калды. Тавыклар менеп актара торгач, җәй буена чокырланган түбә саламына яңаны өстәмичә кыш чыгарлык түгел. Җитмәсә, өйнең бүрәнәләре куышланып, мүкләре череп беткән, көнгә ике кат мич яксаң да, җылысы тормый. Наратлар ылыс койгач, Динә, балаларын җитәкләп, урманга китә. Урманны тырмалап җыйган ике сарба[1] ыры[2] өйне тышкы яктан киртәләп тореп алырга җитә, тәрәзәләрнең өске өлгесе генә томаланмыйча кала. Өй эче караңгыланса да, җил үтми, җылы югалмый. Бәлки, инде киләсе елларга нигез өеп торасы булмас, Шәйхи салам түбәле өйләрне бетерәбез, дип, җыелыш алдында вәгъдә бирде.

Динә сәнәк белән ыры чөя, Фазыл аны таптап тора. Киртәне үстереп менә торгач, өстәмә «нигез» кәрнизгә килеп терәлә, авыр гәүдәле зурлар өчен бик тә җайсыз саналган әлеге эш Фазыл кебекләргә уенга әверелә.

Бакчаның «плугарь» ягын өяргә дип ыры ташыганда, әллә каян гына Мәгъсүм килеп басты. Аның да Фазыл белән бергә ыры өстендә ауныйсы килә иде. Нотфулла малаеның уйнарга чыгуы иртәрәк тоелды Динәгә.

— Ник эштән качып йөрисең?

— Әти малайларны өйдән куып чыгарды.

— Ачуын китергәнсеңдер әле.

— Җук. Әнине Питрәчкә апкитәргә дип ат җигәләр.

— Ниткән сүз сөйлисең, кичкырын районга чыгалармыни? — диде дә, сәнәгенә элгән ырыны кире куеп, Динә нәрсәнедер исенә төшергәндәй итте һәм Нәфисәләргә йөгерде.

Малайлар үзләре генә калгач кинәнделәр уйнап: чүмәлә өстеннән мәтәлчек атындылар, тәгәрәделәр, күмелделәр. Кыш буе ямь-яшел булып урман төсен саклап торган ылыслар җәй уртасыннан саргаешып коела да урманга түшәлә. Ул өй түренә урман ямен алып кайткан, анда чәер исе, кояш төсе, сары энәләр өеме дисәң дә — кадамый, муен арасына кереп кытыклый, учыңа кыссаң, йомшак үләнгә әверелеп кала. Мәгъсүмнәр ыры ташымый, аларның өе нык.

Динә кергәндә, җигүле ат инде капкадан чыгу уңаена борылган. Арбадагы түшәкнең баш асты турысын күтәртеп куйганнар. Нәфисәне олы кызы белән Нотфулла ике ягыннан култыклап алып чыкты-

лар, ул, юка боз өстен кичкән ихтыярсыз адәм кебек, аяк очларына басып кына атлый — гәүдәсенең авырлыгы үзендә түгел. Күршегә килен булып төшкәннән бирле иң якын дустына әверелгән Динәне күргәч, Нәфисәнең ап-ак чырае бит алмасы турыннан бер мизгелгә кызарып алды. Нотфулла капканы ачкан мәлдә, Динә түшәккә сеңгән Нәфисәнең колагына иелде.

— Кай арада аяктан егылдың соң син? Әле бая гына эштә идек ич!

Нәфисә дәшмәде, аскы иренен тешләп торуыннан шәйләп кенә җан ачысы барлыгын тоеп була иде.

— Егылдың мәллә?

Ниһаять, Динә, эшнең нидә икәнлеген төшенгәндәй, пышылдавын көчәйтте!

— Әллә, Ходаем, кул уйнаттыңмы?! Биш айлык корсаккамы!..

Нәфисә, ике кулы белән йөзен каплап, кинәт елап җибәргәч, күңеленә килгән шик-шөһбәнең чынбарлык икәненә ышанды Динә.

Баскыч төбенең биш басмасында сиксән яшьлек әби канаты астына кереп елап калган дүрт кыз бала, әниләре кием алыштырганда урамга куылган өч малай, иртәнге сәгать икедә ятим каласыларын белмиләр иде әле.

Нотфулланың аты тәүлек буе тугарылмады.

Вазифасы буенча фельдшер-акушерка дип аталса да, авыл врачы әлеге очракта ярдәм итә алмады һәм район больницасына атап язылган юллама чынлыкта исә Нәфисәнең гафу ителмәслек ялгышына хөкем карары иде.

Чана җигәргә иртә, арба җигәргә җайсыз чак. Атны бераз куаласаң, арба, түмгәктән түмгәккә сикереп, Нәфисәнең кан сауган гәүдәсен вата. Район белән авыл арасын сигез чакрымлы урман каплап тора.

Нотфулла соңгы тапкырында шушы юлдан җиде баласын төяп район сабан туена алып барган иде... Кайткан чакта бәйрәмдә уйнап-көлеп, сыйланып алҗыган балалар арба төбендәге чыптага тәгәрәшеп йокыга китте, атны агачка бәйләп, әти белән әнинең җиләк аланына кереп чыкканнарын да сизмәделәр. Нәфисәнең күлмәк итәгенә җиләк сытылып беткән иде, йокы чүлмәкләрен арбадан бушатканда кожан бөркәнеп йөрде ул.

Ә хәзер зәңгәр күлмәге канга батты. Ястык өстендә яткан килеш, күлмәк төсендәге күк йөзендә арбага ияргән сыңар болытка карап бара. Нарат урманы җиләк аланнары белән кирегә йөгерә, Нәфисәдән кача. Батыр ананың ут янып торган бит алмалары сүнгән, күзләре нурсыз, җиде баланың керен юа-юа юылып беткән куллары, тагын да агарып, корсак өстендә кушйозакланып калган.

Мәрхүмәнең ястык өстендәге гәүдәсен капкадан алып кергәндә, икенче көннең кояшы кичке якка авышкан иде инде. Җигүле ат иңләп йөрерлек иркен ишегалды күрше-күлән белән тулды. Кичәгенәк көндез сөенә-сөенә яшәп йөргән Нәфисәнең бүген вафатына ышанмады халык.

Кеше тудыруның бер генә дөрес ысулы бар... Ә җан кыю — миллион төрле...

Адәм баласы туганда ук канга батып туа. Гадәттә, әти кеше аны күрми. Тәненә яра төшсә, ирләр ныграк каушый. Хатын-кыз кан коюдан курыкмый, балигъ булган көннән башлап күнегә ул аңа... Хатын-кыз хирурглар да каты бәгырьлерәк. Операция ясаганда ир-ат хирургка авыруны кызгану хисе комачаулый. Йөкле хатыннар ир-ат гинекологка ныграк ышана... Малайлар үскәндә уенчык машиналары ватыла-җимерелә, ә кыз баланың кеше сурәтендәге курчаклары туза, өзгәләнә, ыргытыла...

Хатын-кыз — тудыручы, ир кеше — кабер казучы...

Нотфулла тавык фермасында бөтен гаиләне туендырырлык эш тапкач, Нәфисә аның нужа камытын җиңеләйтергә теләде, тапканнарын исән-сау үстерсәк, бик җиткән, дип, сигезенче көмәненнән котылырга булды. Күрше-күлән белән киңәшләшеп тормады, кирегә үгетләячәкләрен белә иде. Осталыгы белән тирә-юнь авылларга даны таралган Олы Елга карчыгының да биш айлык йөккә кул күтәрмәслеге билгеле, гөнаһысыннан курыкмаса да, законнан куркыр... Һәм Нәфисә үз җанына үзе кул сузды.

Дустының кырыгын үткәргәнче, тавыклар фермасында Динә берүзе йөреп торды. Колхоздан нәрәт белән көн саен яңа кеше кушалар иде кушуын. Ләкин алар, бер генә көнгә ялланганнарын бик тиз аңлап, артык өшәнмичә булыштылар, төп эш барыбер Динә өстенә өелде.

Мәктәптә укулар тәмамланганнан соң, Мәгъсүм Фазылга иярмәскә тырыша, тавыклар янында кызык тапмый ул хәзер. Буш вакыт барында ике ятим урамның ике ягында аерым-аерым уйнады... Берсенең әтисе юк, икенчесенең — әнисе... Фазыл Мәгъсүмне ничек юатырга кирәклеген белми, менә мин тумышымнан ятим үсәм ич әле, җыламыйм, дип әйткәли иде... Ә Мәгъсүм, аның саен: «Әти кешенең нәрсәгә кирәге бар аның, әни булсыные хәзер!» — дип, капка төбендәге чирәмлектә тәгәри-тәгәри елый... Инде ул турыда сүз чыгармаска тырыша Фазыл.

Балдызлары ягыннан сазамыклары-толлары юк иде Нотфулланың... Өчкә җидене кушсаң, ун була, ике тол кавышса, уң була, дип, Динәнең колагына да пышылдамады түгел... Ләкин күрше хатыны Нәфисәнең үлемендә Нотфулланы гына гаепләде. Һәм аңа булган нәфрәт әнисез калган җиде баланы кызганудан көчлерәк иде.

Җиде кашыкны бер тирәдә тотар өчен, Нәфисәнең сиксән яшьлек каенанасы мәчет урамындагы берәүгә үзе яучы булып китте. Ятимнәрнең иң олысына унбиш яшь, ашарга пешерү, керләр юу дисәң, кулыннан килә. Хуҗалык тирәсендәге эшләргә малайларның көче җитәр иде. Ләкин гаиләне саклар өчен

эти кешегә ул гына җитми шул... Сиксән яшьлек яучыбыз сазамык Айҗамалның ризалыгын алып кайткач, Нотфулланың нурсыз өенә сүрән генә булса да яктылык өстәлде. Үги анага төпчек кыздан гайресе «әни» дип дәшә алмады. Нотфулла күпме үгетләсә, кыйнаса да, балалар өчен аның исеме «Әй!» булып кына калды.

Айҗамалның яңа кушаматы Динәнең дә теленә керде. Тавыклар фермасында Нәфисә урынын хәзер шушы — чегән хатыннарына охшаган «Әй» алыштырды. «Әй, бодай сип әле... Әй, аяк астындагы кош тизәкләрен кырып себер әле», — дип аралаша торгач, яшь хатын үзенең яңа исеменә ияләнде. Тик Динә аңа ияләнә алмады, эшләгәндә җаны өшеде, елаганда бәгыре катты...

## Зимагур баеп кайткан...

1959 елның мартында Сакал Шәйхи районга барып сәер йөкләмә алып кайтты... Чирәм җирләрне үзләштерү программасы биш ел буе дәвам итеп, ниһаять, ахыргы этабына җитте дигәндә, авылның биш гаиләсен Урал ягына җибәрергә кушалар.

Анда, кырык миллион гектар кыргый җирне кулга ияләштердек, дип, күрше Күн авылыннан киткән гаиләләр чирәмлектән качып кайта башлады, ә монда Сакал Шәйхи, Ырымбур далаларына җибәрер өчен, Нотфулланы үгетләп маташа. Юаш ризалашса, калган дүрт гаиләне үгетләү берни тормый.

Нотфулланы ул Айҗамалы белән бергә чакырттырды. Үксез гаиләдә ярты ел яшәп караган үги ананың карт каенана күзеннән, күрше-күлән сүзеннән котылыр өчен, җиде баланы ияртеп, Себергә олагырга риза дигән сүзен ишеткән иде ул.

Шәйхи ашыктырып үгетләмәде. Иркенләп хәл-әхвәл сорашты. Бәйнә-бәйнә зарланасын белеп, гаилә арасындагы борчуларны күбрәк Айҗамалдан сорашты... Тавык фермасы хакында ләм-мим, сүз чыгармады, чөнки Нәфисә исеме телгә керсә, әңгәмә әрләшүгә күчәргә мөмкин иде... Нотфулланың утыны күп икән, ә менә мал-туары бала-чага кулына калгач, печәнне урык-сурык тотканнар — яз чыгарга җитмәс кебек, ди. Балаларын берәм-берәм телгә алганда, Шәйхи кул астындагы зур кәгазьгә теркәп торды... Аннан соң ил күләмендәге мөһим вакыйгаларга күчте, кая карама зур төзелешләр бара, кеше кулы җитми... Иң мөһиме — икмәк. Чирәм җирләрне иген мәйданына әйләндерү Совет халкын икмәкле итәр, егерме беренче елгы ачлык кабатланмас... Кыскасы, гаиләң белән Урал елгасы итәгендәге яңа колхозларга күчеп китсәң — уңарсың... Юл чыгымнарын без түлибез. Гаиләңне өч ел асрарга җитәрлек пособие бирелә — колхоз кассасыннан бүген үк кереп ал. Моннан биш ел элек киткәннәр палаткаларда, вагоннарда яшәгән, ә сезне аерым өйләр көтеп тора. Әзергә — хәзер, рәхәтләнеп эшлә, акча җый, баеп кайт... Унбиш процент «уральский» өстәмә түләүне дә исәплә. Ике малаең тракторда, хатының белән олы кызың — сыер сауса, син терлек симертүдә — учти, анда, пнимаете так, хезмәт көне дигән система юк, айныкын айга акчалата түлиләр...

Сакал Шәйхи кире чигенмәслек итеп байлык юрап сайрады, ә Нотфулла ахыры матур бетәчәк әкият итеп тыңлады да тыңлады, сораулар бирмәде, каршы дәшмәде. Нәфисә кайгысыннан күндәм иде ул...

Башка вакытта сыный карарга җае килмәгәнме, рәис бүлмәсенә кергәч кенә күреп алды Айҗамал, Юаш Нотфулласына кырык яшеннән чал иңгән, чәч түбәсендәге аркылы буразнасы тирәнәеп, аны ике башлы иткән, чигә сакалы төбеннән чыккан буй-буй җыерчыклары иягенә чаклы төшкән, маңгае карт өянке кайрысы шикелле каушакланган, зәңгәр күзләре сурәтендә вак-вак кан тамырлары чатнаган...

Озак уйларлык вакыт калмаган, язгы чәчүләр башланганчы барып урнашырга кирәк иде. Исемлектәге калган дүрт гаиләне Нотфулла үзе үгетләп йөрде. Аның ышандыра белү сәләте хакында артык җәелеп аңлатасы юк.

Шәйхинең партия бурычларына ышыкланып уйланылган мәсләге көн кебек ачык — Ырымбурга җибәреләсе биш гаилә барысы да Таҗины алып ташлауда катнашкан дуслар иде. Ә дуслар белән көрәшү җиңел түгел. Нотфуллаларны ераккарак олактырмыйча, Сакал Шәйхи тынычлап утыра алмас, отчет-сайлау җыелышы саен маҗара көтеп яшәргә тиеш иде.

Язгы ташуга әзерләнеп, Мишә аша салынган агач күперне сүтә башлаганнар иде. Ялланган гаиләләрне, боз йомшарганчы дип, иртән-иртүк трактор чанасына төяделәр. Озата килүчеләр арасында биш гаиләнең нәсел тамыры, участковый Архипов һәм гыйбрәт итеп сөйләгәндә белеп сөйләр өчен дип, аерылышу галәмәтен үз күзләре белән күрергә теләгән авылдашлар бар. Директор Мөлеков китүчеләр арасындагы дистәгә якын мәктәп баласын кызганып торучы укытучылар төркеме арасында иде. Нотфулла белән кочаклашып хушлашкан арада, алар янына Шәйхи килеп басты. Ул гадәттәгечә, райкомга ашыккан кыяфәт чыгарып, тиз генә саубуллашырга теләгән иде. Ләкин Нотфулла аның кулын җибәрмичә кысып тотты, ә үзе Мөлеков белән сөйләште:

— Менә күр, бу Сакалсыз Шәйхине без синең белән йомырка кабыгыннан үзебез чыгардык. Ә ул, кәккүк баласы шикелле төрткәләп, безнең ише кычыткан чыпчыгы чебиләрен туган ояларыннан куып чыгарды. Хәзер чират сиңа инде, Марат Әбдрәсүлевич, Себергә озатырмы, өтөрмәгә утыртырмы?.. Ну мин, баеп кайткач, иманын алам әле моның, балалар гына аякка бассын!..

Һәм Нотфулла, рәистән ычкынган кулына кар йомарлап алып, трактор тәрәзәсенә ыргытты:

— Киттек!

Мәгъсүм, трактор кузгалып киткәч, чанадан сикереп төште. Озатып калучылар арасында елап калган Фазылны кочаклап алды.

— Әти исән булса, без дә сезнең белән китә идек, баеп кайткач, минем ишеләрне танымассың да инде...

Мәгъсүм җавап урынына Фазылны кар өстенә төртеп екты һәм тракторны куып китешли артка борылып кычкырып калды:

— Син мине сагынма! Юкса юлыбыз уңмас!..

## Песиләр дә адаша

Казан — Куйбышев поездына тагыласы өч вагон чирәм җир күтәрергә ялланган гаиләләр өчен махсус эшелон рәвешендә бирелгән булып чыкты. Татарстанның ераграк районнарыннан килүчеләр язгы бураннар аркасында озак җыелды. Ничә көн көтәргә икәнлекне белүче юк. Тупиктагы вагоннарда дүрт көн буе яшәргә туры киләчәк, дип алдан әйтүче табылса, ярты халык түземлеген җуеп, бәлки, кире өйләренә йөгергән булыр иде. Ә болай: «Ташкент поездына кушасылар... Юдинога чаклы мотовоз илтеп куя... Куйбышевка безнең өчен өстәмә поезд бирәләр...» — дия-дия, «вербованный»ларны, тимер юл тирәсеннән җибәрмичә, өстәмә хәбәрләр белән юмалап тоттылар. Нотфулланың колхоз базарына барып май-каймак сатучы авылдашлар белән саубуллашып килергә исәбе бар иде, җибәрмәделәр. Колхоз идарәсендә төзелгән килешү кәгазе партия өлкә комитетыннан беркетелгән уполномоченный кулында иде, аның сүзеннән чыкмадылар.

Нотфулланың тавык фермасына йомырка эчәргә ияләнгән песиләрне капчыкка тутырып адаштырганы бар. Печмән күленә илтте — югалмадылар, капчыкны Шиһап чүннигенә китереп бушатты — тагын кайттылар. Карурман читеннән карабодай ташучы «ЗИЛ» әрҗәсенә утыртып, «җәһәннәм»гә илтеп ташлагач, бер атнага югалып торганнар иде. Ләкин озак көттермәделәр, берсе-бер югалмыйча, тагын да симереп, тавыклар фермасын сагынып кайтып җиттеләр.

Ул Казан күздән югалгач кына исенә килгәндәй булды. Күр әле син Сакал Шәйхине, үзенә рәис кәнәфие алып биргән тынгысыз ирләрдән берьюлы котылды — төркеме белән калай капчыкка тутырып, Урал елгасының аръягына адаштырды... Вокзал тирәсендәге йончулардан соң, билгесезлеккә тәмам ияләшкән авылдашларның биштәр өстендә изрәгән чырайларын күргән саен, уаулыгы артты Нотфулланың. Туган якта йокыга китеп, чит җирләрдә уянасы балалары алдында үзен гаепле дә, җаваплы да итеп тойды ул. Һәм юлда үткән ике тәүлек буе керфек какмады. Тәрәзәгә маңгаен терәп һәр вокзал исемен, һәр елга күперен, юллар чатын дәфтәргә төшереп барды, картадагы тамгалар белән чагыштырды. Ягылмаган вагонда җылыга кинәнмәгән халык кул астындагы бөтен киемне иңенә элде, төенчекләрдән чыгарып төренде. Айҗамал бик еш саташып уянды, өнендә уйлаганы төшендә күргәне дә бер борчу — Нотфулла тукталышларның берсендә урамга чыгар да югалыр, җиде үги бала итәгенә тезелеп калыр кебек тоелды аңа. Уянган чакларында мамык шәлгә уралган каратутлы Айҗамал, ирене өстендәге коңгырт миңен сикертеп, Нотфулланы әрли: «Нәрсә дип тәрәзә ялап барасың инде, җанашым, кеше йоклаганда ял ит!..» Нотфулла, утырган килеш мәрткә киткән ил агаедай, ишетмәмешкә сабыша.

Дамбар станциясендә аларны арба таккан тракторларга күчереп утырттылар. Көнозыны барганнан соң, ниһаять, «Килеп җиттек!» дигән җылы сүз ишетелде. Ырмаулы такталардан җыелган тиңдәш өйләрне бер сызыкка тезеп, дүрт урам иткәннәр. Монда чирәм җирләргә илле алтынчы елларда ук күчеп килгән гаиләләр яшәгән. Сөрү җирләренә якынрак булсын өчен елга-сулардан йөз чакрым читкә салынган бу ясалма авыл бердәнбер артезиан коеның санаулы суы белән генә туена, шуңа күрә өй түрендә бакчалар юк, агачлар үсми. Буш өйләр, төзүчеләрдән калганча, бер-берсенә охшаган, кәрниз почмагына сугылган номерыңны онытсаң — чит гаилә өстенә килеп керәсеңне көт тә тор! Чирәм җирләрне Мәгъсүм капка төбенә хәтфәдәй түшәлгән бәбкә үләне дип күз алдына китерә иде. Ә монда — офык әйләнәсе чиксез дала, өй тирәләре яланаяк басып булмастай дөя чәнечкесе. Кулга ияләштерәсе җир — көрәк күрмәгән кара туфрак — узган елгы типчак, кылган, әрем ише әрсез үләннәр, язга чыккач, каракура болынына әверелгән.

Далада көннәр гел бертөрле. Әйләнә-тирәдәге мохит стенага эленгән сагышлы рәсем кебек. Бары тик ел фасыллары алышынганда гына җирдәге төсләр үзгәрә. Яңгырлар яуганда, кыр эшләре туктап, бераз ял бирә. Ә инде кыш көннәренең эчпошыргыч төннәре, утсыз өйләре, мәрхәмәтсез җилләре этиләрне эчүгә сабыштыра, балаларны азындыра, әниләрне елата һәм өч елга ялланган гаиләләрне качып китәрлек хәлгә төшерә.

Фазыл сигезенчедә укыганда, әйләнеп кайткан иде инде алар. Тик Нотфулланыкылар гына күренмәде. Туган авылга кайтып, яңадан үги ана исеме күтәрәсе килмәде Айҗамалның. Монда ул гаилә хуҗасы, яңа көн туды исә, алай ит, болай нит, дип, Нәфисәдән калган карт каенана тыкшынмый. Иярә килгән балаларга өстәп үзе дә икене алып кайтты. Карынында үскәннәре аның өчен «Әни!» дип өзелеп то-

ра. Ләкин үгиләрнең «Әй»ләре дә колакка якын. Авылдашлар кайтып киткәннән бирле аңа Айҗамал дип дәшкән кеше юк. Нотфулла — Никита, Айҗамал — Аня, Мәүлия — Маша, Мәгъсүм — Яша хәзер.

Исемсез авылдан алар Орск якларына күчеп киттеләр. Тора-бара Нотфулла Казакъстанның Ырымбур белән чиктәш Уральск шәһәре тирәсеннән Җаеклы һәм Урманлы исемле авылны белешеп кайтты... Ләкин Уральск якларына да күңеле ятмады. Күчмә тормышка иялəнгән дүңгәләк гаилә тагын кузгалды. Сайлана торгач, Ташлы районының Ранняя дип теркәлгән саласына килеп төпләнделәр. Айҗамал каршы дәшмәде, ияреп тик йөрде. Нотфулланың күчә-күчә юньле урын таба алмавы үзенчә Шәлегә охшаган авылны эзләве иде.

Ранняя авылын Мәгъсүм янына бәхет эзләп килгән Фазыл да яраткан иде. Урал яры, урман ышыгы, күлләр шәплеге, киек-җәнлекләр күплеге, кыш көне килеп урырдай печәннәре гашыйк иткән иде Фазылны. Хәмдияне алып киләсе дә яшисе иде кана... Ләкин бу өмет Хәмдия урланган көнне үк чәлпәрәмә килде...

Ә Нотфулла Ранняя авылында берүзе калганчы яшәде. Трактор чанасына төялеп, чирәм җирләргә алгысынып чыгып киткәннән соң кырык ел үткәч кенә, ул, Айҗамалны урыс зиратына җирләп, тугыз баланы тугыз якка таратып, инде бүтән кайгы сыймас язмышын йомгаклап, туган авылына кайтып егылды.

## Боларын язып торма...

Мәгъсүмнең Яңа ел белән котлап җибәргән ачык открыткасы кышкы каникулның өченче көнендә генә килеп җитте. Шултиклем ерак араларны үтеп тә бөгәрләнмәгән, әйтерсең лә Шәленең хат ташучысы, өеннән алып кына, үзе язып тоттырган. Котлау сүзләре һәм Нотфулла гаиләсенең яңа адресы өстенә өч урыннан почта мөһере сугылган. Икенче ягында әкияти рәсем: йолдызлы күк йөзендә җигүле өч ат оча, түрле чанада кызыл тунлы яшь егет — ак бүрегенә «1961» дип язылган, култык астына өстәл чыршысы кыстырган, җирнең ясалма иярчене елмаеп юл бирә... Открытканы өй эчендәгеләр кулдан-кулга йөртеп карады. Ниһаять, Динә өстәлгә бер конверт куйды.

— Дәфтәр бите җыртып бирегез, — диде ул, өч укучыга берьюлы дәшеп. Өч куш бит җыелгач, кара савыты белән ручка сорап алды.

Балаларга бу хәл бик кызык тоелды. Башлангыч белеме булмаган абый-апаларны кечке мәктәпкә җыеп, латин имласы белән уку-язуны яңарта башлаганнар иде. Кырыктан узган Динә, Мөлеков сүзен олылап, ярты ел чамасы укырга йөреп карады. Колхозлашу елларында укып азапланган грамотаны хәйран искә төшерә башлаган иде. Ләкин белем алу — ул җиләк вакыты кебегрәк икән. Кыш җиткәч, тубал күтәреп урманга керүдән ни файда... Өч баланың укыганы да җиткән. Кич белән аларның үзләрен генә калдырып йөрү килешмәс. Болай да ятимлектә үсеп, ялгызлыктан туйганнардыр инде... Калын китапларны укырга йөрәге җитмәсә дә, сыздый-быздыйга кулыннан килә Динәнең. Ләкин аның хат язарга теләве балалар өчен көтелмәгән яңалык иде.

— Гомергә бер хат язып бирергә иренәсез инде, — диде әни кеше, лампочканың матчадагы кадакка уралган шнурын озынайтып.

— Мин клубка соңга калам, — диде кызы.

— Мине әби көтә торгандыр, — диде олы улы, юлның клуб аркылы үткәнен искәрмичә генә. — Әнә Фазыл язып бирсен, марҗа кызлары белән хат алышырга бик ярата.

Хатның баш өлеше: «Исәнме, Нотфулла, Айҗамал һәм балалар?» — дигәне генә латин хәрефләре белән язылды. Калганын Фазыл дәвам итте. Әнисе әйтеп торды...

*«...Үзебез һаман шул иске өйдә яшәп ятабыз. Кышлар суык бездә, көнгә ике тапкыр мичкә ягабыз. Әбиегез исән әле. Аны күрше Минниса карый...»*

Фазыл каләмен кара савытына манган арада, Динә язылган кадәр хатка күз салып ала, хата белән язмый микән, ди.

*«Ферма тавыклары кырылып бетте. Сыер күлендә гараж хәзер. Колхоз куяннарының исәннәрен мәктәпкә бирделәр.*

*Мәктәп дигәннән, Мөлеков эшеннән китте. Унынчы классны бетергән йөз бала урыс теленнән язма эш буенча имтихан тапшыра алмады. Көзгә калдырганнарые, анда да өч кенә кызның эше үткән. Син аларны беләсең: берсе — Таҗи кызы, берсе — Сәрвиназ кызы, өченчесе урыс теле укытучысы Бәйрәмгалинең сеңлесе иде. Калганнары катыргы ала алмады. Инде минем олы малаем яңадан унынчы класста укып йөри...»*

— Әни, — дип бүленде Фазыл, — абыйлар күчми калды дип кенә языйм әле, алай кыскарак була.

— Тутырып языйк, улым, бер абыең гына күчми калган икән дип уйлар. Алар бит анда йөздән артык бала! Аннан соң мәктәпне тәмамлаган елны күчми калу дип язсаң, тагын аңламаслар. Нотфулла абыең Юаш булса да, төпченергә ярата.

— Мин барыбер аңламыйм. Дүрткә-бишкә генә укыган абый нишләп экзамен бирә алмады икән ул?

— Хатны ни өчен язабыз дип уйлыйсың? Мөлековның эштән киткәнен белсен. Сәбәбен үзе чамалар... Кулың армаса, яз әйдә...

*«...Бәйрәмгали бөтен язма эшләргә икеле куйган, күчерергә ирек бирмәгән, әллә нинди хаталар эзләп тапкан. Мөлеков балаларны яклап маташкан, тыңламаганнар. Бөтен ил алдында хурга калдык...»* — диген улым, яме!

— Ашыгып әйтмә, әни, юкса хата китә.

— Төн озын. Иртәгә укырга барасың юк. Мондый суыкта колхоз эше дә качмас. Яз әйдә...

*«Яңа акчаларга ияләнеп булмый, бик вакландык. Ун тәңкәлек шикәрне бер сумга алабыз. Базарда бәрәңгенең килосы ун тиен, бигрәк хур иттеләр, саткан акчаң кесә төбенә төшеп җитми. Онытa язганмын. Мәктәптә яңа директор хәзер. Читтән китерделәр. Әллә Зиннәт шунда...»*

— Наил Зиннәтович ул. Озын чәчле, кечкенә буйлы, бик усал абый. Линейкага тезеп әрләвен күрсәң... Марат абый алтыные ул.

— Боларын язып торма, улым. Читтән килгән кешеләрне барыбер белмәс Нотфулла. И-и, самый главныен онытып торам икән, яз әле, яз.

*«Сакал Шәйхи Бәйрәмгалине парткомга куйды — секретарь итеп. Кабат сәлам белән Динә...»*

Хатны кем язганын Мәгъсүм аңласын өчен, Фазыл җәяләр эченә үз исемен өстәп куйды.

— Әни, художниклар килгәнне язмадык инде.

— Анысы икенче хатка калсын.

Хаталар китмәде микән дип, язганнарны бер кат укып чыккач, Фазыл көрсенеп куйды.

— Әни, Сакал Шәйхине мин ялгыш Шакал дип язганмын, бозам инде.

— Калсын, улым, тимә, Нотфулла абыең көлә-көлә укыр.

Ырымбур белән ике арада ярты елга бер булса да хатлар йөреп торды. Нотфулла ягыннан гаилә яңалыклары гына килә, чөнки аларның нинди тормышта, нинди җирдә яшәвен күз алдына китерү мөмкин түгел, авылларын, күрше-күлән, дус-ишләрен дә белүче юк. Шуңа күрә хатлары гел бертөрле: Мәгъсүм — көтүдә, абыйлары — тракторда, Нотфулла үгез симертә. Айҗамал сыер сава, олы кыз бозау карый, кечкенәләре өй тирәсендә.

Фазылдан килгән хатлар, кулдан-кулга йөреп, кат-кат укылып, таушалып бетә. Алардагы вакыйгалар Нотфулланың күз алдында калган авыл сурәтен яңарта, үзгәрешләр кертә, андагы кешеләрнең исемнәрен искә төшереп тора.

Еллар үткән саен, Фазылга хат язардай адреслар да артты. Абыйсы армиягә киткән җиреннән, Каспий диңгезе тирәсен яратып, хезмәт срогы беткәч, янәдан китеп барды... Апасын үзбәк егете Караком чүлендәге «җәннәт»кә алып китте.

Фазылның хатлары төрле тарафларга кыйбла тотса да, эчтәлекләре бер булды. Сирәк-мирәк бер хат яза да, шуны күчереп, өч адреска җибәрә... Хатларның сирәклеге язарга иренүдән түгел, ә яңалыклар җитмәүдән генә. Елдан-елга саркып кына җыела ул яңалыклар...

## Кукурузлы рәсемнәр

Көн саен яңа көн туа торыр. Ләкин һәр яңа көн авыл тормышы өчен яңалык алып килми. Көндәлек гадәти вакыйгалар кеше теленә керми. Өйдән өйгә, урамнан урамга, авылдан авылга җиткереп сөйләр өчен яңалыкның йә мәзәге, йә фаҗигасе, йә гаебе, йә әһәмиятле мәгънәсе булырга тиеш. Авыл җирендә яңалык ясаучыларның берсе — колхоз рәисе.

1963 елның җәендә, «Кубань» автобусына төялеп, авылга кунаклар килеп төште.

Шәһәр якын булгач, кунакларның өзелгәне юк, әлбәттә, өч йөз илле тамашачы сыярдай клуб барлыгын белгәч, атна саен артистлар сагынып килеп тора, районара семинарлар үткәрер өчен колхозның ашханәсе җайлы. Тере балык, карбыз, алма сатучылар, кырык тартмачылар, Саба көмешчеләре, күршетирәнең Балык Бистәсе, Лаеш кебек районнарында янгыннан ярлы калган хәер сорашучыларың берсе дә дүрт мең ярым кешеле авылның олы юлына тузан кунарга ирек бирми... Ләкин автобустан коелган кунаклар үзенчә сәерләр иде. Аркаларында биштәрләре шәһәрчә ыспайлыкларына килешеп тора, кыска җиңле күлмәкләре, аксыл чалбарлары бөгәрләнмәгән, яңа сандалиларына тузан кунып өлгермәгән, башларында киң кырыйлы салам эшләпә. Араларында хатын-кызлар затыннан берәү дә юк. Кулларында әкәмәт әйберләр... Чемодан дисәң — юка, куна тактасы дисәң — калын, аяксыз өстәл дисәң — дилбегә кисәгеннән кагылган тоткасы бар.

Авыл үзәгенә якынайган саен, кунакларга ияргән малайлар төркеме зурая барды. Каникулга дип тугарылган мәктәп баласы маҗара эзләп су буйларында, ватык трактор тирәсендә, иске фермаларда уйнаса уйнар, әмма мәктәп янына якын бармас. Анда уен бетә, укулар сагындырмаган әле. Кибет тавын күтәрелгәч, юл икегә аерыла. Кунаклар кая борылыр — идарәгәме, мәктәпкәме, дип аптырап торганда, малайларның үзләреннән сорадылар: «Колхоз правлениесе бу яктамы?»

Малайларга җан керде, шөкер, болар яңа укытучылар түгел икән... Сакал Шәйхидән сөенче алырга дип, кунаклардан алгарак чыгып йөгерделәр.

Шәһәрдән чыкканчы ук телефоннан киңәшеп өлгергәннәр, ахрысы, Шәйхи гомердә булмаганны көн уртасында эш бүлмәсен саклап утыра. Ялтыравык «Победа»сы кояшта кибенә.

Рәис сөенечен тыя алмастай тавышы белән малайларга йомыш өләшә:

— Менә бу абыеңнар, пнимаете так, художниклар, авыл кешеләренең рәсемнәрен ясарга килгәннәр... Син, — диде ул кул астына эләккән беренче «йомышчы»га, — менә бу абыеңны Җанкай Габдулхайларга озатып куй... Син... дуңгыз көтүчесе Галимулла абзаңның кайда торганын беләсеңме? Белсәң — давай шунда. Җиһанша малае янына кайсыгыз бара?.. Ә син, — диде ул, Фазылга төртеп, — Мәрфуга апаңнарга!

— Нишләп Мәрфуга апага, ә нишләп безгә түгел? Минем әни дә матур, ясасыннар рәсемен...

Рәссамнар көлешеп куйды. Ә Шәйхинең чырае кинәт икегә бүленде сыман: бер бите кунакларга кушылып елмаерга теләде, ә икенче яңагы ачудан тартышып куйды.

— Бөтен малайлар да «ярар!» дип торганда, пнимаете так, нишләп син генә киресен сөйләп торасыңдыр?! Хәерченең теле әче, диләр!.. Мәрфуга апаң Хезмәт герое, алдынгы сыер савучы. Ә синең әнкәң төрле эштә эшләүче гади колхозчы гына! Бар, телеңә салынма! Художник абыең юлдан килгән, карыны ачкандыр, тизрәк озатып куй.

Фазылга ияргән чандыр рәссамны Сакал Шәйхи аркасыннан сөеп калды.

— Энем, син бу көчекнең өрүенә игътибар итмә. Нәселләре-күршеләре белән шундыерак алар.

Чандыр рәссам ашыгып атламады, Фазылны сөйләндереп калырга теләде, ахрысы.

— Председательгә үпкәләдеңме, ник дәшмисең?

— Шәйхи абыйга үпкәләргә ярамый. Безнең әле өй салып чыгасы бар... Ә безнең өй рәсемгә ясарга матур, түбәбездә алабута үсә, күрмичә калсак — тавыклар менеп актара, черек саламны яраталар алар. Сәке астында ояда утырган каз, урамда минем тавышны ишетсә, куыш бүрәнәдән башын тыгып кычкыра.

Чандыр рәссам Фазылны тыңлый-тыңлый алга чыгып барды, әйтерсең лә ул Батыр Мәрфуга янына малайны үзе озата бара. Бактың исә, сөйләгәннәрен тыңлаганда, йөзенә чыккан кызгану хисен сиздермәс өчен шулай итә иде ул. Ә Фазыл сөйли дә сөйли.

— Абый, сез үзегез Казаннанмы?

— Әйе, агайне.

— Мин дә үскәч Казанга китәм. Анда утын-печән ташымыйлар. Көз җиткән саен өйләргә ыры белән нигез өясе дә юк, кайнар торбалар җылыта. Суны да чишмәдән ташымыйлар — кухнядагы өстәл артыннан гына үрелеп аласы... Минем апай үзбәк егете белән хат алыша, анда гел җәй икән, утынның һич кирәге юк, ди. Җәен-кышын җиләк-җимеш үсеп ята.

— Арттырасың инде, Фазыл, кыш көне үсми торгандыр...

— Ник үсмәсен! Колхоз базарында үзбәкләр җәен-кышын өрек сата — каян килә соң ул?

— Сезнең авыл да җәен-кышын бәрәңге ашый. Кар астыннан чүпләмисездер ич?

— Чүплибез... Гаилә башына гектарлап бүлеп бирәләр ул колхоз бәрәңгесен. Безнең эти булмагач, эш озаккарак сузыла. Күчләрдән төяп җибәргәндә, карлар яуган була... Ярый, әнә ул Мәрфуганың өе. Мин шушында гына калам, курыкмагыз, этләре юк.

— Ә син, агайне, ник шүрләдең?

— Минме?! Һе... просто якын барасым килми... Безнең авылда Хезмәт батырларын бик өнәп бетермиләр.

— Көнләшәләрме?

— Өенә кергәч күрерсең әле... Нәрсәсеннән көнләшәсең инде аның?!

Фазыл, чандыр рәссам белән саубуллашу сүзен кыскарак тотып, тагын идарә янына йөгерде. Аның уенча, әле Казан кунаклары таралып бетмәгән һәм ул аларның берәрсен, һичшиксез, үзләренә алып кайтачак, әнисенең рәсемен ясаттырачак иде. Ләкин Шәйхи эшне кызу тоткан, рәссамнар инде исемнәре Мактау тактасына күчкән алдынгыларга, хәллерәк гаиләләргә, яңарак өйләргә өләшенгән иде.

Язгы сессияләрнең берсендә Шәйхинең урыны Рәссамнар союзы идарәсе рәисе Харис Якупов белән янәшә туры килде.

Алдан килгән депутатлар арткы рәттән җайлырак урынны сайлап ала, соңга калганнары иң алга — обком секретаренең күз алдына килеп утырырга мәҗбүр була.

Сессиядә каралган җиде мәсьәләнең иң мөһиме — икенчесе иде. Днепропетровск шәһәренең Кукуруз институты Идел буе районнарында чәкән өлгерерлек кукуруз үстерү өчен салкынга чыдам сорт эзләп тапкан. Хәзер исә ул сортны тиз арада Татарстан кырларына җәелдерергә кирәк иде.

Сөекле халкына нинди ризык ашатырга кирәген патшалар үзләре белә. Украин егете — Кукуруз Патшаның тозлы суда пешкән чәкән яратуы бер дә гаҗәп түгел. Ләкин ул җыелыш саен кукурузны бөтен Совет халкы яратырга тиеш, дип кычкырды.

Бөтен кырларны кукуруз басты, силосы — сыерларга, чәкәне — халыкка. Арыш ипие белән бодай күмәчләре артта калган илләргә китә, ә безгә сап-сары кукуруз каравае! Кайнар килеш кулыңа эләксә, ашап өлгерәсең, өлгермәсәң, уалып төшә. Ярмасыннан ботка пешә, крахмалыннан кесәл болгаталар,

мәлтүзеннән конфет ясыйлар... Халык үзе кукуруз үстерә, үзе көлә: «Әле дә ярый Кукуруз Патша борчак яратмаган, бөтен Советлар Союзы чалбар төбеннән кикереп йөрер иде», — ди.

Әле дә ярый банан яратмаган...

Казанга килгәч, Хрущевны чәкчәк белән каршы алганнар. Ә ул йола нигъмәтен умырып капкан да: «Кукуруза штоли?» — дип, бик сөенгән имеш, ди.

Кукуруздан Шәленең дуңгызларына да өлеш тиде. Алар өчен Казанның крахмал заводыннан әчегән мәлтүз ташыдылар. Мичкәле машина белән алып кайтып, янгыннан саклану өчен җиргә күмелгән су чаннарына бушаттылар. Ә Галимулла әлеге кукуруз балын ат арбасына салынган калай мичкә белән дуңгызлар улагына ташып торды. Ай эчендә чучкалары Галимуллага гашыйк булды: арба көпчәгенең шыгырдавын ишетүгә үк, утар коймасыннан сикереп чыгардай булып ашкыналар, колгага сапланган казан чиләге белән үрелеп улакка мәлтүз сосканда кулларын үбәләр. Галимулла аларга карап уйлап-уйлап тора да тагын бер уйлап куя: «Нәрсәсен яраталар икән шулчаклы?» Улак ялагач, чырайлары Сакал Шәйхинеке төсле кызарып чыга түгелме? Мичкә тирәсендә чебеннәр генә түгел, карабодай басуына барышлый юлларыннан язып бал кортлары да саташып йөри икән, димәк, пүчтәк нәрсә түгел... Галимулла имән бармагын мәлтүзгә манып ялап карады — үзе хуш исле, әчкелтем, сыек повидло кебек ябышкак баллы... Бәй, чүпрә генә өстисе моңа, су да кушып торасы юк!

Дүрт чиләкле сөт бидонын калай түбә астындагы кызуга ничек күтәреп менгәндер Галимулла, анысын өйдәгеләр күрми калды... Ә ике атнадан бер төркем ирнең Галимулла чормасында җырлашып утыруын бөтен урам ишетте... Кукуруз балының даны бөтен авылга чорма җыры булып таралды. Ун тонналы чаннар төн чыкканчы коргаксыды. Крахмал заводыннан кайтып килүче сөт машинасын урман эченә алып кереп бидоннарга саудылар. Дуңгызларның тагын Галимулладан күңеле бизде. Участковый Архипов катышкач кына, мәлтүз ташуны вакытлыча туктатып тордылар... Менә сиңа кукуруз!

Харис Якупов белән сөйләшеп утырганда: «Безнең авылда атлы казак күмелерлек кукурузлар үсә!» — дип мактанудан башланган сүз рәссамнарның зур төркемен Шәлегә иҗади кунакка чакыру белән тәмамланды.

Мактаулы кукуруз өчен «Карповка» дип аталган җитмеш гектарлы мәйдан бирелгән. Анда аны тәрәзә төбендәге тамчылы гөл кебек сокланып һәм иркәләп үстерәләр — мактаныр өчен. Быел кыш буе мәктәп ишегалдына җыелган табигый ашламаларның бөтенесен китереп чәчтеләр. Әле һәр балага өеннән иллешәр кило тирес алып килергә дигән йөкләмә биреләсе иде, җыеп торырга ышык урын тапмадылар.

Зур авылның үз кыенлыклары бар. Өй саен икешәр-өчәр машина утын, кыш чыгарлык печән әзерләргә кирәк. Өч бригадага бүленгән авылдан һәр көн иртән алты көтү чыгып китә. Колхозның сигез фермалы сыерларын да җәйләүгә куып чыгарсаң, хуҗалыклар өчен печән чабарлык болыннар калмый. Кулында транспорт булган гаиләләр җәһәннәмдәге сазлыктан кычыткан ура, карурманнан юкә себеркесе җыя, күрше колхоз чигеннән сорамыйча гына клевер төяп кышка җитәрлек азык әзерли. Фазыл кебек арбасызлар печән урынына буразнадан чүп үләннәр йолкып ташый. Ике куллап үлән йолкый-йолкый, аның чәнти бармакларына үлән яшеле йога һәм ул беренче уку чиреге тәмамланганда гына юылып бетә. Арбасызлар ябырылгач, җил тегермәне янындагы басулар тиз чистара, чүп-үлән авылдан ерагая... Фазыл, бер көпчәкле тачкасын комлы юлдан сөйрәп, Карповка басуына юнәлә, аңа көянтә тоткан апасы да ияргә.

Ах, ул кукуруз арасындагы үләннең шәплеге! Кукуруз бераз күтәрелгәч, рәт араларын эшкәртергә трактор керми, эт эчәгесе, сөтле билчән, тал үләне, кәлшә, ак чәчәк кебек вак хайван ятырдай чүп үләннәр котырып үсә.

Биек кукуруз арасында шунысы рәхәт — кояш өтәләми. Озын җиңле күлмәк кисәң, үткер кырлы аскы яфраклары кискәләми. Бер буразна башыннан утарга тотынасың, култыклап-култыклап тезә барасың, шул эздән кире чыкканда җыеп алып чыгасың.

Фазыл тачкага таптый-таптый төяп, бау белән бастырыклап куя. Апасы, үзенә җыйганны колач җитмәстән ике көлтә итеп, чиләк баулары ялтыраткан көянтә ыргагына элә.

Карповка басуында чүп җыю кыен түгел, иң хәтәре — Сакал Шәйхинең күзенә чалынмау. Буш көянтәне кукуруз арасына ыргытып була. Ә кул арбасы чаклы тачкаңны күрсә — «Победа»сыннан монтажка таягы алып килеп, ватып-җимереп йомычка өеме итә... Үзеңне эләктерсә, капка төбеңә җиткәнче туктый алмаслык итеп, арт ягыңа тибә. Елый-елый печәнсез, арбасыз килеш кайтып керсәң — өйдә тагын өстиләр.

Берсендә Фазыллар басуга төшеп, тачканы язгы ташулар ярган ерганак төбенә яшереп өлгергәннәр генә иде, авыл ягыннан теге Алла каһәрләгән «Победа» килеп чыкты. Малай бер якка, апасы икенче якка сикереп, кукуруз буразнасына сузылып ятты. Шәйхи, машинасын сүндермичә генә җиргә төште, кыр читендә әрле-бирле йөренде, эчкә кермәде — ак кепкасын чәкән сарысына буярга теләмәде... Ә Фазыл шул минутта, буразна төбендәге эт эчәгесенә борынын терәп, сулыш алырга куркып ятты. Кукуруз арасыннан өркетеп чыгарырга теләдеме — «Победа» китәр алдыннан сузып-сузып кычкыртты...

Чүп үләне җыйганда, күлмәккә тамыр туфрагы коела, анысы берни түгел. Фазыл, апасының тузанга баткан чәч толымын күргәч, күз төбендәге тирне бик озаклап сөртте.

Олы юлга чыккач, Сакал Шәйхи күрсә дә тия алмый. Машинасын туктатып: «Каян җыйдыгыз?!» — дип җикеренсә, җавап әзер: «Андреевка кырыннан!..» «Победа» тачкадагы печәнне төтен исенә батырып кузгалып китә, тәрәзәдән: «Җитешмәгән җирләре юк шул хәерче көчекләренең!» — дигәне генә ишетелеп кала.

Кайтыр юллар кыскарак, дип, туган авылны сагынып кайтучылар гына сөйләнә торгандыр. Учың белән йолкып җыйган үләнне челлә кояшына ияреп комлы юлдан тачка белән этеп кайтсаң, һай ерагая ул юллар... Андый минутларда синең өчен бердәнбер этәргеч өмет бар — фермалар янына кайтып җитсәң, су эчәсең!

Баганага беркетелгән чуен чүмечнең сыер борынына җайлаштырып бөгелгән тишекле теленә басып су җыясың. Сыерлар көнләшерлек комсызлык белән шул автопоилкага капланып чөмерәсең. Су җитмәгәч, бөгәлҗәле тимерне маңгаең белән этәсең... Сулышың беткәч, юеш чыраеңны ферма түшәменә текәп тирән итеп тын аласың да тагын, тагын чөмерәсең. Бу җәйнең үги челләсендә синнән дә бәхетлерәк кеше юк!

Син тагын яши башлыйсың. Өеңә кайтып егылырлык хәл керә. Рәхмәт су иясенә! Хәтта шушы сулы фермаларны салдырган Сакал Шәйхигә дә рәхмәт! Кукуруз үстерергә кушкан Хрущевка да рәхмәт!

Харис Якупов үзенең шәкертләре белән авылны рәсемгә күчерә башлады. Кемдер, җәйләүгә килеп, сыер көтүен ясапятты, берсе көтүче Җиһанша малаеның чыбыркысына иярде. Дуңгыз караучы рәсемен ясар өчен Мәрзияны мәктәп күләгәсендә ун көн буе утырттылар, дуңгыз фермасы янында ярты гына сәгать түзә алган рәссам — укшыган, диделәр... Араларындагы чандыры Сакал Шәйхинең эш бүлмәсендә яткан. Иртәнге дүрттә килә, идарә утырышында катнаша, нәрәт биргәндә председательнең һәр карашын, йөзендәге һәр чалымны, кул хәрәкәтләрен, басып торышын, кыскасы, сүгенүеннән гайре бөтенесен кәгазь битенә карандаш белән төшереп барган...

Художниклар Казанга бик күп рәсемнәр күтәреп китте.

Фазыл мәктәпне тәмамлап килгән елны сәнгать музеена еш кергәләде. Ул диварларга эленгән көчле кешеләр арасында авылдашларын күрер өчен генә түгел, бәлки, теге чандыр рәссамны очратып булмасмы дип йөри иде. Әллә юанайды ул, әллә юллар кисешми — туры килгәне юк.

Авыл турында әле бик күп рәсемнәр булырга тиеш иде. Кая соң алар? Төрле нәшриятларда басылып чыккан яңа альбомнар актарган саен, Фазыл кабаланып-кабаланып таныш күренешләрне эзли... Салам түбәсендә алабута үскән кечкенә өй кая? Үзеннән биек кукурузлар арасында атка атланган позага баскан Сакал Шәйхи рәсеме кая? Колхозны миллионер итәбез дип, хезмәт көненә алданып яшәгән көчсез кешеләр кая?..

Хатлар язганда, Фазыл әлеге вакыйганы яңалык итеп бер җөмләгә сыйдырыр:

*«Безнең авылга художниклар килеп, җәй буе рәсем ясап яттылар...»*

Әйе, иркенләп сөйли китсәң, һәр яңалык зур бер вакыйга. Тәҗрибәсез хат язучының дәфтәр битенә яңалыклар сыя — вакыйгалар сыймый...

*«Элеккеге идарә бинасын участок больницасы иттеләр. Сакал Шәйхинең җиңгәсе баш врач булып кайтты. Авылда бер исән кеше юк икән, больницада көн саен чират...»*

*«Районнан «ПМК» төзүчеләре килеп, Казан юлы өстендә зур плотина кордылар. Колхозның бер миллион сум яңа акчасы киткән, диделәр. Инеш суы диңгез булып җәелде».*

*«Яңа мәктәп өчен Питрәч заводыннан кирпеч ташыйлар. Без унынчыны тәмамлаганчы, төзеп бетерәчәкләр, ди».*

*«Почта урамындагы Зәйнулла өр-яңа «Москвич-412» машинасы откание. Сакал Шәйхинең энекәше отышлы билетын сорап килгән. Зәйнулла ризалашкан. Иске машина белән ике мең сум акча өстәп биргәннәр».*

*«Быел яз көне теге плотинаны ташу алып китте. Цементы юылган, баганалары уалган, диделәр. «ПМК» начальнигын алыштырдылар. Шәйхигә сүз булмады...»*

*«Колхоздан ссуда алып өй салдык. Өмә белән күтәрдек. Бурасы усак катыш юкә иде, өйне кырмыска басты. Атна саен агуладык. Әби мәктәп өеннән безгә килеп үлде...»*

*«Өйне сатып ссуданы түләдек. Әни апа янына Үзбәкстанга китте. Абый һаман читтә... Мин унны бетердем. Яңа мәктәп өлгермәде әле...»*

Һәм Фазылның мәктәпне тәмамлап бәхет эзләп китүе соңгы хатларга кергән соңгы яңалык иде. Аның Мелиорация министрлыгы каршындагы су скважиналары бораулау оешмасына эшкә урнашуы туганнары арасында хатлар өзелүгә сәбәп булды. Фазылның даими адресы юк. Аны хат ташучылар эзләп табарлык түгел. Үз кирәген ул бары тик үзе генә эзләп таба ала иде...

## IV. МӘДИЯР

### Иске бишмәт

Адреслар өстәленнән бер-берсен эзләүчеләр күбәйгән, ахрысы, Фазыл өчен кирәкле белешмәне калын кәгазь өеменнән көч-хәл белән актарып чыгардылар.

— Миңлегалиев Мәдияр Ярулла улы... Сез эзләгән кеше шушымы?

— Әйе, әйе, — диде Фазыл сөенеп, әйтерсең лә Мәдияр шаяртып адреслар өстәле астында качып яткан. Һәм ул менә хәзер үзе килеп чыгарга тиеш.

— Адресы: Мамадыш районының Зюри авылы.

— Зюри түгел, Шүләнгер... Ул авылдан чыгып киткәненә бишбылтыр инде аның.

— Кызганычка каршы, архивта туган авылы гына теркәлгән. Әгәр кая да булса вакытлыча пропискага керсә, безгә андый адрес хәбәр ителми. Ул чагында туган авылын гына әйтеп бирәбез.

— Кайда туып үскәнен сездән башка да беләм мин аның. Вакыт әрәм итеп, көтеп йөрисе юк.

— Бүтән чарагыз калмаса, телевидение аша фотосын бирегез.

— Мин бит җинаятьчене эзләмим. Миңлегалиев элеккеге хезмәттәшем — ул эш өчен кирәк.

— Гражданин! Алайга китсә, үзегез табыгыз!

Адреслар өстәленең нәни тәрәзәсе ябылды.

Нәсел агачының тамыры авылда булса, адәм баласын эзләп табуы җиңелрәк. Туганнары, күршеләре, классташларының берәрсе аның турыда ниндидер хәбәр саклый. Кайтканые, күргәнием, ишеткәнием, дип, син эзләгән кеше хакында өметләндереп юатырлар, күчеп яшәгән җиренең кайдалыгын аңлатырлар. Авыл үз баласын югалтмыйча хәбәрдар булып саклый. Менә шуңа күрә дә курсташлар, хезмәттәшләр, юлдашлар үзара адрес алышканда туган авылларын күрсәтеп язалар. Хәтта күченеп шәһәр туфрагына тамыр җәйгән кешеләр дә үзенең авылын ышанычлырак адрес итеп исәпли. Бәхет эзләп зур-зур калаларны санап йөрергә була. Ләкин туган авыл бер генә.

И Шүләнгер, әле дә ярый Мәдияр өчен син бар!

Мәдияр, Мелиорация министрлыгы таркалгач, су бораулау эшенә кул селтәп, тагын Мамадышка кайтып урнашты. Районның кулланучылар җәмгыяте ишегалдында атналар буе яңа шофер көтеп яткан бөркәүле иске машина бар иде, шуның белән кибетләргә йөк ташырга ризалашты. Шимбә һәм якшәмбе көннәрендә Шүләнгергә ашыга. Саладан кала булып азынган Мамадышның бер читендә фатирант булып яшәгән буйдак өчен атнаның ике көнендә эти-әнисе ягына кайту күңелле юанычка әверелә.

Фазыл аны Шүләнгердә көтеп алды. Өй түрендә бөркәүле машина күренгәч, эти-әнисе нишләргә дә белмәде. Кунак егетне качырып торыргамы, ачык тәрәзәдән дәштерергәме, көтелмәгән очрашуны ни рәвешлерәк оештырырга, дип баш ваткан арада, Фазыл үзе шамакайга әверелде. Ул, эти кешенең малахаен, сырган чалбарын, җиңсез сырмасын киеп, җәй көне дә болдырдан төшмәгән киез каталарны сөйрәп машина янына чыгып басты. Мәдиярның, капка төбенә кайтып туктагач, эти-әни күрсә, яхшы түгел дип, кабинадан чыкмыйча гына берәр стаканны «төшереп» куя торган гадәте бар иде. Бу юлысы, стаканны тутырып салып, кулына колбаса сыныгы алуга, капкада колакчынын салындырып кигән малахайлы «әтисе» күренде. Күз алдында оялмыйча ничек эчмәк кирәк — Мәдияр, каушавын тыя алмыйча, хәмер тулы стаканны кабина тәрәзәсе аркылы әтисенә сузды. «Чәчрәтеп түгә, әрәм итә инде» дип уйлап куйды үзе, чөнки ул әтисенең соңгы ун елдан артык авызына грамм да хәмер капмаганын яхшы белә.

Фазыл, кырын баскан килеш, йөзен танытмыйча, стакандагыны каплап куйды, аннан соң кабымлык сорап учын җәйде. Әгәр каушамыйча җентекләп күз салса, эш бияләе кадәр кулның әтисенеке түгеллеген таный иде инде ул. Сизмәде.

— Әти, — диде Мәдияр, кыерчыгы сындырып алынган тоташ колбасаны тәкъдим итеп, — өйдә берәр күңелсезлек бар мәллә?

Фазыл дәшмәде, кеткелдәп көлүеннән туктый алмыйча, җилкәсе белән борылып басты.

— Әти, карале, килешә бит сиңа! Гәүдәләрең турайды, буең үсеп китте! Әти, сәгать ничә икән инде? Кибет ябылганчы барып тагын бер ярты алып килим. Стаканны кире бир монда, машина бардачогыннан ул.

Кырлы стакан эчендәге ком сәгатен күреп, Мәдияр кинәт сискәнеп китте, битендәге шадралары кызыша башлады, бармакларын тарак итеп җирән чәчен еш-еш артка сыпырды.

— Мастер! Фазыл! Кияү! Итит-митит! Нихәл, иске бишмәт?! Сине шушы киемнән буровойга алып китәсе генә бар.

— Әйдә, тизрәк өегезгә керик, — диде Фазыл, туганнарча кочаклашып күрешкәч, — мин исергәнче сөйләшеп өлгерәсе бар.

— Күңелем сизә, «кияү», син мине тагын коткарырга кайткансың!..

## Качкыннар

Мәдиярның «тагын» дип, ни әйтергә теләгәне аңлашыла — үзенчә җитмешенче еллар башындагы хәлләрне искә төшерүе аның...

Әмирне ашык-пошык пенсиягә озатып, Фазылны «Ростов-Донводстрой» мәктәбенә укырга җибәргәннәр иде. Бригада үзеннән-үзе таралды. Мәдияр бер мәлгә эшсез калды. Әлбәттә, башка бригадага

күчү мөмкинлеге бар иде, сау-таза, тәҗрибәле бораулаучылар һәркайда кирәк. Ләкин Мәдиярның күңел түрендә качып-посып кына яңа хыял яшәп килә... Ни өчен әле яраткан һөнәрем, дип, гомер буе гаилә җылысы күрмичә яшәгән Әмирнең язмышын кабатларга? Әмир урынына бораулау остасы итеп Фазылны куярлар, укып кына кайтсын! Остамы ул, бригадир дип атыйсыңмы аны, йоласына туры китереп, үткәннәрне гел искә төшерер өчен «кияү» дип дәшәсеңме — барыбер... Туганың кебек якын егет, ышанычлы хезмәттәш һәм тугры дус булса да, Фазыл Мәдияр язмышына артык яңалык өсти алмаячак. Әмирне алыштырганга карап кына, су бораулаучысының авылдан авылга йөреп эшли торган «зимагурлык» тормышы үзгәрмәячәк. Качарга кирәк бу бәхеттән. Романтикасына, кыргый ирегенә, акчасына карамыйча качарга, үзгәрешләр матавыгыннан курыкмыйча иялнгән һөнәрне алыштырырга кирәк... Галина белән кавышкач, бик күп кыенлыклар үзеннән-үзе хәл ителергә тиеш.

— Мин сине озата барам, — диде Мәдияр беркатлыланып.

— Кичкырын аэропортта чиләнеп йөрмәсәң дә ярар.

— Аңламадың мәллә, Батайскига чаклы озатып куям.

Билет кассасына чиратлары килеп җиткәч, Мәдияр үзенең паспортын Фазылныкына кушты.

— Милая девушка, Ростов-Донга ике билет бирегез әле. Урыным менә бу Шәмсетдинов белән бергә булмаса да үпкәләмәм, эштә гел бергә без аның белән.

Кассир кыз елмаюга елмаю белән җавап кайтарды һәм урыннарны янәшә бирде.

— Шуткыңны аңлап бетермәдем, — диде Фазыл, үз билетын аерым кесәгә салгач.

— Борчылма, «кияү», сиңа ияреп йөрисем килгәннән түгел, буш вакыт барда Галинаны күреп кайтырга кирәк. Сагындырды.

Шулай итеп, алар, икесе бер самолетта янәшә утырып, Каф таулары итәгенә олактылар. Әмирләр язмышын кабатламыйм, Фазыл кебекләрнең бәхетеннән ераграк качыйм дип, ныклы карарга килгән Мәдияр өчен сәер юл иде бу.

Язилә, «Ан-24»нең түгәрәк тәрәзәләренә кул болгап, Арча кырындагы аэродромда елап калды.

Сөйгәне белән көн саен күрешкән кеше сагынуның тәмле газабын, комарлы ләззәтен тоя белмәс. Мәдияр өчен сагынып күрешү яшәү рәвешенә әверелеп бара. Хезмәт хакы алган көнне кабаланып юлга әзерләнсә — кая барасың дип сорыйсы юк. Санаулы ял атнасы беткәч, бер-ике көнгә эшкә соңга калса да, аптырамыйлар. Бригаданың кайсы авылга күченәсе алдан ук билгеле. Ростовтан Казанга кайтып төшүгә, ул егетләрне эзләп таба. Көн азагына өлгерсә, кичке ашка кушыла, төн уртасына калса, яшел вагонны дер селкетеп, уятып керә.

Ростов аэропортына төшү белән Фазылга ошаганы шул булды — Мәдияр инде үзен җирле казакларча иркен тота, як-ягына каранмый, аптырап уйланып тормый, тукталышларны сорашмый — ул хәзер барысын да үзе белә. Сабырсызлыгыңа төкәнеп, сагынуыңнан үләр дәрәҗәгә җитеп ашкынсаң — Азов ягына йөри торган «электричка»га өлгереп, Галинаны ун минутка иртәрәк күрергә була. Мәдияр әллә кайчан бер сынады инде ул мөмкинлекне, ләкин кабаланып килеп утырган вагон бөтенләй капма-каршы тарафка — Таганрогка алып киткән иде. Шул вакыттан бирле егет Ростовта тимер юл вокзалы барлыгын онытты, Ростовны Кавказның капкасы дип атыйлар, ул Грозный, Тбилиси, Ереван калаларының юл башында тора. Ләкин Мәдияр Кавказ капкасыннан кергәч, Дон күперен чыгып ярты сәгать үтүгә, автобустан төшеп кала. Аның өчен бу якларда бары тик Батайск шәһәрчеге генә бар. Пассажирлар аңа артык игътибар итми, милиция хезмәткәрләре паспортын тикшерми, ник дигәндә, ул грузинга, әрмәнгә дә, чеченга да охшамаган. Мәдиярның нур бөркеп торган җирән чәче, шадра чәчрәгән табак бите, шадралыгына карамастан печтик борыны һәм җирән каш сихерендә калган зәңгәр күзләре шик тудырмый, киресенчә, кара-каршы килгән һәркемнең йөзендә елмаю уята иде.

Батайск — эшчеләр бистәсеннән үсеп шәһәргә әверелгән. Киң яңа урамнарында заманча төзелгән күп катлы йортлар тезелешкән. Ә Галиналар яши торган тар урамда һәркемнең саманнан салынган шәхси өе.

Һәр килүендә Мәдияр, бар дөньясын онытып, сөйгән кызының өй түренә йөгерми, татар мужикларына хас шикләнүен җиңә алмыйча, мин югында кемнәр белән күңел ача икән ул дигәндәй, шәһәр бетереп эзләнә башлый.

Бүген ул ашыкмады.

— Шушы шәһәрчектә бер ел буе укырга тиеш инде син, Фазыл кияү. Күңелсез озын кичләрдә, Казанда калган дусларыңны сагынып газиз башкаеңны кая куярга белмичә моңаеп йөргәндә, менә монда рәхим ит, — диде ул, «Кавказ» кафесына ымлап. Фазылны юлдан килгән килешкә үк яңа шәһәрнең йөз мең кешесе белән берьюлы таныштырырга теләп йөрүе — әлеге дә баягы Мәдиярның үзенчә Галинаны эзләве иде.

«Кавказ» кафесында шашлык ашап, «Кавказ» кинотеатрындагы чиратны сөзеп, «Кызыл Кавказ» бакчасын айкап чыккач кына, күңелнең караңгы почмагында посып яткан шик юкка чыккандай булды.

— Саф хатыннар, бозык кызлар була, — диде Мәдияр, үзалдына сөйләнеп һәм, ниһаять, Фазылны Галиналар яши торган урамга ашыктырды.

Кайткан саен кызның өйдә чагына туры килә: йә ул балалар бакчасының мәктәпкә әзерлек төркемендә ясалган контроль эшләрне тикшереп утыра, йә ишегалдындагы буржуйка казанында кер кайната, йә мич тирәсендә йөри. Әти-әнисе Галинаның Казан самолеты көтеп яшәвенә борчылалар иде, ник дисәң — әгәр җирән татар өйләнмәсә, гел өйдә утырырга күнеккән бердәнбер кызлары сазамык булып утырып калырга мөмкин...

Бораулау осталары әзерли торган мәктәпкә укучылар атна буе агылды. СССРның дүрт кыйбласыннан Дон буена юл табып җыелганнарын тулай торакта көтеп ятканчы, Осадчийларда кунак булуы күңеллерәк, әлбәттә... Килгән көннәрдә Фазыл Мәдиярга тагылып йөрде. Сергей Иванович караңгы чырай күрсәтмәде. Аларга ашау-эчүне хуҗалар белән бергә әзерләделәр. Икесенә ике караватк куеп верандада йоклаттылар. Галина егетләр тирәсендә бик чуалмады, әти-әнисе каршында инсафлык саклап, үзен сөйгән егете белән кавышасы кыз итеп түгел, ә күбрәк кунакханә өчен җаваплы кеше кебегрәк хис итте.

Укулар башлангач, Фазыл тулай торакка авышты. Шуннан соң алар Мәдияр белән сирәк күрештеләр. Эшләрен ташлап укуга килгән шәкертләр өчен программа бик тыгыз төзелгән иде, кабинет белән полигон, лекция белән практика арасындагы матавык көн саен ун сәгатькә сузыла, төшке ашка дигән озын тәнәфесләре дә егерме минут кына иде... Һәм «кияү»ләр тора-бара атнага бер — ял көннәрендә генә очраша башладылар.

## Казак молодой...

Кешенең кем булуы, кайда яшәве, нинди эштә эшләве аерылышканда гына кирәк икән ул. Язылышканда берсен дә сорамадылар. Паспортының урта битләрендәге тамгаларына күз салгач, гариза яздырдылар да якшәмбе көнне иртәнге унбергә килергә куштылар. Көне-сәгате җиткәч, кулга никах кәгазе тоттырып, зур залга чакырдылар. Дүрт яңа гаилә үзенең туганнары белән никах вәгазе тыңлады. Мәдиярдан бигрәк Фазыл йотлыгып тыңлады, чөнки үзенең «чегән туенда» аңа вәгазь укырдай кеше Язиләнең әтисе Әмир генә иде. Ә монда — чәчәкле-чуклы, ялтыр-йолтыр, зиннәтле-гыйбрәтле залда — никах мөдирәсенең һәр сүзе зиһенеңә сеңә, бәгыреңә үтә, кавышу уены, гипнозланып, чынбарлыкка әверелә. Әле күптән түгел генә мазутлы бушлат, сырган чалбар эченнән чыккан Мәдияр, күзләренең зәңгәрлегеннән күчереп, кәчтүн-чалбар тектергән, кызыл күлмәгенең сәдәфләрен каплаган зәңгәр галстугындагы чәчәк сурәтендә йөзек кашы җемелди.

Никах йортында һәркем үз кияве, үз килене тирәсендә мәш килә. Мәдиярның кара кәчтүн кимәвенә дә исләре китмәде. Гаилә берлеген тикшергән очракта да, Осадчая Галина Сергеевнаның ниндидер Миңлегалиев Мәдияр Ярулловичның хатыны булырга риза дигәне гаҗәпләндермәде. Кавказ капкасыннан кердең исә, син инде милләтләр бәйләменең бер вәкиле.

Дон аръягында зур туйлар күбесенчә көз көне була. Мәҗлескә чакырып йомышчылар бөтен станицаны йөреп чыга, ничә кунак киләсен хуҗалар белми дә хәтта. Утарда булган бөтен тактадан ишегалдына өстәлләр ясала, утыргычлар кагыла. Батайск үзенә күрә шәһәр дип исәпләнсә дә, анда яши торган халык йоласы, холкы-фигыле белән гел станица казагы кебек иде.

Уртада биергә мәйдан калдырып, өстәлләрне ишегалды тирәли түгәрәкләп тезделәр. Чаңгы таягына уралган шакмаклы киң тастымал төргәге өй борынча мәҗлестән мәҗлескә йөри торган тоташ ашъяулык булган икән... Табында ак күмәчтән гайре камыр әйберсе юк. Ысланган дуңгыз ите тирәли табак-табак тозланган яшелчә, буш урыннарда бакча җимеше, матурлык өчен генә чирекле шешә белән сөтләч көмешкә кукыраеп тора, ләкин кунаклар кибет аракысын бушата.

Мәдиярның әти-әнисе бармы, кая, кемнәр, дип сораучы табылмады. Шуңа күрә аның янында утырган Фазыл үзе шаһит, үзе кода, үзе дус, үзе кунак. Мондагы туйларда сыйлаучы юк, тамада сүз биреп үгетләми, кем аягүрә торып баса — шул сөйли, утырган килеш кенә сөйләүчеләр башкаларны тыңламый. Ашап туйганнан соң, төн уртасында яшелчә ашы бирелә һәм халык, айнышып киткәндәй булып, яңабаштан эчәргә тотына. Татарда «Килүегезгә рәхмәт, кунаклар, инде кайтыгыз!» дигәндәй, чәй тараталар. Ә боларда чәй, җимеш суы, куас ише эчемлекләрне мәҗлес башында ук бирәләр. Хуҗаның таң этәче кычкырмыйча кайту турында уйлаучы юк. Үз йорты белән яшәгән кеше шәһәр уртасында да тавык асрый, кунакчыл хуҗа мәҗлес алдыннан әтәчләрен күршегә кертеп куя.

Күп сөйләргә яратучыларны бүлдереп җыр арты җыр яңгырады.

Һәр халыкның күмәк җырлый торган «Күбәләгем» кебегрәк такмазасы бар.

...По Дону гуляет, по Дону гуляет,
По Дону гуляет казак молодой...

Әлеге җыр туй таралганчы өч-дүрт тапкыр кабатланды. «Молодой казак» роленә кергән Мәдиярны үртәр өчен, Фазыл мәҗлес хорына татарча кушылды.

Дим буенда йөри, Дим буенда йөри,
Дим буенда йөри Казан малае...

Фазылның бу кыланышын «кияү»нең иң якын күршесе Галина да яратып, балдаклы бармагы белән дирижерлык итеп, иҗеген-иҗеккә ияртергә тырышты.

— ...Шүләнгердән берәрсе килгән булса: «Карасана казакларны, гел безнең авыл кешесенә охшаганнар!» — дияр иде. «Атлы казак» дигән кушамат бар бит безнең якларда.

— Нәкъ шуны уйлап утырам, «кияү», болар юри генә татарча сөйләшмиләр бугай... Ат яратулары да нәкъ безнеңчә.

— Әүвәл мин Дон казакларын киң балаклы шароварга кыстырмыйча гына күлмәк кигән, биленә эзәр ураган, бер тотамчук калдырган такыр башлы, салпы мыеклы юлбасарлар дип уйлый идем. Бактың исә, болар безнең кебек кешеләр, киемнәре дә безнеңчә...

— Әгәр син Галинаң янына гражданнар сугышы чорында килгән булсаң, кемлекләрен күрер идең. Советлар Союзы аларны да чукындырды инде.

Колгаларга эленгән лампочкалар нуры көн яктысы белән тигезләнгәндә, Фазыл, вакыт дөреслегенә ышанмагандай, кул сәгатен боргалый башлады һәм шул арада ул күз чите белән генә Мәдиярны күзәтте... Яшь кияү уң кулына тозланган карбыз кисәге тоткан, ә сул кулы кәләшнең тез башында — бармаклары туй күлмәге аркылы массаж ясый иде бугай. Галинаның ике кулы да өстәлдә, күзләре, табын читендә бушлык табып, билгесезлеккә төбәлгән, аның өнсез калуы йокы килгәннән түгел иде. Ул әле туйның озак-озак дәвам итүен тели. Чөнки кунаклар таралышкач, үзен нәрсә көткәнен белә. Ә Мәдияр, киресенчә, вакытны куаларга тели. Менә хәзер бөтен күрше-тирәдәге әтәчләр туй мәйданына җыелсын иде дә кунакларны таратырлык итеп кычкырсын иде...

— Миңа китәргә вакыт, — диде Фазыл, яшь кияүне сискәндермәслек тында, — тагын дүрт сәгатьтән дәресләр башлана. — Һәм үз соравына үзе җавап тапкандай өстәп куйды. — Барыгыз, сез дә җаныгызны кыйнап утырмагыз. Кунакларның «горько!» кычкырырлык та рәте юк. Югалуыгызны сизмәсләр...

Җыр озынга китте.

Галина, сөйгәнен сөендереп, вәгъдәле елмаеп, читкә ымлады. Җырдан ерак та түгел, бакча читендә слива куаклары арасында мунча кебегрәк өй бар иде. Кечкенә тәрәзәле, мичсез, базсыз, түшәмсез әлеге куыш чиллә борчуларыннан качып ял итә торган урын. Ишек тоткасына исемнәрен белеп бетергесез чәчәкләрдән үреп такыя элгәннәр.

— Мәхәббәт сарае... — диде Галина, такыяны төшермәскә тырышып кына ишекне япканда, — сезнең якларда бармы бу нәрсә?

— Белмим, өйләнеп караганым юк!

Мәдиярның озын-озак итеп сөйләшеп торырга сабырлыгы беткән иде инде. Галина эчке яктагы келәне бикләгән арада, куыш эчен күздән кичереп өлгерде. Бүрәнәдәге кадакларга эленгән үлән бәйләмнәрен, чәчәк көлтәләрен, бал тәпәне, гөмбә тубаларын күреп аптырамады, ял итәргә кергәне бар аның монда. Бүген бер кешелек агач караватның бизәлеше сокландырды. Ул операция өстәле кебек, кайчылык сиртмәсенә эленгән озын шнурлы лампочка астына туры китереп уртага куелган. Калын түшәге ап-ак япма белән төрелгән. Мендәрләре юк, аның каравы япма астындагы калай тәлинкәдә куагыннан кичә генә өзелгән ике тәлгәш кызыл йөзем бар икән...

— Мин йөземне сиңа күрсәтмәскә тиеш идем, — диде кәләш, горур тавыш белән.

— Әгәр ялгыш өстенә ят... утырсаң, бөтен урын җиргә сытылып, кызылга мана иде ич...

— Нәкъ шуңа исәпләнгән инде ул йола.

— Алайса, яңадан каплап куй. Күрмәдем, белмәдем.

— Минем синең алда гөнаһым юк. Виноград буявыннан башка да исбатлый алам...

Һәм Галина, йөзем тәлгәшләрен тәрәзә төбенә куеп, пәрдәне корды.

— Рәхмәт, Галина.

— Ә сездә кәләшләр кияүләрне ничек алдый?

— Кичә өйләнгән булсаң, мин кыз идем әле, дип, бер үкереп елый да гафу үтенә.

— Гафу үтенергә теләмәсә?

— Кияүгә бик чыгасы килгән кыз хәйләсен таба торгандыр инде.

— Алдатмас өчен кияү өч көн буе эчмәскә тиеш.

— Галя, шушындый минутта ник минем башымны катырасың инде? — Мәдияр аны ярсу көч белән күтәреп алды.

— Мәдьярчик, милый мой! Ашыкма! Туй күлмәген бөгәрләргә ярамый. Аны әле кунаклар килгән саен киеп күрсәтәсе. Борылып тор. Мин үзем чишенәм.

— Тизрәк чишен, Галя!

— Ашыкма, бу тормыш безнеке хәзер.

Ләкин кияү җавап кайтармады. Түземлеге тәмам бетеп, кирәксә, бозлы суга, әйтсәләр, дөрләп янган утка сикерер хәлгә җиткән Мәдияр, боерыкны онытып, кызга таба борылды. Ә ул... стенага таба карап баскан да башын иеп, куллары белән яңакларын каплаган килеш тик басып тора, күлмәген салу турында уйламый да... Кияү, кисәк хәрәкәттән чак тыелып, аяк очларын шудырып кына, кыз басып торган

сайгакка күчте, бармак очларын чак кыймылдатып, куе кара толым астындагы каптырмага үрелде. Кәләшнең карышмавына тәмам инангач, «молния» йозагын аска төшерә башлады. Озын чылбыр сөендереп бил өстенә чаклы тәнне ачты. Мәдияр, чишендерү турында онытып, кызның ачылган кадәре тәнен үбә башлады. Туй буена шытып өлгергән сакал-мыегы кытыкладымы, әллә һич аңлата алмастай эчке энергия көчәнешеннәнме — Галинаның гәүдәсе җәя кебек киерелде. Иреннәр үз эшен эшләгән арада, куллар да тик тормады. Туй күлмәге балавыздай сары идәнгә төшеп өелде. Кызның карышырлык көче, үз иреге белән караватка барып җитәрдәй ихтыяры калмаган иде. Кияү аны ак күлмәк өеменнән өзеп алгандай итеп, кулларына күтәрде, түшәккә китереп куйды. Алай да кыз ак япманы ялангач тәненә каплап өлгерерлек көч тапты. Ләкин кияү, әкрен-әкрен генә шудырып, ике тәнне аерып торган әлеге чаршауны җыеп алды. Ул үзен бик җитди операциягә әзерләнгән хирург кебек хис итте, туй күлмәгеннән чыккан тәнне сыйпап, гүя гаепле урынны эзләде. Кәләш кул белән ул урынны каплап, уң кулы белән тиздән, бик тиздән ире буласы кияүнең гыйшыклы бармакларын озатып йөри. Мәдияр, караватчитендә басып торган килеш кенә үрелеп, түшәккә чумган Галинаны үбәргә теләде.

— Туйда үбеп туймадыңмы?

— «Горько!» кычкырган саен кеше алдында чын күңелдән үбешә башласаң, рәттән егерме инфаркт алырсың, йөрәгең ярылыр...

Кызның гәүдәсе сүнде. Сүлпән сулавы һәм коңгырт күзләренең сагаеп кына егет артыннан күзәтүе җанындагы уяулыкны сиздереп тора. Сәер инде бу әхлак кануннары... Ничә еллар буе кунакка кайткан егете алдында сарафанын алыштырырга да оялып күрше бүлмәгә бикләнә торган, сагынышып үбешкәндә гәүдәләрне артык якынайтмас өчен терсәкләре белән читкә этәрүче сөекле Галина бүген Мәдияр алдында ирекле кол булып ята. Уртага бөкләнгән заем кәгазе чаклы гына никах таныклыгы үсеп буйга җиткән, әти-әнисе җил-давылдан саклап егерме өч яшенә чаклы үстергән кыз баланы буйсындырып кулыңа бирә...

— Ашыкма, берүк ашыга күрмә... — дип, күзен йомган җирдән кызый кинәт сискәнеп куйды. Аның кайнар күкрәк өстенә ниндидер салкын тимер кисәге тиеп китте. — Нәрсә бу?! — Галина егет муенында эленеп торган чылбырлы алтын айны учында тотты.

— Талисман. Беренче получкадан алдым. Ә синеке нәрсә? — Мәдияр, кызның муеныннан читкә салынып төшкән алтын тәрене ике бармагы белән уйнатты.

— Унсигез яшемә әтием бүләге.

— Улыбыз тугач, муенына нәрсә элербез икән? Икесен бергәме?! — диде дә тынды кияү. Ул хәзер бәхәс кузгатырлык халәттә түгел иде.

Әгәр мөмкинлек бирсәң, яңа парлар «мәхәббәт сарае»нда ничә көн буе бикләнеп ята алырлар иде икән? Мөгаен, өч көннән ары түзмәсләр...

Галина, буяу карандашлары белән дәфтәрләр тутырылган сумкасын туй бүләкләре арасыннан көчхәл белән эзләп табып, балалар бакчасына ашыкты. Дәү балалар төркемен беренче сыйныфка керердәй мәктәп баласы итеп үстерәсе бар. «Мәхәббәт сарае»нда үткән өч көн өчен программаны куаларга туры килер әле.

Мәдияр-Михайло, өстәлләрне сүтеп, кунаклардан калган чүп-чарны себереп чыккач, кинәт эшсез калды. Ул Осадчийларның көнкүреш мәшәкатьләренә иярә алмады. Сергей Иванович, булачак бораулау осталары яныннан кайткач, Михайлога Фазыл хлопчиктан сәлам әйтә дә, каеш алъяпкычын бәйләп, дуңгыз сараена кереп югала. Кияү аңа ияреп дуңгызлар арасында йөрми, хатынын балалар бакчасыннан каршы алырга китә.

Якшәмбеләрдә Фазыл Осадчийларга утырмага килә. Укытучысының өендә кунып калырга теләмәсә дә, көнозын дигәндәй кунак була. Андый көннәрдә Михайло тагын Мәдиярга әйләнә.

Хатынының корсак ялына чыкканын өйдә көтеп ятмасын өчен, Сергей Иванович пропискасыз кияүне дуслар аша йортлар идарәсенә сантехник итеп урнаштырды. Михайло моңа бик сөенде. Әле язга чаклы Галинаны алып китеп булмый. Сигезәр сәгатьләп саный торгач, көннәр тизрәк үтәр, ни дисәң дә, эш урыны су һәм торбалар тирәсендә.

Мин сезнең шәһәрдә укып киткән идем, бер кызыгызга гашыйк булып тагын килдем, дигәч, яңа хезмәттәшләре беренче көнне рәхәтләнеп көлгәннәр иде. Хәзер көлмиләр. Михайло су юлын белә, пычрак эштән курыкмый, җирәнми. Ә җирәнердәй көннәр бар... Батайск шәһәре саз өстендә утыра, туфракны күтәреп, җирне тигезләп кеше яшәрдәй урын иткәннәр. Ләкин өске сулар шултиклем якын, торбалар тыгылган чакта канализация коелары сазлы су белән мөлдерәмә тулган була. Шул пычракны чиләк белән түкмичә, кое төбенә төшәлмисең. Җирәнмәде, зарланмады Михайло, чөнки вакытлыча дигәндә, адәм баласы моның ише кыенлыкларга түзә ала. Йортлар идарәсенең кызыл почмагын душ иткәннәр. Эштән соң хатыны янына гел юынып, кырынып кайтып керде ул. Көндез нинди чокырларда торба чистартып ятканын белмәделәр дә хәтта...

## Галя, Галя, Галия...

Корсагы борынына җиткән марҗа хатынын ияртеп кайтканда, Шүләнгер бакчалары ак чәчәккә күмелгән, каз бәбкәләре чирәмгә баскан, көтүләр чыккан, чәчүлек бәрәңгеләр үргән иде инде.

Дон күпереннән Нократ кичүенә чаклы ерак кайту юлын үткән Мәдияр үзенең хәләленә җае килгән саен алдан ук үгет-нәсихәт бирде: «Бусагадан атлап керү белән «Исәнмесез?» диярсең. Киткәндә үзеңә «Хуш!» диярләр. «Гафу итегез!», «Рәхмәт», «Ярар» кебек сүзләрне тизрәк өйрәнсәң, бала туганчы чүкердәшеп яшәрсең. Чын татар кешесе буласың килсә, иң мөһиме: теге, бу, ни, менә, шушы нәрсә кебек алты-җиде сүзне хәтерлә, сине бөтен җирдә аңларлар».

Танышканда киленнең:

— Мин — Галя, Галя — я, — дип әйтүен Ярулла бабай бик ошатты, улы өчен сөенеп туялмады.

— Һи, Галия икән бит, хәзер ана телен белмәгән кызларга исең китәсе юк, — диде.

Хезмәт кенәгәсендә өзеклек чыкмасын өчен, Мәдияр Нократ кичүендәге паромга урнашып торды. «КамАЗ юлы» кисеп чыгасы урында таш күпер салалар иде, шуңа күрә җүнлерәк эш тапкан ирләр паром ябылганны көтмичә үк үз җайлары белән китә тордылар. Сезонлы эш дип артык борчылмады Мәдияр, Галия бәби тапкач, Казанга күчәрбез, диде, Фазыл укып кайткач, үзен эзләячәкләренә бик нык ышана иде ул.

Бәләкәй Регинаны Шүләнгер кызы дип теркәп куйгач та, ике ай вакыт үтеп китте. Галия, көн саен искә төшереп зарлануына карамастан, зур шәһәргә күчеп яшәү хакында җитди вәгъдә ишетә алмады.

Ниһаять, тынычлыгы-муллыгы, җылылыгы белән сөендереп торган җәй холыксызлана башлады. Кояшны сагыш каплады. Көннәр дә сап-сары хәзер. Мамадышның Тирәк яфраклары өстеннән, сары буран туздырып, йорт казлары күтәрелә. Җиләкле аланнарны бәс сарды. Җәй буе тарих серләрен җылыткан Пугачев тауларына сукмаклар сүрелде. Язга чаклы өяз ягында калдырырга теләгәндәй, төнге салкын иске паромны боз белән яр читенә ябыштырып куя — эш башлаганчы төртке белән ваткаларга туры килә. Кисәк туңдырып җибәрсә, кичүгә ышаныч юк дигәндәй, халык әйләнгеч юлга күчте, хәрәкәт азайды. Паром Нократның ике яр арасында сагыш ташып йөри. Көз салкыны елганың йөзенә чыккан...

Малай тумыйча — өйләнгәнеңне белмисең, кызың тумыйча — әти дип горурлана алмыйсың. Әти кешенең җаны кыз балада... Эштән кайткач, Мәдиярның юынырга да сабырлыгы җитми. Ишектән керүгә, каршысына килеп баскан Галиянең кулыннан биләүле «сөйдергеч»не ала, ике айлык кызчыкны исни-исни сөя, күккә чөя, кулында йоклатып яңагына сыендыра.

Ә бүген, ишектән керүенә, Галинаның бер кулында биләү, икенче кулында телеграмма... Фазыл үз эшенең остасы булып кайткан. Ул укыган арада эшсез йөргән Мәдиярга канатлар үсте...

— Менә күрдеңме, Галия, Фазыл безне онытмаган! Минем: «Бүтән бораулаучы эшенә аяк та атламыйм!» — дип ваз кичәргә теләүләрем тукран тәүбәсе генә ул. Яраткан һөнәрне, шушындый дусларны ташлап буламы?! Менә күрерсең, ярты ел үтмәс, безгә Казаннан фатир бирерләр...

— Тагын ярты ел көтәргәме? — дип күпсенде Галина.

Әйтерсең лә шәһәрдә буш фатирлар өелеп ята...

— Ярты елмы, берме, күчкәнче, әти-әни янында михнәт күрмичә генә түзәрсең.

— Бәлки, алдан ук Казанга күчә торырбыз, ә?! Тулай торакларда урын бетмәс әле. Гел начальствоның күз алдында булырбыз. Мәдьярчик, милый мой, үз йортыбыз белән яшәсәк тә, мин бит тумышымнан шәһәр кызы. Җылы туалетларны, төн уртасында краннан агып торган кайнар суларны, биек үкчәле туфли киярдәй асфальт тротуарларны сагындым... — Һәм Галина борынын пыршылдатып алды... — Әтине, әнине сагындым, аларның әле Регинаны да күргәннәре юк, — дип, шундук балавыз сыга башлады.

— Ярар, — диде Мәдияр, бала карап авыл өендә бикләнеп яткан хатынын юатырга теләп, — мин каршы түгел. Әүвәл үзем барып эшне яңартыйм әле, озак тотмам, сине алып китәрмен.

Казаннан килгән телеграмманы Ярулла бабай хат ташучы кулыннан алгач та укып чыккан иде. Килен белән малае арасында зур сөйләшү барлыгын сизенепме, ул бүген лапаста өч ел буе кипкән каен утыныннан мунча яктырды. Эченә карлыган ботагы белән мәтрүшкәләр бәйләп ике каен миллеге кертеп куйды. Бәби туе ясый калсак дип, чүлмәк утыртканнар иде, мичкәдән бер литрлы банкага коры сыра агызып килененә бирде:

— Мә, кызым, чарачадагы чиләкле суга батырып куй, суынсын бераз, — диде.

Гаиләнең бөтен мөһим планнары мунчада хәл ителгәнне хәтерли әле Ярулла бабагыз. Мунча ир белән хатынның тәнен дә, җанын да йомшарта... Малай безне карт көнебездә килен хөрмәтеннән мәхрүм итмәс, Казанга алып китәргә ашыкмас, диде. Галия «әти-әни» дип күңел күрерлек кенә татарча белә, шул җиткән. Хохлушкамы, ар кызымы, хет чуаш, хет мукшы булмагае, аның изүе ябык — муенындагы тамгасы безгә күренми...

Телеграмма алып килгән бәйрәм иде бу. Галина, бер аяк басасы җиргә биш басып, мунчада алыштырырга киемнәр әзерләде. Бала чүпрәкләрен үтүкләде. Гаилә өстәл артына утыргач, каенана кулыннан сосманы алып, ашны үзе бүлде.

— Бала уянгач, мунчаның кызуына без керербез. Юындырып биргәнче, чарачада көтеп торырсың. Аннары әнкәйгә илтеп кулына тапшырырсың. Озак йөрмәссең, син кермичә, себеркеләрне пешерми торам.

Бу сүзләрне килен кеше күбрәк каенана өчен әйтте. Бәби туганнан бирле бала юындыру Мәдияр кулына эләкмәде. Мунча ягылган көннәрдә ике ана бергә кереп алмаш-тилмәш юындылар. Ләгәнле суда тәне шифага кинәнсен дип, чиратлашып коендырдылар. Һәрхәлдә, моңарчы шулай иде. Бүген килен кагыйдәне үзгәртте. Аның Мәдиярга бәйнә-бәйнә аңлатуы үзенчә хәйлә иде — ягъни каенананың колагы ишетсен, яшьләр парлашып керә бүген...

Баланы өйгә илтеп тапшыргач, Мәдияр мунча белән ике арага салынган чирәмле сукмактан үткәндә җиргә басмады бугай... Чарача ишегенең келә шалтыравына мунча эченнән гыйшыклы тавыш ишетелде.

— Милый мой, синме бу?

— Юк. Мин түгел...

Галина сәерсенеп мунча ишеген ачып карады. Беркем күренмәгәч, чарача келәсен тикшермәк булды, ләкин өлгермәде, ишек артында качып калган Мәдияр аны арттан килеп кочаклап алды. «Юк. Мин түгел...» дигәнче, өч сүз эчендә чишенеп беткән иде инде ул.

— Ой! — дип курыккандай итте Галина. — Монда булмый. Әйдә, эчкә керәбез.

— Анда эссе, хәл бетә.

— Алайса, тыныңны чыгарма.

— Әйе, әйе... Өйләнгән көнне дә бу чаклы сусамаган идем мин сиңа. Сагыну җыелды. Теге «Мәхәббәт сарае»нда ниндидер курку, шикләнү бар иде. Бүген бары тик сине сөяргә теләү генә. Мин синнән башка яши алмыйм хәзер. Озак көттердең. Врач ике генә ай тыелып торырга кушкан. Ә безнең инде ике ай да дүрт көн узды... — дип, өзек-өзек пышылдады Мәдияр.

Галина ирен бүлдермәде, һәр сүзнең чын күңелдән әйтелгәнен кайнар тәне белән тоеп торды. Әгәр алар каенана-каенатасыз аерым яшәсәләр, Мәдияр, мөгаен, түзмәс, врач киңәшен санга сукмыйча, әллә кайчан үгетләгән булыр иде инде. Әле ярый, төннәрен салкынайткач, верандадан керделәр. Хәзер биш почмаклы өйне пыяла ишек бүлеп тора. Ялынып-ялварып тавыш күтәрсәң, онытылып ыңгырашсаң йә ләззәтле ымлыклар ычкындырсаң — эрләшәләр бугай, араларына керим дип, Алла сакласын, каенанаң өстеңә килеп керер. Шуңа күрә бу санаулы көннәрдә ике арада бала ятты. Ниһаять, «карантин» чорын үтеп яңадан кавышкач, Мәдиярның тыела алмыйча сөйләнүе аңлашыла. Сөйләсен! Назлы сүзләрне үзең сөйләүгә караганда, сөйгәнеңнән ишетүе ләззәтлерәк.

Галина кыш күрмәгән кеше түгел. Ул туып үскән якларда йомшак кышның кары азрак та, җилләре зәһәррәк. Вятка буенда яуган карны исәпләсәң, Дон буйларына ул өч-дүрт кыш өчен җитәр иде. Тегендә кар яуса, яшеллек юкка чыга, ә монда чаңгы таягы күмелерлек көртләр өелсә дә, урманнар яшел. Якты урманнар авылга киләсе ярсу җилләрнең егәрен тыеп тора. Шүләнгердә кар тынлыгы. Мал-туар, ашар өчен генә уянып, түшәлгән салам өстеннән ерак китми. Этләр дә өрергә иренә.

Кышка кергәч, Шүләнгер үз гаменә бикләнеп, Себер урманындагы ялгыз хуторга охшап кала. Җәй буе кабык җөбетеп мунчала каезлаган юкәчеләр дә базарга йөрүдән туктый. Көзен сатылып бетмәгән бал аертылмаган килеш кәрәздә кала.

Галинаның иң курыкканы — юл өзеге. «Не дай бог» балаң ныгытып авырып китсә, трактор чанасына салып Мамадышка илтеп җиткергәнче, ярты юлда ук җаны чыгар. Регина ялгыш төчкереп йә йөткереп куйса, Ярулла бабайларда ыгы-зыгы куба — бөтен белгәннәре юкә чәчәге белән зәңгәр мәтрүшкә кайнатып эчертү. Медпунктка алып барсаң, фельдшер пенициллин кадаудан арыны белми. Ике айлык баланың укол энәсе төртерлек тәне дә юк бит әле.

Җәй көннәре, атнага бер килеп, «передвижка» кино күрсәтә күрсәтүен, ләкин татар хатыннарына ирләреннән башка клубка чыгарга ярамый икән. Кыш көне ике өйнең берсенә телевизор карарга йөриләр. Мәдияр өй борынча йөрмәскә кушты, телевизорны үзем алып кайтам, Казаннан фатир алгач, өй җиһазы итеп күчербез, диде.

Озын кичләр кыскарсын дип, авылның бөтен хатын-кызы кул эшенә тотына. Борынгыдан суык бәгырьләренә үткән — бәйләгән нәрсәләре — йон оек, мамык шәл, гамаш, бияләй, джемпер. Галия киленгә җылы кием кытлыгы юк. Ул челтәр бәйләргә өйрәнде. Мендәр өстенә капларга дип унлы кәтүк җебеннән зур кар бизәге үрде.

Мәдияр кайтырга чыкса, машина тавышын күрше авылдан ук ишетеп алалар бугай...

Ләкин сирәк кайта егет. Кышкы суыклардан көннәр кысылды, вакыт тыгызланды. Җәй көне сигез сәгатьтә өлгерердәй эшләр хәзер атналар буена сузыла. Иртән двигательләрне, пычрак насосны ачык ут белән җылытып, радиаторларга кайнар су салып, ниһаять, бораууларга керештек дигәндә генә, инде кич җиткән, дөм караңгыга калганчы суларны кире агызасы, инструментларны җыеп өлгерәсе бар. Хатынны сагындым дип, су ташучы машинаң белән Шүләнгергә кайтып китсәң, әйләнеп килгәнче өч көн үтә. Ул арада бригада эшсез торырга тиеш. Әле буран чыкмаса ярый. Мамадышка Казаннан бердәнбер коридор Теләче — Тәкәнеш аркылы уза. Йөз җитмеш чакрымлы араның яртысы текә тау, яртысы җәяүле

буран оясы. Әби патша салдырган ташлы юлның түшәүләре исән калган урыннарда гына бераз хәл ала-сың. Мамадыштан Шүләнгергә җиткәнче дә утыз биш чакрым буе бульдозер көтәсе бит әле.

Галина ирен Казанга чыгып киткән көненнән көтә башлый. Кызын беләгеннән төшермичә, тәрәзә-дән тәрәзәгә йөри. Ләкин Мәдияр биш тәрәзәнең берсендә айлар үткәч кенә пәйда була. Ул кайткан са-ен, Регинаның һөнәрләре арта. Теге телеграммадан соң урап кайтуында, кызлары йөзтүбән салган җир-дән башын күтәреп матаушты. Икенче кайтуында — мендәргә сөяп куйган җирдә утырып тора. Яңа ел алдыннан чыгыр эчендә тәпиенә басты. Сигезенче март бәйрәмендә йөреп күрсәтте. Ә туган көнендә әнисенә җавап кайтарырлык сүзләр эзләп тапты. Кыскасы, Мәдияр өчен Регина күрше баласы кебек тиз үскәндәй тоелды. Галина биш тәрәзә арасында яшәүнең, елга унике тапкыр гына сөелүнең, исән-сау ки-леш әтием, әнием дип әйтер кешеләреннән мәхрүм булуының ни икәнен үзе генә белә иде. «Казанның яңа төзелеш районында — Икенче Таулар бистәсендә Мелиорация министрлыгы өчен дүрт подъездлы өй сала башлаганнар, начальник көтәргә куша» дигән вәгъдә Мәдияр кайткан саен кабатлана торгач, инде иске әкият булып яңгырый иде. Көтәргә кирәк, фатирны да, ирне дә көтәргә. Вятка буенда көттең ни дә, Дон буена чыгып көттең ни... Мәдияр янында Галия булдың ни дә, Галина янында Михайло бул-дың ни...

## Коры елның тузаны...

1972 елның язында ут белән су бергә кушылды.

Март ахырында ук җылы яңгырлар явып, Нократ ярындагы бөтен карны шулпалады. Ашыгып ак-кан гөрләвекләр зур елгага төшеп өлгерде, ашыкмаганнары җиргә сеңде. Ел фасыллары бер-берсенә һө-җүм итте, — апрель азагында ук июль чилләсе башланды. Чишмәләрнең гайрәте сүрелгәч, инешләр хәлсезләнде, хәлсез инешләрдән зур елгалар саекты, диңгезләр оеды.

Казанның эшче һәм интеллигенциясе, яшел отрядларга берләшеп, Татарстанның утыз биш районы-на юл алды. Урман куелыгында күләгә дымына сөенеп яткан тереклек ияләрен өркетеп күгәргән чалгы-лар уйнады, дистә еллар буе онытылып яткан ураклар юкә, тал, усак һәм имән ябалдашларын кыйды, көн кызуында кикереп яткан симез саз тирәләреннән ике чиртеш калынлыгы кәз каезланды. Һәм бары-сы да силос базларына тутырыр өчен турагыч машиналар авызына ташланды.

Юлларда көннән-көн тузан калынайды. Машина үтеп китсә, ярты сәгать буе күз ачкысыз томан эле-неп тора. Чирәмлек өстендәге намазлыкка маңгай орып, Ходайдан яңгыр ялварулар, бер атна буе ява-чак яңгыр турында төш юраулар, балалар көн саен диярлек оештырган «карга боткалары» корыган өметләрне сугармады. Су табигатьнең үзеннән артмады. Әйтерсең лә чиллә үзе дә сусаган, ул, кешеләр өлешенә кереп, туктаусыз су эчә иде.

Кайда су күрсәң — шунда эчәргә тотынасың.

Корылык артезиан коесы бораулаучыларның яшәү рәвешен үзгәртте. Бригадалар дошманга каршы күтәрелгән хәрби халык кебек өйгә кайту юлын онытты. Ел фасылларының дөрес килерлегенә исәп то-тып алдан ук расланган планнар чигерелде. Фазыллар хәзер иртәгә нинди фәрман киләсен, кайсы авыл-га күчеп эшлисен дә белми. Чөнки «Обком кушты», «Министрлыкның махсус карары бар», «Идарә на-чальнигы рөхсәт итте» дигән зур күрсәтмәләр хәрби приказ кебек яңгырадылар.

Әмирнең биштәр күтәреп эштән бөтенләйгә китүенә инде ике ел була. Фазыл, укып кайтып, брига-дага үзе хуҗа булгач, өченче кешене алырга ашыкмады. Әмир ял итеп алҗыр да ияләнгән эшенә яңадан сагынып килер кебек иде. Куркынычсызлык техникасы буенча җаваплы инженер Фазылны күргәч, бер-ике тапкыр искәртте инде, бригадаларда ким дигәндә өч кеше исәпләнергә тиеш, диде. Без, авылларга баргач, шундагы егетләрне яллыйбыз, әлегә шулай ерып чыгарбыз, дип аклангач, тагын онытып тора-лар... Бригадага яңа кеше алу — балалар йортыннан тәрбиягә нарасый алу белән бер бит ул...

Гадәттә, кое борауланып беткәч, акча күчерергә тиешле оешма белән «процентовка» дип аталган исәп-хисап кәгазьләре тутырыр өчен генә килә торган прораб Сәфәров бу юлысы эш башланганчы ук килеп басты. Бостон пинҗәген салып, вагон сандыгыннан эш киемнәре эзләтте. Әмирдән калган сатин комбинезон, киндер бияләй, кирза итек таман гына иде аңа. Прораб, җае килгән саен, бораулаучы бу-лып эшләгән яшьлек еллары белән мактанырга ярата иде. Димәк, югарыдагылар ишеткән моны, булы-шырга кушканнардыр. Корылык елының фәрманнары да коры...

Мелиорация министрлыгыннан пенсиягә чыгып, көчен кая куярга белмәгән Каратаевка электр при-борлары заводының директоры урынын биргәннәр иде. Яңа эшкә күчүенә карамастан, бораулаучылар-ның җәйге маршрутын үзгәртеп, чиратсыз-нисез су скважинасы казытырлык кына сүзе үтә иде әле аның.

Гомер буе ерак районнарга, чит авылларга күченеп эшләргә ризалашкан егетләр кинәт Казанга кай-тырга күрсәтмә алгач, әллә ни сөенеп өлгермәделәр. Күз-кул астында эшләүдән бизеп гел иркен яшәргә өйрәнгән кешене бер көн эчендә «серле» завод кысаларына күчерсәң, кыен икән ул. Кояш сәгате белән яшәргә күнеккән Фазыл, төгәл иртәнге җидегә завод капкасына килеп басар өчен, вакытның калыбына сыеша алмады. Элеккеге министр алдында оятка калмас өчен, ул берәр сәгать алдан килеп баса һәм

смена алышыныр чак җиткәнче капка төбендә көтеп тора иде. Мәдияр исә, вакытлыча Киндерледәге тулай торакта яши һәм, билгеле инде, яртышар сәгатькә соңга калып йөри. Соңга калгач, аны заводка кертмиләр. Ул, табель тутыру бүлегенә барып, үзенең цех эшчесе түгел, ә Су эшләре төзелеш-монтаж идарәсеннән чакыртылган ирекле бораулаучы икәнлеген исбат итәргә, каравылчылар начальнигы рөхсәте белән Каратаевның урынбасарына акланырга тиеш. Шуннан соң гына проходнойдан эчкә уза торган коридорның дүрт канатлы тимер күбәләге сине чакырып ала: «Миннегалиев, проходите!..»

Үч иткәндәй, завод мәйданы ундүрт метр калынлыгындагы ком өстендә утыра. Бораулый башлаган коең җимерелмәсен дисәң, туктаусыз су ташырга, комлы катламнарны кызыл балчыклы измә белән өзлексез тутырып торырга кирәк. Су ташучы машина аерым капкадан йөри. Кергәндә, юл кәгазьләрен тикшерсәләр, чыкканда, кабиналарны тентеп, ачкыч тартмаларына чаклы актарып, су мичкәсенең капкачын ачтырып, үзеңне капшап чыгаралар. Кайбер көнне бу тамашаны җидешәр-сигезәр тапкыр кабатларга туры килә.

Корылык кызган саен, түрәләрнең боерыгы күбәйде.

Каратаевның: «Ашаганыгыз-эчкәнегез чишмә суыннан булыр!» — дип, завод халкы алдында биргән вәгъдәсен ком эчендә калдырып, Фазыл бригадасын ашыгыч рәвешчә «КамАЗ юлы» төзүчеләре янына җибәрделәр. Долотоны борауланып бетмәгән скважинадан тартып чыгарганда, Каратаев сүгенеп калды:

«Хатыны өстеннән ирен сөйрәп төшергән кебек иттеләр, билләһи!..»

Юл салу — илләр-җирләрне яулап алуның бер төре.

«КамАЗ» кендеген Мәскәүдән өзмәс өчен олы юлны «Каздорстрой» тресты сала иде. Куштырнаклар эченә алынып, кар көри торган көрәк чаклы фанерага язылган әлеге сүзнең «...дорстрой» дигәнен аңлавы кыен түгел, ә «Каз...» дигәне исә аның Казан түгел, Казакъстаннан килгән юл төзүчеләре булып чыкты.

Йөгәнсез дала җилләреннән алҗыган халыкны, озын автопоездлар белән күчереп йөртә торган вагоннарга урнаштырып, үзәнлеккә тезгәннәр. Фазылларның яшел вагоны кызыл «вагонград» янында ятимләнеп калды.

Казан ягыннан санаганда туксанынчы чакрым иде бу.

Рәт араларында машина белән йөрергә уңай булсын дипме, вагоннарны иренмичә тигезләп тезгәннәр. Электр чыбыкларын күтәреп торган баганалар арасында усак агачлары да туры килгән, ахрысы — андыйлары төптән мыек чыгарып, яфрак ярып маташа. Димәк, болар монда көздән бирле яши инде, дип уйлап куйды Фазыл.

Механизатор ирләрен яңа юл буйлап эшкә озаткан киң маңгайлы, кысык күзле, чем-кара чәчле ханымнар, татарлар аңларлык телдә сөйләшеп, су кайнаталар, утын яралар, кер юалар. Шундый ук маңгайлы, чәчле һәм күзле малайлар, аяк астында буталып, уен оештырган, уенчыклары — машина-трактордан коелган тимер-томыр.

Шушындый челләдә учак янында маташуларын аңлап була — ут янында су бар! Балаларның кечерәкләрен, авызы зур итеп кисеп алынган калай мичкәләргә тутырып, җылы суга җебетергә салганнар. Алар юынып чыккач, зурракларга чират җитә.

Әниләре читкә борылган арада, малайлар буржуйка авызына консерв савыты белән солярка сибеп өлгерәләр һәм калай морҗадан гөлт итеп кисәк бүселеп чыккан кара-кучкыл ялкынлы төтенгә кумәкләшеп, «һа-а!» дип куаналар. Әниләре балчык ата-ата аларны ут яныннан куа, тегеләре тагын качкан була. Күптән уйныйлар, күрәсең, мич тирәсендә тиз генә кулга алып ыргытырлык балчык кисәкләре дә калмаган, малайларның битләре дә әниләренекенә караганда корымлырак иде.

— Суны каян ала икән болар?

Әмир киеменә керсә дә, Сәфәровта прораблык позасы исән, Мәдиярга җавапны озак уйлап тормады:

— Әнә паровоз чаклы тагылмалы мичкә бармы — шуннан!

— Дегеткә баткан ич ул, аннан буялмыйча ничек су алырга кирәк? — дип кушылды Фазыл.

— Эче чистадыр. Су кытлыгы булмаса, безне чакырмаслар иде.

— Юлны төзеп бетереп күчеп китсәләр, безнең скважина әрәм каламы? — диде Мәдияр.

— Сез, агайнеләр, башта суны чыгарып бирегез әле, аннан кайгырып утырырсыз. Боларга су күп кирәкми, тизрәк кирәк. Сигезенче номерлы долото җитәр. — Сәфәров, үзе биргән күрсәтмәне үзе гамәлгә ашырып, арбадан өч сырлы тәгәрмәчле долотаны җиргә ыргытты. — Җир астыннан чыкканына бер көн үтмәгән, кызыл балчыкка баткан да каткан бу.

— Хәзер майлыйбыз аны, — диде Мәдияр, — суда җебетәбез дә чүкеч белән кыйныйбыз.

Прораб-бораулаучы Сәфәров, юл төзүчеләрдән соң яңадан Каратаев заводына кайтып, башланган коены бораулап бетерәбез, дигән иде. Ләкин бер көнгә алданрак «Җиде күл» совхозының директоры килеп өлгерде. Аның кулында мелиорация министры имзасы куелган рәсми приказ бар иде. Тагын срочно!

Казанга терәлеп торган «Җиде күл» — кәбестә үстерүгә көйләнгән хуҗалык иде. Бөтен хикмәт тә шунда, кәбестә ул җәй уртасында көнгә унышар литр су эчмәсә, үсә алмый. Һәм атналар буе ял күрмәгән бригадага, утка ташланган янгын сүндерүчеләр шикелле, кичекмәстән «Җиде күл»гә күчәргә кирәк иде.

## Сөенеп калды Зөмәйрә

Регинаны урамга алып чыккан җиреннән ишетеп кайтты Галина — иртәгә рәиснең брезентлы «уазиг»ы Мамадышка техосмотр үтәргә барачак икән. Колхоз бухгалтеры белән медсестра янында бер буш урын кала, ди.

Әле Мәдияр киткәнгә атна-ун көн генә вакыт үткән иде. Галинаның, Казанга барып, иренең эш урынын күреп кайтасы килде. Бәлки, начальствосы белән дә сөйләшергә насыйп булыр, ни дисәң дә, бала күтәргән хатынның ялваруы, ирләрнең горур гозереннән көчлерәк тәэсир итәр. Ярулла абзыйлар күпме генә үгетләсә дә, килен баланы үзеннән калдырмады. Иртүк торып документларын барлады, җитәрлек акча алды, бала киемнәрен салып, җиңелчә сумка асты. Рәис машинасына соңга калмас өчен колхоз идарәсе янына ашыкты...

«Әйбәт кенә яшәп торганда...» — дип, карт белән карчык бик еш искә төшерерләр әле бу иртәне. «Какмадык-орынмадык. Тәк томалдан, кисәк уйлады да китеп барды. Әйтәм аны дукаментларын җыйды... Баланы да калдырмады. Бу хәтлек акча нигә кирәк микән аңа, дип уйлаган идем аны... Һай, хәзерге яшьләрнең тешләклеге — тел яшермичә бәхилләшеп китсә ни булган... Ичмасам, оныгыбызны туйганчы сөеп кала идек...»

Рәисне йөртүче малай, кичен әйләнеп кайткач: «Ярулла бабай, килененңне Казан автобусына утыртып җибәрдем!» — дип, тәрәзә аша кычкырып узды. Ул көнне өйдәгеләр аны-моны уйламадылар. Айлап кайтмый торгач, Ходай кушып, берәр бүлмә биргәннәрдер әле, дип юрадылар. Көннәрдән бер көнне Мәдияр су ташый торган машинасы белән берүзе генә кайтып төшкәч... Карт белән карчык бухгалтерга, медсестрага, рәискә һәм аның шоферының өенә барып допрос оештырып йөрделәр: «Киткән көнне килен берәр сүз әйтмәдеме? Юлда еламадымы? Безне орышмадымы? Кунакка-фәлән Ростовка барам, димәдеме?..» Кыскасы, сораулар күп, тик ул сорауларга «юк!»тан башка җавап юк.

Галина Казанның татар зираты артындагы бораулаучылар конторасын эзләп тапканда, эш көне бетәргә ярты гына сәгать вакыт калган иде. Хезмәткәрләрне Киндерле бистәсенә илтергә тиешле вахта автобусы инде капка төбенә килеп ишеген ачып туктаган. Эшен алданрак төгәлләгәннәр берәм-берәм җыела.

Мәдияр Миңлегалиевның хатыны мин, дигәч, контор хатыннары вахта автобусына урынсыз калуларын да онытып, төсе-бите белән этисенә охшаган бер яшьлек кызны кулдан-кулга йөртеп сөйделәр, аннан әнисен әйләндереп-әйләндереп карадылар, татарча аралашуына ышанмыйча, юк-бар турында сөйләндерделәр. Яңа уенчык белән уйнап туйган сабый бала шикелле, соңыннан яшь киленне кадрлар бүлеге инспекторы Зөмәйрә янына кертеп куйдылар.

Инспектор кыз, эш сәгате беткәндә чит кешеләр йөрмәслегенә ышанып, ишеккә җилкәсе белән баскан да, әрдәнәләп өйгән чәчен төзәтә, түгәрәк көзгене иренәнә терәп, баш бармак юанлыгы көпшәдән иннек яга иде. Борылып баскач, ул, бала иярткән һәм алҗыган чырайлы яшь ханымны күреп, каушап калды.

«Тагын алимент сорап килүчедер» дип уйлап куйды Зөмәйрә. Ләкин вәкаләтенең кагыйдәсе кушканча, уйларын сүз белән әйтмәде.

— Сезгә кем кирәк? — диде Зөмәйрә, үзе кирәкмәгәнне сизенеп.

— Мәдияр...

— Кайсы Мәдияр? — Автобуска ашыгу гаме белән буталганга, Зөмәйрә «алимент түләргә тиешле» кешене тиз генә искә төшерә алмады.

— Гафу итегез, — диде ул бераз уңайсызланып, — без үзебезнең эшчеләрне фамилияләре белән санарга күнеккән.

Галина үзенә карата ышанмау дип кабул иттеме — загс кәгазе белән паспортын чыгарды, ләкин бирергә ашыкмады.

— Без Мәдияр белән Батайскида язылыштык. Ул сезнең оешмадан укырга килгән иде. Аннан ул мине Мамадышка алып кайтты, шунда бәбиләдем. Минем әти бораулау осталары әзерли торган мәктәптә укыта.

— Зинһар, гафу итегез, — диде Зөмәйрә, сүзнең җитдилегенә төшенеп. — Сез, мөгаен, Фазыл Шәмсетдинов бригадасындагы Мәдиярны әйтәсездер.

— Әйе, әйе! Фазыл! Ул әле безнең туйда шаһит булып утырды.

— Баштук әйтәләр аны, гафу, исемеңне ишетми калдым.

— Галина Осадчая. Ну, Шүләнгердә Галия Миңлегалиева булып яшим. Авылдан районга, аннан Казанга килеп җиткәнче кич җитте. Эш сәгатегез беткәнгә охшый. Иртәгә иртән килермен.

— Казанда туганнарың бармы соң?

— Каян килсен. Абдурахман Абсалямов этием белән бергә Карелия фронтында сугышкан. Татарстанда башка кешене белмим.

— Мин эти кызы, дип, язучы өенә барып керүе читен инде. Ә гостиницалар мәсьәләсе Казанда бик читен, оешмалар исеменнән хат язып, берәр көн алдан заявка бирмәсәң, буш урын табу мөмкин түгел... Беләсеңме, без хәзер миңа кайтабыз. Мин әнием белән генә яшим. Әйдә, — диде ул, Галинаны ирексездән ашыктырып, — автобусыбызга өлгерәбез әле.

Һәм Зөмәйрә, бәләкәч кызны күтәреп, урамга ашыкты. Көне буе юлда килеп алҗыган Регинаның чит апаны ятсынып шыңшырлык хәле калмаган иде инде.

Иртәгесен Фазыллар бригадасын ярты көн буе эзләделәр.

Баш инженер әйтә: «Миндә быелгы планның маршруты бар. Фазыллар бригадасы хәзер «Точмаш» заводының пионер лагерында», — ди.

Начальник инженерны сүгеп ташлады: «Эшчеләреңнең кайда эшләгәнен белмәгәч, ник йөрисең портфель күтәреп?! Миңлегалиев бригадасын срочный рәвештә «Нырты» совхозына күчердек!» — ди.

Эзли торгач, тагын бер билгесезлек ачыкланды: идарә управляющиеның шәхси әмере белән Фазылларга «Нырты»га барып җитәргә ирек бирмәгәннәр, бораулау агрегатын «Электроприбор» заводына кертеп бикләгәннәр, имеш.

Чынбарлыкта исә, завод капкасына килеп җиткәнче үк, бораулаучылар кәрванын министрның ак «Волга»сы куып тотты һәм, кәбестә басуын корылыктан коткарыр өчен, ашыгыч рәвештә «Җиде күл» совхозына җибәрде.

Галина кадрлар бүлеге инспекторының каршына эленгән расписаниеләрне күреп алды. Автобус, поезд һәм самолетлар йөреше турындагы мәгълүматлар аерым-аерым эленгән иде. Бүген сишәмбе көн, тагын өч сәгатьтән Ростовка самолет китәчәк икән. Мамадыштан килгән чакта аэропортны күреп калган иде ул — үзәктән троллейбус белән җиде-сигез тукталыштан ары артмас.

— Ярар, сезгә рәхмәт инде, — диде Галина, башына килгән яңа уйдан кабаланып, — кыр кешесен шәһәрдән эзләп кем тапкан?! Зарплата алгач, үзе кайтыр әле, өйдә генә көтеп ятыйм.

Гараждагы буш машина белән сөйләшеп, Зөмәйрә балалы хатынны Совет мәйданына чаклы илтеп куярга кушты. Теләче, Тәкәнеш, Мамадыш кешеләре юл уңае кайтучы машиналарны шунда көтә. Бу тукталышта төшеп, якында гына аэропортны күреп алгач, әй сөенер әле Галина...

Озатырга чыккач, капка төбендә Зөмәйрә сорап куйды:

— Ә Фазылның сезнең якта сөйгән кызы калмадымы?

— Юк... Ул беркем белән дә йөрмәде...

Ни өчендер Галинаның шушы җавабыннан сөенеп калды Зөмәйрә...

Үскән чакта, кеше әйберенә кызыксаң: «Каян алдың — шунда куй!» — дип, кулга суга торганнар иде безгә, сүз тыңламас, уеннан туймас, иләс-миләс малайларга, үгет-нәсихәт биреп, акыл өйрәтеп, әрәмгә күпме михнәт кичергән эти-әниләребез! Балачак уеннарында мавыгып, вак-төяк маҗараларга алыштырдык без ул гыйлемне.

«Милый мой! Кайтып җиттем. Эшкә урнаштым!» дип, Ростовтан телеграмма килеп төшкәч кенә аңлады Мәдияр, димәк, ул Идел ягында, ә Галина Дон ярында калды. Бу язмышның ике яры. Ярдан ярга күчәр өчен беркем ярдәм итә алмый...

Өйдән йөкле килеш чыгып киткән Галинаның бер яшьлек кыз бала ияртеп кайтуы сөенечле көенеч иде. Исән-сау кайткан, ләкин аерылмаган; ирне көтә, ә үзе эшкә урнаша; Регина марҗа кызына охшаган, тик фамилиясе дөрес итеп яза торган түгел...

Табын артында икәүдән-икәү генә калган бермәлне язмышның Идел — Дон каналын кичеп кайткан Галина Сергей Ивановичка гомер буе гаиләне сөендергән хезмәтеннән гайрәт чигерерлек сүз әйтте:

— Әти! Син бәхетсез ирләр әзерлисең! Мин синең профессияң корбаны...

## Бишкә – биш

Галинаның бөтенләйгә киткәнен белми иде әле Мәдияр...

Җир астында чүлләр юк, андагы комнар лай булып тора. «Җиде күл»дән әйләнеп килгәнче, Каратаев заводында төгәлләнмичә калган коеның авызы ишелеп бүрәнкәләнгән иде, бораулау агрегаты белән якын килеп иске эзенә бастырырлык түгел. Озын-озын калын такталар белән җиргә идән җәеп, эш урынын ныгытырга туры килде.

— Мин нәрсә әйтсәм, шуннан артыгын эшләмәгез! — диде Каратаев һәм сүгенү урынына илдәге хуҗасызлыкны эттән алып эткә салды. — Эшләнгән эшне ярты юлда калдыру — ялкау җәмгыять галәмәте ул. Тоташтан төгәлләп чыкмагач, ике-өч тапкыр мәшәкатьләрәк булачак хәзер. Һәр артык мәшәкать ахыр чиктә заказның бәясе артуга китерә.

Бораулаучылар каршы дәшмәде, акча түлисе заказчик белән дошманлашу — үзең утырган ботакка селтәнү кебек килеп чыга.

— Комның өске катламын унике дюймлы кондуктор белән ныгытыгыз! — Каратаевның тавышында җитәкчеләргә хас басым бар. Ләкин кыска җиңле, ачык изүле соры җитен күлмәген тирән төпле чалбарына кыстырмыйча гына кигән сандалилы әлеге агайның кайчандыр су министрлыгының хуҗасы булганлыгына читтән карап торучы берәү дә ышанмас иде. Бүгенге бораулаучылар да бу турыда инде ишетеп кенә белә. Безнең илдә кечкенә буйлы кәй-кәрләләрне зур урыннарга җитәкче итеп куймыйлар, партия уставы кушмый. Фазылдан да кечерәк булып калган күптәнге пенсионер Каратаевның директор кәнәфиенә куелуы «серле» заводның бер середер. Муены киң җилкәдән алга таба авып төшсә дә, ул йөзен текә тота, сөйләшкәндә әңгәмәдәшен күз карашыннан читкә җибәрми, хәтта ике-өч кеше белән берьюлы сөйләшергә кирәк булса да.

— Кондуктор дигән нәрсә трамвайда билет сатучы апаңнар гына түгел. Буровойда ул бөтенләй башка әйбер.

Һәм экс-министр, өйрәнчек малайларга дәрес аңлаткан остаз роленә кереп, сүзен дәвам итте:

— Өстә ком катламы калын булганда, алга таба борауларга комачауламасын өчен, аны юан торба белән ныгытып калдырырга кирәк. Аннан соң тынычлап эшлисең, йөз метрга төшсәң дә, скважина эченә ком ишелми. Аңладыгызмы?!

— Ие, ие, — диеште Фазыл белән Мәдияр.

Әле ярый Сәфәров, кәгазьләр артыннан куып, трестка китте. Өч ел эшләгән, өстәвенә махсус белемнәре булган егетләргә бораулау әлифбасы укытып вакыт әрәм иткән «бывший»га аркылы төшмичә түзмәс иде ул. Хәер, Фазыл да түзмәде.

— Сезнең сүзегез үтә. Кондуктор өчен кыска-кыска торбалар сорагыз. Базада бар алар, резервта ята.

— Нәрсәгә кирәк ул кыскалар? Юан торбаларны резьбага утыртуы бик авыр. Биш метр саен борабора ялгаганчы, унышар метрлы ике оч төшерүе тизрәк була. Ком өстендә бораулаганда, иң мөһиме — вакытны сузмаска кирәк.

— Минем әле ахырынача төшеп утырган кондуктор күргәнем юк. Ишелгән катламда тәртелеп кала да кисеп ташларга туры килә. Автоген белән кискән җирдә резьба калмый.

— Нәрсәгә соң ул резьба? — Каратаев, малай актыгын сөзәргә теләгән үгез кебек, текә йөзен җиргә төбәде.

— Эченнән шалтыр-шолтыр бораулый башлагач, кондуктор үз урынына төшеп кача. Резьбасы булса, аны эзләп табуы җиңел.

— Все! Җитте! Акыл сатма. Техникасыз заманда мин кулдан бораулап йөргәндә, син әле атаң башында булгансыңдыр. Мин ничек әйтсәм — шулай эшләгез.

Мәдияр белдекле кешенең күңеле кителмәсен, өйрәтсен дигән алымга күчте.

— Абый, мин аңламыйм, ник кондуктор дип атала соң ул торба?

Каратаев аңа якынрак килеп басты.

— Элеккеге агач трамвайларда микрофоннар юк, билет сатучы кондукторлар тукталышлар исемен атап кычкырып тора иде... Безнең кондуктор да юнәлеш биреп тора.

— Абый, йә, нәрсәдән башлыйк?

— Платформагызны тигезләгез. Дизельне кабызыгыз. Вышканы күтәрегез. Редуктор, ротор, картерларның маен тикшерергә онытмагыз, — дип тезеп китте Каратаев, диктант әйтеп яздырган кебек.

Күтәреп-төшереп дөмбәсләүнең файдасы тимәде — чынлап та, егерме метрлы юан торба билгеләнгән тирәнлеккә төшеп утыра алмады. Кагып карадылар, селкеткәләделәр, боргаладылар, әмма аның җир өстеннән артып калган өч метр чамасын барыбер кисеп алырга туры килде... Ә инде эченнән үтеп, алга таба бораулый башлагач, «башмак асты» юылып, кондуктор шуып төшеп китте һәм күздән югалды. Аңа хәзер ялгап та булмый, тартып чыгарыйк дисәң — тотар җире юк, җир астыннан торба башы эзли торган иң зур «колокол»ның юанлыгы җитми.

Фазыл дәшмәде, ахыры шушылай бетәсен алдан ук әйтер өчен әллә ни әүлия булуның кирәге юк иде. Комлык ул кайда да холыксыз.

— Абый, инде нишлик?

Каратаев хәзер Мәдияр белән генә сөйләшә.

— Менә, энекәш, кондуктор ерак түгел, эченнән бораулауны дәвам итегез, мин астан чыккан балчыкны үз кулларым белән тикшереп торам, су катламына җитсәк, әйтермен.

Алга таба да кызыл балчык катламы ком белән аралашып барды: йә ул сыек плывунга әверелә, йә шикәрләнеп ката. Проектта күрсәтелгәнчә, сиксән метрга чаклы төшеп тә Каратаев су катламын сизә алмады. Бораулаганда куерган су җир астыннан чыккан балчыкны гел үзе белән әйләндереп йөртә, шлам утырмый.

— Абый, инде нишлибез?

— Бу сиксән метрны да сигезле торба белән каплыйбыз.

— Алайса, ике катлы кондуктор булып чыга түгелме?

— Әйе, зыян юк. Сиксән метрдан соң Казан астында диңгез ята, аның суы бихисап.

— Ә проектны яшерәбезме?

— Проект ул банктан акча күчергәндә чыгымнарны чамалар өчен генә. Чын бораулаучы суны үзе эзләп таба. Тирәнгәрәк төшәсез икән — сезгә акчасы күбрәк килә.

Сиксән метрдагы диңгез ярыклы-карстлы таш арасында иде. Аны белгечләр төп катлам, дип әйтергә ярата. Ләкин Каратаев моңа сөенмәде.

— Скважинаны юдырыйк та анализга алып карыйк. Әгәр каты су булса — андые безгә кирәкми.

Башка вакытта су анализы өч көннән соң гына әзер була торган иде. Каратаев, санэпидстанциягә барып, үзе тикшерткән. Ярты сәгать эчендә әйләнеп кайтты. Ләкин алынган судагы магний белән кальций катнашмасы, гади генә итеп әйткәндә, юшкыны, рөхсәт ителгәннән өч тапкырга күбрәк иде.

— Абый, нишлибез инде?

— Шартлатабыз! — диде «серле» завод директоры. — Сез төче су катламын үтеп киткәнсез.

— Сез ни әйтсәгез, без шуны үтәп торабыз инде, абый.

Гомер буе су бораулап, скважина шартлатканны күрмәгән остазлар бар. Фазыл да әлеге авария очрагын дәреслекләрдән укып кына белә. Башта, махсус машина белән гамма-каротаж ясап, торба артында капланып калган су катламын эзләп табасы. Шул турыга буын-буын шартлаткыч бәйләме төшерелә. Ядрә урынына корылган корыч кадаклар көчле шартлау белән торбаны тишә һәм су йөри башлый... Моның өчен завод эшчеләрен эвакуациялисе юк, җир өстенә чыккан тавыш Чыршы бәйрәмендә атылган хлопушка чаклы гына. Ә инде серле завод эченә шартлаткычны алып керер өчен Оборона министрлыгының махсус әмере кирәкми. Шартлатырга килгән ике малайның дүрт кулына бер сумка. Ачып карагач, каравыл начальнигы:

— Нәрсә бу? — дип, вазифасын үтәү йөзеннән генә сорап карады.

— Электр кирәк-яраклары... — дигән җавап «серле» заводның җисеменә зыян китерердәй шик уятмады. Чынлап та, сосискалар чылбыры сыман бәйләнеп, төсле чыбыкларга уралган төргәк бик гади нәрсә булып күренде.

Шартлатучы егетләрне үз итеп «браконьерлар» дип үртәп йөртәләр. Моның ике сәбәбе бар. Беренчедән, су эчендә маташалар, икенчедән, сыйфатсыз, ягъни «бракланган» скважиналарны төзәтеп йөриләр.

«Браконьерлар», ярты сәгать эчендә гөрселдәтеп, утлы кояш астында исән-имин саклап алып килгән динамитларыннан котылгач, сулы күләгә эзләп, Үзәк парк ягына юнәлделәр.

— Абый, инде нишлибез?

— Теге сиксән метрдан соң бораулаган өлешне бетонлап куясыз, тозлы су үтеп кермәсен.

— Абый, цементлы измәне завод алып кайтамы?

— Юк, энем, үзегез әзерләрсез. Килешү кәгазендә «тампонаж ясау» дигән яңгыравык юллар бар. Цементлы измәне кулдан болгатып, бер кубометр бетон ыргытуны шулай купшы сүз белән алыштырганнар. Шуңа өстәп ике кондуктор арасына вак чуерташ тутырасыгыз бар — анысы фильтр өчен...

Бәхетсез прораблар бар инде бу дөньяда... Идән такталарыннан җыелган зур утлык янына егерме капчык яшел цемент китереп бушаткач кына, Сәфәров килеп җитте. И сөенде егетләр...

— Нишләп ятасыз шушы заводта һаман? Сезне ике көннән бирле «Нырты» совхозы эзләтә.

— Ныртыга юл юк, — диде Каратаев, һәм, цемент болгатыласы утлык янына өч көрәк кадап, кабынырга торган яңа бәхәскә алдан ук нокта куйды. — Каравылчыларга әйтеп куям, минем рөхсәттән башка сезне заводтан чыгармаячаклар...

— Бәлки, ярдәмгә эшчеләр бирерсез? — дигән иде Сәфәров, ләкин комбинезон киеп азапланган прорабның сүзе үтмәде.

— Безнең заводта кирәк тотардай белгечләр юк...

Уф, эссе...

Кояшның җылысы ел саен бер градуска кими, дигән галимнәрне эзләп табасы килә. 1972 ел исләренә төшкән саен, бизгәк тотар аларны... Күктән ут ява, җирдән кызу бәрә. Кырык градустан башка яши алмый торган сәрхушләр дә кар базына төшеп утырды — пешеп үлгәнче, өшеп үлүең җиңелрәк... Радиолардан «Күләгәдә утыз алты градуска җитә...» дигән хәбәрләрне ишеткәч, үзеңне юньсез кешенең куенына кергән кебек хис итәсең. Көпчәк күчәрләрендә мае кипкән трамвайлар өч тиенлек мунчага әверелгән, пассажирлар салырга мөмкин булган киемнәрен кулына тотып, түбәдәге төннектән һава йота.

Халык балыкка әйләнде. Ул, мөмкинлегеннән чыгып, инеш, күл, сазлык, елга һәм диңгез буйларында телсез ята. Су... Су... Су кирәк! Кояш көн саен байый, шуңа күрә ул байлар яклы. Хәерчене өтә, мөлкәтлегә ял бирә. Хәлләләр сыра күбеге, җылы куас, кайнар су сата, ут йотарга күнеккән хәлсезләр чират торып чөмерә.

Утны су җиңә. Ләкин суны ут җиңә алмый. Серле заводның ишегалдында салкын су фонтаны бәреп чыкты.

Фазыл ком сәгатен кояшта кызган платформа өстенә куйды. Бер куыктан икенчесенә кайнар ком агыла... Җир куеныннан кызган асфальт өстенә салкын су коела. Биш минутлык вакыт үлчәмен кисеп, ком агып бетә. Ә су һаман ургыла, димәк, ул бар, димәк, ул бик күп!..

«Серле» заводның су шаулавы ишетелерлек хәрби тынлыгы бозыла. Ак халатлы пролетариат урамга агыла. Аларның кызган таш өстенә җәелгән салкын рәхәткә яланаяк басып тыпырдашуы сай күлдә йорт казлары биюен хәтерләтә. Ак халатлыларның чыр-чуына кызыгып карап торган капка каравылчысы да чишмә янына якыная башлаган иде, ләкин шул минутта Каратаевның: «Эш урыныңны ташлама!» дигән ымлавыннан кире борылды.

— Абый, инде нишлик, агрегатны җыя торсак ярыймы?

— Демонтаж качмас, өлгерерсез. Әйдәгез, дебетны үлчәп карыйк, скважинагыз күпме су бирә икән? Сәфәров ун литрлы чиләкне су шарлавыгына куйды.

— Бер, ике... — диде ул, үзенчә ашыгыбрак санап, һәм, кинәт батыраеп, баш бармагы белән чәнтие тырпайган йодрыгын Каратаевның йөзенә терәде, — секундына биш литр — артыгы белән!

«Серле» завод директоры иңенә төймәләре коелып беткән халат элгән ялтыр маңгайлы бер ирне чакырып алды:

— Бишкә — биш! Егетләргә биш литр спирт китерегез! Бездән башка бүләк юк...

## Салкын мунча пәриләре...

Җир шарының теге ягыннан офык астына кояш килеп терәлгән — аның нуры ялгыз болытларга балкыш булып сеңгән һәм ерау тынлыктан изрәгән җиһанга сүрән яктылык сирпеп тора. Таң атар алдыннан шундый илаһи халәт бу — дөнья тыныч, тормыш имин, табигать дөрес, кешеләр һәммәсе тигездер кебек. Ләкин кояш күтәрелеп, көн ныграк ачылган саен, әлеге мәрхәмәтле минутларны яшәү гарасаты күмеп китә.

Яңа төзелә торган «КамАЗ юлы» өстендәге урманнан көткән бораулаучылар Казан ягыннан килеп төште. Колакка сизгер, күзгә үткер, телгә җитез Нырты халкы: «Көн саен ару гына «карга боткасы» пешерә торгач, Ходай безне ишетте, яңгыр яудыручы карендәшләребезне җибәрде», — дип мактанып йөрде.

Артта калган колхозны илленче елларда гына «чукындырып» совхоз иткәннәр. Ыртының кунакханә тотарга хәленнән килмәде, кунакларны директор үтенече белән Марфа түтинең өенә урнаштыралар иде. Ялгыз карчыкның биш почмаклы өе, кеше теленә кереп, тора-бара «колхоз гостиницасы» дигән ялган статус алды. Килгән кунакларны совхоз ризыктан өзми, вәкаләтләренә карап саллы гына мәҗлесләр дә оештыра. Марфа түтигә бигрәк тә әнә шул сыйлаулар ошый. Түгәрәк аяклы зур өстәле караватк кырыенда. Табын түрендә сыйлаучы булу аның эше, кунаклар үпкәләмәсен өчен алар белән тигез эчә, тиз исерә. Авырайгач, утырган җиреннән ястыкка авышып, сандугач йокысы чаклы гына черем итеп ала, ул уянганчы әле кунаклар таралышмый, түти яңадан башлый.

Мәдияр күчтәнәч итеп фатир хуҗасына спирт алып кергәч, Марфа түти, биш литрлы банканы кочаклап, өй эчендә төрле-бирле йөренеп, яшереп куярдай тыныч урын эзләп «аһ» итте. Ахыр чиктә ул аны идән астына төшереп куйды, калай тышлы коргаксыган сандыкны баз капкачы өстенә шудырды.

Бораулаучыларны өч көннән бирле көтеп, тәүлек саен мунча өлгерткәннәр. Дөрес, өченче көнне Марфа түти мичкә утын өстәүдән баш тарткан. Урамдагы кызу мунчаны сүрелдерми, ташы суынмаган, суы — кайнар. «Башта килсеннәр әле кое казучылар, аннары күз күрер», — дигән.

Кызу көннәрдә мунча аеруча тансык. Челләнең тозлы тиреннән тән әчетә, тузан ягыла, киемне алыштырып өлгерер хәл юк. Ыртыга килеп агрегатны урнаштыру белән, егетләр мунчага ашыкты. «Серле» завод комнарын, цемент тузаннарын, гомумән, Каратаев тирәсендә җыелган авыр тәэсирләрне юып төшереп, тәннәрен җиңеләйтәсе килде аларның.

Юынып чыгып, ачык тәрәзә янында чәй эчеп утырганда, ишегалдында ике хатын-кыз пәйда булды. Кулларындагы сумкаларының зурлыгына караганда, кызлар мунчага юынырга баручыны түгел, сабан туена бәйрәм итәргә әзерләнеп чыккан гаиләне хәтерләтә иде. Марфа түти кызлар янына ашыкты. Мунча сукмагында көлешә-көлешә нәрсәләр турында сөйләшкәннәрдер, анысы ишетелми, ләкин шунысы аңлашыла, кызлар чакырылмаган кунаклар түгел иде.

— Татый белән Галка, — диде Марфа, тирләп-пешкән бит алмаларын халат итәге белән сөртә-сөртә кереп, — директорыбыз сезнең арканы ышкырга дип җибәргән. Бик ару кызлар, савхуз өендә торалар. Берсе пекарняда эшли, икенчесе дуярка. — Һәм түти, түр почмак шүрлегендәге икона каршына басып, көлә-көлә чукынып алды.

Мәдияр, әнисе кушкан йомышны оныткан күрше малае шикелле, аптырап басып торды. Фазылның «кияү»не фаш итәргә теләп мут елмаюын күргәч, ниһаять, анык карарга килде.

— Монда иркенләп яшәргә туры килмәгәе әле. Совхозның ятмас Дусай бүлекчәсенә дә бораулыйсыбыз бар. Зур эшкә тотыныр алдыннан Шүләнгергә кайтып килергә кирәк. Үземнең Галкам нишләп ята микән? Кызны сагындым. Әти-әни үпкәләгәндер, — дип санап китте Мәдияр, акланган кыяфәт белән. — Әйдә, Фазыл, киттек, ерак ара түгел, сине күреп сөенерләр генә...

Нишләп Шүләнгергә кайтып йөрсен инде Фазыл?! Айлар буе күрешмәгән Мәдиярның Галина белән пышылдашкан серләрен тыңларгамы? Бераз ял итәргә мөмкинлек барында, мунча кереп тугарылгач,

тагын юлга чыгаргамы? Янында сөекле ярың табылса, парлашып кунакка йөрешүләре күңелледер. Ләкин ялгыз башың түбә күләгәсендә, бүрәнә ышыгында челләдән качып ятуың, бәхетле Мәдиярга иярчек тай булып тагылып йөрүгә караганда, мең өлешкә яхшырак!

Мәдиярга канатлар үсте — Шүләнгердәге оясына очты... Марфа түти өстәл артындагы ястыгына түнтәйде. Фазыл буш караватларның берсенә ял итәргә дип ятып торган җирдән йокының иң тирәненә чумды.

Иртән ул завод капкасына соңарган эшче кебек сискәнеп уянды. Күзен ачса — Марфа түти ястыгына сеңгән. Тәрәзәгә төшкән кояштан мич кызуы бәрелә. Мәдиярның өйдә юклыгы исенә төшкәч әйләнеп ятмакчы иде Фазыл, ләкин йокы туйган. «Урын өстендә аунап, ял иткән гәүдәңне таушалтканчы, торып юынырга кирәк, җылы су бардыр әле» дигән уй аны мунчага алып килде... Сәер күренешкә юлыкты әле ул — мунча ишеге ачык, сайгакта ялтыравык туфлиләр, сәкегә күлмәкләр, эчке киемнәр өелгән. Фазылның мунча эченә керергә кыюлыгы җитмәде, корымлы тәрәзәдән генә үрелеп карады — ләүкәдә ике шәрә кыз ята, куллары салынып төшкән, аяклары бөкләнгән, чәчләре тузгыган, баш очларында аумаган ике шешә... Фазыл кабаланып өйгә йөгерде.

— Марфа түти, тор, тор әле! — диде ул, фатир хуҗасын уятырга теләп. «Үлгәннәр!» дип кычкырырга ашыкмады, махмырдан уянган кешегә кинәт авыр хәбәр әйтсәң, йә йөрәге ярылыр.

Ул аны ястыгы белән күтәреп стенага сөяп утыртты. Аннан соң өстәл өстендә калган ярты стакан чамасы спиртны иснәп карады — су кушылган иде.

— Марфа түти, баш төзәтергә вакыт!

Хуҗабикә спирт исенә күзләрен ачты, ләкин тозлы кыяр кисәген генә кабып куйды.

— Суң, ниемә дип куалыйсың, миндә махмыр гупчым юк?!

— Марфа түти, мунчада теге кызлар үлеп ята. Ис тиеп микән?

— Китсәнә! Өченче көн ягылган мунча, ниткән ис калсын?!

Марфа түти мунчадан җәһәт әйләнеп кайтты. Җавап көтеп тилмергән Фазылның йөзенә туры карамаска тырышты.

— Ул салкын мунча пәриләренә чуртым булсынмы! Уяттым. Сезне көтеп ятканнар. Директор сүзен олылап килгәч, уңның бер гаебе җук. Сораша-нитә калса, ипләбрәк әйтегез. Кызларны җаманламагыз...

* * *

Мәдиярның Ныртыдан Шүләнгергә ашкынып кайтуы заяга түгел, әлбәттә. Туып үскән нигезендә иман нуры бөркеп торган әти-әнисе бар бит әле... Әнә, яңадан үз эшенә әйләнеп кайткан төпчек малай өчен ничек сөенәләр алар! Үз балаң алтыда да, алтмышта да сабый инде ул. Бәләкәй чакта сабыеңның һөнәре арткан саен сөенәсең, ә зур үскәч, аның эшкә урнашуы, вакытында гаилә коруы, тормышларының муллыгы куандыра. Бала күңеле далага чыгып очса, нигез капкасына эзләре суына, сирәгрәк кайтыр өчен кырыкмаса-кырык сәбәпләре табыла.

Галинаның каенана белән каената янында тотык булып калуы Мәдиярны бик еш кунакка кайтырга мәҗбүр итәчәк иде. Киленнең, оныкны күтәреп, Дон аръягына китеп олагуы картларның өметен кисте.

Ай буе командировкада йөргән малай, өйгә кайткач ял итеп, туган-тумачаларның хәлен белеп, абзар-кураларны төзәткәләп, ким дигәндә, ике-өч көн юана торган иде. Бу кайтуында, ишектән керүенә алпан-тилпән атлап, яңа тәпиле Регина килеп сарылмады, акчадан бигрәк фатир ордеры көткән Галина кочаклашкан уңайдан куен кесәсенә кулын тыкмады. Юк алар бүген... Әтисе белән ирләрчә иңнәрне иңгә бәреп күрешкәндә, Мәдияр башын читкә борды — тәмәкеле тынын яшерү өчен түгел, ул бүлмә эчендә уенчык куып йөргән кызы белән сөекле хатынын эзләде. Юк алар бүген... Бүтән булмаячаклар да...

Унлы җептән үреп бәйләнгән кар бизәге генә салкын карават өстенә өелгән мендәрләрне каплап тора.

Табын артына утыргач, улларының беренче сүзе шул булды:

— Миңа бүген үк китәргә кирәк, караңгыга калганчы, Чияле урманын чыгасы иде. Анда Фазыл үзе генә калды. Һәр минутыбыз исәптә. Дөньясы көя, бөтен кеше су сорый.

Әле дә ярый, кайтып керүгә: «Нихәл яшәп ятасыз соң, әни?» — дип хәл белешеп өлгергән иде.

* * *

Сәгать комы әле бер, әле икенче якка ага торды.

Саный китсәң — инде адреслар өстәле аркылы дусларыңны яңадан эзләрлек вакыт үткән. Мәдияр бүген урта яшьләрдәге тол ир... Фазыл белән чагыштырганда аның язмышында әллә ни аерма юк шикелле. Шүләнгер хохлушкасы Регина егерменең бу ягына чыккандыр. Ул әле һич көтмәгәндә әтисен эзләп табар кебек. Фазыл үзенең улы Салих белән очрашты ич әнә...

Адәм баласына бәхетле булыр өчен яраткан эш, сөеп иркәләрдәй кеше һәм саулык кирәк. Әлеге өч шарт кәҗә, бүре һәм кәбестә турындагы әкият кебегрәк: берсе исән торсын дисәң — икенчесен югалтасың, монысы янында калам дисәң — тегесен алып китәләр, ятраканын саклап ятсаң — бүтәннәреннән

колак кагасың. Мәдияр сау-таза кеше. Фазыл аны тагын яраткан эшенә чакырып килгән. Димәк, бәхетнең өчтән ике шарты бар. Инде сөекле кешесен яңадан эзләргә вакыт, ә эзләгән кешенең юлда булуы хәерлерәк.

## V. ЯҢА ВӘЛИ

### Бер үбеп кал

Туган авылыңа кайтыр өчен дә юлны кат-кат сораштыра торган заман бу.

Теләсә кайсы авылның исемен әйтеп бирегез Фазылга... Анда ничек барасы, кайдан юл кыскарак, яңгырлы көнне кайсы тирәдән әйләнеп үтсәң яхшырак, теге яки бу күпер бораулау агрегатын күтәрә аламы, дип, вак-төякләп аңлатып торасы юк. Бирегез сез аңа зур ак кәгазь, тоттырыгыз кулына каләм, кучермичә, дәреслекләргә, атласларга карамыйча, Татарстан картасын сызып куя ул сезгә! Урманнарын киметмичә, елгаларын турайтмыйча, юлларын югалтмыйча, авылларын кимсетмичә сыза да куя, менә күрерсез! Дөрес, кайбер үзгәрешләр кертмичә, купшылык өстәмичә калмас ул аңа. Әйтик, Казан каласы Баш кала дип аталган икән, ни өчен әле татарның Баш саласы булмаска тиеш ди? Чагыштырмача иң зурысы, эшләп яшәүчеләре саныннан беренчесе, алдынгысы, танылганы, вак авылларның атаманы... Бик беләсең килсә, Фазыл ул Баш саланың гербын һәм байрагын да уйлап куйды. Герб туры почмаклы булырга тиеш. Аның аскы өлешендә кылычка-кылыч килгән ике балта сурәте, ә уртада — тәрәзәләре көлеп торган ак түбәле нарат өй. Байрагы да бик гади: тегермән кәүшәсеннән бушап кайткан кычыткан капчыкның кырыйларын башак сыман укалар белән чигәсең дә, авылның иң биек ноктасына — янгын сүндерү каланчасына элеп куясың. Әлбәттә, мондый геральдикага лаек бер генә саланы белә Фазыл — ул Шәле! Шәле саласы — Баш сала! Калган авыллар аның янында энекәш һәм сеңелкәш кебек кенә.

— «Җиде кулдә» көтәләр сезне, — дип башлады сүзен Наил Кадыйрович, бораулау агрегатын ремонтлап яткан егетләрнең эшен беркавым күзәтеп торганнан соң. — Гараждан кайчанрак чыгып китәрсез икән?

Шушы соравына җавап ишетмичә генә китеп барса ярый иде кана, ләкин Наил Кадыйрович бүген моңарчы сиздермәгән үҗәтлек белән җавап көтте.

Фазыл арбада пычрак насос белән маташа иде, начальник янына сикереп төште. Күрешергә туры килсә дип, комбинезон кесәсеннән мамык кантары чыгарып, мазутлы кулын сөртә башлады. Ләкин «Ак Чишмә» президенты кул бирергә ашыкмады.

— Ыслушай, Фазыл, агрегатыгыз аягына басты, запчасть сораудан туктадыгыз, бригадаң тупланган — тагын нәрсә дип казынып ятасыз гаражда?! Җәй беткәнне көтәсезме?

— Алмагачлар чәчәк коймаган ич әле.

— Бакчачылар өчен урак өсте инде бу. Көннәр көзгә авышкач, суның кирәге юк.

— Кыш көннәре дә коелар казыдык ич.

— Элек ул, Фазыл, элек! Ә хәзер, кем әйтмешли, вазгыять үзгәрде. Бакчалар, дачалар, вилла, коттеджлар, арендаторлар — яңа байлар су сорый.

— Ә колхозлар, авыллар, шәһәрләр?

— Сорамый. Дөрес, аларга да су кирәк, ну скважиналар бораулатырлык акчалары юк. Акча яңа байлар кулында хәзер, безгә менә шушы чорны файдаланып калырга кирәк.

— Яңа байлар искергәнче, арендаторлар бөлгәнче, ярлы халык үлгәнче, ул акчаларны безнең кулга күчерергә кирәк. Әйеме, Наил Кадыйрович?

— Нәкъ шулай! Тик сәяси телдә сөйләшмә, матди телдә сөйләш. Менә сез бригадада өчәү... Һәр бораулаган су скважинасыннан өчегезгә илле процент хисабыннан түләнер, калган яртысы контор файдасына. Сез ул акчаны үзара ничек бүлешерсез — анысына мин катышмыйм. Ә бер коедан конторга күпме табыш кергән — монысына син катышмыйсың! Килештекме?

Кардан «тәресенә» май төеп яткан җиреннән Мәдияр тавышы ишетелде. Ул үзе платформа астыннан күренмәсә дә, сүзләре аермачык аңлашыла иде.

— Гафу итегез, минем дә сүзгә катышасым килә. Элек без айга ике-өч коедан ары бораулый алмый идек. Эшенә күрә яңа вәгъдәләрегезне бик төшемле урын дип әйтеп булмый икән.

— Әйттем бит, «элек»не онытыгыз, дидем. Элеккегечә йөз илле, өч йөз метрлы су скважиналары төшегезгә генә керәчәк сезнең. Яңа байларга йомшак су кирәк. Ә йомшак суны беләсез — Казан тирәсендә ул өске катламнарда гына. Димәк, җәйге көннәрдә сез көн саен берәр кое бораулый аласыз!

— Ул хәтлек эшне безгә каян табып өлгерерсез икән, Наил Кадыйрович?

— Эш күп. Бүгенгесе көндә «Җиде кул» бакча ширкәтен алсак кына да, унҗиде заказ бар. Акчалары түләнгән, скважина бораууланды, дип кул гына куйдырасы бар. Йә, Фазыл, гараждан куып чыгарыйммы, әллә үзегез кузгаласызмы?

— Арканнарны алыштырасы бар да пычрак насосның пешкәкләрен сүтеп җыясы...

— Вәт! Төгәл ике көнлек эш. «Җиде күл»гә барыгыз да заказчикның өй түренә җәелеп ремонтыгызны төгәлләгез.

— Ник ватык агрегат белән килдегез, дисә?

— Димәс, димәс! Киресенчә, ниһаять, килделәр, дип сөенер генә. Юкса һәр заказчик көнгә икешәрөчәр кат шылтырата: «Бораулаучыларыгыз кая, кайчан килә?!» Аптырагач-йөдәгәч, юатыр сүзем, яңа вәгъдәләрем калмагач, телефонны алыштырдым, автоответчик куйдырдым. Язылган гозерләрен кереп тыңлый аласың. Әйдә...

— Юк, ышанам инде, болай да.

Наил Кадыйрович хәйләкәр елмаеп кына Фазылны читкәрәк дәште. Тегесе «囲тә минем бернинди серем дә юк» дигәндәй, иңбашларын сикертеп егетләр ягына ымлады. Начальникның чынлап торып чакыруын күргәч, берәр мөһим сүз барлыгына ышанып ризалашты үзе.

— Кадрлар бүлегенә кереп, контрактка кул куярга онытма.

— Зөмәйрә янынамы?

— Әйе, Зөмәйрә Харисовна әбәткә бикләнгәнче, кәгазь эшләрен бетереп чык.

— Ник Харисовна, ник әле Зөмәйрә ханым гына түгел?

— Анысын да әйтиммени инде? — Наил Кадыйровичның рәхәтләнеп елмаюдан күзләре кысылып бетте.

— Нәрсә, бәбәкләрең ярыгыннан карап көлеп торасың, президент яшьти?! Бер башлагач, җөмләңне әйтеп бетер инде.

— Син куенында төн кунып чыккач...

— Монысын да беләсеңме?

— Соң, Фазыл, бер авыл кешеләре лә без. Кемнең кем янында кунып чыкканы сер түгел.

— И шуннан?

— Син киткән көнне үк ханымың гәҗиткә белдерү биргән, танышу-кавышу өчен. Күрсәң, Фазыл, ярты Казан буйдак картая диярсең — сәгать саен шылтыраттылар: «Зөмәйрә Харисовна! Зөмәйрә Харисовна!» — дип өзгәләнеп очрашуга чакырып торалар. Инде без дә хәзер «Харисовна» дип дәшәбез.

— Ә теге танышлары?..

— Берсен йортка кертте. Үземнең күргәнем юк, ну егерме яшькә кече, диделәр ирен. Зөмәйрә бала тапты. Ике ел була инде... яшәп торалар.

— Вәт, Фазыл, мәхәббәт һәм нәфрәт кайда ул! Гомер бакый бер коллективта эшләп, Зөмәйрәнең серенә төшенмәгәнбез. Тол картаерга ант иткән ханым, синең белән бер төн эчендә үзгәрде дә куйды... Бар, кер, күр үзен, сөендер...

— Син инде, крутой президент, контракт кәгазьләрен юри аңа бирдең, әйеме?!

— Юк, Фазыл. Маркетинг эшләре дә Зөмәйрә Харисовна кулында хәзер. Так што бергәләп эшлисе.

«Ашыгып кияүгә чыкты, бала тапты, ике ел инде» дигән сүзләрдән Фазыл кинәт сискәнеп китте. Әйтерсең лә моңарчы аның җанында нерв җепселләренең иң кирәкле чылбыры өзек булган, шушы өч фикер ул өзеклекне өч катлап бәйләп төенләп куйды. Һәм Фазылның җанына ут капты. Кызыксыну, көнчелек, тизрәк күрешергә теләүдән иде ул ут... Өч төен бергә төйнәлгән икән — монда очраклылык юк... Машинасына ут капкан абзый янгын сүндерү почмагына комлы чиләк эзләп килгәндә, Фазыл кадрлар бүлегенә кабаланып килеп керде:

— Зөмәйрә!

Зөмәйрә үзе генә түгел, аның янында тагын ике кыз төшке чәйгә әзерләнәләр. Кайнап чыккан ак чәйнекнең шнурын уттан өзмәк булып үрелгән чагы иде аның. Фазылны күргәч, каушавыннан, ялгыш оядан чыгып бетмәгән штепсельгә кулы тиеп алды. Һәм Зөмәйрәне дерелдәтеп ток сукты. Ул «ой!» дип өзгәләнеп кычкырып җибәрде. Ләкин бу аваз ток чеметеп алган имән бармакның авыртуыннан түгел, һич түгел... Фазылның җан уты Зөмәйрәгә дә кучте. Кызлар, кызгану йөзеннән, тынсыз калганнар иде, Зөмәйрәнең елмаюын күргәч, аңа кушылдылар.

— Зөмәйрә Харисовна, — диде Фазыл, әлеге кызларның ике арадагы серне белгәнен белмәмешкә сабышып. — Зөмәйрә Харисовна, контрактка кул куясы бар икән.

— Әле сез аңа кул куймадыгызмыни? — дигән булды Зөмәйрә һәм, ашыкмыйча гына, калын өемнән килешү кәгазен эзләргә кереште. Эзләмәде, кайда ятканын белә ул. Күреп кал мине, дип, соңгы тапкыр мөмкинлек бирүе аның Фазылга.

Зөмәйрә... Яшәрүнең әллә нинди ысулларын белә... Соңгы өч дистә елда хезмәттәшләре аны бары тик озын муенлы шәмәхә свитердан гына күрергә күнеккәннәр иде. Бактың исә ачык изүле, кыска җиңле, сыланып торган футболка да бик килешә икән үзенә. Әрдәнәләп өелгән җирән толымнарын юксынып өлгергән иде Фазыл — җилкәсенә тузгытып салгач та купшыланып ымсындыра. Өр-яңа балдак киелгән бармагы белән читкә сыпырып куяр өчен генә калдырган маңгай чәче, чын яшен яшереп, самимилек өстәп тора.

Контрактка кул куйгач, иркенләп сөйләшер вакыт бетте, тик әйтәсе килгән сүзләр бар әле. Зөмәйрәнең бүлмәдәш коллегалары артык яшь күренсәләр дә, күзгә-күз карашып сүзсез калган ике йөрәкнең

аулак минут көткәнен генә аңларлык иделәр, кайнар чәйнекне күтәреп, салатка диелгән яшел кыярны юар өчен урамга ук чыгып киттеләр. Ябык түтәлләрдә үскән «Зозуля» сортлы озын кыяр турындагы Шәрәфи мәзәген искә төшерделәрме — кызлар артыннан серле көлү ишетелеп калды.

Икесе аулакта калгач, вакытны әрәм итмичә, бер-берсен борчыган сорауларга җавап эзләделәр. Гадәттә мондый аңлашулар аерылышканнан соң, күп вакыт үтеп кинәт очрашкан элеккеге ир белән хатын арасында була торган иде.

— Мин сине икенче көнне үк көттем, ник кайтмадың, Фазыл?

— Саубуллашып киткәчме?..

— Эзләгәнеңне таптыңмы соң?

— Өйләнү кайгысы юк әле миндә, күрәсең ич — эш яңартып йөрим.

— Кызыл кар яуганчы сайлан инде алайса.

— Ә син үзең ник ашыктың, Зөмәйрә?

— Соңга калам. Ана буласым килде.

— Шулай көтмәгәндәме?

— Мәхәббәттә бала тиз туа.

— Миңа кызыңны күрергә ярыймы?

— Юк! Әгәр син аны күрсәң — тормышыбыз пыран-заран буталып бетәчәк.

Дөреслекне ахырынача ачып бетерергә теләмәде Зөмәйрә. Әгәр ул шушы минутта баланың чын әтисе кем икәнен әйтсә, соңарып корылган гаиләнең терәүләре җимерелер, куанычлары коелыр иде.

— И Фазыл, телеңә салынып вакытыңны әрәм итмә, ичмасам, кызлар әйләнеп кергәнче, бер үбеп кал, теге төндәгечә татлы итеп, соңгы тапкыр... Бу күрешү иремә хыянәт итү дип аталмас. Минем моңа хакым бар...

## Кайда йөрдең?

Егерменче гасыр төгәлләнер алдыннан бик күпләргә Текә дигән кушамат тагылды. Гомер кыскартып озын берлек артыннан куу, инглизчә аталган исерткечләргә мөкиббән китү, эксклюзив киемнәргә төренү, мактаныр өчен генә юкка-барга көрәкләп акча чәчү, тән сакчылары белән масаю — Текәләрнең яшәү рәвешенә әверелде.

Унсигез миллион коммунист сул яктан уңга борылып яткач, байракларның төсе алышынды, кешеләрнең холкы үзгәрде, дөньяның асты-өскә килде — явызлар өскә менде, мәрхәмәтлеләр аска төште. Эшсез, өйсез, мөлкәтсез калганнар сулга каерды; эшсез, өйсез, мөлкәтсез калдыручылар уңга сөйрәде... Текә Вәли боларның берсенә дә керми — ул урталыкта. Әлеге мактаулы кушамат аңа руль артындагы тәвәккәллеге өчен ябышты.

Түрәләрне Рәсәй машиналарына күчереп утырту турында Мәскәү хакимиятенең Указы чыккач, Наил Кадыйрович үзенең «Волга»сын иске шоферы белән бергә сатып җибәрде һәм җаваплылыгы чикләнгән ширкәттән яңа «джип» кайтартты. Әлбәттә, кирәкле төсне эзләп тапканчы, бер ай чамасы көтәргә туры килде. Ул дүрт атна буе машинасыз эшләде... «Ак Чишмә»гә иртәнге җидедә килеп җитәр өчен, бишләрдә өеннән чыгып, автобустан трамвайга күчте, шәхси таксилар туктатты, яңадан тәпи йөрергә өйрәнде... Дөньяга карашы үзгәрде. Көн саен шәһәр транспортында изелгән гади халыкны яклап, шәһәр мэриясенә хатлар язарга җыенган иде инде ул. Вакыты гына җитмәде...

Яңа «джип»ка килешеп торырлык яңа йөртүче кирәк иде.

Колхозның мактанчык җитәкчеләре, банкетларда ярыштырыр өчен, җырга-биюгә һәвәс кызларга өйләнергә тырышалар... Кабул итү бүлмәсенең юл өстенә «мисс...» конкурсларында җиңгән чибәркәйләрне секретарь итеп кую да түрәләр арасындагы бәйгенең бер төре... Шәхси шофер сайлау исә — үзе бер сәнгать: машинасына карап начальствоны бәялиләр, ә йөртүче исә, үзенә утырып йөрүченең ни сөйләгәнен ишетмәскә, кем янына йөргәнен белмәскә, күрмәскә... әйтмәскә һәм, кирәксә, машинасын сүндермичә, көне-төне көтә белергә тиеш.

«Ак Чишмә»дә вакантлы урыннар бушаса, баганаларга игъланнар ябыштырып, радио-телевидение аша чакыртып, кадрлар эзләү гадәте юк. Наил Кадыйрович кирәкле кешене үзе эзләп таба. Аңа, Салмачы бистәсеннән «Оргсинтез» факелы астындагы эш урынына төгәл килеп җитәр өчен, елның теләсә кайсы фасылын тигез күреп, зарланмый һәм каушамый торган асыл йөртүче кирәк.

Түбән Осланнан килгән бакчачылар ширкәте рәисе белән борауланасы коеның бәясе хакында ишек бикләп килешә торгач, өйгә кайту вакыты чамадан сикергән иде. Кичке җидедән соң: «Кайда йөрдең?!» — дип чырайга-чырай килә торган хатынның барында кабаланмый нихәл итәрсең?! Әлбәттә, Түбән Ослан заказчигына әйтсәң, «уазиг»ы белән шәһәр читендәге әйләнгеч юлдан «әһ!» дигәнче, Салмачыга илтеп куя ала. Ул чагында, гореф-гадәт кушканча, рәисне өеңә дәшеп сыйларга, кунак итәргә туры килә. Бу исә яңа таныш белән якынаю, дуслашу дигән сүз. Ә дус-ишләргә һәм туган-тумачаларга коеларны чиратсыз бораулыйсы, бәяне дә төшерәсе була... Шуңа күрә Наил Кадыйрович ширкәт рәисенә сер бирмәде, коры гына саубуллашып, очраклы машина ауларга дип олы юлга ашыкты.

Озак көттермәде, шәфәкъ күләгәсеннән бер «Жигули» килеп чыкты. Кул күтәргән кешене узып илле метрлап үткәч, кинәт туктады үзе һәм Наил Кадыйровичның куып җиткәнен пошынмыйча көтеп торды.

— Шеф, кая барабыз? — диде ул, ачык тәрәзәдән башын тыгып.

Пассажир — Шеф, йөртүчесе Командир булып, юл хакын килештеләр. Шеф өйгә ашыгуы турында ашыгыбрак әйтеп ташлады бугай, Командир завод тирәсендәге ерганакларны үткәнче үк куаларга тотынды. Чокыр-чакырларны кистереп, каршы килгән машиналарны өркетеп, узарга тиешләрен янга кысып, җәяүлеләр сукмагын юл итеп тизлекне арттыруын белде. Шеф саклану каешын каптырып, ишек тоткасына ябышты. «Исемең ничек, Командир?» — дигән өч сүзле җөмләсе дә дүрт җирдән өзелде, сорау җавапсыз калды.

Шунысы сәер, ун минут чамасы узгач, Шеф бу тизлеккә тәмам ияләнде һәм аның Командирга ышанычы арта барды, ишек тоткасыннан кулын алып, каештан тугарылып, утыргычка җәелде.

Урамда көзге кич, кабинада июнь рәхәте. Ян тәрәзә ярыгыннан кергән тыгыз җил борын төбендәге гарәп касәсенә салынган җофар маеның хуш исен туздыра.

Ул җәйге чама белән киенгән. Кыска җиңле ак күлмәгенә элмәген бушатыбрак яшел галстук таккан. Мул гәүдәсен искәртеп, кесә авызы чекерәеп торса да, чалбары сызык төшереп үтүкләнгән. Туры башлы олы туфлиләре педальне бөтенләй каплаган. Аяк савытына күрә буе таман, утыргычны соңгы сырына чаклы этеп куйган, арткы рәттә аның турысына кеше сыярлык хут калмаган. Тагын искәрердәй нәрсә шул: егетнең башы зур, күзләре кечкенә; сыны авыр, кул хәрәкәтләре җитез; чәче кара, чырае ак. Вак тешләре тезелешеп тулган зур авызы тәҗрибәсез рәссам ясаган шаяру кебек шыксыз күренсә дә, ул аның үзенә килешеп тора хәтта.

— Ашыгам дигәннән, Шеф, бервакыт гаишник туктатты, — дип, ятланган хикәясен тезеп китте егет, — кырыклы знакны күрмисең мәллә, кая куалыйсың шулхәтле, ди бу миңа. Минәйтәм, Яңа елны каршы аласым бар... Ниткән Яңа ел, 8 Март җитә бит инде, ди бу... Вәт, вәт, минәйтәм, шуңа ашыгам да, хатын ике айдан бирле борчылып көтә торгандыр, дим... Гаишник карап-карап торды да якын ук килеп, «А ну, өреп кара әле» ди... Мин «Һау, һау, һау!» дип өреп күрсәттем үзенә.

— Штраф түләттеме соң?

— Юк, иске булса да, анекдотларың ошады, бу юлга гафу итәм, — диде.

Шоферларны күп күрде инде Наил Кадыйрович. Әлеге егет әрсез йөртсә дә, светофорларны санлый, ашыгам, дигәнгә карап, сары утларга ыргылып керми, юл аркылы чыккан гамьсез җәяүлеләргә сүгенми, кычкыртмый, янәшәсендәге пассажир белән сөйләшеп барганда, алгы тәрәзәсен онытып, җавап көткән якка башын боргаламый. Бу гадәтләрен бик яратты ул аның...

— «Шестерка»ң искергән, яңартасы бар, — дип башлады Наил Кадыйрович, сүзне вакансия тирәсенәрәк борырга теләп. — Өр-яңа машинада йөрисең киләме?

— Килә шул. Менә яңа машинага җыеп йөрим ич инде. Сезне гаиләгезгә илтеп тапшырсам, яңа домкратлык була. Кичә юл ныграк уңды — карбюраторлык җыелган иде... Хәер, төн озын әле, бүген дә җыелырга мөмкин.

— Җыеп бетерәсеңме соң инде машинаңны?

— Төнлә «бомбить» итеп йөреп кенә куандырып булмый, бәяләрне куып җитәр хәл юк.

— Көндез берәр җирдә эшлисеңме соң?

— Кибеттә каравыл торам. Бер төн эшлим, ике төн ял итәм. Акчасы әллә ни юк инде, аның каравы буш вакыты күп кала.

— Ә миңа шофер кирәк. Машинаны фирмачылардан үзеңә сайлап аласы. Әйдә, тәвәккәлләп кара?!

Егет хутлы барган машинаны кисәк туктатты: «Ә син үзең кем буласың соң?» — дигәндәй, Наил Кадыйровичка таба борылган җиреннән, симез ияген иңбашына терәп, хәрәкәтсез калды.

— Шеф, может синең «такси»га түләргә акчаң гына юктыр, шуңа шыттырып барасыңдыр, бушлай йөрткән юк минем, кул китә...

Наил Кадыйрович сул кесәсеннән визит карточкасы, уң кесәсеннән йөз сумлык чыгарды. Егет визитканы алды алуын, ә акчаны кая куясын имән бармагы белән ике утыргыч арасындагы тартмачыкка таба төртеп күрсәтте.

— Шабашка акчасын кулга алсаң, хәрәм була... Кул китә, — дип кабатлады ул. — «Ак Чишмә» президенты!.. Бүген графигым каравылга туры килгән булса, Казанда «Ак Чишмә» дигән акционерлык кампаниясе барлыгын белми каласы икәнмен.

Яңадан кузгалып киткәч, егет машинасын артык куаламады. Хәер, Наил Кадыйровичның өенә дә ерак калмаган иде инде.

— Мин алай ук лихач түгел, сез ашыкканга гына куган булдым, — дип акланды егет, әлеге начальникның үзенә яңа хуҗа булу ихтималын күздә тотып.

— Алайса, таныштык дип исәплик.

— Әйесен әйе, тик минем исемем сезнеке шикелле катлы-катлы түгел, просто — Вәли генә.

— Вәли дисәң, бигрәк кыска килеп чыга, мин Текә Вәли дип кушып әйтермен... Кайсы коттедж янында туктыйсы, дип ник сорамыйсың, олы урамнан барасың да барасың.

— Бу Салмачының почти бөтен ташпулатында кемнәр яшәгәнен беләм инде мин. Әйттем ич, төнлә такси булып машинага акча җыям дип, әнә теге — өч катлы, чатыр түбәле, ике гаражлысы сезнекедер дип уйлыйм.

— Әйе, нәкъ үзе. Бакчасындагы су мичкәсеннән чамалап әйттеңме?

— Юк. Балконыннан яртылаш чыгып, бер ханым бинокль белән безне күзәтә — шуннан таныдым.

— Һе... Бүген ерак юлга чыгасым юк, кичке киңәшмәләр дә күренми, вакытында кайтырмын дип, иртән эшкә киткәндә ялгыш шапырынып өлгергән идем. Вәт борчылып көтә инде...

— Борчылу — көнләшүнең бер төре!.. Алай да мин сезнең акчагызны кире бирмим. Сезгә эшкә киләмме әле, юкмы — билгесез. Ә балконга чыгыплар көтә торган хатын миндә дә бар. Акчасыз кайтсам, ул да бик... борчыла...

— Инде «Ак Чишмә»нең кайда икәнен беләсең, иртәгә иртүк кил.

— Бәлки... Кем белгән?.. Ниме, Наил әфәнде, ә сезнең оешмада хатын-кызлар күп эшлиме?

— Коелар бораулау — ирләр эше ул. Бухгалтерия белән кадрлар бүлеген кушып санасаң, дүртәү булыр.

— Хатын-кызның күп булмавы әйбәт икән анысы.

— Өйдәгеләрең борчыламы? — Наил Кадыйрович «борчыламы» дигән сүзгә аеруча басым ясады.

— Өйдәгеләрдән бигрәк, үзем борчылам... Хатын-кыз күп булган җирдә тынычлап эшли алмыйм мин...

Килде Текә Вәли, иртәгесен үк килде...

## Президентны кем йөртә?

Шул көннән башлап «Ак Чишмә» президентын Вәли йөртә башлады. Каравылга чыгар төн җиткәнче үземне сынап карыйм, дип килгән егет яңа машинадан төшәргә теләмәде.

Дус-ишләрен, таныш-белешләрен күргәч, Наил Кадыйровичның беренче сүзе «Исәнмесез?» булса, икенчесе Текә Вәли турында башлана иде: «Сез ул егетнең ничек йөрткәнен күрсәгез!!!»

Һәм күрергә теләгәннәр дә шактый табылды. «Мелиорация» траст кампаниясенә, Кремльгә барасы булса, һич югы, Юдино станциясенә килергә тиешле адреслы вагоннарны каршы алырга дигәндә, Наил Кадыйрович машинасына гел артык юлдаш иярә торган иде. Вәлинең руль артындагы кыланышларын күреп сокланучылар да, яшәүдән туйган каскадер, яңа машинаң җылы тәнеңдә тузсын, дип үртәүчеләр дә табылды. Шунысы сәер, телдән телгә күчеп халык шоферына әверелә башлаган Текә Вәлине кызык өчен үз ягына авыштырырга теләүчеләр дә юк түгел иде. Ләкин егет, көндезге түләүгә артык зарланмыйча, материаль ярдәмнәр сорап гаризалар язмыйча гына эшли торды. Юлда йөргәндә, үзе узынып сүз башламады, Наил Кадыйрович сораулар бирсә, җавапсыз калдырмады. Эшлекле очрашуларга җыелганда, кабинадан чыгарга ашыкмады, юкса буе-сынына карап һәм заманча киенүен бәяләп дигәндәй, яңа танышлар иң әүвәл Текә Вәлигә кул бирә торганнар иде. Ә гәүдәгә шактый кайтыш һәм җәяү йөргәндә колхозчы адымнарыннан бизә алмаган Наил Кадыйрович, киресенчә, Текә Вәлинең шоферы сыманрак күренә иде. Президентның кисәткәнен көтмәде, Текә Вәли моны үзе сизеп алды.

Диңгезнең яшь дулкыннары төсендәге машинаның рәхәтен күреп өлгермәде Текә Вәли... Көннәрдән бер көнне Наил Кадыйровичны Салмачыдагы ташпулатына илтеп куйгач, кайтыр якка дип борылган иде, аяк астыннан гына дигәндәй, бер милиционер калкып чыкты, үзе, ашыккан юлчы рәвешенә кереп, болгый-болгый кул күтәрә. Туктамый чарaң юк. Дөрес, бу халыктан юл хакы түләтә алган шофер тумаган әле безнең Рәсәйдә. Шуңа күрә, артыгын көйләмичә, өенә хәтлек илттермәсен өченгә кискен сәбәп табарга кирәк иде.

— Иптәш капитан, трамвайга чаклы гына булса — рәхим итегез! — Һәм Вәли сәгатькә карап алгач, тавышын кырысландырды. — Һай, тагын ун минуттан, гаражга кайтып җитеп, машинаны икенче сменага тапшырып өлгерәсем бар, бик ашыгам.

— Ярар, — диде капитан, — бу байлар тупигыннан чыгып җитсәм, кайда төшереп калдырсаң да үпкәләмәм.

Юл читендә ян белән басып торганга күренмәгәнме — капитанның билендә уенчык шлагбаум сыман аклы-каралы таякчыгы эленеп тора иде. ГАИ инспекторы икән үзе... Күкрәк кесәсендәге селектордан постларның үзара сөйләшкәне ишетелеп бара.

— Мин дә ашыгам, — дип сүз башлады инспектор тыныч кына. — Рәхмәт, әле менә син очрадың.

— Җәяү йөри торган гаишниклар да бар икән! Җитмәсә, үзегез офицер кеше.

— Экипаж кибеткә дип киткән иде. Берәр авария күреп туктадылар, ахрысы, мине оныттылар.

— Ярар соң, алай ашыккач... ГАИ капитаны гел утырмый безгә, кем әйтмешли, инспектор үзебездә, юлдагыларыннан шүрлисе юк.

Һәм Текә Вәли, бераз масаеп, бераз капитанны үртәп дигәндәй, «джип»ка көч бирде.

— Син элек «скорый»да эшләмәдеңме?

— Юк, иптәш капитан, «01»-«02»-«03» машиналарына утырганым юк әле минем.

— Круто йөрисең.

— Гел начальство йөрттем мин, ә начальство, үзегез беләсез, ашыга торган халык.

— Штраф түли-түли синең техталонда кул куярга урын юктыр инде.

— Ялгышасыз, иптәш капитан, талоным чип-чиста.

— Инспекторларның бер дә туктатканы юкмыни?!

— Туктаталар. Праваны сорый башласалар, машинамны калдырам да китәм. Икенче көнне китереп бирәләр. Әйтәм ич, начальство йөртәм, дип.

«Финляндия» кибете янына килеп җиткәч, капитан туктарга кушты. Үзе кабинадан чыгарга ашыкмады.

— Барыбер ышанмыйм. Крутой шоферлар бездә дә бар анысы, тик рульдә шушылай йөреп, техталоныңа бер кисәтү язылмавына ышанмыйм... Праваң бөтенләй юктыр әле синең, шуңа шапырынасыңдыр.

— Минме шапырынам? Менә, пожалысты, ике категорияле.

Капитан Вәлинең юл кәгазьләрен учына алды.

— Тәк, гражданин Сабиров, Салмачыдан монда килеп җиткәнче, унҗиде нарушение ясадың: кырыктан арттырмаска дигән дүрт знакны сиксән белән үттең; алты очракта, ярамаган килеш, узарга кердең; олы юлдан килгән өч транспортны үткәреп җибәрмәдең; ике тапкыр рөхсәт ителмәгән җирдә трамвай юлын кисеп чыктың... Саныйммы тагын?..

— Шаяртмагыз инде, капитан, әйтәм ич, ашыгам. Документларны бирегез дә хушлашыйк. Ярар, шуңа күрә рәхмәт әйтеп тормассыз.

— Бернинди шаярту юк, гражданин Сабиров, — капитан документларны куен кесәсенә салды. — Әнә минем экипаж килеп туктады. Ул безгә Салмачыдан бирле ияреп кайтты, син аңа игътибар да итмәдең. Хәзер шунда күчеп утырып, унҗиде статьялы беркетмә язабыз.

— Иптәш капитан, үзегез ашыгам, дидегез ич, шуның өчен генә.

— Син рульдә. Пассажир нәрсә димәс сиңа, һәрберсен үти башласаң...

Һәм Текә Вәли Казан шәһәренең Мәскәү районында, Чистай урамындагы «Финляндия» кибете каршында правасын алдырды. Ярты сәгать буе беркетмә язганнан соң, капитанның йөзендә канәгатьлек хисе чагылды:

— Гражданин Сабиров! Бәлки, сиңа праваңны иртәгә үк китереп бирерләр. Ләкин минем әле моңарчы, болай рәхәтләнеп, протокол тутырганым юк иде...

Икенче көнне түгел, ике ай үткәч тә китереп бирмәделәр. Беркетмә шундый бай эчтәлекле иде ки, хәтта Урман арты бистәсендәге хуҗалыгына чиратсыз су скважинасы казытып биргән өчен рәхмәтләр укыган полк командиры да ярдәм итә алмады.

Фазыл бригадасына кушылганда, Текә Вәлинең машина йөртергә хокукы юк, кушаматы гына бар иде. Тик Наил Кадыйрович аны эштән куарга рөхсәт итмәде. ГАИ капитанын эзәрлекләп чыгарга мәҗбүр иткән шикаятьчеләргә үч итеп, башка байлар кулына эләкмәсен өчен, ул аны ничек кенә булса да «Ак Чишмә»дә калдырырга теләде.

Ул әле бригадада беренче атнасын гына, Фазыл белән Мәдияр ни кушса, шуны гына эшләп йөри. Килгән көнне үк агрегатның һәр җиһазы, һәр эш коралы белән җентекләп танышып чыкты, һәм үзен шундук тәҗрибәле бораулаучы кебек хис итте. Аның көндәлек эш барышында еш телгә алына торган ротор, редуктор, барабан, вертлюг, насос ише кирәк-яракларны күргәне бар. Ләкин төп эш җир астында бара. Тирән катламнарга су каян килә? Аны ничек эзләп табалар? Син тәҗрибәсез әле, дип, әзрәк түләмәсләрме? Үзләре белгәнне өйрәтерләрме?.. Кыскасы, җир астындагы һәм яңа һөнәр эчендәге билгесезлек аны маҗарасы белән түгел, ә көн күрергә ярардай гамәл буларак кызыксындырды...

## Байлар коесы

Алар тагын «Җиде күл»гә килеп төште. Төште дип чын мәгънәсендә әйтергә була, чөнки машина туктап өлгердеме, юкмы, Фазыл инде җиргә сикереп тә төште. Мәдияр да сикерергә ашыкты, Фазылны кабатлар өчен түгел, сагынып, үз итеп, таныш болыннарда еллар чалымын тоеп. Ул елларны санар өчен бармакларың җитмәс. Хәер, Текә Вәлине дә кушып санасаң, җитә. Ләкин аның өчен «Җиде күл» әле хатирәләргә уелмаган билгесез авыл гына. Әнә ул кабина ишеген ачып куйды, аякларын, урамга чыгарып, утыргычлар өстенә сузылып ятты. Аңа: «Төш!» — дип әйтүче юк. Ул әле яңа кеше, әйтеп тормасалар, нәрсә эшлисен белми. Фазыл белән Мәдиярның тау итәгенә ник төшеп барганын да аңлап бетерми. Кирәксәм, чакырырлар әле дигәндәй, буш вакыт барында ял итә. «Җиде күл»гә килгәндә, янда утырып барды. Фазыл аңа рульне бирмәде, правасыз йөртүчеләргә машина ышанып тапшырган кешенең үз правасын алалар, диде. Хак әйтә әйтүен. Текә Вәли үзенең хокуксыз көннәрен бик авыр кичерә, белмим, озакка сузылса нишләр?!

Фазыл белән Мәдияр үзәнлектә, ярышып-ярышып, нидер эзли.

— Кайсы тирәдәрәк әле ул?

— Хәзер табабыз аны, Мәдияр!

— Миңа ияреп йөрмә, читкәрәк чык.

— Үзәнлеге нәкъ шушы, өянкесе күренми...

— Әллә кайчан авып, учакларда янып беткәндер инде. Син хәзер кычыткан өелеп үскән җирне тап, өянке төбе шул булыр.

— Менә вагон торган җиргә охшаган. Вышка әнә тегендәрәк — кәбестә басуы читендә иде.

— Ат колагы басуы бу... Нинди җир кыргыйланып беткән.

— Бүлгәләп сатасылары бардыр, шуңа сөрмәгәннәр...

— Фазыл! Менә безнең скважина!

Алар икәүләшеп әйлән-бәйлән уйнадылар. Көлтәләнеп үскән кара әрем уртасыннан тырпаеп торган торба башы — әйтерсең лә балачак бәйрәмнәренең яшел чыршысы! Сөенечтән шигырьсез, моңсыз такмаза туды:

Тиле-миле күптөрле,
Диваналар бертөрле...
Их-ма!
Күргән кеше шаккатыр,
Безнең яшьлек тап-такыр...

Вәли сагаеп калды, яннарына килеп баскач, әлеге тамашаны нәрсәгә юрарга белмәде. Ил башлыгы булырдай ике ирнең үзләренә генә мәгълүм сүзләр тезеп, ясле баласыдай сикеренүе — дөрес хәл түгел... Бәлки, йоласы кушадыр, дип, уенга кушылды. Өчәүләшеп әйләнүе күңеллерәк тә иде.

— Мужики! Сез бурильщиклармы әллә?!

Уен өзелде. Сорау бирүченең эшлекле тавышы сискәндерде:

— Сез Наил Кадыйровичтанмы?

— Юк, без «Ак Чишмә»неке! Ә Наил Кадыйрович кешесе менә бу, — диде Мәдияр, Текә Вәлигә төртеп.

— Мин — Хәсәншин! Ишеткәнегез бардыр...

— Ә-ә-әйе, сезне белмәгән кеше юк, — дигән булды Вәли, һавалы Хәсәншинның мин-минлегенә тимәс өчен.

Ул, Текә егетне остазга санап, күрешкән җирдән кулын ычкындырмыйчарак торды:

— Исәп-хисап тәртиптә, мин сезне кичәдән бирле көтәм.

Ялан тәпиенә мунча чүәге кигән, өзек балаклы джинсы чалбарын хат ташучы сумкасы кебек итеп иңбашына каеш белән элгән күлмәксез Хәсәншин үз капкасына таба юл күрсәтте.

— Сезгә яңа кое бораулатып акча түгәсе юк, — диде Фазыл, хуҗаны кире үгетләргә теләп. — Менә чын чишмә бу! Суы — диңгез! Әйбәт сакланган — торба башын тимер капкач белән япканнар. Илле адым арага канау казып, ишегалдына чаклы сузасы гына кала.

— Каян беләсең?

— Мастерыбыз ул безнең, — диде Вәли, ниһаять, җавап тотуны үз өстеннән төшереп.

— Җитмеш икенче елны бораулалык, — диде Мәдияр да өлешкә кереп.

— Брат, анысы шулайдыр, ну миңа персональный кое кирәк. Колхоз суына калгач, крәстиянга әйләнәм ич мин.

Мәдияр тагын такмакларга кереште:

Персональный компьютер,
Персональ машина,
Персональ скважина,
Персональный пенсионер...

Беренче көннән үк заказчы белән әчелешле булырга теләмәде Фазыл, тату сөйләшүгә күчте.

— Акча түләгән кеше — һәрвакыт хаклы! Без сезнең кулда...

Хәсәншинның күңеле булды:

— Вәт, ичмасам, монысы братларча.

Мәдиярның өйрәнчек малай кебек сүзсез басып торасы килмәде.

— Хәзер, ишегалдыгызга кереп, вышканы урнаштырыйк. Эшне иртәдән башларбыз.

— Карасана! Сез бөтенегез дә мастерлар икән. Бик дөрес, изге эшне иртән башлау фарыз, ди, теге китап... Өйнең подвалы белән беренче каты сезнеке. Бассейндагы су атна башында гына алыштырылган.

— Каян алдыгыз? — диде Фазыл, иртәгесе көнгә бораулар өчен дә су кирәген белеп.

— Казаннан китерттем, Зәңгәр күлдән... Ярты кавымнан сауна өлгерә. Суыткычлар тулы. Тәк, «баяннар» мәсьәләсе нихәл — өчәү җитәме сезгә?

Хәсәншинның тел уйнатып әйткән сүзләрен авылчарак кабул итте Фазыл. Баян булгач, җырлата торган нәрсә — мөгәричтер дип аңлады:

— Кеше саен берәү җитәр. Күпкә китсә, иртән кыенга төшә...

Балаклары өзелсә дә, чалбарының кесәләре исән калган икән, Хәсәншин телефон чыгарып, аягүрә генә кемнәргәдер йомышлар кушты. Бирелгән әмерләрнең барысы да кечке ялны тиешенчә үткәрү өчен иде.

Ләүкә почмагындагы датчик йөз егерме градус күрсәтә! Мәдиярның битендәге, маңгаендагы, иягендәге һәр шадрасына тир бөртеге ябышкан, йөзе җемелдәп тора.

— Һәр заказчик шушылай каршы алса, эшләп үләрсең... — Текә Вәли тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, сулыш юлы пеште.

— Борчылма, рәхәттән үлмәссең, — диде Мәдияр, йөзендәге җемелдәвекне сыпырып.

— Без монда парга очып бетмәбез микән? Артыгын утырмыйк, — диде Фазыл, — әле бераз баян уйныйсы да бар.

Ишекләр күп инде ул дөньяда. Ләкин аларның һәммәсен дә шакып, рөхсәт сорап ачасы түгел. Әйтик, кибеткә, кинотеатрга, өеңә кайтып кергәндә... Трамвай, гараж, бакча капкаларын шулай ук шакып тормаслар.

Ләүкә тулы ирләр утырганда, сауна ишеген шакысалар, шиккә төшәсең икән ул... Тиргә баткан күзләр бер-берсенә аптырашып карап торган арада, вак-вак такталардан корамаланган ишекнең икенче ягыннан Хәсәншин тавышы ишетелде:

— Егетләр, «баяннар» керә!

— Чыккач эчәрбез, монда исереп үләсең! — дип әйтеп бетергәнче, аккошлар кебек тезелешеп, сәхнәгә менгән балет артистлары шикелле аяк очларына басып, билләренә уралган сөлгеләрне кыска итәк сыман итеп өч кыз кереп өлгерде.

«Привет, мальчики?!» дигән сәламнәреннән абайлап кына кызларның кайсы милләттән икәнен төгәл әйтеп бирүе мөмкин түгел иде. Хәер, милләтнең мунчадагы роле — сүнгән машинаның руле кебегрәк, әллә ни әһәмияте юк. Шулай да Мәдияр: «Боларның берәрсе Ростов якларыннан түгел микән?» — дип, пошаманга төшеп өлгерде һәм күңелдә шик калмасын өчен ачыктан-ачык сорап куйды:

— Девочки, сезнең кайсыгыз Галина исемле?

Өчесеннән дә «юк!» дигән җавап ишеткәч, Мәдияр сөенеченнән авызын җыя алмады.

Күз алдында торган өч кызның берсе — озын, берсе — кыска, берсе — ябык. Озыны — сары чәчле, ябыгыныкы — чем-кара, кыскасы — көл төсенә кергән. Сары чәчлесе — зәңгәр күзле, чем-карасыныкы — яшел, көл төсендәгенеке — коңгырт. Зәңгәр күзлесе — үпкәләгән сыман аскы иренен турсайткан, яшел күзлесе — көләргә генә тора, коңгырты — ун бармагының тырнагын ун төскә буяган...

Сауна эчендәге кызулык термопара тоя алмаслык дәрәҗәдә артты. «Мальчики», йөрәк тибешенә кислород җиткерә алмыйча, авыз ачып суларга керештеләр.

Алты кеше берьюлы сүзсез калгач, ишек артындагы Хәсәншин шикләнә калды:

— Аңыгызны югалттыгыз мәллә? Бу «баяннар» сезгә миннән бүләк, туйганчы уйнагыз!

«Моны Наил Кадыйрович кушуы буенча оештырганнардыр, иртәгә үк Зөмәйрәгә ишетелер...» дип уйлап куйды Фазыл.

«Болар чакырулы «баяннар»дыр. Өчесе белән берьюлы уйнап карасаң, ә?!» — Монысы Мәдиярның уе иде.

Текә Вәлинең дә уе бар:

«Кемнәр генә укымаган инде боларны?! Аптечканы үзләре белән йөртәләр микән?.. Вәт блатной эш икән бу! Ә мин дурак, начальство йөрткән булып, рәхәт күрмичә үлеп китәр идем...»

— Әйдә, Вәли, бассейнга чумабыз, кызлар туңып кергән, җылынсыннар бераз, — дип, Фазыл Мәдиярны борчыган уйларга чишелеш тапты.

Картлачлар чыгып китүгә, Мәдияр өч кызны да чыркылдатып, сөлгеләрен җыеп алды...

Бассейн дигәне, саунадан чыгып ун метрлы киң басмадан үткәч, аерым түбә астына иркенләп казылган иде. Фазыл белән Вәли берьялгызы су коенып яткан Хәсәншинга иптәш булдылар.

— «Баяннар» ошадымы соң үзегезгә?

Хәсәншинның комарлы соравына Фазыл төгәл җавап бирергә теләмәде.

— Уйнап карамадык бит әле... Ник «чувиха» йә «телка», йә «мочалка» дип кенә әйтмисез? Баян дигән шәп, милли музыка коралын хурлап...

— Сезнең Төркиягә барганыгыз юкмыни? Анда ирләрне бәй — безнеңчә бай, диләр. Ә хатын-кызлар баян булып чыга. Фестивальләргә барган чакта, артистларга еш искәртәләр: баян сорамагыз, мин — баянчы, дип мактанмагыз, ягъни мәсәлән...

Үзенең чит илгә барганы юклыгын сиздереп, бай Хәсәншин алдында мескенләнмәс өчен, Фазыл сүзне үз җирлегебезгә кайтарды.

— Авыл җирендә канализация юк ич, бассейндагы суны кая түгәсез?

— Бакчага сибәбез: агачларга, бәрәңгегә.

— Кыш көне күлгәме?

— Юк. Күлне саклыйбыз. Без анда затлы балык үрчетәбез. Яр әйләнәсен унҗиде хуҗага бүлдек тә койма белән уратып куйдык.

— Алайса, кыш җитүгә бассейннарны киптерәсез?

— Сезне шуңа чакырттым да инде... Хәзер күп кеше бассейндагы суны түгәр өчен дренаж коелар бораулата.

— Коенган суларны түгәр өченме? Пычрак су ич бу, моны ничек итеп җир астына агызмак кирәк?

— Ниткән пычрак? Сез — пычракмыни?

— Ну, юк та. Әнә саунадагы «баяннар»ны кем белгән. Хәзер шулар госелләнгән юынтыкны коега кусаң... Ул бит якын-тирәдәге чишмәләргә ияреп чыгачак!..

— Кем, Фазыл агайне, син мине бөтенләй үк наданга санама. Авылда өй саен кара мунча, ак мунча. Аларның юынтыгын кем кая куя? Шул яшәгән урынында җиргә сеңеп бара бит...

— Өстән сеңгән су тирәнгә төшкән саен фильтрлана ул. Ә дренаж өчен казылган скважина җир астына туп-туры алып керә. Җинаять ич бу — җир асты суларына зараза тондыра.

— Ә нефтяниклар нишли? Җир катламыннан нефтьне кысып чыгару өчен елгадан куылган суны чистартып торалармы әллә?

— Шуңа күрә чишмәләр пычрак...

— Бөтен Казан халкы Идел суын эчеп ятканда, безнең коелар кәүсәр әле ул. Йөз төрле чистарткыч аркылы үткәрсәң дә, Идел суы — эчә торган су түгел инде. Эчәләр ич әнә, миллион ярым халык исән.

— Сезгә ул коеның дренаж өчен генә кирәклеген Наил Кадыйрович беләме соң?

— Нинди кое?! Сез миңа егерме метрлы скважина бораулап бирәсез. Эчәмме мин аннан, бассейн суын түгәмме мин аңа — монысы минем эш. Акчасы түләнгән.

— Акчасы түләнгән, баяны уйналган, — диде Вәли, беренче көнне гаугага әверелдермәс өчен. — Хозяин — барин, ничек әйтсәгез, шулай бораулarбыз, әйеме, Фазыл! Сауна кызуы башка сукты бугай, үтәр, боерган булса...

Ул арада саунадан алсуланып чыккан кызларның чыркылдашуы ирләр арасындагы киеренке сүз көрәшен җиңде. Алар артыннан, дуңгыз көтүчесе кебек куалап, Мәдияр килә. Сул беләгенә эленгән өч сөлгене куярга урын тапмагач, бассейн читендә гәүдәсеннән су саркытып торган Фазылның иңенә каплаган иде, тегесе өнәмәде. Ләкин чиркануын сүз итеп кайтармады, сөлгеләрне йомарлап, талдан үрелгән утыргыч өстенә ыргытты.

— Коеныгыз, — диде Фазыл, әллә үртәп, әллә битәрләп, — берсекөнгә бу суны без казыган коега агызырлар. Аннан соң ул җир астыннан юл табып берәр чишмәгә килеп кушылыр. Бу тирәләрдә озаклап эшләсәк, үзебез эчәрбез.

## Кызыл тамгалы Шомбай

Көне буе егетләр ни эшләгәнне күзәтеп, хуҗаларча нәтиҗә ясап барган Хәсәншинның, кичкә кергәч, сөяге авырайды. Ул бүген, көнозын йөреп, күлгә су коенырга төшмәде, егетләр белән бергә утырып ашады, туктап ял итсәләр, яннарында басып торды. Сөйләгән сүзләренә колак салды, уйларын фаразлады. Инде җәйнең озын көне сүрелеп, ишегалдындагы баганада лампа кабызырлык караңгы иңгәч, хуҗа кеше түзмәде, черки ябырылган муенын каплардай кием эзләп, өйгә кереп киткән җиреннән юк булды. Мәдияр Фазылның күптәнге гадәтен белә, әгәр ул көне-төне эшләргә җыенган икән, димәк, бу урыннан тизрәк китәргә тели... Яңа Вәли исә моны төнге берләр тирәсендә генә аңлап алды.

— Ник, Фазыл абый, бүген ял итү юкмыни?

— Син кереп ят, агайне. Без Мәдияр белән бик сагындык әле бу эшне.

— Әйе, — дип җөпләп алып китте Мәдияр, алдан ук килешенеп куйгандай, уен кагыйдәсен саклап. — Безнең акча көри торган сезон башланды.

— Минем болай гына соравым иде. — Яңа Вәлинең үзенчә аклануы бу. — Төннәрне күргән бар, йокысыз Казан буйлап адашкан юлаучыларны күп ташыдым инде мин. Аннан соң бу бит әле минем гомеремдә беренче кое, беренче чишмә, ягъни мәсәлән. Ничек оялмыйча йоклап ятмак кирәк...

— Синең беренче... Ә безнең өч йөз дә беренче! — Бу сүзләрне Фазыл гына түгел, Мәдияр да әйтергә теләгән иде.

Таң яктысы аяк астына төшкәч, Фазыл Вәлине йокла, дип үгетләргә үк кереште. Аның аяк астында чуалмавы бик кирәк иде. Мәдияр белән киңәшәсе бар. Һәм чирәм өстендәге сырмага йөзтүбән капланган Вәлинең йокыга киткәненә ышангач, Фазыл, бораулауны туктатып, скважина эченнән балчыкны юдыра башлады.

— Нишлибез, Мәдияр? Хәсәншинга чишмә бораулыйкмы, әллә егерме метрлы коры чокыр гына казып бирәбезме? Хәзер су катламы башлана, тимәскә иде аңа...

Фазылның «нишлибез?» дигән соравына җавап бирер өчен, Мәдияр бераз уйга калды.

— Гамәлгә ярамаган кое казып бирсәк, бушлай эшләү була.

— Наил Кадыйрович акчалары түләнгән, диде.

— Яңа байларны белмәссең. Без китүгә, насос төшереп суын чыгарып караса. Коры скважина бораулап киткәннәр, дип гауга куптарыр. Әле яңа гына эшли башлаган килеш... беренче скважинадан ук конфликт китсә?!

— Аның каравы тыныч йоклыйсың. Җир асты сулары пычранмый!

— Әйе! Азатлык мәйданындагы кебек митинг үткәрәсе генә кала: «Суларны саклыйк!», «Яңа байларга хурлык!» Карын ач, кияргә юньле кием юк, фатир сатып аласы бар. Галина җиңгәң минем хәерчелеккә бер генә ел түзә алды, качты... Акча кирәк, Фазыл яшьти, намуслы бораулау остасы буларак, мин сине биш-алты елдан соң мактармын, яме.

— Мәсьәлә хәл ителде...

Агыйделнең аръягына Галя качты,
Утыз еллап куа-куа карным ачты.
Ач тамакны туйдырырга бик күп кирәк,
Байлар белән сөйләшергә хәйлә кирәк...

— Татар халык җырыннан бу. Шигырь яза башлаганмы, дип, мине кызгана күрмә!

Һәм Фазыл әйләнеп торган квадрат валның тормозын бушатты. Егерме метр тирәнлектәге долото су катламындагы чуерташларга эләгеп бөтен агрегатны калтырата башлады.

— Үч иткәндәй, суы да күп булачак әле моның! Мин мастер, дип күкрәк кагып әмер бирә торган чак түгел, кирелекне җиңәргә туры килә!

Тәүлекнең егерме алтынчы сәгате киткән иде инде.

Ташлы катламны үткәндә, бораулау торбаларының бер-берсенә ялганган урыннары нык кысыла, кувалда белән кыйнамыйча сүтеп ала торган түгел. Тимер тавышына Хәсәншин уянып чыкты.

Ул арада Вәли дә, чирәмлектән сикереп торып, астына җәеп йоклаган сырманы өстенә киеп өлгергән иде.

— Нәрсә, братлар, авария-мазармы?

Фазыл:

— Юк. Шулай тавышланып эшлибез инде без, — дигәч, Хәсәншин үзенә-үзе уйлап тапкан күнегүләр белән ишегалдында физзарядка ясый башлады.

— Хәзер полиэтилен торбагызны ялгап төшерәбез дә, артына ком тутыргач — вәссәлам. — Мәдияр Фазылга якынрак килеп дәвам итте. — Төне буе эшләгәнгә исе китмәде моның. Суы күп булачакмы, дип тә сорамады... Да... Син хаклы бугай, яшьти... Чынлап та, чишмә кирәкми, юынтык түгәргә тирән чокыр бораулата бу...

Маршрут кәгазендәге өч исемгә Наил Кадыйрович кызыл кара белән тамга суккан. Күрәсең, бу кешеләрне көттерергә ярамый, йә зур урында эшлиләрдер, йә туганнарыдыр... Егетләр ул кадәресен белергә тиеш түгел. «Ак Чишмә»нең президенты кызыл тамга суктыручыларны үзе генә белә. Мисал өчен, әгәр журналист Шомбайның өен күрмичә үтеп китсәң — тагын тынгы юк. Кабминнан шылтыраттылар: «Ни теләсә — шуны эшләгез. Скважина өчен бер тиен акча алмагыз. Чыгымнарын оешмагызның эчке резервы хисабына каплагыз!» — янәсе. Өстәгеләрнең сүзен санламасаң — тигез җирдән түмгәккә абынасыңны көт тә тор... Наил Кадыйрович бик кечкенә президент. Кирәкле кешеләре биегрәк кәнәфидә утыра. Аның куен дәфтәрендәге телефон номерларын барлап чыксаң — кемнәр генә юк! Ул теләсә кайсы генераль директорның, ГАИ начальнигы, министрларның өен белә. Дәүләт эшлеклеләре, премьер һәм хәтта Ил башлыгының үзе белән турыдан-туры элемтәгә керә ала. Гел түгел, тегеләрнең энекәш-сеңелкәшләренә, абый-апаларына, балдыз-кияүләренә, ханым-туташларына, сакчы-хезмәтчеләренә су скважинасы бораулаткан чагында гына. Саный китсәң, аларның туган-тумачалары бөтен илне яулап алган кебек... Әйтерсең лә суда гына яши ала торган тереклек ияләре — коеларның тирәнен, чишмәләрнең шаулысын сорыйлар.

Исемлекне җентекләп укып чыккач, Фазылның биленә кинәт утлы күмер тиеп үткәндәй булды. Унҗиденче кеше — невропатолог Кукушкин Г.Н. иде... Яңадан туып дигәндәй, эшли башлавына айлап вакыт үтмәгән килеш, «Әҗәл хәбәрчесе» белән көрешеп, бәхәсләшеп торырга әзер түгел иде әле ул. Фаҗигале көннәр ерагайсын, онытылсын бераз. Ордым-бәрдем генә хөкем карары чыгара белгән табибка карата күңел рәнҗүе басылсын.

— Бу капкага берәр елдан әйләнеп килербез, боерган булса. Исемлектән сызып торам мин аны, — дигәч, Мәдияр белән Вәли дә каршы төшмәде.

Кызыл тамгалы Шомбайның капкасына ялган йозак эленгән иде. Ачып керсәң — ишегалдында ыгы-зыгы. Ике малай тирес тарата, дүртесе — җир тигезли, түмгәк вата. Гаиләсе зур икән бу Шомбайның, дип уйлап куйды Фазыл. Ләкин сөйләшеп хәл-әхвәлне белешкәч, кирәкчеләрнең дә, бораулаучылар кебек үк, ялчылар икәнлеге ачыкланды. Малайлар совхоздан килгән, директор кушуы буенча, иртәдән бирле тырышалар, төшке ашка да кайтмаганнар. Монда чәй эчертеп сыйлап каршы алучы бар дип белгәннәрдер. Шомбай иртән күренгән үзе, нәрәт биргән дә югалган, бораулаучылар килә калса, менә

шушы урында тишсеннәр, дип, мунча кырыена казык кагып калдырган. «Җиде күл»дәге имеш-мимешләргә ышансаң, Шомбай — ветеран-журналист икән. Премьер-министр турында китап яза ди бугай... Гел зарлана торган, көйсез, әмма татарның беренче мактанчыгы икән. Дүрт сутыйлы бакчасын сукалатыр өчен совхоздан чылбырлы трактор чакырткан, әнә дүрт малай сүгенә-сүгенә шул буразнаны тигезли. Ике тазлы мунчасына сиксән метр тирәнлектән су чыгарырга кушып киткән...

— Менә шундый Шомбай, — диде Фазыл, үзенекеләргә хәлне аңлатып. — Хәсәншинның капкасы бикләнде. Шомбай коесын сохари белән борауларга туры килер...

Язгы ташкын чигенгәндә, җәелеп аккан елга эзендә чокыр саен кар суы җыелып кала. Алар кибеп, соңгы бака иске елгага күчеп киткәндә, инде җәй башланган була. Түгәрәк-түгәрәк камышлы тал түтәлләренә карап, язның куәтен күз алдына китерәсең.

Яшел Үзән белән Биектау төбәкләренең чиктәш авылларын йөреп чыккач: «Моннан нинди диңгез чигенде икән?» — дип уйлап куясың... Күлләрдән генә торган авыллар бар монда. Җиде күл... Аккош күле, Тирән күл, Олы Күлбаш, Якты күл, Раифа күле, Шарлавыклы чишмә, Суыксу, Аксу... Һәр яралган авылга исем таба алмаганга шулай кушканмы борынгылар? Юктыр... Бүгенгесе көндә исән калган өч мең ярым авылга кабатланмас исемнәр табылган ич...

## Ике яшьлек арасы

Зур су тирәсендәге авыллар ачлыкка бирешмәгән, корылык елларны җиңелрәк кичергән.

Борынгы бабаларыбыз, халыкны үрчетер өчен, Идел белән Чулман кушылдыгына күчеп утырган.

Хәзерге эшкуарлар, мөлкәтләрен саклар өчен, күл тирәсенә тамыр җәя.

Элеккегеләр сулы корылмалар белән дәүләтнең башкаласын саклаган.

Хәзергеләргә су — күңел ачу өчен кирәк...

Элек су чыгару бөтен авыл сөенерлек изге эш иде. Хәзер исә Фазыл бораулау остасы дигән һөнәре белән масая алмый. Чәнечкеле таш коймалар эчендә бикләп сакланган персональ чишмәләр суга сусаган гади халыкны куандырмый... Байларга эшләүнең сөенече юк... Ишегалларына кергәч, үзеңне батрак итеп тоясың...

Гомер юлы элек һәм хәзер, кичә һәм бүген, яшьлек һәм картлык дигән төшенчәләр белән үлчәнә. Син картайганга карап кына яшьлек югалмый... Әмирне әйтсәк, ул Фазыл белән Мәдиярның яшьлегендә яшәде. Инде Фазыл белән Мәдияр үзләре Текә Вәлинең яшьлегендә эшләп йөри. Кемнең яшьлеге дөресрәк, мактаулырак, күңеллерәк үткән дигән сорауга җавап юк... «Синең» белән «минем» яшьлекләрне чагыштыру бәхәскә керә.

Без, чабата киеп, кичке уенга чыга идек; черек бәрәңге күмәче ашап үссәк тә, Ватанны дошманнан саклап кала белдек, дияр Әмир. Ә без, яшь чакта, яңгыр явып үткәч, гөрләвекләрдә су коена идек, бозау, бәтиләрне кыш чыкканчы өйдә үстерә идек. Ул суыклардан өйнең бөтен бүрәнәләре шарт-шорт ярылып бетә, Сафура бураннары авылларны күмеп китә иде. Кар астына төшкән суны кер юарга ташыдык... Ә Казан каласында урамдагы колонка суларына сироп кушып, стаканын өч тиеннән саталар иде, дип элдереп китә Фазыл... Текә Вәли кушылмыйча калмас... Мин кибет суын гына эчәм, беткәннән-беткәнгә фирмачлар баллон белән китереп торалар, һәр көн иртән чиләк-чиләк апельсин, ананас, банан кабыклары түгәм; кызыл уылдык ягылган күмәч кисәкләрен берсенә-берсен каплап, ике катлап ашыйм, дип кызып киткәч, яңалар исеменнән мактанган Текә Вәлине туктатырлар. Чөнки черек бәрәңге ашаган, яңгыр суында коенып үскәннәрнең яшьлеге гарьләнә башлый. Текә Вәлиләрдән соң килгән буынның яшьлеге ни белән мактаныр, белмим, Җир шары түгел, Су шары өстендә яшибез лә — аның өчтән ике өлеше диңгез һәм океаннар белән капланган, калган өлешен дә коры җир кисәкләре дип әйтеп булмый — каян тишсәң, су бәреп чыга. Җитмәсә әле, ул сулар катлам-катлам... Су өстендә яшәгәч, халык ни күрмәс... Суның өч төрле халәте бар лабаса!..

Яшьлек белән яшьлекне чагыштыру — кешеләр арасындагы бик күп бәрелешләрнең сәбәбен фаш итә... Без йозак күрми үстек, капка-ишекләрнең келәсенә бау гына элә идек — өйдә юклыкны күрсеннәр өчен. Ә хәзер һәр яңа йортның беренче өч каты төрмә — тәрәзәләре рәшәткәле, ишекләр тимердән... Элек кыз бала, укыйсы килмичә, клубка чыга икән — аны шундук урлап, тормыш итә башлыйлар иде, ә хәзер клубка чыккан кызыйларны сумкаларын тутырып, тизрәк калага озаталар... Элек, ярты кило арыш урлаган өчен нәселеңне корыталар иде, ә хәзер, күбрәк урлаган саен, зуррак эшкә күтәрәләр...

Яшьлек белән яшьлек бәхәсләшкәндә, җиңүчеләр була алмый... Элек, һәр су скважинасын бораулатыр өчен, «Гипроводхоз» институтында махсус проект төзетәсе һәм аны, ким дигәндә, алты баскычтан имзалар куйдырып раслатасы бар иде. Ә хәзер кем кайда, ничек тели — су чыкканчы бораулый да китеп бара. Хәтта эчәргә ярыймы ул, ярамыймы дип, анализ ясарга кушучы да юк...

— Аның каравы хәзер кирәкле кешене хөрмәт итә беләләр. Сауналарда кыздырып, «баяннар» белән су коендыру яшь чагыгызда төшегезгә кералмаслык әкият булган әнә...

— Алай димә, Вәли!

— Мәдияр абыеңның сиңа әйтәсе килә: саф сөю, керсез-чиста мәхәббәт безнең яшьлектә дә барые...

— Мунчадан соңмы?

— Әйе, Вәли брат, Фазыл белән яшь чакта колхоз хисабына «баяннар» белән мунча кергән көннәрне онытмадык әле без.

Гомердә булмаганны Мәдияр, бүген Вәли алдында калай әтәчләнеп, яшьлекнең башкаларга сөйләргә ярамаган күренешләрен искә төшереп маташа. Нырты совхозындагы мунча керүләрне Текә Вәлигә тасвирлап бирүдән егетлегеңнең мәртәбәсе артамы? Шушы бер очраклы вакыйга белән мактанып, дөрес яшәлгән гомернең матур чынбарлыгын ямьсезләп куяргамы? «Син күргәнне — мин киптереп элгән» дияргә телисең икән, димәк, син хәзер үзеңнән егерме яшькә кечерәкләр белән ике арага тигезлек билгесе куярга омтыласың, ике яшьлек арасындагы вакыт үлчәмен санга сукмаска тырышасың...

Юк, сөйләмәде Фазыл Нырты хәлләрен, Вәли алдында Мәдиярны серле, горур һәм мәгънәви итеп саклап калыр өчен сөйләмәде. Нырты мунчасы — су өчен барган көрәшнең бер күңелле сәхифәсе генә ул... Чатнама суыкларның җил уртасында көннәр буе вахтада торган өчен; карлы бураннарны җиңә алмыйча, өзелгән юл өстендә куныып калган төннәр өчен; тездән ләпек ерып машина көпчәкләрен казып чыгарган өчен; урман-кырлардан ризык эзләп ачлы-туклы үткән айлар өчен; шәфкать кулы күрмичә төзәлгән тән җәрәхәтләре өчен. Егерменче гасыр казанышларыннан ваз кичеп, кыргыйларча, табигать кочагында һәм тагылмалы яшел вагонда үткән яшьлек елларында рухи һәм матди югалтулар бәрабәренә табылган күңел юаткыч иләслек, тыелган алма иде ул Нырты мунчасы.

Иске җәмгыятьтән ваз кичеп, яңача яшәү рәвешенә күчү — иске бәрәңгене ташлап, яңа бәрәңге ашый башлау гына түгел шул. Кешеләрнең үзаңы сул яктан уң якка бик авыр күчә. Кичәге коммунист Наил Кадыйрович та әнә үзен яшь капиталист дип исәпли, сул аягындагы итеген уң аягына киеп азаплана. Итекләреңне бутап кисәң, юлың турайганчы аягыңа шактый сөял чыгар... Бер уңайга яшәргә өйрәнгән элеккеге бораулаучыларны бүгенге шартларга күнектерәсе бар...

Фазыл, ике гасырның ызан сызыгына басып, як-ягына карана. Иске дә, яңа да түгел әле абзагыз... Ачлы-туклы, кырыс, югалтулар белән тулы үткән заман ни аңа, океан артыннан яңа урысларга ияреп кайткан сәяси хөррият, интернациональ акчалар, базарлы вәгъдәләргә күмелгән киләчәк заман ни... Көянтәсенә эленгән тәлинкәләре буш булса, бизмән, як-якка авышмыйча, тигез тора ала. Ләкин Фазылның гамь бизмәне буш түгел... Бүгенге вазгыять дигән чынбарлык битарафлыкны яратмый, уңга авышырга куша. Үткән заман шөгыльләре ял иткәндә искә төшереп юаныр өчен генә кирәк. Бүгенге уңышларны исә: эшли, эзләнә, үзгәрә дигән хәзерге заман фигыльләре хәл итә...

«Ак Чишмә» җыйнак оешма, ул үзенә-үзе хуҗа. Аның хәзер ялтыравык кәгазьләргә төреп приказлар, күрсәтмәләр, кисәтүләр җибәреп торырлык трестлары, идарәләре, министрлыгы да юк. Наил Кадыйрович үзе президент, үзе министр, үзе управляющий... Эшчеләрнең көнкүреш шартларын яхшырту, ел ахырында өләшерлек табыш китерү, иске бораулау агрегатларын яңарту. Иң мөһиме, бригадалар тик ятмасын өчен, өзлексез эш белән тәэмин итү...

Элек бораулаучылар эш күплектән интегә иде. Ел башыннан кулыңа план тоттыралар. Унөч авылга барып, унөч кое бораулап, колхоз яисә совхозларны сөендереп кайтсаң, әйбәт бригада исәбенә керәсең. Әгәр инде планыңны өч-дүрт авылга арттырып үтәсәң — син хезмәт батыры! Министр фәрманы белән синә матди рәхмәт явачак...

Ә хәзер... Бюджет акчасын капка төбенә җәйгән яңа байларга персональ кое бораулап бирәсең дә яңадан заказлар җыелганны атналар буе көтеп йөрисең. Димәк, әлеге өзеклекне билгесезлек, мескенлек, хәтта вакытлыча эшсезлек дип атасаң да була. Эш барында җыйнап, заказлар югында тарата торгач, егетләр өметсезләнеп, кайсы кая үз мәшәкатьләре белән тарала, аларны кабат чакыртып китерүе шактый вакытны ала. Агрегатны гаражга илтеп куйгач, бер-береңне эзләп табарга дигән сурәттә: «Син кая кайтасың, кем тирәсендә югаласың, телефоның ничек әле, кайдалыгыңны туганнарың беләме?» — ише сораулар ява башлый...

— Атна саен шылтыратып торыгыз! — диде Наил Кадыйрович, егетләрне Восстание урамында төшереп калдыргач. — Мин яңадан «Ак Чишмә»гә киттем. Вәлине сезгә бораулаучы итеп җибәргәннән бирле, аның урынына яңа шофер алганым юк әле. Рульдә гел үзем йөрим... Өйләрегезгә таратып тормыйм, үпкәләмәгез, вакыт юк.

— Тупиктан олы юлга чаклы чыгарып куйгач та рәхмәт инде, — диде Мәдияр, «джип» тирәсенә килеп кунган ике «күбәләк»кә сәлам биреп.

Наил Кадыйрович кире борылып «Оргсинтез» ягына юнәлгәч, Вәли «джип»та шәхси шофер булып йөргән көннәрне юксынганын сиздермәде, киресенчә, хуплады гына бугай:

— Бу кеше мине яңадан үз шоферы итмәкче, ахрысы! Юк инде, байларга кое бораулап йөрү ошый миңа!

— Чакырса, ризалашмый нихәл итәрсең?! Алар хәзер безгә эш бирүчеләр. Сүзләрен тыңламасаң, урамга куа да чыгара.

— Менә Восстание урамына чыгарып ташлады ич әле, тагын кайчан дәштереп алыр, анысы билгесез, — диде Фазыл, Мәдиярны хуплап.

Вәли, әллә үртәлеп, әллә сүз көрәштерүдә алга чыгарга теләп, башында ниндидер хикмәтле уй йөрткәнлеген сиздереп өлгерде.

— Алайга китсә, минем әле бик шәп планым бар... Тагын берәр ай эшләп карыйк та, әйтермен...

— Юк инде, — дип чәчрәп чыкты Мәдияр, — хәзер үк әйт! Җавабын әйтмичә йөдәтсәләр — табышмакларны җенем сөйми. Кроссвордлар чишә башласам — психланып бетәм. Сюрприз, дисәләр, сүгенәм... Серем бар, дисәләр, йоклый алмыйм... Сүзеңне башлагансың икән, ахырынача әйтеп бетер!

— Мәдияр, син Вәлигә бәйләнмә! Танышканыбызга айлап вакыт үтмәгән, ышанмый торгандыр ул безгә. Бәлки әле, аның планнары безгә кагылмыйдыр. Буровойны рәтләп белмәгән кеше яңалык кертә алмас.

— Яңача яшәп карар өчен һәркемгә дә хезмәт ветераны булырга димәгән. — Вәлинең тавышында үпкәләү-сукрану моңы юк, киресенчә, үз уена үзе бик нык ышанганлыгы сизелеп тора. — Кулыннан килгән кеше ялланып эшләргә тиеш түгел. Юкса хәерчелектән башың чыкмас.

— Бер башлагач, аңлаешлырак итеп әйтеп бетер, — диде Фазыл да сабырсызланып.

— Бораулау агрегатын үзебезгә алабыз!

— Бетең беләнме?! — Мәдияр бу сүзләрне Вәлигә түгел, күбрәк үзенә-үзе әйтте. — Бөтен Советлар Союзы буйлап Галина белән кунача эзләп йөри торгач, кесәм такырайды, күңелем бушады.

— Минем дә запас күп түгел, — диде Фазыл, Мәдиярның моң-зарын зурга җибәрмәс өчен. — Коммунистлар заманында эшләп җыйган акчам демократия җылысында эреп бетте. Җитмәсә, авылда өй саласым бар... Дөрес, безнең Әмир дә бар бит әле. Зурдан кубып эшкә тотынсагыз, минем барлыкны онытмагыз, дигән иде...

— Запас ягыннан үзем дә әллә ни мактана алмыйм, — дип, үзе дә ярлылар ягына авышты Вәли. — Без бит әле эшләп торабыз. Күргәнегезчә, алай ук акчасыз эш түгел. Өч борынга «общяк» ясап туплыйк та Наил Кадыйрович каршына килеп басыйк: «Ак Чишмә»дән бүленеп чыгабыз, «Ак су» дигән фирма төзибез, диярбез.

— «Ак су», «Ак су»... Аксубай кебек, мин ул районны яратмыйм, — диде Фазыл.

— Причем монда Аксубай районы, «Ак су», ягъни ап-ак су дигән сүз килеп чыга, әйеме, Вәли?

Фазыл Вәлигә сүз әйтергә ирек бирмәде.

— «Ак су»... Көмешкә кебек. «Ак таныш» фирмасы итик.

— Котырдың инде, Фазыл, шул Актаныш белән. Президент итеп Аксубайның берәр кешесен сайлап куйсалар... «Ник?» дигәнеңә үкенерсең әле...

— Үзең әйтмешли, причем монда ил башлыклары, Актаныш — минем беренчем. Син аны, Мәдияр, бик яхшы беләсең.

— Беләм, беләм, Аккүздәге Әлфинәң намаз ияседер инде, сиңа да зыян итмәс, әнә ахшам вакыты...

Сүз куерту әрләшүгә әверелмәсен тагы дигәндәй, Вәли тавышын көчәйтте:

— Карагыз әле, егетләр, яңа фирмалар өчен менә дигән исемнәр бар икән: Аккүз, Акшам, Аккош, Акбаш...

— Атланма, билен сындырырсың! — диде Фазыл, хыялый Вәлине туктатып. — Сүз башына әйләнеп кайтсак әгәр, синең тәкъдимеңдә җелек бар. Барыбер яңача яшәргә өйрәнергә туры килер... Пермь өлкәсенең Кунгур шәһәренә барып килсәк, заводның үзеннән өр-яңа станок алып кайтабыз инде дә, ну өч йөз мең доллар җыярлык гомер калмады... Ә менә Наил Кадыйрович белән уртак тел табып, үзебез ремонтлаган шул искесен сатып алырга тәвәккәлләп була... Ә бүгенгә таралышыйк...

— Тукта әле, Фазыл, башланган сүз ярты-порты килеш калмасын. Димәк, без, әгәр теләсәк, аерым фирма ача алабыз?

— Әгәр Наил Кадыйрович ризалашса, әйе! — диде Вәли, никтер Фазыл өчен җавап тотып. — Әлегә мөлкәт аның кулында.

— Алайса, буш хыял гына бу! Җир астыннан акча көри торган бораулау станогын ник безгә бирсен инде ул!

— Бирә. Һәм фирманың дүрт учредителе була.

— Без өчәү генә ич, — диде Мәдияр, беркатлыга сабышып.

— Наил Кадыйровичны кушып сана.

— Начальниктан котыла алмагач, нинди мөстәкыйльлек соң инде ул?

— Табыш дүрт өлешкә тигез бүленәчәк. Фирма кәгазьләренә кул куеп, банк аркылы чеклар үткәрер өчен беребез директор, теләсәк, генераль директор итеп исәпләнәчәк.

— Кем? Фазылмы?

— Юк, Мәдияр, — дип аркылы төште Фазыл, — директор да, президент та буласым килми. Мин гомергә начальствоны сөймәдем. Андый хыялым юк!

— Ну, йөрисең инде, алайса, ялчы булып.

— Тукта әле, Мәдияр, — дип, тагын дилбегәне үз кулына алды Вәли, — безнең арада ялчылар юк, барыбыз да компаньоннар булып калабыз.

— Син нәрсә, Вәли, безгә әйтмичә генә Наил Кадыйрович белән алдан ук сөйләшеп куйган идеңме? — диде Фазыл, егетнең үҗәтлегендә төпле киңәшче фикере барлыгын сизенеп.

Текә Вәли җавап бирмәгәч, Мәдияр да батырайды:

— Димәк, безнең яңа хуҗабыз син буласың?!

— Әйе... Ләкин сезнең белән тигез эшләячәкмен мин.

— Буровойга «джип»тан төшкән кеше генә ич син. Гидрогеологиянең сыңар хәрефен дә белмисең.

— Сез белгәне җиткән, Фазыл. Аның каравы минем машиналар төзәтү буенча фирма ачып карагаsuccessful бар.

Һәм Текә Вәли егетләр белән кул биреп саубуллашкан уңайдан гына узгынчы машина туктатып китеп тә барды. Ул киткәч, Фазыл белән икәүдән-икәү генә калып кабат сөйләшергә исәбе бар идеме, Мәдияр күзгә текәлеп тик торды. Ләкин яңача яшәргә өндәгән текә егет хакында бүтән сүз кузгалмады.

— Бар, вакытыңны әрәм итмә, — диде Фазыл, Мәдиярны билгесез тарафка ашыктырып.

— Ә син үзең кая кайтасың? Әйдә минем белән. Аена йөз доллар түләп торышлы аерым фатир таптым, икебезгә дә урын җитәр!

— Юк. Мин кунакханәгә ияләштем. Анда кеше күп, ыгы-зыгысы рәхәт. Таныш кунаклар да күп очрый... Фатир хакы синекеннән артык чыкмый...

Аерылышу күңелсез тонда бетәчәк иде. Шулчак җете кызыл блузка кигән, кукуруз чәкәнедәй үтә сары чәчле, өлгергән күгән җимешедәй зәңгәр күзле бер «күбәләк» килеп басты. Ашыгычлык белән итәген кияргә онытканмы — елан кабыгыдай челтәрле кара колготкие тулысынча күренеп тора.

— Мальчики, — диде кыз, ике күзенә бер юаныч эзләп, — ял итәсегез киләме?

— Урам бәясе күпме соң бүген?

— Тулы программа белән дисәгез — ун бакс!

— Урының бармы соң, кызый?

— Болары вак мәсьәлә, кирәк дисәң...

— Ә синең исемең Галина түгелме?

— Юк.

— Жәл.

— Алайса, Галканы чакырам. Бик хәтерләп калгач...

— Кирәкми. Галина ерак инде.

— Аңламадым. Минме, әллә Галка кирәкме?

— Китмә, хәзер миңа кайтабыз! — диде Мәдияр, «күбәләк»не канатыннан сыйпап. Ә үзе Фазыл алдында акланасы итте. — Кайсыдыр җире белән Галинага охшаган бит бу, ә?!

— Галинаң әби яшенә җиткәндер инде. Син аның исемен яхшылап сора, Регина түгел микән?..

Регина дигән исемнән Мәдияр, бәке суына таеп төшкән малай-шалай шикелле, куырылып калды.

— Ну, Фазыл, әгәр чит кеше булсаң, моның өчен ияк төбеңә менеп төшә идем инде. — Һәм Мәдияр, «күбәләк»кә илле сумлык акча сузды. — Бар, кызый, минем рәт юк бүген.

— Танымадыңмы тәки?! Хәсәншин мунчасындагы «баяннар»ның берсе бит ул...

— Әгәр уйласаң, беркая китмә! Шушында гына тор. Егерме минуттан әйләнеп киләм мин, — дип кычкырып калды «күбәләк», «Газель» машинасына утырганда.

Кызык, дип аптыраштa калды Фазыл, челтәр ботлы, кызыл канатлы, сары башлы бу «күбәләк»нең кайсы төше Галинага охшаган икән соң?.. Әйе, бозыклыгыңа аклану кирәксә, юксынган кешеңне капма-каршы төсләрдән эзли башлыйсың икән ул...

## Сәяхәтче күрше

Фазылны ишек шакып уяттылар. «Совет» кунакханәсенең гореф-гадәтләрен яхшы белә ул. Әгәр бикле ишек аркылы: «Сезнең бүлмәгезне җыештырасы бармы?» — дип эндәшмәсәләр, димәк, чакырылмаган кунак кызлар үзенә түләүле юаныч эзләп йөри...

Йокы туйган кебек тоелса да, сәгать унике генә иде әле. Төн уртасында хезмәткәрләр борчымый. Бүлмә саен кереп оялаган чикле-шикле фирмалар да офисларын кичке алтыда ук бикләп таралыша. Кунаклар берән-сәрән генә калды хәзер ханәләрдә.

Күңелдә коткы бар анысы... Өч йөз тәңкә акча бәрабәренә унтугыз-егерме яшьлек чибәркәйләр тансык рәхәтлекне ишек төбенә үз иреге белән алып килә. Ләкин уйнашчы кызлар, тәнне тауар итеп сатучы сутенерлар, миңгерәйткеч үлән таратучылар, арзанга ясалма аракы китерүче шинкарь түткәйләр — барысы-барысы да муллык арбасына ачыктан-ачык ияреп кергән базар вируслары гына. Белгән кешеңне генә кочарга, белгән җирдә генә эчәргә, таныган ризыкны гына ашарга өйрәткән заман бу. Әгәр берәр зәхмәт эләктереп, аяктан егылсаң, сине кем карый? Кемгә сыенырсың, газиз башкайларыңны кая куярсың? Чире азынган сукбай кебек, чүп савыты төбендә кәкрәеп катасыңны көт тә тор! Һәм Фазыл,

очраклы сөешүләрнең әхлакый ягыннан бигрәк, әнә шул зәхмәтеннән курка. Бу курку рәхәткә сусауны төннең теләсә кайсы вакытында да тыя ала.

Шакылдау күрше ишеккә күчте. Тупса чыелдаган тавыштан соң шактый вакытка тынлык урнашты. Ләкин йокы качкан иде инде.

Фазыл асылмалы кара сумкасын бушатып, яңадан тутыра башлады, юл кирәк- яракларын барлады. Гадәттә, ул сумканың йозагын ябар алдыннан иң өскә ком сәгатен куя торган иде. Бу юлысы ашыкмады. Әле юлга чыгарга иртә. Көне буе кайтасы бар, бераз ял иткән очракта, юл газабын кичүе җиңеләер. Ул, ком сәгатен кулына алып, киенгән килеш кенә тагын урынга барып ятты. Биш минут саен вакыт дигәнең ком булып әле бер якка, әле икенче якка агыла. Ком агышына күз ияргәч, йокы куера.

Атна башында Актаныш автобусы яртылаш буш йөри икән. Казаннан чыккан чакта егермеләп пассажир бар иде, алары да Чаллы белән Минзәләдә коелып беттеләр. Ахыр чиктә алты гына кеше калды. Юл тигез, йөк әз дигәндәй, автобус үкереп бармый, тәрәзә артында шаулаган җил ике күршенең сөйләшүен дә җиңә алмый. Алты кеше салон буйлап урын сайлый, дөресрәге, юл борылган саен, күләгә эзләп, әле бер, әле икенче якка күчеп, кояштан кача.

— Без яшь чакта Актанышка самолет белән йөрешле иде. Башта «Ил-14», аннан «Л-410» очты, — диде Фазыл, алдагы рәтнең ике кешелек утыргычында үзе генә тугарылган малайга сүз катып. Ул аны Актаныш кешеседер дип уйлады.

— Беләм. Билет бәясе тугыз сум иде... — Борылып җавап биргәндә, күршесенең йөзен күреп алды Фазыл. Юк, яшь егет түгел, буйга гына шулай малайларча бәләкәй икән. Чаларган чәчен кына буявы белән яшергән. — Ә син ник ком сәгате тотып барасың, дару эчәсең мәллә?

— Юк, эчмим. Ком сәгате йөрәгемне тынычландыра. Ә сез Актанышка кунакка кайтып барасызмы?

— Каян белдең? — диде малай-агай, «сез»гә «син» белән җавап кайтарып. — Әйе, мин кунакка кайтам. Ну, син уйлаганча ялга түгел. Журналист мин. Гомерем буе ерак районнарның арадашчысы булдым. Яшьләр еракка чыгарга яратмый хәзер.

— Эш буенча почти братлар икәнбез.

— Әллә син дә журналистмы?

— Юк. Мин артезиан коелар бораулаучы. Гел юлда.

— Мин командировкада чакта сезнекеләр килеп бораулап киткәннәр. Премьер-министр миңа көн саен шылтыратып, хәлемне белешеп тора. Сүктем әле беркөнне үзен. Мин, димен, атаңның яшьлек дусты, сине энекәшләрең белән теземә утыртып сөйгән кеше. Мине сусыз яшәтеп, «Җиде күл»нең яңа акулалары алдында мыскыл итәсең, димен... Гафу үтенде, иртәгә үк килерләр буровиклар, ди... Сиксән метрга төшкәнче казысыннар, дип әйтеп калдырдым. Байлар суны тирәннән алып эчә. Сай кое — хәерчеләр коесы... Эшләгәннәрен күзем күрмәсен дип, бер атна буе Нурлатта йөреп кайттым. Андагы глава минем белән киңәшмичә бернәрсәгә дә тотынмый...

— Сезнең исемегез Шомбай мәллә?

— Шомбай — минем әдәби кушаматым. Ә син каян беләсең мине?

— Сезне белмәгән кеше юктыр ул.

— Анысы шулай, теләсә кайсы главаның ишеген тибеп ача алырдай бердәнбер журналист инде мин. Популярлык буенча Салаваттан кала икенче кеше.

Фазыл ни дип тә җавап бирергә белмәде. Җиде күлдәге скважинаңны мин бораулап бирдем сиңа, карун, әрәмтамак, кызыл сөлек, дип әйтергә теле бик кычытып торса да, түзде. Сүзне автобус маршрутына кайтарды.

— Мин Актаныштa утыз ел элек эшләп киттем. Менә сагынып кайтып килә̆м. Районны аркылы-торкылы йөреп чыгарга исәбем.

— Һи, агайне, Актанышны алыштырып куйдылар, танымассың син аны. Утыз ел элек иске агач авыл иде ул. Ә хәзер бишәр катлы конторлар, бассейнлы сарайлар, Мәскәүчә фатирлар, рестораннар, игелек йортлары. Инфраструктура гөрләп үсә... Гади халыкка эш кенә юк. Их, шунда бер кечкенәрәк завод салып куярга!

— Шулай дип яздыгызмы соң?

— Син нәрсә, политически неграмотный мәллә?! Ил башлыгының туган ягына кайтып, акыл өйрәтеп йөрергә, әллә син мине чын Шомбай дип белдеңме?

— Нәрсәгә генә кайтасыз соң алайса?

— Тираж эшләргә. Подписка башланды.

— Мин сезнең журналистлар телен аңламыйм.

— Актанышның укый-яза белә торган халкын бөтен республикага начальство итеп таратып бетерделәр. Грамотный кешеләре бик аз калып бара, алары шул — беркая куярга ярамаганнар гына, журнал алдырмый, китап укымый. Тиражлар кими Актаныштa.

Автобус Актаныш базарына туктап, ике ишеген дә ачты. Идән астындагы әрҗәләрдән тауар бушатырга дип калган дүрт пассажир янына ярдәмче егетләр килеп басты.

Журналист, җиргә төшкәч, чалбар балакларын сыпыргалады. Җете зәңгәр күлмәк якасын буган яшел галстугын төзәтте.

— Ашыкма, китми тор! — диде ул Фазылга. Һәм бер йозаклы кара портфель кесәсеннән тар, озын тарак чыгарып, озак итеп чәчен тарады. Күренеп тора, ул вакытны сузарга тели, үзен каршы алырга тиешле кешенең тоткарлануына эче пошканын сиздермәскә тырыша, кечкенә генә гәүдәсен дә мәгърур итеп тота иде.

Каршы алучы егет буй-сынны нygыткан, тавышы өлгергән, мәҗлескә килгән кунак кебек пөхтә киенгән. Бер минутка соңга калганы өчен ярты минут буе гафу үтенде.

Каршы алучылар йоласы дигәндәй, журналист аңа портфелен тоттырмакчы иде, тегесе аңламаганга сабышты, адымын кызулатып алгарак чыкты. Ләкин журналист әрсезләнүен дәвам итте.

— Мәле, иптәш буровой мастер, — диде ул, Фазылның буш кулына портфелен тоттырып, — синеке җиңел күренә, иңбашыңа эленеп кенә бара. Ниме, — диде ул, хакимият вәкилен тукталырга мәҗбүр итеп, — менә бу абзаңны үземнән калдырмыйм. Минем әле утыз ел редакциядә эшләп, кое бораулаучылар турында язганым юк иде. Сезнең районда эшләгән икән. Икебезгә бер машина бирерсез, Актанышны йөреп чыгабыз.

— Гафу итегез. Мондый мәсьәләне глава гына хәл итә ала. Мин бүгеннән Казан кешесе. Мәдәният министрлыгына эшкә күчерделәр. — Вәкил, һәр авазның дикциясен төгәл итеп, логик басымны дөрес куеп, нокталарны ишеттереп әйтте.

— Әһә... сине дә Казанга, значыт. Актаныш хатын-кыз түрәләр кулына кала икән...

Фазыл, үзен артыксынып, журналистның портфелен кире бирмәкче иде, тегесе ике кулын кесәсенә тыкты.

— Юк, агайне, бергә барабыз. Монда мин хуҗа. Дүртенче власть диләр мине, шуны бел. — Ахрысы, ул әлеге сүзләрне вәкил ишетсен диебрәк әйтте.

Сигез сәгать буе автобуста кайтып, Фазыл уйларга теләмәгән бер мәсьәлә бар иде: Актанышка килеп төшкән кичне кайда кунып калырга? Әгәр иренмичә, бик җентекләп җавап эзләсәң, әлеге сораудан каушап, килгән автобусыңнан төшеп тормыйча, кире Казанга китәргә туры килер иде. Ник дигәндә, район кунакханәләрендә хәзер нибарысы ике-өч бүлмә булып, анысы да үзәктән килгән тикшерүчеләр, салым инспекторлары, министрлыклардан җибәрелгән ревизор, журналистлар һәм артистлар белән тулыр. Әгәр инде төн кунып чыгарга теләсә кайсы авылда элеккеге фатирларның берәрсе танып кертер әле дип ышансаң... моннан утыз ел элек үк илле-алтмыш яшьтә исәпләнгән хуҗабикәләрнең кайсысы гына исән икән инде?! Тәвәккәллек өчен дә җитди сәбәп бар. Әле көн озынлыгы кыскара башлаганга унбиш кенә тәүлек, челләдән кызынып калган җәйге төн таң атканчы суынмый. Фазылның иңендәге юл сумкасы җиңел, әгәр Казан автобусыннан Богады авылында төшеп калсаң, дүрт чакрымлы сукмакны яктыда үтеп, әби-бабайлар капка бикләгәнче, Каенлыкка барып җитәргә була. Әлфинәне фәкать Каенлык авылыннан гына эзләргә мөмкин. Анда Ниса кортка исәндер әле, бәлки. Фазылны күреп таныр, сөенер, онытмаганы өчен хәтта рәхмәт тә әйтер. Якын туганнар да бер-берсен оныта. Ә Фазыл бөтенләй чит кеше, фатирант, утыз елдан соң сагынып килгән. Ниса кортканы түгел, җәйге каникулда кунакка төшкән Әлфинәне эзләп йөриме? Барыбер горурлык — Әлфинә Ниса кортканың оныккачы лабаса!

Шомбайның очравы Фазылның сәер сәяхәтенә үзгәреш кертте. Гомер буе каләм белән казынып җан асраса да, җир кешесе иде, кунакханәдә үткәрелгән төнге әңгәмәдә бораулаучы абзагызның ни югалтканын һәм, утыз елдан соң әйләнеп килеп, кемне эзләп йөргәнен бик тиз төшенде ул. Төшенде, ләкин сиздермәде. Егетнең хезмәт юлы журналистика өчен яңа тема иде. Яңалык — укучының икенче азыгы. Журналист Фазылның рөхсәте белән диктофонны кабызып өстәлгә куйды. «Истәлеккә» дип язылася әңгәмә озаграк сузылсын өчен, ул сүзне Фазылның Актаныштагы яшьлек мәхәббәте турында башламады.

— Фазыл, мин наданга аңлат әле син, Казан шәһәре ник Идел суы эчә? Җир асты саранмы?..

— Казан халкына Идел суы эчертү — бүгенге җитәкчелекнең иң зур җинаяте. Безгә килеп җиткәнче, Идел, 1200 чакрым үтеп, үз юлында зур пристаньлы җиде шәһәрнең әшәкесен юып алып төшә. Шәһәрне юу дигәндә, аның канализациясен, завод-фабрика калдыкларын, кыш буе җыелган мазутлы, әшәке кар суларын уйларга кирәк. Шуның өстенә Иделнең әле Ока, Сура, Зөя кебек дистәләгән кушылдыгы бар, аларның нәҗесен дә кушып сана.

— Әйтәм җирле, өйдәге су юынганда күзне әчеттерә...

— Борынгы кешегә шәһәр торбаларыннан без эчә торган суны бер стакан бирсәң — шундук агуланып үләр иде.

Журналист, йөзенә чиркану чыгарып, стаканлы чәйне читкәрәк этеп куйды, ләкин авызында эреп бетмәгән карамель тынгы бирмәгәч, чәйне тагын үзенә алды.

— Фазыл, Казан халкын ничек саклап калырга була, буралы коелар казырга кирәкме?

— Коеларны, чишмәләрне без өске сулар дип атыйбыз. Яңгыр, язгы ташу, юынтык сулар үтеп кергәнгә күрә. Олы юл читендәге чишмәләргә дә ышанмагыз. Асфальт өстендә тузган каеш көпчәкләр циа-

нитка таркала. Аларны яңгыр юып төшерә. Әгәр чишмәдән алып кайткан су өстенә юка элпә утырса — берүк кайнатмыйча эчә күрмәгез.

— Алайса, Мәликә, Хәмит чишмәләренә дә ышаныч юк?

— Актаныш, Мөслим, Мамадыш, Кукмара, Балтач, Әгерҗе һәм Идел белән Каманың аръягындагы районнарда мин теләсә кайсы чишмәнең суын улакка ятып эчә алам. Тугайлары, урманнары сау-сәламәт Җирдә — су да сихәтле.

— Безнең редактор саннар белән мисал китергәнне ярата. Суның киләчәге хакында фикерегез ничек?

— Татарстанның җир астында ике миллиард кубометр төче су бар. Нефть беткәч, без әле валютага су сата башлаячакбыз. Кибетләргә керсәң, су бәясе сөтнекен узып китте инде... Җөмһүриятебез уникаль урынга урнашкан: биш йөз елгабыз, җиде мең күл, өч мең чишмәбез бар. Шуның өстенә бүгенгесе көнгә алты мең артезиан кое бораулапган.

— Рәхәтләнеп эч, әйеме?! Йөз елга җитә!

— Дөрес, безнең илдә су белән сүзнең бетәсе юк. Диктофонны сүндерсәк тә була.

— Гафу ит, Фазыл әфәнде, әңгәмәне төгәлләр алдыннан үзең турында бер-ике генә сүз әйтеп үт.

— Аны әйтеп торасы юк, «Ак Чишмә»дә эшләүче бөтен бораулаучыларның да язмышы бер төрле. Авыл малайлары, гомер буе юлда. Хәзер инде безнең эшкә яшьләр бик килми. Элек, Ростов-Дондагы махсус мәктәпкә җибәреп, бораулау осталары әзерлиләр иде, хәзер укыту өчен түләрлек оешмалар бетте. Шуңа күрә бүгенге бораулаучылар арасында илледән дә яшьрәкләрне табуы бик кыен. Яшьләр хәзер комфорт ярата: утыз каналлы телевизорлар, төнге клублар, сауна-бассейн, сыраханәләр, әзер кызлар кирәк аларга. Ә без кыр кешеләре...

— Авылдан авылга йөреп, Татарстанның иң чибәр кызын сайлап алдың инде, әйеме, Фазыл әфәнде?

— Иң чибәр кыз... — Фазыл бармагы белән диктофонга төртеп сүндерергә ымлады. Шуннан соң гына, урындык аркасына терәлеп, җиңел сулап куйды. — Иң чибәр кыз, утыз ел элек шушы Актанышта калды.

Журналист үзе дә туганнарча сөйләшүгә күчте.

— Һәм син аны эзләп кайттың. Кем ул, кайсы авылдан? — Һәм, Фазылның көлемсерәп эндәшми калуын өнәмичә, дәвам итте: — Мин Актанышның һәр авылын, һәр җан иясен беләм. Язмаган кешем калмады...

— Ә Аккүздән Самат абыйны?

— Галимҗановмы? Аның әле бертуган энекәше райкомда эшләде. Беләм мин аны. Хатынының энисе Каенлык авылында яши иде.

— Нишләп иде?

— Үлгәненә җиде еллап бардыр. — Фазылның, кинәт борылып күзләрен яшерүе, журналист өчен көтелмәгән хәл түгел иде инде. — Димәк, син Әлфинәне эзләп килгәнсең...

— Ерактан гына, гәүдәсенең шәүләсен күрәсе иде, тавышын гына булса да ишетәсе иде.

Журналист, мәсьәлә чишкәндә җавабы дөрес чыкмаган мәктәп баласы шикелле, ручкасын өстәлдәге кәгазь өстенә ыргытты. Стенага кадакланган радионы ачып карады — ләкин ул көндез генә сөйли торган нәрсә иде. Тимер өстәл өстенә беркетелгән «Чайка» телевизорының унике төймәсенә басып чыкты, әйтерсең лә үзен борчыган сорауга җавапны шуннан эзли иде ул. Экранда Чаллы программасыннан боевик килеп чыкты, ОРТда — сәясәтчеләр мәҗлесе, СТСта — сабынлы сериал... Ә калган каналларда «яңгыр ява».

— Фазыл, агайне, син романтик кеше инде. Ну бит, тормышның чынбарлыгы көчлерәк... Син беләсеңме соң, Әлфинәнең ат хәтлек улы, буйга җиткән кызы бар. Ире автобус йөртә. Әбиләре үлгәч, Чаллыдан күчеп кайттылар. Ниса кортка нигезендә кирпечтән менә дигән өй салып чыктылар, авылда кибет ачтылар. Алар җир кешесе. Рәхәтләнеп яшәп яталар. Син килеп хәзер гаилә бозарга телисең.

— Араларына керәсем, димим ич, күрәсем генә килә.

— Очраклы күрешүләр була, анысын аңлыйм мин. Ну бит син махсус эзләп килгәнсең, астыртын өмет белән. Яшьлек — ул, Фазыл, альбомнарда кала торган фото гына. Тимә, якын килмә син Әлфинәгә. Давай, иртәгә торабыз да иртәнге автобус белән Казанга китәбез.

Ут сүндереп, мендәргә чумып, бер-берсеннән төнге караңгылык белән ерагайсалар да, уйлар һаман ике арада йөрде.

— Фазыл, ниме, синең башка туганнарың бармы?

— Апам... Караком чүлендә яши. Үзбәкнең алты баласын үстерә.

— Вәт, барып кайт янына. Сөендер апаңны. Үзеңә бер күңел юаткыч сәяхәт булыр...

Журналист йокыга киткәнче әйтеп калыйм әле дигәндәй, Фазыл үзенең үтенечен җиткерде:

— Син боларын яза күрмә, яме...

— Кайсыларын?

— Ну, диктофонга сыймаганнарын... Яме?!

Фазыл, кабат сорап, журналистны «Ярар!» дип әйтергә барыбер мәҗбүр итте.

## Бер көрешү – үзе йөз доллар

Автобус базарның капка төбендә кунган бугай — тәрәзәләре тыштан тирләгән. Кузгалырга бер сәгатьләп вакыт бар, шуңадырмы шофер ишекләрне ачмый, салонда утыргыч япмаларын төзәтә, канистра, чиләк ише калай савытларны шалтыратып урнаштыра. Руль артындагы панель өстенә беркетелгән тирән эчле сабын савытына кесәсеннән вак акчалар бушатты. Кыскасы, урамда бөкшәеп басып торган пассажирларны утыртырга ашыкмый, вакытны суза.

Кодрәтеннән килсә, журналист үзеннән калдырмас өчен Фазылны беләгеннән тотып торыр иде — бер адым читкә җибәрми, китеп басса — артыннан иярә.

Яңа сәүдәгәрләр сөйрәгән куларбаларның майланмаган көпчәк чыелдауларын, көнбагыш сатучыларны көтеп күкшегән чыпчык чыркылдауларын һәм эчтәге урамнан ара-тирә үтеп киткән җиңел машиналарның шыбырдавын исәпкә алмаганда, иртәнге тынлык инде бу. Кояш һаман Агыйдел үзәнендә, Актаныш басмалары буйлап өскә күтәрелмәгән. Тау битендәге «нахаллар бистәсе»нә бишәр катлы йортлар салып күчерелгән гаиләләр йоклый әле. Аста — Иске Актанышта истәлеккә калган әби-бабайлар эт өрдереп көтү куа. Сәяхәткә килердәй кунакларны көтеп, Мәликә чишмәсе өстендәге каенлыкта ялгыз былбыл өзгәләнә.

Ниһаять, Казанга барырга теләүчеләрне ишек ачып керттеләр. Журналист Фазылны тәрәзә кырына утыртты. Ул әле һаман да аның төшеп калу ихтималын онытмый, янына утырып, үзенчә чыгар юлын каплаган иде. Сәфәр мәшәкате белән иртәнге йокылары кимегән пассажирлар, йомшак утыргычларга арка терәгәч, автобус кузгалып киткәнче үк тынып калдылар. Журналист та тынычланып күзләрен йомды, йоклар өчен түгел, күршесен сынар өчен.

Ә күршесе Фазыл, автобус кузгалып киткәч, коточкыч зур югалтуга дучар булган адәмдәй, журналистның тезләре аша сикереп кенә чыкты да шофер янына килеп тукталырга кушты.

— Гафу итегез, гостиницада документларым онытылып калган, төшәргә кирәк, — диде ул, үз ялганына үзе ышанып.

— Көтәргәме?

Шоферның нияте изге иде. Монысы Фазылны тагын да ныграк каушатты.

— Юк, юк! Мин калам. Менә билетым, мәгез! — Һәм ул үгетләмәсеннәр тагын дигәндәй, кабаланып ишекне ачтырды.

Автобус, Казан юлына сеңеп, күздән югалгач, и сөенде Фазыл! Әйтерсең лә аңа Актаныштагы яшьлеге әйләнеп кайтты, әйтерсең лә аңа Әлфинәле хатирә белән тулган сөенечле язларны, өметле төннәрне, күрештерергә атлыгып торган юлларны бүләк иттеләр. Менә ул, ниһаять, Актаныш! Нинди генә сукмакка бассаң да, кая алып бара икән, дип баш ватасы юк. Монда бар да таныш... Шушы минутта гүя Җирнең тарту көче утыз тапкырга кимегәндәй булды — атлаганда очып-очып адымнарын зурайтты, гәүдәсе утыз тапкырга җиңеләйде, гомеренең утыз елы юкка чыкты.

Ул, басмаларны саный-саный, кояш янына төште. Көтүне куып чыгарганнан соң, авыл тагын тәрәз пәрдәләрен корган. Тын урамнарда абзар исе эленеп калган. Бәрәңге бакчалары киселгән җирдә Агыйдел өелеп тора. Иске Актаныш Чулман сусаклагычына корбан итеп калдырылды. Мондагы халык иртән уянган саен, идәнгә басканчы, карават астыннан дулкын эзли. Шөкер, берәүнең көчле кулы, бакча башындагы иске-москы киртәләр белән терәп, ул дәһшәтле дулкыннарны тотып тора бугай. Әйтергә кирәк, бүген-иртәгә батып үләбез дип, егерме ел буе көтә торгач, әби-бабайга әйләнгән абый-апалар инде Әҗәл белән туганлашты, коткарырга килгән Нух пәйгамбәр көймәсе кебек тау башында калыккан биек йортка күчәргә ашыкмый. Актаныш басмаларыннан менәргә аларның дәртләре дә, теләкләре дә юк. Балалары телефон керттерде, көн саен диярлек хәл белеп тау башыннан шылтыратып торалар.

Бар иде бу авылның гөрләп торган чаклары.

Министрлар Советы карары буенча, Актаныш белән Минзәлә кушылып, ике генә ел бергә яшәп карады. Фазыл килгәндә аларның аерылышып, мал бүлешкән еллары иде. Берара вәкаләтсез калган административ йортлар, оешмалар һәм конторлар, яңадан җанланып, үз эшенә керешкән. Яңа район үзәгенең йөз чакрымга ерагаюын өнәмәгән халык, ниһаять, яңадан сөенеп, йомышы булса да, булмаса да, Актанышка килә. Иртәнге алтыдан, дүрт урамны тутырып, машина-трактор гөрли. Ашханә, универмаг, райком, почта һәм «Үзәк» колхозы идарәсенә чаклы сузылган таш сукмактан кирәген эзләп көр халык йөренә. Чәчәкле-чуклы гөлләрен күрсәтер өчен урам ягындагы тәрәзәләр ачылган. Тузан кер дип борчыласы юк. Яңгырлы көндә ерак авыллардан машина көпчәгенә ияреп килгән үзле кара балчык, кояш чыккач, асфальт юл өстенә сумала булып ката... Әгәр вакыт-вакыт сукмакка сыймыйча, халык төркеме олы юлга чыкса — йә Казан белән Свердлаудан, йә Бөгелмә белән Минзәләдән самолет төшкән булыр. Портфель күтәргән, кызыл галстуклы яисә комсомол значоклы балаларның татарча җырлап кайтуы район үзәге дип аталган авылның көндәлек тормышына аһәң бирә. Кечкә таба ашханә тирәсендә мотоцикллар күбәя, Культура йорты ишегеннән репетиция авазы яңгырый. Кунак егетләр Идел буена тө-

шеп, сабан туеннан адашып калган кызларны эзли... Кулларына читән таягы тоткан әбиләр, Фридрих хәсис кулына эләкмәсен тагы дип, көтүдән аерылып калган кәҗәләрне чакыра...

Ә бүген Иске Актанышта су асты тынлыгы.

Атлый торгач, авылдан бер чакрымлап үтелгәндер, олы юлдан бүленеп чыккан көяз сукмак үзенә ымсындырды... Күр әле, Хәмит чишмәсен уенчык иткәннәр. Улак тирәли купшы утыргычлар куелган. Тау итәгеннән бәреп чыккан суның көче үрелеп эчәрдәй фонтан булып бөркелә. Фонтан, агымга әверелеп, бетон боҗраларны тутыргач кына, көяз сукмак читеннән йөгереп, Агыйделгә төшеп кача.

Фәлән чишмәнең тәме төгән чишмә суына охшаган, дип сөйләнгән кешеләргә ышанмагыз. Һәр чишмәнең үз тәме бар. Фазыл да әнә Хәмит чишмәсеннән үрелеп су эчте. Улак төбендәге яшькелт комташка карап, ул аны үзе бораулаган артезиан чишмәләр суы белән чагыштырып карады. Адай авылында эчкән су тәме дә бар кебек, Уразай чишмәсенә дә тартым, Әлфинәләр өй түрендәге коеныкына да охшаган... Ләкин Хәмит чишмәсенең тәме үзенә бер аерым, тешеңне сындырырлык салкын булса да, тамак төбенә зәйтүн мае кебек ягыла. Фазыл үзе бораулаган өч йөз коеның да суын хәтерли сыман. Йә Хода, ник шулкадәр хискә бай соң бу хәтер?! Үзең рәссам, үзең музыкант, үзең экиятче бит син, хәтер... Хәзинәңдә хатирәләр күбәйгән саен, үзеңнең үткәнеңне ныграк сагына башлыйсың һәм синең бүгенге белән киләчәккә карата омтылышың сүрелә, канатларың салына, өметең кими. Әнә шул хәтер тозагыннан котылыр өчен килде инде Фазыл Актанышка. Каенлык авылына барып ике сусауны тыясы бар: анда — Әлфинә, анда — иң беренче бораулаган чишмә...

Кояш әкренләп тау башына менеп бара. Көн бөркүләнде, Хәмит чишмәсенең суы тиргә чыгып бетте. Егерме чакрымлы араны җәяү үтәсе килү теләге сүрелде. Изүне чишеп, җиңнәрне сызганып атласаң да, юлда күләгә юк. Гадирәк машина очраса, кул күтәрергә иде исәбе. Ул арада, узып киткән кара «ауди», илле метрлап үтмәгәндер, кинәт әкренләп арткы тизлеккә күчте дә Фазыл турысына җитеп туктады. Машина унсигезенче регионнан иде. Тәрәзәләрнең арттагысын төшереп татарчалатып дәштеләр.

— Бу юл Чаллы трассасына алып чыгамы?

— Чыга, әгәр борылышларны бутамасагыз.

— Короче, кәгазьгә сызып аңлата аласыңмы?

— Богадыга чаклы утыртып барыгыз. Аннан сезгә ерак ара калмый.

Берәр минут үзара киңәшкәннән соң, алдагы ишекне ачтылар. Һәм Фазыл бу яктагы юлларны әйбәт белгәненә сабыйларча сөенеп, иномаркага кереп утырды. Шунысы сәер, алдагы рәттә буш урыннары була торып, өч егет арткы рәткә кысылышкан, өчесе дә кара күзлектән, лач-лач сагыз чәйниләр.

Кара тәрәзәләр ябылгач, машина эчендә кич җиткән кебек булды. Салкын һава өрә башлагач, Фазылның кәефе күтәрелде.

— Әгерҗедә бораулаганда Ижауга еш бара идек без, — диде ул, караңгы тынлыкны өнәмичә.

Ләкин беркем сүзгә кушылмады, унсигезенче регион егетләре Ижау дигән шәһәрне әйтерсең лә ишетмәделәр дә. Әллә җавап урынына инде — магнитоладан көчле музыка җибәрделәр. Юл өйрәткәндә Фазылга «уңга-сулга» диясе урынга бармак белән төртеп күрсәтергә туры килде.

Фазыл, Богады урамына кергәч, рәхмәтләр әйтешмичә генә төшеп калды. Һәм саубуллашу урынына:

— Шушы юл туп-туры трассага алып чыга, — диде.

Шофер егет, ярар дигәндәй, ияк чөйде һәм машинасын сүндермичә генә колонкадан салкын су алырга төште.

Кеше дигәнең рәхәткә бик тиз ияләшә. Егерме минут буе кондиционер җилендә утырып, салкынча һавага күнегелгән. Урамга чыккач, кояш, үч алгандай, сулыш юлларын көйдерде, бит тиресе чатнарга теләгәндәй тартылды, беләкләрне пешереп, кайнар җил сирпелде. Фазыл, капылт килгән уйдан рухланып, колонка янына ашыкты. Шофер егет пластик шешәгә тутырып салкын су эчә иде инде.

— Братан, зур йомыш бар иде, бушка түгел, түлим.

— Ну, — диде теге, эчелеп бетмәгән суны җиргә түгеп. Ул иптәшләре өчен яңадан тутырды. — Әйт шабашкаңны.

— Ике чакрымда гына бер авыл бар. Иномарка белән кайтып күренәсе иде шуларга.

— Озак торасыңмы?

— Исәнмесез, дип әйтәм дә китәм.

— Күпме түлисең, абзый?

— Мең сум...

— Ну, абзый, грунтовой юлдан, «Ауди» белән.

— Яхшы, өч мең бирәм. Башкасы юк, әле Казанга кайтырга кирәк...

— Йөз бакс, значит... Утыр әйдә, күрсәт авылыңны.

## Ике җиләк

Элек Богадыдан Каенлыкка күн итек кимичә үтмәле түгел иде, дамба күтәреп чуерташ сипкәннәр. Фазыл белән Мәдияр кайчандыр Әлфинә белән Нәсфияне озата кайткан сукмак калын балчык астында, эзләрне юл күмгән.

Ике авыл арасы шултиклем кыска, Фазыл хәтта Әлфинә белән күрешүне күз алдына китереп тә өлгермәде. Сораулар бер-бер артлы туа тора, җавапларын кем әйтер? «Утыз ел буе кайда йөрдең, ник моңарчы килмәдең, димәсме? Күрешү белән күздән яшь бәреп чыкса нишләргә — кызгандырыр өчен елаган атлы булыр. Чукынып йөрмә монда, зимагур, дип куып чыгарса?.. Ире, балалары өйдә булырмы?.. Әллә кире борылып китимме? Ник соң мин әйтер сүзләремне кәгазьгә язып ятлап куймадым икән?»

Дамба авылга кушылган җирдән ерак түгел су күтәргеч озын мичкә бастырганнар. Белгечләр телендә ул «Рожновский манарасы» дип йөртелә. Чиләк-көянтә белән килгән кыз-кыркынга су алырга җайлы булсын дип, улак рәвешен китереп, торба чыгарып калдырганнар. Өч кеше — әби, апа һәм мәктәп баласы чиратлашып су алып торалар иде, аларның иномаркага бик исләре китмәде, үз өйләрендә дә машинадан гарык иделәр бугай.

— Суы тәмлеме соң? — дигән булды Фазыл.

— Без гомер буе сазлы коедан ләм сөзеп яшәдек, — диде әби, — намаз саен догадан калдырмыйм шушы суны чыгарган кешеләрне, әйтәм ич, Ходай мәдәт-куәт бирсен, йөргән җирләрендә фәрештәләр канат җәйсен, бәхеттән аермасын үзләрен.

Фазылның авызы колагына җитте:

— Амин! Рәхмәт, әбекәй!

— Ут беткән чакта, сусыз утырабыз, — диде апа кеше.

— Безнең бүтән чишмәбез юк, шушыны мактап эчәбез инде, — диде мәктәп баласы.

Көянтәне иңнәренә элгәч тә, әби кеше артына борыла-борыла карады, кем өчендер рәхмәтләр әйтеп елмаеп торуларының серен аңларга теләде бугай. Ләкин Фазыл моны сизмәде. Чөнки ул, элеге мәктәп баласының йөзен күргәч, аның тавышын күңеленнән генә тагын бер кат яңгыраткач, өнсез калды.

— Син Әлфинә түгелдер ич?

— Әлфинә — минем әниемнең исеме, — диде кыз, үртәлеп, — ә минеке — Әлфия.

Кибеткә килгән саен: «Әнисенең кызы», — дип шаяртуларга күнегә алмады Әлфия. Сатучы кызы булма икән ул — аны бөтен кеше белә, таный, исеме белән дәшә. Җитмәсә, бу абзый водокачка төбендә ачу китереп торган була.

Әлфиянең бәхет эзләр чагы җиткән, быелгы җәйдә аның соңгы каникулы. Зур үсте инде ул — чиләкләре җирдән биек, әнисенең яшь чагындагы күлмәкләре ярый үзенә. Итәгенә ак челтәр йөгертелгән кыска җиңле, күпертмә иңсәле кызыл күлмәген Фазыл шундук танып алды. Аккан сулар кире кайтмый, диләр, менә бит — утыз ел элек югалткан яшьлек кире әйләнеп кайтты. Хәзер аңа иярсәң, Ниса кортканың нигезенә ак кирпечтән салынган «Мәхәббәт сарае»на килеп керерсең...

Тимер улакта су агышы туктагач, авыл өстенә ишелеп үскән каен урманы тынып калды. Корылыкка сөенеп черелдәгән һәр чикерткәнең, куләгәдә хыялланып яткан романтик бәбкәләрнең, каенлык яравында сөенешкән һәр кошның, тугай өстенә күтәрелеп сайраган һәр тургайның тавышы аермачык ишетелеп тора. Менә аларны кәккүк тавышы бүлдерде. «Кү-кү-кү-кук-кү...» дигән аңлаешсыз санау җәй уртасыннан ишетелә. Каен яравлыгына ияләшкән кәккүк сакауланган иде. Пыкрау бу — сайрар кошларның җыры беткән, ояларга сыймас балаларны ерак сәфәр алдыннан очарга өйрәтер көннәр җиткән... Җәй уртасының сагышлы якка авышкан чагы...

— Ну, нәрсә эшлибез, абзый, вакыт үтә бит?!

Шоферның ашыктыруына җавап итеп Фазыл тимер улактан шаулатып су агызды.

— Менә, братан, мин утыз ел элек бораулаган иң беренче чишмә бу! Шагыйрь әйткәндәй: үзем тапкан чишмәләрдән ятып су эчсәм — башка бер ни дә кирәкми!

Фазыл улакны тутырып аккан суга йөзе белән чумды, яңакларын тидереп иркәләнде, агым эчендә күзләрен ачып карады, тончыга-тончыга йотлыгып эчте, тагын яңакларын тидерде. Шоферның йөрәге түзмәде, ул да кысрыклап улакка үрелде, Фазыл ни кыланган булса — шуны кабатлады. Суның җан ияләрен үзенә тарта торган магниты бар. Нормальный ике кешенең, чүмечтә су коенырга теләгән ата каз шикелле улак эчендә быкырдавы, машинада калган өч егетне дә битараф калдырмады.

— Мужики! Вы че, в натуре?! — дип, җиргә төшүләре булды, шофер егет аларга кушучлап су сибә башлады, барыбер улакта коенырга, бит-кулларын юарга мәҗбүр итте. Җәйге челләдә чишмә суы салкынын бернинди кондиционерлар да алыштыра алмый шул. Егетләр көрәйде, тавышлары ачылды, алай гына да түгел, су чәчрәгән кара күзлекләрен салгач, баягы братаннар яңадан гади авыл малайларына кайтып калдылар.

Шофер егет машинадан чәчәкле йөнтәс сөлге алып килде һәм башта Фазылга бирде.

— Авылны сухой законга калдырабыз, — диде ул, суны туктатып.

— Әрәм-шәрәм итмәү кирәк анысы, но бу авыл диңгез өстендә утыра, кырык метр тирәнлектә генә, искиткеч калын су горизонты...

— Во, мужик — крупнейший специалист, ә? Син может безнең кешеләргә дә су скважинасы бораулап бирерсең, — диде шофер. Ул, үзе рульдә утырса да, әлеге өч малай алдында җаваплырак иде бугай.

— Менә минем визиткам, сиңа бер айлык заказ бар. — Һәм Фазыл адреслы телефоннарны укыган арада өстәп куйды. — Ә сто баксов миндә кала, задаток өчен.

— Ярар, заказ булса, безнең регионнар арасында чикләр юк, Чаллы юлында сөйләшеп бетерербез. Ә хәзер әнә теге кыз кереп киткән өй янына барып туктыйк.

Әлфинәләрнең өе дүрт почмаклы гына иде, зурайтыр өчен арткы өлештә таштан коеп нигез күтәртелгән. Ишегалды иркен, өч торыклы абзар бәрәңге бакчасына кертеп салынган. Лапас түбәсендә әле генә чабылган печән күпереп ята.

Машина көтмәгәннәрдер, өй түрләренә килеп туктагач, урам ягына караган өч тәрәзәнең берсендә дә шәүлә чалынмады.

Ә күке, сакаулыгын танырга теләмичә, һаман санарга маташа.

Җил капкадан керүгә Фазыл үзен сәхнәгә чыгып баскан артист кебегрәк хис итте, аңа бу рольне ахырынача уйнап чыгарга кирәк иде.

— Әлфинә апа! Әлфинә апа!

Кычкырмады ул, ишегалдыннан чебен-черки кермәсен өчен корып куелган марлялы ачык тәрәзәгә якын килеп дәште генә.

— Кем бар анда?! — дигән тавыш урам ишегенең бусагасына чыгып басты. Исе китми генә, колачын җәеп, ишек яңагына таянды. Каршында кем торганлыгын шундук төшенеп, боегып калды.

«Әһә, яшьлек миннән имтихан алырга килгән...» — Әлфинәнең беренче уе әнә шул булды.

«Өенә чакырырмы? Әллә танымаганга сабышырмы?» — Фазыл уйлары ишетелмәсен өчен иреннәрен кысты.

«Әллә, өйләнмичә, шушы гомер мине көтте микән? Язиләсе куып чыгаргандыр әле, аптыраганнан гына искә төшергәндер...»

«Беткән баш беткән! Каравыл кычкыртып кочаклап алам хәзер».

«Үземнең дә сине эзләп китәрдәй чакларым күп булды, Фазыл!»

«Чегән хатыны юраган сүзләр сакау күке тавышында: баламны кеше үстерде, акча күп эшлим — үзем баемадым, егерме яшь тулганда, миңа дигән хатын туар — димәк, ул Әлфинә түгел... Яңадан бәхет эзләр өчен озын гомер кирәк... Яшьлегемнең ишек төбендә сакау күке булып басып торам, хәтта күрешкәч сөеклем белән сөйләшерлек тә хокукым юк...»

«Машиналарына чыгып утырсам, кая чаклы алып китәр иде икән?»

«Менә бит инде ул — утыз ел буе тынычлап яшәргә ирек бирмәгән Әлфинә! Ник соң сине алып китеп булмый?»

Әнисенең авызына су капкандай телсез басып торуын күпсендеме, Әлфия йөгереп чыкты. Печәнгә барган җирдән чеме белән җир җиләге җыйганнар икән. Әлфинәне биленнән кочаклап, ул бусагадан төшмичә генә, җиләкле кулы белән ишек яңагына таянды. Читтән карап торган кеше әлеге күренешне, ике балалы тигез гаилә учагын саклап калу өчен, амбразура каплау дияр иде.

— Инәкәй, нәрсә кирәк боларга? Әле бая гынак улактан су эчеп калганнарые.

— Үзләреннән сора, кызым.

— Алып куйган коньягыгыз юкмы? — диде Фазыл, баласы алдында әнисенең хәлен җиңеләйтергә теләп.

— Безнең авыл халкы аракы гына эчә, шуңа күрә инәкәй коньяк алып кайтмый, әйеме, инәкәй?..

Әлфия әлеге текә егетләрне үзе артыннан ияреп килгәннәр дип уйлады, шуңа күрә кылтаеп сөйләшүе иде.

— Әйе, юк бездә коньяк. Тотмыйбыз...

— Актаныш универсамында бар. — Һәм кыз иреннәре белән үрелеп кенә кулындагы җиләк бәйләменнән берне өзеп капты.

Артык җәелеп, буш сүз уйнату — һәр мизгеле кеше язмышына торырлык минутлар белән шаяру булыр иде. Уйлар кисешкән җирдә вакыт үлчәме югала икән. Фазыл, ике күзгедән бер сурәтне эзләгән кебек, әле уңга, әле сулга күз ташлады... Эре җиләк — үсә торыр, кечкенәсе — пешә торыр... Кайсыгыз Әлфинә, кайсыгыз Әлфия соң сезнең? Югалган елларның кай ягында басып торасыз? Алар үзара сөйләшкәндә, тавышлары бер чордан икенче чорга күчә. Әлфиядә унҗиде яшьлек Әлфинәнең яңгыравык тавышы; Әлфинәдә ул тавыш бераз басынкы, моңлы, бишек җырыдай ягымлырак. Әлфия әнисенең яшьлеген кабатларга тырышыпмы — соргылт чәчләрен иңбашына төшереп кистергән һәм сандык төбендә утыз ел буе сакланган күлмәкне кигән. Әлфинә исә, кызына яшьтәш булырга теләгәндәй, маңгай чәчен тигезләп алга тараган, тез башына тияр-тимәс чия кызыл сарафан өстеннән юка кара жилет кигән. Әлфиянең иреннәрендә сытылган җиләкләре — Әлфинәнең юка иреннәренә орынып үткән иннек төсендә... Менә шушы инде ул мәхәббәтнең мәңгелеге!

«Нишләдегез инде анда?!» — дип, әтиләренең чыгуына: «Коньяк сорап килгәннәр!» — дип, Әлфинәнең күздән югалуы булды.

Әгәр шушы минутта Әлфинә: «Мәктәп елларымда сөешеп йөргән егетем эзләп тапкан...» — дип сөенсә, йә булмаса, Фазыл: «Мин Әлфинәдән башка яши алмыйм!» — дип, хискә бирелеп ялгыш әйтеп ыргытсамы — бер кеше бәхете өчен дүрт кеше бәхете шундук чәлпәрәмә киләсе иде. Мәхәббәт ул табигатьнең үзе кебек көтелмәгән хәвефле афәтләрдән тора. Уйламаган җирдән зилзиләләр кубып, гомер буена тапкан-табынганыңны туздырып, йортсыз-җирсез калдырырга, балаларыңнан, таянычыңнан мәхрүм итәргә мөмкин. Гадәттә, ул афәт гаилә башына бер минутлык ләззәт сыйфатында, яисә гафу ителмәслек сүз рәвешендә килеп керә. Табигать стихиясеннән үзгә буларак, гаилә башына килгән гарасатны туктатып калырга мөмкин.

— Коньяк кирәксә, Байсар кибетенә сугылып карагыз! — Һәм әти кеше, тамашаны таратыгыз дигәндәй, Казан юлына таба күрсәтте.

Бар да бетте. Фазыл тагын ачы хакыйкать белән бергә-бер калды. Елларны күчереп, фасылларны бутап, сәгатьләрне алыштырып бары тик җәзалар өчен генә килеп киткән ләззәтле күрешү йөрәккә тагын җәрәхәт өстәп югалды. Әтиләре белән кабат күзгә-күз очрашмагаем дип, борылып карамаган иде Фазыл, караса яраган икән — ике тәрәзәдән ике Әлфинә аңа кул болгап калганнар иде...

## Мин риза

Нигезенә чаклы янып төшкән туган йорт урынында түбә корырга күңеле бармады Фазылның. Аңа Яңа планнан чирәмле урын тәкъдим иттеләр. Хуҗалык җитәкчесе яшьтәш егет булып чыкты, ун ел буе күрше классларда янәшә укыганнар иде. Су эшләре буенча универсаль белгечнең күз алдында йөрүенә сөенде генә ул. Яңа урын үсә торган урамның читеннән әлэкте, уң якка билгесез күршеләр киләчәк икән.

— Сул ягымда кем? Нигезен таштан коя, коттедж салдырта, ахрысы?

— Әнә үзе килә, сорарсың, — диде җитәкче. — Пенсиягә чыкканына унбиш ел үтте, әле һаман председатель булып сөйләшә. Ичмасам, миңа үч итеп идарәгә сайлап куялар, утырыш саен аягүрә басып: «Элек болай иде, элек тегеләй иде», — дип, мозгамны эшерә инде. Әйтерсең лә СССРны мин тараткан... Ярар, вак-төяк сорауларың булса, мин конторда көтәм. Ә моның белән бик күрешәсем килеп тормый. Президентлыкка сайланырга теләгән иде әле ул. Юаш Нотфулласы белән бөтен районны бетереп имза җыеп йөрделәр... Кандидатурасын теркәмәгәннәр — яшен күпсенгәннәр... Инде кеше күзеннән гарык дип, Яңа планга качты.

Әйе, яшь алмагачларга тлә агуы сипкән җирдән эшен ташлап, кулларын юеш чүпрәккә сөртә-сөртә килүче кеше Сакал Шәйхи иде... Киптергәннәр абзыйны — элеккеге пәһлеванлыгы коелып беткән. Пеләше белән тоташкангамы — маңгае шыксыз киң булып күренә. Бер ягыннан терәве төшкән — авышыбрак атлый. Ул, колактан колакка гына сөйләшергә теләгәндәй, якын ук килеп басты. Туры караса, үтеңне сытарлык күзләре генә элеккечә.

Шәйхи, бөтен яшьлеген берьюлы исенә төшергән хыялый кебек, бер мәлгә иңрәп торды да Фазылны кочаклап алды.

— Нихәл, күрше, күптән күренгәнең юк, агайне... Теге кая ашыга? — диде ул, «Нива»га утырып киткән рәискә таба күрсәтеп. — Деловойланып кыланган була, үзенең кассасында сукыр бер тиен кереме юк. Елына өчәр миллион табыш китерә торган хуҗалыкны бомж хәленә төшерделәр. Үләт базын хайван белән тутырдылар, үстергән икмәкләрен сатып алучы юк, сыер савучылар колхоз сөтен урлап май язалар — өендә кәҗәдән гайре савымлыгы булмаган Һәдия әби колхоз базарында каймак сатып ята, пнимаете так...

— Шәйхетдин абзый, безнең авылда гына түгел, бөтен сферада шул хәл.

— Мин председатель булып эшләгән чорда алай түгел иде.

— Элекме?! Докладларыгызда мактанган саннарны әле дә хәтерлим... Колхоз миллионер чакта мең морҗалы авылыбызда җиде телевизор, ике мотоцикл, бер «Москвич» бар иде — анысы да отышка чыккан машина... Ә бүген — капка төбе саен машина, бүлмә саен телевизор. Байлык шәхси кулга күчте...

— Ну бу бардакны кемдер туктатырга тиештер ич инде, пнимаете так?

— Үзе туктый ул. Җитмеш ел буе партиядән куркып эшләгән халык ирекккә чыкты. Ял итеп арыгач, эшләрләр әле.

— Җимерелеп беткәчме?

— Әйе. Иске урында яңаны төзер өчен иң әүвәл җимерергә кирәк. Менә сезнең белән безгә Яңа планнан урын бирделәр — җимерәсе юк, — дип, Фазыл сүзне икенчегә бормакчы булды.

— Укыдым, газетага интервью биргәнсең, пнимаете так. Үзең язмагансыңдыр инде?

— Юк, бер журналист белән Актаныш гостиницасында сөйләшеп утырган идек. Язганын беренче сездән ишетәм.

— Яңадан укы әле син аны. Анда теге су скважиналары өчен проектлар эшли торган оешма, ничек әле... «Татводпроект»ның генераль директоры өстәмә фикер белән чыккан... Шәп әйткән, слушай. Ка-

занның ике ягында — Столбище белән Урман арты бистәсендә искиткеч көчле су катламнары бар икән.

— Һәм, төче су, дигәндер...

— Әйе, пнимаете так, әгәр хөкүмәт акча бирсә, Казанны йомшак су белән тәэмин итәрлек коелар бораулыйбыз, дигән, торбалар буенча китерергә. Аннан соң бөтен Казан халкы чишмә суы гына эчеп ятачак икән.

— Гомердә тормышка ашмаячак ул хыял.

— Нишләп алай дисең, Фазыл, пнимаете так?..

— Беренчедән, Идел суын эчерергә өйрәнгән «Водоканал» каршы чыгачак. Икенчедән, шәһәр халкы сихәтле су күрсен өчен акча бирергә тиешле кешеләр үзләре күптән инде чишмә суы гына эчә, ташпулатларына, бакчаларына да хәтта икешәр кое бораулаталар. Һәм, өченчедән, Шәйхи абзый... бер көрәшүдә үк бөтен проблемаларны илаһи уптым сөйләшеп бетермик, минем китәсе бар.

— Да-да! Пнимаете так, ну син бит инде яңа нигезеңдә эшне кое бораулаудан башларсың?

— Туры килер, ахрысы.

— Мине дә онытма, яме! Полиэтилен торбалар әзерләп куям. Сезне үстергәндә, әниегезгә бик нык ярдәм иттем мин. Утырган казыгыз иске өегезнең мүк арасыннан башын тыгып кычкыра торган иде. Динәгә процентсыз ссуда бирдек.

— Әни шул ссудага колхоздан бура сатып алды — аскы эргәләре каеннан, калган өлеше усак белән юкәдән. Бүрәнәләре куышланып, өйне кырмыска басты... Ну, озак яшәмәдек, ссудагызны түләр өчен әни өйне сатарга мәҗбүр булды...

— Иске өйләр күп иде. Урманны санап кына бирделәр.

— Аның каравы Сәрвиназ апага шыңгырдап торган нараттан бушлайга алты почмаклы өй салып бирдең.

— Бер кулда бармаклар да тигез түгел, Фазыл агайне.

— Ярар, Шәйхи абзый, мин үпкә саклап түгел, сүз уңае гына телдән ычкынды. Әйбәт күршеләр булырбыз без...

Ул арада Фазылның куенында кесә телефоны уйнады. Наил Кадыйрович шылтырата: яңа байлардан заказлар күбәйгән, бригаданы җыярга куша. Тавышы аермачык ишетелгәч, сөенеп куйды әле Фазыл, Казан белән элемтә әйбәт, димәк, монда яшәргә була! Кирпеч кайтартырга кирәк.

Фазыл тукталышка җәяү төшәргә булды, авылдашлар танып сөйләштереп, вакытны алмасыннар дигәндәй, ул юл белән янәшә салынган сукмактан атлады. Шәле тукталышын базар мәйданы иткәннәр. Кафе, ашханә, бистро, сәүдә киосклары тезелешеп, ерак сәфәргә чыккан шоферларны, пассажирларны тәүлек буе көтә. Төн узганчы куна калучы машиналар өчен киң мәйдан җәйгәннәр, ләкин ул мазутка лыкырдаган. Инештән су алып килеп кабиналарны юа торгач, аяк асты июль чилләсендә дә кипми. Фазыллар ландыш җыярга төшә торган урман тоташ бәдрәфкә әверелгән. Фу!..

Бораулаучыларның төшке ашка туктый торган чагы лабаса бу...

Фазыл бистрога кереп, берәр таяк шашлык алып, Шәйхи белән көрәшү тәэсиреннән калган юшкынны юып төшерергә ниятләгән иде.

Маҗаралар күбәйде. Бала чакта, яшьлектә күргәннәр, аралашкан-яшәлгәннәр, югалганнар-сагындырганнар, сөенечле һәм көенечле маҗарага күчеп, яңадан әйләнеп кайта тора. Ауга чыккан мәргән кебек гел эзләнеп йөргәнгә шулай микән? Әнә икмәк сата торган киоск белән янәшәдә Фазылның теге яшел вагоны. Ачык тәрәзә астына буйдан-буйга «Китаплар» дип татарчалатып, зур итеп язып куйганнар. Баскыч төбендәге өстәл өстенә елкылдап торган китаплар җәелгән. Кояш астында калҗайган юка тышлыкларын юл җиле уйната. Ә өстәл артында, кайчандыр Әмир, Суфия, Язилә, Мәдияр һәм, әлбәттә, Фазылның үзеннән калган тимер аяклы табуреткада Гөлсөяр китап укып утыра иде. Ул шундый мавыгып һәм ышанып укый, хәтта яңа гына килеп туктаган «Газель» йөртүчесенең ашханәгә барган җиреннән онытылып, баласына китап сайлаганын да сизми. Фазылны да сизмәде.

— Миңа мәхәббәт турында берәр китап кирәгие...

Егетнең тавышы укый торган әсәрдән яңгырады дип уйладымы, Гөлсөяр кинәт кенә кулындагы китабының тышына күз салды. Шунда гына ул, янында кем торганын аңлап, табуреткадан күтәрелде. Кыска итәген китаплы өстәл генә каплап торган икән. Сул кулы ак блузканың төймәләрен санап чыкты, уң кулы итәген төзәткәләде. Үзен күпме генә тыныч тотарга тырышмасын — барыбер сөенечен яшерә алмады.

— Хәтерсез кешеләрнең йөрәге тазадыр ул, әйеме, Фазыл? Уйламый, эзләми, сагына белми, тик яши шунда...

— Мин бу вагонны теләсә кайсы базарда күрсәм күрермен, тик менә шушында очратырмын дип һич уйламадым.

— Үзең калдырып киткән җирдән эзләрләр аны. Айдан артык вакыт үтте ич инде... Нихәл соң син?! Сызлауларың басылдымы?..

— Рәхмәт сиңа, Гөлсөяр, аякка бастырганың өчен рәхмәт! — Һәм Фазыл, тизрәк акланырга теләгәндәй, тезеп китте. — Бораулау агрегатын җыйнап, көйләп, бригаданы яңадан туплаганчы шактый үтте шул. Аннан соң эш күрсәтеп карадык.

— Алайса, Әлфинәңне барып күрергә җае килмәде әле.

— Бардым. Күрдем.

— Гел сине көтеп яшәгәнме?

— Каенлыкның күкеләре сакауланган инде...

— Әйбәт булган, дисәм, үпкәләрсең микән?

— Аның каравы күңел тыныч хәзер. Күңел тыныч, киләчәгем — ачык.

— Ә бүген авылыңа Хәмдияңне эзләп кайттыңмы? Рәхәт яшисең син... Яшь чакта сөйгән кызларыңа кунакка йөрисең.

— Сине эзләп кайттым.

— Ышандылар ди. Менә синең бу китапны күргәнең юктыр әле. Сезнең авыл турында ул. Марат Мөлеков язган. Ишеткәнең бармы шундый кешене? Тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, ТИҮ президенты, депутат булган.

— Беләм, беләм, мин укырга кергәндә, ул безнең мәктәп директоры иде.

— Әйбәт булган! Китапта әйтелгәнчә, Харис Якупов дигән зур рәссам сезнең авыл кешеләре турында тулы бер альбом иҗат иткән.

— Хәтерлим мин аны. Рәсемнәрендә безнең иске өй бар.

— Әйбәт булган! Вәт, альбомны ул «Көчле кешеләр» дип атый... Ә көчле кешеләр хәйләкәр булмый, Фазыл, инде әйт, туган авылыма болай гына, сагынып кайттым, диген.

— Сугышсыз-нисез генә егерме сутыйлы дәүләт яулап алдым. Мин анда патша сарае салам, җәннәт бакчасы үстерәм. Һәм син алмагач күләгәсендә китап укып утырырсың... Әйдә, су коенырга киттек. Көн озын әле. Казанга кичкырын китәрмен.

Фазыл Гөлсөяргә кире уйларлык чара калдырмады, өстәлдәге китапларны күчкә өеп, вагонга ташый башлады.

Китап сәүдәсенең үз өстенлекләре бар. Менә хәзер Гөлсөяр вагонны бикли дә китеп бара. Сатучысы кая моның, дип, ник берәрсе тавыш чыгарсын... «Кибет басу» дигән афәт тә китап кибетенә кагылмый. Янап, акча дәгъвалап йөрүче текә малайлар синең яннан көлеп кенә үтеп китә. Салым инспекциясе ташламалар бүләк итә. Дөрес, әлеге урында бер тапкыр, Гөлсөярнең китап әрҗәләрен тикшереп, вагонны актарып чыктылар, икътисади җинаятьләр бүлегеннән килгән ике егет суррогат аракы эзләп йөргәннәр. Гафу үтенделәр... Кайвакыт мотоциклга төялеп, тукталыштагы сәүдә мәйданына авыл малайлары килә. Алар инде Гөлсөярне танып белә, шуңа күрә бистрога кергәнче, китап өстәле кырында телләренә салынып торалар.

«Их, менә бу китапны укысаң иде...»

«Чө! Акчаң җитсә, укы!»

«Урлыйк без аны, өчәүләшеп укырбыз».

Малайларның кем турында сөйләнгәнен чамалый Гөлсөяр, ләкин аңламаганга сабыша. Курыкмый ул алардан, котылыр өчен бер эндәшү җитә үзләренә.

«Ягез әле, егетләр, сөйгән кызларыгызга бүләккә берәр китап алып җибәрегез!»

Һәм матайлылардан җилләр исә.

Болынлап бүлеп бирелмәгәч, халык каян туры килсә, шуннан печән ташый, печән өсте икешәр айга сузыла. Мишә буенда су коенып ятучылар бар икән — алар авылныкылар түгел, кунакка кайтучылар булыр.

Яр буйлап, агымга каршы атлый торгач, су коенучылар, балык тотучылар күздән югалды. Сайрар кошлар туктагач, чикерткәләр хуҗа булып калган — чабылган болынлыклар сызгырып тора. Гөлсөяр, биек үкчәле туфлиен кулына тотып, яланаяк атлады, чабылган камыл, тояк чокырлары, чалгы урап узган шайтан таяклары тиз барырга ирек бирми, Фазыл, кулындагы әбәтле пакетны куеп торып, аны күтәп-күтеп ала... Мишә борылышындагы ярыматауга килеп җиткәч, Фазылга әллә нәрсә булды: гөлҗимеш куакларыннан өлгермәгән гөләп өзеп капты, шомырт агачына үрмәләп яшел тәлгәш алып төште, сөзәк ярдан аска таба мәтәлчек атынып кабырчыклы комда аунады, сандалиларын ике якка ыргытып, маймычлары өерелеп йөзгән су читләтеп йөгерде... Аннан соң, яр өстенә менеп, шомырт куаклары белән кысрыкланган аланга чыкты.

— Менә монда «пионер бүлмәсе» өчен зур палатка тора иде. Бу җирдә әләм колгасы, вожатыйлар чатыры... Ашханә өстәлләре — мин басып торган җирдә, — диде Фазыл, пакеттагы ризыкларны ашъяулык өстенә җәеп. — Беләсеңме, Гөлсөяр, иртәнге йокыдан безне нәрсә уята иде?

— Пионер быргысы!

— Аппетит уята!.. Ә быргы кычкыртканда без инде ашханәдә шкаф актара идек. Көне буе һавада, кырда эшлибез, су коенабыз, үсә торган чак — ашау төткәрер хәл юк... Шуннан калгандыр инде, ач карынга хыяллана да алмыйм.

— Аңлашылды. Ләкин шәрабны су коенып чыккач эчәрбез.

— Сал халатыңны, кызынып кал. Тагын берәр сәгатьтән черкиләр котыра башлый, алар монда шундый усал... Пионер лагерьлары беткәннән бирле кан эчәргә кеше таба алмыйлар...

Гөлсөяр судан курыкмый, Чаллыда җае чыккан саен сәүдәгәр кызлар белән җыелып, «Нарат» шифаханәсенең Чулман ярындагы комлыгына коенырга йөрделәр. Кирәксә, дулкыннарны колачлап сәгатьләр буе йөзә ала. Ләкин Фазыл белән коенганда, ул ярышып йөзәргә теләмәде. Шомыртлы текә ярлар арасына юл салган Мишә елгасының агымы тымызык, дулкыннары вак булгангамы — ниндидер шомлылыгы бар сыман. Ул әле Гөлсөяр өчен яңа елга, төсе томанлы зәңгәр, төбе чоңгыллы, ярлары — аулак... Ләкин суның җылылыгы, йомшаклыгы, чисталыгы һәм Фазылның юк-бар хәрәкәт ясап, тәнгә орынып сәбәп уйлап табуы, әлеге шомны әкренләп оныттырды.

Фазыл сөенә-сөенә йөзә. Чумып беркавым югалып тора да Гөлсөярнең аяк арасыннан килеп чыга, кулларын чәпердәткән атлы кыланып кызның ботларына кагылып үтә, бергәләшеп йөзәргә теләгәндәй, билләреннән кочаклый, муенына, иягенә сөлек булып ябышырга тели, иреннәренә орына. Гөлсөяр карышмый, чәрелдәп кычкырмый, киресенчә, Мишә гипнозына бирелеп, һәр кыланышка теләктәшлек кылып, очрашу уенына иярә. Ул монда үз иреге белән килде. Су өстендә көрешү кагыйдәләрен алдан ук сизенеп, белә торып, ризалашып, көтеп һәм эзләп килде. Ул, сыену-назлануларны тыймыйча, һаман саен Фазылны газаплап, моңарчы эзләп тапмаганы өчен җәзаларга тели... Ләкин бу җәза уеннан узды. Гөлсөяр үзе дә иләсләнде, карышу көче кимегәннән-кими барды, Мишә суы әкренләп кайнарлана төсле тоелды аңа. Һәм ул, кабаланып йөзеп килгән уңайдан, комлы ярга чыкты. Бу ләззәттән качып котылырга теләп, йөгерергә иде исәбе. Ләкин Фазыл аның аякларына тышау булып уралды. Кыз егет өстенә ауды. Назланып орынулар көрәшкә әверелде. Куллар гына түгел — сүзләр дә көрәште.

«Кинәндең минем белән бүген, дәшмәгән саен...»

«Гөлсөяр, бу хәтле ялынуга шомырт агачлары авышыр иде инде...»

«Агачларны давыл гына ега».

«Мин сине монда белеп алып килдем. Яңадан яши башлыйм. Син миңа кирәк...»

«Шатлыкның ялганы күп була. Ышанмыйм».

«Без бүген кавышырга тиеш».

«Болай түгел бит инде!»

Сүзләр көрәшкән арада, Гөлсөяр тәнендәге су коену әсбапларының элмәкләре сүтелеп беткән иде инде. Бу хәл кызны бөтенләй каушатты.

«Кавышу түгел, көчләү бит бу!»

Һәм Гөлсөяр, ике кулы белән юеш ком актарып алып, үзенең битләренә сөртте, тагын алып күкрәгенә сылады, иреннәренә якты. Ике арада саз исе таралды, комлы чырайда ике күз генә нәфрәтләнеп калды... Фазылның гайрәте сүнде, куллары хәлсезләнде, гәүдәсе дерелдәде.

Алар көрәш барышында актарылып беткән ком өстендә ярты сәгатьләп чалкан яттылар. Каршы ярдан күзәтеп тормагайлары дип, кыз низаглы әгъзасына кайнар ком сыпырып өйде. Аннан соң алар яңадан парлашып су керделәр. Ләкин бу коену түгел — юыну иде инде. Фазыл киемсез калган Гөлсөярне үз куллары белән юды. Ике арада гамәлгә сыймаслык берни дә булмады кебек, шулай да кызның саф күңеле уяулыгын югалтты, егет кодрәтеннән әсирләнде, буйсынырга теләде. Җиңелмичә җиңдерде...

Фазыл озаклап юар өчен куш учына суны әз-әзләп алды. Мишә исеменә сыенып, никадәр чишмә килеп туктаган бу ярыматауга. Һәр чишмә кулга үзе керә. Мине Гөлсөярнең муенына сип, мине — иңбашына, билен коендыр, күкрәгенә чәчрәт, кендеген үзем юам, дип, кулга кергән берсе юмалап тора. Кыз балага су күбрәк кирәк бу дөньяда... Ул самавыр куя, аш пешерә, бала коендыра, кер юа... Чишмәләр кызлар өчен кирәк...

Кайтыр юлда, үпкәләшмәгәнне раслау өченме, әллә ком өстендә кабынган утны сүндермичә саклар өченгәме, алар туктап-туктап үбештеләр. Үбешкәннән соң Фазыл аны куеныннан чыгармыйча торды, кызның муеныннан тәмле конфет исе килә иде. Кыз егетне култыклап барды. Аяк астында каты камыл туры килсә, кулына асылынып калды.

Вагонга кайтып кергәч, нишләргә белми аптыраган Фазыл китаплар актара башлады. Әле берсен, әле икенчесен укып карады, тагын эзләнде. Әйтерсең лә кайсыдыр ки нәсыйхәтле китапка иртәгесе көн өчен кирәкле киңәш язылган булырга тиеш иде.

— Сүтеп җыйдың син мине, Фазыл.

— Югалган көмеш алтынга әверелә, мине югалтма.

— Бүген синең тавыш белән йорт иясе дәште.

— Вагонның йорт иясе юк. Өй салып чыгарбыз.

— Ярат кына син мине, Фазыл. Артыгын сорамам.

Тагын көрәш башланды. Ләкин бу юлысы көч кулланып түгел. Иреннәр, күзләр, иякләр, куллар үзара сүз куешып, Гөлсөяргә ләззәт һөҗүме оештырды. Мондый һөҗүм мускул көченнән күпкә көчлерәк иде. Кыз барыбер нык торды. Салкын һава эзләп еш-еш сулады, егет кулы ни эшләсә — шуны кабатлады, күзләреннән яшь чыгарып ыңгырашты. Мәгәр аягыннан егылмады.

— Йә Ходa! Каян килә соң сиңа шушының чаклы карышу көче?! Әйдә, алайса, үзең көчлә мине, Гөлсөяр! Без бүген кавышырга тиеш. Ишетәсеңме, бүген! Юк икән, бүтән беркайчан да...

— Юк. Әйе. Ну мин болай кавышуны теләмим. Кешечә гариза бирик. Үзәк загска барып. Минем бик күпләргә күренәсем килә.

— Зурдан кубып никах тантанасы кичәргә оялам. Минем бәхетем өчен генә саклангансың икән — исбат ит бүген. Иртәгә үк авылга менеп язылышабыз.

— Юк! Болай түгел... Китаптагыча кирәк...

— Димәк, ялганың бар. Куркасың.

— Ирештермә, үртәмә! Юк дигәч юк!

Гөлсөяр Фазылны ачу белән этеп җибәрде.

— Безгә бүген бер түбә астында калырга ярамый.

— Мин беркая да китмим. Иртәгә шылтыратам. Текә Вәли килеп алыр әле.

— Алайса, мин китәм. Китаплар калсын, укып чыккач, китапханәгә тапшырырсың.

— Озатып куям.

— Юк! Мә, вагон ачкычыңны ал.

— Шуны бел, Гөлсөяр, син миңа бик кирәк...

Җиңелчә сумкасын иңенә асып, зурысын беләгенә элеп, чыгып китте Гөлсөяр. Вагон эче кинәт ятимләнеп калды. Никтер сабыйларча үксеп-үксеп елыйсы килде Фазылның, тик күз яшьләре чыкмады — Мишә суында юылып беткән иде, ахрысы. Иртәгә дигән киләчәкнең мәгънәсе калмады. Көне буе июль кояшында кызган вагон эчендә тәмуг уты йөри. Мордарлыкка илтә торган бушлык иде бу. Ләкин әле сакау күке саный алмаган еллар һәм чегән хатыны юравының рас килеп бетмәгән шартлары бар. Шуларны күрер өчен булса да яшәргә дә яшәргә!

Юл читендәге заправка станциясенә авыл тракторы килеп туктаган иде. Солярка салган арада Фазыл хәлне аңлатып бирде. Тракторчы егет аны танымаса да, бу якларны белеп сөйләшүеннән авылдаш дип кабул итте. Бәхет эзләп арыганнар берәм-берәм кайтып егыла ич туган авылга, бу да шуларның берседер инде, диде. Яшел вагонны Яңа планга китереп, тагылмадан ычкындыргач, акча да алмады. Астагы урамда тора икән, кирәк чакта чакырырга кушты.

Сакал Шәйхи аңа дүрт бүкән бирде. Һәм Фазыл яшел вагонны шул бүкәннәргә утыртты. Ә салдырылган көпчәкләрен тракторчы егеткә биреп җибәрде — бөтенләйгә!

Төн уртасында, калай суынып, вагон эче яраулангач кына изелеп йокыга китте Фазыл. Ул таң әтәчләре кычкырганны да ишетмәде, Яңа план аркылы көтү киткәнне дә тоймады, йоклады да йоклады. Кояш түбәгә менеп кыздыра башлагач, ул Мишәгә су коенырга ашыгучы малай-шалайлар тавышына уянып китте. Тәрәзәдән караса, ни күрсен — икесе зур сумка бавын тоткан, дүртесе Гөлсөярне җитәкләгән. Вагон ишеген ачтырдылар, апаларын баскычтан этеп менгезделәр, сумканы калдырдылар да читкәрәк китеп бастылар. Ни белән бетәсен көтәләр, янәсе.

«Низам белән Шәмсия кавышты», — дип уйлап куйды Фазыл, сөенүен тыя алмыйча.

Гөлсөяр бу төнне кафеда эшләүче кызлар янында үткәрде. Каядыр китеп күздән югалырга исәбе юк иде аның. Пешекчеләргә артыгын сөйләп тормады ул — Гөлсөярнең хәлен азмы-күпме беләләр алар. Ләкин төнгә каршы чыгып качуын ошатмадылар, Фазыл абый кебек кешене бүтән таба алмыйсың түлке, диделәр. Иртән су коенырга барышлый, әниләре янына тәм-том эзләп кергән малайлар, Гөлсөярне Яңа планга чаклы озатып куйдылар.

— Мин риза... — диде Гөлсөяр һәм әле йокы җылысы суынып та өлгермәгән урын өстенә барып утырды.

Фазыл ишек ачып малайларга бер уч акча сипте:

— Миннән сезгә кияү бүләге тиеш!..

*2000–2002*

## Ак бүрек
*(Повесть)*

### Бауның бер очы

Үзең яшәгән шәһәргә бөркет канат җәярлек биеклектән карасаң — түбә дә түбә генә... Бөтен тормыш түбә күләгәсендә.

Шәһәрдә кышкы төн. Кереп яшеренергә ышык җир тапмагандай, анда-санда йөк машиналары урын эзли; буш калай савыт тәгәрәгән тавышлар чыгарып, соңгы трамвай-троллейбуслар чабыша; тәүлекнең егерме дүртенче сәгате килеп терәлгәч кенә, исләренә төшкән йомышлар белән, кешеләр йөренгәли.

Төн уртасы. Хәрәкәтнең иң аз чагы: тимер ишекләр бикле, рәшәткәле тәрәз пәрдәләре корулы, утлар сүнгән. Шәһәр тоташ зур күләгәгә әйләнгән дә йоклап ята, хәтта багана башындагы лампалар бәйләме дә, реклама утлары да ул күләгәне эретә алмый.

Урам буйлап Ансар килә. Җәяүлеләр сукмагыннан түгел, машиналар йөри торган ак сызыклы киң юлдан. Тыныч. Төннең шундый чагы бу — юлыңа кеше очраса, кая барышың, дип, юри генә сорап кара. Өйгә кайтышым, дип җавап бирерләр. Ә менә безнең Ансар дигәнебез, олы юлдан аерылып, таш коймалы урамга килеп керде. «Каракүл» берләшмәсенең икенче сменасы өйләренә кайтырга әзерләнә. Ансар бераз алданрак килде. Ул әле Венераның кайсы капкадан чыгасын тәгаен белми, телефон номеры гына бар. «Каракүл» берләшмәсе зур, аның бер тирәдә Венера кебек кызлар эшли торган фабрикалары гына да өчәү. Ансарга хәзер, таш койма буйлап атлап, каравылчылары, вахтерлары белән шыгрым тулы өч капканың берсенә барып чыгарга кирәк. Анда берләшмә фабрикаларына тоташкан телефоннан өч урынлы санны җыйнап шылтыратасың да — Венера кайсы капкада көтәргә кирәклеген үзе хәбәр итәчәк.

Таш койма кырыендагы баганаларда балкырга тиешле лампалар көзен үк яфраклар белән бергә коелып беткәннәр. Барлы-юклы ай яктысы да ялга чыгар көнен көтеп алҗыган мехчылар чырае төсле сүрән. Койманың яшел төсе танырлык түгел.

Яңа урамда, билгесез тыкрыкларда сизгерлек икеләтә арта икән... Һәр күләгәнең үз төлкесе була дигәндәй... Кинәт... Койманың икенче ягында кыштырдаган тавыш ишетелде һәм Ансардан ике-өч адым алгарак, канатлы еландай уйнаклап, бер бау очып төште, дөресрәге, җир белән күк арасында, үрелсәң, кул җитәрлек биеклектә эленеп калды. Ансарның йөрәге биш тибешне бер итеп дөпелдәп куйды. Әллә куркудан, әллә кызыксынудан — Ансар бау очын ике куллап тотып кисәк тарткан иде, аяк очына ярты капчык чамасындагы биштәр шапылдап килеп төште.

## Егетеңне шуннан эзлә...

Завод-фабрикаларда төнге сменада эшләүчеләр тирән йокыдан башкаларга караганда соңрак уяна ала. Тик Венера бүген, зәңгәр күзләрен зур итеп ачып, тизрәк таң атканны көтте. Йокы качты — төне буе кызга якын да килмәде. Карт кызлардан Ансар кебек сөйкемле егетләр генә түгел, төнге йокылар да кача микәнни?!

Кызларны сәер халык дип беләбез, алар үсмер чакта аймылышкан егетләрнең берәрсен гомер буе сагынып яшәр, аңа «тәүге мәхәббәтем» дигән яңгыравык исем кушар. Озын-озак төннәрдә, язмыш сайлап биргән хәләл җефете белән үпкәләшеп ачуланышкан сәгатьләрдә, хәтер яңартырлык минутларда «тәүге мәхәббәт»ләр искә төшкәч, күпме мендәрләр дымлана торгандыр: «И унҗиде яшьлек чагым, и тәүгем...»

Яшьлек дигәнең үтә дә китә икән. Ул син йоклаганда да, тукталышларда трамвай көткәндә дә, чәй эчеп телевизор карап утырганда, тулай торактагы иптәш кызларың янына килгән егетләр белән үртәшкәндә дә үтә тора. «Каракүл» капкасыннан эш сәгатеңне җиңеп чыкканда да, сигез сәгате үткән була инде ул яшьлекнең...

Ансар белән танышкан көнне Венераның унҗиде яшь чагындагы көндәлекләре ягылып, стенадагы артистлар рәсеме бала-чагалы фотолар белән алышынып, яшь-җилкенчәкләр яшәгән бүлмәләр белән ике арага межа төшә башлаган иде инде.

Тормышта киребеткән үҗәт һәм котылгысыз гап-гади бер канун бар — кеше гадәттә гел бер ияләнгән сукмактан йөри: эшенә бара, өенә кайта; эшенә бара да тагын өенә кайта. Һәм көн саен шулай кабатлана торгач, бу сукмакка шулхәтле күнегәсең — айларны аванс белән получкаларга, елларны туган көннәргә, гомерне яшьлек белән картлыкка гына бүлеп саный башлыйсың. Таныш һәм такыр сукмакта ялгызаклар нык чиләнә, чөнки үзеңә пар сайлыйм дисәң, башка сукмакларга да аяк басарга кирәк. Күпләрнең тормышы бер генә сукмаклы. Шуңа күрә врач — врачка, укытучы — укытучыга, эшче — эшчегә, начальник үзенең секретаршасына, министр министрлар кызына — кыскасы, бергә эшләгән-аралашкан кешесенә өйләнә яки кияүгә чыга. Ә Венераның эш урынында йөз дә егерме хатын-кыз. Ирләр мәсьәләсенә килгәндә, хезмәт хакы алган көннәрдән соң тиз генә эшкә чыга алмый торган ике слесарь һәм дүрт йөк бушатучы гына, аларын да хатыннары килеп каршы ала... Димәк, «Каракүл» кызларына башка профессия кешеләренең сукмагына төшү зарури. Эзләнергә кирәк.

Зоопарктан юлбарыс качкан иде. Җәбраил зиратында эзләп табып атып үтерделәр. Шул җанвар яшәгән читлекне күрәсе килде кызның...

Зоопаркка килде Венера. Иптәш кызлары көлеп калды: өйләнердәй егет, дөньясын онытып, буш читлек карап йөрмәс, танцыда булыр, зоопаркка түгел, төнге клубка барырга кирәк сиңа, диделәр. Венера сер бирмәде: «Мин кияүгә чыгарга җыенмыйм! Гороскопка язылган хайваннарыбыз нихәл яшәп яталар икән, күреп кайтыйм...»

Венераның аклануы җавапсыз калмады: «Безгә дигән арысланнарны читлекләргә ябып бетергәннәрдер. Авылдан килгән бозауларны эләктерсәк кенә инде...»

Яшәешнең һәрбер үзгәрешен саннарга әйләндереп теркәүче галимнәр бер әйтерләр әле: кияүгә чыкмыйм дип йөргән кызларның туксан тугыз бөтен йөздән туксан тугыз проценты мин кияүгә чыкмыйм, дия-дия көтмәгәндә генә кияүгә чыгып китә.

Зоопаркта вәгъдәләшкән килеш, беренче «свидание» кичендә үк Ансар Венераны эштән каршы алырга килмәде. Кыз урамга чыгуга авыр сулап саф һава йотты да үз-үзенә ишетелерлек итеп кенә: «Килмәсә, шуннан ни...» — дип куйды. Әйтерсең лә аның уйларын кемдер тыңлап бара да акланырга мәҗбүр итә. Адымнары әкренәйде, күзләр сүрелмәс өмет белән «Каракүл» берләшмәсе тирәсен айкады. Шаяртадыр әле, якында гынадыр Ансар, эшеңнән каршы алырга киләм, дип, бик ышандырып әйткән иде бит ул... Менә күрерсең, трамвай тукталышына җиткәндә, каршыга килеп басар әле...

Ә Ансар юк та юк. Ашыктырып трамвае да килеп җитте, үч иткәндәй, кешесе дә әллә ни юк. Башка көннәрдә, төнге смена алышыныр чакка туры килсәң, трамвайларда тотынып барырлык та урын калмый торган иде. Утырды да китте Венера. Күңеленә килгән беренче тойгы — үртәлү булды: карасана, мин җүләрне, бер күрешүдә үк ышанып... Үзе дә бит, адресларына хәтле әйткән була, зоопаркта маймыл карап йөргән нәмәрсә — берәр хәсис, итәк җиледер әле йә ике-өч хатын аерган кешедер. И сайраганын күрсәң... Венера тавис кош тирәсеннән китмичәрәк торганда килде дә кинәт: «Бу кош сезгә охшаган», — диде. Венераның өстендә яшел пәлтә, пәлтә чабуыннан чуар күлмәк итәге чыгып тора, башына кызыллы-яшелле чәчәктән тукылган чуклы шәльяулык бөркәнгән. Венера Ансарның үртәү сүзләрен елмаеп кабул итте. Тагын да сөйкемлерәк күренергә тырышыпмы, уч төбендәге түгәрәк көзгесенә күз салып өлгерде. Канатланып торган җиңел һәм калын чәчләрен тузгытып җил исәр якка борылып басты. Чәче — өлгереп, кишәнкәсенә сыймаган чикләвек төсендә дисәң, кызның күзләре яңгырга чыланган күгән җимеше зәңгәрлегендә иде. Ансар ирексездән кызга иярде. Әгәр дә хәзер аннан калышмыйча гел тагылып йөрсәң, бәхетнең нәкъ башкаласына ияртеп алып китәр төсле ул. Сөйләшми-нитми генә җанвардан — киеккә, читлектән — читлеккә, пыяла түбәле ботан бакчасыннан кышкы фермага килделәр. Тау кәҗәсе үзенең туган ягын онытып, купшы сакалын җилпеп печән чәйни.

— Менә бу кәҗәнең сакал селкетүе кемгәдер охшаган. Исемен әйтеп тормыйм, чөнки үзем дә белмим. — Венераның елмаюы көлүгә тартым иде.

Ансар як-ягына каранып алды. Алай, бу тирәдә сакаллы җан ияләре икәү генә: берсе тау кәҗәсе үзе, икенчесе Ансар. Курстагы егетләр белән бер чамадарак күреним дип, соңгы айда кырынмый башлаган иде ул — очлы ияген сакал басты. Тора-бара сакал белән мыек бергә тоташты, кызыл ирене уртада чекерәеп калды.

— Рәхмәт, — диде Ансар, — маймыллар яныннан үткәндә дәшми калуыңа рәхмәт.

— Ә мин маймыллар турында бер анекдот беләм.

— Мин дә беләм. Сөйлимме? — диде Ансар, кызлар мәзәгенең беркатлырак икәнен чамалап.

— Оятсыз булмаса, сөйлә...

— Әдәпле итеп үзгәртәм алайса... Ир белән хатын аптыраганнан гына зоопаркка килгәннәр. Үпкәләшкәннәр бугай, хатын ирне үртәргә теләгән, маймыл читлеге янына килеп баскач, изүен чишкән, итәген күтәреп ботларын күрсәткән. Ата маймыл түзмәгән, читлекне каерып хатынны агач башына алып менеп киткән дә көчли башлаган. Ир хатынына кычкыра икән: «Йә, йә, башым авырта, кәефем юк, эштән бик арып кайттым, дип, акланып кара инде моңа», — дигән.

Венера көлмәде.

Шәһәр күленнән инде көз көне үк чайпалып кергән җыентык күлләвектә соскы борынын көчкә күтәргән пеликаннар яшәргә азаплана. Алар янына җиткәч, Венера туктап калды. Нәрсәнедер исенә төшерә алмыйча интеккән кыяфәт белән аяк очына текәлде, дөресрәге, кыланды. Чөнки зоопаркта бүтән карар нәрсә калмады, утыз тәңкәлек билетыңны ерта-ерта кайтыр юлыңны эзләргә вакыт. Әгәр егет белән танышып өлгермәсәң, капкадан чыккач соң булырга мөмкин. Бәлки, егетнең артык тагылып йөрергә исәбе юктыр, күңеленә өмет җылысы бөркисе бар.

— Кемнәргә охшаганыбызны белдек, исемнәребезне дә әйтешсәк...

— Мин Ансар атлы.

— Венера дип эндәшерсез.

— Юрфактан. Быел диплом бирсәләр, адвокат булып баерга исәп.

— «Каракүл» берләшмәсеннән. Бүрекләр тегәм.

— Фатирант.

— Тулай торакта.

— Менә таныштык та, — диде Ансар, сөйләшүнең рәсми өлешен түгәрәкләп, — исемеңне сорый алмыйча, зоопарк буйлап ике-өч әйләнеш ясауның кирәге калмады.

Ә көн әйбәт. Февраль аеның кәефе күтәренке чак. Кояшы күзгә күренмәсә дә, шәһәр сөтсел пыяла аркылы яктыртылган төсле — ни иртә, ни кич икәнне белерлек түгел, гел бертөрле яктылык. Салкыны да парлылар бер-берсенә сыенып барсын өчен генә. Бозлы түбәләргә бәби сөңгеләр эленгән. Авыл ягыннан җәяүләп кенә буран килә — кырда механизаторлар тота алмаган карлар шәһәр урамына кача.

Венера мулине җепләр белән чигелгән ак йон бияләенә саф сулышын өрде. Ансар аңласын дип инде. Шәһәрдә кул җылытырлык урын беткәнме? Дистәләгән театр, биш культура сарае, юып капланган тәлинкәгә охшатып төзелгән тирән эчле цирк, планетарий, биш музей, киметеп кенә санаганда да уналты ресторан, егерме дүрт бистро, төнге клублар һәм башка җылы урыннар...

Ансар Венераны «Чәй йорты»на алып керде. Монда ни теләсәң, шул бар: ит белән пешерелгән белен, шулпалы өчпочмак, манты, лимонлы чәй... Һәм өч кашык туңдырмага бер кашык чия вареньесы тамызсаң, чырага кадап урам буйлап суырып йөри торган «Пломбир»га «Кала утлары» дигән исем кушыла икән. Чират җитеп, өстәл артына утыргач, колак төбендә музыкага бәхетле ярлар чөкердәшүе дә кушылгач, кыз күңелендәге шик-шөбһәләр бөтенләй онытылды. Яңа таныш иске дус булып тоела башлады. Эшем кешеләре өчен түгел икән бу ашауханә. Әллә ни җитди сүзләр сөйләшмәделәр. Ансарның бер җөмләсе генә аеруча хәтердә калган: «Мин сине иртәгә эшеңнән каршы алам!..» Әйе, икенче көнне үк, һичшиксез, күрешәчәкбез, дип, туңдырма ялый-ялый вәгъдәләр биргән иде ул. Ә үзе бүген Венераны каршы алырга килмәде...

Икенче көнне шимбә иртәсендә, әллә гарьлектән, әллә тынычлыгын җуйган күңелне юатыр өчен, Венераның башына бер уй килде. Уй дигәннән бигрәк, кешелек яралганнан бирле, буыннан-буынга күчеп, хатын-кызлар арасында әле һаман көчәя генә барган зәгыйфь гадәт — ирләрнең ялганын фаш итү теләге иде ул. «Адресын дөрес әйткәнме? Буйдак кеше микән? Укыган урыны, исеме — үзенекеме?» Менә шушы сораулар кичекмәстән җавап таләп итеп, Венерага, горурлыгын җиңеп, Ансар исемле кешене эзләп китәрдәй көч өстәде.

Иске универмаг артындагы Дегетле урамын бик тиз эзләп тапты ул. Тәрәзәләрен күлгә төбәп туңып калган ике катлы агач йорт ишегенә килеп җиткәч, ишек яңагындагы кызыл төймәгә үрелеп маташмады, борылып басты да ишек тактасын биек үкчәле итек табаны белән төйде.

Фатир хуҗасы, ишекне болай дөбердәтүгә кисәк кенә аңгыраеп, ялан аягы белән баскыч басмаларын саный-саный, икенче каттан тыпырдап килеп тә төште. Тик ишек шудырмасына кагылырга ашыкмады, такта аркылы гына кемнең кем икәнлеген ачыкларга керешге.

— Кем бар анда?

— Мин.

— Белмәгән кешегә ишек ачмыйбыз.

— Ансар янына килдем.

— Алып киттеләр аны.

— Кая?!

— Кая-кая?! Сасы күлгә, вәт кая.

— Кем алып китте?!

— Берни белмәгәндәй кылануын күр син аның... Карак ялгыз йөрми, бергәләшеп урлагансыздыр әле. Кач лутчы, сине дә эләктерерләр. Кит! Ату каравыл кычкырам!

Тагын әллә ниләр әйтә алыр иде бу фатир хуҗасы, әле ярый ялан тәпиләре февраль салкынын өнәми икән, бик тиз генә баскычыннан менеп шылды.

Венера сөенде дә көенде...

Адресын дөрес әйткән Ансар, алдамаган. Ә менә урлаганы өчен кулга алынуы күңелгә шом сала. Зоопаркта танышкан булып йөрүе Венераның бүрекләр тегә торган цехта эшләгәне өчен генә түгел микән?! Венера шуңа ышанып, өметләнеп, эштән соң сагынып күрешәбез дип көтеп торды... Хурлыгы ни тора... Гомереңә кияүгә чыкмаска антлар бирерсең... Бер ышанычлы егет калмады, таныштың исә, хушлашыр чак та җитә.

## Монысы – сержант, тегесе – майор...

Кеше дигәнең гомере буе мажарага сусап яши: җирдә ялтыравык нәрсә аунап ятса, иелеп карый; ботак тишеге күрсә, бармагын тыга, чокыр-чакыр төбеннән нидер эзли; пышылдау ишетсә, туктап кала; төркемгә юлыкса, ерып-сугып кеше арасына керә, тизрәк вакыйганы беләсе, мажараны башкалардан алданрак күрәсе, яңалыкны иң беренчеләрдән булып ишетәсе килә аның...

Ансар, каршысына шапылдап килеп төшкән биштәр янынан гамьсез генә, серле табылдыкны чишми генә, мажара аркылы атлап китә алмады. Бу минутта Венера да, беренче очрашу да онытылды, әлбәттә. Беренчедән, ул инде бүген-иртәгә закон сагына басасы яшь юрист; икенчедән, монысы, әлбәттә, иң зур сәбәпчесе — башкалар кебек үк ул да мажарага сусап яши.

Төнге урамны аулакка санап кәперәеп йөрерлек түгел икән, Ансар биштәргә тыгылып, чәшке тиресеннән тегелгән бүрекләрне санарга да өлгермәде, әллә кайдан гына милиционер пәйда булды — якадан эләктереп тә алды...

Бүрек индустриясенең үз тарихы бар...

Бу дөньяда бүрегеңә карап сәлам бирәләр. Ил башында агайлар утыра. Шуңа күрә сүз ирләр бүреге турында бара... Мавзолейдагы юлбашчыбыз сукно белән тышланган бүрек кигән, ул, сарык тиресеннән

тегелеп, зәңгәр төскә маныла һәм колакчасы төшерелеп бәйләнә... Атамыз Сталин, сукно бүрекләрне күн белән тышлатып, маңгаена кызыл йолдыз кадатты... Аннан соң колакчасыз папаха кигән Кукуруз Патша тәхеткә килде. Гади халык, аңа охшамаска тырышып, куян, бүре, кәҗә, эт һәм төлке бүрек киде... Генеральный секретаребыз су кондызыннан тегелгән йөнтәс бүреген егерме ел буе саклады... Брежневтан соң бик күп бүрекләр идарә итте. Шуңа күрә түрәләр башында су эте, болан баласы, чәшке яисә ак төлке ише җәнлекләр буталып бетте.

Бүрек ул — санлы кешенең җәмгыятьтәге урынын билгели торган җылы символ, баштан башка күчә торган җонлы валюта, адәм башына җитә торган купшы хәвеф...

Ансар тартып төшергән биштәрдә унбиш кешене башлы итәрлек бүрек иде. Мондый очракларда бирелергә тиешле сорауларны яхшы белгәнгә күрә, җинаять процессы кагыйдәләренә туры китереп, алдан ук җавап кайтарды ул:

— Исемем — Ансар, фамилиям — Субаев, 1980 елгы, юрфакның соңгы курсында укыйм. Вакытлыча Дегетле урамындагы сигезенче йортта яшим. Моңарчы хөкемгә тартылганым юк. Капчыктагы бүрекләр минеке түгел.

— Ачыкларбыз, — диде милиционер, кесә фонарен төбәп.

Җинаятьчене тоткан агайнедә бераз масаю сизелергә тиеш иде, ә бу никтер көчәнеп кенә сөйләшә. Ләкин тавышы таныш. Баядан бирле искә төшерергә азаплана Ансар, әгәр фонарьны үзенә каратып булса...

Шулчак тәртип сакчысы, тәмәке кабызырга дип, газлы зажигалкасын яндырды. Ялгыш газы күбрәк ачылды бугай, бер карыш буе ялкын күтәрелде, аның яктысында Ансар сержантның йөзен танып өлгерде.

— Вәт сиңа мә! Райнур! Тавышыңны үзгәрткән булып...

— Әйе, мин сержант Райнур Асланов. Ләкин безнең танышлыкка исәп тотма. Син, гражданин Субаев, җинаять өстендә тотылдың. Бу бүрекләрне сиңа кем ыргытты? Шушы сорауга дөресрәк итеп җавабыңны әзерлә.

— Мин ялганлый белмәдем, хәтерлисеңдер, Райнур... авылдаш, классташ, сержант Асланов.

— Ышанасы килми, урлау ялгансыз булмый ул.

— Төлкегә дигән капкынга керпе дә эләгә.

— Җинаять өстендә тотылдың.

— Исбатлый алырсыңмы, иптәш сержант?!

— Җинаятьчесе тотылгач, җинаяте күп аның бездә — табылыр... Менә дигән итеп исбатларбыз, Субаев, дипломыңны күрергә мәхрүм булырсың.

— Минем белән юанып, юкка вакыт әрәм итмә, Райнур, бавыннан тартып төшермәгән булсам, бүрекләрне эзләп чын угрылар үзләре килер иде. Тотасы кешегез шушы тирәдә безне күзәтеп торадыр әле.

— Гражданин Субаев, тот капчыгыңны! Киттек!

— Хәзер, капчык күтәреп йөрисем калган икән, үзеңнең аркаңа сал.

— Грубо сөйләшмә!

— Барыбер капчык минеке түгел.

— Синеке шул, минеке диярсеңме әллә?

— Минеке түгел, дим.

— Минеке дә түгел...

Кинәт кенә, күктән төшкәндәй, ике егет килеп басты:

— Берегезгә дә кирәкмәсә, безгә бирегез. — Һәм егетләрнең берсе капчыкка килеп ябышты.

— Шаяртмагыз, — дип кырт кисте сержант. — Сез хәзер шаһитлар, менә бу каракны, — диде ул, Ансарга төртеп, — кичекмәстән алып китәргә кирәк.

— Шаһитлар... безме?! Сез кемнәр соң, каян килдегез? Бу шәһәрнең исеме ничек? Ни бүлешәсез? Күрмәдек, белмәдек. Хуш иттек.

Ике егет, тигез атлап, дөп-дөп басып китеп тә бардылар. Сержант ни эшләргә белмичә аптырап калды. Шаһитларны куып китәр иде... Ансар үзе генә кала, беләгеннән эләктереп тегеләрне куа китсәң, капчык кала. Күзгә күренгән шаһитларны югалталармы соң?! Һәр ике як өчен дә бик кирәкле кешеләр алар.

Ансар сержантка ярдәм йөзеннән, ике бармагын авызына кабып, милиционер сыбызгысы шикелле сызгыртып җибәрмәсенме!.. Шуны гына көткәндәй, агач өйләрнең берсеннән тәбәнәк, әмма юантык гәүдәле ир кеше очынып чыкты. Чыкты да, йөгергән егетләрне каракларды дип уйлап, аларга:

— Стой! Атам! — дип кычкырды.

Шаһитлар, тукталып, тавыш килгән якка борылдылар. Чынлап та, ир кеше кулында мылтык иде. Шуннан соң алар бер-берсе белән пышылдашып киңәшеп алдылар һәм әкрен генә капчыклы Ансар янына килеп бастылар:

— Без шаһит булырга риза!

Шушы районда патрульдә йөрүче милиция «Жигули»е килеп туктагач, сержант экипажга рапорт биргәндәй итте:

— Иптәш майор, засаданың тагын бер корбанын эләктердем. Монысы да бүрекле капчыкны бавыннан тартып төшерде, — диде ул, Ансарга баш бармагы белән төртеп. — Шаһитлар да табылды, качып китмәкчеләр иде, менә бу агай ярдәм итте.

Майорның погонындагы йолдызы караңгы төндә дә уттай янып тора. Ул мылтык тоткан ир кеше янына кочагын җәеп дигәндәй килде:

— Рәхмәт, Гадигали агай, син барында бу тирәдә милициягә эш әзәя.

— Эш дип инде, шаһитларны гына туктаттым.

— Кайчагында опергруппа белән тотарга туры килә әле аларны. Барыгыз, Гадигали агай. Тынычлап йоклагыз... Шаһитларыгыз өчен тагын бер кат рәхмәт.

— Агайны җибәрәсез, ә мылтык тотарга рөхсәт язуы бар микән? Иске бистә Мари урманы түгел ул, ауга йөрер җир юк, — диде Ансар, боерулы тавыш белән.

Майор белән Гадигали агай шундый итеп көлделәр... Болай итеп бары тик агач мылтыктан гына көләргә мөмкин иде.

Гадигали агай аксый-аксый китеп барды.

— Тозакны да, шаһитлар белән Гадигали бабайны да алдан ук әзерләп куйдың инде син, әйеме, Райнур?

— Алайга киткәч, шаһитлар белән дә танышыйк. Фамилияң бармы? — диде сержант, егетләрнең берсенә фонарь уты төбәп.

— Мирзин.

Мирзин дигәне минут саен чалбарын күтәреп ала. Төшми инде чалбары, тик гадәте — ике куллап чалбар путасына тотына да кисәк-кисәк йолыккалый, пәлтә төймәләре чишелгән. Нервлары какшаган, күрәсең. Гаепле кешеләрнең шуныңише берәр алама гадәте була, диләр иде психология дәресләрендә. Йә ул еш-еш тамак кыра, черт-черт күзен йома, көннәр буе җыр җырлап йөрергә мөмкин... Ә Мирзин, чалбарын күтәреп-күтәреп куймаса, үз-үзенә урын таба алмый бугай.

— Байгушов.

Монысының йөзе өчпочмакка охшаган: маңгае киң, яңаклары ябык, ияге очлы. Сөйләгәндә, коелган алгы теше урынына теле кысыла.

Ул арада махсус машина да килеп җитте.

Әгәр ара-тирә сирена үкертеп алсаң йә түбәдәге ялт-йолт итә торган утны сүндермәсәң, «Каракүл» берләшмәсеннән милициянең район бүлегенә кадәр араны «Жигули» ике минутта үтә ала. Ләкин сержант Асланов шоферга ашыкмаска кушты, чөнки ул бүген үзенә бирелгән рольне үтәр өчен барысын да ныклап, тагын бер кат яхшылап уйлап чыгарга тиеш иде. Ә Ансарның җене котыра...

— Син мине беләсең, Райнур, ун ел бергә укыдык, кеше әйберенә кызыга торган гадәтем юк. Кеше ярлары, дисәләр, кызларга да күңел салмыйм хәтта. Теләсәм, Алсу җанашыңнан коры калдыра ала идем мин сине. Безнең авылда кыз урлау мәртәбәгә санала...

— Монда дәүләт милке турында сүз бара, Субаев!

— Кыз бала хосусый милек түгел ич. Син урлап өйләнден аңа, сержант!

— Яратмаган кызлар урлатмый, Ансар. Без хәзер егерме беренче гасырда яшибез. Йолалар, традицияләр, дин һәм әхлак яңара торган чорда. Гел кирегә сукалап утырасың.

— Бу минутта караклык турында бәхәс куптарырлык сәбәп бар дип исәпләмим мин.

— Алай түгел шул. Без кеше кесәсенә керүне караклыкка саныйбыз, ә дәүләт милкен кесәгә салып та, күтәреп тә, машинага төяп тә ташыйбыз... Шартын туры китереп, өй саен рәттән тикшереп чыксаң — иң намуслы, иң акыллы, иң гадел дигән хуҗаның да чәлдергән яки эштән болай гына алып кайткан, һич югы, бушлай кергән берәр әйберсе табылыр. Без бит миллион кешеле шәһәрдә яшибез: миллион авыз, ике миллион кул, ким дигәндә, биш-алты миллион кесә...

— Артыгын аңлатасы юк, биш ел буе дәресләрдә сөйләнгән болар... Бәхәсле әйбер. Кемдер ярты капчык бүрек урларга җыенган икән, аңа карап бөтен ил халкына «урлыйсыз!» дип кычкырыргамы? Әгәр кешең завод-фабрикада эшләмәсә?! Әйтик, интеллигенция үзенең эш урыныннан нәрсә ташый ала? Безнең кафедра мөдирен генә алыйк, чык бөртеге төсле саф күңелле... Университетта, белгәнеңчә, кирпеч измиләр, бензин кумыйлар, мануфактура цехлары ачылмаган әле... Аннан нәрсә күтәреп кайтмак кирәк?

Райнурга үз сүзен өскә чыгармыйча ярамый. Ни дисәң дә, ул сержант кеше, ә рульдә кичә генә эшкә алынган рядовой «салага». Авторитет бәхәсләрдә яулана ул.

— Мөдирең үз йорты белән яшиме, Субаев?

— Ундүрт катлыда.

— Машинасы нинди маркалы?

— Җыелма велосипеды бар бугай.

— Туганнары олы урындамы?

— Детдомда үскән ул... Йә, әйтерең беттеме?
— Дачасы бармы?
— Кешечә инде. Дачасызлар юк ул хәзер.
— Вәт, күрдеңме, — диде Райнур, үзе шоферның җилкәсенә төртеп, — мин хаклы — дача төзегән агайнедә җитәрлек инде ул чәлдергән материал!.. Шунысы кызганыч, безнең балаларга урларлык нәрсә калмый, алар үсеп җиткәнче, дөньяны талап бетерәләр инде...
— Сержант дәрәҗәсенә хәтле ничек үсте микән бу, дип, баш ватам тагы, грамотныйланган син.
— Пагонны бушлай өләшмиләр. Димәк, кирәк чакта җанымны кызганып тормаганмын. Сиңа сөйләп торасы юк, тәвәккәллегемне хәтерлисеңдер?!
— Авылга кунакка кайткач, танцыга чыкмаганы өчен Алсуның күкрәгенә пистолет терәгәнеңне әйтәсеңме? «Батырлыгыңа» клубтагы бөтен яшьләр шаккаткан иде шул.
— Уенчык пистолет бит ул, теге, утыз ике тәңкәлек. Клубка корал күтәреп чыгарга әллә башыма тай типкәнме? Синең кебек студентларны биш бармагым белән дә каптыра алам мин... Нәрсә трамвайга ияреп барасың, — диде Райнур, кинәт шоферга җикеренеп, — тизрәк отделга кайтасы бар.
Милиция бүлегенә кайтып кергәч, сержант белән майор аңлашкан арада, Ансар янына бер агай килеп басты. Күрер күзгә җан этәргеч кешедәй тоелса да, яңа чутланган бура исе килә үзеннән.
— Сине кем тотты? — диде ул Ансарга үз итеп.
— Әнә, сержант.
— Мине дә. Юк белән яндым. Мебель фабрикасыннан мин. Диван аягы апчыгып бара идем, апаем, дүрт штукны кесәгә тыгып. Охранникның исе дә китмәде, ә урамда сиздермичә генә болар качып торган. Нәмәкәйгә дип шушы проходнойга килгәнмен, белмим, апаем? Безнең цехныкылар юкса гел койма ярыгыннан йөри. Эшкә килгәндә генә проходнойдан керәбез. Каравылчыга күңелсез булмасын дип, капкага килгән идем... юк белән яндым.
— Үзең әйтмешли, нәмәкәеңә кирәк иде инде ул таяклар? Лутчы диванын гына күтәреп кайткан булсаң...
— Бәй, апаем! Анысы зур караклыкка керә бит аның!
— Болай да диван урлагансың, диярләр...
— Китче, исәр... Күрәсең ич, салмыш мин, аңгырайган башкаем белән тиктомалдан, ялгыш ияреп чыккан, дип нык торачакмын. Иртән штрафлап озатырлар. Үзең нәмә белән каптың?
— Бүрек белән, чәшке тиресе.
— Белдем, «Каракүл» берләшмәсенә алыш-биреш эшем төшкәне бар. Бәй, апаем, син дә исереккә сабыш. Икебезне бер «КПД»га ябарлар.
— «КПЗ»гамы?
— Без миндәләлеләргә барыбер ул, апаем... Бер «КПД»га ябарлар... Иртән дус булып аерылырбыз. Тик кара аны, сержантларга каршы дәшә күрмә, авыр сүз әйтмә: «Әйе, әйе!» — дип кенә тор. Майордан курыкма, беләм мин аны. Аның генераллары да берни түгел, ә менә сержантлары...
Агайның фикере бүленде. Ансарны күрше бүлмәгә дәштеләр. Сержант Асланов, берничә бит чиста кәгазь куеп, аңлатма язарга кушты:
— Яз әйдә. Почмагында буш урын калдыр. Начальник исеменә яз.
— Беләм, беләм, — диде Ансар, — өйрәтмә!
Венера белән күрешергә дип ашкынулар, капчыктагы бүрекләр, классташ Райнур белән бәхәсләшүләр — барысы-барысы ярты бит кәгазьгә сыйды да бетте.
— Тәк... — Аңлатманы укып чыккач, сержант Аслановның беренче сүзе шул булды. — Син монда көн кебек ачык хәлләрне генә язгансың. Биш ел буе нәрсәгә генә укыттылар соң сине?
— Аңлатма, дидең, әкият язарга кушмадың ласа.
— Ә син версияләреңне әйтеп кара. Бүрекләр биштәрдә тумагандыр бит, койма башына да җил белән менмәгәндер?! Свиданиегә барам, дигәнсең, ул кызның исеме юк.
— Причем монда ул кыз?! Мин аны әле үзем дә бер генә тапкыр күрдем, зоопаркта. Исемен белмим.
Кеше дөресен сөйләргә теләмәсә, мәҗбүр итмәгез, юкса ул барыбер ялганларга керешәчәк. Дөреслекне сөйләп бирсә, ул кемнедер югалтырга тиешле була. Гомер буе дөреслекне сөйләп йөрүчеләр, һаман саен кемне дә булса югалта барып, ахыр чиктә берүзе, япа-ялгызы кала. Ансар Венераны югалтырга теләми. Сержантка турысын әйтеп бетермәвенең сәбәбе шул.
— Гражданин Субаев, исемен белмәгән кызны төнге унбердә эзләп киләләрме?!
— Чибәр кызлар төн уртасында да таныла ул... Ни, иптәш сержант, колак очыма телефон номеры чалынды: 3–52 бугай. Проходнойдан шылтыратасы.
— Ә син причем, дисең! 3–52 номеры берләшмәнең унынчы фабрикасы бит инде. Әлеге бүрекләр шунда тегелә.
— Чынлап мәллә?! — Ансар аптырашка калды.

— Белмәгәнгә сабышма. Болайга киткәч, каптың инде, Субаев. Йә бүрекләрне үз өстеңә аласың, йә безгә булышасың!

Сержантны инспектор ашыктырды.

— Ашыксак та ярый, Субаевның торган җиренә барып җиткәнче, тентү ясаганчы, таң ата.

Һәр эшнең үз тәртибе бар.

Заводта яки фабрикада берәр карак тотылса, җинаять кодексы нигезендә, урлаучының өенә кичекмәстән тентү ясалырга тиеш. Ягъни өендә урланган мал сакланмыймы — шуны белер өчен. Дөрес, әлеге маддәнең бер почмагында: инспекторны проходнойда торучы каравылчы чакырырга тиеш, диелгән. Моны ничек аңларга?.. Хикәябезгә кагылышлы булмаган бер мисал китерик. Әйтик, бер шаян ханым, үзенең нечкә биленә урап, эшкәртелгән тире алып чыгып карамакчы иде ди. «Күбәләк канаты» аркылы үткәндә, каравылчы дәдәң, сизгер куллары белән ханымны капшап, әлеге тирене күпертмә койрыгыннан тартып чыгара. Шул мизгелдә «күбәләк канаты» шартлап бикләнә. Тавышка каравылчылар начальнигы йөгереп килеп җитә һәм нечкә билле ханымны тәмәке төтененнән ысланган кечкенә бүлмәгә ябып та куя. Карышып-нитеп маташуның хаҗәте юк, җиңәрләр, сменада берьюлы дүртәүләп саклый алар... Ханымның тән җылысы сеңгән тун өлгесен минималь хезмәт хакы белән бәяләп, акт төзелә дә шундук инспекторга хәбәр ителә... Ләкин ни хикмәттер инспектордан алдан цех начальнигы килеп өлгерә (белмим, кем җиткергәндер аңа?!). Ул тиз генә акт кәгазен кесәсенә салып куя һәм инспекторга ияреп ханымның фатирына тикшерергә бара, пүнәтәй рәвешендә. Ханымның өендә имгә дисәң дә затлы мех әйбер табылмый: туны ясалма тиредән, көзге пәлтәсе — якасыз ясалма замша, бүреге — чебурашка курчаклары тегә торган йонлач тукымадан әвәләнгән, чит кешеләрне күрсә, эт булып өрергә әзер торган кара песи генә, «натуральный тунын» кабартып, аяк астында буталып йөри... Димәк, әлеге хатын гомер буе купшы тауар янында эшләп тә беренче тапкыр гына шаярган. Бәлки, аның нечкә биле туңа башлагандыр... Артык гауга куптарырлык сәбәп юк... Акт кәгазе цех начальнигы кесәсендә кала, ханымның «эше» халык судына барып җитми. Ак чәчәкнең дә күләгәсе бар, ханымның башыннан сыйпап рәхмәт әйтмәсләр, әлбәттә, цех җыелышында аягүрә бастырып оялтырлар. Өч минималь хезмәт хакы күләмендә штраф түләтерләр, бәлки әле ике генә айга арзанрак эшкә дә күчереп торырлар. Тик хөкемгә тартыру кирәкми. Ханымга да, цех начальнигына да кирәкми ул суд. Ни өченме?

Шәһәрнең яшәү гаме бүрекләләр ярышына корылган: җыеннары — бәйге тотып, уңыш бәйрәмнәре — сүз куешып, атлары — чабышып, машиналары узышып куандырыр. Бүрек тегүчеләр үзләре дә ярышып яши. «Каракүл» берләшмәсенең һәр ун фабрикасы арасында сыйнфый көрәш бара. Продукциянең сыйфаты, эшкә мөнәсәбәт, вакытны дөрес файдалану, чималны янга калдыру, эш урынындагы тәртип кебек мөһим күрсәткечләрне чагыштыргач, ел ахырында кайсы цех начальнигының күбрәк премия аласы ачыклана...

Сержант Асланов «капчыклы бур»ны койманың урам ягында тотып алды, шуңа күрә дә әлеге вакыйганы проходнойдагы каравылчыларга сиздереп мәшәкатьләнмәде. Иртәгә белерләр алар бу турыда, ә бүген вакыйгага Асланов үзе хуҗа.

Шәһәр күленә саф һава суларга чыга торган чаклар, калын боз тынчыган суны томалап куйган. Ансар урнашкан фатир — ике катлы агач йорт, Дегетле урамының теге башында, алгы тәрәзәләре белән шәһәр күленә акаеп тора. Фатир хуҗасы, түләү мәсьәләсенә килгәндә, студентлардан акчаны ел фасылына карап ала: тәрәзәләр ачылыр чакта, тирләп-пешкән шәһәр күле боз астыннан чыккач, бер айга ун доллар, ә тәрәзәләр ябылып, кышка пластилин белән сылап куелгач, унбишне сорый.

Челт-мелт лампалы милиция машинасы килеп туктагач, келәт хуҗасыннан өреккән ата мәчеләр шикелле, подъезд ишегеннән бер кабилә малай-шалай ишелеп төште.

— Һай! Һоп! Уһ! — дип бармак янап калды сержант. — Вакыт кына юк, мин сезне өерегез белән бергә...

Яр буендагы әлеге ике катлы агач йорт затонга качкан йөзмә пристаньга охшаган иде. Тәрәзәләре күп күбен, ләкин ишеге бер генә икән. Ишек яңагына уелган төймәгә баскач, әллә кайдан гына саңгырау тавыш ишетелде.

— Ыхтутам?

— Без.

— Апа, мин әле бу, — диде Ансар, сержант тавышына ишекнең ачылмаячагын белеп, — дуслар белән.

— Шушы вакытка хәтле йөргәч, таң атканны көтсәң, ни булган. Тәмле йокыны әрәм итеп... Студент халкын фатирга кертерлекме соң... Эштән арып кайтсалар, йокы кадерен белерләр иде, — дигән зарлануларга кушылып, эчке яктан ишек шудырмасы ыңгырашып куйды. Ишек ачылып китсә дә, каршы алучы күренмәде. Сержант кесә фонаре кабызып болдырны айкаган иде, ишек шудырмасына бәйләнгән озын бау күзгә чалынды — бауны икенче каттан торып кына тарталар икән... Такта баскычтан икенче катка менгәч, каршыга тагын ишек килеп басты, — үзе зур, үзе калай белән тышланган. Берәмберәм йозаклар келтерәде, келәләр шалтырады.

— Фатирантларны шәп саклый апагыз, — дип көлемсерәде сержант, — мал кадерен белә!

Пүнәтәйләр эзләп урамга чыгасы юк икән, янәшәдә генә тагын бер калай ишек бар. Күршедән карт белән карчык килеп керделәр.

Хуҗа кеше, биш ел фатирда торган Ансарны танымагандай, усал карап куйды. Төнге «кунаклар» белән мазасызлап йөрүен өнәмәде. Шулай да милициянең күрше-тирәләр жалобасы буенча түгел, ә Ансарны тикшерер өчен килгәннәрен белгәч, үзен тыныч тотты.

Тентү беркетмә кәгазе өчен генә кирәк иде, сержант өметләнгән нәтиҗә күз алдында.

Инспектор, сержант белән ник килгәненә үкенгәндәй, йорт эчендәге җиһазларга: ян-ягы фанерадан түгәрәкләп бөгелгән кием шкафына, рамнарына кара җимеш төшләре ябыштырып, кулдан эшләнгән нәзек озын сервантка, агач эшкәртү остаханәләрендә өйрәнчекләр этмәлләгән дүрт кырлы такта утыргычларга, үз гомерендә әллә ничә кат буяу күргән тимер караватларга тагын бер карап куйды да фатир хуҗасыннан гафу үтенеп чыгып китте.

Фатир хуҗасы, пүнәтәй күршеләренә һәм сержантка яхшы күренергә теләп, Ансарның бар мөлкәтен — китаплары белән кием-салымын ишек төбенә өя башлады. Ансар уңайсызланудан күз карашын кая яшерергә белмичә интекте, аптырагач, түшәмгә текәлде. Анда олы бер үрмәкүч, яшәүдән туйган җан ияседәй, матча тирәли «бау» күтәреп йөри... Бауның бер очы—аудa...

— Апа, китапларга кагылмагыз, аларның гаебе юк. Берүк идәнгә чәчә күрмәгез! Иртәгә көндез өегезне бушатырмын. — Бу Ансарның соңгы сүзе иде.

Баскычтан йөгереп диярлек төшсә дә, Ансарның ашыгырлык урыны юк.

«Жигули» тагын милиция бүлегенә юнәлде.

— Ансар, туганнарыңамы, дусларыңамы — кайсысына илтеп куйыйк соң үзеңне? — диде Райнур. Ул инде хәзер баягы кырыс сержант түгел. Масаюы сизелми, тавышында кинаяләү тоны да юк.

— Рәхмәт, классташ. Фатирымнан кудырттың, инде туганнарым йөз чөерсен дисеңме?

— Алайса, әйдә безгә!

— Ы-һы!.. — Ансарның бу ымлыгы: шушы хәтле кәмитләреңнән соң өеңә чакырырга ничек телең әйләнә, дигәнне аңлатса кирәк...

— Алсу да сөенер. Чынлап, Ансар, әйдә!

— Уйларымны бүлдермә әле, Райнур...

— Менә син, Ансар, бүген авыр хәлдә калдың, фатир хуҗасы алдында, дим... Ә миңа, киресенчә, җиңел булып китте.

— Үч алгачмы?

— Нинди үч? Бүлешер малыбыз юк ла... Минем урында булсаң, син үзең дә нәкъ шулай эш итәр идең бүген.

— Шушы тирәдә туганнарым бар, төшеп калыйм әле мин.

— Үпкәләмә, Ансар, — диде Райнур, «Жигули» туктагач, — егет бул!

— Бик тиз үсәрсең, классташ, мин өйгә кайтып җиткәнче, өлкән сержант итеп куярлар үзеңне.

— Үпкәләсәң үпкәлә, тик бүрек каракларын тотарга булыш. Шундый шәп план корып куйдым, шаккатарсың. Синең белемең дә, ярдәмең дә бик кирәк безгә, Ансар. Диплом алгач, сине милиция эшенә җигеп булмас. Адвокатлар алар өстәл артына утырып кына безгә караганда да күбрәк акча алалар. Без гаеплеләрне эзлибез, куабыз, тотабыз, кан коябыз... Ә син менә аларны яклап яшәрсең, гаепле түгел, дип аклап, кире җибәрерсең.

— Конституция бөтен кешене якларга куша.

— Ашыкмый тор, Ансар. Киләчәк турында зурдан кубып сөйләшмик. Син әүвәл үзеңне якларга өйрән әле — менә булырсың адвокат!

— Укуны ташлап, хулиганнар куып йөрергә кушасыңмы?

— Ташлама! Җаен тап. Яз җиткәч, кар астыннан тукталыш саен бишәр-алтышар буш акча янчыгы килеп чыга. Без инде трамвай-троллейбуслардагы кесә каракларын җинаятьчегә дә санамыйбыз — шук куллы малайлар гына, дибез. Бүрек салдыручылар, машина талаучыларны да күрмәмешкә сабышабыз. Вакыт юк безнең вак-төяк эшләр белән йөрергә. Бер миллион карак төрмәдә утыра, әле тотасылары күпме?! Бүреге зуррак булган саен, кулга алуы кыенрак.

— Беләм, — диде Ансар, соңгы яңалыклар турында хәбәрдарлыгын сиздерергә теләп, — каракны хәерче чагында тотып калсаң гына, баегач тоттырмыйлар алар...

— Мине аңлавың өчен рәхмәт! — диде сержант саубуллашып.

«Рәхмәт» сүзен әллә ничә төрле мәгънә белән әйтеп була икән.

## Йокың ничә сум тора?

Калын-калын кодексларны рәттән укып чыксаң, рөхсәт ителә, ярый, мактаулы эш, хокукың бар... кебек сүзләрне бик аз очратырсың. Аның каравы: катгый тыела, җинаять санала, мәҗбүри, мәхрүм ителә, ярамый һәм башка шул мәгънәдәге сүзләрнең исәбенә чыгарлык түгел. Сабыймы син, үсмерме, яшь иптәшме, олы яки өлкән яшьтәме — барыбер синең өчен «ярый»га караганда «ярамый» күбрәк. Ярый-

ярамый, белә-белми, җиңә-җиңелә, сөя-сөйми, табыла-югала... Табуга караганда, югалтулар күбрәк. Бер бәхетеңне эзләп табу өчен күпме югалту кичерергә кирәк.

Ансар урамда калды. Дегетле урамыннан куылгач, бүген инде барып сыенырлык кеше калмаган иде. Төн уртасында кемнең кемгә кирәге бар?

Кышның бик мактанчык чагы, атналап-атналап салкыннар гайрәтләнә. Тик торган җирдә бигрәк кыен — түмрәннәреңне чатнатырлык үткер суык. Җәйге төн булса, таң атканчы урамда йөрер идең, кышкы төн кешене сөйми, урамнан бик тиз куып кертә.

Рельслар буйлап атлый торгач, каршыга дежур трамвай килеп чыкты. Йөртүчесе, ялгызлыктан туеп, пассажирлар эзләп йөри мәллә — шундук ишеген ачып тукталды. Уйлап-икеләнеп торырга вакыт юк, салкын дигәнең ашыктыргач, Ансар тимер баскычлардан очып кына менде... Бу кадәр буш урынны күргәне юк иде әле егетнең. Ике вагонлы трамвайга бер пассажиры бар — анысы да кайтыр юлын югалтып гырлап йоклап ята, сәләмә бүреге аяк астына төшкән. Маршрут буйлап тик әйләнсен, дип, йөртүче кыз аны уятмаска тырышадыр, буш йөргәнче, пассажир булыр шунда.

Ансар үзен суыткыч эчендә бикләнеп калган малай-шалай кебек хис итте. Ләкин башка чара юк, вокзал тукталышына җиткәнче түзәргә кирәк. Ә анда җылы... Анда, таң атканчы, рәхәтләнеп черем итеп алырга була.

Төн шул... Вокзалның танырлыгы калмаган. Көндезге мәхшәр сүрелгән, залдагы халык тыныч: килгән-киткән поездларга ис китүче юк, уяулары ярты тавыш белән генә сөйләшә. Көнозын ике аяклы ларек сыман шәһәр буйлап чабып арыган базар хатыннары да, бер күчкә өелеп, сатылмый калган тауарлары өстенә сөялгән килеш йоклап яталар... Аларга ярый, әмма Ансар урындыкка сузылып ятса, башка урынсызлар аны шундук төрткәләп уятырлар иде әле. Их, йокла идең шулар кебек рәхәтләнеп!

Диктор, саташып уянгандай, йокы аралаш кемнәрнедер ниндидер поездга утырырга үгетләп карый. Залдагылар аңа колак салмый, әллә ышанмыйлар, әллә пассажир буласылары килми. Утырып йоклар өчен махсус күнегергә кирәк. Ансарның ул яктан тәҗрибәсе юк. Йокы дигәнең керфекләреннән тотты инде үзен. Муенның баш күтәрерлек хәле юк. Ансарны күргәч, дружинниклар да тыныч кына үтеп китә алмадылар.

— Гражданин, йоклап калмагыз, 111 нче поезд китәр чак җитә, — диделәр алар, яттан шигырь сөйләгәндәй кистереп кенә.

— Поезд?! — Гаҗәпләнүдән бигрәк, Ансар сөенгән иде, чынлап та, ял итәр өчен поезд шәп нәрсә бит, әй! — Рәхмәт, егетләр, әле ярый искә төшердегез.

Ансар кассага йөгерде. Билетны ул күрше шәһәргә кадәр генә алды, биш сәгатьлек юл җитәр, кайтканда тагын биш сәгать үтәр. Барып кайтырга ун сәгать — бу кадәр йокы бәйрәм көннәрне генә тәти ул студент кешегә. Йокысы да әллә ни кыйммәткә төшми, бару-кайтуы белән ярты стипендия хакы. «Русия» кунакханәсендә бер төн уздырган өчен дә өч айлык стипендияңнән колак кагарга кирәк. Йокы иң арзан ризык, димәссең, түбәңне югалтсаң.

Поезд кузгалганчы, Ансарга юешләп төрелгән соры урын-җир китерделәр. Өстәге сәндерәдә тыныч иде. Салкын җәймәгә тән җылысы үтеп керү белән, йокы дигәнең изрәтеп егетне өнсез калдырды. Тик ләззәтле йокыны кыска-кыска төшләр бүлгәләде. Ул төшләрнең үзәгендә гел проводник хатын гына. Студентлар җәйге каникулда төзелешкә кия торган яшькелт-соры куртканы тәненә ябыштырган да әллә кем булып йөри, җаны теләгән кешегә җаны теләгән сүзен әйтә. «Сыер», «йокы чүлмәге», «капчык» дигән сүзләрне аеруча күп куллана. Ансар аңа: «Институтыңны ташлап бик дөрес эшләгәнсең, синнән рәтле педагог чыкмасые!» — дип әйтергә тели теләвен, ләкин уянып китүдән куркып дәшми кала. Ә төш дәвам итә... Менә проводник хатын милиционер ияртеп килгән, сәндерәдә аның башы гына күренеп тора, аяк очына басып үрелә-үрелә Ансарны күзәтә ул, Райнурга охшаган бу милиционер — борыны бөтен битенә җәелгән, калын кашлары бергә тоташкан — күз өстенә мыек чыккан кебек. Имеш, Ансардан сорау алалар.

«Кая киттең?»

«Йокыга».

«Эзләп тапмас дип белдеңме, алдана торган Райнур түгел мин».

«Әйтерием, фуражкаңнан оялам...»

«Иртәгә розыск белән кайтарам».

«Тыныч йокы, сержант Асланов! Ха-ха-ха, хы-хы-хы, хыр-хыр-р-р...»

Төшләрнең дәвамы юмористик пландарак иде... Алары эротик күренешләр белән алышынды. Урыны-урыны белән оятсызрак мизгелләре дә булмады түгел. Тик ул төшләр, уянгач, станция исеменә күз салуга ук, онытылып бетәрләр.

Ун минут чират торырга иренмичә билет алып, Ансар кебек икенче каттагы сәндерәгә менеп ятсаң, икенче ягыңа борылганда, урта яшьләрдәге бер станциягә җителгән булыр. Поезд тәрәзәсенә ябырылып карасаң, бу станциянең ярты гәүдәсе агач авыл, икенче яртысы көймә бүрекле Кукуруз Патша заманында салынган эре панельле — тиз өелешле йортлар тезмәсеннән торган шәһәр икән.

Юлга чыкканда кулың буш булса, рәхәт тә соң! Пәлтәсе белән сарык йонынннан эрләп бәйләнгән баш киемен эләктереп, вагоннан чыкты Ансар. Озак та үтмәде, кайтучы поездга дигән билетын учына кысып, янә сәндерәгә — бу юлысы инде өченче катка ук менеп ятты ул.

Ансарны поезд баскычларындагы бозны вата торган кисәү белән төртеп уяттылар. Өченче катта вагон тәрәзәсе юк, тәбәнәк түшәм генә. Вагон эченең бушап калуыннан чамалап, поездның миллионер шәһәргә кайтып туктаганлыгын абайларга була иде.

Кичәге борчулардан качып, йокы туйдырып йөргән арада, көннең чырае яктырган. Ак эскәтергә йоккан лимон табы кебек кенә кояш беленеп тора, аның түгәрәклеге югалган, чит-читләре тузгыган — тануы кыен. Кояштыр инде, шәт, сөтсел болыт каплаган шәһәр күгендә тагын ни булсын?! Үзәк мәйданга юл күрсәтеп торучы ялангач юкәләрне ап-ак бәс сарган, ерактан караганда, алар ялтыравык кәгазьгә төрелгән ясалма чыршы кебек җемелдәп балкыйлар...

## Тарих сакчысы

Ханкала стенасы тирәсендәге чокырларга калын кар өелгән. Кыш уртасында ул кар, тарих җәрәхәтенә яңа каплаган мамык кебек, ап-ак булып тора.

Җәен-көзен әллә кайдан ук акшарланып балкып торган таш диварлар кышкы аклыкка бик җиңел кушылдылар. Кышын мондагы һәр манара, һәр бина кардан өелгән текә тау төсле, алардан салкынлык бөркелеп торуы да шуннан бугай. Манараларның берсе, «Ханбикә» атлысы, җәй дә, кыш та төсен алыштырмый — гел кызыл төстә. Аны акшарламыйлар, алтынга манмыйлар, тарихны кимсетергә теләмиләр.

Заманында һәр таш кисәге саен гаскәри мәргән беркетелгән Ханкала стенасын бүген берүзе саклый Гадигали агай. Саклый дигәч тә, кулында мылтыгы йә дудуры мазар юк. Йөнтәс бүрекле абзыйларның берсенә корал сорап кергән иде ул. Тыңламадылар.

Юньсез кеше генә утлы корал йөртә, синең кебек изгеләргә беркем тими, диделәр. Корал ул угрыларга халык нәфрәтеннән сакланыр өчен бирелә икән, вәт... Кемнең күпме урлаганын коралына, тән сакчысына, иномаркасына һәм коттеджына карап белеп була, ди. Тән сакчысы — «текә» агайнеләр өчен уйлап табылган заманча «конвой» гына, имеш... Корал ышанып тапшыра алмыйбыз, Ханкалада каравылчы штаты буш түгел, диделәр. Министр абзаңнар эш сәгатен төгәлләп өйләренә таралышкач, монда инде урланыр нәрсәләр калмый бугай.

Гадигали агай элек-электән ханбикәләргә гашыйк. Каравыл киченнән җилләнеп кайтып кергәч, Сөембикә җиңгәгез җылытып куйган кайнар юрган эченә чумасы бар әле аның. Гадигали агайның буш вакыты тарих һавасында үтә, өйдә аяк астында чуалып йөрми. Хезмәт хакы сорап интектермәгәч, күргәнбелгәннәр каршы төшми.

Һәр тәрбияле гражданинның ике эше булырга тиеш: берсе, әлбәттә, акчага әйләнә торганы, ә икенчесе бушлай гына — җәмәгать эше, диләр аны. Беренче эш мәсьәләсенә килгәндә, Гадигали агай хезмәт срогын тиешенчә «тутырган» пенсионер, сугыштан соң ул кырык ел буе уналтынчы завод капкасында каравылчы булып утырды. Әлеге икенчесе — җәмәгать тәртибендә тарих сакчысы булып йөрүе. Дөрес, баштагы мәлдә ул пенсия кенәгәсенә кимсенеп, акча түли алырдай бер оешмага тагын каравылчы булып урнашып караган иде, балавыздан ясалма умарта кәрәзләре эшләү заводына. Бик тынгысыз җиргә эләкте. Янәшәдә генә шәраб заводы ис куа, аның тирәсендә, төне буе ач күселәр төсле, ирләр йөгерешә. Стакан мазар яки кабарга берәр сынык ипи сорап туктаусыз капка дөбердәтәләр. Иртәнге якта ишекләрдәге йозакка чәпәлгән балавыз пломбаларның исәнлеген тикшереп журналга кул куясың да күрше шәраб заводыннан йөзеңне яшереп кайтып китәсең... Ә беркөнне, йозак өстенә исерек чыпчык кунып, йозактагы балавызны чукыган... Шуннан китте ревизия ясаулар... Урларлык әйберсе булса иде, ичмасам, складлары тулы иске балавыз да сумала!

Өйгә кайткач, Сөембикә җанашы тиргәде соң үзен: пенсияңне әзсенеп завод капкасыннан чыпчыклар куып йөрүе ничу!.. Әнә, вакытыңны кая куярга белмәсәң, тарихны каравылла, дип, бушлай эшләү урынын әйтеп тә бирде.

Баштагы мәлне Ханкала тирәсендә борчулы уйлар белән йөрде Гадигали агай, кызыл манарасы ава башлаган, дип, үзәккә үтteләр. Көне-төне белән өенә кайтмыйча манара саклап кунган чаклары да булды абзагызның, ауганын күреп калыр өчен түгел, күңеленнән генә әллә нинди терәүләр куярга планнар корды. Яшәсен иде әле ул. Борынгыдан калган хәзинә ләса. Кирәксенмәсәләр, чит илдән килгән туристлар сырып алмаслар иде аны. Ханымнар алдында кылтайган сыман, фотоаппаратларын аркылы-торкылы тотып, фотога төшерәләр, нигезен колачлап үлчиләр, гидлары күрмәгән арада, кирпечләрен кырып карыйлар, иснәп тә китәләр... Бүгенге төзүчеләребез салдырган, эченә керсәң чыгасы килмәслек мәһабәт йортлар, сарайлар бар... Юк, туристларга тарихны давай! Инде тарих серләренә төшенәбез дип, Ханкала стенасының казылмаган төшен калдырмадылар. Актаралар гына тарихны... Түзә ул тарих. Ханбикә манарасы да түзә. Аумаячак ул, нигез өлешенә кыйгач скважиналар бораулап, бетон измә тутырып ныгыттылар аны.

Кояш шәһәр өстеннән китеп көнбатышка авышкач, чиркәүләрнең арзанлы алтын ягылган гөмбәзләре яктырып кала. Кояш баешының кызыл нурлары, аларның бәясен күтәргәндәй, борынгы алтын төсенә кертә, вакытлыча гына...

Ак диварлар буйлап бер әйләнеш ясап, бер мең җиде йөз илле адым юл үтә дә Гадигали агай, археологлар җәйдән үк казып калдырган тирән эчле сандык сыман шакмаклы чокырлар янында туктап кала. Кар өсте шул килеш — димәк, тыныч! Кеше килмәгән, казымаган. Бу сандыкларда әллә нинди табылмаган хәзинәләр ятадыр әле. Сизмичәрәк калсаң, кибет баскан кебек кенә итәрләр. Кремль стенасының нигезенә көрәк төрткән саен, хәзинә ияреп чыга. Кая җыялар ул табылдыкларны, кемнәр хуҗа аларга хәзер, исәбе алынамы? Димәк, тарихка каравылчы кирәк. Әле дә инде, моңарчы начар каравыллаганнар. Әнә урта гасырларда манаралар саны унөч булган, диләр. Бүгенгесе көнгә сигезе генә исән калган. Адәм рәтлерәк саклардай каравылчысы табылмаган, күрәсең. Гадигали ага килеп җитү белән иң әүвәл манараларны санап чыга... Ике башлы бөркет күргәнче, сигез манаралы Хан Шагыйрь мәчетен күтәреп өлгерерләрме?..

## Кемлегеңне белеп йөр...

Ашыкма син...

Ашыксаң, бөтен нәрсә үчегер үзеңә.

Әгәр йокы поезды бер сәгатькә соңарып килмәгән булса, әгәр туксан тугызынчы шәһәр поездыннан төшкән пассажирларны каршылаучылар, арба-чаналар сөйрәп, перронны каплап алмаса, әгәр тукталыштагы саилче агайның уч төбенә салырга хәер эзләп вакыт әрәм итмәсә, әгәр трамвай көтмичә уку йортына чаклы җәяү генә килгән булса, әгәр унсигез катлы корпусның өч лифты да, җирнең тарту көчен җиңәлмичә, беренче катта ук туктап калмаган булса... Ансар икенче лекциягә өлгерә ала иде әле.

Ул соңгы лекциягә генә килеп җитте.

Егетне гаҗәпкә калдырганы шул: курсташ дуслары аны көлешә-көлешә каршы алдылар. Хәтта бүген иртәнге җидедән бирле елмаеп карамаган педагог — кафедра мөдире дә студентларына хас эчкерсезлек белән елмаеп азапланды һәм, елмаюын сакларга тырышып, криминалистика өлкәсендәге яңа техник казанышлар турындагы плакаттан аерылгач, кулындагы эбонит таягын Ансарга төбәде.

— Сезнең каршыда сирәк очрый торган, әмма типик күренеш. Районның эчке эшләр бүлеге хәбәр итүенә караганда, Ансар Субаев гафу ителмәслек җинаять эшләгән. Менә-менә диплом алам дип торганда, булачак юрист кеше дәүләт милкенә кул сузган. Алибиең бармы, Субаев?

— Юк.

— Алиби юк. Ишеттегезме, бернинди дә алибие юк! Иптәшләренең ышанычы гына бар. Алар Субаевны гөнаһсыз, самими һәм вөҗданлы егет, дип, теләсә кемгә расларга әзер торалар. Гражданин Субаев, гаебеңне таныйсыңмы?

— Юк гаепне ничек танымак кирәк?! Хуҗа Насретдин мәзәгендәге хәл бу. Бау урлап кына харап булдым, дигән Хуҗа, бауның икенче башына сыер бәйләнгәндер дип кем уйлаган... Мин дә шулай, бау гына тарткан идем, ярты капчык бүрек килеп төште. Ант әгәр, һич гаебем юк.

— Эчке эшләр бүлеге мөһерле кәгазь җибәрсә, синең антыңнан көчлерәк булыр, шулай бит, Субаев?

— Әйе. Ләкин... Шуңа карамастан... ничектер... белмим... кыскасы, гаебем юк.

— Җинаять өстендә тотылуың фактмы?

— Анысы чынлап та факт кебек килеп чыга...

— Димәк, үзеңне акларлык дәлилләрең юк. Гаебеңне танырга туры килә. Башка чара калмый.

— Бар. Чара бар!!!

— Нинди?

— Мин чын каракларны үзем эзләп табарга тиеш!

— Менә бу фикереңдә яшь юрист авазы бар! Диплом эшеңнең темасын үзгәртәбез. Әгәр практикаң беткәнче үз-үзеңне шушы адәм көлкесеннән йолып ала алсаң, диплом эшеңә бишле дип исәплә. Инде каракларны тотып китермәсәң... ул чагында синең эшеңне башкалар яклар...

— Бик дөрес.

— Диплом эшеңнең җитәкчесе булып үзем калам. Ә хәзер бар, утыр, — диде кафедра мөдире, эбонит таягы белән буш партага таба юл күрсәтеп.

Кафедра мөдире үзенең мәртәбәсе белән теләсә кайсы районның халык судьясына «син» дип кенә дәшә алырлык кеше. Шуңа күрә аның «утыр!» дигән сүзеннән аерым мәгънә эзләп, студент егетләр дәррәү күтәрелеп көлешеп алдылар.

Ансар, дәресләр бетүгә, студентлар арасыннан кинәт юкка чыкты — иярмәүләре хәерлерәк, киңәшләреннән туйган. Әгәр алар сүзенә колак салсаң, алар уйлап чыгарган версияләр буенча эзләнергә тотынсаң — бу инде диплом эшен күрше партада утыручы дустыңнан күчереп алу белән бер. Ансарга әйтеп торучы кирәкми.

Кичке аш вакыты.

Бензин имәргә дип, колонкалар тирәсенә машиналар тезелешеп яткан... Эш сәгатеннән котылган хатыннар, сумка күтәреп, базар санап йөриләр. Халыкның кышлаудан чыккан чагы, кайда яшел үлән күрсә, шунда барып ябырылырга әзер тора. Яшелчә кибетенә кергәннәре беләкләренә кыярга охшаган озынча яшел «уклау» салып чыга. Алар арасында салат яфраклары да күренә. Ниһаять, кибетләргә яшел төс керде, авитаминозга каршы көрәш башланды. Кибет янында башы белән капчыкка чумган ат та, солысын ялмарга онытып, кыяр күтәргән хатыннарга ияреп китәргә тора. Аяклар үзләреннән-үзләре «Чәй йорты» ягына атлады, әйтерсең лә шул тирәдә Ансарны Венера эзләп йөри...

Өчпочмак буына килеп кергәч, бөтен мәшәкатьләр онытылды. Кайнар өчпочмак — ит әйбере талонлап бүленгән чорларда да исән калып сокландырган тәгам, шәһәрнең милли горурлыгы!..

Өчпочмак чираты тиз үтә, чөнки сайлана торган товар түгел, микродулкынлы мичтә җылынып өлгергәнен эләктерәсең дә рәхмәтеңне әйтәсең.

Кеше тикшерү дигән алама чир чиратларда яралган булса кирәк. Ак калфаклы ханым, алтын-көмеш балдаклардан салмакланган симез бармаклары белән вак акча санап тилмерә. Чиратның тиз узуы аның акча санау тизлегенә бәйле. Чираттагылар эш юктан гына бер-берсен күзәтә башлый. Һәр профессия кешесе күршесен үзенчә күрә, үзенчә бәяли. Әйтик, чираттагыларның берсе «Руслан» ательесында тегүче ди. Ул өчпочмак сорап тезелгән сафның кием-салымын күздән кичерә дә чыраен сытып читкә борыла йә бөтенләй китеп үк бара; лавкә тирәсендәге идәнне таптап биеп торган читекләрне барлап торучысы — аяк киемнәре берләшмәсенең фирменный кибетендәге дизайнердыр; бу чиратка чәч кистерүчеләр дә элэгэдер — тузгыган чәчләрегезне яшерегез; чиратсыз кергәннәрнең якасына ябышырдай булып, педагог карап тора; тимер акча санаучы бармакларның шулпалы өчпочмакка батып керүен врач абзаң түзеп карап тора алмый — теге «Руслан» тегүчесенә ияреп китеп бара.

Ансар чиратның «койрыгына» китереп басты һәм, әлбәттә, чират ялт итеп аңа текәлде. Үз нәүбәтендә Ансар да алдагы кешеләрне гражданлык һәм җинаять кодексы статьяларына сыйдырып карады. Чиратта күпме кеше бар — һәммәсенә өлеш тия, һәркемнең үз статьясы. Ник дигәндә, закон күзлегеннән карасаң, бу фани дөньяның һәр фигыле, һәр сыйфаты, эзләнү-табышлары, ачыш-югалтулары, сөенечкөенечләре һәм барча-барча вак-төякләре, билгеле бер рәвешкә туры китереп, кодекслаштырылган... һәм кешенең бөтен тормышы статьяларга таркатылган. Кодекс-статьялар синең бәхетеңне бөтен килеш сакларга тиеш.

Чират койрыгы Ансардан соң да сузылды. Янәшәгә туры килгән күзлексез агай кай ягы беләндер игътибарны үзенә җәлеп итеп тора, күз карашларының танышлыгы белән, ахры. Бер ноктага төбәлсә, ул шул ноктада бик күп нәрсәләрне күрә бугай, карашының җитдилеге, уйларының ераклыгы белән шулай тоела.

Ансар, кайнар өчпочмакны кулдан-кулга күчереп, үзе дә сизмәстән күзлексез агайга иярде. Бер аягына катырак баса икән — атлаган саен, сай чокырга туры килгәндәй, чүгеп-чүгеп ала. Максатлы кешегә охшаган, юкка-барга игътибар итеп тормый — алга карап туп-туры һәм тиз атлый. Шигырь ятлаган мәктәп баласы шикелле авыз эченнән сөйләнә үзе. Ансар эндәшмичә түзмәде, чөнки таныды ул аны. Соң, әлбәттә, бу бит теге шаһитларны агач мылтык белән куып тоткан Гадигали агай.

— Гадигали агай, сезнең берәр хәсрәтегез бар мәллә?

— Дөньяда хәсрәтсез кеше — шамакай гына. Минем яшькә җиткәнче хәзер үк бер нәрсәне аңлап куй — кеше сабый чактан ук үзен каравылчы итеп тоярга тиеш. Кая карама — байлык...

— Нинди байлык, Гадигали агай?

— Син үзеңне кем дидең әле? — Гадигали колакка катырак бугай, теге сорауны ишетмәде.

— Ансар атлы мин, студент...

— Шулай... Көндез пенсиядә, кичен җил куам... Сугышып йөргән өчен пенсия түлиләр. Биш ел сугыштым, һичнинди пуля тимәде. Буй кечкенә булгач, исән калдым. Озын егетләрне снайпер чүпләп бетерде. Җиңеп кайтучылар арасында калкулары бик сирәк. Иртәгә җиңәбез дигәндә генә яныма снаряд төшеп, шушы аягымны йөз дә сиксән градуска — кайту ягына таба борып куйды. Врачлар бик нык изаландылар. Баштарак бик борчылганыем, мәйтәм, бер аягым алга, бер аягым артка таба йөри торган булып калса, нишләрмен?

Гадигали агайга хөрмәт йөзеннән нindидер җылы сүз әйтәсе килде Ансарның.

— Алайса, сез әле заманында Җир шарын исән-имин саклап калгансыз икән?! — Бу юлысы Ансар ишетелерлек итеп дәште.

— Әйе, энем, Җир шарына һаман каравылчылар кирәк, олы каравылчылар...

Ансар Гадигали агайны калдырып китәргә ашыкмады, дөресен генә әйткәндә, ашыгыр урыны юк иде аның. Бүген кайдагы мендәргә баш куясын белгән юк әле. Курсташ егетләр янына елышырга туры килерме, әллә тагын поездга утырып, тәгәрмәчле «кунакханә» көненә калырмы?!

— Әгәр мең дә җиде йөз илле адым атларга иренмәсәң, ак диварлар тирәли бер әйләнеп киләбез, кем, энем?!

— Ансар мин, Гадигали агай... Сез мине беләсез, ярты капчык бүрекне хәтерләсәгез...

— Ә-ә... Син шаһитларның берсемени?
— Юк шул...
— Алай укмыни?! Каз ауларга чыккан төлке шәһәргә керми, монда таш арасында нишләп йөрисең, бар «Каракүл»еңә.
— Уйланып йөрим, Гадигали агай, чын каракларны ничек тотарга микән, дим.
— Алай укмыни?! Әйтәм җирле андыйга охшамагансың үзең.
Байлыкка табынып яшәүче, хөсетле һәм эчкерле кешеләр бер кул белән генә күрешергә тырышыр — икенче кулын кесәсеннән чыгармас. Күрешү — холык көзгесе. Бирәү — ришвәт биргән шәе генә кул суза; йөрәксез һәм кансыз кешеләр авырттырып кысарга тырыша; гамьсез кеше гүя биш салкын сөяк тоттыра. Ярлы куштан — билен бөгеп, бай куштан аркадан сөеп күрешер. Гадигали кушучлап күреште, ләкин колакка катырак кеше булганга, башлаган сүзен бетермичә, Ансарның кулын җибәрми торды.
— Әгәр каракларны тота алмасам... Фатирдан кудылар, инде университеттан да куарлар...
— Алама хозяйкага туры килгәнсеңдер, юкса аңлар иде.
— Кеше гаепләп торасы юк, үзем гаепле...
— Юньсез кеше бервакытта да мин юньсез, дип әйтә алмый, димәк, ничава егеттер син. Әйдә, безгә кайтабыз, Сөембикә җиңгән дә сөенер. Тик берүк минем урамда өчпочмак алып ашаганны җиткерә күрмә. Юкса миңа көн бетә. Гомер бакый яшәп шулпалы өчпочмак пешерергә өйрәнә алмады, бахыр...

## «Йолдызлар арасында...»

Әгәр самолет тәрәзәсеннән башыңны тыгып карарга рөхсәт итсәләр, өстәл-өстәл сыман тезелеп яткан түбәләрне генә күрерсез. Бөтен шәһәр: завод-фабрикалары, мәктәп-бакчалары, барча кешеләре түбә астында. Һәр түбәнең каравылчысы, бәлки, вахтеры яки лифтеры бар. Алар үзләренә беркетелгән түбәнең иминлеген саклыйлар.

Гадигали агайларга күчеп яши башлагач, Ансар ныклы бер карарга килде: диплом практикасы чорында төнге каравылчы булып эшкә урнашырга, кемлегеңне сиздермичә генә «Каракүл» берләшмәсенең эчен-тышын яхшылап өйрәнергә...

Уку йортыннан бирелгән белешмә дүрт почмаклы кәгазьгә язылса да, каравылчылар начальнигы аны әйләндереп-әйләндереп укыды, мөһере түгәрәк иде, шуңадыр инде. Бу оешманың йорты Эчке эшләр бүлеге бинасына өстәп салынган. Чөнки әлеге оешмаларның әти-әниләре бертуган. Җитәкчеләре дә бертөрле киенә — бөтенесе фуражкалы, погоннарына йолдызлар сибелгән.

Каравылчылар начальнигының өч йолдызы бар — өчесе дә олы-олы булып бүрткән. Урынбасары — чырае белән начальниктан олырак булып күренсә дә, погонында бер йолдыз кимрәк. Замполитка бер зур йолдыз эләккән. Йортның кысан булуы сәбәпле, бөтен җитәкчеләр бер бүлмәдә. Шуңа күрә Ансар йолдызлар арасында иде.

Белешмә, кулдан-кулга күчеп, замполит кулына барып җитте.
— Төнлә сакта торулар шүрләтмәсме?
— Студентның куркырлыгы юк, байлыгы күп кеше генә куркак була, — дип рас җавап кайтарды Ансар.
— Алайса, милиционерларның нидән батыр икәнен аңлыйсың инде. Окладың күпме булачагын чамалыйсыңмы?
— Студент кешегә җитә.
— Ә безгә каравылчылар кирәкне каян белдең?
— Күңелем сизде. Яхшы каравылчылар гел кирәк.
Ансарның бу сүзләреннән соң тәрәзәдән төшкән кояш нурында йолдызлар җемелдәште.
— Студент та студент, дисең... Әгәр студент булмасаң, без синең белән сөйләшеп тә тормас идек. Каравылда йоклап ятырга студент белән пенсионердан гайреләрне алмыйбыз... Бер төн эшләп, ике төн ял итәсе, дигәч, буш вакыт ярата торган гайрәтле ирләр күп урнашты инде безгә. Сакка куйгач, графиклары үзгәрде — бер ел эшлиләр, ике елга утыралар... Мин сине резерв бригадасына кушам. Вазифаң бик гади. Кичке алтыга өлкән дежурный янына җыеласы. Кайсы объектта пост ачык кала — шунда илтеп куярлар. Аңлашылдымы?
— Без, студентлар, күп нәрсәне соңрак аңлыйбыз...

Ансарның беренче эш төненә ничек әзерләнгәнен чамалар өчен сабантуй мәйданына җиңү алып кайтып килүче чаптарны күз алдына китерү җитә. Көне буе теләктә йөрде ул. «Каракүл» мехчыларының берәр каравылчысы эшенә чыкмый калса иде; балыкка киткән җиреннән табышлырак урынга эләксен; сәгатьләре туктасын; оныкларын куяр өчен урын тапмыйча, өеннән чыга алмыйча ятсын; берәр маҗаралы вакыйгага тап булып, көнен шаһитлыкта үткәрсен, һич югы, күршесенең «Лотто-миллионга» акча отканлыгы турында хәбәр ишетеп, эчүгә сабышсын... тик графигы буенча каравылга эшкә чыкмасын!.. Аннан каравылчылар оешмасына өлкән бригадирдан хәбәр килсен: «103 нче пост ачык. Резерв җибәрүегезне сорыйм...» Һәм Ансарны, төн чыкканчы сакларга дип, «Каракүл» берләшмәсенә куярлар.

Кулындагы көмеш сәгате ике минутка бер генә кыймылдый төсле тоелды Ансарга, еш караганга, еш тыңлагангамы, акрын йөри кебек... Билгеләнгән вакыттан йөз егерме минут алдан эшкә килгән студентны күреп, өлкән дежурный күкрәгендәге медальләрен челтерәтеп көлеп куйды.

— Беренче вахтаңны матур көндә башлыйсың. Иртәгә получка биреләсе, шуңа күрә эшкә чыкмый калган каравылчылар булмас. Иртәгә акча аласы дигәндә, прогульщиклар юк ул бездә... Сиңа бүген минем белән контор саклап кына утырырга туры килер. Борчылма, монда күңелсез түгел... Әйдә, йокы чүлмәге, танышыйк, мин Язит абыең булам.

— Мин Ансар, Субаев.

— Көндезен укып, кичен эшләргә дисең инде... Ә берәүләр, киресенчә, көндез эшли, кичен укый. Тик шунысы бар: көндез эшләгән кеше кичен авыр укый, көндез укыган кеше кичен начар эшли, ягъни йоклый.

— Замполитыгыз шундыйрак фикер әйткән иде инде.

— Хакыйкатьне беләбез.

— Белә торып биш йөз каравылчыны йоклатып яткырасызмы?

— Уятып йөрер өчен махсус «проверящийлар» бар. Тик менә биш йөз постны йөреп чыгар өчен аларга бер төн генә җитми.

— Язит абый, үзегез дә йокы аралаш эшлисездер әле?!

— Мин көндез укымыйм, постымда уяу торырга тиешле кеше, — дип әйтүе булды Язит абыйның, шуннан тотынды телефон чәрелдәргә...

«Алло, Язит абый, бишенче бригада әле бу. Посттагыларның фамилияләрен язып алыгыз. Прогульщиклар юк!»

«Алло! Отдел! Егерменче бригаданың рапортын язып куегыз: прогульщиклар юк!»

«Алло! Телефоныгыз гел «занято», көчкә туры китердем. Постлар ябык. Ниме, Язит абый, иртәгә получка булыр микән?»

Ул арада өстәлдәге бәләкәй тартмадан оператор кызның куркынган тавышы ишетелде.

— Язит Язилевич, бишенче супермаркетның контроль уты кабынды, пультка куйганнарына ярты гына сәгать иде әле!

Язит Язилевич кулындагы телефон трубкасын күкрәк кесәсенә тыкты да селекторга үрелде.

— «259»... «259»... «259»... элемтәгә керегез.

— «Волга»... «Волга»... Мин «259». Ни булды?

— Тиз генә бишенче объектны тикшерегез. Әгәр реле-фәләне эшләмәсә, электрик килгәнче шул тирәдән китмәгез. Аңладыгызмы?

— Әйе!

«259» нчы номерлы МПГ (милициянең патруль группасы): «Кибетне пультка тапшырдык, директоры өй ачкычларын онытып калдырган, шуңа ачып кергән, инде бар да тыныч», — дип рапорт биргәндә, Ансарның көмеш сәгате белән ун минутлап кына вакыт үткән иде әле.

Ниһаять, бригадирлар шылтыратудан туктап, кадерле объектлар пультка куелып беткәч, дежурный бүлмәсендә кыска гомерле тынлык урнашты. Язит Язилевич, зур кулъяулыгын куш учына җәеп, маңгай тирен сөртте. Аш ташый торган олы термосны авыштырып, ике стакан чәй агызды.

— Әйдә, студент, сугарылыйк, чәй икебезгә дә җитәрлек. Хәзер тирләп-пешеп оперативниклар кайтып җитәр. Чәйне алар өчен дип күп йөртәм.

«Каракүл» капкасына сакка куярлар әле, дигән өмет мае беткән шәм кебек сүнде. Бүген Ансар артык солдат булып резервта ята. Өметсезлектән йокы басты, хәтта Язит Язилевичның мәтрүшкәле каты чәе дә ул төшенкелек халәтен куып тарата алмады. Ансар, эч пошканнан гына кызыл почмакка кереп, президиум өстәленә менеп яткан иде, ялгыш йокыга китте...

Авыл җирендә әхлакый кодекска әверелгән ырымнар бар. Әйтик, бусагага утырырга ярамый, мал чалган урынга төкермә, өй эчендә сызгырма, зираттан җиләк өзмә, чүплеккә икмәк ташлама, кош оясына тимә, мунчада йоклама ише нәсихәтләрне бозсаң, зур гөнаһ булачак икән. Әлбәттә, «гөнаһ» сүзен балалар «зыян киләчәк» дип аңларга тиешләр. Президиум өстәленә менеп ятма, сәяси төшләр саташтырыр, дигән юрамышлы ырымны белми иде әле Ансар. Психиатрларның раславынча, төш — өндәге уйларның дәвамы, әйтергә кыймыйча йөргән сүзләрнең яңгырашы, чынга ашмый калган хыялларның гәүдәләнүе һәм курку хисенең йөгәннән ычкынуы икән... Менә безнең Ансар, җыелыш саен дәрәҗәле йодрыклар белән төелгән кызыл постаулы президиум өстәленә чалкан ятып, үзе яшәгән шәһәрнең Баш бүреге белән сөйләшә...

«Бер миллион карак төрмәдә утыра, ә җинаять кимеми, киресенчә арта гына. Милиция гаеплеләрне конвейердан бушатып өлгерә алмый, судтагы эшләр әрдәнәләп өелгән, адвокатларга чират. Юрфакта бер урынга йөз абитуриент килә. Илгә тимер ишекләр җиткереп булмый, йозак бизнесы чәчәк ата. Сез, йөнтәс бүреклеләр, җавап бирергә уйлыйсызмы?»

«Син чәпчемә, җинаять ул — базар вирусы. Бәяләр арткан саен, җинаять артачак, чөнки урлаган кешенең дә чыгымнары арта».

«Сез шулар яклы. Хәрәм байлыклары кесәгә сыйсын өчен, акчаларның нульләрен кистегез, ришвәт биргәндә долларлар сыйсын өчен, конвертларны озынайттыгыз, яшерен маллар сыйсын өчен, банкларны күбәйттегез...»

«Кесәңә күпләп акча кергәч, фәлсәфәң үзгәрер әле. Базар ул — акча өчен яшәү. Бөтен эшне акча гына эшли ала. Акча ул — тәрбияче, акча — җиңүче, акча — азатлык, акча — яшьлек, акча — акыл...»

«Алайса, сезнең акылыгыз — кесәгездәме?!»

«Безне сайлап куйдылар».

«Сайлау — урлаучыларның урыннарын алыштыру гына түгел микән? Нократ ярында тотылса, Сез аларны министрлыкка куясыз, министрлыкта азынгач, Чулман аръягына Хан итеп җибәрәсез. Шуңа күрә мандат өчен көрәш саклану өчен көрәш баталиясенә әверелә...»

«Әй студент, ярлы белән бай бәхәсләшә алмый. Синең алда акланырга җыенмыйм. Шуны бел — Яңа йортка күчкәндә, иске нигездә чүп-чар өелеп кала. Син белгән нәрсәләр әнә шул социализм нигезендә өелеп калган чүп-чарлар гына. Якты киләчәккә барып җиткәч, ул чүп-чарлардан котылырбыз».

«Русияне караклык эпидемиясеннән дәваламыйча торып, якты киләчәккә чыгу мөмкин түгел! Караклык сүзенең синонимнары бик күп: урлау, талау, хосусыйлаштыру, мәхрүм итү, үзләштерү, дефолт ясау, рөхсәтсез алу, ришвәт бирү, сугыш ачу, илләрне яулау... Бөтен җинаятьнең нигезендә караклык ята!..»

«Сугыш ачу — илләрне урлау дип әйтергә телисеңме?»

«Әлбәттә! Һәм ул ил өстендә сугышып, Империя казнасыннан күпме акча талана! Безне сугышлар белән таласыннар өчен без үзебез налог түлибез! Чит илләр котыла алмаган бүгенге караңгылыкны без үзебезгә якты киләчәк итеп куярга тиешме?»

«Студент! Акыллы сүз тиз туйдыра! Югал күземнән!..»

Ансар шабыр тиргә батып уянып китте. Төшендәге әңгәмәдән соң гәүдәсе авырайган иде аның. Ләкин, студентларча уяулык белән, үзенең эш урынында икәнлеген абайлап, ул тиз генә президиум өстәленнән төште. Талымсыз йокысы белән көрәшеп йөргән арада, бишенче супермаркеттан тагын хәбәр килгән булган.

Өченче тапкыр хәбәр алгач, оператор кыз Язит Язилевич янына үзе йөгереп керде:

— Тагын бишенче... Контролька кабынды.

Селектордан диалоглар чәчелде.

— «259», кай тирәдә сез хәзер?!

— Отделга җитәбез. Капкабыз күренә инде.

— Срочно борылыгыз. Бишенче маркетка! Никтер тагын шылтырады.

— Теге директор түгел микән... Кунарга урыным юк, дигән иде. Бәлки, борчып тормабыз?!

— Бернинди ни-ни! Кибет гостиница түгел ул! Ишетсен колагыгыз! Хәзер үк объектка китегез! Хәбәрләшеп торыгыз!

— «Волга», «Волга»! Мин «259». Бишенче суперны басканнар. Тәрәзәсен ватып кергәннәр. Берсен эләктердек. Икесе качты. Куып киттек.

— «259»!!! Объектның иминлеге өчен без җавап бирәбез. Берсе эләккәч, калганнары тотылыр. Кибет яныннан китмәгез!

— Ватык тәрәзә саклап төн чыгаргамыни инде?

— Мин сезгә резерв каравылчымны җибәрәм.

— Минме? Язит абый?! — дип гаҗәпләнде Ансар. Дөресен генә әйткәндә, аның өлкән дежурныйдан «юк!» сүзе ишетәсе килгән иде.

— Әйе, Субаев. Такси илтеп куяр үзеңне.

— Шаярталардыр әле, директоры ачкандыр да...

— Юк инде, студент иптәш! Эфирдан ялган сөйләшергә ярамый. Безнең сөйләшү шәһәрнең бөтен постларында ишетелеп тора. Менә хәзер проверяющий дәдәң килеп җитәр.

— Барыбер ялган «тревога» бу. Бер сәгать эчендә бер җирдән өч хәбәр килсен дә, ышан, имеш...

— Практикада әлләниләр бар, Субаев. Әйтик, әлеге кибет ишеге яңагындагы кыңгырау күрше урамнарга ишетелерлек итеп ике тапкыр чыңлады ди. Ике тапкырында да милиция килде, ә ЧП дигән нәрсә юк. Димәк, кыңгырау өченче тапкыр чыңласа, милиция әүвәлге кебек чатыр чабып килми дигән сүз. Урларга ниятләнгән кешегә шул гына кирәк тә: тәрәзәне вата, кыңгырау чыңлый башлый, милиция ашыкмый, шул арада кибетне чистартып та өлгерәләр... Ә син, Субаев, ышанмыйм, дисең. Бер объект төн чыкканчы ун тапкыр «тревога» күтәрсә, егетләрне ун тапкыр җибәрәчәкмен!..

Ансарны ватык тәрәзә янындагы йомшак кар өстенә бастырып куйгач, экипаж аңа хәерле төн теләде:

— Студент! Әбиеңә сәлам әйтикме, бәлки, тун китерер?!

## Каравылчыны кем саклый?

Беренче эш төне Ансар теләгәнчә килеп чыкмады. Бәлки, бүген, икенче төнендә юл уңар?! «Каракүл» капкасына өстәмә сакчы итеп куярлармы, тагын бөтенләй башка объектка җибәрерләрме? Сабырлыкны йолыккалап диплом практикасының санаулы көннәре үтә.

Язит Язилевич Ансарны ишектән керә-керешли үк эшкә кодалый башлады.

— Получкадан соң дөньяның асты өскә килә. Бүген резервны төткәр генә. Кая телисең — шунда җибәрәм! «Росбакалея» базасына кеше кирәк, буладыр бер. «Коопторг» складында урын бар — ике. Алты винзаводның өчесе каравылчы сорап «каравыл!» кычкыра — өч!.. Кәрәз эшләү заводы—дүрт. Мебельләр эшләү фабрикасы икенче капкага кеше сорый, менә сиңа биш. Промбаза ягындагы гаражга, галантерея әйберләре базасына, «Исле гөл» фабрикасына... кыскасы, санап бетергесез. Ә синең кебек запас егетләрем өчәү генә. Шуннан чамала инде калганын.

— Өч постка безне куярсыз куюын, ә калганнары нишли?

— Нишләсен, тора шул килеш. Каравылчылары юкны белмәсәләр, тора... Капка биек, йозак зур, эт өрә.

Мин үзем рядовой каравылчы чагымда Идел ярындагы причалда төзелеш материаллары саклап кунгалый идем. Навигация ачылуга, дәү-дәү баржалар яр читенә Себер наратларын китереп аудара, саны-хисабы юк, тау-тау өелә. Шунда ук аның тактасын ярдыралар, идән-түшәмлек итәләр, ишекләр, тәрәзә рамнары ясап, төрле төзелеш оешмаларына озаталар. Идел ярында көндез тыныч. Ә менә төнлә, җитмәсә, берьялгызың калгач... моторлы көймәләр «һөҗүм» итә башлый. Йөзеп киләләр дә әрдәнәдән ике-өч наратны бау белән тагып алып китәләр. Мин бит инде аларның артларыннан су өсләтеп куып йөри алмыйм. Яр читенә басып, Идел өстенә йодрык селкеп озатып калам. Анысы ярый, Себер наратының бетәсе юк, тик урласыннар... Мәгәр эшкәртелгән, юнылган, читләтелгән тактаaларны саклый алмасаң, эш харап! Сакта торам шулай бервакыт. Утыз кубометр юнылган юка тактаны өеп, өстеннән яшел буяу белән сызып тамгалаганнар, яшел пута бәйләгән төсле. Күчтәге берәр тактаны суырып алсаң, буяулы пута өзелә дә иртән смена алышынганда ревизия ясарга туры килә. Каравылчының айлык хезмәт хакы шул тактаның кубометрын түләргә дә җитми. Такталар өстенә менеп утырдым, мин сиңа әйтим, кулга ботаклы такта башын кысып тоттым — корал, янәсе. Таң атканчы Идел өстен күзәттем. Белмим, кай арада гына күз йомылгандыр, уянсам — йа Раббым, ун тактадан җилләр искән. Ничек үземне күтәреп китмәгәннәр?! Коелдым да төштем, такта күче белән... Ярый әле, иртән алмашка килүче каравылчы хәлемә керде, әллә кайдан гына банкылы яшел буяу табып, яңа такталар өстенә сызды да куйды. Борчылма, ди бу мине юатып, мал югалган саен кесәгә тыгыла башласаң, каравылчыга гел бушлай эшләп йөрергә кала, пенсияң дә, стипендияң дә кулыңа эләкмәс, ди... Менә шулай, Ансар туганым. Вәт. Менә шулай итеп мин сине яңа урынга әзерләдем... Кайсы объектка барасым килә дисең әле? Росбакалеягамы, базагамы, причалгамы?

— «Каракүл» берләшмәсенә җибәрсәгез иде, Язит Язилевич.

— Бара тор!

Язит Язилевич үртәгән сыманрак итеп елмаеп калды, ни хикмәттер, элеккеге студентлар, тире исеннән җирәнеп, «Каракүл»гә бармас өчен җан талашалар иде, ә бу егет үзе үк ашкынып тора.

Кич әллә нинди бүген, кояшы бар — җылытмый, болыты күренми — зимагур кар бөртекләре очып йөри. Язгы җилләрне сизенгән тупыллар кай якка авышырга белмичә аптырап торалар... Бәйдәге этләр өй тирәсенә килгән бәйсез этләргә өреп кала.

Җәяүле бураннан бераз гына өстәрәк, каршы яктан тагын бер җил исә — анысы, чана шуасыны китереп, кызыктырып торган карлы түбәләрне себереп йөри. Аяк асты ялтыравык боз гына — машиналар, егылам-егылам дигәндәй, таеп-таеп китә. Яз исе сөт комбинатына йортка кергән солидол заводы исе белән алышына, ул да булмый, РТИ заводыннан ияреп килгән кыздырылган каеш исен яңа кыркылудан чыккан сарык көтүе исе күмеп китә. Димәк, «Каракүл» берләшмәсе ерак түгел.

Ансар яшел таш коймага җиткәч, теге капчыклы бау эленеп торган урында тукталмакчы иде, тыелып калды. Йә тагын Райнур сагалап йөридер. Сизмәве хәерлерәк.

Каравылчы кенәгәсендәге фото кисәген чын йөзе белән янәшә куеп карагач кына якты чырай күрсәттеләр Ансарга, юкса каравыл начальнигы бик кырыс кешегә охшаган.

— Ярыйсы, — диде ул, Ансарның иңбашына сугып, — безгә бергәләп сакта торасы. Икенче смена бетеп өченчеләре кергәндә, эш кызулана. Чамалыйсыңдыр инде, цехлардан чыккан берсен тикшереп калырга кирәк.

— Тентепме?

— Һушлы егет икәнсең... Әйдә, кунак бүлмәсе белән таныштырам. Теләгән чакта алмаш-тилмәш ял итәрбез.

«Кунакханә» аракы әрҗәсе хәтле генә бер бүлмә иде. Стенаны янган кирпечтән өяргә кушалар, сулый, диләр, ә бу бүлмәнең стеналары, тәмәкеле төтеннән тончыгып, күптән сулаудан туктагандыр ин-

де. Утырган килеш йоклар өчен баскычлап кагылган сәке һәм мамык түшәвен хәзинә эзләүчеләр ботарлаган тирән эчле утыргычтан гайре һичбер җиһаз сыймаган.

— Бераз җилләнеп керим әле, юкса чебеннәр уяныр, — диде Ансар, елмайганга сабышып.

— Бар, койма эчен айкап кил. Ашыгып йөрмә, смена алышынырга иртәрәк әле.

«Каракүл» берләшмәсенең һәр алачыгы таш коймага терәп салынган. Ансар йөри торгач, цех ишегенә килеп төртелде. Керергәме-юкмы? Әгәр шушы цехта Венера очраса, ни дип сүз башлыйсын да белми иде әле ул.

Бер көтү сарыктан туналган тире төяп электр арбасы килеп туктаган иде, Ансар аңа ишек ачып торды. Тик арбаның ничек күздән югалганын хәтерләми калды, чөнки цех эченнән үтәли җил алып килгән авыр истән куркып, ул авызын-борынын гына түгел, ялгыш күзләрен дә каплаган иде. Бу исне күз алдына китерер өчен сабынлы йон исенә көйгән йон исен кушарга, пешкән йон исенә кипкән тире исен өстәргә һәм шул тирәдә мичкәсе-мичкәсе белән формалин түгәргә кирәк... Теге җил Ансарны җилтерәтеп урамга куып чыгарды, цех эчендәниләр барын күрәсе бар иде. Ул, күкрәк читлеген урам һавасы белән кабартып, үҗәтләнеп цех уртасына ыргылды.

Урамнан алып кергән һавасы җиткәнче генә цех эчен күзәтеп өлгерде ул. Электр арбасына төялгән тиреләрне олы ванналарга бушатып торалар. Ике агай, трусик белән майка өстенә капланган каеш алъяпкычларын шыгырдатып, олау чаклы мичкә авызыннан — баркастан — озын кисәү белән тире чүпли. Ике станок, очкыннар очырып, тиренең йонын тигезләп кыркып бара. Түрдәге... юк, анысын күрергә Ансарның сулышы җитмәде. Ул янәдан урамга йөгереп чыкты. Шәһәр күлендә тончыккан чабак су өстенә сикергән кебек, йотлыгып-йотлыгып һава сулады, янә цехка керде. Тик бу юлысы тагын да тизрәк борылып чыкты. Түрдәрәк — центрифугалар тире сыккан арада — әбәткә утырган ханымнарның кулында арчылган йомырка белән ипи сыныгы күргәч, Ансарның өченче көн ашаган ризыклары өскә күтәрелә башлады. Тизрәк икенче ишек эзләргә кирәк иде.

Монысы буяу цехы иде, ахрысы. Анилин пары әчеттереп-әчеттереп күзне кисә. Эшчеләр кулында зәңгәр, көрән, кара төстәге тиреләр уйнаша. Ләкин боларны инде тире дип әйтү килешмәс. Боерык кәгазьләренә теркәүгә мех дип исем кушарлар аларга. Матурлык тусын өчен җирдә корбаннар кирәк. Колхоз базарына килсәгез, чәчәк сатучы ханымның мутон тунына күз салыгыз әле — өстендә көмеш дулкыннар бии... бу тунны, кайчандыр тигәнәккә батып, көтү тузаныннан ютәлләп һәм җәй буе эче китүдән интеккән корчаңгы сарык ябынып йөргәндер дип кем уйлар?!

Тагын бер ишек.

— Егетем, унынчы цехка чит кешеләр кертелми!

Ансарның юлына аркылы төшкән кеше, тавышына, басып торышына, киеменә караганда, һичшиксез, остаз булырга тиеш, һәрхәлдә, Ансарга шулай тоелды.

— Мин сезнең кеше, — диде Ансар, каравылчы кенәгәсен күрсәтеп, — Венераның эш урынын күрсәтегез...

— Кайсы Венерадыр бит, бездә өчәү алар...

Бу цехның үзенчәлеге шунда: җиһазлар-станоклар бәләкәйрәк, эшчеләрнең өстендә ак халат, кая карама чиста — әле генә бәйрәм өмәсе үткәрелгән диярсең... Ә тиреләре чәшкенеке, кулдан кулга гына йөртәләр.

Венераларның берсе тире кыручы.

Икенче Венера әзер мехны өлгеләп кисеп тора.

Өченче Венера тегелгән бүрекләрне ундүртәрләп тартмаларга тезә. Әйе, өченче Венера Ансар эзләгән кыз иде.

— Исәнме, Венера?

— Исәнмесез. Әнә мастер, әнә цех начальнигы.

— Миңа син кирәк.

— Гафу итегез, мин кияүдә инде. — Һәм Венера көчәнеп кенә елмайгандай итте. Их, елмаймаса ни булган инде, болай да Ансарның күңеле китек.

— Бу мин бит, Ансар, хәтерлисеңме, зоопаркта...

— Хәтерләмим, сезнең ишеләргә бернинди катышым да юк!

Әйтер сүз булмаса да, авыз ачылып калган чаклар була икән ул. Китте Ансар. Аңлашырга — ятлар бар, гафу үтенергә — вакыт тар... Венерага үпкәләргә иртәрәк әле.

## И чибәр кыз...

Әгәр кыр чәчәкләре арасында берәр роза үсеп утырса, аны озак тотмаслар, өзәрләр шул, өзәрләр...

Әгәр кеше юл башында салкын чишмә очратса, сусаудан интекмәсә дә, барыбер аның суына ирен-нәрен чылатыр...

Әгәр иртәнге кояшны үзенә сыйдырган чык бөртеге сиңа карап торса, шул чык бөртеген учыңа аласың килер...

Әгәр болында кеше күзеннән яшеренеп сусылланып пешкән җир җиләге тапсаң, авыз итмичә түзәрсеңме?

Әгәр, әгәр, әгәр...

И чибәр кыз — кыр чәчәкләре арасындагы ялгыз роза, ымсындырып торган салкын чишмә, кояшлы чык бөртеге, сусылланып пешкән җир җиләге бит син...

Венера чибәр кызларга хас язмыш кешесе. Ансарга кул селтәргә тырышуы, танышу шатлыгын нәфрәткә алыштыруы, әйтелмичә калган сүзләрне тыеп, киресенчә, дорфа сөйләшүе — болар барысы язмыш кайтавазы гына.

Тулай торакларда кызлар кияүгә чыкмасын өчен бөтен шартлары килгән. Кер юарга өйрәтмәс өчен кабул итү пунктларын торакка терәп салганнар. Сазамыклар блогында елак балалар тавышы чыгарырга рөхсәт юк, балаң туса — почмак эзләп китәсең. Берүк ашарга пешерә күрмәгез дигәндәй, тулай торакның аскы катына урам ягыннан ишек уеп, «Бистро» ачтылар, үзалдыңа зарланып йөргәндә, күңел юатыр өчен телевизор бар. Тән җылысы кирәксә — төне буе «Бистро» ирләре ишек шакып йөри... Ләкин инвентарь саны сугылган җиһазга әверелгән кызлар гел кияүгә чыгу турында хыялланып яши. Ник дисәң, тулай торак әсирлегеннән бары тик никах кына коткара ала...

Яшьлеген унсигезгә җиткереп, шәһәр урамнарына адашып килеп кергән мәлне, Венера бер егеткә юлыкты. Атнага җиде тапкыр килә. Ыспай киенгән, галстугы тагулы, чәче открыткадагы шаһзадәләрнекедәй пөхтә итеп алынган, сөйләшүләре магнит тасмасына язылган кебек — һичбер ялгышсыз. Кыз күңелен тәмам алгысытты, гел балкып кына тора. Унбиш көн үтте дигәндә, унбишенче тапкыр килүендә, кызларның бүлмә идәнен юып чыккан чагы иде. Гөлләргә су сибелгән, урын-җирләр алыштырылган. Ишек бусагасыннан түрдәге плинтуска хәтле тулай торакларда сирәк очрый торган киң палас җәелгән. Егеткә туфлиен салып керергә туры килде. Аяк савытыннан чыккан үкчәдә биш тиенлек иске акча кадәр оек ертыгы күренеп калды. Бетте... Унбишенче очрашудан соң Венера егеткә борылып та карамады.

Унтугыз яшь тулып узганда...

Венераның алтынчы трамвайда йөри торган айлык билеты тулай торакта онытылып калган иде. Ай ахыры. Ишекләренә КРС (контрольно-ревизионная служба) дип язылган машиналар чат саен. Венераның беләгеннән тотып алдылар. «Билетсыз йөрүче»не каптыргач, ревизор агай сөенеченнән икенче беләгенә дә кызыл тасма бәйләп куйды, үз эшенең тәмен белә, сөйкемсез. Венераның «Проездноем бар, өйдә калган» дигән сүзләреннән ревизорга кушылып пассажирлар да көлә башлады. Көтмәгәндә арада баш түбәсенә түбәтәй каплаган озын буйлы егет килеп чыкты да Венера өчен билетын күрсәтте.

— Ә үзең куян тиресен бөркәнәсеңме? — дип бәйләнделәр егеткә.

Егет үзе штраф түләде.

— Безнең якларда КРС дип сыер фермасының капкасына гына язалар иде, ревизорлар түгел, рэкетирлар болар, — дип аклана башлады Венера егет алдында, — билетым бар, өйдә генә калган, билләһи, ант әгәр. Ышанмасагыз, әйдә, тулай торакка кайтабыз, күрсәтермен, — дигәнен сизми дә калды.

Ә егет:

— Ышанам ич инде, ышанам. Андый хәлләр була ул, — дия-дия, тәмам тагылды.

Танышып, «Мәхәббәттә гөнаһ юк» сериалының өчесен карап өлгерделәр. Ләкин ни хикмәттер, егет урамда йөрсә дә, өйгә керсә дә, өстәл артында утырса да, түбәтәен салмый гына бит. Түзмәде Венера:

— Гел түбәтәйдән йөргәч, колхоз базарында җиләк-җимеш сатучы танышларың күптер, — диде ул, башта шаяртып.

Егетнең җавабы әзер иде.

— Әгәр эшләпә кисәм, буем тагын бер карышка арта.

— Бу түбәтәй башыңа ябышмагандыр ич? — диде Венера, бу юлысы инде үпкәләвен яшермичә.

— Ә мин аны сизмим, әллә бар, әллә юк. Кайчак йокларга ятканда да салырга онытам.

— Түбәтәйле колга күргәнем бар ла...

Һәм Венера сериалның калган өлешләрен үзе генә карарга булды.

Ә беркөнне аңа егерме яшь тулды. Йоласына туры китереп, шушы түгәрәк санны билгеләп, бүлмәдәш кызлар белән цәйлүн чәе эчеп утырганда, чакырылмаган кунак килеп керде. Буе — сикерсә дә, ишек кашагасына башы тимәс, шөкер, түбәтәйле колга түгел. Бәдәне — һава белән өреп тутырылган пинжәк кигән төсле. Күзләре — яңа гына калыккан йолдызларың көнләшерлек. Исән калган чәчләрен төзәткәләде, баш кагып кына күреште.

— Мин йортлар идарәсенең дежур электригы, сезнең чакыру буенча килдем.

— Ә безнең беркемне дә чакырганыбыз юк, — дип гаҗәпләнде кызлар, — бөтен җиһазлар тәртиптә, ут чыгарлык түгел.

— Йөз чөерергә ашыкмагыз, кызлар, бүлмәгездә миңа эш җитәрлек әле. Әйтик, үтүгегезнең регуляторы эшләми, электр плитәгездән янган каеш исе чыга, телевизорыгыз чытыр-чытыр итә... Шулаймы?

— Әйе шул, каян белдегез?! — Кызлар аптырашка калдылар.

— Белми ни, бүлмә саен бер үк ватык инде ул.

— Алайса, бәйрәмебезне сизеп кергәнсездер, — диде Венера, дусларын тынычландырырга теләп, — рәхим итегез, ватык-мотыкларыбыз бик күп. Без күңел ачыйк, ә сез вакытыгызны әрәм итмичә эшкә тотыныгыз. Җырлагыз, кызлар!

— Юк, юк, җырлаганчы, паспортын тикшерик.

Электрик егет, кызлар керфек каккан арада, күкрәк кесәсеннән паспортын чыгарып өлгерде.

— Кулыгызга бирмим, менә сезне кызыксындырган битләрен актарам. Күрәсезме, артык пичәтләре юк, балалар исемен яза торган урыны чиста. Ә сезнең, сул күзегезнең уңнан җиденче керфеге коелып, сөрмәгезгә кунып калган, — диде электрик һәм паспорт белән Венераның борын төбендә җил уйнатып алды. Паспортыннан «Шипр» исе килә иде. Венера аның бер сөйкемле гадәтенә игътибар итте: матур итеп көлә белә ул, чукынчык, авызын ерып битенә җыерчык чәчми, күзләре белән генә елмая бугай.

Кайда ничектер, тулай торакта чәйне электр чәйнеге белән үлчәп сөйлиләр. Кызлар ике чәйнек бушатканда, үтүк төзәлгән иде инде.

— Калган эшләрегезне иртәгә күрсәтерсез, берьюлы төгәлләсәм, тагын килер өчен сәбәп калмый, — дигән булып чыгып китте электрик.

Венера уйга калды.

Икенче көнне телевизор төзәлде. Венера ныграк уйга калды... Өченче көнне күмерләнеп беткән розеткалар алышынды... Венера тынычлыгын югалтты... Ә дүртенче көнне, ишек төбендә адымнарын ишетү белән үк, кызый елмаюдан тыела алмады... Бишенче көнне электрик күренмәде. Сөйләшенгән вакытка Венера каршысына түм-түгәрәк гәүдәле яшь хатын килеп басты. Әүвәл эндәшмичәрәк торды. Аннан соң...

— Венера дигәннәре синме?!

«Әйе!» дигән бер сүзгә ялганып киткән җөмләләрне кабатлап торуның кирәге юктыр. Ирен югалтудан курыккан йөкле хатын тарафыннан көндәшкә ни әйтелергә тиеш дип исәпләнсә, барысы да әйтелде. Хәер, Венера артыгын ишетмәде, иң кирәклесен генә отып калды: «Туймас җан ул. Әтәч булып кына туасы калган аңа. Кулыннан бөтен эш килә, шуңа масая. Паспортының никах пичәте сугылган битен алып куйган... Өйдән чыгуга, балдагын кесәсенә сала...»

Тәмам йомылды Венера. Кибетләрдә йөрмәс булды. Шәһәр транспортларында янәшәсендә ирләр туры килсә, икенче утыргычка күчеп утырды. Күршеләр сөйләштермәсен өчен, кулына китап тотты. Берара, шулай боегып көн итә торгач, егерме бер яшь тә тулып китте.

Күп уйлаган кешене унөченче хезмәт хакыннан мәхрүм итәләр...

Көзге төн ай-һай озын, уйланырга уең җитмәс. Венера йокыны уйга алыштырды. Тырыш җил тәрәзә артындагы өрәңгенең соңгы яфракларын өзә. Өзә дә, Венерага санап барырга кушкандай, өлгенең киң пыяласына алып килә. Өрәңгенең иң очындагы нечкә чыбыклары, җилне тарап, кыз бала елаган тавыш чыгара. Һәм Венераның, кайнар юрган астыннан чыгып, шул елак җилне бишеккә салып юатасы килә. Көз ахыры — квартал ахыры, ел ахыры, ә өзеләсе яфраклар бар әле. Шуңа күрә җил икешәр-өчәр смена буена тынмый, шәһәр Советы графигына сыешырга теләгәндәй, ашыгып-ашыгып, туктаусыз яфрак өзә, якынлашучы кышка урын әзерли.

Өзелгән яфракларны саный-саный, төннең иң тыныч чагы җитә. Тулай торакта ул тынлык иртәнге өч белән биш арасына туры килә. Аннан соң инде беренче сменага ашыгучылар уяна башлый. Кухняда чәйнекләр дөбердәшә, табалар чыжлый, шабырдап су ага, ишек ярыкларыннан янган май исләре бәреп керә.

Көн яктысын уянгач кына абайлап өлгерде Венера, кичә тәки йокыга кителгән икән. Ләкин баскычларда үкчәләр тыпырдашудан һәм шуңа өстәп пружиналы ишекнең еш-еш итеп бәргәләнүен исәпкә алсаң, инде трамвай тукталышында басып торыр чак җиткән. Өлгермәсәң — эшкә соңарасың, соңарсаң — проходнойдан кертмиләр, «прогул» куйсалар, унөченче хезмәт хакына зыян килә...

Венера утырырга тиешле трамвайның йөртүчесенә дә егерме бер тулды микән, никтер күренми?! Тукталыштагы халыкны сыйдырыр өчен ким дигәндә ике катлы ике трамвай кирәк хәзер, әле башка тукталыштагылар да өстәлер. Өч тыкрык читкәрәк китеп, олы урамдагы машиналарга ялынырга туры килә. Машиналар тыз да быз йөреп тора. Венера, кулын күтәргән килеш, гел өметләнде. Иртәнге йөгерешкә чыккан өлгер егет ише генә бер зәңгәр «Волга» үтеп киткән иде, кисәк туктап кирегә чигенде. Ишеге ачылуга, Венера кереп тә утырды.

— Троллейбуска кадәр генә алып баралам.

— Җидегә чаклы табельныйга килеп өлгермәсәм...

— Унөченче хезмәт хакына түт-тү-үт!

— Аңлавыгызга рәхмәт, буш итмәм.

— Мине дә шеф-директор нәкъ җидегә көтә. Сине илтсәм, үзем өлгермим.

— Алайса, төшереп калдырыгыз мине.

— Такси тотасыңмы? Ха-ха-ха! — дип көләргә теләге барлыгын аңлатты егет. — Таксиларның нәкъ смена алыштырган чагы... Йә, ярар инде, синдәй кызлар өчен унөченче зарплатам жәл түгел.

Һәм зәңгәр «Волга» «Каракүл» берләшмәсе ягына борылды.

Эштән кайтышлый Венера, яшел коймага борынын терәп торган таныш «Волга»ны күргәч, юри генә якынайган иде, егетнең авызы ерылды. Тагын кабина ишеге ачылды.

— Әгәр директорың күрсә, рульсез дә калырсың әле.

— Директор төшке ашта.

— Сәгать дүрттәме?

— Аларның шулайрак көйләнгән, иртәнге ашлары унбердә, төшкесе дүрттә...

— Ә кичкесе?

— Кичкене ашамыйлар, тазарудан куркалар... Буш вакытта машина үз кулымда, шулай килешенгән. Юкса ике мең тәңкәгә кайсы шофер ризалашсын?! Буш вакытларда «ундүртенче зарплата»га эшлим...

— Мин сезгә күпме тиеш инде? Иртәнгесе өчен дә...

Егет кинәт тормозга басты.

— Төшереп калдырам...

Венера, директорларга охшарга тырышып, утыргычка ныграк чумды.

Көн саен диярлек егет килеп ала, китереп куя. Вакыты иркенрәк чакта шәһәр буенча йөртә. Гел юлда...

Директорлары диңгез буена өч көнлек симпозиумга киткәч, Венерага өч көнлек программа тәкъдим ителде. Беренче көн. Җомга. Көндез урамга, кич аулак урындагы «Башак» ресторанына. Икенче көн. Шимбә. Иртән Аккош күленә, көндез «Алтын дага» ресторанына, кич дус тиешле танышларда банкет. Өченче көн. Якшәмбе. Көндез «Нарат» ресторанына, кич наратлыктагы дачага...

Эштән кайтуга, Венераның җавабы әзер булырга тиеш. Әлбәттә, «юк» дигән җавап шул мизгелдә үк әзер иде, ләкин Венера дәшмәде. Бу шоферның кемлеген ахырынача ачыклар өчен ике арада сынаулы тынлык кирәк.

Егет мондый тынлыкларны авыр кичерә икән.

— Беләсеңме, Венера туташ, ирләр гадәттә ике төрлегә бүленәләр: бер ишләре өйләнеп газиз хатыны белән гомер буе яши. Аерылышу турында ләм-мим, авыз да ачтырмый. Ә үзе гомер буе сөяркәләр белән типтерә. Икенче берәүләр, киресенчә, сөяркәләр турында ишетергә дә теләми. Аның каравы хатыннарын еш алыштыра. Син шуларның кайсысын яклыйсың? Беренчесенме, әллә икенчесенме?

— Өченчесен!

— Ниндиен?..

— Бердәнбер хатынына гына табынып яшәүчесен.

— Мәхәббәт яклы.

— Әйе шул. Юкса яшәүдән ни мәгънә?!

— Мәхәббәт килә дә китә ул, Венера туташ, ә хатын кала.

— Димәк, син, «Волга»лы егет, беренче төркемдәгеләрдән икән. Хатының бер, сөяркәләрең мең дә бер...

— Бик мөмкин, Венера туташ, бәлки, мөгаен... белмим тагы. Күпме китап укыганым бар, академиклар, зур җитәкчеләр, врачлар, педагоглар... бөек кешеләр турында. Кайсын гына алма... бөек кешебез хатыныннан туйган, аңа сөяркә кирәк... Кызык өчен, телевизордагы чит ил фильмнарын рәттән карап барганда да төп геройлар сөяркәләр хәзер... Һәм мин дә бөек кешеләр каныннан яралган, ахрысы.

— Туктат әле машинаңны, никтер күңел болгана башлады...

Венера соңгы сүзен тротуарга аяк баскач кына әйтә алды.

— Бигайбә, сөяркәң булалмадым инде...

Ансар белән танышканда Венерага егерме бер яшь тулып, егерме икенченең бер-ике-өч ае кимеп өлгергән иде инде. Бер күрүдә үк кызның күңеленә хуш килде ул егет. Зоопаркта чакта, тоткындагы җәнлек-җанварларны кызганып, кош-кортларны юатып, ябылудагы чәчәкләргә соклана белүе өчен үз итте ул аны. Моңарчы очраган кешеләр арасында Ансар кебеге юк иде сыман... Ә баксаң исә, Ансары да шул бер үк иш икән!.. Кемгә генә ышанырга соң бу дөньяда?! Дөньясы ике генә көнлек бит — аның да бер көне яшәлгән.

Тулай торакка елап кайтырга ярамый, кайткач та еларга ярамый. Анда яше егермедән узган кызлар бер Венера гына түгел.

Ул, тукталып, ярты сәгать чамасы ак каен кәүсәсен сыйпап торды...

## «Гыйшыклы тегүче»

Фабрикада бүрек тегүчеләрнең эш сәгате бетүгә, каравылчыларның кызу эш сәгате башлана. Эш бетте дип исәпләнсә дә, эшчеләр проходнойга күчләре белән өерелеп килмиләр. Кеше робот түгел, сәгате суккач сүндереп куеп булмый. Күпчелек халык эш киемен салу белән душка керә, анда инде су буе чират, җитмәсә, юыну-киенү дигәндә, һәркемнең җитезлеге төрлечә. Планны арттырып үтәү белән мавыгып, душка соңга калучылар да бар... Шуңа күрә смена алышынганда бер сәгать буена капка аркылы халык әрле-бирле йөренә.

«Каракүл»дә куна калучылар да юк түгел. Икенче катка күтәрелсәң, йон җыйгыч камераларда, ким дигәндә, өчәр кеше очрый. Урын-җир йомшак, вентилятор йон суыргыч торбалардан мамыклы җылы һава өрә. Таң атканчы өч кешегә ярты чиләк «шулпа» (су кушылган спиртның эшчеләр арасындагы атамасы) җитә.

Әгәр «Каракүл»нең бөтен эшчесе, бер булып җыйналып, капкага ябырылса, аларны тентеп чыгару мөмкин булмас иде. Ә тентергә кирәк... Чөнки алар затлы мех арасында кайнашалар, бераз эш урынына күнексәң, затлы нәрсә кулга иярә башлый, нәфесне азындыра. Күп бит ул, бакчы, бихисап.

— Әй, студент, урыныңа бас! — дип әмер бирде каравыл начальнигы. — Оялып-нитеп маташма, теләсәң кайсын тот та тенти башла. Миңа ярамый, унсигез ел шушында эшләгәч, бөтенесе үземнең балаларым төсле, тентергә кулым күтәрелми. Резервка дип каравылчыларны шуңа сорыйбыз инде без. Кара аны, берсен дә тәк кенә җибәрмә, кыюрак бул!

— Бәлки, шиклеләрен генә тентергәдер. Урлаган кеше әллә каян күренә ул.

— Каракның бүреге янмый, ышанма син мәзәккә. Каравылчы өчен шиксез кешеләр юк.

Җәй көне булса бер хәер, өстә артык кием йөрмәс, сыланып торган джинсы чалбар белән кысан күлмәк эченә егетләр һәм кызларның үз гәүдәләреннән гайре артык берни сыймас. Күлмәкләре дә кәгазь кебек, эчендәге — тышында, мех яшереп чыгам димә. Ә менә кыш көне калын-калын киемнәр аркылы кеше капшау өчен көч кирәк икән...

— Күбрәк бил тирәсен тикшер, башка җиргә яшерә алмаслар, — дип өйрәтеп торалар Ансарны.

Иң әүвәл Ансар өч егет каршысына килеп басты. Егетләр, сүз әйткәнне дә көтмичә, алдан ук төймәләре чишелгән пәлтәнең колачын җәеп, ян-якларын да күрсәтер өчен дигәндәй, баскан җирләрендә бөтерелеп алдылар, кәефләре шәп, өйрәтелгәннәр болар... Ясалма мех якалы плащ-пәлтә кигән бер кыз адымын акрынайтты, ул путасын шулкадәр нык будырып бәйләгән ки — биле муены чаклы гына, юк-юк, чәч толымы калынлыгы гына калган. Ансарның тентергә көче җитмәде. Шуннан соң кызый иңбашына асылган озын буйлы сумкасын ачып күрсәтте. Ярар, бусы да үтеп китте... Шундук юан бер ханым килеп басты. Баягы нечкә билле кызны шушы ханым сурәтенә китерим дисәң, аның биленә ким дигәндә биш... җиде, унике сарыкның тиресен урап куярга кирәк. Сырма кигән яланбаш ирне Ансар җиңеннән тартып туктатты, тыңламаска маташа теге. Тәки күзгә чекрәеп карап тора. Әллә моңарчы бер дә тентемәгәннәр үзен?! Усал агайдыр әле. Бәлки, урамда әшнәләре көтеп торадыр, шуңа масаядыр. Билләһи, мех чәлдергән кешегә охшый, бил тирәсе төзек формасын югалткан. Ансар сабырсызланып аның сырма төймәләрен чиште дә, пинҗәк аркылы чеметеп карады һәм мыймылдап торган симез корсак тирәсеннән чирканып, кулын тиз генә тартып алды. (Каравыл начальнигы кая югалды соң әле?!)

— Гафу итегез, инструкция кушуы... — дип авыз ачкан иде Ансар, тегесе сорау белән бәрелде:

— Фамилияң бармы?

— Субаев. Резерв.

— Жәл. Менә дигән каравылчы чыгар иде синнән.

Телогрейкалы ир үтеп киткәч, каравыл начальнигы пәйда булды.

— Фабрика директоры ул... Шәп иттең, кирәген бирдең! Юри дәшми тордым. Кызык ич. Унсигез ел буе эшләп бер тентисем килә иде үзен. Безнең карамакта тагын өч фабрика. Инде ике генә директорны капшыйсың калды. «Каракүл» берләшмәсенең директорлары күп лә ул...

— Булса ни, әллә директорларның кулы юкмы? — дип акланса да, Ансарның күңелендә авыр юшкын калды.

— Директорлар берәм-сәрәнгә кызыкмый. Кыюлыгың җитсә, капкадан чыкканда җиңел машиналарын тикшерерсең. Ха-ха-ха...

Каравыл начальнигы көлә-көлә егылыр дәрәҗәгә җиткәндә, Ансар каршысына Венера килеп басты.

Судта очратса шаккатмас, тик менә шушы урында очратырмын дип уйламаган иде кыз. Әллә керфекләре кашына тиде Венераның, аптыраудан аның күзләре киптергечкә тамган ике тамчы язу карасы төсле җәелделәр бугай. Ә бит бу күзләрнең өлгереп пешкән күгән җимеше төсле чаклары да бар иде. Венера шаккаткан килеш ишеккә юнәлде, ләкин Ансар уяу иде, чөнки ул бу очрашуга әллә кайчан әзер. Тормоз педаленең дөбердәвеннән күбәләк канатлы тимер рәшәткә кызның юлын бүлде. Үзенә таба сузылган кулларны күргәч, Венераның күзләре янә үз хәленә кайтты. Өлгереп пешкән күгән җимешенә охшаса да, карашы шулкадәр үткен, әгәр егет бер мизгелдә йөзен читкә борып өлгермәсә, электр дугасына белештермичә карап торган кешеләрнекедәй өч көн буе кадап-кадап, сулкылдап-сулкылдап, кан савып күзләре авыртасы иде аның.

Ул арада чират үсте. Каравыл начальнигы икенче коридорны ачарга мәҗбүр булды. Зур чиратта мут хатыннар да табыла.

— Мин бу бабайга тентетеп тормам инде, яшь егет кулларыннан кытыкланасым килә.

— Студент чиратына кем ахыргы?!

— Гыйшыклы тегүче диген син аны...

Юл ябык. Венера тынсыз калды. Ансар кулларын яшерергә урын табалмый. Ике арадагы тынлык киеренкелеккә әверелде. Кем кемне җиңәр икән? Венераның горурлыгымы, әллә Ансарның үҗәтлеге-

ме? Йөрәк ныклыгы менә шушындый тынлыкларда сынала инде... Венера җиңелде, чөнки әлеге көтелмәгән очрашудан аның кинәт хәле китте. Ул куенын ачты.

— Тенте, давай, эзлә!..

Кызыл пәлтә канат җәйде... кызыл бәрхет күлмәк, кызыл челтәрле бәби итәк, кызыл җиң, кызыл түш... Ансар, ике куллап бар көче белән Венераның биленнән кысып, үзенә якынайтты.

— Син дә мине аңламагач, Венера!

— Аңлаучылар табылыр.

Ансарга да җиңелер чак җитте... Куллар тыңламады.

Венера, кып-кызыл ялкын сыман, җилфер-җилфер дөрләп, карлы төн эченә кереп югалды. Янып бетәрме бүген?.. Ялкын... Кызыл чәчәк...

Күз алдындагы кызыл томан таралып өлгермәде, бер егет үтеп китте.

— Әй, коллега, буразнада тугарылган ат шикелле бик онытылма әле син анда! — Каравылчылар начальнигы тавышы бу.

Дөрестән дә, әлеге егет шома гына чыгып сызды түгелме? Йөзе дә таныш. Карасана: маңгае киң, яңаклары ябык, ияге очлы — өчпочмаклы йөз. Таныш, бик тә таныш. Хәтер дигәнең вак-төякләр белән әллә ни күмелеп өлгермәгән. Капчык тапкан төндә Ансарлар янында бөтерелгән шаһитларның берсе — Байгушов ич бу!

Ансар тиз генә урамга йөгереп чыкты... Ләкин урамда өчпочмакка охшаш берни дә күренмәде, җилләр генә исә...

## Гуд бай, мадам!

Мәхәббәт сүзен шагыйрьләр уйлап чыгарган. Яңгырашлы, аһәңле бу сүз башкалар күңеленә дә хуш килгән — отып алганнар, кабатлаганнар... Хәзер инде бөтен Җир шары, хәтта шагыйрьләр үзләре дә шушы уйлап чыгарылган газаптан интегә. Мәхәббәтнең үзенә генә хас чирләре бар. Әйтик, физик чирләр... Йөрәк сызлый, күзләр тоныклана, үгет-нәсихәтләргә каршы колак саңгыраулана, буыннар йомшара, гәүдә җиңеләя, сагыну дәрәҗәсенә карап ябыгуы сизелә... Психик чирләре дә җитәрлек. Гашыйк кеше ялгыз минутларда кулына каләм ала, мәхәббәт теориясен баета, шагыйрьләр белән очраша, үз-үзе белән сөйләшеп йөри башлый. Гашыйк кешенең зиһене чуала, хәтере начарлана, аппетиты бетә... Без әкренләп физиологик чирләрне санауга күчәбез... Ул кеше ашаудан калырга мөмкин. Көнчелек уты кабына, күңеле нечкәрә, бала-чага турында хыяллана башлый. Төшләренең сюжеты катлаулана, төне-төне белән гыйшыклы төшләр борчый. Колагында туктаусыз кемнеңдер исеме шаулап тора яисә берәр җырның өзеге, чатнаган патефон тәлинкәсе кебек, кабат-кабат мыгырдандыра, телгә күчә... Бик күп ул чирләр... Һәм ул чирләрне дәвалый алырдай бер генә табиб та тумаган, тумады, тумас та... Бу чирләр, вакыты җиткәч, әкренләп үзеннән-үзе бетә. Вакыты җиткәч — кавышкач... Шунысы сәер, без һәммәбез дә мәхәббәт сырхавына сабышырга теләсә кайчан әзер...

Ай ахыры, беренче квартал ахыры. Маллар кышлауда. «Каракүл» берләшмәсенә чимал җитми. Ә чимал дигәнең — чи тире. Суеласы сугымлыклар беткән. Җәнлек хуҗалыкларында үрчү чоры. Чит илдән кергән чималны көтеп атналар заяга үтә. Ләкин акционер Венераның ул проблемаларга исе китми. Ул эшеннән җәяү кайтып бара. Аның газиз башкайлары шагыйрьләр уйлап чыгарган газап белән тулы. Әллә кайдан гына, кылт итеп, сабыйлар җыры искә төште, уйларны бүлдерә дә кайтып-кайтып кабатлана.

Чоландагы ак майга ияләшкән күселәр...

Әле генә Ансарны кулга алынды дип фараз кылдык, бактың исә, ул мал арасында сакта тора.

Мияу-мияу, пескәем, хыянәтче икәнсең...

Шушы җыр юньләп уйларга да ирек бирми, килә дә яңгырый, килә дә яңгырый... Димәк, тәти егетебезнең минем белән танышуы яратудан түгел, бүрек чәлдерү ниятеннән генә. Димәк, ул мине алдан ук күзәтеп йөргән, әзер продукция складында эшләвемне белгәч, танышырга сәбәп эзләгән.

Чоландагы ак майга ияләшкән күселәр...

Нияте тормышка ашмады егетнең, милиция комачаулады... Ә ник соң андый кешене каравылчы итеп куйганнар?! Алдап-юмалап котылдымы икән? Әллә бөтенесе бер мафия микән?

Мияу-мияу, пескәем, хыянәтче икәнсең...

Карале син аны, тасма телне, тыйнак, сабыр, тәртипле булып кылана. Оста караклар гел шундыйдыр инде ул. «Каракүл»нең үзендә генә аз иде ди синең ишеләр?! Товарыбызның ун проценты, күзгә күренмәс бүрек шикелле, әллә кая юкка чыга. Бүрек нәрсә ул... Менә тунны әйт син. Фирменный кибет-

ләребездән тун сатып алган кешене күрмәссең дә. Бактың исә, мутон тун кигән хатын-кызлар адым саен. Каян алалармы? Әнә шул — «ун процент» Ансар кебекләр аркылы тарала торгандыр... Нәтиҗәдә... Экономияләнгән материалны экономияләргә туры килә. Бүрекләрнең үзкыйммәте арта, туннарның размеры кечерәя, киеп карамыйча ни яраганын белер хәл юк...

Саклый торган маеңны үзең ашап киткәнсең...

Яхшы гына егет кебек үзе, бәлки, тәрбияләргә соң түгелдер әле. Тиешле органнарга хәбәр итәргә кирәк. Тик бүген үк түгел, иртәгә. Мактыйсы кешеңне бүген макта, гаепле кешеңне иртәгә орыш... Ашыкмаска, тагын берәр тапкыр күзгә-күз очрашырга, бәлки, сүз катып карарга кирәктер?!

Икенче дежурствога Ансар килмәде, аның урынына култык астына немецча-русча сүзлек кыстырган «керпе» чәчле икенче бер студентны җибәргәннәр. Тентеп чыгарганда, немецча кылана. «Хэнде хох!» дип кулларны күтәртә, «Гут! Гут!» дип, билләрне капшый. Соңыннан «Гуд бай, мадам!» дип саубуллашып кала. Беренче курс студенты булса кирәк, бөтен кеше белгән сүзләрдән гайресен отып өлгермәгән. Ичмасам, «Гуд бай, мадам!» дип кычкырып калмаса соң! Егетләр куенында сөелеп карамаган кыз бала «мадам» була диме?! Үртәлде, кимсенде Венера... Ансар да студент бит, тик ул болай ук дорфа түгел...

## Гафу итегез...

Ә Ансарны бу кичтә, ай-ваена карамыйча, ашханәгә куйдылар. Үз каравылчылары, эшкә килеп җиткәч кенә, ишек төбендәге бозлыкка таеп егылган да бүтән тормаган... Авыр туфрагы җиңел булсын.

Директордан башлап идән юучысына кадәр күмәкләшеп, Ансар килгәнне көтеп торалар иде.

— Гафу итегез, без, килгән кешенең дукаментын тикшереп тормыйбыз, сине кем җибәрде, шуны гына әйт тә? — дип дәшүчесе хуҗаларыдыр, ахрысы.

— Язит Язилевич кушты.

— Ә-ә... Алайса, ышанычлы кеше икәнсең. Әйдә, иң мөһим урыннарны күрсәтеп чыгыйм. Иң-иң-иң главные — менә шушы суыткыч. Бүген кич ит белән май китерделәр, пломбасын күз карасыдай сакла, яме! Он склады, йозагына мөһерле кәгазь ябыштырылган, ачкыч белән төртә күрмә.

Җаваплы «нокталар» белән таныштырганда, бөтенесе ияреп йөрде.

— Җиләк-җимеш склады, — дип дәвам итте хуҗа, — шунда ук консервлар саклана. Бишенче складта вак-төяк нәрсәләр. Ашханәгә тәрәзә ватмыйча керерлек түгел, үзең аңла инде, төне буе йокламыйча, тәрәзә санап йөрергә туры килер. Мәчене дә урамга чыгарасы түгел, ишекне үзебез ачып керәбез. Төнлә ачыксаң, складларда актарынып йөрмә, әнә плитәдә калган аш, калҗалар, чәй дә бар. Без киттек. Ишегеңне тыштан биклибез, ә син эчтән ныгытып бикл ә. Иртән берәм-сәрәмгә ачма. Бөтен кешеләребез җыелып беткәч кенә кертерсең безне.

— Ник алай? — Вакытны сузарга теләде Ансар, аның бүген ашханәдә каласы килми иде.

— Акционерлаштык без. ЗАО «Токмач» булдык. Бары — уртак, югы — бергә! Бер генә пешекчебез дә склад тирәсендә ялгызы иснәнеп йөрергә тиеш түгел.

— Контроль дигәнегез бер-берегезгә ышанмау икән.

— Устав кушкан нәрсә...

— Уставмы? Бик дөрес әйтәсез. Гафу итегез, безнеңчә инструкция дип атала ул. Мин сезнең сумкаларыгызны тикшереп чыгарырга тиеш. Хәзер үк каршыма тезеп куегыз.

Башкалар үзара күз атышып торган арада, бер тәвәккәле, бәбкә чыгарган каз шикелле, җиңел сумкасын Ансар алдына китереп тә куйды. Савыт-саба юучы булып эшли торгандыр, ахрысы. Үзе кәй, үзе чандыр, бармаклары каезлап киптерелгән юкә чыбыклар сымак кына.

«Селтеле суда юылып беткән бу апа!» дип уйлап куйды Ансар, аны кызганып.

— Дөрес эшлисең, энем, — диде ул, хуҗага таба борылып.

Хуҗа ике айлык сәяхәткә чыгарга дип тутырылган юл капчыгы кадәр сумкасының бавын кысыбрак тотты.

— Ниткән хурлык бу! Шушы гомер эшләп, мондый кимсетүгә түзәргә... — Ул шундук телефон янына күчеп утырды. — Алло, Язит Язилевич! Эх, Язит абый, Язит абый, гафу итегез, ну синнән мондый этлекне көтмәгәнием. Каравылчы дигән булып тикшерүче җибәргәнсең ич... Нәрсә дисең?.. Студент кынамыни?! Рәхмәт, Язит абый, дөрес итәсең, икенчесен җибәр. Монысынмы?.. — Хуҗа ханым телефон трубкасын йөрәгенә кысты. — Бар, җанкисәгем, каян килдең — шунда олак!

— Язит Язилевич янынамы?! Рәхмәт!

— Тиле, мәкинә баш, шалапай, котырган. — Һәм шуның ише калдык-постык сүзләр белән озатып калдылар Ансарны.

«Ур-ра!» кычкырып кайтып керүен ошатмады Язит Язилевич, аны янына утыртты да бәйнә-бәйнә аңлатырга кереште.

— Шатланырлык нәрсә күрмим. Ашханә дип көлеп карама, алар безнең заказчиклар. Ел саен даими рәвештә акча күчереп торалар. Шул акчага без каравылчылар яллыйбыз, синең кебек студентларны асрыйбыз. Килешми, игелекле оешмалардан көлү бер дә килешми. Заказчикның зарланганын яратмыйлар бездә. Сумка актару, кызлар тентү ошап китсә, мин сине янә «Каракүл»гә җибәрә алам, үзеңә үпкәлә. Бар, сыпыр!

«Каракүл» дигәч, Ансар тагын «Ур-ра!» кычкыра язды.

— Әй, студент, кара аны, әгәр берләшмәдән дә жалу килсә... замполитка синең хакта рапорт язам, әйтте диярсең!..

— Гафу итегез, Язит Язилевич, сүзегездән чыкмам.

«Каракүл» берләшмәсенә җитәрәк, Ансар, урам таксофоны табып, кафедра мөдиренең өенә шылтыратты.

— Алломы?

— Әйе! Өегезгә шылтыратуым өчен гафу итегез, кафедрага килгәнегезне көтеп торырлык сабырлыгым калмады. Вакыт юк, эшкә ашыгам. Өметле бер очрашуга әзерләнәм. Алдан ук сезнең белән киңәшәсе иде... Шаһитларның берсе — Байгушов, берләшмәдә эшли икән...

— Алло, егетем, Иске бистәнең ярты халкы «Каракүл»дә эшли, моның ни яңалыгы бар.

— Туры килүе сәер шул. Төн уртасында аяк астыннан шаһит булып калкып чыккач та шикләнгән идем.

— Ә син соң, Субаев, ул кичне төн уртасында мехчылар тирәсенә үзең каян килеп чыктың? Аптыраган икәнсең. Байгушов та яшь кеше, нигә әле ул да синең кебек кызлар куып йөрмәскә тиеш? Шикләнәм дип, төнлә очраган һәр кешене кулга алыргамы? Сүзең беттеме?

— Юк, бетмәде...

— Алло, егетем, шаһитларның кемлеген каян белдең?

— Хәтер шәп минем... Райнур Асланов — теге сержант, беркетмәгә кул куйдырганда хәтерләп калган идем.

— Шуннан, егетем?

— Шул. Белештем. Байгушов әзер продукцияләр складында йөк төяүче. Товарга әйләнгән бүрекләрне бәйләме-бәйләме белән генә кулдан уздыра. Бер урында озак эшләгән кеше үзләштерү алымнарына җиңел өйрәнә ул.

— Аңлашылды. Хуплыйм. Сорауларым өчен гафу, Субаев, версияңнең ныклыгын сынамакчы идем.

— Рәхмәт.

— Диплом эшеңнең чиреге язылды дип исәплик.

— Тагын бер кат рәхмәт. Зинһар өчен, өегезгә шылтыратканга ачуланмагыз. Гафу итегез.

Эш урынына, яшенә карап үзеңнән күпкә олы кеше белән сөйләшкәндә, рәхмәт, гафу итегез, зинһар өчен... кебек йомшак сүзләрне кызганмаска кирәк. Бу — дипломатик мөнәсәбәтләрне ныгытырга ярдәм итә.

«Каракүл»гә барып җиткәнче юл буе «Ур-ра!» кычкырып барды Ансар, яңгыратып түгел, сөенечен тыеп кына. Ләкин урамда очраган узган-барганнарга аның «Ур-ра!» дигәне «Урла! Урла!» дип ишетелде бугай...

## Яшьлек дустың милиционер булгач

Райнур өнгә охшаш детектив төшләреннән көч-хәл белән арынып күзләрен ачты. Вакчыл каената төсле санап кына йоклатырга күнеккән будильник шылтырарга оныткан, колак төбендәгесе тукталып йокыга талган. Әле ярый, төгәллек дигән гадәт сизгерлеккә өйрәткән — патрульгә чыгар чак җитүгә, күзләр ачыла, йокы кинәт кенә туеп китә. Башка сәгатьләр уята башлаганчы, аякка басасың.

Әгәр беренче көнне үк чакырылган уңайга Райнурларга килеп керсә, өйнең зал ягында бихисап күп сәгать күреп аптырашка калган булыр иде Ансар. Телевизор өстендә — мәрмәр плитәгә уеп ясалган сәгать, серванттагы савыт-сабалар арасында шырпы тартмасы хәтле генә электрон сәгать. Стенада герлесе, күкелесе, чаңлысы, агач тартмалысы...

Райнурның нәчәлствосы тынгысыз һәм дә ки кайгыртучан полковник. Эшкә төгәл йөрүчеләрне бик, ә иртәрәк килүчеләрне аеруча ярата. Шуңа күрә бәйрәм саен сәгать өләшә. Ә бәйрәмнәр күп... Ял һәм бәйрәм көннәренең саны ел әйләнәсендә йөз тәүлектән арта... Аннан соң милиция хезмәткәренең эше дә мактаулы, патрульдән исән-имин кайткан саен, сәгать өләшерлек. Райнурның уйларын хуплап бүлмәдәге сәгать йөрешләре көчәйгәндәй булды. Вакыт! Киң юрганның икенче яртысы суынган — хатыны Алсу, инде әллә кайчан торып, кухняда кайнаша. Райнур, ике мендәр арасына кысылган башын күтәреп, кәккүген көчкә тыеп торган сәгатькә карады. Вакыт! Хәзер биш минуттан нәни тәрәзәдән кәккүк бәрелеп-сугылып килеп чыгар да, хуҗасын уятырга оныткан будильник өчен, чаңлы-чаңсыз, көйлекөйсез сәгатьләр өчен үрнәк булып кычкыра башлар. Вак-кыт!.. Көн саен шулай...

— Хатын! — дип өзгәләнеп кычкыруга, камырлы куллары белән нәрсәгә тотынырга белмичә беркавым аптырап торгач, Алсу кире кухняга кереп китте.

— Яна мәллә?!

— Соңга калам, бүген политуку көне. Тиз...

Ул арада Алсу, ике кулына ике электробритва тотып, аны көтеп тора иде инде. Райнурның утыз ике теше сумса турый, ике яңагында ике бритва «камыл чаба». Бу мәшәкать ир белән хатын арасында шулкадәр килешенеп башкарыла ки, хәтта, читтән күзәтеп торучы булса, мондый хәлләр көн саен кабатлана бугай, күнеккәннәр, дияр иде.

Гаиләдәге ызгышлар йә акча күплектән, йә акча юклыктан чыга. Иренең каршы дәшәргә чарасы юклыгыннан файдаланып, Алсу ике бритва гүләвен җиңәрлек итеп кенә тезеп китте:

— Туйдым бу эшеңнән. Юньле-башлы ялың юк. Исән-имин кайтырмы бүген, дип, көн саен утка төшеп көтәргә кирәк. Таптың һөнәр... Хезмәтенә күрә акчасын түләсәләрие, ичмасам! Әнә күршең, уналтынчы заводта токарь гына, йөзлекләрне ай саен башланмаган пачкасы белән алып кайта, акцияләренең бәясе күтәрелә башлаган, ди. Ялы — ял, ашы — аш, эше — эш, ичмасам...

Иртәнге ашка кушып нотык сөйләсәләр, тамак тиз туя икән. Райнур кабыл-тибел әзерләнеп чыгып китү ягын карады. Башка вакытта, политуку буласы көннәрдә, ул бер кат фатир стенасын күздән кичерә иде. Чөнки ике бүлмәле фатирының бер стенасы гадәттәгечә чәчәкле кәгазь белән эчләнмәгән, ә соңгы айлардагы докладлар, вәгъдәләр, карарлар, указлар игълан ителгән газеталар белән тоташтан ябыштырылган иде. Эшкә китәр алдыннан бер кат танышып чыксаң, политукуларда бик җиңел була. Мәгәр, генерал булырга теләгән сержант моның өчен ким дигәндә ике-өч сәгать иртәрәк уянырга тиеш. Бүген Райнурның стенадан газета укып торырлык вакыты калмады.

Ир бусагага утырып аяк чолгавын җәеп салды. Казна итеген киеп өйдән чыгып киткәнче әйтеләсе сүзләр бар иде әле аңа. Алсу Райнур каршысына килеп басты, ашыгырга исәбе, юкса аның шәхси милиционеры бу итекләргә шулкадәр тиз кереп баса, «уф!» дип көрсенергә дә өлгермисең.

— Уф!.. Кичә син алып кайткан зарплатаны квитанцияләргә алыштырып йөрдем. Квартплата түләдем, баланың яслесенә дә түләр чак җиткән иде, язгы пәлтәңнең тышлыгын әйләндерергә бирдем, җир участогы өчен взнос тапшырдым, йорт әйберләрен страховать итәргә килделәр, коттеджлар идарәсенә барып ссуданың бер өлешеннән котылдым...

— Яхшы булган, — дип җөпләде Райнур.

— Яхшы булмый ни, минем акчага яшәргә калгач.

— Минем акчаны бик азга чыгарма әле син. Бушлай кием бирәләр. Ел саен кәчтүнен, күлмәген, ботинкасын, итеген дигәндәй... Аларны кушып сана. Сатып ала калсаң, арзан түгел.

— Мундирың белән мактанма, театрларга киеп барырга да ярамагач... Эш киеме генә ул сезнең өчен. Завод эшчесенә дә комбинезон бирәләр ул...

Озын җөмлә ишеккә кысылып калды.

Әрләшкәндә кешенең йөзеннән нуры сүнеп тора. Хәер, Райнур эштән кайтканчы, Алсуның йөзе тагын нурлана үзе. Аның пыр тузынып йөрүен гаиләдә берәр вакыйга якынлаша дип юрарга кирәк. Гелән шулай ул, иртән-иртүк күчәреннән ычкынган көпчәк шикелле, атылып-бәрелеп бөтерелә дә кичен Райнур эштән кайтуга, менә сиңа сюрприз! Йә танышкан көннәре, йә кавышкан төннәре. Йә улларының туган көне, йә үзенеке. Райнур шушы бәйрәмнәрне барлап куен дәфтәренә теркәгән иде. Ачып караса... бүген Алсуның туган көне. Эш белән мавыгып онытыла күрмәсен, кибеткә кереп бүләк юнәтәсе булыр.

Көн әйбәт бүген, кояшка бер карап алсаң, кәеф күтәрелә. Вак болытлар, итәкләренә капкан утны сүндерә алмыйча, Идел өсләтеп ачык бәке эзләп йөриләр. Ашык-пошык очып килгән каргалар, үз ояларын өнәмичәрәк, тополь ботагына яңа планнар корырга тезелгәннәр, кайберләре үзләрен бик «важный» тота — авылга кайтып китәселәредер инде... Шул каргалар төсендәге бер мәче, капка өстенә менгәч, як-ягына каранып алды да, этләр уянганчы дигәндәй, күрше мәчеләрнең ишегалдына сикерде.

Замполитның рапортына өстәп «Пионерская правда» газетасындагы яңа мәкалә буенча фикер алышкач, профком председателенең паспортлар алыштыру турындагы белешмәсен тыңлап, кичке мәктәпкә йөрүче һәм йөрмәүче бердәнбер егеткә бармак белән төрттереп тә күрсәткәч, политукучылар эш урыннарына таралды.

Урам — милиционерның эш урыны.

Райнурларның зәңгәр билле аксыл «Жигули»е, киң елгага чыккан җилкәнсез көймә кебек, шәһәр агымына иярде. Язгы көннең холкын аңламассың. Политуку беткәнче, кояш инде, болытларга үпкәләп, әллә кая китеп барган. Күк йөзе күгәргән. Көн тоташ күләгәгә әверелгәч, сузан-сузан йортларның, киң бәдәнле агачларның күләгәсе югала икән, кешеләр дә шәүлә ияртеп йөрмиләр.

Игътибар итегез, милиционер утырган машинаның бөтен тәрәзәләре чиста булыр. Тирә-юньдәге тәртипне җентекләп карап барыр өчен киң экранлы телевизор кебек ул тәрәзәләр. Шәһәрнең тигез ритмлы чагы: ашыгасы кешеләр урыннарына барып җиткән, завод-фабрикаларда тыгыз эш сәгате. Маршрутлы таксилар җилкенчәк кенә, трамвай-троллейбуслар да пассажирларны кабаландырмыйча

салмак йөренәләр. Урамда күренгән җан иясе йә пенсионер, йә студенттыр шунда. Күзгә төртерлек артык үзгәреш сизденме — димәк, ритм бозылган, димәк, нииндидер тәртипсезлек дигән сүз.

— Стоп! — дип, имән бармагын тырпайткан иде Райнур, шофер егет шундук аңлап алды һәм бизәнү әйберләре кибете янындагы чуалышка таба руль тотты.

Ишек төбендә чират. Студентлар-пенсионерлар түгел, ә бернинди иҗтимагый һәм сәяси үлчәмгә дә сыймый торган ирләр өере.

— Фу, «Тройной» одеколон саталар. Хәзер дефицит нәрсә ул, әллә хатынның туган көненә бер-ике шешә аласы инде?

— Өстәвенә Парижда чыкканы да булса, — диде шофер егет, Райнурны үртәп.

— Өеңдә берәр шешә хушбуй тотуның зыяны юк, дару урынына булыр, алып килим әле. Озак тормам, — дип, тәвәккәлләгән иде, киредән утыргычка утырды.

— Кемне күзлисең?

— Авылдашымны күрдем, Ансар Субаевны.

— Студент кешегә дә кирәк нәрсә ул «Тройной».

— Сәер төлке. Әнә кара, бер шешә алды инде, ә үзе тагын чиратка тыгылып маташа.

Сержант Райнур, шыпырт кына килеп, Ансарны култыклап алгач, кайберәүләр чиратны ташлап китү ягын карады.

— Сәлам, якташ, артыңнан күзәтеп йөри икән дип уйлама тагын, Алсуның туган көненә бүләк эзләп килүем иде.

— Минем исемнән дә тәбрикләргә онытма.

— Маңгай почмагын үбәрмен инде: «Ансар өчен!» — диярмен.

— Хет теләсәң кайсы җирен үп, минем хакта искәрергә генә онытма.

— Үпкәләү килешми сиңа, Ансар.

— Кем үпкәләгән? Минме?

— Яшьлек дустым милиционер булгач, караклар куып йөрим, дип зарланасыңдыр.

— Үзем сайлаган һөнәр. Бүген булмаса, иртәгә дигәндәй, барыбер җинаятьчеләрне киметер өчен укылган. Шәп практика бу минем өчен, рәхмәт сиңа...

— Үзеңә дә рәхмәт, Ансар.

— Анысы ни өчен тагын?!

— Теге кичне үҗәтләнеп беркетмәләр төзетеп маташмаган булсаммы? Син тынычлап кайтып йоклар идең дә вәссәлам. Ә мин ни эшләргә тиеш? Минем өстә бер «Каракүл» берләшмәсе генә түгел лә.

— Беләсеңме, Райнур, ни өчен безнең илдә җинаятьне киметеп булмый? Беләсеңме?

— Иркенләп җавап бирерлек вакытым юк.

— Алайса, үзем әйтәм. Җинаятьчеләрне сержантлар белән студентлар куып йөри, ә олыраклар шуларны санап утыра.

— Оста икәнсең, бик тирәнгә кермә... Бүген бу чуалышта берәмләп-берәмләп «Тройной» одеколон алып маташуыңның серен белмәс дисеңме? Лотокка кибет эченнән эрҗәләп товар ташып торучы ике егетне мин дә таныдым, шаһитларыбыз. Берсе — Байгушов, икенчесе — Мирзин. Мирзин кибетләргә товар ташучы автохуҗалыкта шофер, әнә теге «Москвич» рефрижераторы анықы. Ә Байгушов аңа ярдәм итеп йөри, вакыты иркен, ул бүген икенче сменага бара. Бу ике егет арасында бәйләнеш барлыгы көн кебек ачык. Болайга киткәч, эзләренә төшәрсең, Ансар! Ярый, комачауламыйм, эшеңә тыкшынмыйм.

Алар очраклы рәвештә күрешкән кешеләр сыман гына кул биреп саубуллаштылар. Ләкин Райнур китәргә ашыкмады.

— Ансар, әгәр Алсуның туган сәгатенә икәүләшеп кайтып керсәк, ә?! Их, сөенер иде карчык! Классташларны бик сагына ул. Әллә тәвәккәллибезме, якташ?!

— Миңа ни, мәҗлесегездә ятим бала кебек утырырмын шунда...

— Ниткән мәҗлес, алай зурлап үткәрмибез, юбилей түгел лә. Ятим дигәннән, теге кызың белән бергә килегез. Бәйрәм көнне кунак сыя ул.

— Венера белән арабыз бозылды.

— Минем аркада...

— Бәлки, аңлашыр да идек, сөйләшергә теләми.

— Гаепле икәнмен, үзем җайлармын. Бүген кич Венера белән икегезне табыныбызның түр башында күрмәсәм, исемем Райнур булмасын... Тәк, кичке алтыда нәкъ шушы урында очрашабыз. Пока!

Райнур алтынчы ярты тирәсендә тулай торакка килеп керде. Козырегы матчага текәлгән фуражкалы сержантны күргәч, яшьләр арасында «каенана» дигән кушаматы телдән телгә күчкән вахтерша ханым аягүрә басты. Сөенеченнән солдатларча сәлам бирергә дә уйлаган иде, кулбаш сөягенең тамыры сузылыр дип курыкты.

— Сержант Асланов! Махсус задание белән йөрим. Менә таныклыгым, — дип, Райнур куен кесәсенә тыгылып өлгермәде, вахтер аның кулына асылынды.

— Син үзең тере дукамент бит, җаным. Милиционер күрсәләр, безнекеләр шым булалар, җаным. Юкса бик кыен урынга эләктем. Сул якта кызлар яши, уң якта ирләр блогы. Ә төн уртасында, кайсы ягың уң да, кайсы ягың сул икәнен аңларлык түгел. Әллә ни рәвешле тулганышып бетәләр. Менә шуңа күрә әйтәм, җаным, әгәр буйдак милиционер дусларың артса, монда алып кил, кәләшле итәрбез үзләрен. Хет гозер дип аңла моны, җаным, хет теләк дип кабул ит.

— Тырышырбыз, — дип кырт кисте Райнур, сүз куертырга вакыты юклыгын аңлатырга теләп, — 212 нче бүлмәне генә әйтегез дә...

— Ирләребез сулга йөри, дидем, баскычтан икенче катка менгәч тә, сулга борыл, җаным. Уңга китә күрмә, анда ирләр...

Бүлмә ишеге нык ябылган, тартып карыйм әле, дип, тоткага ябышкан иде Райнур, кәгазь төргәген култыклап, бәби итәкләре белән җил чыгарып, бер активист кыз үтеп китте:

— Катырак шакыгыз, иптәш милиция, карт кызлар колакка катырак булалар.

Тәки ачылды ишек дигәннәре. Бүлмәдә йозак саен бер кыз. Ансарның тасвирлавыннан чамалап, Райнур дүрт кыз арасыннан Венераны бик тиз танып алды.

— Исәнмесез, Венера!

Җавап урынына Венераның кырыс тавышы яңгырады:

— Кызлар, кайсыгыз милиция чакыртты?!

Дүрт кыз бик нык көләселәре килгән кешеләр сыман хихылдаган булдылар.

— Венера, бүген минем эш сәгатем бетте инде, формадан килеп керүем өчен ачуланмагыз. Срочно сезнең ярдәмегез кирәк, — диде Райнур, кызларның ерык авызлары ябылачагын алдан ук сизеп, — икәүдән-икәү генә сөйләшәсе сүзләр бар иде.

Өч кыз, әйткәнне дә көтмичә, аякларындагы җиңел чүәкләрне урам киеменә алыштырдылар.

— Юк, юк, — дип, аркылы төште аларга Райнур, — безнең үзебезгә урамга чыгып сөйләшергә кирәк, кеше ишетмәсен.

Чыгып барышлый гына искәрде Райнур, коридор буйлап атласаң, бүлмә саен бәрәңге исе килә икән: кыздырылган, томалап пешерелгән, бөтен килеш көйдерелгән, шулпалы бәрәңге исе аңкып, ашыйсыны китереп тора. Әйе шул, армиягә киткәнче Райнур да Алсулар торагына «чикмәнле бавырсак» ашарга еш килә иде. Дөньяда гел бәрәңге белән генә яши ала торган ике төр тереклек бар: берсе аның — тулай торак буйдак-сазамыклары, икенчесе — колорадо коңгызы...

Әгәр Венера янында Райнур урынына Ансар булса, ул әүвәл урамдагы пейзажны күздән кичереп телгә күчерер иде. Ишек төбенә җыелган тамчыларның кичке салкыннан шүрләп каядыр югалуларын, сыерчыклар кайтасыны алдан ук сизеп нервылары какшаган чыпчыкларның урам малайларыдай усал сызгырышуларын, машина көпчәкләре астында ярмаланып уалган иске кар шыгырдавын һәм тагын әллә ничаклы үзгәрешләрне сизгән булыр иде Ансар... Венера да бу үзгәрешләрнең һәммәсен тоеп-күреп торды.

— Синең ярдәмеңнән башка эш бармый. «Каракүл» берләшмәсендә безне кызыксындырырлык бер гражданин бар, беләсең син аны, бергә эшлисез.

— Әгәр Ансар исемле студент дисәгез... Аның белән безнең арада берни юк.

— Берни дә юкмыни, Венера?!

Райнурның елмаеплар торып, тавышларын йомшартып, күзгә текәлеп каравына Венера ачылырга мәҗбүр булды.

— Мин бит аны җүнле кеше дип уйлаган идем, иптәш сержант, юрфакны тәмамлап киләм, дигәние үзе.

— Уйларың дөрес, гел шулай уйла.

— Ничек инде?!

— Ансар кебек егетләр күбрәк тусын иде әле! Күңеле саф, кулы чиста, сүзе хак аның. Әйбәт кешене күп итеп мактап булмый, кыскасы, рәнҗеткәнсең син аны, Венера. Мәсьәләнең асылына төшенмичә торып егеттән йөз чөерәләрмени?!

— Рәнҗеткән дип, йөзенә төкермәгән лә, укасы коелмас.

— Ансар махсус эш белән йөри... Ни, диплом практикасы үтә. Профессиясе сәеррәк аның, аңлыйсыңдыр...

— Ник соң үзе шулай аңлатып бирмәде?

— Тыңларга теләмәгәнсеңдер. Яраткан кешене аны бер күрүдә үк аңларга кирәк. Фатир хуҗасының каһәрләвенә ышанып, нинди мировой кияүдән коры кала язгансың.

— Язган гынамы, югалттым инде, хәзер ул мине гафу итмәс...

— Бик теләсәң, кавыштыра алам мин сезне. Әгәр һәр сүземне тыңлап, мин кушканны үтәп, кирелә́нмичә, артык эреләнмичә түзсәң... бүген үк, хәзер үк очраштырам. Ризамы?

— Риза...

— Тәк. Әнә теге «Жигули»ны күрәсеңме?.. Арткы утыргычына кереп утыр. Мин киосктан газеталар алып киләм, яңа указлар игълан ителмәде микән?

Венера, зәңгәр билдәмәле «Жигули»ның герб сурәте төшерелгән ишеген ачып җибәрүгә, Ансарны күреп «аһ!» итте. Ансарның «Исәнме, Венера!» дип ялынуына, һич югы, «Сәлам!» дип кенә булса да җавап бирергә кирәк иде, ә ул биш минут буена телсез калды.

— Яшьлек дустың милиционер булгач, рәхәт, ә?! — диде Венера, ниһаять, хәлне аңлап.

— Алам дигәннең авызы яман.

Райнур килгәндә, Ансар белән Венера, иңгә-иң терәлеп, нәрсә турындадыр хыялланып утыралар иде. Сөйләшкән сүзләре ишетелмәсә дә, йөзләренә караганда, аларның, һичшиксез, мәхәббәт хакында аңлашкан минутлары икәнлеге күренеп тора.

— Бик беләсегез килсә, бу машинада мәхәббәт сүзләре яңгыраганы юк. Әйдә, сайрашыгыз. Ә машина сезне-безне хәзер Аслановлар гаиләсенә алып кайтыр.

— Кая, кая?

— Райнурларга, Венера. Райнур минем якташ, классташ, хезмәттәш тә.

— Ай-һай, шома егетләр дә соң сез.

— Без дигәнчә барып чыкса... ялгышмадык дип исәпләрбез.

— Әгәр барып чыкмаса...

— Ул чагында... — дип, җөмләсен уртага бүлде Ансар, — мине утырталар.

Венера аптыраудан аягүрә сикереп тормакчы иде, «Жигули» түшәменә башы бәрелеп, кире утырды.

— Абау, нык авыртты.

— Көньяк халыклары башлары белән сулы чүлмәк күтәреп йөри алалар. Вәт, ташбаштыр алар?!

— Баш чүлмәк ташыр өчен түгел ул. Шаяртмагыз, Райнур... Ничек инде Ансарны утырталар? Ни өчен? Тәки гаебе бармы? Ник миннән яшерәсез? Ышанмыйсыз икән, сөйләргә теләмисез икән... Юлларыбыз аймыл, туктатыгыз машинагызны, төшеп калам.

— Кызма әле, кызый, кеше юатып арган инде, болай да... — диде Райнур, тизлекне арттырып. — Йә, Ансар, кайсыбыз сөйләп бирә, синме, әллә минме?

— Син сөйләп кара, Райнур!

— Тыңла, Венера... Ансарның синең янга килеше булган, ялгышмасам, эштән каршы алырга.

— Һәм беренче тапкыр...

— Бүлдермә, Венера. Әйе, вәт, Ансар сине көткән арада, «Каракүл» тирәли вакыт уздырып йөри. Шулчак ул запас капка янындарак таш койма өстеннән эленеп калган бау очын күреп ала һәм бала-чага кебек аны тартып карый. Бауның икенче очына ярты капчык бүрек бәйләнгән икән, Ансар алдына килә дә төшә... Без, гадәттәгечә, мех берләшмәсен башкаларга караганда күбрәк күзәтәбез.

— Тик торгандамы?

— Юк, Венера, «Каракүл»дән күпләп мех югала дигән сигналлар ешайды, күзәтүне көчәйтергә, диелде. Ул көнне мин булмасам, барыбер Ансарны кем дә булса эләктерәсе иде. Чөнки бау турында шылтыратканнар иде инде.

Бу юлысы Ансар түзмәде.

— Күрү белән сезгә шылтыратканнар, бауны тартып карамаганнармы?

— Алар да шул, Ансар, синең кебек түзмичә капчыкны сөйрәп төшергәннәр. Без, тизрәк «табылдык»ны үз урынына куеп, бауны яңадан ыргыттык. Чын угрыларның алырга киләсе бардыр, дидек. Ансар килеп тагын бөтен эшне бозды. Аның юрфакны тәмамлап маташуын бөтен авылыбыз белә. Тукта, мин әйтәм, гөнаһсыз Ансарны эзләнүгә җигик әле, укымышлы кешенең белеме ярап куяр, дим. Күреп торасыз, дөрес иткәнмен. Инде бүгенге көн тәртибенә килгәндә, эш сәгате тәмам. Хатынымның туган көне икәнен онытмагыз! Белеп тор, Венера, минем Алсу Ансарның яшьлек мәхәббәте.

Шулаймы дигәндәй, Венера Ансарга текәлде.

— Райнур гомер буена дуслык белән мәхәббәтне бутады. Мин мәхәббәтен югалтып йөрүчеләрдән түгел, яраткан кешемне беркемгә бирмәм. — Һәм Ансар, дустына сиздерми генә, Венераның җылымса кулын кысты.

Чәчәк сатучыларны куандырып, яз килә...

Райнурларга кайтасы юл чәчәк сатучылар яныннан үтә. Кул җылысына алгысынып, авыз ачмасыннар дип, лалә таҗларын тегәрҗеп белән бәйләп куйганнар, кояш баеп көн сүрелгәч, ул җепләрне сүтә башладылар. Төнгә каршы чәчәк үзе дә йомыла. Сатылып бетмичә калганнарын иртәгә тагын бәйләрләр. Яз кеше гомерендә бик кадерле чор, аның ашыктырып үстерелгән чәчәкләре дә бик кадерле... Сатучы кулындагы яшел чиләктән Ансарның бер айлык стипендиясенә торырлык бәйләм алынды. Өч кеше кулына өчәр чәчәк тиде...

Алсу, ишекне ачып җибәрүгә, нәрсәгә сокланырга кирәген онытып, исен-акылын җыя алмыйча торды. Әле үзенә дип үрелгән өч бәйләм чәчәккә омтылды, әле мәктәпне тәмамлаганнан бирле күрмәгән классташына сарылды, хәтта Ансарга ияреп килгән сөйкемле кызга — Венерага да елмаеп өлгерде.

Әгәр килгән кунакларны җәлеп итәрлек ялтыравык җиһазларың, алтынга манылган савыт-сабаларың, чәчәкле-чуклы китапларың, һич югы, тыелган видеотасмаларың да булмаса, чәй кайнаган арада кунакларыңны алдарлык шаян малай үстер.

Райнур бердәнбер (төпчек түгел) улына Садир дими, иркәләбрәк яңгырасын өчен «Садик» дип дәшә.

— Садик, эзлә, өй эчендә шоколад бар!

Райнур үзенең Садирын милиционер итәргә тели. Биш яшьлек тиктормас тәмлетамакның шәхси ихтыяҗларын исәпкә алып, көн саен күнегүләр үткәрә.

— Садик, эзлә! Өй эчендә шоколад бар.

Райнур шоколадны үз куллары белән яшереп куя да улының эзли-эзли әлсерәгәнен күзәтеп сөенә. «Югалган әйбер эзли торган җирдә ятмый», «Син гел бер урыннан эзлисең», «Шоколадны табуы җиңелрәк...», «Көндез өй эчен игътибар белән күзәтеп йөрергә иде» кебек күрсәтмәләре белән нәни «милиционер»га эзләргә булыша. Әтисе яшенә җиткәндә, Садир ким дигәндә милиция капитаны дәрәҗәсенә ирешергә тиеш. Райнур шулай тели, династия дигән сүзне шулай гына кабул итә ала ул.

Ниһаять, яшерелгән шоколад табылгач, чәчәк бәйләме тирәли табынга чакырдылар. Кулыңа кашыкчәнечке тоткач сөйләшүдән туктасаң, ашап-эчәргә генә килгән икән дип уйлarлар. Бүген Алсуның бәйрәме, хатирәләр өч кеше арасында «Хәтерлисеңме?», «Исеңдәме», «Теге чакны»... дип башланып китә. Дүртенче кеше — Венера — кайсын тыңларга белми. Садир да шул хәлдә икән:

— Әни, синең туган көнең ничәдә бетә? Аннары Ансар абый белән Венера апаның туен башлыйек...

Искә алулар шушы минутта кырт өзелде. Венераның тел өстендә калган бер йотым сөтле чәе эремчекләнеп тамак төбенә утырды... Соңгы бишьеллыкта болай каты итеп тамак кырган кешене ишеткәне юк иде әле Райнурның.

— Һи, якшәмбе көн яралган нәмәрсә, апаңны әнә теленнән яздырдың. Бүген-иртәгә кулга алынырга торган Ансарга кияүгә чыгып, тулай тораktагы җәннәтеннән колак каксынмыни ул?!

— Минем алай дигәнем юк...

— Ә нәрсә дигәниең?

— Әйтмәдем...

## Ике чиләк ислемай

Кем сүзедер, имеш, шәһәрләрнең берсендә эксперимент үткәргәннәр, ди: сизмәгәндә генә барлык каравылчыларны тәүлек буена эшкә чыгармаганнар. Статистлар шундук хисаплап өлгергәннәр — каравылчысыз төндә дәүләт милкен әзрәк урлаганнар, ди... Әле каравылчыларның үзләренә түләнә торган хезмәт хакын да кушып санасалар, югалтуларның күплегеннән компьютерлар телсез калыр иде... санамаганнардыр.

Каравылчы белән йозак арасында охшашлык бар, алар икесе дә мөлкәт саклар өчен. Аермалары да шунда ук, йозак салкын тимер кисәге, ә каравылчының җаны бар: берәр җылы сүз әйтсәң, йозак кебек йомарланып тормас, хәзер йөзе ачылыр. Каравылчы янындагы кайбер ишекләргә йозак эләләр...

— Язит Язилевич, мине бүген «Исле гөл»гә җибәрегез әле.

— Кызык кеше син, Субаев, башка резервныйлар кая җибәрсәң, шунда атлыгып торалар. Ә син... Әле, мех берләшмәсенә җибәр, дип ялвара идең, инде «Исле гөл» фабригына телисең! Ислемай иснисең килдеме? Күп иснәсәң, туйдыра ул. Нәрсә калган анда сиңа?

— Өйләнәсе елым быел, сайланып калырга кирәк.

— «Исле гөл» фабрикасы дигәч тә, әллә кызлары хуш иследер дип уйлыйсыңмы?

— Язит Язилевич, җибәрегез инде, күреп кайтыйм.

— Бар. Тик кара аны, Язит абыегызга берәр хушбуй җибәрәм, дип кыстарлар, ала күрмә!

Кыш белән яз әбәкле уйный. Куыша торгач, көн уртасындарак яз кышның эзенә баса һәм кар астыннан гөрләвекләр йөгереп чыга, тал бөреләренә гыйшык керә, купшы кызларның җиңел пәлтә чабуыннан күренеп торган юка күлмәк итәкләренә тамчылар чәчри, малайларның чалбар балаклары җеби... Ә кайвакыт, бу тирәдә йөрмичәрәк торсана дигәндәй, кыш төн уртасында язны куып тота да кирәген бирә. Һәм гөрләвекләр, ерак сәфәрдән гайрәтләре чигеп, бозга әверелә, тал бөреләре кысыла, кызлар җиңел пәлтәне салып якалысын кия, ә тамчылар, җиргә төшәргә куркып, түбәдәге сөңгеләргә ябышып кала.

Календарьга карасаң, кыш өчен күңел әрни, язның өченче аена кердек. Сыерчыклар, алып кайткан җырларын җырлап бетереп, авыл хуҗалыгы эшләренә керешерләр — берәр атнадан. Кеше өстендәге кием-салымга карап та ел фасылының җылыга авышуын тоясың. Бүрек сатучыларга сезон ябыла. «Каракүл»некеләр урламыйчарак торырлар микән? Угрының кулы тик тормас шул... «Табышсыз кайткан көннәреңдә ничек түзәсең?» — дип сораганнар бурдан. «Яңа көн итегемне күршемнең ишегалдына атам да сиздермичә урлап алып чыгам, шунсыз йоклый алмыйм», — дип җавап биргән теге. Бүреккә кызыгучылар туктамаслар, тавык фермасына иярәшкән төлке шикелле, җае чыккан саен ояларына ташырлар.

Ике капка урам аркылы күзгә-күз карашып тора: берсе — «Каракүл», икенчесе — «Исле гөл» фабрикасы. Һәр ике капка да игезәкләр сыман охшаш. Бары тик әрдәнәләп өелгән бихисап күп һәм төрле фасондагы ислемай шешәләре өеменнән чамалап кына кайсы капканың кемнеке икәнен белеп була. Ул шешә өемен күз алдына китерер өчен иллеләп вагон йөкне бер күчкә өеп, бер-ике вагонын чәчеп, өч-дүрт вагонын ватып сибәргә кирәктер.

Зур тимер ишекнең ачылышына, борынга йөз төрле хушбуй исе килеп бәрелде. Хуш истән күңел сөенә хәтта.

— Аромат, нинди аромат! — дип, берөзлексез кабатлады Ансар. — Төне буе туйганчы иснә, акча сораучы юк.

Спирт белән эш итүче урыннарда каравылчы итеп хатын-кызларны куялар. «Исле гөл»нең каравылчыбикәсе, Ансарны күргәч, сыерчык оясы хәтле генә пыяла бүлмәсеннән чыкты, биленә таянып басты: аяклары бер-берсе алкынсу буасына каккан субайлар кебек, җиңе сызганылган, беләкләре каезланган сөян төсле — үзе ак, үзе ялтырый, куллары бокс бияләен учына сыйдырырлык.

— Субаевмы?!

Мондый тавыш белән сорасалар, фамилияң Чуртов булса да, Субаев диярсең.

— Шылтыратты Язит Язилевич, сезгә каравылны ныгыту өчен җитез егет җибәрәм, диде. Бүген кичкырын ишегалдына цистерна китерделәр — алтмыш биш мең литр спирт! Бушатып өлгермәделәр. Сиңа башка эш йөкләмәм. Шул мичкәне таң атканчы исән-имин саклап чыксаң... Мин монда, телефон төбендә утырырмын. Ник дисәң, «проверящийлар» килүе бар. Шиклерәк нәрсә сизсәң, цистернага тимер белән сук, тавышына очып килеп җитәрмен, минем кулга эләксәләр... Сорауларың бармы?.. Ярый, ишегалдын өйрәнә тор. Сәгать унбергә хәтле цехлар эшли, тыныч.

— Ишегалдыгызда адашмам микән?

— Капка каравылчысына ияреп йөр, аның барыбер эше юк.

Капка каравылчысы — алтмышны үткән, җитмешкә җитмәгән агай иде — Ансарны күрү белән күзлеген алыштырды.

— Абый, мине кечкенәгә санавыгызмы, нык зурайта торган күзлегегезне кидегез?!

— Һай, энем, һай, берүк көлдерә күрмә, юкса бума ютәлем кузгала. Кичә генә Мирзинның анекдотыннан көләргә тотынган идем, ютәлдән тукталыр хәл юк, тәки «скорый» чакыртып укол кадатырга туры килде. Син студентмы?

— Әйе, абый.

— Яшәртеп дәшкән буласың, рәхмәт инде. Бу күзлегемә аптырама, бик җаваплы минутларда гына киям мин аны.

— Кешеләр белән танышкандамы?

— Һәм капкадан кереп-чыгып йөргән машиналарның боерык кәгазьләрен тикшергәндә. Әйдә, фабриканы кабул ит, энем... Менә бу цехта пар белән эш итәләр, ислемай шешәләрен пешеклиләр. Алга барабыз. Монысы лаборатория, әнә тегендә ишегалды калай мичкәләр белән тулганмы? Ул мичкәләрдәге сыеклыкны композиция дип атыйлар. Бер мичкәгә... «Ландыш» композициясе дип язылган, димәк, ландыш исе килеп торган ислемайлар, хушбуйлар ясарга китә дигән сүз. Әнә — «Сабантуй», «Тройной», «Сирень» композицияләре... Мичкәләрнең барысы да лаборатория аркылы үтә.

— Теге цехта нәрсә?

— Әкренрәк атла, мин өченче-дүртенче тизлекләрдә йөри алмыйм. Аяклар сызлый. Элек Берлинга хәтле җәяү йөри идек... Хәзер шулар чыга торгандыр инде... Теге цехта композицияләр спирт белән бутала.

— Әзер продукцияләр цехы кайда?

— Менә ул — эче тулы ислемай, чиләге-чиләге белән агызып алырга була. Бездә ике сменалы эш. Төнге унбердән соң бу цехның ишегенә бозау хәтле йозак эленә.

«Исле гөл»гә килгәч, хуш исле җилләрдән күңел сөенгән иде, инде туйдыра башлады.

— Сиңа ике киңәшем бар, энем. Каравылда торганда угрыларга юлыксаң, икегез дә куркып калырсыз: син дә, угры да. Мондый мизгел озакка сузылмый, ике куркакның берсенә йөрәк керә — батырая. Алданрак йөрәклән, чөнки дөреслек синең якта. Икенче киңәшем... Угры күрсәң, куып кына чыгар, тота күрмә... Куян шәп йөгерә, бик теләсә, төлкене куып җитә ала. Ләкин минем әле төлке тоткан куянны, генералын кулга алган сержантны күргәнем юк.

— Абый, сезгә ничә яшь хәзер?

— Яшьнең күплеге белән мактанмыйлар. Атлаганда уфылдап, сулаганда гыжылдап, бөкре күләгә ияртеп йөрүчеләрнең барысы да минем яшьтә, кем, энем. Ярый, пост сәгатем тулды. Кичке алтыдан соң капка аркылы транспорт йөрми, иртәнге тугызларда килеп җитәрмен.

— Абый, абый, теге машина фабриканыкымы ул?

— «Москвич»ны әйтәсеңме? Сәүдә гаражыннан, Мирзинныкы. Машинасын күрсәм дә көләсем килә. Бик җор егет. Ремонт белән чиләнә. Еш ватыла. Ватылгач, калдырып кайтып китә. Иртән-иртүк за-

пас часть алып килер ул, тумблерын алыштырасы, диде. Капканы ачып чыгарырсың шунда. Ну, Мирзин, искә төшсә, көләсе килә... Ә мин көлгәндә, машиналарның сигнализацияләре эшли башлый...

Һәм бабай бума ютәлен тыя алмыйча китеп барды.

Икенче смена таралышыр алдыннан әйләнеп керде Ансар. Керсә, каравылчыбикә көтеп тора икән үзен.

— Җиңнәреңне сызган, студент, эшкә тотынабыз. Әнә берәүсе килә дә, эшен иртә бетергән... — Каравылчыбикә ул эшчене ике кулын сузып каршы алды. — Кая әле, бәгырькәем, куен кесәңә тыгылып карыйм. Әһә, шампунь «Особый». Әгәр икенче кесәңнән дә кулыма ияреп чыкса, студент акт яза тора. Әһә, бәхетең икән, калган кесәләрең буш. Тагын эләксәң, кызганыр димә. Бар, юлыңда бул!

— Тентергә бик нык өйрәнеп китеп, трамвайларда ялгыш кына кеше кесәсенә керә күрмә тагы... Шампуньны бир инде, үзеңнеке мәллә?!

— Әле син, рәхмәт әйтәсе урында... китер әле пропусканны!

— Ярый, ярый, апа, рәхмәт, ачуланма, гаеп итмә, үпкәләмә...

— Күптән шулай диләр аны. Чәчеңне кер сабыны белән юарга өйрән.

— Ә синең фетр эшләпәң ник бүлтәйгән? — дип каршы алды ул икенче эшчене. — Һи, «Наташа»ны шунда яшерәләрмени? Кулыңа гына тотып чыгарлар...

Өченче эшче каравылчыбикәнең күзгә карап кесәләрне күрә торган карашларыннан шиңеп төште.

— Нәрсә, туймас җаным, «Бүләк»нең бөтен наборын берьюлы алып чыгыйм дип тырыштыңмы? Кешеләр әнә берәмләп кенә урлый. Бизәкле тартмага салмасаң, бу ислемайларның хакы бер тиен... тартмасы кая? Яле, бу кесәңә бигрәк калын дәфтәр кыстыргансың, стена газетасы журналисты түгелсеңдер ич?.. Сүтелеп җыела торган булгач рәхәт шул, бөклисең дә кесәгә саласың... Бар, күземә күренмә!

Күп еллар буе бер урында каравылда торганнарга сабырлык бирсен, дип шаккатып тора Ансар. Болай тентү өчен йөрәк кирәк. Ә бу каравылчыбикә җитез, үз эшен бигрәк яратып башкара. Бер кешене дә кул тидермичә үткәрми.

— Кил тизрәк, вакытны алма, оялып торма. Синең җиң эчеңдә гел берәр шешә эликсир була торганые. Сулышыңны өрмә, зинһар, туйган ул спирт исеннән.

— Ташладым мин ул гадәтне. Ышанмасаң, менә кара, җиңнәрем буш.

— Авызымдагы тешләремә дә ышанмыйм мин, тәмлерәк ризык капсам, телемне тешли... Дөрес, җиң эчең буш... Һи, җитмеш сумлык эликсир өчен җитмеш долларлык итегеңнең кунычын бозгансың.

Ә колакчасын ияк астыннан бәйләгән бәләкәй иргә кул да тимәде.

— Чыгарып сал!

— Буш кул белән чыгып барам.

— Ату мин сине белмим ди. Чыгар, диләр, чалбар төбеңә җирәнмичә кул тыгар хәлем юк. Сиңа әйтәм!

— «Памперс» бит ул...

— Алыштыр...

Теге ир читкә борылды да бер шешә «Геракл» хушбуе чыгарды.

Кыскасы, соңгы кеше итеп цех начальниклары да чыгып киткәч, өстәлгә тау чаклы хуш исле товар өелеп калды.

— Уф! — дип, тирән итеп авыр сулап куйды каравылчыбикә.

Ансар аның авыр сулышы җиңеләйгәнен көтеп торды.

— Инде боларны кая куябыз?

Каравылчыбикә әүвәл елмаюын сиздерде, аннан җәһәт кенә җитдиләнде.

— Башта исәбен белергә кирәк.

— Санап тордым, сиксән дүрт флакон.

— Җөп сан икән... Мин үз эшемне эшләдем, акт язу синнән. Икешәр данәдән сиксән сигез акт.

— Тотылган кешеләрне кайтарып җибәргәч, ничек төзисең ди ул актны, ичмасам, таныклыкларын алып калмадыгыз?!

— Вәт. Тезеп куясы шушында сиксән дүрт кешене, төне буе сорау алып акт язып утырасы. Ә фабриканың ишегалдын, мичкәдәге спиртны кем саклар?

— Белмим шул...

— Син белмәсәң — мин беләм, китер портфелеңне. Сиксән сигез икегә төгәл бүленә ул.

Һәм каравылчыбикә тентеп җыйган байлыкны ком чүмәләсе кебек итеп кенә беләге белән ике өемгә аерды.

— Хәзер артың белән борылып бас... Бу күч кемгә?

— Икесе дә сезгә, — диде Ансар, ачуын сиздермәскә тырышып.

— Миңа кеше өлеше кирәкми. Эше дә, ашы да уртак тиеш.

— Нишлим ди мин шушы хәтле ислемай белән, чәч кистергәндә дә сибәргә яратмыйм... Кырынгач, сөртенмим.

— Иптәшләреңә өләшерсең. Каян алганыңны әйтмә.
— Фатирга алып кайтыйммы?
— Хуҗаңа бир, сатып керсен, стипендияңә өстәлер.
— Кирәге юк.
— Кибеткә тапшыр. Ярты бәягә кайсы сатучы да ала.
— Кирәге юк.
— Нинди отказ ди ул! Тот сумкаңны!

Ансар, теләсә-теләмәсә дә, өлешенә тигәнне портфеленә тутырырга мәҗбүр булды. Соңыннан хәл ителер әле. Каравылчыбикәнең мондый гадәтләре төзәтелер. Ләкин бүген түгел. Бүген теге машинаның серенә төшенәсе бар...

Ул урам салкынына ашыкты. Вагон мичкәсе алтмыш биш мең литр сыйдырышлы булса да, сөялеп торырлык урыны юк, тимер салкыны пәлтә аркылы бик тиз үтеп керә. Ирексездән йөренергә туры килә. Дөресен генә әйткәндә, биек-биек коймалар, чәнечкеле тимерчыбыклар аркылы үтеп, бу тирәне белмәгән кемнәрнеңдер завод-фабрика мөлкәтен урлауларына ышанмый Ансар. Әгәр урлыйлар икән, бауның икенче очын, һичшиксез, завод-фабриканың үзеннән эзләргә кирәк.

Ансар машина янына килде. Бу «Москвич»ның номеры таныш иде аңа. Бизәнү әйберләре сата торган кибет янында күргәне бар. Юрфак студентын төрле техника белән эш итәргә, йөртергә, хәтта сүтәргә өйрәтәләр, әз-мәзләп, әмма кирәгенчә... Ныклап өйрәнәсе килгәннәргә тормыш дигән мөгаллим үзе өйрәтер, диләр.

Күпме азапланып кабина ишеген ача алмады Ансар — ачкыч белән бикләнгән. (Монысы өчен юрист белеме генә җитми, машиналар чәлдерүче булу кирәк.) Китәсе килми бит «Москвич» яныннан. Шөкер, кузовның ике яклы ишеге җиңел ачылды. Тыштан кечкенә шкаф кебек кенә күренсә дә, эче ярыйсы ук биек икән тагы, бөкрәергә иренмәсәң, йөреп тә була. Киң ачылган ишек аша баганадагы көчле лампа нуры яктырып тора: артык нәрсә күренми, тузан да тузан гына. Тузан белән сөремләгән егерме литрлы канистраны абайлап алды Ансар. Запас бензин йөртәләр микән? Кызыксыну дигән нәрсә өметне куалап тора. Ансар канистраны күтәрде — буш. Бөкесен ачып иснәп карады... Уйга калды... тагын иснәде, тагын, тагын... Хушбуй исен бензин исеннән аерыр өчен дегустатор булу кирәкми. Әллә Мирзин дигәннәре «Москвич»ка бензин урынына хушбуй гына саламы?.. Машинасы да ватык түгелдер әле, логика буенча шулайрак килеп чыга.

Ансар үзен бүгенге төннең хуҗасы итеп тойды. Ишегалдында башка кеше юк. Димәк, серле билгесезлек Ансарга буйсынырга тиешле... Ян тәрәзәнең кыек өлгесен каера торгач, тупсалы пыяла бигеннән ычкынды. Инде кулны тыгып кабина ишеген эчке яктан ачасы гына... Аккумуляторы яңадырмы, суынып майлары куерса да, двигатель тиз кабынды, бер-ике тапкыр төчкереп күрсәткәч, тигез, күңелле гөрелте белән эшләп китте... Артыгы кирәкми. Ансар, двигательне сүндереп, ишекләрне элеккегечә бикләп калдырды. Димәк, цехларда беренче смена башланганчы, капка сакчысы постка басканчы, Мирзин иртән-иртүк килә... Аны монда беләләр, үз итәләр. Каравылчыбикә шикләнми үзеннән. Канистраны хушбуй белән ничек тутыра соң ул? Көндез үк цехтан алып чыгып яшереп куямы? Ә инде иртүк килгәч, канистрага бушатып — өйгә... Иртән цехлар ачык булмагач, каравылчыбикә машинаны тикшереп чыгаруны кирәк дип тапмый... Юк, Мирзин канистраны иртән килгәч тутыра... Ачкыч яратып цехка керә, бер тәңкә көмеш юанлыгы торбадан кирәгенчә агызып ала. Янәшәсендә генә «Консул», «Командор», «Геракл» кебек кыйммәтле хушбуйлар булыр. Ләкин Мирзин барыбер «Тройной»ны сайлап алыр. Ни өченме? Арзан товар үтемлерәк була. Кибетләрдә хушбуйны чүмечләп сатмыйлар, ул сыра түгел. «Исле гөл» фабрикасының капка төбендә теләсәң күпме буш шешә әрҗәсе-әрҗәсе белән аунап ята, кирәгенчә күтәреп кит, бушлай ул. Канистраны вак шешәләргә бүлеп салырга өйдәгеләр булыша ала. Вак эш, әлбәттә, шырпы сыярлык кына гурласыннан тамызып ике йөз граммлы флаконны тутырып кара әле син!.. Ләкин Мирзин кебекләр аның чарасын табар: аптекадан ике йөз грамм сыешлы шприц сатып алырлар да шешә саен кадарлар. Куен кесәсенә салып алып чыккан этикетка кәгазьләрен ябыштырсаң — эше бетте, тауарга әйләнә, кибетче дусларыңа илт тә бир...

Ансар әзер продукцияләр цехының ике канатлы зур ишегенә сокланып карап торды — бу кадәр авырлыкны тупсалары ничек күтәрә аладыр?! Ил нужасы ишекләрдә... Ишекләр тыгыз ябылган, идән белән ике арада күсе йөрерлек тә ярык юк. Ишек канатларын алкалы йозак тыеп тора. Мондый ярты потлы йозаклар сатылуда беткәннән бирле кибетләрдә ике-өч буын сатучы алышынгандыр инде.

Җентекләбрәк карый башлагач, тагын бер нәрсә сизелде — йозакны җыеп торучы кендекләр заводта эшләнгәнчә түгел, кулдан чүкелгән. Димәк, бу йозак күптән түгел генә төзәтелгән. Ачкычын югалткач, сүтеп яңадан җыйганнар. Алкалы йозакларга ачкыч ясау өчен аны сүтеп җыярга туры килә. Ачкычы чынлап югалганмы? Ачкыч бервакытта да югалмый, җиргә төшсә төшәр, суга батар, яшергән җирдә онытылыр, мәгәр юкка чыкмас, кулдан кулга гына күчәр. Югалган ачкыч Мирзин кулында булыр!..

Ансар, үз-үзеннән имтихан алгандай, вакыт-вакыт бер сорауга җавап эзләде: ике чиләк ислемай белән ярты капчык бүрек арасында, Байгушов белән Мирзин арасында уртаклык бармы? Бар! Алар икесе ике төрле җирдә эшләсәләр дә, чынлыкта исә юллары бер. Димәк, Мирзинның эзенә төшү — ул Байгу-

шовның сукмагына чыгу дигән сүз. Бүген инде аз гына нәрсәгә ирешәсе калды, «Исле гөл» капкасыннан чыккан чакта, инструкциягә туры китереп, Мирзинның «Москвич»ын тикшерергә. Ул машинаны «төзәтергә» иртәнге дүртләрдә килеп җитә, диделәр, ә Ансарның әле эш сәгате сигезгә кадәр, вакыт җитәрлек...

Төннең бер җирендә теләсә нинди сакчыңны да егып салырлык йокы китергеч минутлар бар. Жылынып чыгыйм дип кергән чакта, каравылчыбикәнең күз алдында, көймә мичкә арка терәгән килеш, Ансар йокыга изрәгәнен сизми калды. Хәер, йокы дип әйтү артык зурлау һәм чамасыз яңгыравык булыр, бәлки, саташу — уяна алмыйча интегү дип кенә әйтергәдер... Күзен йомганын көтеп тордылар да Мирзин машинасының калай әрҗәсенә бикләп алып киттеләр. Әй баралар болар, әй алып баралар Ансарны... Ниһаять, туктатып агач авылның киртә капкасы янында төшерделәр. Урамдагы кешеләрнең һәммәсе Алпамша кеби икән...

Мирзин Ансарны авыл эченә алып керде дә:

— Менә, иптәш дипломсыз адвокат, без шушы авылда торабыз инде, йортларыбыз «Русский лес» белән буралап, түбәләре «Шипр» белән ябылган. Син безне якларга тиеш!

Әллә төшке аш вакыты җиткән, авылныкылар кайтып киләләр. И Раббым, бу Алпамшаларны туйдырырга да... Нинди әзмәверләр!.. Пилорамнан кайтучыларның балта очына ияргән чумарасы бүрәнә хәтле! Печән өючеләренең сәнәк очына эләгеп кайткан печән өеме кибән чаклы. Ә амбардан икмәк җилләтеп кайтучы ханымнарның билләренә күтәреп бәйләнгән алъяпкыч итәкләре бер капчык бодай сыйдырган. Комбайннан бөртек ташучы машиналар, автоүлчәүдән чыгуга, туп-туры үз өйләренең имән капкасыннан кереп югалалар, имеш. Ансар кайсысының якасына барып ябышырга белмичә тик тора. Кычкыра башлаган иде, «сарыкмахерский»га алып керделәр. Чукмар беләкле, уклау бармаклы тотткаң йон кыркый торган кайчы белән Ансарның чәчен алып атты. Шуннан чәчтән котылган такыр башка бер чүмеч «Тройной» сиптеләр.

— Сипмәгез, кирәкми, мин «Исле гөл»дә бүген туйган хуш истән! Бүрегемне бирегез!.. — дип кычкырган минутында аны каравылчыбикә уятты.

— Тор, йокы чүлмәге, күп яттың. Син бит эшкә килгән кеше!..

Ансар, бәрелеп-сугылып дигәндәй, ишегалдына йөгереп чыкты. Чыкса — мичкәле вагон урынында тора, ә менә Мирзин машинасыннан хуш исле җилләр искән... Нишләргә?! Сактагыларны бастырып, әлеге «Москвич»ны эзләтергәме? Көләрләр... Ярый ла, Мирзин бүген «чумара» алган булса... Әгәр, күңеле сизенеп, буш кул белән чыгып китсә?! Йокы, йокы! Иң арзан ризык!

Ансар ислемайлар тулы сумкасын күтәреп килеп кергәндә, Райнур дежурга чыгар алдыннан соңгы сәгатьләрен йоклап ята иде. Алсу, Ансарга ияреп кергән хуш искә аптырап, иңбашларын җыерып куйды.

— Одеколон эчтең мәллә, бөтенләй якын килерлек түгел?!

— Кондитер фабрикасыннан кайтсам, конфет исе килә, дияр идегез әле... Уянган булсаң, тор, Райнур! — Һәм Ансар сумкадагы байлыкны идәнгә бушатты.

Алсу «аһ!» итеп идәнгә утырды да ислемай шешәләренә үрелде. Юрган астыннан чыккан килеш басып торган Райнурга ишарәләп:

— Менә кеше иртә таңнан мал таба белә. Ә син йоклап ятасың!

— Райнур түгел, мин йоклап калдым әле монда. Кул астыннан шуып чыгып качты, инеш балыгы шикелле.

— Кем качты? Кем йоклаган? Кемнекеләр бу?

— Урланган нәрсәләр болар. Акт төзеп исәбен алыйк та кирәге чыкканчы саклап торыйк. Ә калганы турында юлда аңлатырмын, киен әйдә.

Кояш — кышкы ялкау кояш түгел, иртүк торып офыкның иреннәрен кызылга буяп куйган. Талларның сыек чыбыгына тезелгән тук бөреләр шул якка таба борылдылар. Сагынып кайткан кара каргалар, тимер юл читендәге тупылларга сарылып, иртәнге нәрәткә җыелганнар, үзләре, кайтасыларыбыз кайтып бетте микән дигәндәй, станциягә иренеп килеп кергән һәр поездны күздән кичерәләр.

— Ислемай сипкән кешеләр очрамаса ярар иде, — дип төгәлләде Ансар, төнге маҗаралар турындагы сүзен.

— Бәлки, «Исле гөл»дә каравылчыларны кисәтеп куяргадыр? Мирзинның машинасын тикшергәләсеннәр...

— Каравылчыбикәләргә ышанмаска хакым бар. Атна үтәр, ай үтсә үтәр, әмма ул Мирзинның машинасын үзем эләктерермен.

— Бүгенге шикеллеме?!

## Яратырга вакыт юк

Ансар кайтып кергәндә, Гадигали агай җиз самавырга кушылып җырлап утыра иде. Ул, үзенә генә билгеле эш сәгатен төгәлләп, чәй эчә. Сөембикәсе өстәл артында, йокы аралаш, картның күңелен күрер

өчен, теләсә-теләмәсә дә чәй чөмерә. Самавыр яңа кайнап чыккан, ахрысы, чынаяк тәлинкәсенә бик еш өрәләр.

Ансарны күрү белән Гадигали агай, чынаяк токкан кулын селкетми генә, сыңар куллап яңа чәй агызды. Вак көмеш чыбыктан үрелгән кәрҗиннән бер шакмак шикәр алып бирде. Сөембикә карчык утыргыч шудырды. Бабайның кәефе юк, дип уйлап куйды Ансар, чәйне көлешә-көлешә эчә торганнарые.

— Гадигали агай...

— Әйт шуны.

— Әллә чирләбрәк торасың инде?

— Миңа дигән чирнең исемен белмиләр ди әле.

— Бабакаеңның шүрлеген сүтә башлаганнар, — дип сүзгә кушылды әби кеше, үртәүле кеткелдәү белән. Үзе кеткелди, үзенең кулындагы чынаягында чәй дулкыннары лепердәшә.

— Авызыңны ерма, чәең түгелер, — дип кырт кисте хуҗа кеше, — әллә синеңчә урлау түгелме? Аякка бастырабыз дигән булып иске диварны сүттеләр дә яңа кирпечтән өйделәр. Ә үз кирпече — изге ташлар, чүп-чар өеменә әверелде, чокырга илтеп саласылар, ди. Йөнтәс бүреклеләр шуны авыз ерып карап тора.

— Таш урынына таш ярамаган тагы, — дип каршы дәште карчык.

— Акыллы сүзгә кушылмыйча, «әйе» дип кенә утырсаң, исәрлегеңне күрсәтми калырсың шул.

— Берәү гомер буе кешегә акыл саткан да үзе акылсыз калган, ди...

— Минем турыда түгел бу сүз. Манаралар тирәсендә йөрүемне гел юләрлеккә санадың. Өйдә эшсез ятсам, сугышып бетәр идек без синең белән. Көне-төне самавыр янында утырып... Пенсиягә чыкканыма биш ел — биш ел буе самавыр сыгам, инде буыннарымны мүк баса.

— Әнә акчалы эшкә кер, ичмасам, бушлай йөргәнче...

— Нишлим артык акча белән, бары җиткән! Акча — урлашучыларның эшен җиңеләйтү өчен уйлап табылган зәхмәт ул. Күтәрә алмастай мөлкәтне акчага әйләндереп ташыйлар. Кулдан кулга, кесәдән кесәгә, илдән илгә йөреп никадәр халыкны талап чыга ул акча!

— Акча бер тирәгә җыйнала торган нәрсә ул, күбәеп китсә, кассага салырбыз. Яшьләрчә күкрәк кагып яшәрмен, дисеңме? Картаерсың бер, пенсияңне даруга әйләндерер чак җитәр, әйткәние диярсең.

Яшь дип үстереп әйтүен ошатты әле Гадигали агай, тиз күнде хәләлкәе сүзенә.

— Кем алсын мине эшкә?

— Мин сине «Исле гөл» фабрикасына урнаштырам, Гадигали агай, син анда бик кирәкле кеше.

— Кулыңнан килсә — рәхмәт!

— Мең рәхмәт! — дип тезеп китте Сөембикә карчык. — Ансар, улым, аргансыңдыр, төнге каравылдан кайткач. Әнә ястыкны идәнгә ыргыт та рәхәтләнеп тәгәрә...

— Көпә-көндез урын өстендә аунасам килешерме соң?

— Төнлә генә йокларга дигән закон юк ул, йокы үз вакыты белән килә.

— Дөрес! — дип, җанашкаеның сүзләренә мөһер сукты Гадигали.

— Йокы алдыннан Венераны күрәсе бар, иртәнчәрәк кенә свиданиегә барып килермен, барыбер йокы качты.

Ансар белән Венера кебекләр нишләргә тиеш соң? Кыз беренче сменада чагында, эштән кайтып бизәнеп-ясанып өлгергәнче кичке алты тула. Ләкин алтыда Ансарның каравылга китәсе бар. Ярый, Венераның икенче сменага чыгуын көттек ди. Көндезге өчтән төнге унбергә чаклы эштә ул. Ансар белән кайчан күрешәсе? Төнге унбердән кафе-ресторannар эчтән бикле, паркларда ут юк, урам әйләнер идең — арылган... Димәк, Венераны өченче сменага җибәрдек, төнге унбердән иртәнге җидегә чаклы аяк өстендә ул. Тизрәк кайтып мендәргә капланасың, юкса төнге смена хәзер килеп җитә...

Аңлавыбызча, Ансарның хәле бик үк мактанырлык түгел.

Гашыйкларны иртән-иртүк очрашудан тыйган кеше юк.

Егетләрнең паспорт эчтәлеген журналга теркәп торырга тиешле вахтер апа Ансарны күрмәде дә, ниһаять, төнне исән-имин үткәрү шатлыгыннан, өстәлгә башын куеп, утырган килеш гырылдап йоклап ята.

Ишек шакыдылар. Баштагы мәлне бу тавыш Венерага күрше йорттан ишетелгән кебек тоелды. Аннан күрше бүлмәдән ишетелгәндәй булды. Соңрак гүя караватны селкетәләр иде... Ишекне ачып, эчке күлмәктән килеш, Ансарга килеп бәрелгәч кенә уянып китте кызый.

— Абау!

Ишек яңадан ябылды. Ләкин эчке яктан бикләнергә тиешле йозак кыймылдамады. Шулай итеп, ишекнең ике ягында ике йөрәк калды. Теге якта да, бу якта да тынлык. Мәхәббәттә күп кенә мөнәсәбәтләрне тынлык фаш итә, мизгелләр хәл итә. Әгәр, шушы тынлыкны кичекмәстән җиңеп, бусага аркылы атламасаң, Венераның юрган җылысы сеңгән тәненә язгы пәлтә бөркәләсе иде...

Бүлмә эчендә яз. Форточкадан бүлмәгә җитәрлек кенә язгы җил кереп тора. Өстәлдәге ашъяулыкка кояш бөгәрләнеп яткан. Тәрәзә төбендәге гөлләр чәчәк атарга әзер...

Шәһәр читендәге авылларның кайберләрендә егет белән кызның янәшә йоклау йоласы яшәгән, элегрәк, әлбәттә... Ягъни кавышасы кешенең тән җылысын, уяулыгын, тәрбияви ягын, сабырлыгын һәм шуның кебек аеруча кирәкле сыйфатларын сыныйсың. Мондый элеккеге йоланы бүгенге яшьләрнең кайберләре сынап карый каравын, әмма сынаталар шул...

Вахтер соңгы дүрт-биш сәгать эчендә тулай торактан чыгучы ирләрне күрмәде. Хәер, ул бит әле иртәнге йокы белән булышып, Ансарның килгәнен дә сизми калган иде.

## «Тот, машинаны!»

Көннәр кабатлана, айлар, еллар кабатлана, ләкин бер-берсенә охшап түгел, һәркайсы үзгә... Вакыйгалар да шулай...

Теге көнне «Исле гөл»дә мичкәле вагон саклап Ансар һич көтмәгәндә генә Мирзин машинасының күләгәсенә баскан иде. Инде менә айга якын вакыт узды, ә бу вакыйга һич кабатланырга теләми. Еш кына Ансарны башка объектларга җибәрделәр, бәлки, шул арада Мирзин әллә ничә чиләк ислемай алып чыккандыр. Бервакыт, «Исле гөл»гә килеп, Мирзин машинасын кабат очраткан иде ул, тик теге канистра юк иде. Урланган малын озатып бетермичә, көн саен канистра күтәреп килми, күрәсең... Язит Язилевич Ансарны күрүгә җайлы урын тәкъдим итте.

— Беләм инде, «Исле гөл»дәге кызың янына барасың килә... Ләкин, нишләмәк кирәк, өстәмә каравылчы сорамадылар, буш урын юк, диләр. Түлке борыныңны салындырма, килешми. «Исле гөл» янындагы заводка җибәрәм мин сине, сакчылары ремонтка туктаган — больницага кергән. Капкалары каракаршы гына, ислемайчы кызыңның хәлен белеп чыгарсың.

Язит Язилевич кешенең күзенә карап сөйләргә яратмый, шулай да аның тавышында Ансарга ярдәм итәргә теләү сизелә. Ничек дип аңларга моны? Әшне тизрәк тотарга иде дип, кафедрадан берәр педагог шылтыраткан мы? Язит Язилевич Ансарның нинди студент икәнлеген белә ләбаса! Монда эшкә урнашкан чакта бик җентекләп тикшерәләр: пенсионер гынамы, студент кынамы?! Әгәр бөрек каракларын үзем тотам дигән уен белсәләрме... Юк-бар сәбәпләр табып, Ансарны якын китермәсләр иде. Каравылчы икәнсең — каравылла! Эзәрлекләүнең үз кешеләре бар...

— Хатынны бик авыр сайлыйсың, Ансар энем...

Язит Язилевичның шулай дип озатып калуы Ансарның күңелендәге сорауны сызып ташлады.

Ансар әлеге уйларыннан арынганчы ук, «Исле гөл» каршындагы завод капкасына килеп басты.

Күршең бай булсын. «Мә!» дип күтәреп килмәсә дә, «бир!» дип сорапып кермәс... Бу ике капка арасында әрле-бирле килеп, тегене эшлә, монысын тап, дип йөренүчеләр юк. Ике капка — ике җәмгыятькә, ике бүреккә буйсына: «Исле гөл» — җиңел, ә завод — авыр сәнәгатьнеке. «Исле гөл»нең җитештергәне шулкадәр җиңел, озаграк саклап ятсаң, парга оча башлый. Ә завод чыгарган әйберләрне вакытында алып китмәсәләр, капка төбендә күгәрепләр ятса да, югаласы юк.

Ансарга йокларга ярамый бүген. Ул, бер капкада торып, икенче капканы күзәтә.

Иң авыр эш — эшсез утыру икән...

Бер ноктага текәлеп, сигез сәгать буе тик утырасы бар, ялгызың гына, телевизор карамыйча, китап укымыйча. Ә уяулык кирәк. Эшсезлектән сүрелеп, вазифаларыңны онытып, күңелсезлектән йокымсырасаң да, сизгерлек сакта торырга тиеш.

Каравылчы йортының көл төсендәге бүлмәсендә утырып алҗыгач, Ансар завод ишегалдына чыкты, «Исле гөл» капкасына текәлде. Койма ярыгыннан гел бертөрле генә сурәт күренсә дә, Ансарда таң атканчы мавыгып күзәтерлек көч бар.

Йолдызлы тымызык төн. Чалт аяз күк йөзендә галәм төсе. Йолдызлары җемелдәгән күк капусының чиксезлеге алгысыта. Һәм шунысы кызык, ул чиксезлектә бер карак та, урларлык нәрсә дә юк...

Кешегә чир генә әйләнеп кайта, ә үткән вакыйга кире әйләнеп кайтмас, дисәләр, Ансар ышанмас иде. «Исле гөл» капкасыннан чыккан кеше Мирзин иде. Ике капка арасында машиналар кара-каршы узыша алырлык ара бар, Мирзинның йөзен таныр өчен бер карау да җитә. Ул үзе генә, урамда көтеп торучысы юк, эшлекле кыяфәт белән трамвай тукталышына ашыкты. Ниһаять, менә ул Ансар көткән төн! Мирзинның машинасы «Исле гөл»нең ишегалдында, ул иртүк әйләнеп киләчәк. Бүген Ансарга йоклап калырга ярамый!

Ялгызлыктан интеккән тутый кошның кеше телендә сөйләшергә мәҗбүр булганын белә Ансар. Ләкин ул бүгенге ялгызлыкның шушындый буш, борчулы һәм авыр тынлык белән килүен теләмәгән иде. Венерага шылтыратырга кирәк, икенче сменада ул, эшеннән чыгуга туп-туры монда килсен.

Венера белән чүкердәшеп утыра торгач, эшсезлек икегә бүленде, сәгатьләр икеләтә кызу йөри башлады, ялгызлык уртак, сүзләр парлы, хисләр кайнар... Диплом практикасының әле тагын бер ай чамасы вакыты бар. Венераның да отпуск алырлык җае бар икән. Бактың исә, бер-береңнең авылларына кайтып, туган-тумачаларга мәшәкать чыгарырга шәп мөмкинлек бу. Төне буе сөйләнгән сүзләр күбесенчә әнә шул бер айлык ял тирәсендә бөтерелде.

Завод вакыты белән иртәнге бишләр тирәсендә капкага шакыдылар, җитмәсә, аяк белән дөбердәтә үк башладылар. Ансар, Венераны кая яшерергә белмичә, дүрт квадрат метрлы каравыл йортында арлы-бирле йөренергә тотынды. Бары тик Венераның тыныч, сабыр һәм самими карашы белән күзгә-күз очрашкач кына, ниһаять, кыз алдында үзен-үзе кулга алырлык хәлгә килде.

Ансар капканы ачты, Венера Райнурга шылтыратыр өчен телефонга үрелде.

Бәрелеп-сугылып дигәндәй, буш погонлы бер милиционер килеп керде. Аңа хатын-кыз ияргән иде.

Кеше ышанмаслык хәлләр: милиционер Ансардан сорау ала башлады.

— Менә бу кешене таныйсызмы? — диде ул, ияртеп кергән хатынга күрсәтеп.

— Күргәнем юк, — диде Ансар, исе китмичә генә.

— Ә сез, гражданка, таныйсызмы?

Әлеге хатын милиционерның җиңеннән тартты.

— Әйдә киттек, абый, бу кеше ул кеше түгел.

— Ашыкма, апаем, хәзер ачыкларбыз.

— Мәгънәсезлек күрсәм, җенем котыра, тизрәк аңлатып бирегез, ни булды? — диде Ансар, тәмам сабырсызланып.

— Сөйләп бир!

Күрер күзгә генә олы күренә, болай бөтенләй яшь икән әле милиционерның сеңелкәше. Тавышында балаларча яңгыравык бар. Өстендәге мамык курткасы кабарып, олыгайтып тора. Башындагы куян бүреге, кайчандыр яңгыр астына эләгеп, үз җанвары төсенә кергән.

— Кичәгенәк, төнлә эштән кайтып килгәндә, мин гел шушы урамнан йөрим, бер адәм туктатты. Буйга озын, озын буйлылар озынча яңаклы булалар иде, ә бу адәм түм-түгәрәк йөзле. Кызлар шикелле — түгәрәк йөз, йомры ияк, хәтта үзенә килешми дә кебек... Вәт, ул каршыма килде дә, индийский чәй кирәкме, ике кило, ярты бәясенә, ди. Кирәкмичә соң, сөенә-сөенә алдым, хәтта акчамнан сдача да кайтарып бирде. Миңа кеше өлеше кирәкми, ди. Шулкадәрле дә инсафлы, гадел, беркатлы кешегә охшаганые... Минәйтәм, туры килгәндә шулай саткала миңа, күбрәк тапсаң, ишу да яхшы, авылга күчтәнәч итеп алып кайтырмын, дим. Теге әйтә, теләсәң, ящигы белән табып бирәм, ди. Минәйтәм, кирәкмичә соң, әйдә... Теге әйтә, иртәгә эшеңнән кайтышлый шушында көт, төгәл мең тәңкәлек чәй китерәм, ди... Сөйләшкән вакытка килсәм — чынлап та тора теге. Озак көттердең, ди. Товарны койма эченә яшердек, дуслар саклап тора, давай сумкаң белән акчаңны, ди. Бозау сыярдай сумкага өстәп мең тәңкәмне тоттырдым... Кереп китте бу коймадагы бер тактаны кубарып. Көтәм дә көтәм. Ике сәгать үткәч, кычкырып та карадым... Аннан соң инде менә...

— Милиционер абыегызны алып килдегезме?

— Әйе.

— Аферист, койма тактасын кубарып, сезнең заводка кереп качкан. Ә сез, Субаев, каравылда торасыз, кемгә сылтарга соң тагы? Җитмәсә, сак торасы урында... хатын-кызлар белән кәеф-сафа корып ятасыз.

Венера, бер Ансарга, бер милиционерга карап, ни әйтергә белмичә, телсез калды. Ансарның кәефе кырылды.

— Син, энекәш, кызлар алдында телеңне чамалап ач. Мундирың хакына булса да, башкаларны хөрмәт итә бел.

Дөрес, Ансар әлеге егет белән якалашып маташмас иде анысы, алай да бу минутта Райнурның килеп керүе бик урынлы булды. Райнурга «чыгып тор әле» дип әйтергә милиционер егетнең погоннары такыррак иде.

Хәлне сөйләп күрсәткәч, дүрт квадрат метрлы бүлмәдә тәгәри-тәгәри көлде Райнур:

— Диплом эшемне алданрак бетереп, калган вакытымны ял итәрмен, дигән идең. Күрәсеңме, Ансар, профессияң нинди — бер эше бетсә, икенчесе туарга тора. Коллега, — дип, олылап дәште Райнур милиционерга, — сезнең алдыгызда юрфакның соңгы курсы студенты Субаев! Ул махсус эш белән йөри.

— Алайдыр да, тик менә фактны актлаштырасы иде.

Ансар кул селтәде:

Акты, дисвителни факты:
Мамадыштан кайткан чакта,
Бер шешә аракыбызны
Ат типте дә ватты...

— Яз беркетмәңне, кул куям.

Беркетмә язылган арада, тынлык урнашкан иде.

Кинәт күршедәге «Исле гөл» капкасының тупсалары чыелдаган тавышка Ансар «үрә» катты:

— Райнур, чыгып бара теге машина. Тагын ычкына... — Соңгы «а» авазы әйтелеп беткәнче, Райнур белән теге милиционер егет урамга чыгып басканнар иде инде.

Капка бөтенләй ачылып беткәнне дә көтмичә, кызыл төстәге «Москвич» урам ягына ашыкты.

Каршысында пәйда булган Райнурны күргәч, Мирзин кисәк тормозга баскан булды. Моңа ышанып, Райнур кабина ишегенә таба килә башлады. Ләкин шул минутта машина бөтен булган көченә үкереп алга ыргылды. Ишек тоткасын эләктереп өлгергән Райнур, мәтәлеп дигәндәй, читкә атылды. Алай да өч сүз әйтеп өлгерде:

— Ансар, тот машинаны!

Каушабрак калгандыр инде, теге милиционер егет читтәрәк тора иде, Райнурның Ансарга эндәшүе аңа кискен адым ясарга этәргеч булды. Егет «Москвич»ның капот өстенә сикереп менде һәм менгән килешкә үк алгы тәрәзәгә китереп типте... Күзенә пыяла валчыклары керүдән шүрләптер, Мирзин ике кулы белән йөзен каплады. Милиционер егет, шул форсаттан файдаланып, ачкычны тартып алган иде инде. Машина, тауга каршы атылган тәгәрмәч төсле, озак баралмыйча тукталып калды.

Сүз белән язып аңлаткач, күпкә китте, ләкин чынбарлыкта исә әлеге көрәш йолдыз атылган мизгелгә сыйды да бетте.

Венерадан алда теге кыз йөгереп килде.

— Абыем, алмам, берәр җирең имгәнмәдеме?! — диде ул өзгәләнеп. — Юк, апаем, мондый шалапайлар өчен яраланып торырга. Бәреп-сугып машина куган була бит әле. Урлый белмәгәненә без гаепле диярсең. Һәр карак машина белән милиционер таптата башласа, фуражка кияргә кеше калмас.

Райнур белән Ансар килә килешкә үк кузов ишеген ачып карадылар: канистрадан гайре берни юк. Анысын Мирзинның үзеннән ачтырдылар. Мирзин, гадәтенчә, ике куллап чалбарын күтәреп куйды да капкачны каерды.

— «Тройной» гына икән, — диде егет, канистрадагы сыеклыкны иснәгәч.

— Мондыйларга күбрәк ирек бирсәң, вагонлап урлый башларлар...

— Ирекнең кадерен белә торган кеше түгел бу, — диде Ансар, Райнурның сүзен җөпләп, — әзер продукция цехының икенче ачкычын бир монда...

Мирзин уч төбенә чак сыярлык бер ачкыч сузды.

Закон кушканча, хәзер кичекмәстән Мирзинның өенә тентү ясарга кирәк иде.

Мирзинның күршесеннән ике агайны уятып, пүнәтәйләр исемлегенә теркәгәндә, урамдагы лампалар, көн яктысыннан оялып, рәте-рәте белән сүнә башлаганнар иде инде. Пүнәтәйләр тәмле йокыларын бүлдерүчеләргә офтанмадылар һәм күршеләренә тентү килүгә һич аптырамадылар, киресенчә, пүнәтәй булып керергә әллә кайчан әзер инде без дигәндәй, йокламыйча көтеп ятканнар бугай.

Йокыңнан уятып тентү килеп төшсә, иң пошынмас җаннар да каушар. Мәгәр Мирзинның хатыны такмаклый-такмаклый шашынып елаган икән — бу каушаудан түгел, ә ир өчен үзен гаепле санаудан гына иде:

— Әйттем, ахыры юньле бетмәс, дидем. Тыңламадың! Дус дип йөргән Байгуш кына харап итте сине... Ичмасам, өйдән куып чыгаргач та ташлап китәлмәдең, бу хурлыкны күрәсе кеше түгел идем мин. Әле ярый, сиңа ышанып бала тапмадым...

Бер бүлмәле булса да, фатир биш стеналы иде: дүртесе бетон белән тышланып, эчтән чәчәкле кәгазь ябыштырылган. Ә бишенче стена «германский» дип телгә кергән көзгеле-көзгесез, ябылулы-ишексез, шифоньер, сервант, антресоль һәм сандыклардан өелгән чит ил җиһазы. «Кызганыч, — дип уйлап куйды Райнур, ә бит бу затлы җиһазны конфискацияләргә мөмкиннәр. Кем белә, бәлки әле хәләл акчага алынгандыр...» Бу «германский»ның тартмалары шулкадәр күп, хәтта аңа өйдәге әйберләр генә түгел, читтән кергәннәре дә сыйган. Берсеннән өчәр литрлап тутырылган ике банка хушбуй чыкты. Райнур аларны пүнәтәйләргә иснәтеп карады.

— Боларын сатып өлгермәгән, тагын канистра күтәреп чыккансың?

— Күптәннән кирәк-яракка дип тотам, иптәш сержант. — Мирзин күршеләренә туры карамаска тырышты.

— Әллә кырынгач башыңнан коясыңмы шулхәтле?!

Ансарның бу сөйләшүләргә исе китмәде. Ул башка нәрсә эзли — башка нәрсә! Мирзинның хушбуй урлавы исбатланган инде. Ләкин аның «Каракүл» берләшмәсе белән элемтәсен исбатлар дәлилләр юк әле.

Тартмаларны капшый-кармалый торгач, зур целлофан капчыкка кулы тиюгә, Ансар, күбәләк тоткан сабый төсле, чак кычкырып җибәрмәде. Әлеге минутларның кем өчендер бик зур хәсрәт икәнен белгәнгә күрә генә тыелып калды ул. Үтә күренмәле капчыктагы бүрекләр, без бик күп дигәндәй, күзгә төртелеп торалар иде.

— Бүрекләр чөйдә торырга тиеш, Мирзин! — диде Ансар, тавышын көчкә тыеп.

— Сезон бетте бит инде, көя төшмәсен дип төреп куйдым.

— Мирзин, — диде Ансар, бишек янында әкият сөйләгән әтиләрдәй әкрен генә, — каян алдың боларны?

— Иптәш малай китерде, кирәк кеше табылса, сатарсың, диде.

— Кем ул?

— Сез белмисез аны.

— Белербез.

— Мин дусларны исемләп сатмыйм.

— Сатмый, имеш, — диде Райнур үртәлеп, — аның ише дусларны сату гына аз, аяк-кулларын бәйләп тапшырырга кирәк.

— Байгуш ул, Байгушов! — дип төзәтте Мирзинның хатыны.

— Беләбез, үз авызыннан әйттерәсе килгән иде. — Ансарның тавышында җиңүчеләргә хас көрлек сизелә...

Мирзиннар өендәге соңгы сөйләшү аның хатыны белән Ансар арасында булды.

— Минекенең эше зурга китәме инде?

— Җинаятьнең зурысы, кечкенәсе юк. Законны бозган кешегә җәза тиеш.

— Аңа карап илдә урлашу бетәр дисезме?

— Бераз тынып торырлар әле... Әгәр инде законның барлыгын шулай сиздереп тормасак, җәмгыятьне ике көндә өйләренә ташып бетерә болар...

## Бетте дигәндә генә...

Сөембикә карчык сумкага ризык тутыра — Гадигалиен төнге каравылга әзерли.

— Ак бүрегеңне ки. Синең өчен яз җитмәгән әле.

— Карчык, дим, мавыкма шулхәтле ашау әзерләп, әрмиягә китмим ич!

— Алай димә, карт, яңа урында беренче көнең айдан да озаграк тоелыр әле. Эчең пошкан саен тамак ялгарсың. Бәлки, тәмле ризыкларымнан күңелең йомшарып, «Исле гөл»дән ярты гына шешә исләмәй алып кайтырсың, артык кыйммәтлесен, димим, ярый миңа нинди дә...

— Чынлап мәллә?

— Ихластыр.

— Ансар, Ансар, чык әле...

— Нәрсә бар? — дип, күрше бүлмәдән Ансар йөгереп чыкты.

— Сөембикә түткәңә штраф сал, мине дәүләт милкен урларга котырта.

— Ярар, ярар, бүләк сораган өчен бинаватт такма...

— Бүләк дисәң, беренче получкадан, миннән калмас.

— Гадигали абый, мине көт, трамвайга хәтле бергә барабыз.

— Әллә Венера көтәме?

— Көтә. Эштән соң автовокзалга киләә.

Ансар кулына юл сумкасы тотып чыгып басты.

— Венераны бозлы фонтан янында атналап көтәргә җыенмыйсыңдыр, сумкаң бик дәү күренә.

— Авылга кайтабыз, икәүләшеп. Безнең якка. Таныша торсын, минем эти-әни дә бар бит әле...

— Бардыр шул, эти-әниең булмаса, юрфакларга укырга керә алмасыең... Ярый алайса, хәерле юл, — дип теләк теләүдән гайре эш калмады Сөембикә карчыкка.

Апрель киче. Кояш гөрләвекләргә алтын буяу булып кушылган. Диңгез буеннан кайткан түрәләр сыман, ботак саен сыерчыклар кәпрәеп утыра. Урамда хуш ис — ислемай шешәләренә сыймаслык тупыл бөреләре исе. Урам себерүчеләр, кыштан тизрәк котылырга теләгәндәй, ашыгып-ашыгып кар чәчә. Һәм ярмалы кар, гөрләвектә эреп, киң Иделгә ашкына.

Шәһәр үсеп, яңа аэропорт салынгач, искесен якын-тирә авылларга йөрүче автобуслар өчен зур туктальш иттеләр. Якташларыңны, сабакташларыңны бик сагынсаң, шушында гына кил.

Ансар ике айдан бирле авылга кайта алмады. Венера белән икесен бергә күргәч, туган якларда күптәннән югалып торуын өйләнү мәшәкатенә юрарлар, борчуларың бар идеме, төнге эшкә урнашкан идеңмени, дип төпченеп тормаслар.

Җомга көн кичкә, гадәттәгечә, кайтырга теләүче кунаклар хәтсез күбәя. Венераны көткән арада, Ансар инде, чират кичеп, ике билет алып өлгерде. Ярты бәягә рөхсәт итә торган таныклыгын күрсәтергә хурланды егет. Беренчедән, күргән-белгәннәр алдында вакланып торасы килмәде, аннан соң шушы ике ай эчендә отыры олыгаеп, инде студент итеп түгел, ә яшь белгеч итеп тойды ул үзен. Касса төбендәге этеш-төртешне уенга санап, Ансарның һәр фигылен энә күзеннән үткәргәндәй күзәтеп торучы авыл кызлары да сизә иде моны... Ансар ботинка үкчәсенә тиеп торырдай озын кара пәлтә кигән. Муенында юка ак шарф. Башында чәшке мехыннан тегелгән купшы бүрек. Сдачага тигән кәгазь акчаларны, санап та тормыйча, тышкы кесәсенә бөгәрләп салды. Атлаганда, авыр сумкасын читкә тотып, пәлтә чабуына тидермәскә тырыша. Үзе әле сәгатькә карый, әле шәһәр ягыннан килгән троллейбусларны күздән кичерә.

Автобус кузгалырга ун минутлап кына калган иде инде. Венера, килә килешкә үк, Ансарны култыклап читкә алып китте. «Кайта алмый микән? Ник, алайса, юл сумкасын дөмбәсләп тутырып чыккан?» — дип уйлап өлгерде Ансар.

— Соңга кала яздың бит, Венера!

— Мин синең фатирыңа сугылдым.
— Ник?! Шушында очрашабыз дип сөйләштек ләбаса...
— Сөембикә әбине күреп сөйләшкәч кенә, эчемә җылы керде. — Һәм Венера кесәсеннән чәчәкле ак кулъяулыгын алып өлгермәде, керфекләре арасыннан күз яше саркып чыкты.
— Сине елатырлык нәрсә булды соң, Венера?! Тукта, зинһар, кешеләр әллә нәрсә уйлар...
— Кешедә минем эшем юк, үз хәлем хәл. Бүген теге Байгушовны күрдем. Берни булмагандай складта эшләп йөри. Смена беткәнче башларыма уй капты, тизрәк синең хәлне беләсем килде.
— Менә бит инде мин, Венера, яныңда исән-сау килеш басып торам. Борчылырлык сәбәп күрмим.
— Минем күз алдымда кулларына богау салып озаттыгыз ич сез аларны. Ә бүген ул иректә йөри. Йөри генәме, шул ук бүрекләр складында эшләп йөри!.. Байгушовны яба алмагач, син гаепле булып каласың түгелме?..
— Алай түгел ул, Венера. Байгушов белән Мирзинның гаебе расланды.
— Ник иректә соң алар?!
— Венера! — Ансар, дәресен өйрәнмичә килгән мәктәп баласы шикелле, күз карашларын төбәрдәй нокта эзләп, аяк очына текәлде. — Байгушовны яклап Ханкаланың бер йөнтәс бүреклесе шылтыраткан. Берләшмәгез мактап характеристика җибәргән.
— Байгушовның хатыны, ике баласын җитәкләп, безнең ашханәдә имза җыеп йөрде. Әтиләренең эше зурга китсә, бу хәерче ятимнәрне ничек үстерермен, дип үкереп елый.
— Имза куйдыңмы соң?
— Кызганыч шул. Бөтен цех яклап күтәрелгәндә, мин генә читтә калмам. Бер имза каян килеп кая китмәгән.
— Менә күрдеңме? Хөкем карарын үзегез чыгарып та куйгансыз инде. Байгушовка күп дигәндә өч ел бирерләр, анысы да шартлы рәвештә генә. Син эштә яклаган, мин аны судта якларммын...
— Син?!
— Мин түгел, минем кебек башка берәү... Барыбер шул ук мәрәкә инде ул.
— Урлый. Тотыла. Хөкем итәлә. Котыла. Тагын урлый...
— Һәм бүтән тоттырмый... Ә син беләсеңме, Венера, караклыкка каршы бер генә чара бар.
— Нинди чара?..
— Урлатма!..
Ун минутка сузылган әлеге кискен сөйләшүне читтән күзәтеп торучы авылдашлар: «Болар әрләшteләр!» — дип, ялгыш нәтиҗә ясамасын өчен, Ансар белән Венерага юл буе елмаешып кайтырга туры килде...

*1985–2002*

**Эчтәлек**

Сакау күке *(роман)*
Ак бүрек *(повесть)*

Литературно-художественное издание

**Каримов** Камил Адгамович

**Картавая кукушка**

Роман, повесть
(на татарском языке)

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *Г.З.Хисмәтуллина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, Л.Ш.Шәфыйкова, Г.Х.Сундукова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 19.01.2005. Форматы 84x108$^{1}/_{32}$.

Офсет кәгазе. «Times» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 15,96 + фор. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 16,70.
Нәшер-хисап табагы 18,17 + фор. 0,36. Тиражы 3000 д. Заказ Э-972.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.